Илдар Низамов

НӘФИС СҮЗ ОСТАЛЫГЫ

Риторикадан уку-укыту кулланмасы

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ
2013

Ильдар Низамов

ИСКУССТВО СЛОВА

Учебное пособие по риторике

КАЗАНСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ
2013

УДК 80(075.8)
ББК 83.7я73
Н 61

Казан (Идел буе) федераль университетының
Иҗтимагый фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты
гыйльми советы рекомендациясе белән басыла

Рецензент –
филолгия фәннәре докторы, профессор **И.Б. Бәширова**

Низамов И.М.
Н 61 **Нәфис сүз осталыгы:** риторикадан уку-укыту кулланмасы / И.М. Низамов. – Казан: Казан ун-ты, 2013. – 280 бит.

ISBN 978-5-00019-145-3

Бу фәнни-публицистик язмалар мәҗмугасы югары уку йортлары студентлары өчен “Риторика” фәненнән дәреслеккә уку-укыту кулланмасы сыйфатында тәкъдим ителә. Анда татар милли нәфис сүз сәнгатендә тирән эз калдырган, риторика фәненә дә саллы нигез салуга өлеш керткән күренекле әдипләребез Мифтахетдин Акмулла, Галимҗан Ибраһимов, Афзал Шамов, Ибраһим Сәләхев, Сибгат Хәким, Хәсән Сарьян, Туфан Миңнуллин, Әнгам Атнабаев, Эдуард Касыймов, Шамил Анак, Рахмай Хисмәтулла, Хәкимҗан Халиков һәм башкаларның осталык сабакларын бәян иткән язмалар тупланган. Аларның әсәрләреннән китерелгән үрнәк-өлгеләр программаны үзләштергәндә хрестоматия материалы буларак да хезмәт итә ала.

Кулланма студентларга да, өлкән сыйныф укучыларына, ана теле сөйләм үзенчәлекләрен өйрәнергә теләгән һәр укучыга да адреслана.

Учебное пособие представляет собой сборник научно-публицистических статьей, расскрывающих мастерство красноречия выдающихся татарских поэтов, прозаиков, публицистов – классиков риторики.

Пособие адресовано студентам, аспирантам гуманитарных отделений вузов, а также ученикам старших классов и читателям, интересующимся тонкостями употребления татарского художественного слова.

УДК 80(075.8)
ББК 83.7я73

ISBN 978-5-00019-145-3

© Низамов И.М., 2013;
© Казан университеты, 2013

КЕРЕШ

Югары уку йортлары өчен беренче татарча “Риторика” дәреслегенең (Казан, 2005) йомгак сүзе болайрак тәмамлана: “Программага күз салсагыз, искәрми калмассыз: анда “Ораторлык (нәфис сүз) осталыгы дәресләре” дигән махсус бүлек бар. Димәк, бу дәреслегебезнең дәвамы шушы максатка багышланырга тиеш була. Анда нәфис сүз осталыгы дәресләре аерым нәфис сүз осталарының: язучы, журналистларның, артист, эстрадачыларның, укытучы-мөгаллимнәрнең, галим, дин әһелләренең, җәмәгать эшлеклеләренең – риторика сәнгате кыйбласында туплаган тәҗрибәсен фәнни нигездә җентекле анализлау юнәлешендә барланыр, тиз һәм җиңел үзләштерелә торган күнегүләр ярдәмендә өйрәтелер, дип өметләнәбез”.

Әйе, бу җыентык менә шул өметне гамәлгә ашыру ниятеннән әзерләнде. Аны җентекле үзләштерә башлар алдыннан, әлбәттә инде, дәреслекнең үзен кабат укып чыгу зарурдыр. Шулай да бу кереш сүздә үк риторика, нәфис сүз осталыгы төшенчәләренең асылын искә төшереп китү мәслихәт.

“Риторика” сүзе-төшенчәсе үткән гасырның сиксәненче елларыннан фәнни даирәдә, югары уку йортларында гына түгел, көндәлек сөйләмдә, гадәти мәктәпләрдә дә ешрак ишетелә башлады. Хәер, бу сүз-төшенчәдән безнең халык моңарчы да бихәбәр түгел иде – өлкән буын кешеләребез аны иҗтимагый тормышта ораторлык, нәфис сүз, сәхнә-артистлык эшчәнлегенә бәйләп, шигърият, публицистика, сәнгать темаларына гәп корганда кулланганлый иде; кайбер фәннәрдән термин буларак та истә калган (әйтик, тел, әдәбият фәннәрендә: “риторик сорау”, “риторик җөмлә”, “риторик фигура” һ.б.).

Җыебрак барлаганда, риторика төшенчәсе безнең аңда һәм кулланышта бүген өч төп мәгънәдә яши: сүз сәнгатенең бер төре (асылы матур сөйләм, нәфис сүз осталыгы, сәнгатьчә сөйләү, ораторлык, вәгазь-хөтбә-хатыйблык һ.б. төшенчәләрендә дә чагыла); шул сәнгатьне өйрәнүче фән; шул фәнне мәктәптә һәм башка уку йортларында өйрәтә торган предмет.

Сәнгатькә карата кыска гына билгеләмәсе болайдыр: риторика ул – фикереңне кемгәдер ышандыру (инандыру) өчен ана теленең иң үтемле, тәэсирле (нәфис) чаралары белән, телдән башка чаралар (тавыш-өн-интонация, ым-ишарә-хәрәкәт һ.б.) белән җиткерә белү осталыгы.

Бу билгеләмәдән әһәмиятле ике нәтиҗәгә килергә мөмкин: беренчесе – мондый сәнгатьнең һәм аны тикшерә торган фәннең бүгенге кирәклеге бәхәссез. Ул мөстәкыйль фикерләргә, актив аралашырга, шушы максатларда ана теленнән һәм башка чаралардан оста файдаланырга өйрәтә. Татарга бүген нәкъ шул кирәк тә.

Икенчесе – менә шушы ихтыяҗны канәгатьләндерер өчен татарның нигезе дә бар, татар риторикасы сәнгатенең дә меңнәрчә еллык хәзинә-тәҗрибәсе тупланган. Ул үз җирлегендә, шул ук вакытта Көнчыгыш һәм Көнбатыш риторикаларының да йогынтысын тоеп үскән. Татарның кешене нәфис сүз белән үзенә җәлеп итү, ышандыру (инандыру), рухи хәләт[1] тудыру осталыгы халык авыз иҗатында, гореф-гадәт, йолаларында (туй, җыен, сабан туе, өмә, бәйрәмнәрендә һ.б.) мәҗүсилек, шаманлык чорларында ук, аннары чичәнлек дәверендә, бераз соңрак исә ислам дине кабул ителгәч, шуңа бәйле йола-ритуалларны, тәртип-кагыйдәләрне (вәгазь, хөтбә сөйләү һ.б.), гомумән, татарның бөтен яшәеше борынча бөртекләп тупланган.

Тулаем алганда да, фикереңне, ният-теләгеңне ышандыргыч, үтемле-хисле итеп белдерү, бәян итү осталыгы кешене һәрчак кызыксындырган. Илбаш-ханнарның, талантлы чичәннәрнең, мулла-хатыйпларның, шагыйрь, артистларның, җитәкчеләрнең сөйләү осталыгын халык һәрвакыт хуплаган, үзе дә җор телле, тәмле телле булырга омтылган, андыйлар абруйлы саналган.

Кызык бер хәл: янәшәбездән аерылгысыз бер күренеш булуына карамастан, сәнгать буларак та, фән буларак та *риторика* сүзе көндәлек сөйләмебездә кулланылмый диярлек. Эш шунда ки, аны башка сүзләр, аерым алганда, *тел, сүз, сөйләм* сүзләре алыштыра. Мәсәлән, *теле телгә йокмый, тел юата да, елата да, бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы, мие сыекның сүзе сыек* һ.б. Бу очракларда төп мәгънә риторика бит!

Кызганыч ки, чын риторика совет хакимияте елларында берьяклы хәрәкәттә булды – башлыча партия, хөкүмәт идея-ихтыярын массаларга көчләп җиткерү (ул ораторлык дип атала иде) рәвешендә булды. Асылы үз фикереңне оппонентларың белән иҗтимагый диспут, дискуссияләрдә бәхәсләшеп ышандыру, үткәзү юлыннан түгел, ә бәлки инде мәгълүм – классиклар яисә рәсми түрәләр әйткән (язган), тайпылышсыз дип кабул ителгән – директиваны, догма-постулатны тәкърарлаудан гыйбарәт иде.

---

[1] Текстта автор орфографиясе сакланды.

Ә чын нәфис сүз сәнгатенә ихтыяҗ, әлбәттә, сакланган, халык акыллы киңәшкә, ихлас аралашуга, үтемле, тәэсирле сүзгә, сәнгатьчә сөйләү осталарына мохтаҗ булган. Үзебезчә моң-җырның, театр-эстрада, рәсем сәнгатенең, матбугатның, радио, телевидениенең бөтенләй дә сүнмәве, халыкның шуларга тартылуы, күңелендә саклавы, ана телен онытмыйча, аңа сусап яшәве шуны раслыйдыр.

Тик халыкның милли сүзгә ихтыяҗын канәгатьләндерү аның табигый теләгенә, иркенә генә бәйле түгел шул, дөнья цивилизациясендә риториканың озак дәверләр буе авызы томаланган, зиһене тоныкландырылган чакларны да беләбез. Мәмләкәтләр арасындамы, әллә бер ил эчендәме сугыш-талаш барганда яисә диспотлык, тоталитаризм, империя-державачылык хөкем сөргәндә, фикер хөрлеге, сүз, вөҗдан иреге буылганда, милли изү хакимлек иткәндә чын риторика турында хыялланырга гына кала. Милли, дәүләти мөстәкыйльлек шартларында, чын хөррият мөхитендә генә ана теле кешенең үз фикерен ачык, үтемле, хисси итеп җиткерү өчен хезмәт итә ала, үз сәләти мөмкинлекләрен тулысынча ача ала. Адәм баласы шул сәләтне тәмам ачу, аны эшкә җигү өчен эзләнә, уйлана, иҗат итә башлый.

XX гасыр азакларында бездә дә риторикага тернәкләнеп китәргә шартлар төсмерләнде. Иң әүвәле риториканың нигезе – татар теле дә – дәүләт теле дип рәсми игълан ителде, димәк, хәзер ана телебезнең хокуклары да артырга, аны кулланырга тиешле өлкә, даирәләр дә моңарчы булмаганча ишәергә тиеш була. Риторика сәнгатенә шул кирәк тә. Аңа хәзер сәхнәдә, матбугатта, аеруча радио, телевидениедә җәмәгать җыен, митингларында киңрәк колач алу гына түгел, парламент утырышларында, төрле рәсми оешмаларның корылтай, съездларында вә моңарчы урыс теле генә хакимлек иткән башка өлкәләргә дә үтеп керү мөмкинлеге ачыла.

Тик нигә соң татар җәмәгатьчелеге, беренче нәүбәттә мәгариф хезмәткәрләре, шушы яктылык нурына шундук ябышып китмәде; әле дә башлыча битараф кала бирә. Һич югы урыс җәмәгатьчелегеннән үрнәк алып, ияреңгә кирәк иде. Аларда бүген махсусый, профильле уку йортларында гына түгел, гадәти урта мәктәпләрнең күпчелегендә риторика фән буларак укытыла; риторика җанланып киткән елларда бала бакчаларыннан алып югары уку йортларынача йөзләп исемдә дәреслек, кулланмалар бастырып чыгарылды.

Әмма татар мәктәпләрендә, гәрчә алар да шул ук мәгариф системасында булса да, мондый җанлану бик сизелми; баштагы дулкын-

да кертелгән дәрес, курсларның күпчелеге ябылды; моңарчы татарча программа, дәреслек, кулланмалар да күренмәде.

"Моңарчы" дигәнгә ике өстәмә бирү кирәктер. Беренчесе: Октябрь инкыйлабына кадәр күпчелек мәдрәсәдә риторика (башлыча, хөтбә сөйләргә өйрәтү юнәлешендә) укытыла. Бу максатта нигездә ахун Җиһангир Абызгилдин язган дәреслекләр кулланылган. Аларны кабат чыгару турында тәкъдимнәр әйтелүгә карамастан, шуңа җөрьәт иткән оешма, шәхесләр генә табылмый.

Икенчесе: шулай да якты чаткылар да булмый калмаган икән – 2003 елда "Мәгариф" нәшриятендә дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең 1нче, 2нче, 3нче сыйныфлары өчен (галимә Мәрьям Хәсәнева, Балтач районы мәктәп укытучылары Гөлсинә Сафиуллина, Миләүшә Гарифуллина, Әминә Мөхәммәтҗанова) дәреслекләр басылып чыкты. Ә аңарчы шул ук нәшрияттә К.М. Зарипованың "Балалар риторикасы" дигән һәм Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы 1–2 сыйныфлар өчен сынап карау максатында тәкъдим иткән дәреслек-кулланма бастырып чыгарылган иде.

Кызганыч ки, бу әһәмиятле башлангыч җәмәгатьчелектә, беренче чиратта укытучылар даирәсендә, әлләни җанлану кузгатмады, министрлык та, нәшрият тә "беренче карлыгачны" сынауга битараф калды. Бәлки моңа дәреслекләр үзләре дә гаепледер. Дөресен әйткәндә, нәкъ менә риторика фәне өчен яңалык буларак алар үрнәк булырлык, зур кызыксыну уятырлык булмагандыр, күрәсең. Үз вакытында без дә аларның татар теле фәне дәреслекләреннән әлләни аерылмавын, үкенечкә санап, кисәтергә мәҗбүр булган идек.

Чыннан да, җәмгыятебездә әле бүген дә риториканың асылын, аның алдында торган бүгенге бурычларын ап-ачык итеп күзаллау җитми. Мәгариф җитәкчелеге, укытучылар үзләре дә риторика фәнен укытуда тоткарлыкны "риторика бурычлары әдәбиятне, телне укытканда хәл ителә, риторикага алар исәбеннән сәгатьләр бирү файдалы булмас..." дип аңлаталар. Мондый фикерләүдә ике зур хата ята. Беренчедән, кем әйтте әле, риторикага сәгатьләр тел-әдәбият исәбеннән тиеш, дип; белешегез әле, риторика укытылган мәктәпләрдә урыс теле сәгатьләре киметелдеме икән? Риторика ул фәлсәфә, психология, мантыйк кебек үк мөстәкыйль фән, аның үзенә сәгатьләр бирелергә тиеш. Шуны аңламаудан икенче хата – риториканы тел, әдәбият фәннәре белән, аеруча аларның "сөйләм культурасы", "сәнгатьле уку" кебек тармаклары белән тәңгәлләштерү килеп

чыга. Чынлыкта алар берничек тә риториканы алыштыра алмый. Монда, кем әйтмешли, пәри башка, җен башка.

Әлбәттә, “Татар риторикасы” татар телендә генә була ала, шуңа күрә ул татар теле фәне белән берникадәр керешә дә, әмма, әйтик, тарих фәнен яисә географияне татарча укытудан алар татар теле фәненә әйләнмәгән кебек, шуңа карап кына риторикага татар теле сәгатьләрен “тартып алу” мәгънәсезлектер, ләбаса.

Риториканы сәнгатьле уку белән бутау бигрәк тә еш очрый, хәлбүки риторика ул ышандырырга (инандырырга) теләгән фикереңне ана теленең нәфис чаралары ярдәмендә үзең уйлап чыгарып, уйлаганда ук адресатка (аудиториягә) ничек тәэсир итәсен күз уңында тотып, күңелеңнән кичереп, димәк, мантыйкый-психологик, сәнгати чараларның (телдән башка чараларны да кертеп) барысын да үзең нечкә белеп, үз җаваплылыгыңа алып җиткерү, ә сәнгатьле уку – ул бүтән кеше уйлап әзерләгән текстны укып (сөйләп) җиткерү. Ни кызганыч, мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслек, кулланмаларыбызда әлегә риториканың төп бурычы – уйларга өйрәтү, шул уй-фикереңне ышандыру (инандыру) максатында бәян иткәндә, тасвирлаганда ана теленең иң тәэсирле нәфис чараларыннан, фикер белдерүнең телдән башка (экстра-, паралингвистик) чараларын да оста кулланырга өйрәтелмәгән әле, шушы фәнгә генә хас, катгый эзлекле методик система булдырылып бетмәгән. Димәк ки, нәфис сүз осталыгы төшенчәсенең һәм нәзәри нигезләрен, һәм гамәли күнекмәләрен ачык күзаллау өчен эшлисе дә эшлисе әле. Кайбер факторларга гына аерып тукталыйк.

Риторика уйлау барышын гына түгел, фикерне ышандырырлык итеп җиткерү чараларының барысын да төгәл күзалларга өйрәтергә тиеш, дидек. Бүгенге мәктәп бит беренче сыйныфтан алып унберенчегәчә татар телен язма чыганакларга гына таянып өйрәтә, ә фикерне ышандырырлык итеп җиткерү өчен оратор гына түгел, көндәлек сөйләм оештыруда һәркайсыбыз телнең мәгънәви берәмлекләреннән тыш күпме өстәмә чаралар җәлеп итә. Алары мәктәптә өйрәнелми диярлек. Бу кимчелекне бетерергә нәкъ менә риторика булыша алыр иде.

Аңлашыла ки, бүген татар риторикасы фәненә юлны галимнәр дә, укытучылар да, методистлар, сәхнә осталары да салырга тиеш. Дәреслек, кулланмалар язар өчен аларга татар теле, әдәбиятен укыту өчен тупланган белем, тәҗрибә, мәгълүмәт-материаллар гына җитми, һәрхәлдә “сәнгатьле уку” дәреслек-кулланмаларына күнеккән

биләмәләр белән генә чикләнү мөмкин түгел. Иң мөһиме: бүген укыту өчен гаилә тәрбиясе – бала бакчасы – мәктәп – махсус уку йорты – югары уку йорты баскычларын эзлекле, бердәйлекле колачлаган программа һәм дәреслек, кулланма-әсбаплар булдыру зарур.

Тик осталыкка өйрәнүнең мондый фәнни нигезләнгән чылбыры турында әлегә хыялланабыз гына. Шулай да, шөкер, бу юнәлештә соңгы егерме елда берникадәр җанлану булып алу, кайбер уңай нәтиҗәләр алга таба да өметләнергә нигез була аладыр. Мәсәлән, Казан (Идел буе) федераль университетында унбиш ел инде булачак журналистларга татарча "Гомуми риторика нигезләре", "Журналистика һәм риторика" курслары укытыла. Махсус программалар, югары уку йортлары өчен дәреслек язылды. Башка кайбер уку йортларында да татар риторикасы тулаем яисә аның кайбер өлеш-бүлекләре ("Сөйләм культурасы", "Сәхнә сөйләме" һ.б.) укытыла. Бу – заман таләбе. Риторика сәнгате осталыгы бүген һәр һөнәр иясенә, һәр белгечкә мотлак кирәк.

Шул ук вакытта югары уку йортында яисә махсус уку йортларында яңалыкны күтәреп алучылар алдында уртак бер киртә тора – татар мәктәпләрендә бүген риторика укытылмау сәбәпле, алар төп вакытны риториканың беренчел нигезләрен өйрәтүгә сарыф итәргә мәҗбүр. Риторикадан азмы-күпме мәгълүматлы абитуриент килгәндә югары уку йорты үз белгечлекләренә (укытучы, инженер, табиб, юрист, артист, җитәкче, журналист һ.б.) караган хосусый (махсусый) риториканы үзләштерүгә күбрәк вакыт бирә алыр иде.

Йомгаклабрак әйткәндә, бүген риториканы мәктәптә, бүтән уку йортларында укытуны да, үзара бәйләнешле система булдыруны да, программа, дәреслек-уку әсбаплары бастыруны да бездә читтән килеп җайга салмаслар, җиң сызганып үзебезгә җигелергә генә кала. Бу юнәлештә бөртек кенә яңалык, мөмкинлекләрне дә күтәреп алырга, тамчы гына тәҗрибәне дә өйрәнергә, таратырга кирәк. Бүген – татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү бурычы әле эленке-салынкы гына үтәлгән бер вакытта – бу юнәлештә зур вазыйфа башкара алырдай риторика сәнгатен һәм фәнен гамәлгә кертү киң колачлы, дәүләткүләм эш саналырга тиештер. Аны бәлки бер үзәккә туплап, барыбыз бер йодрыкка укмашып башкарырга вакыт җиткәндер.

Бу юнәлештә аеруча әһәмиятле кыйбла – нәфис сүз осталыгын үзләштерү бурычын хәл итү кыйбласын – кичектермичә үзләштерү максатын күздә тотып әзерләгән бу җыентык гомуми максатка ярашлы булыр, дип өметләнәбез.

БУБЫЙЛАР САЛГАН НИГЕЗДӘ

1906 елның 21 марты – имам-хатыйп һәм мөгаллим Габдулла Бубыйның хәтеренә бик тирәнтен уелып калган көн. Җомга. Иж-Бубый мәчетенең эче-тышы халыктан шыгрым тулы. Авыл халкы, шәкертләр бер ел буе озак сәфәрдә, хаҗда булып кайтып төшкән имамнарын бик сагынган. Габдулланың да йөзе нурлы, карашы очкынлы. Менә ул шактый дулкынлы, ягымлы тавышы белән җомга хөтбәсен башлап җибәрде. Башта, мәхәллә каршында хисап тоткандай, Бәйрутта, Димәшкъ, Мисыр вә Хиҗазда булуын, хаҗ кылу тәэсирләрен бәян итте. Аннары үзе югында, узган җәйдә авылның, шул исәптән мәктәп-мәдрәсәнең дә, янып бетә язуына бик борчылуын белдереп, авылдашларының кайгы-хәсрәтен уртаклашты; ярый әле халык, мөгаллим, шәкертләр бик югалып-бетерешеп калмаган, яңа мәктәп-мәдрәсә дә салынып ята – шуңа сөенүен белдереп, күп рәхмәт әйтте.

Кешеләр, үзләрендә сәер бер күңел тибрәнүен тоеп, күбесе моның сәбәбенә төшенә дә башлады: бәй, бу юлы мулла саф татарча, нәкъ менә үзебезчә, гап-гади итеп сөйли ләбаса. Элек гел, башка муллалар кебек үк, гарәпчә, динчә сөйли иде. Ә нинди тәмле, рәхәт, күңелгә якын, бернинди төерсез!

Башкалар да моны сизәме, дигән кебек бер-берсенә карашып та куйдылар. Бу җанлануны күреп алган хәзрәт, шуны гына көткән кебек, әңгәмә агышын шул якка борып җибәрде: әйе, әйе, бүген ул җомга вәгазь-хөтбәсен аларга нәкъ менә ана телебездә сөйләп җиткерергә булды. Монда бернинди ялгыш, каршылык та, гөнаһ та юк – Аллаһыбыз бихисап милләт, төрледән-төрле телләр биргән икән, димәк, ул үзенең ихтыярын, әйтергә теләгәнен һәр халык, һәр гавам үз телендә төшенү мөмкинлеген дә биргән. Боларны ул илһамый бер кайнар дулкын белән, нык ышаныч белән әйтте: күп уйланып йөргәнлеге, тәмам инанганлыгы күренеп тора иде. Шуннан бу яңалыгының нәкъ менә халыкның үзенә кирәклеген, Аллаһының ихтыярын, шәригать канун-кагыйдәләрен төплерәк, ихласыйрак үзләштерү, дөнья хәлләреннән дә ачыграк хәбәрдәр булып тору өчен мәслихәт икәнен ышандырырлык дәлил, тасвирлар тезә башлады.

Халык колагын торгызды, бераз сагайды да – ишетелгән хәлмени! Моңарчы бер генә мулланың да җомга вәгазен, хөтбәне татарча сөйләгәне булмаган!

Сагайса сагайдылар, сәерсенсә сәерсенделәр, әмма ризасызлык белдерүче, каршы дәшүче булмады. Хуплау сүзләре генә әйтелде;

башка муллалар да иярсен иде, үзебезчә аңлаешлырак инде, Ходайга тагын да якынайган кебегрәк булдык, дигәнрәк сүзләр.

Чөнки мәхәлләдәшләр ерак илләрдә, хаҗда булып, олуг галимнәр белән төрле телләрдә аралашып, дини белемнәрен дә эстәп кайткач, Габдулланың әйтер сүзе төплерәк, колачлырак, ышанычлырак була баруын тойды, әлбәттә. Үзе дә бит ул нәкъ менә шуңа исәп тотты да, хөтбәне татарча сөйләү нияте күптән инде бөреләнеп җитеп, үзен ул мәдрәсәдә дәрес, нәсихәт сөйләгәндә, фикердәш муллалар, авылдашлар белән очрашкан-аралашканда сынап, телен чарлап, үз-үзенә ышаныч беркетә килсә дә, халык алдына чыгып, диннең, яшәешнең иң җитди темаларын да ана телебездә сөйләргә ярый дип, алай гына түгел, лязем, фарыз дип рәсми белдерү өчен менә шушы мизгелне көтеп алган иде.

Аллаһка шөкер, максаты акланды – халык аны хуплады. Зурдан кубып әйткәндә, халык бит аның бу гамәле йөзендә, аның сүзләре белән тагын бер тапкыр Аллаһны, динебез исламны һәм шулар белән беррәттән ана телебезне дә хуплады, зурлады. Нәкъ менә шушы хәл Габдулланы үз башлангычын бүтән имам, мулла, мөгаллимнәргә дә кыюрак тәкъдим итәргә илһамландырды, дәртләндерде. Шул канатландыру аны “Татарча хөтбә уку дөрестме?” дигән китап язып, аны бастырып чыгарып (Казан, 1908), таратырга да көч, илһам бирде.

Кайбер яшь муллаларның да үзенә иярүләренә куанса да, Габдулла татарча хөтбә укыла башлауны “бик мөһим бер инкыйлабның башы” дип атый. Чөнки инкыйлаб икән, ул инде тартыш, көрәш дигән сүз. Чыннан да, бу юлы да нәкъ менә Бубыйдан чыккан яңалыкны тулаем татар халкы, беренче нәүбәттә мәгърифәтчеләр, әдип, шагыйрьләр, яшь мөгаллимнәр күтәреп алса да, бу хәрәкәт гасыр башында – кадимчелек белән җәдитчелек тартышының нык көчәеп барган чорда – җәдитчеләр башында торган Иж-Бубый мәдрәсәсеннән чыкканы өчен генә дә кадимчеләр аңа кара көйгән, аны каралтырга, хәрәкәтенә таяк тыгарга маташканнар.

Иж-Бубый мәдрәсәсен, аның җитәкчеләрен электән күрә алмаган Ишми ишаннар мәдрәсәгә, аның мөгаллимнәренә өйгән тавык чүпләп бетермәслек гаепләр өстенә монысын да өстәгәннәр.

Ә нигә әле боларны без искә төшерергә булдык? Әлеге мәгълүмат һәм, тулаем да, Иж-Бубый мәдрәсәсенең милләткә, халык мәгърифәтенә керткән тарихи өлеше яхшы мәгълүм. Мәдрәсәнең 200 еллык тарихы бар. Бер игелекле нәсел генә дә – Нигъмәтулла, аның улы Габделгаллэм, оныклары Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөслихә –

мөгаллимлек иткән елларда патша самодержавиесе аны 1912 елда яптырганчыга хәтле милләтебезгә, ислам диненә, татар мәдәниятенә керткән олуг өлеше турында тарихыбызда бай материал теркәп калдырылган. Халкыбыз аны әледән-әле исенә төшереп тора. Узган гасырның егерменче елларында ук мәдрәсә эшчәнлеге турында матбугатта: ”Заманында үзенең яңалыгы, тәрбия ысулларының куелышы ягыннан алгы сафта торган мәктәбе белән үз янына эчке Россия, Төркстан, Кыргызстан тарафларының һәр почмагыннан укырга, мәдәнияткә, яңалыкка сусаган күп кешеләрне җыйган иде”, – дип язганнар.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең уңай тәҗрибәсе заманында Җәмал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, безнең чорда исә язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев, шәрык белгече Равил Үтәбай-Кәрими хезмәтләрендә яктыртылды. 1999 елда “Рухият” нәшрияте “Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе” дигән тарихи-документаль җыентык чыгарып (төзүчеләре Р. Мәрдәнев, Р. Миңнуллин, С. Рәхимев, фәнни мөхәррире М. Госманов), изге бер эш башкарды. Мәдрәсә үзе дә, тарихи шәхесләр Гобәйдулла, Габдулла, Мөслихә Бубыйлар да “Татар энциклопедиясе”ндә дә лаеклы урын алган.

Габдулла Бубыйның “Бубый мәдрәсәсенең кыска тарихы” дигән безнең темага турыдан-туры караган язмасына аерым диккать итү сорала. Габдулла Бубыйның тарихи эшчәнлеген хәтердә яңартуыбызның төп сәбәпләренең берсе – Иж-Бубый мәдрәсәсенең һәм аның күренекле мөгаллимнәренең ана телебезне саклау, үстерү, кулланууын дәвам иттерү юнәлешендә гаҗәп зур өлеш кертүе. Кызганыч ки, әле телгә алган һәм башка хезмәтләрдә дә Бубыйларның бу кыйбладагы эшчәнлегенә, безнеңчә, тиешле бәя биреп җиткерелмәгән.

Бүген, милләтебез, халкыбыз мөстәкыйльлеккә ирешү максатында үз дәүләтчеллеген, кыйбласын беркетергә омтылганда, телебезнең, дәүләт теле буларак, дәрәҗәсен үстерү, куллану өлкә, даирәләрен җәһәтрәк ишәйтү өчен тарихи тәҗрибәләр дә бик кирәк. Алай гынамы! Монда безгә, гомумән дә, төрледән-төрле телләрнең куллану тәҗрибәсен туплаган бөтен бер фәннәргә мөрәҗәгать итү вакыты җитте. Мәсәлән, дөньякүләм мәгълүм риторика фәненә.

Риторика фикерәңне бүтәннәргә җиткерү, үткәзү, аларны ышандыру өчен телнең әйтеп һәм язып белдерелә торган барлык чараларын файдалану сәнгате, шул мөмкинлекләрне кулланырга өйрәтә торган фән дә. Совет чорында ораторлык осталыгы, тел культурасы дип соңгы чиккәчә тарайтылган риторика фәне кайбер уку йортларында бик очраклы гына укытыла иде, соңгы елларда гына ул кайбер

мәктәпләргә кайтып алды. Урыс телендә балалар бакчаларыннан алып югары уку йортларынача укыту программалары төзелеп, дәреслек-кулланмалар бастырып чыгарылды.

Тик “Татар риторикасы” турында әле авыз тутырып сөйләшә алмыйбыз. Телебезнең куллану асылын өйрәнүгә дәүләткүләм игътибар бирелмәгәндә, биш йөз ел буе аның кулланыуын юк итү максаты гына хакимлек иткәндә бу мөмкин дә түгел иде. Бүген, шөкер, менә шул хакта уйлана, сүз кузгата алабыз. Рәхмәт Бубыйларга, бу хакта аларны искә төшергәндә уртага куеп сөйләшүләр оештыра алабыз.

Хәзер татар нәфис сүз осталыгы сәнгате һәм фәне хәрәкәт итсен өчен дә азмы-күпме шартлар туып алды. Риторика бит ул – демократия булганда гына өлгерә торган җимеш, бездә дә бит чагыштырмача фикер иреге, сүз иреге, фикер төрлелеге мохите сиземләнеп алды. Мондый шартларда телне тормышта куллану мәсьәләләре дә алга чыгып, бу күренешләрне өйрәнә торган сөйләмият, социолингвистика фәннәре хәрәкәткә килә. Алар риторикага да ризык бирә, этәргеч ясый.

Шулай да риторикага бөреләнеп, тернәкләнеп китәр өчен иң башта җирлек – тарихи тәҗрибә кирәк. Ул бар: телебезнең халык авыз иҗатында, иң борынгы чорлардан алып бүгенгә кадәр тупланган нәфис әдәбиятебездә, төрледән-төрле стильләрдә теркәлгән фәнни, рәсми, дини язмаларыбызда, Атилла, Кубрат, Идегәй, Сөембикә кебек падишаһларыбызның өндәү, үгетләрендә, Кол Шәриф, Мәрҗани, Риза Фәхретдин хәзрәтләребезнең вәгазь-хөтбәләрендә, Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиевләрнең кайнар нотыкларында чаткылардай җемелдәп, халык хәтеренә уелып-уелып калган хәзинә-байлыгы ул.

Риторика һәм дин бердәйлеге бик ерак-еректан, һәркайсының дөньяга туган дәвереннән үк килә булса кирәк. Дин адәм затлары зиһененә үтсен, яшәешендә ярдәм итсен өчен аның нигезләмә-кагыйдәләрен телдән сөйләп инандыруда риторика нык булышлык иткән. Ислам динендә вәгазь-хөтбә сөйләүнең гасырлар буе килгән тәҗрибәсе аның үзен дә баеткан.

Вәгазьне татарча сөйләү татар риторикасы үсешенең үзенә бер юнәлеше булып киткән. Бубыйлар керткән яңалыкның әһәмияте бәяләп бетергесез – аларның җиңел кулыннан һәм тырышлыгыннан татар теле яңа бер куллану өлкәсенә-даирәсенә ия булып киткән.

Әлбәттә, бу бер әфсен өрү белән генә, җиңел генә үзләштерерлек яңалык түгел иде. Шунысы әһәмиятле дә: аны гамәлгә ашыру өчен телебез үсешенә бәйле кайбер бүтән үзгәрешләр дә сорала иде. Мәсәлән, халык кадәр халык алдында вәгазь, хөтбә, нәсихәт сөйли

алыр өчен мулла, мөгаллим ана теленең төзелешен, аның тәэсири мөмкинлекләрен, үтемлелек, тасвири чараларын яхшы белергә тиеш. Мәдрәсәләр эшчәнлегендә беренче тапкыр диярлек Бубыйлар татар телен өйрәнүне программа, уку-укыту тәртипләренә кертә башлый. Дәресләрдә матур язу, сәнгатьле уку, фикерне тел ярдәмендә дөрес белдерү (мантыйк) һәм тел куллануның башка юнәлешләрен өйрәнү максатлары куела.

Мәдрәсәнең 1908–1910 елларда гамәлдә булган программаларында нинди фән, предметларны татар теленә бәйле рәвештә укыту каралуына анализ ясау “татарча укытыргамы-юкмы” дигән мәгънәсез, зарарлы шик, бәхәсләрдән һаман башы чыкмаган, татар телен дә юньле-башлы укыта алмаган мәдрәсәләребезгә генә түгел, дөньяви мәктәпләребезгә дә файдалы булыр иде.

Бубый мәдрәсәсендә беренче сыйныфтан башлап сигезенче сыйныфка чаклы ана теленә бәйләп атнасына 24–30 сәгать исәбеннән башлыча 28 предмет-фән укытылып, арада матур язу (хөсне хат), әлифба, татар орфографиясе (төрки имля), татарча уку, татар әдәбияте, телдән сөйләү, уку кагыйдәләре (кыйраәт), көйләп уку, татарча дөрес сөйләү кагыйдәләре (бәлягате төркия) һәм башка фән-предметлар урын алган.

Шунысы мөһим: мәдрәсәдә, табигый ки, иң зур игътибар һәм күп вакыт гарәп телен камил өйрәнүгә бирелгән, шул ук вакытта (бу бүгенге мәдрәсәләргә дә гыйбрәтле) гарәп телен, өстәвенә әле фарсы, урыс, француз телләрен дә татар теле белән чагыштырып өйрәнү алымнары, шул телләрне ана теле-сөйләме, әдәбияте мохитендә өйрәнү гадәттә була. Элекке шәкертләрнең (мәсәлән, Х. Мостакаевның) истәлекләреннән күренгәнчә, “укыту өчен нигездә урыс уку йортлары программалары кабул ителеп, педагогика һәм ислам дине гыйлемнәре өстәлгән иде. Урыс, гарәп, француз телләре укытыла. Төп фәннәрнең күбесе татар телендә алып барылды”. Фарсы теленең төпле укытылуы, төрек теле укытыла башлау да арадашчы телләр буларак гарәп теле белән татар телен тыгыз бәйләү өчен эшләнгән дип уйларга кирәк.

Һәрхәлдә Бубый мәдрәсәсендә шәкертләрдә, алар йөзендә аларның ата-аналарында үз телебезгә хөрмәт тәрбияләүдә эур эш эшләнә. Алар арасыннан Җәмал Вәлиди кебек тел белгечләре, Нәҗип Думавый кебек шагыйрьләр – оста вәгазьче, ораторлар, татар телен пропагандалаучы мулла, мөгаллимнәр чыгуы һич очраклы хәл түгелдер. Әйтик, Җәмал Вәлиди үз мәдрәсәсен нәфис сүз осталыгы белән ничек ихласый, тасвирый бәян итә: “Бубый мәдрәсәсе башта

җәдит мәдрәсәләрдән үзенең хөрлеге, дөньявилыгы, истикьлялы (бәйсезлеге) белән аерыла иде. Фатыйх әфәнде Кәриминең "Бубый шәкертләре дөньяга туп-туры карыйлар, аякларын җиргә нык басып йөриләр", дигән сүзе бик тугърыдыр...", – ди. "...Татар дөньясын каплап алган калын караңгылык эчендә беренче шәмне күтәреп чыккан Бубыйларның артысыннан баручы бер кеше булуым сыйфататы белән баш иям", – дигәндә, ул нәкъ менә алар кебек ана теле хакына армый-талмый хезмәт итәргә тырышуын истә тотадыр да.

Татар телен чын тормышта хәрәкәттә, гамәлдә күрү өчен аның төзелешен белү генә җитми, төрле яссылыкта, даирәдә куллану ихтыяҗы һәм шуны канәгатьләндерү күнекмәләре дә зарур. Әлбәттә инде, иң мөһим, көндәлек ихтыяҗ – ул мәдрәсәдә шәкертләрне киләчәктә нәкъ менә татар халкы белән аралашып, аңа хезмәт итәрлек дини һәм дөньяви белемле итеп тәрбияләү. Габдулла икенче ихтыяҗны да үзәккә куя – үзе яшәгән туган авылы халкы белән турыдан-туры ана телендә аралашу. Ул бит әле үз мәхәлләсенең указлы имамы, мулласы да. Халыкның күпчелегенә – авылныкыларга да, бүтән төбәкләрдән килеп укучы шәкертләрнең ата-аналарына да – аның белән иң катлаулы дини һәм дөньяви мәсьәләләрне дә нәкъ менә ана телендә аңлашып хәл итү мәслихәттер, кулайрактыр.

Кыскасы, Бубыйлар халыкка татар телендә мөрәҗәгать итү өчен татарча дәреслекләрне, җәдитчә оештырыла торган төрле җыелыш, кичәләрне, мәчет мөнбәрләрен, авыл җыеннарын гына түгел ("Бубый мәдрәсәсе үзенең атна саен ясалган җыелышлары, бу җыелышларда вакытына күрә сәяси нотыклары (кара истибдадакага каршы) белән шәкертләрнең фикерен ачуда күп хезмәт итте", ди Г. Мансуров), мәдрәсә, авыл чикләреннән чыгып китеп, җәмәгать ишле туплана торган төрле җыеннардан, ярминкәләрдән дә файдалана. Замандашлары язмаларында Габдулланың ел саен Мәкәрҗә, Минзәлә ярминкәләренә барып, мәдрәсә файдасына татар байларыннан шактый акча җыюы, байлар арасында милләткә хезмәт итү кирәклеге турында ялкынлы чыгышлар ясап, үгет-нәсихәт сөйләве тасвирлана. Аның Мәкәрҗәдәге бер нотык-хөтбәсендә, милләтне тәрәккыять иттерү өчен кан белән, җан белән тырышырга кирәк, дип өндәгән нотыгын халык әле азактан да хуплап сөйли.

Халык белән, мулла, мөгаллимнәр, зыялылар белән татарча болай аралашулар мәдрәсәнең дә даны, дәрәҗәсе үсүгә йогынты ясый. Ә карагруһларның, кадимчеләрнең ачуы, үчләшүе кабарганнан-кабара гына бара. Юкка гына мыни "ходайга каршы" мондый эшләр

хакында “кара” муллалар, шовинистлар губернаторга да, мөфтигә дә шикаять арты шикаять яудыра, юкка гына мыни губернатор фәрманы белән Габдулла Бубыйның мәдрәсәдән тыш “лекцияләр укуы” тыела.

Шулай итеп, Габдулла Бубый ана телебезнең милләтебез яшәешендәге әһәмиятен сиземләп, аның асылын, төзелешен башка телләр белән чагыштыра-чагыштыра тәфсилле өйрәнеп, аның кешеләргә тәэсир итү чара, мөмкинлекләрен җентекле барлап, шул мәгълүмат, белемнәрен нәкъ менә гамәлдә куллану юлына баса. Бу изге эшкә туганнарын, хатыны Хөснифатыйманы (Р. Үтәбай-Кәрими: “...ул ялкынлы оратор булган”), башка мөгаллим, шәкертләрне җәлеп итә. Кыскасы, ул татар теленең яшәешнең төрле өлкә, даирә, темаларына сөйләм кору өчен тулы мөмкинлеге барлыгын, мәгънә чараларына да, хисси бервмлекләргә дә бай булуын, бу яктан башка телләрдән һич тә кайтыш булмавын исбат итеп, татар риторикасына нигез салучыларның берсе дип атарга шик калдырмавын авыз тутырып әйтергә буладыр.

Без әлегә татар риторикларының, аеруча аның классикларының төп сыйфат-үзенчәлекләрен, тәрҗемәи хәлләрен ачыклап бетермәгәндербез. Шулай да Габдулла Бубыйның моңа холкы-фигыле, Ходай тәгалә биргән сәләте-таланты булганын сиземләү кыен түгел. Бу – бәхәссез. Замандашлары аның шул сыйфатларына сокланган булган, шәкертләре аңардан үрнәк алган. Җәмал Вәлиди, мәсәлән, болай тасвирлый: “Мәрхүм Бубый гаять җанлы, үткен, ялкынлы бер кеше иде. Ул үзенең адымнарын тәрәддедсез (икеләнүсез) атлый, фикерен ачык һәм кискен йөртә иде. Гаять нык бер кандгате вөҗдания вә куәтле бер җәсарәте әдәбия иясе (кыю әдәбиятче, публицист) иде. Аның табигатендә булган тизлек вә кискенлекне һәрбер эшендә күрергә мөмкин”.

Аннары, Габдуллада риториклык сыйфатлары: фикер хөрлеге, ана теленең көч-кодрәтенә ышану, нәфис сүз сәләте – нәселдән килгән диярге дә була. Бабасы Нигъмәтулла, Р. Фәхретдинев язып калдырганча, Казан янындагы Бәрәскәдә туган, үз гасырында Мәчкәрәдә гыйлем вә зиһенлек белән, ягъни мантыйк, кәлям вә ысулдан фикер йөртү, бәхәстә осталык белән шөһрәт тапкан дүрт шәкертнең берседер. Үз кулы белән язган “Тәүзих” (ачык аңлату, мәсьәләне аңлаешлы итеп яктырту китабы), “Гакаид” һәм башка китаплар читләрендә үзенең фикерләре вә кайбер гарәпчә язмалары бар. Ш. Мәрҗани аны “Бубый Нигъмәтулла дип танылган гыйлем иясе”, ди. Габдулла үзе: “Нигъмәтулла бабайны белгән кешеләр бик шаян

сүзле, ләкин бик намуслы вә һичкемнең хәтеренә караучан түгел иде, дип сөйлиләр”, – дип язып калдырган.

Габдулланың әтисе белән бертуган абыйсы да (ул да Габдулла исемле) “егерме яшьләрендә сатуларын ташлап (яшьләй урысча өйрәнеп, газетлар да укый), яңадан мәдрәсә кереп укырга тотынган... Эстәрлебашта беренче булып география укытырга тотына. Гарәпчә сарыф вә нәхүләрне, фарсыча укытуны куеп, татарча укытып, гарәпчә белем бирүне реформалаштыру юлында да зур бер адым атламыштыр”.

Янә бер мөһим нәрсә – ул, чын риторик-ораторларга хас булганча, Габдулланың сөйләү осталыгы язу осталыгы белән үрелеп бара. Җәмал Вәлиди билгеләгәнчә, ул “үзенең әсәрләрендә ялкынлы бер публицист булып мәйданга чыга, алда тереләй кыймылдап торган мәсьәләләрне мөзакәрәгә куеп (бәхәс мәйданына чыгарып), шуларны заманның теләгенә муафыйк рәвештә хәл кыла”. Җ. Вәлиди аның егермеләп кисәктән торган (әмма нибары сигезе басылган) “Хакыйкать” әсәренә югары бәя биреп: «“Хакыйкать” вакытында гаять популярный бер әсәр булып, шәкертләр арасында кулдан-кулга йөри. Үзенең дини мәсьәләләрне җәсарәте (кыюлыгы) белән яңа фикере ачылып килә торган яшьләрне хәйран итә иде. Иске голяманың авторитетны югалту һәм иске мәдрәсәләрне туздыруда моның кадәр зур тәэсире булган, белмим, икенче бер әсәр бар микән?», – ди.

Бу биеклектән караганда, Габдулла Бубыйның “Татарча хөтбә уку дөрестме?” дигән хезмәте дә һич тә аңардан кайтыш түгел. Бүген аны теләсә кайсы мәдрәсәгә (һәм башка уку йортларына да) риторикадан кулланма рәвешендә тәкъдим итеп була.

ТАТАР РИТОРИКАСЫ ҺӘМ АКМУЛЛА

Нәфис сүз, ораторлык, хөтбә сәнгатенең үсешендә һәм аның буыннан-буынга тапшырыла килүендә халык ораторларының (телмәрче, нотыкчы, чичән, акын, сәсән һ.б.) тоткан урыны ифрат зур, әһәмиятле. Алар тарихта һәм халык хәтерендә чичәннәр дип саклана. Шулай да бу төшенчә төрле чорда, төрле төбәкләрдә төрлечә аталган. Кыпчак, нугай чоры төркиләрендә җыраулар (җырагулар) атаклы булган. Х1Х–ХХ гасырдан исә аларны чичәннәр дип (казакъларда – акын, әзәриләрдә – ашыг, башкортларда – сәсән, бүтән төрки халыкларда – чәләби, кубызчы һ.б. атамалары белән) йөртергә күнегелгән.

Гадәттә, чичәннәрне фольклор фәне өлкәсе барлый һәм өйрәнә. Риторика күренеше буларак киңрәк мәгълүмат аларга М. Бәкирев (*Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге: гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 141 б.) хезмәтендә бирелгән. Ул Мифтахетдин Акмулланы да шундый тарихи шәхесләр рәтендә саный.

Максатыбыз – Мифтахетдин Акмулланың шәхесен, иҗатын нәкъ менә риторика сәнгате һәм фәненә кагылышлы рәвештә, ягъни риторик – оратор – чичән буларак берникадәр күзәтү ясау, бүгенге риторикага осталык үрнәкләре тәкъдим итү. Моңарчы бу юнәлештә махсус тикшеренүләр булмады әле.

Дөрес, махсус риторика дәреслеге дип тәкъдим ителгән В. Псәншин (*Псәншин В.Ш.* Риторика нигеззәре: 10–11 сыйныф укучылары өсөн укыу кулланмаһы. Өфө: Китап, 2001. 200 б.) һәм И. Низамов (*Низамов И.* Риторика: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2005. 178 б.) кулланмаларында Мифтахетдин Акмулла иҗаты беренче тапкыр риторика яссылыгында, аерым алганда, ритор-чичән сыйфатында тәкъдим ителә. Тик аларда да әле мәгълүмат гомуми таныштырудан ары китә алмаган, чичән шагыйрьнең бу кыйбладагы төп иҗат алымнары, асыл сыйфат-үзенчәлекләре системага салып ачылмаган.

Шөкер, М. Акмулланың чын риториклык (шагыйрьлек, нәфис сүз осталыгы, чичән һәм ораторлык, вәгазьче буларак) осталыгын күзәтү, анализлау һәм гомумиләштереп бәя бирү өчен фәндә (беренче чиратта фольклор, матур әдәбият нәзарияләрендә) берникадәр мая тупланган. Әйтик, әле телгә алынган дәреслегебездә М. Акмулланы татар риторикасы элгәрләреннән күренеклеләренең берсе дип тәкъдим иткәндә без төп чыганаклардан буларак Сәйфи Кудаш (*Кудаш С.* Йәшлек эззәре буйлап: истәлекләр. Өфө, 1964. 26–27 б.), Әхнәф Харисов (*Харисов Ә.* Башкорт халкының әдәби мирасы (XVIII – XIX буаттар). Өфө, 1965. 331–357 б.) хезмәтләренә таяндык.

Дәреслекнең дәвамы булган менә шушы “Нәфис сүз осталыгы” мәҗмугасын әзерләү барышында М. Акмулланы риторика сәнгате аксакалы буларак бәяләүдә һәм тасвирлауда шулай ук М. Гайнуллин (Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1957, 1968), М. Госманов (*Госманов М.* Кереш сүз // Акмулла. Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981), Ә. Вилданов (*Вилданов Ә.* Кереш сүз // Акмулла. Шигырьләр. Өфө: Башк. кит. нәшр., 1981), И. Надыйров (Акмулла иҗатында фольклор традицияләре // Поэт-просветитель Акмулла: мате-

риалы юбилейных торжеств и научной конференции, посвященных 150-летию со дня рождения. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1983. 97–104 б.), Р. Әхмәтев (*Әхмәтев Р.* Мифтахетдин Акмулла (1831 – 1895) // Татар әдәбияты тарихы. 2 т.: XX йөз татар әдәбияты. 70–88 б.), Ү. Гыймадиев (Поэт-просветитель Акмулла: материалы юбилейных торжеств и научной конференции, посвященных 150-летию со дня рождения. 89–96 б.), Х. Курбатов (шунда ук. 54–61 б.), Х. Миңнегулов (*Миңнегулов Х.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999) һ.б. авторларның хезмәтләре файдаланыла.

Риторика сәнгатенең төп мәсләге – ул ышандыру (инандыру), дибез икән, моңа риторика бер-берсеннән аерылгысыз ике кыйбланы тотып кына ирешә ала: нәрсәгә ышандырырга һәм ничек (нинди ысул, алым, чаралар белән) ышандырырга. Мисалга М. Акмулланы алган очракта, аның беренче кыйбласы, ягъни аның шәхес буларак яшәеш һәм чичән-шагыйрь буларак иҗат “эчтәлеге” шактый җентекле өйрәнелгән. Монда ике нәрсәне искәртеп китү сорала: беренчесе – риторика ул һичшиксез иҗтимагыйлык белән бәйле күренеш, димәк, ул үзе яшәгән мөхит, җәмгыять белән бәйләнештә генә карала ала; икенчесе – ышандырырга теләгән фикере, ягъни шәхеснең “эчке” асылы – яшәү рәвеше, мәсләге – аның шул фикерне бәян иткән, тасвирлаган сүзе белән тәңгәл булуы зарур.

Акмулла кемне, нәрсәгә ышандырырга алынган булган? Иҗтимагый оратор – шагыйрьнең үзенчәлеге шунда ки, ул үзе табынган, инанган хакыйкатьне генә башкаларга ышандырырга алынырга тиеш; күрәсең, бу сорауны бүтәнчә куюның да әһәмияте бардыр: чичән иң әүвәле үзе нәрсәгә ышанган, иманы нидән гыйбарәт, нинди фикер-ният-идеяне үзендә генә “яндырып” тынычланмыйча, бүтәннәргә дә җиткерергә омтылган?

Башта чичәннең турыдан-туры шәкертләре санала алырлык, үзләре дә рухы-күңеле белән аның фикердәше, теләктәше булган, үзләре дә татар риторикасының элгәрләре саналган шәхесләребезнең фикеренә колак салыйк әле. Галимҗан Ибраһимов: “Курсави – Мәрҗәни, Каюм Насыйри, Акменла, Акъегетзадәләр татарның әдәбификри хәрәкәте тарихындагы икенче дәвернең – Борынгы Шәрыкъне җимереп, яңару, европалашуның беренче баскычы, беренче адым атлавы иде. Орлыктан сабак, яфрак чыгып үскән кебек, тамчылар белән башланган чишмәләр зураеп елгага әйләнгән кебек, ул икенче дәвер хәрәкәте дә бер ноктада тукталып калмады – баскыч-баскыч күтәрелде, үсте, киңәйде, барлыгы бер кыйблага – Европа мәдәниятен,

гыйлемен алуга карап юнәлүдә дәвам итте” (Поэт-просветитель Акмулла: материалы юбилейных торжеств и научной конференции, посвященных 150-летию со дня рождения. 341 б.).

Шагыйрь һәм галим Сәйфи Кудаш: “...Иске дини фанатизм белән яңалык көрәшләре башланган уяну елларында, төн караңгылыгы белән яңа гына сызылып килгән таң яктылыгы сугышкан вакытта сайраган бер сандугач сыман булып, менә шул хәрәкәтнең мәгърифәтче бер пропагандист-җырчы буларак, әдәбият мәйданына талантлы шагыйрь Мифтахетдин Акмулла һәрвакыт үзенең бердәнбер мөлкәте булган ялгыз атын китап һәм столярлык кораллары төягән арбасына җигеп алган да, Шиһап Мәрҗәни күтәргән яңалыкларны яклап һәм мактап, фанатик муллалар белән сугыша-сугыша, авылдан-авылга, каладан-калага мәгърифәтчелекне пропагандалап йөргән...” (*Кудаш С.* Йәшлек эззәре буйлап. 26–27 б.).

Хәзер килеп, ничек ышандыру мәсьәләсе. Бу юнәлештә әдипнең риторика сәнгате яссылыгында туплаган тәҗрибәсе, осталыгы нидән гыйбарәт? Башта аның иҗатын бөтен яклап, тирәнтен өйрәнгән галим-белгечләрнең аның шул өлкәдәге талант-сәләтенә ишарә ясаган кайбер фикер-күзәтүләре. Ризаэтдин Фәхретдин: “...мәшһүр шагыйрь...”; “...зирәк вә үткен табигатьле һәм дә игътибарлы...”; “...тавышы яхшы гына моңлы булып, җырлауга оста...”; “...үзе яшәгән мөхиттән яхшы ук хәбәрдар булуы...”; “...үзендә шигырь сөйләүгә истигъдад барлыгыны вә шуңа әһәмият бирүе...”; “...үзенең шигырьләрене моңлы тавыш берлә, беркадәре кабзыйәт (каушау) вә гайрәт берлә сөйләде, вә яхшы гына тәэсир бирде...”.

“Акмулла үз иҗатында борынгы әдәбият, тарих, риваятьләр буенча мәгълүм тарихи, легендар шәхесләрне дә поэтик образ итеп куллана. Шул исәптән атаклы философ Әфләтун (Платон), мәшһүр акыл ияләре Сөләйман патша (Соломон), Әл-Фараби, Локман табиб – зирәклекне һәм галимлекне, Йосыф пәйгамбәр – олы җанлылыкны һәм сабырлыкны, Фиргавен, Әбүҗәһел, Тимерлән (Аксак Тимер) – кирелек, усаллык, явызлыкны гәүдәләндергән символлар буларак алынган. Бу образларның баш чыганагы... язма традицияләргә барып тоташа...”; “...Халыклар белән даими аралашып, аларның гореф-гадәтләрен, тел, тәҗрибә, хикмәт байлыгын китап буенча гына түгел, ә җанлы яшәешендә күреп, аларны табигый яңгырашында “эстетик хәтеренә” сеңдереп барган...” (*Надиров И.* Акмулла иҗатында фольклор традицияләре. 99 б.).

“Акмулла әсәрләрендәге югарылык, аларның укучыга ифрат зур тәэсир итү көче олы талантның турыдан-туры тормыштан рухлануыннан һәм дөньяви темаларда ачылуыннан килә. Акмулла дини юнәлештәге шагыйрьләрдән аермалы рәвештә, тормышта үзе күреп, үзе кичереп яки тоеп белгәнне язган, гаделлекне җырлаган, халыкны белемле һәм һөнәрле булырга чакырган...”; “ Акмулла шигырьләрен бастырып чыгарудан бигрәк, халык арасында үзе укыр, яттан сөйләр өчен язган. Менә шуңа, күрәсең, аның әсәрләрендә ишетер колакка ятыш булмаган нәрсәләр, ритмик чатанлык күренеше юк. Истәлекләрдән безгә Акмулланың үз шигырьләрен зур осталык белән, тыңлаучыны тәмам тәэсирләндерерлек итеп укыганы да билгеле...” (*Харисов Ә.* Башкорт халкының әдәби мирасы (XVIII – XIX буаттар). 341–347 б.).

“Акыл-хикмәт иясе, мәгърифәт идеяләренең ялыкмас пропагандисты, изелгән-кыерсытылганнарның сердәше, моңдашы булу белән бергә, Акмулла ялангач фикерләр өләшеп йөрүче коры вәгазьче, дидактив әдип кенә түгел, бәлки чын мәгънәсендәге талантлы, нечкә хисле шагыйрь дә, көчле сүз остасы да иде. Аның әсәрләрен, әгәр чынлап шигырь яратсаң, салкын кан белән укуы мөмкин түгел. Афористик җыйнак, фикри тирән юллар сине уйланырга мәҗбүр итсә, көтелмәгән уңышлы борылышлар, тапкыр табышлар сине сокландыра, мавыктыра. Чын сәнгать әсәре кабат-кабат укылган саен яңа серләрен, элек күрелмәгән “алмаз кырларын” ачкан кебек, Акмулла әсәрләре дә кат-кат укуны сорый, укыган саен яңа әсәр кебек яңа хисләр, яңа фикерләр уята...” (*Госманов М.* Кереш сүз. 42 б.).

Болар Акмуллага – халыкчан шагыйрьгә, чичән-ораторга – хас гомуми сыйфатлар иде. Хәзер шул сыйфатларның аның әсәрләрендә чагылышын конкретрак күзалларга омтылып карыйк. Моның өчен сөйләм күренеше-категориясен, аерым алганда риторик сөйләм (ораторлык сөйләме, хөтбә-вәгазь сөйләме һ.б. төрләре барлыгын да искәртеп) төренең фәнни асылын искә төшереп китик. Аның гомуми схемасы татарның бихисап төрләренекеннән аерылмый: сөйләм мотивларына бәрабәр сөйләм чаралары. Мотивлары: сөйләм иясе (С.И.), сөйләм адресаты (С.А.), сөйләм нияте (С.Н.), сөйләм шарты (С.Ш.). Чаралары: башлыча тел һәм экстра-, паралингвистик чаралар (тавыш-интонация, ым, ишарә, хәрәкәт һ.б.).

Риторик сөйләмнең үзенчәлекле булуы аның һәр мотивына чараларының да тәңгәл килүендә чагыла. Бу хакыйкать Акмулла иҗаты мисалында да раслана.

Сөйләм иясе буларак, М. Акмулла татар-башкорт мөхитендә татар телендә аралашучы гади авыл халкы йогынтысында үсә, тәрбия ала. Мәдрәсәдә һәм үзаллы укып, татар әдәби телен дә үзләштерә, шул уңайдан гарәп, фарсы телләреннән дә хәбәрдар була. Үсә төшкәч, казакъ телен, мәдәниятен дә үз итә. Кыскасы, ул күп төрле сөйләмдә аралашучы, шул аралашу барышында кемгә әйтүенә карап, берничә телне нечкәләп белеп файдаланучы иҗатчы була: “...кирәк икән – татарча, кирәк икән – башкортча, хаҗәте килгәндә саф казакъча сөйли алган, яза алган, ихтыяҗ булса, аларның өчесен бергә кушкан...” (*Госманов М.* Кереш сүз.).

Кайбер тикшеренүчеләр кисәтергә омтылганча, бу хәл аны һич тә телләрне урынсыз бутауга, әсәрләренең дә “корама” телле итүенә китермәгән. Андый куркыныч аңа янамаган да. Әти-әнисе, халкы биргән тел хәзинәсен ул яраткан, хөрмәт иткән, тәэсир көчен, тәмен тойган һәм, иң әһәмиятлесе, аны куллану нечкәлек-закончалыкларын тоемлап эш иткән – шул хәзинәне кешесенә карап, фәнчә әйтсәк, С.А. карап максатчан куллану сәләтенә, талантына ия булган. Шул таләпне үзенә генә түгел, бүтәннәргә дә куйган; мәсәлән, хәлфәләргә шәкерткә сабакны “мәгънәсенә үз телендә төшендерергә”, “үзеңезнең телеңезгә анык кылып, баласы мөселманның аңлагандай итеп дәрес бирегез”, дигән.

Сөйләм кору закончалыкларын тою, гамәлдә куллана белү аңарда табигый сәләттән, аннары халык авыз иҗатына игътибарлы булудан килә. Аннары бит, галим әйтмешли, “Акмулланың тирән тамырлы татар поэзиясе чишмәсеннән мул һәм даими су эчкәнлеге дә бәхәссез”.

Сөйләм иясен ачыграк аңлау өчен аның текстта “мин”не ничек белдерүен күзәтү әһәмиятле. Бу уңайдан “мин” дигәндә Акмулланың үзен гомумән дә кем сыйфатында тоюы кызыклы. Мәсәлән:

Укыдым кан йотып кайгы китабын,
Мөдәррисләр кебек гүйанә булдым (гүйанә – сөйләп торучы)

юлларыннан күренгәнчә, ул үзен сөйләп торучы рәвешендә күрергә күнеккән икән. Бүтән шигырьләрендә аның “мине” нинди мәгънәдә, үзен ничек атый, сөйләм адресатын ничек дип атый? Акмулла моңа бик сизгер. Әйтик, бөтен чыгыш буена – “җыру”мы ул, әллә шигырьме – “мин” дип тәкърарлауның тискәре тәэсир ясаячагын ул сиземли. Фикеренең тыңлаучыга, аудиториягә сеңә баруының ни дәрәҗәгә җитүенә карап, ул “без”гә, хәтта “сез”гә күчә:

Үгәй ана кулында йәтим *калдым*,

Андан да бик эрәтем китеп *калдым*.
Өстемдә керле күлмәк, йыртык дамбал,
Кайда мелла бар дисә, йитеп *бардым*.

Фәкыйрьлекдән артык фән күрә *алмадык*,
Шәһәр чыгып, алыс юлга йөрә *алмадык*;
Мәргәннәрне танырлык хәлемез бар,
Шул сәбәпдән сабыр кылып тора *алмадык*.

Бер караганда “без”дән “сез”гә күчү каршылыклы кебек (алар бит контекстуаль антоним да була ала), ә Акмулла еш кына контрастлыкны, антонимлыкны максатчан киметә. Әйтик, надан муллалардан көлеп язган шигырьдә ул “сез”, “сез” дип төртеп, басым ясап әйтеп барырга, тәкърарларга тиеш иде кебек:

Тәһарәт, намаз дөресләп белмәсәң дә,
Меллалык төрле фәннән ормак (сөйләмәк) кирәк;
Һавасына муафыйк гәпләр сөйләп,
Тозак, ау кормак кирәк...

Гавам халкы башларын *без* кайгырттык,
Вөҗүдемез гайне бер афәт булды.
Фетнәнең күбе чыгар телемездән,
Сәлләсе (чалмасы) өлкән, фәлән дигән кешемездән.

Бу очракта “фәлән” дигән бик конкрет кеше күздә тотылса да, тискәре күренешне гомумиләштерү максатында, шулай итеп әлеге кешенең үзенә, аның даирәсенә генә адреслана дип аңлашылмасын, ә бөтен укучы, тыңлаучыга барып җитсен дип, ул аны да “без” ди.

Без сатдык меллалыкның коры атын,
Бездән артык яулыклы дөрест хатын.

Күренә ки, сөйләмдә аның иясе белән адресаты органик бәйләнештә. Риторик сөйләмнең ышандыру максатын гамәлгә ашыру иң башта **сөйләм адресаты**н ачык сайлау, аны анык күз алдына китерү һәм аңарга турыдан-туры мөрәҗәгать итүдән башланадыр. Бу яктан да Акмулла иҗаты үзенчәлекле. Аның сөйләм адресаты, бер яктан, конкрет шәхесләр, һөнәри, социаль катлам, төркемнәр булса, икенче яктан, гомумиләштерелгән, типиклаштырылган укучы-тыңлаучы, халык. Аннары, адресаты конкрет зат, шәхес булган очракта да аның төрле милләтле, төрле телле булуын да истә тотарга кирәк. Әйтик, бервакыт аңа Ризаэтдин Фәхретдин оештырган зыялылар мәҗлесендә дә катнашырга туры килә. Югалып калмый, бик дәрәҗәле шагыйрь-чичәннәр белән дә, үз дәрәҗәсен белеп, алар белән ярыша-бәхәсләшә шигырьләрен сөйли. Р. Фәхретдин үзе дә: “Шушы сәгатьтән соң үземә дә мондый бер күңелле мәҗлес очрамады...”, – ди.

Тел байлыгын сөйләм адресатына карап төгәл куллану өчен шагыйрьнең байлыгы-мөмкинлекләре дә мулдан була шул.

И. Надыйров болай ди: “...өч халыкның фольклорына хас аерым билгеләрнең органик рәвештә үрелеп, тукылып бирелүен күрәбез. Икенче төрле итеп әйткәндә, аралашу мөхитенең киңлеге һәм этник җәһәттән чуарлыгы Акмулла фольклоризмында үзенчәлекле һәм кабатланмас синтезны барлыкка китергән. Әмма бу фольклоризм күп очракта өстә генә ятмый, аерым бер милләткә караган “тышкы” колорит сыйфатында күзгә нык бәрелеп тормый. Шагыйрь үзе әсәрендә теге яки бу халык иҗат иткән конкрет тел байлыгын, сурәтле тел бизәкләрен башкаларныкы белән кушып, күзгә ташланып тормаслык дәрәҗәдә нечкә итеп, нәзакать һәм нәфислек белән үреп бирә белгән” (*Надиров И.* Акмулла иҗатында фольклор традицияләре).

Сөйләм адресаты белән тыгыз бәйләнешкә керү ышандыру (инандыру) максатында аның игътибарын җәлеп итү өчен кулланыла торган чаралардан аңа мөрәҗәгать итү аерым әһәмияткә ия. Акмулла иҗатында аларны ике төп төргә: тел чараларына һәм экстра-, паралингвистик чараларга төркемләп булыр иде. Тел чараларына тәфсиллерәк тукталыйк.

Адресатның кемлегенә карап мөрәҗәгать чаралары: 1) конкрет зат; турыдан-туры исеме, вазыйфасы атамасы, яисә икесе бергә атала:

Бәгъдәсәлам, *Нургали мулла*, сезгә,
Ходаем инсаф бирсен күңеленезгә.

Ялгызлык исеменә махсус мөрәҗәгать берәмлекләре дә өстәлә: “***Әфәндем,*** күп сәлам, *Нургали мулла*, сезгә!

Кереш, эндәш сүз рәвешендәге мөрәҗәгать берәмлекләре дә сөйләм адресатын ачыграк күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, текстның хиссилеген көчәйтә:

Газалидәй риҗальгә кем туктамый,
Үзегез дә беләсез, *алла колы*!
Берадәр, сезгә үтенәм сәлам язып
Күзең сал: Мәрҗани – ул тимер казык!
Сәфәр – алыс, инсаф кыл, хакъдан оял,
Борынгы кабәхәтлек йитәр, *энем*!
(Үзенә-үзе шулай ди.)

Мөрәҗәгать берәмлегенә аны көчәйтүче, уңай йә тискәре төсмер бирүче эпитетлар да өстәлә: Җиһангирханга багышланган мөнәҗатен ул “Әссәламегаләйкем *асыл зат*ка” дип атый; “*Хөрмәтле әткәемә* йөз-мең сәлам...” ди дә, ачыклый: “Хөрмәтле әткәемә – сезгә сәлам”.

Аннары: “*сезләр”,* *“эткәем*”, дип кабатлый, “*әй солтаным”,* *“миһербаным*”, ди.

Сөйләм адресатын шулай ук: 2) конкрет бер төркем (милләте, һөнәре, торган урыны, социаль хәленә карап та төркемнәр) итеп тә, 3) гомумиләштерелгән тыңлаучы, укучы, халык итеп тә күз алдына китерә:

Башкортларым, уку кирәк, уку кирәк,
Арабызда наданнар күп, уку кирәк.
Аңгыра аюдан Уралдагы курыккандай,
Әй, *туганнар*, наданлыктан курку кирәк.
Бер нәрсәдән, агалар, хәүфитәем (хәвефләнәм)
Анасы нугай кызы димисәңез.
Файда жук артык сүздән, *бөрадәрләр*.

Кагыйдә буларак, мөрәҗәгать чарасы үгет-нәсихәт, өндәү, сорау, таләп итү һ.б. гыйбарәләре белән килә:

Яраннар, илтифат ит безем хәлгә.
Язылды кайгы менән, гаеп итмәгез,
Динкарендәш, барчаңызга күп-күп сәлам.

Мөрәҗәгать, эндәш берәмлекләре синонимнары белән аралашып, көчәйтелеп тә бирелә:

Әсир диеп, *бөрадәр*, сүкмәңгезләр
Күземдән канлы яшем түкмәңезләр
Теләп алмадым үземә моны, әй яр.

Эндәш, кереш, мөнәсәбәтлек, хәбәрлек чаралары да өстәлә: “*Әлбәттә*, бер ялган ат тагарсызсез”, “Мең мулла рәдд кылсаңыз (кире кагу) – ни кайгы бар?”, “Кил, *зинһар, бөрадәрем*, инсафка кил...”.

Күренә ки, шагыйрь-чичән сорау формасын бик урынлы, актив куллана:

Аңа булса мөкарин туры фәһем
(аңар дөрес аңлау якын булса)
Гатасына манига юк,– *беләсезме*?
(әҗеренә каршы төшүче юк)

Эндәш + сорау чарасы да актив кулланыла: “*Бөрадәр*, чын мелла кем, *беләсезме*? // Тасауф (суфыйчылык) китабларын күрәсезме?”.

Татар телендә мөрәҗәгатьлек төсмере кайбер сүзләрнең семантикасына да салынган. *Кирәк, тиеш, мотлак* һ.б. шундыйлардан:

Иң әүвәл *кирәк* эчнең керен,
Эчтә тулып ятмасын сасык эрен.
Аһ дәрига, эч тазар*сын*, эч тазарсын,
Булмаса, файда бирмәс коры белем.

Күренә ки, мөрәҗәгать төсмере сүзләр белән бергә башка грамматик категорияләргә, мәсәлән, боеру, үтенү, таләп, нәсихәт һ.б. төсмерле аффикс, морфемаларга да хас. Кайберләре әлеге мисалда да (*-сын/-сен* кушымчасы) чагылды.

Риторик сөйләмдә **сөйләм нияте** башлангыч, этәргеч һәм оештыручы үзәк булуы белән әһәмиятледер. Сөйләмгә тел чараларын җәлеп итүдә дә ул хәлиткеч урын тота. Риторикада ният (максат) – ул ышандыру (инандыру). Чичән-ораторның да төп максаты, әлбәттә, ышандыру. Аның сәбәби нигезе мәгълүм бер ният, максат, мәсләк һ.б. М. Акмулланың яшәеш, иҗади максат, ният, мәсләкләрен без гомуми планда күзаллаган идек инде. Шулай да чичән-шагыйрьнең инандыру максатын гамәлгә ашырудагы үзенчәлеген аерып әйтергә дә кирәктер. Галим Ә. Харисовның бер күзәтү-нәтиҗәсенә игътибар итик әле: "...Ислам динчеләре элек-электән сәнгатькә һәм шигърияткә карата ачыктан-ачык дошманлык күрсәтеп киләләр, шагыйрьләрнең, аеруча Акмулла ише, ачыктан-ачык дин әһелләрен наданлыкта гаепләүче әдипләрнең иҗатын бидгать эш дип, ислам сыйдырмый торган хәл, дип кире кагалар. Поэзиянең яшәү хокукын яклап, Акмулла мөселман руханыйларының менә шул үтә реакцион раславына каршы чыга. Аның "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән" дип башланган шигыре менә шушы мәсьәләгә багышланган.

Акмулланың дәлилләре шактый төпле. Ул, хәтта шул ук исламның үзенә һәм аның тарихына таянып, шигырьнең яшәүгә хокукы барлыгы ачык икәнен исбат итә. Акмуллага хас билгеле бер фәлсәфи караш һәм культура тарихыннан хәбәрдар булу аның бу әсәрендә дә ярдәмгә килгән. Аның поэзияне рухи тормыштагы тулы хокуклы күренеш икәнен раслаучы дәлилләре шуңа кайтып кала.

Беренчедән, шигырь – акыл җимеше, ә акыл иҗат иткән нәрсәнең яшәргә хокукы бар. Менә шуңа күрә "һәр фәндә шигырь белән китап тулы". Үзе галим, үзе шагыйрь булган Газзәли сымак бөек шәхес үзе генә дә ни тора! Андыйлар барысы да "гаҗәеп кыйммәт әсәр калдырганнар, акылның келәтеннән шигырь ачып". Шагыйрьләрнең акылына шигъри сүзләрне Алла үзе чәчкән, ди Акмулла, шулай булгач аның шигырьне тыюы мөмкин түгел, ди...

Икенчедән, хәтта Мөхәммәтнең иң динле юлдашы Ибне-Мәлик тә "эч пошканда, шигырь түгел, җыр җырлаган", шулай ук гает көн пәйгамбәрнең ишек алдында кол кызлардан җыр җырлату булган. Моңа юл куелгач, шигырьнең дә яраганы һәм яшәргә тиешлеге аңлашыла, ди Акмулла.

Хәзер килеп, шагыйрь-чичән ышандыру максатында телне һәм башка төрледән-төрле алым, чараларны ничек куллануын күзәтик. Тулаем алганда, әдипнең ышандыру максатында кулланыла торган төп дәлилләрен ике төркемгә тупларга була: 1) фактик дәлилләр, 2) образлы дәлилләр.

Холкы-табигате белән үк "турысын ярырга" сәләтле чичән-шагыйрьнең дәлилләү арсеналында фактик чараларның мул булуы үзеннән-үзе аңлашыладыр. Әле китерелгән өземтәдән дә күренгәнчә, иң гомумиләштерелгән, фәлсәфи темаларга язганда да ул конкрет шәхесләрнең исемен, аларның әсәрләрен, шулардан конкрет өзекләрне, мисалларны китереп, дәлил чарасы буларак урынлы, оста файдалана. Шигырьләренең исеменә үк игътибар итик: *"Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе", "Нургали хәзрәткә", "Бикмөхәммәт Карый улына", "Коргамбәккә шикаять"* һ.б. Әсәрләренең турыдан-туры эчтәлегенә кагылган *Галимҗан әл-Баруди, Зәйнулла ишан*, казакъ байлары *Исәнгилде белән Батучка* һ.б. Төрле төбәк, мәмләкәт, кала, салалар исемнәре: *"Истамбул, Мисыр, Шамда* нәзыйре юк, *Кышкар, Казан, Дагыстан* болай торсын!".

Ышандыру максатында фикерне сөйләм адресатына үз телендә, шивәсендә кулланылуы да фактик дәлилнең иң көчлеләреннән саналырга хаклыдыр. Моның әһәмиятен шагыйрь үзе дә тоеп, тоемлап кына калмый, ачыктан-ачык таный да:

Казакъча шигырь яздым ачык кылып
Хасидләрнең (көнче) йөрәген ачындырып.

Әлбәттә, әдипнең әсәрләрендәге төрле тел сүзләрен төрле яссылыкта анализларга була. Мәсәлән, М. Госманов хезмәтендә мондый анализ бар. "Җүкәне майлау менән кайыс булмас" дигән бер генә юлны алып карыйк. "Менән" теркәгече башкорт һәм казакъ телләренә хас булып, татарча нормага сыймаса, ә "кайыс" бары казакъ ягына тартса, утрак тормыш һәм урманчылык традициясенә бәйләнгән "җүкә" сүзенең килеп керүе бары татар теле стихиясенең генә тәэсире. Мондый мисалларны Акмулла теленнән дистәләп-дистәләп китерергә мөмкин.

Телнең берәр ягын өйрәнгәндә мондый анализ да кирәктер, бәлки, тик сөйләмгә бәя биргәндә аның гамәли әһәмияте юк. Бу – басылган текст. Акмулла нәкъ шулай язганмы, мәгълүм түгел, әмма мәгълүме һәм иң әһәмиятлесе шулдыр ки, Акмулла аны татарларга саф татарча, казакъларга саф казакъча, башка шивә кешеләренә аларча сөйләгән.

Фактик дәлилнең белдерелү формалары да үзенчәлекле: мәгълүм шәхескә багышланган мәрсия, бәет, ачык хат һ.б. Текст эчендә мондый синтаксик чаралардан туры сөйләм дә санала ала. Персонажның, аерым алганда оппонентның, үз сүзләре – көчле дәлил.

Әйтделәр: ***"Әсатирел әүвәлин***", дип (борынгы риваятьләр).

Сөйләм иясенең үз сүзләре дә еш очрый:

Сезгә каршы сүз әйтсәк – ник ярамый
"Вә һәм фи тогъяни һәм йәгъмәһун", дип.
(Алар үзләренең азгынлыкларында баталар.)

Өченче зат туры сөйләме дә актив кулланыла: *"Безгә йитәр кеше юк"*, дип өмед өзмә.

"Өченче зат" дигәндә аерым даирә, төркем, катлам (муллалар, галимнәр, төрмә залимнәре, авыл кешесе, шәкертләр һ.б.) сөйләмендәге гомумиләштерелгән, һөнәри, социаль шартларда барлыкка килә торган штапм-калып, жаргоннар, шома гыйбарәләрне дә истә тотабыз. Алардан да әдип оста файдалана.

Ниһаять, шигырьләрдә иң ышанычлы, иң көчле дәлилләр – халыкның үз "туры сөйләме" – мәкаль, әйтем, канатлы гыйбарәләре. Болар һәр шигырьдә диярлек энҗе каш булып җемелдәп тора.

Әдәби, шигъри осталыкка бәя бирүче галимнәр моны халыкчанлык диләр. Халыкчанлык, дәлил чарасы буларак, гап-гади сүздән башлана. Шулар инде әсәрнең төп тукымасын тәшкил итә дә.

Көче бар мирзаларга *җарамсынып*,
Шәригатьне күңел өчен *борып салган*.

Төрле халыкның тел хәзинәсеннән тупланганга күрә алар шулай мул да. Андый лексик хәзинә, беренче чиратта, нәкъ менә мәкаль-әйтемнәр, канатлы гыйбарәләр, халык җырлары, чичән-шагыйрьләрнең үрнәк әсәрләре белән "ияреп" керә. Ә аларга Акмулла ифрат бай.

Хәер, болар инде фактик дәлил чарасы булудан бигрәк образлы дәлил чарасы саналырга хаклыдыр. Вакыт-вакыт аларның функцияләре аерылмый да диярлек: икесенең дә беренче бурыч-максаты – ышандыру (инандыру). Шулай да шагыйрьнең төп таянычы, коралы инде ул – образ. Акмуллага бу яктан иң беренче чиратта, галим таныганча, "шигъри образ өчен (үзебездән өстик: күз алдына китереп дәлилләр өчен) халыкның көнкүрешенә хас әйберләрне файдалану, табигатьнең үсемлек һәм тереклек дөньясына мөрәҗәгать итү хас".

Әлбәттә, гадилек үзмаксат түгел, халык сөйләмендә нинди гади сүз бар, барысын да эшкә җигә, дию мәгънәсезлек булыр иде. Монда

сүз алган темасына, шул төбәккә, этник үзенчәлеккә карап, нәкь шушы мәгънәгә, хис төсмеренә тәңгәл сүз, гыйбарә, җөмлә төзелешен табу бәрабәренә ирешелгән “гадилек”, “халыкчанлык” турында бара.

Әйтик, Акмулла иҗатында ышандыру-тәэсир итү чарасы буларак сатира һәм юмор үзенә аерым урын биләп тора. Кайбер шигырьләрендә ирония, сарказм, яисә җиңелчә көләмәслек, елмаю чаралары алгы планга чыга. Көләмәс сүзләрне, шигъри бизәкләрне, бигрәк тә каламбурны оста файдаланып, ул кайбер җитди, фәлсәфи фикерләрен дә нечкә юмор төсмере белән өретә, “җиңеллек”, җанлылык бирүгә ирешә, ди Ү. Гыймадиев. Моның өчен аның арсеналында иң көчле әдәби чаралар, мәсәлән көтелмәгән охшату, әзер тора:

Ау корып чебен тоткан үрмәкүчдәй,
Кандала, бөргә (борча) менән таласамыз.

Төрттерү, көләмәслек, елмаю белән ул иҗтимагый кимчелекләрне дә күз алдына китерүгә ирешә:

Бокаларны сөзештереп, бак-бак булып
Мөселман сыерлары кысыр калган.

“Йомры” сатирик, көлкеле, иронияле гыйбарәләр белән ул үзүзеннән ничек көлә*: байгыш, таз эт, әфлисун арасындагы бер кишер* һ.б.

Сатира, юмор максатында тел бизәкләү чараларыннан антоним, антитеза, оксюморан кебекләр дә оста эшкә җигелә:

Бер йиргә килештереп хат язалмай
Берәүне яманларга кандай оста!
Әфәндем, *Мәрҗани кем, үзеңез кем*?
Әгәр син *мылтык* алсаң, мин *туп* алам!

Шулар ярдәмендә шагыйрь сатира, юморның иң дәлилле образ күренешләренә – ирония, сарказм, аллегория һ.б. кебекләрен дә “туптан ата”: Хур булдым хата төсеп *козгындарга***.**

Хәзер образлы дәлилләү чараларына тәфсиллерәк тукталыйк. Әйтем, мәкаль, шулай ук тел бизәкләү чаралары (кабатлау, чагыштыру, сынландыру, троплар, риторик фигуралар һ.б.) конкрет шәхескә, әсәрнең мәгълүм персонажына карата кулланылса да инде образ тудыру сәләтенә, күзаллауны конкретлаштырып, тәэсир, ышандыру, дәлилләү көченә ия була.

Алыйк чагыштыруны. Менә Шиһабетдин Мәрҗанигә карата: “*Ай булмаса, йолдыз берлә төн яктырмай*”. Ә инде аның дошманын “мондый гали галимгә тел озаткан – ул үзе *дүрт аяклы малдай* икән”, дип тасвирлый. Шәхсән үзен ул:

Адашканда киз килеп (туры килеп) балга төшкән –

Мин байгыш бер кырмыска гарык булган.

Аның шушы төбәк күренешләре, табигатьнең тереклек, үсемлекләре белән бәйле чагыштыру, ассоцияләр аеруча образлы, тәэсирле.

Шаһбаздай ялтыраган бер шоңкарлар,
Тойгынның аягындан элгәндәйләр.
Мин бер арык бүредәй җилеп йөргән,
Куян, карсак, төлке исен сизеп йөргән.

Шагыйрьнең чагыштыру нигезендә барлыкка китергән сынландыру, сурәтләү манзара-күренешләре дә үз тирә мөхитеннән, табигатьтән.

Арыкны атлаган аргамак идем,
Тәрәлеп туктап калдым текә ярга (бүгенге сөйләмгә күчерелгән).

Чичән-шагыйрьнең сөйләме риторик (синтаксик) фигураларга да ифрат бай. Мәсәлән, кабатлауларга. Гади генә анафора (*Кирәк ул – бай, кирәк ул – ярлы булсын!!*), эпифора (Аһ, дәрига*! Эч тазарсын, эч тазарсын*!) кебек кабатлаулардан алып бөтен бер шигъри симфонияне хәтерләткән тезмә-фигураларга кадәр очратып була:

...ябарсыз сез.
...ягарсыз сез.
...тагарсыз сез.
...чагарсыз сез.
...язарсыз сез.
...нәзарсыз сез.
...начарсыз сез.
...качарсыз сез.
...аҗарсыз сез.

Бер сулышта укылырлык, колакка ятышлы, өндәү белән сугарылган көчле бер шигарь бит!

Ш. Мәрҗанигә багышланган мәрсиянең мөнәҗәткә тартым бүлегендә 11 строфаның һәркайсы *“Җөда булдык, дәрига, аһ!” (Аерылдык, үкенеч, аһ*) дип кабатланып тәмамлана.

Дөресен әйткәндә, Акмулла әсәрләрендәге образлы дәлил сурәтләре халык авыз иҗатыннан киләме, әллә аларны ул үзе уйлап тапканмы, аеруы да кыен. Хәер, әсәрне уку барышында моны уйламыйсың да, ул йотылып укыла, хисләндерә, ышандыра.

Ат менән ни күрмәйде адәм башы.
Бозау күп уйнакласа, утка баса.
Нәтиҗә хасил булмай кысыр малдан.

Хәзер инде бу гыйбарәләрнең халык сүземе, әллә Акмулладан халыкныкы булып киткәнме икәнен дә белмәссең.

Бу бүлекчәне йомгаклап, менә нәрсә әйтергә кирәктер: Акмулла чичән мисалында менә мондый гыйльми нәтиҗәгә ирешү татар риторикасы фәненә дә зур өлеш дип саналырга хаклыдыр: “...Акмулла күп кенә әсәрләрендә үзен импровизация остасы, чичән итеп таныта... Аңарда акыл шигърияте халыкчан үткен формада чагылыш таба. Аның шигырьләре мәкаль һәм афоизмга бай булу, шагыйрьлек белән хәкимлек бергә кушылу белән аерылып тора. Мондый шигырьдә “фикер гомумән акыл чагылышы булып кына түгел, шагыйрьнең мөнәсәбәтен ачык чагылдырган рәвеш тә ала”. Шуңа күрә “акыл шигъриятендә лиризмның яңа сыйфатлары шәхеснең үз-үзен тирәнрәк тану нәтиҗәсе буларак ачыла бара” (Н. Юзиев).

Шагыйрь тел-сурәтләү чараларын да югары поэтик яңгырашлы итеп куллана. Беренче карашка үгет-нәсыйхәткә корылган хикмәтләр дә эмоциональ-шигъри төс ала. Акмулла әйтергә теләгән фикерен күчерелмә мәгънәдә бирергә ярата, әсәрнең төп идеясен төрле поэтик чаралар ярдәмендә ачарга омтыла. Мәсәлән, шоңкар образы анда яңа идеяләр өчен көрәшеп, яктылыкка, бөеклеккә омтылучы мәгърифәтле, азат кеше символы булып килә. Шагыйрь тулпар, йолдыз кашка, мәргән кебек чагыштыруларын да халык авыз иҗатыннан алып, үстереп, баетып, киң картина рәвешендә бирә. Традицион поэзиядә мәхәббәт символы булып йөргән сандугач образы – Акмуллада хөр фикер, оста сүз сөйләүче чичән символы:

Дөньяда тулып яткан газизләр бар,
Телләрен сандугачтай акча кискән.

Акмулла дүртюллыклары афористик, үткен, кыска, халык мәкаленә якын. Хикмәт лирикасында шагыйрь үзен “иске, китап сүзе”еннән яңа поэтик мәгънә тудыручы новатор итеп таныта.

Сөйләм шарты дигән мотив риторик сөйләм өчен аеруча мөһим. Чыгышның кайчан, кайда, нинди физик һәм психик халәттә оешуы, ничек бәян ителүенә карап телдән һәм башка чаралардан файдалану төрлеләнә. Риторик сөйләмдә, иң беренче чиратта, әйтү белән язу мөнәсәбәтен ачыклау бик әһәмиятле. М. Акмулла иҗаты бу яклап фәнни һәм гамәли анализ ясау, дөрес нәтиҗәләргә килү өчен колачлы, төрле аспектлы хәзинә. Ул кайбер классик шагыйрьләребез кебек халыкка язмача гына мөрәҗәгать итмәгән, киресенчә, шигырьне ул нәкъ менә сөйләп ышандырыр өчен язган. Шул ук вакытта кайбер чичән, акыннар кебек язмыйча гына да чыгыш ясамаган. Аның иҗатында язу белән әйтү (сөйләү) мөкәммәл рәвештә, органик үрелә алган.

Кызганыч ки, бу феномен әлегәчә өйрәнелмәгән, риторика фәнен кӧтеп яткан. Хәлбүки, бу – риторика фәненең беренче бурычыдыр. Сӧйләү дигәндә риторика әйтү чараларын (тавыш-интонацияне) гына түгел, паралингвистик (ым, ишарә, хәрәкәт, чичән-ораторның үз-үзен тотышын һ.б.) чараларны да күз алдында тотарга кирәк. Менә шушы чараларның органик бердәйлеген, синтезын сӧйләм шарты категориясе буларак нәкъ менә риторика ӧйрәнергә тиештер дә.

Мифтахетдин Акмулла чичән-ораторлан таләп ителә торган менә шул тӧп сыйфатка ия талантлы шәхес була. Аның тәрҗемәи хәлен һәм иҗатын шактый тӧпле ӧйрәнгән бүгенге галимнәребез менә ни ди: “Акмулла үзенең холкы, фикерләве, эш-гамәле белән шагыйрь, чичән табигатьле. Ул уйлаган-кичергәннәрен яшермичә әйтергә, бәхәсләшергә яраткан. Чыганаклар аның сӧйләшергә “маһир” булуын, җырлавын, үзенең һәм үзгәләрнең күп кенә әсәрләрен яттан белүен телгә алалар” (*Миңнегулов Х.* Дӧньяда сүземез бар... 336 б.).

Мондый нәтиҗә, әлбәттә инде, чичән замандашларының бихисап истәлек-хәтирәләренә таянып гомумиләштерелгән. Миндә дә бер хәтирә саклана: “Учалы тирәсендә сабан туенда сәсәннәр белән ярышып, үзенең шигырьләрен сӧйләгәнен ишеткәнем бар иде “, дип сӧйләде Башкортстанда бер агай.

Шулай да бу хакта иң дәлилле, риторика фәне ӧчен үтә әһәмиятле күзәтү ул Ризаэтдин Фәхретдиннеке. Без инде аның эчтәлеген бәян иткән идек. Шул тасвирнамәдән Акмулланың чичән-шагыйрь-оратор буларак чын йӧзен шактый тӧгәл күзаллап була. Р. Фәхретдиннең бу язмасын шушы яссылыкта кабат ӧйрәнеп чыгарга кирәк.

Бүген исә безгә чичәннең мирас булып калган язма хәзинәсеннән аның риторикасы чаралары синтезын күзаллау ӧчен мисал-үрнәкләрне бӧртекләп барлау бурычы тора.

“Шигырьне сӧйләр ӧчен яза иде...” Менә бу хакыйкать тикшеренүчегә методик ачкыч була ала.

Шулай ук әйтергә уйлаганын яисә әйткәнен язган да бит! Димәк, язу процессы да әйтү белән бәйле булган, дип фаразлыйбыз. Нигез дә бар. Мәсәлән, тӧрмәдә утырганда ул еш кына **мӧнәҗәт жанрын** сайлаган, ягьни кӧйләп сӧйләү (җырлау) алымын. Бу уңайдан бер факт игътибарны җәлеп итә. Ике мӧнәҗәтен ирекккә ул мәдрәсә укучысы Хафиз хәлфәгә адреслап чыгара. Хәлфәгә язган хатыннан Акмулланың мӧнәҗәтне ничек аңлавы күренә: “Мелла Хафиз! Сез ләтафәт вә фәсахәтдән беркадәр миһермәндсез”. Бу текстан *ләтафәт* һәм *фәсахәт*не матурлык һәм нәфис сүз дип аңлыйбыз. Шагыйрь дә

мөнәҗәтне нәкъ менә сөйләр (җырлар) өчен язылган нәфис сүз әсәре дип аңлаган. Аңлап кына калмаган, сөйләмен оештырганда бу закончалыкны гамәлгә ашыру чараларын да күргән.

“Акмулла шигырьләрен бастырып чыгарудан бигрәк, халык арасында үзе укыр, яттан сөйләр өчен язган. Менә шуңа, күрәсең, аның әсәрләрендә ишетер колакка ятыш булмаган нәрсәләр, ритмик чатанлык күренеше юк”, дип кистереп әйтә аның иҗатын бөртекләп өйрәнгән Ә. Харисов (*Харисов Ә.* Башкорт халкының әдәби мирасы. 345 б.).

Икенче бер галим моны фәнничәрәк төшендерә: “...беренче юл белән өченче, икенче юл белән дүртенче юл рифмалашып килгән (халык иҗаты үрнәгендә. – *Н.И.*). Монысы гына җитмәгән: шигырьдә һәр икенче юлның башында һәм уртасында үзара рифмалашып килгән тагы икешәр сүз бар. Логик басым да, эмоциональ басым да менә шушы өчәр рифмалы сүзләргә төшә, һәм алар әсәргә аеруча көч, музыкаль аһәң бирә...”.

Әйтү – язу гармониясенә янә бер мисал:

Кайгы-хәсрәт тарта-тарта башымда һуш калмады,
Гомречендә булмадык бер кайгы-хәсрәтдин җода.
Бары гомрем көя-көя йөздә нурым калмады.
Ялгыз булмаганымын бер газиз җанымдин җода.

Чын мәгънәсендә җырлап тора! Чыннан да әйтү – сөйләү – көйләү максатында язылган. Монда чичәннең синтагмага, ягьни әйтмә сөйләмгә, күнеккән булуы, тотлыкмыйча, шома сөйләү өчен моны язуда да чагылдырырга омтылуы ачык күренә.

Синтагма шундый көйле, аһәңле булсын өчен шагыйрь төрле манипуляцияләр ясый: Булмасын “мөселманмын” дигән *корат* (коры ат, бары исем генә); кай китаб ул кешене мөселман *дир* (дияр); әле генә китерелгән мисалда – ***гомречендә*** булмаган... (гомер эчендә) һ.б.

Сүзтезмәне язганда да әдәби тел нормалары, аның эчке законнары (сингармонизм, басым, ялганмалылык, тәртип, аһәң һ.б.) сакланырга тиеш, ә аларны чын-чыннан гамәлгә ашыру, саклау мөмкинлеге синтагманы әйтү барышында тәгәлрәк саклана. Мәсәлән, шагыйрь менә бу очракта сингармонизм законына ничек тугъры калган: “*Бу айтканым* китабка хилаф имәс...”, “Җан калтырап, *кан-җас* түгеп зарлагандай...”.

Язу – әйтү нисбәте, закончалыгын шагыйрь лексик-грамматик категорияләрне кулланганда да саклауга ирешә. Әйтик, нигә ул күпчелек шигырьләрендә “башын*дан”*, “башын*дин*” дип язса да, еш

кына “башын*нан*” рәвешен дә куллана. Әлбәттә, бу С.Ш. карап куллану, ягьни әйтмә сөйләм таләбенә буйсыну.

Алынма берәмлекләрне куллану да шуның белән аңлатыла. Чын язма шигырьләрендә гарәп, фарсы алынмалары өстенлек итсә, турыдан-туры гади халыкка мөрәҗәгать иткәндә шушы төбәк, шушы катлам даирәсе еш куллана торган урыс алынмаларын, башкорт шивәсе берәмлекләрен, казакъ теле сүзләрен куллана: “Кирәк солтан булсын, кирәк – *император...*”; “*Салдат”, “чинауник”, “әфисәр”, “кантон”, “наград”, “бырат*” һ.б.

Әдип аларны да ана теленең башка берәмлекләре рәтендә сыгылмалы, көйле ишетелерлек итеп тел законнарына буйсындыра. Әлбәттә, ул инде башкорт, казакъ шивәсе элементларына да шундый таләпләр куеп эш иткән.

Бу бүлекчәне дә йомгаклап, әдип шигырендәге бер детальгә игътибар итик.

Гыйлемең зур, йәшең өлкән ага булсаң,
Сөйләшеп кара син бер энең белән...

Димәк, Акмуллача әйткәндә, кешене аңлау, аңа нидер төшендерү, ышандыру өчен аның белән сөйләшергә кирәк.

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ СУРӘТ КОЛАЧЫ

2003 елның 20 мартында “Г. Ибраһимов һәм татар мәгарифе” дигән темага фәнни-гамәли конференция булган иде. Анда катнашырга чакыруны теләп тә, шул ук вакытта дулкынланып та кабул иттем. Журналист осталыгына караган дәресләремдә Галимҗан Ибраһимовның иҗатын мул куллану тәҗрибәсен туплавымнан бүтән коллегаларыма да өлеш чыгару мөмкинлеген сизеп, докладка алынырга булдым. Тик уйлану да материал туплау да берьюлы ике юнәлештә китте: Г. Ибраһимов әсәрләрен мәктәптә татар телен укытуда куллану һәм югары уку йортында стилистика һәм риторика фәнен укытуда куллану. Бу конференциядә күбрәге укытучылар, мәгариф хезмәткәрләре катнашканга, докладымны “Г. Ибраһимов әсәрләрен укучыларның сөйләм культурасын үстерүдә файдалану” дип атадым. Икенче юнәлеш доклад өчен тезислар сыйфатында әзерләнде. Бүген укучы игътибарына икесен дә тәкъдим итәм.

Татар телен дәүләт теле итеп рәсмиләштерү, аның шушы сыйфатына ирешү максаты телебезгә, аралашу чарасы, куллану коралы буларак, моңарчы беркайчан куелмаган таләпләр куйды. Әмма безнең әле өстебезгә төшкән менә шушы җаваплылыкны тулысы белән, төбенә чаклы аңлап бетерә алганыбыз юк, күрәсең, югыйсә, бу юнәлештәге беренче изге кануннарыбызны – Татарстан халыкларының телләре турындагы Законны һәм Дәүләт программасын үтәүдә унбиш ел буена мондый гына нәтиҗәләргә ирешер идек мени?! Мәктәптә дә тамырдан үзгәрешләр булырга тиеш иде бит.

Тамырдан дигәнебез нәрсә?! Безнеңчә, бүген мәктәптә һәм югары уку йортларында ана телен өйрәнү катгый-мәҗбүри өч буынлы методик нигезгә корылырга тиеш.

Беренче буында ана теленең төзелеше, ягъни грамматика, лексикология бүгенге куллану ихтыяҗына җавап бирерлек дәрәҗәдә өйрәнелә (1–5 сыйныф); икенче буында тел ярдәмендә (һәм телдән башка чаралар ярдәмендә) сөйләм оештыру закончалыклары, шәхси һәм күмәк сөйләм төрләре үзләштерелә (6–9 сыйныф), өченче буын ул телнең һәм сөйләмнең иҗтимагый хәлен, ягъни социолингвистика өлкәсен өйрәнү (10–11 сыйныф).

Галимҗан Ибраһимовның фәнни, әдәби-публицистик һәм иҗтимагый эшчәнлеге – менә шушы системаның һәр буынының нәзари нигезләрен дә, гамәли нигезләмәләрен дә бердәй колачлаган бербөтен күренеш. Бу – бик сирәк очрый торган уникаль бер милли хәзинәдер. Татар телен һәм нәзари, һәм гамәли яссылыкта әлегедәй өч буынлы системаны колачлардай тагын кайсы галим-әдипне тәкъдим итеп булыр иде? Каюм Насыйри, Гомәр Бәширев, Хәсән Сарьян, Суфиан Поварисов... Тик алар да бу системаны Галимҗан Ибраһимов кебек бөтенлекле-түгәрәк итеп колачлый алмаган.

Галимҗан Ибраһимовның шушы системага муафыйк иҗади юнәлешләрен барлау, әлбәттә, бер язманың бурычына сыя алмый, аны бик кыскача гына барлап чыгу да әле киләчәк эше. Әйтик, остазның тел төзелешен өйрәнү, укыту методикасына, тел тарихына караган хезмәтләрен санаганда, аның бу юнәлештәге һәм берникадәр сөйләмият-өслүбият һәм социолингвистика юнәлешендәге хезмәтләрен күрсәтеп, аларга гомуми бәя биргән хезмәтне – академик Мирфатыйх Зәкиевнең Галимҗан Ибраһимовның сайланма әсәрләренең 8нче томына язган "Галимҗан Ибраһимов – тел галиме" мәкаләсен искә төшерү белән генә чикләнергә туры килә. Әдипнең бу ике юнәлештәге

эшчәнлеге һәм хезмәтләре соңгы вакытта якланган диссертацияләрдә дә тәфсилле чагылыш тапты.

Галимҗан Ибраһимовның татар телен куллану, ягъни сөйләмият, өлкәсенә керткән өлешен исә ике юнәлештә күзалларга кирәктер: беренчесе, тел куллану, сөйләм нәзариясе нигезен салган хезмәтләрен барларга, өйрәнергә, дәрестә кулланырга вакыт. Без әле генә әйткән өч баскычлы укыту системасын Галимҗан Ибраһимов 1913 елда ук болай тасвирлый: “Тел вә әдәбиятне мәктәптә ничек укыту мәсьәләсенә килсәк, монда, педагогиканың гомуми кагыйдәсенә бинаән һәрнәрсәдән элек җиңелдән авырга, кисәктән бөтенгә күчү тәртибе ригая ителәдер (игътибарга алынадыр). Шуның иҗабы белән (кушуы белән) тел вә әдәбият дәресләре биш дәвергә бүленәдер. Бу бишнең һәр кайсы аерым вә үзенә бер фән шәкелен (формасын) ала да, соңрак һәммәсебер бөтеннең кисәкләре рәвешендә бер-беренә багланалар...”. Өчесе дип галим имляны (фонетика), сарыф (морфология), нәхүне (синтаксис) саный, бишенчесе итеп галим “”нәзәрияте әдәбия”не атаган, аны төрекләрнең “кавагыйде әдәбия”се (әдәбият кагыйдәләре), “бәлягате госмания”се (госман телендә матур сөйләү, язу), урысларның “теория словесности” (сөйләү теориясе) белән чагыштырган, асылын болай бәян иткән: “...зур тел вә әдәбият тәгълимиянең бер кисәге, имля, сарыф, нәхүнең дәвамыдыр. Ләкин бу инде анларның тәмам диярлек үсеп җиткән агаларыдыр. Әүвәлге өч дәвер җөмлә кисәкләрен карады. Бу дүртенчесе исә әдәбиятнең бөтен вә мөстәкыйль иҗазәләрен (җөмләләрен) тикшерә. Нәхү дәвамы булган бу фәндә, мәгълүм ки, хикәя, роман, тамашалык әсәрләр, өслүб (стиль), бәлягать (матур сөйләү, язу) вә шуңа охшаш хәлләр сөйләнелә”.

Сүз, әлбәттә инде, сөйләм фәне – сөйләмият турында бара. Моннан берничә ел элек без аны күнегелгән, ятышлы терминнарга (әдәбият, шигърият, исламият һ.б.) охшатып яңачарак атадык. Эш исемдәмени, җисеме булсын! Ә җисемен, күрдек, Галимҗан Ибраһимов шактый төгәл билгеләгән.

Икенче юнәлеше һәм иң әһәмиятлесе шунда ки, татар теленең кулланыш, ягъни сөйләм нәзариясенең үзе билгеләгән башлангыч нигезләрен үк Ибраһимов үзенең гамәли иҗаты белән беркетә, дәлилле килгән. Ана телебезне төрле өлкәдә, төрле стильдә куллану тәҗрибәсе ягыннан да Галимҗан Ибраһимов кебек колачлы әдип тагын бармы икән! Бу яктан да, ягъни телне куллану өлкәсен өйрәнү өчен дә, остазның иҗаты төзек, тулы, эзлекле бер система тәшкил итә. Ул татар әдәби теленең барлык сөйләм төре, стильләрендә (матур

әдәбият, публицистика, фәнни, рәсми, эпистоляр һ.б.) иҗат иткән; алай гынамы, аларның күпчелегенә нигез салган, камилләштергән. Шунысы игътибарга лаек, ул иҗат төре буларак кайсы да булса әдәбият төренә, стиль тармагына өстенлек бирмәгән, һәркайсының үзенчәлеген, нечкәлеген, башкалардан аермасын тоеп эш иткән.

Искә төшерик: Ибраһимовта әдәбият төшенчәсе астында телне чара-корал итеп файдалана торган теләсә кайсы объектны (телдән сөйләү хаҗәте, фольклор, фәнни чыгыш, информациянең һәм пропаганданың язма һәм әйтмә чаралары, ягъни сөйләменең һәр төре һ.б.) күздә тотыла.

Моны истә тоту бик мөһим: моңарчы телнең төзелешен (грамматикасын, лексикасын) өйрәнгәндә әдипнең матур әдәбият әсәрләре генә кулланылды, ә телнең кулланылышын – сөйләмиятне – төпле, системалы өйрәнү ихтыяҗы барлыкка килгән шартларда ул иҗат иткән барлык төр әдәбиятне да, барлык төр стиль катламнарын да өйрәнү, дәреслек, кулланмаларга җәлеп итү мөмкинлеге туа.

Барыбызга да мәгълүм, моңарчы телнең төзелешен генә түгел, аны куллану өлкәсен өйрәнгәндә дә, мәктәптә өйрәткәндә дә башлыча матур әдәбияткә таянылды, язма сөйләм үрнәкләренә; кайсы гына дәреслекне, кулланманы искә төшермәгез, барысы да образлы әдәбият белән шыплап тутырылган, ә көндәлек яшәебездә бу төр фикерләүгә күнеккән кешеләр бармак белән генә санарлык. Көндәлек сөйләм, нигездә әйтмә сөйләмнән, конкретлыкка, документальлеккә нигезләнгән (публицистика, рәсми һ.б) стильләргә корыла. Укытуны шушы нигезгә корганда Галимҗан Ибраһимовның күпкырлы, төрле стильле иҗаты алыштыргысыз чыганак-хәзинә була ала да.

Аннары, язучының тел куллану тәҗрибәсе моңарчы норматив-стиль юнәлешендә өйрәнелде. Ягъни әдипнең әсәрләрендә телнең теге-бу категориясе, беренче чиратта, телнең тасвирлау-бизәкләү, образ тудыру чаралары ничек-ничек кулланыла дип барланды. Әйе, бу юнәлештә әдәбият һәм тел фәне аз эшләмәде. Шул хисаптан Ибраһимов әсәрләре дә шактый төпле анализланды. Без, беренче чиратта, Суфиян Поварисов хезмәтләрен истә тотабыз. Аларны да инкарь итәргә ярамый.

Әсәрне сөйләм максатында анализлаганда алгы планга функциональ-стиль мөмкинлекләрен барлау чыга. Монда инде әдип телнең теге-бу категориясен, чарасын сөйләмнең нинди бурычын үтәү өчен куллана дип өйрәнү зарур. Моңарчы өйрәнелгән хезмәтләрдә, әйтик, телнең образлы чараларына (эпитет, метафора, аеруча чагыштыру)

Ибраһимовның матур әдәбият әсәрләреннән бихисап мисал китерелә. Тик менә шул чараларның нинди функциональ максатта кулланылуы тирәнтен ачылмый. Әйтик, Галимҗан Ибраһимовның “үз” чагыштырулары бар: мәсәлән, *“Бер самавыр кайнарлык вакыт үтмәгәндер...”*, яисә “*суланган йоннан тигәнәкне тартып алгандай...*”. Стилистикага караган хезмәтләрдә болар теркәлгән, әмма сөйләм мотивына бәйләп, ягъни функциональ планда төшендерелмәгән, ә бит төрле текстта алар төрле максат-бурыч ала, хәтта шуңа карап формасы да үзгәрә: *“бер самавыр кайнап чыгарлык...”*.

Күренә ки, язучының әсәрләрен норматив-стилистик яссылыкта анализлаган хезмәтләргә, аларны функциональ-стилистик максатта файдалануны күздә тотканда, берникадәр тәнкыйтьчел дә карарга кирәктер. Бер генә мисал (бер уку кулланмасыннан өзек): “Язучы һәр предмет, күренеш, вакыйганы сүзләр аша укучы күз алдына китереп бастыра. Моның өчен ул образ тудыру чаралары сайлый. Г. Ибраһимов, мәсәлән, базар күренешен тасвирлаганда, менә нинди *эпитетлар* (ассызык безнеке. – *И.Н.*) куллана: “Базар кайный. Әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән товарлар белән тулган кибетләрнең алдында, умарта корты кебек, халык шаулый (диккать итегез әле. *–И.Н.): кысык күзле, түбән кашлы, кара-соры чикмәннән* чувашлар*; киң маңгайлы, елгыр күзле, ак чикмәнле* кара башкортлар; күбесе *итекле, картузлы, кыска киемле, зур сары сакаллы, озын мыеклы* руслар; *көмеш тәресен ялтыратып йөргән озын кара киемле* поплар; *ак йөзле, ак сакаллы, кара казакилы, итекле яки читеклекәвешле* сәүдәгәр татарлар,– һәммәсе алалар, саталар, алдыйлар, алданалар, үзара гөж киләләр ” (*Поварисов С.* Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү).

Мәкалә авторы эпитет дип ассызыклаган дистәләрчә гади сыйфат, рәвешләрнең берсе дә эпитет түгел. Эпитет бит ул күчерелмә мәгънәле берәмлек, образ тудыру чарасы, ә болар конкрет-номинатив сыйфатлар, хәтта атама, терминнар. Бу очракта нәкъ шулар кирәк тә, язучы бит төгәллек, конкретлыкка, хәтта документальлеккә ирешү максатын куйган. Һәм моңа бик оста ирешкән дә.

Хәер, сөйләм оештыруда мәгълүм мотивка ярашлы тел чарасын сайлап алуны өйрәтә торган мисал-күнегү эзләгәндә бу очракта мисалны әдипнең башка төр әсәрләреннән, аерым алганда, документаль әсәрләреннән, тәкъдим итү хәерлерәк булыр иде. Инде әйткәнебезчә, Галимҗан Ибраһимовның иҗади мирасы ифрат та бай.

Түгәрәкләп әйткәндә, бүген татар телен мәктәптә һәм югары уку йортларында дәүләт теле дәрәҗәсендә укыту өчен, беренче чиратта аны киң куллану максатларында укыту өчен, бөек әдипнең иҗат җимешләрен тулысынча файдалану бурычы галимнәр алдына да, укытучыларыбыз алдына да бөтен кискенлеге белән килеп баскан.

Хәзер килеп, килешкәнебезчә, югары уку йортларында татар риторикасы дәресләрендә нәфис сүз осталыгына өйрәнүдә Галимҗан Ибраһимов тәҗрибәсен файдалану мисалларын барлый башлаганчы, аның телне өйрәнү системасын ничек күзаллавын янә искә төшерик: бу системаның соңгы буыны дип, телне өйрәнүнең барлык буыннарын-фәннәрен санап чыкканнан соң, ул әдәбиятне атый. Матур әдәбиятне түгел. Әдәбият аныңча фикерне ана теле ярдәмендә язып белдергән барлык язма текст. Кабатлыйм: матур әдәбият кенә түгел. Димәк, әдәбият ул, иң беренче чиратта, тел өлкәсе. Телне куллану өлкәсе. Сөйләмиятне өйрәнү чыганагы.

Матур әдәбият барлык төр язма чыганак арасыннан сөйләм төзергә өйрәтү үрнәге була аладыр. Бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов иҗаты. Ник дигәндә, сөйләм мотивлары (сөйләм иясе, адресаты, ниятe һәм шартлары) аерым стиль-сөйләм төрләрендә аралашу-аңлашу максатына бәйле рәвештә бер юнәлешлерәк, бер яклырак була, димәк, тел чаралары да аерым юнәлешле, таррак күләмле була. Ә матур әдәбият әсәрләренең мотивлары, тормышны ничек бар шулай, дөрес һәм реаль чагылдыру максатын куйганда, тулырак, колачлырак була, Димәк, шул максатка муафыйк-ярашлы буларак тел чаралары да (экстра-, паралингвистик чаралар да) төрле тармаклырак, төрле стильлерәк, ягъни байрак була.

Сөйләм иясен алсак, бу очракта ул әдип-язучы, укучыга ихласый мөнәсәбәттә булуы бик мөһим. Шунда гына аның сөйләме үтемле, тәэсирле булыр. Ә ихласлык ул авторның башкалардан аерым үзенә генә хас чара-алымнары булуында да, беренче чиратта, әйтүдә тавышының-интонациясенең үз төсмерләре, ә язуда исә фикерләү рәвешенең, мантыйгының үзенчәлеге, ягъни фикерләвендә һәм аны бәян итүдә тел һәм телдән башка чараларны куллану үзенчәлеге – укучы көткән, күнегеп, тәэсир чарасы дип кабул иткән шәхси иҗат үзенчәлекләре булырга тиеш.

Иң беренче, әдипнең кайсы гына әсәрен укыма (матур әдәбиятме ул, публицистик чыгышмы, фәнни яисә рәсми-тарихи язмамы), авторның үзен тоясың: аның нәкъ менә шушы теманы, шушы өлкәбелгечлекне энәсеннән-җебенә белүен, шушы мәсьәләне төшендерү

өчен телнең барлык нечкәлек-мөмкинлекләрен белүен, сиңа шуларны бәян итәргә, үгет-нәсихәт бирергә аның үз тәҗрибәсе, осталыгы, үз хокукы барлыгын укучы тоя килә, шул тоюдан уңай хис – канәгатьләнү – ала.

Язучының сөйләм иясе буларак үзен тоемларга тиешлеге турында Г. Ибраһимовның үзенең бер фикере искә төшә: Шәкерт-журналист И. Биккулов турында ул болай ди: “Һәр язуында нидер сизелә, ләкин аның “үзе” кайда икәне, гомумән аңарда “үзе” дип атарга мөмкин бер нәрсә бармы икәне хакында ачык бер дәлил бирә алмыйм. Кайбер вакыт шулай хәтергә килә ки, аның бөтен язулары каләм фабрикациясе түгелме икән, дип уйлыйсың. Ләкин диккать иткәндә аның “үзе”нә ишарәләр бар. Миңа ул “Казан журналисты” булыр (аның псевдонимы), аның “үзе” киләчәктә шул исем белән тәгъбир ителергә тиеш бер мәгънә рәвешендә калыпланыр кебек хис ителә (*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: Әдәбият һәм сәнгать турыда мәкаләләр, хезмәтләр. 214 б.).

Әдипнең сөйләм иясенә карата таләпләре иң әүвәле аның персонажларының сөйләмендә ачык чагыла. Менә балта остасы сөйләме: “Минем атай,– ди (Гыйлаҗи),– гомер буена балта остасы булса да, кулга алырлык коралы юк... Минеке алай булмас... Мин балтаны корычтан эшләтәм. Ул агачны гына түгел, *каты ташны да кыеп төшерер.* Минем пычкыларым, өтергеләрем, ышкыларым кул тидерү белән үзләре йөреп торырлар... Мин Сәйфи карт кебек күземне кыйшайтып, башымны бөгеп, төзләп маташмам... Минем үлчәүләр *ике бүрәнә арасына ялгыш кысылган яфракны да сизәрләр.* Беләсеңме!” (*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. 2 т. 429 б.).

Янә бер өзек – монысы исерек кеше сөйләме: “Гали сикереп тора да авызыннан күбекләрен чәчеп Фазыйлны кочаклап үбәргә азаплана... Юк, юк,– ди,– *син* китмә... *Син* киткәч... дөньяның яме бетә, күрке бетә. *Син... син* безнең кояш бит, Фазыйл туган! *Эчмә дисәң, эчмим... бетте... Сүзем юк... Сорамыйм...* Шулай да бер генә, менә шундый нәни генә чокыр эчәргә рөхсәт бир инде!– ди. Үзе хахылдып көлә” (2 т. 428 б.).

Авторның сөйләм иясен тоемлавы, шушы тоемлавы белән укучыга тәэсир итәргә теләве аның тел чараларыннан максатчан файдалануы белән ирешелә. Беренче мисалда тасвир чараларыннан **гротеск**, икенче мисалда **кабатлау, сегмент, инверсия, парцелляция** кулланыла. Ике мисалда да сөйләм ияләре бер-берсеннән үзенчәлекле интонация белән дә аерыла.

Төп мотивлардан сөйләм ниятенә күчик. Бу риторика сәнгате өчен иң төп мотивлардан. Риторик сөйләмнең төп максаты – ышандыру (инандыру); барлык тәэсир чаралары да шушы максатка юнәлдерелә. Ничек ышандырып була? Беренче чиратта, сүз алып барыла торган предмет, күренеш, вакыйганы ап-ачык күз алдына китерерлек итеп иң төгәл конкрет чаралар белән бәянларга, тасвирларга кирәк. Ул конкретлыкны белдерә торган лексик берәмлекләр, көнкүреш сүзләре, атамалар, терминнар: "Гөлбану зур *җилпучы* белән йөгереп *келәткә* барды, *өсәктән* тутырып *арыш оны* алды да *аш өенә* керде. Анда *сәке* өстенә киң *куна тактаны* иплән куйды, *он вагын* туздыра-туздыра иләде, өлкән *юкә агач савытка* икмәк изде, чамалап *тозын* салды да өстен *чүпрәк* белән каплап куйды" (3 т. 533 б.).

"Өлкән килен Фәүзия келәт башыннан *печән тырмаларын* төшерде, зурлы, кечкенәле *сәнәкләрне* ыргытты, чүмәлә тарттыра торган *арканнарны* сузып ташлады; кыекның буена өрлеккә уңайлап куелган зур, озын *кибән сәнәген* иплән алып бирде, Закир белән уртанчы ул Фәсхи озын арба тирәсенә *камытларны, йөгән, нукта, дилбегә, арканнарны* таратып, юнәйтергә керештеләр. Өлкән ул Алтынбай аш өенең сәке астыннан *пычкылар, ышкы, өтерге, балта, чүкеч, бораулар* чыгарды, утынлыктан төз агачлар сайлап алды да тырмаларны төзәтергә тотынды" (шунда ук).

Табигать күренешләренең чынбарлыктагы реальлеген дә ышандыру әһәмиятле. Моңа үзенә бер лексик төркем берәмлекләр табыла: "Исәнбикә – өчпочмаклы бер *култык болын*. Аның *төньягы* ташлы, чокырлы тауларга терәлә. Бу таулар бераз гына сөзәкләнеп, дулкынланалар да кинәт баскычланып ак башлары белән күккә таба күтәрелеп, менеп китәләр. Болынның *көнбатыш ягы* аз гына калкулана да киң *арыш басуына* тоташа. *Көньягы* белән *көнчыгыш* якларын бераз әйләнеп килеп *Үзәк елга* юып үтә. Монда яшел *таллар* үсәләр, бер җирендә начар селкенчәк *сазлык, түндәклек,* бер урында, кечкенә *тамак* белән кереп, кечкенә түгәрәк, ләкин тирән үк бер *күл* ясап ала" (3 т. 539 б.)

Эш барышын, хәрәкәтне күрсәткәндә төгәллеккә ирешү – зур осталык билгесе ул. Менә бу күренештә һәр сүзгә игътибар итегез әле: "Рәхәт соң, валлаһи, бу машина белән ашлык сугулар! Ындырның бер башыннан икенче башынача тезелешеп, *"без – кем!" дип мактанышып,* бөтен авылга югарыдан карап торган биек кибәннәр кими баралар, каядыр югала баралар! Бер егет кибән башыннан *көлтә ыргытып тора*, ике фурман өзлексез *ташыйлар*; ике-өч малай бөтен авыл яңгыратып, *"һайду... һау... ууу" дип,* сигез атны бер түгәрәк эчендә *шартлатып*

*куалар***.** Машина бертуктаусыз: *“Взз, вззз, вррр”, дип сызылдап, выжылдап әйләнеп тора,* көлтәне бер яктан *йота бара,* икенче яктан *саламны кагып, алга этәрә тора,* шул җирдә хатыннар тырмалар белән ашлыкны *тартып ала торалар,* бераз гына арырак зур җилгәргеч машина *“быз... гыз...” килеп, орлыкны кибәктән аера тора.* Бер читтә таза егетләр, бу якын торган кызыл бодай орлыкларын *йөккә төяп,* таш сарайларга *озата торалар...”* (2 т. 452 б.). Биредә гап-гади **битараф сүзләр** белән бергә *(ыргыта, ташый, куа, кага, озата* һ.б), **терминнарга** *(кибән, көлтә, орлык, тырма, машина, җилгәргеч* һ.б.), **аваз охшашлыгыннан ясалган неологизмнар**га кадәр (*һаууу, вррр, быззз һ.б.)* тасвир-сурәт чарасы буларак файдаланылган.

Риторикада ышандыру өчен кулланыла торган алым-чараларның иң мөһиме, мөгаен, дәлилләү. Татар психологиясе фәне әле тиешенчә үсеш алмаганга күрә, нәкъ менә дәлил чаралары фәнни нигездә барланмаган, системага салынмаган. Моны барларга риторика фәне үзе алынырга тиеш тә бит, ләкин бүгенгә безгә дә кайбер мисалкүнегүләр белән чикләнергә кала.

Дәлилләү уйлау процессында ук “бөреләнә” ала. Менә кырыкмыш тайны уйлап-ниятләп “үзгәртүнең” кирәклеген дәлилләү. Кырыкмыш тайның ялын, койрыгын кыркалар... “Мин алай ямьсез итеп боздырасым килмәде: маңгай чәчен *күзенә төшмәслек кенә ясап, тип-тигез* кистердем. Бу хәзер, алдан караганда, рус боярларының *матур кызлары кебек* күренеп тора. Ялны да, башкалар кебек, бөтенләй үзгәртмәдем: бер чирек кадәрлерәк калдырып, *үзеннән-үзе дулкынланып, күперенеп тора торган* итеп төзәттердем генә.

Әнидән алып, ул ялга ике яклап *чуклар, тасмалар тактым*. Койрыкны да бүтән кешеләр *кәбестә күчәне кебек, ялангыч беләк кебек* ямьсезләп кыралар. Моңа да якын җибәрмәдем: сөяктән түбән ягын гына кистеләр дә матурлап *түгәрәкләделәр*. Кырыкмыш тайлар, бигрәк тә язгы сабан өстендә, *йолыккан карга кебек* чырсыз булып йөриләр. Минем алмачуар исә кунакка барырга ясанган *бояр егете кебек чибәр* булды” (2 т. 522 б.).

Ышандырдымы?! Яратып башкарган берәр эш-гамәлегезне шулай тасвирлап карагыз әле. Ниндиерәк сурәт чаралары табып кулланырсыз икән! Биредә күбрәк **чагыштыру, эпитетлар, хис белдерү лексикасы** өстенлек итте.

Дәлил – ул күз алдына конкрет, тәгаен китерү чарасы. Беренчедән, моның өчен документаль дәрәҗәдәге реаль чынлыкка ирешергә тырышыла. Факт, детальләр белән. “Теге данлыклы күк бия

дә килеп җитте. Күрәгә шуңардан күзләремне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә (кешегә охшатып күзаллау. – *И.Н.*). Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк дигән бөтенләй арсланныкы – шундый киң, шундый нык күренә (малайларча кыска, кискен әйтү. – *И.Н.*). Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым: алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар, уйнап, ялкынланып торалар. Өстенә кечкенә, кап-кара, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән” (2 т. 529 б.).

Шул ук вакытта автор дәлилне сурәт чарасын өстәп тә көчәйтә: “Алмачуарым бу арада *карап туйгысыз* булып чибәрләнде (Бу – тезис. Хәзер ул аны дәлилләр өчен сурәти аргументлар китерәчәк). Ял койрык *ефәкләнеп, дулкынланып* тора. Эч, *каеш белән тарттырган кебек*, нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде. Буе тагы да озыная төшкән кебек күренә. Аяк атлаулары шундый җиңел инде, әйтерсең ул *җиргә басмый,* бәлки, күзгә *күренми торган канатлары белән очып кына бара”.*

Шушы мисалдан файдаланып, уйланып алыйк әле: күпчелек каләм иясе мондый күренешнең сыйфатын бер штамп сүз белән бәяли: *матур.* Әгәр бу – дәлил икән, ул чын дәлил түгел, ясалма, ялтыравык кына, ышандырмый. Әгәр ул тезис икән, ул ышандырырлык сурәтләнеп, дәлилләнергә тиеш. Менә әлеге мисалдагы кебек.

Сурәт белән дәлилләү дигәндә, фикерне гап-гади сүздән башларга кирәк. *Чабышкы, чабу* сүзләре әлләни образ тудырмый да кебек. Ә менә дүрт җөмләле микротекстта *чабышкы, чаба алу, чабышкылык, чабыштырып, чабарга өйрәтәм, чабышкы ясыйм* сүзләре һәм сүзформалары бергә диярлек килү ул инде аваз аллетирациясе генә түгел, сүз-сурәт манзарасы булып та килеп баса.

Дәлил – мөрәҗәгать рәвеше була: “Әнә күрәсез: ул ничек көмеш тавышы белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный” (2 т. 519 б.).

Дәлил – аңлату (төшендерү) рәвеше дә бар: “Икенче яшькә чыкканда, бездә яз көне тайның ялын, койрыгын бөтенләй кыркалар: “кырыкмыш” ясыйлар” (2 т. 521 б.).

Каршы куеп дәлилләү: “Бик күп сөйләш тагын! Алай бик каршылансаң, Алмачуарны тотарбыз да урманга җигәрбез,– дип куркыталар. Моңа җавап кайтарырга сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр!” (2 т. 525 б.).

Бүтәннәр фикере аша дәлилләү рәвеше: "Алмачуар тай була, тик колын гына булмый икән. Дөньяны күп күргән, күп елкы асраган картлар колынның да, туганда башка төстәрәк булса да, әзрәк үскәч, алмачуарга әйләнәчәген алдан беләләр икән".

Күңеленә яткан бу дәлилне китергәннән соң автор үз фаразын-фикерен дә өстәп, дәлилне көчәйтеп тә җибәрә: "Туры бурлы булып туган кайбер колыннарның сабыйлык йоны бераздан соң, *җир өстенә сибелгән ак чәчәкләр яисә ак йөзгә чыккан матур кара миңнәр* кебек, тәңкә-тәңкә булып чуарлана башлый икән" (2 т. 505 б.).

Риторикада тагын **психологик дәлил** дигән төшенчә бар. Г. Ибраһимов әсәрләрендә без аларга еш юлыгабыз. Бер мисал асылында төшендереп карыйк: "Аның иң курыккан нәрсәсе дә шул аяклы малны таратып бетерүгә бәйләнгән иде, ахыры, җиңеп чыкты... Алтынбай болай куйды:

– Ике сыерны сатмый булмас,– диде. (Өйдәге хатыннар моңа каршы чыга. – *Н.И.*) Алтынбай энеләрен сыерларга да, хатыннарга да каршы аякландыра алды, көрәш ачык билгеләнде.

– Ул сыерларны кызгансак, алайса, базарга актык атларны чыгарабыз. Шулаймы, Закир?– дип энесенең күзенә карады. Хатыннарга сыер никадәр якын булса, ир крестьянга ат мең тапкыр якынрак, кадерлерәк иде. Закирнең күзе томаланып китте, миенә кан йөгерде, үзен белми сикереп торып, йодрык белән сәке читенә сукты, хәзер кыйнап ыргытырга әзер торган төс белән апасы Хәернисага йотылды:

– Син нәрсә? Закир атсыз калсын, дисеңме? Мине бәләкәй арба тартып йөри торган хәерче дип беләсеңме? Әйт, мине җәяүле хәерче итмәк буласыңмы?

Ирләр белән хатыннар, атлар белән сыерлар арасында озак барган бу ызгышның, көрәшнең азагы – атларның җиңүе белән бетте" (3 т. 567 б.).

Психологик дәлилнең янә элементлары санала алырдай кисәкләре була, мәсәлән:

1. **Көчәйткеч дәлилләр.** Үзләре берничә төрле:

– кабатлап көчәйткечләр: "*Яратам* мин үзебезнең авылны, бигрәк тә *яратам* авылның төньягын каплаган зур тауларны! Алардан да бигрәк *яратам* шул таулар өстендә мең еллар буенча шаулап утырган зур карт урманны" (2 т. 514 б.). Игътибар итик: монда сүзнең кабатлануы үзе генә дәлилне көчәйтми, ә кабатланган сүз көчәйткеч сүз (*бигрәк, бигрәк тә*) яисә бүтән чаралар (**кисәкчә, ымлык** һ.б) белән үстерелеп җибәрелә.

Яисә: “...Бу урманның гөрләп утыруы, бигрәк тә аның язгы кузгалагы, көпшәсе, җәйге чәчәкләре, исәбе-хисабы булмаган җир җиләге, кура җиләкләре. карлыганнары, бигрәк тә көзге чикләвекләре минем күңелемне ул урманга тарталар, аны йөрәккә якын, бик якын, бик сөйкемле итәләр...”. Бу дәлилне көчәйтә торган факт – ул *бик якын* кабатлануы гына түгел, ә бәлки аны көчәйткән, синонимга якын кабатлау *сөйкемле* сүзе белән гомумиләштерелүе белән, аннары, текстның аңа кадәрге *бигрәк тә*нең кабатлануы һәм дә якын, сөйкемле итә торган җиләк-җимешне конкрет санавы, аларның чыннан да күп, ишле булуы, шулай саналып күз алдына ачык килүләре дәлилне ышанычлы итә дә;

– **арттыру** (гротеск рәвешендә) **белән көчәйтү**: “Баһадирлар тагы түгәрәк мәйданда. Бөтен халык тагын, тыннарын да алмыйча, бу зур көрәшкә карап катканнар!” (2 т. 507 б.);

– **шикләнүле көчәйткеч**: “Авылыбызда бик череп беткән бер кара бай бар иде. Акчасы күп**,** *имеш,* күкрәкчә ясап, янында йөртә, *имеш, дип сөйлиләр* аның хакында” (2 т. 509 б.) (кеше сүзе, икелемикелелек, мөгаенлек белән көчәйтелә);

– **тезис** яисә **нәтиҗә рәвешле көчәйткеч**: “...Бердәнбер абыстай да түбән очның гармунчы Фәхригә ябышып чыга. Ул инде яшьтән башсыз кыз иде: аулак өй булса, биегән дә ул, җырлаган да ул, гармун тарткан да ул, егетләрне кертеп, аякларыннан түшәмгә асып, мәсхәрә кылган да ул...” (2 т. 509 б.);

– **каршы куеп көчәйтү**: “Дөрес, бу урман хәзер *безнеке түгел,* аны әллә ничек итеп безнең кулдан бер бай тартып алган, хәзер безгә аннан *бер чыбыркы сабы да алырга ярамый”* (шунда ук).

Ышандыру өчен татарның көлдерү (сатира, юмор) холкын белдерә торган чараларны куллану да нечкә осталык сәләтен сорый. Менә кайбер өзекләр: “Чех белән учредилка арасында булган оятсыз зинадан бер бала дөньяга килде. Уйнаштан туып, ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен ай үскән аждаһа, тиз арада төрле диннәрнең, төрле кавемнәрнең кара көчләрен үз тирәсенә җыйды да, кара болыт, куркыныч караңгы туфан булып, бөтен Себерне, Уралны каплап алды, Волга буена сузылып ятып, Мәскәүне йотарга авызын ачты... (2 т. 482 б.). Монда татар теленең чын мәгънәсендә образлы эпитет, метафора, метонимия, гротеск чаралары нәкъ үз урынында кулланыла.

Ясалма көлүнең асылын күрсәтү дә көчле бер дәлил була ала: “Сез нәрсә егетләр! Без – перлитарбыз дигәч тә, нигә ул чаклы масаясыз? Мин дә спекулянт түгел, буржуй да түгел. Мин дә сезнең кебек

үк, хезмәт кешесе бит! – диде. Үзе *ярарга тырышлый түбәнчелек катнаш бер тавыш белән хи-хи-хи итеп көлде.* Бөтен гомере буенча рустан, түрәдән, байдан куркып, болар алдында тәлинкә тотарга мәҗбүр булудан, һәркайчан боларга *ярарга, көләч йөз күрсәтергә, ягымлы сүз әйтергә көчәнүдән Җамалыйның җанында гына түгел, елмаюларында, көлү тавышларында ук шундый бер кимсенү катнаш түбәнчелек* ясалган иде...” (2 т. 162 б.).

2. **Бәхәс рәвешле дәлил**: “Бикьярлар – бик көяз халык. Алар турында тирә-якта: эчтән калтырар, тыштан ялтырар, дип көлеп сөйлиләр. Өйләрендә үзләре, алабута ашап, чабата киенсә дә, кунакта, мәҗлестә бик кыланчык булалар. Араларында күбе кырлайчылык, кырык тартмачылык, йомыркачылык, көмешчелек, йон тетүчелек, пимачылык, тегүчелек кебек төрле вак һөнәрләр белән дөнья гизгәнгә, телгә бик шомалар, мәсхәрәчеләр. Юк-бардан көләргә, шаяртырга, мыскыл итәргә бик яраталар...” Текстта алга таба арчилар белән бикьярларның бәхәсләре, шаярту, шуклыклары тасвир ителә (3 т. 525 б.).

Хәзер үзенә күрә бер йомгак сыйфатында әдипнең дәлилләү чаралары буларак аеруча киң кулланылган тасвир-сурәт чараларына, беренче чиратта телбизәкләренә, мисаллар китерик.

– **синтаксик фигуралардан кабатлау:** “Егет менә *шул* утта янды (автор гражданнар сугышы вакыйгаларын санаганнан соң). *Шул* көрәшләр, *шул* газаплар, *шул* каннар, *шул* каһарманлыклар эчендә кайнап, аның яшь йөрәге якты киләчәкнең матур көннәре өчен үзен бер көрәшче иттереп үстерү дәрте белән тулып ялкынланды. *Шул* дәртләр, *шул* өметләр аның гомер юлының якты маяклары булып алга тезелделәр” (2 т. 13 б.);

– **бөҗралап кабатлау**: “Садыйкны беләләр, *яраталар*. Авылның кияве итеп тә, җир-су алып бирешүдә юл күрсәтүче итеп тә. Иске Акташтан бу Байрак авылына күчү эшендә каладан Фәхригә булышлык кылучы итеп тә *яраталар* иде” (2 т. 15 б.);

– **эпифора рәвешле кабатлау**: “Әйтерсең, кемдер, кулына озын чыбыркы тоткан да, хайваннарны, тын алырга, туктап су эчәргә ирек бирмәстән, каядыр *куа да куа; куа да куа; куа да куа!”* (2 т. 457 б.);

– **үзгәртеп кабатлау** рәвеше: “Ул (Ай) бер генә минутка суык вә һавалылыгын азайтып, сәҗдәдән калыккан адәмнәргә *бер генә, тик бер генә* мәртәбә, сөеп иркәләп карый да, калын катлаулы кара болыт артына кача” (1 т. 221 б.).

Әдипнең төгәллеккә ирешеп дәлилләү чара-алымнарын сүзләрдән дә бигрәк, телнең аннан да кечкенә чараларыннан – аваз-

лардан, иҗек, ярдәмче берәмлекләрдән башларга кирәк иде. Менә татар теленең ялганмалык үзенчәлегеннән ул ничек нечкәлекләр таба: *шакылдата* (шакый), *аптырансам да* (аптырасам), *урынлашу* (урнашу), *мөңгердәү, дидертте, чишенмәлек, китмәк булды; ялгызак калдым; ашасыннан (аша).* Телебезнең агглютинативлык асылын ул архаизмнарда да тоемлый ("Залда тагын бер кызыксыну *уйганды")*, шулай ук үз неологизнарын иҗат иткәндә (ясаганда) да файдалана (*чишенмәлек* – гардероб, *хисап* – доклад) һ.б.

Дәлилләү барышында фикер конкретлыгы, төгәллегенә әдип лексик чаралардан **диалектизмнар** (*чобар, бавыргалык, чапчак, җизнә* һ.б.), шулай ук **алынмалар** *(партия, провокатор, комитет, полиция, боевик, отряд, мастерской, фабрик, реферат һ.б)* кулланып ирешә.

Сурәтләп дәлилләү максатында кулланылган **троп, метафоралар, телбизәкләр** һәр әсәрендә энҗе бөртекләре кебек җемелдәп-җемелдәп китәләр: "Бәхетең, туганкаем, – диде (Хәерниса), – хатының *харап уңган*, кул-кулга йокмый,– диде" (**оксюморон**); "Аэропланнан ташланган *бомба белән* һәлак булды" *(***метонимия**); "Үземне үзем белмәдем, шул якка *очтым"* (**метафра**); *Авызы колагына җиту; күзе уйный; мөгез чыгару; балавыз сыгу* (**фразеологизм***).*

ИЛ ҺӘМ ТЕЛ

(Сибгат Хәким шигърияте хәятендә)

Яраткан язучыңның тартып тору, тәэсир итү серен ачыклыйсы килү теләге аның әлеге укырга тартып торган әсәрен кабат кулга алгач башлана бугай. Мондый нәтиҗәгә мин Гомәр Бәширевнең, Афзал Шамов, Хәсән Сарьян, Гамил Афзал, Сибгат Хәкимнең әсәрләрен кабат-кабат укыганда килгән идем. Бу хакта фикеремне укучыларга җиткергәнем дә булды. Әлеге әдипләребезнең осталык тәҗрибәсен ачарга омтылуым да шушы фикердән соң гамәлгә аша башлады шикелле. Нәтиҗәсе күренде дә: кайбер язмаларым матбугатта урын алды.

Язучының тәэсир тылсымы нидән гыйбарәт? И-и-их, моны бер хикмәтле ачкыч белән борып җибәреп кенә ачарга-белергә иде дә бит, булмый шул; иҗат дигән могъҗизаның күпләрдән яшерен тылсымы шунда да инде. Һәр әдипкә, һәр каләм остасына карата, алай гына да түгел, һәр әдипнең һәр әсәренә карата үзенең серле ачкычы насыйптыр, күрәсең. Бу ачкычны табу, мөкиббән китеп укыган әсәреңнең сиңа йогынты ясау серен үзең ача алу – әсәрне уку ләззәтенең бер

өлешедер дә әле. Бүген мин Сибгат Хәкимнең шигырьләрен укыганда әдипнең тәэсир куәтен-көчен ничек-ничек тоя баруым, шул ачышка ничек-ничек куанып, ләззәт алуым белән уртаклашмакчы булам. Сер ачу – ул үзенә бер кызыклы, үзеңне дә танып белергә булыша торган, сәер бер хәләттер.

Уйлана, эзләнә торгач, күзем ачылды: Сибгат Хәкимнең осталык серенә ачкыч бер гыйбарә булган икән – яраткан язучым Гомәр Бәширевнең гыйбарәсе: “Кайда гына яшәмәсен кеше, нинди генә телдә сөйләшмәсен, аның бөек хөрмәт белән әйтә торган ике газиз сүзе бар: туган ил, туган тел”.

Шулай да бу гыйбарә чын ачкыч булып китсен өчен шагыйрьнең дә шундый эчтәлекле, мине тагын да очындырып, дәртләндереп җибәргән иҗат табышына юлыгуым кирәк булган икән:

Туган җирдән безне кем аерыр!
Туган ил һәм туган тел өчен
Гомерләрне хәтта кызганмадык...

Хөрмәтле укучым, бу юлларны язманың иң башында эпиграф дип хис итеп, кабат-кабат укып ал әле; һәр сүзенең мәгънәсен дә, шулардан җыелган-тупланган төп мәгънәне дә хәтереңә уеп куй әле. Шагыйребезнең осталык мәктәбен ачып керердәй төп ачкыч менә шушыннан гыйбарәт икән ләбаса!

Ачкычның асыл эчтәлеген, хәсиятен заманча бер рәвештә – формула итеп күзаллап булыр иде: **Ил+Тел.** Күрәбез ки, әсәрләрен укыганда (тыңлаганда) тоябыз ки, шагыйрьгә гомерлек илһам биргән чишмәнең асылы ике төп “күздән” тора: Ил һәм Тел, дөресрәге, шушы ике чыганакның аерылгысыз кушымтасы Ил+Тел дип аталган илаһый, рухый ризыктан.

Шулай да без бу бербөтенне аны хасил иткән ике кушымтаны фәнни анализ өчен аерып-аерып күзаллап карыйк әле. Башта **Ил** турында. Нигә кирәк шагыйрьгә ил төшенчәсе? Аның иҗатының, илһамының асылы – фикер һәм хис (рух) бердәйлеге бит. Шагыйрь менә шушы бердәйлекнең чыганагы Туган ил дип белә икән:

Яннарына барам агайларның,
Фикерләрен ишетеп карарга;
Җырларымда телим гомерем буе
Алар рухы белән янарга.

Ягъни, аныңча, Ил, нинди генә исем, атамалар белән белдерелмәсен, бәян ителмәсен, ул – бик тә конкрет, ап-ачык күз ал-

дына китерелә торган төшенчә. Иң беренче нәүбәттә Ил – ул шагыйрьнең туган авылы.

Авыруыма врач кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын:
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.
Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

Күрәбез ки, иң башта, авыл аның аңында гомумиләштерелгән, абстракт төшенчә түгел, бик тәгаен – үзе туып-үскән, әтисе-әнисе, туганнары, авылдашлары яшәп яткән конкрет бер авыл, беренче нәүбәттә *Күлле Киме* (Киме). Авыл образын хасыйл иткән башка авылларны да ул үз исемнәре, үз сыйфатлары белән бәян итә: Берсе аның (фронтташның) Сәгъди күршесеннән, // Өчиледән очрый, Күәмнән.

Хәер, иҗтимагый фикерләүче шагыйрь авыл төшенчәсен дә вакыт-вакыт гомумиләштерелгән бер күренеш, образ, хәтта символик бер сурәт итеп күзаллый. Кызыгы шунда: гомумиләштерү дә конкрет төшенчәләр белән күзаллана. Мәсәлән, *Казан арты*. Бу төшенчә ике яклы гомумиләштерүгә сәләтле: аның туган авылы Кимене дә, шул ук вакытта бөтен илне дә: Онытылмаслык итеп кыйнадык без (фашистларны) – // Егетләре *Казан артының*. Монда Казан арты бөтен ил, бөтен халык символы булып күзаллана. Шагыйрьнең “Блокнотлар”ында мондый өзек тә бар: “Туган ил турында уйлансаң, күңелгә иң элек Идел килеп керә, аннан – Кама, Ык, Зөя, Мишә”.

Авыл төшенчәсен әдип төрле параллельләр, чагыштырулар белән дә гомумиләштерүгә ирешә: *бабайлардан килгән нигез; җырлап туйлар иткән өйләр; безнең мәхәббәтнең уелып эзе калган җир*.

Шулай да, нинди генә гомумиләштерү очрагы булмасын, авыл шагыйрь аңында, аның сөйләмендә һичшиксез конкретлыгы белән аерылып тора.

Әйтик, авыл аныңча авыл халкы, авыл кешеләре дигән болай да шактый төгәл төшенчә генә түгел, хәтта аерым бер кеше, шәхес тә. Шәхсән үземне мин Киме кешесе дип саныйм: әнием шул авылныкы, балачак шунда үткән, әле дә баргалап йөрим – әби, бабайның, туганнарның кабере шунда. Димәк, беләм ки: шагыйрьнең шигырьләрендәге *Газзә, Гайфи, Гарәфи, Фәрхинур, Һаҗирә, Көлемсәр...* шушы авылның чын кешеләре. Бу исемлекне, әлбәттә, *Габдулладан – Тукайдан* башларга кирәктер. Сибгат абый якташын

гомере буе көнеленең – шигъри хәятенең төрендә йөрткән, якын авылдашы, якташы дип хис иткән. “Тукай аша карыйм дөньяга”, дигән. Бу исем аның иҗатының үзәген тәшкил итә, бөтен иҗаты буенча үрелеп бара. Туган телгә мөнәсәбәте, фәлсәфәсе, тел тоемлавы да, бәлки, Тукай күзәнәкләреннән киләдер.

Янә, аныңча, авыл – ул кешеләр генә дә түгел, ә гап-гади әйбер, күренеш, фактлар да. “Яратам мин” дигән шигырендә ул шуларны авылны яратуының сәбәбе дип саный: *...кышкы озын төндә юлчыларның җырын тыңларга; ...үтеп баручының кунар өчен ишек кагуын; ...яшь киленнең җылы караш белән, якын итеп каршы алуын; ...яшьләрнең клубка дип шаулап үтүен; ...үсмер баланың иртәгесе көнгә ...дәрес каравын; ...авыл кешесенең күңелле итеп әкият сөйләвен...*

Аныңча, авыл – ул шушы төбәк, шушы халык яшәеше белән бәйле гореф-гадәт, йолалар да: Күп нәрсәдән сез итегез мәхрүм, // Калдырмагыз *сабан туеннан*; Сабый чак... исемдә *зиратка* барганым... // Һәм *төртеп күрсәткәч, тешләвем бармагым*; *Сөенчегә бүләк өмет итеп*, // Кырлар буйлап йөгерер дулкыннар; Миңлебикә *арттан килгән атка // Әйтә ел да нәзер*.

Кыскасы, шагыйрь авылны, аның мохитен, яшәешендәге, тормышындагы һәр күренешне, аның эче-тышындагы һәр манзараны якын итә, ярата. Шул ук вакытта монда ике үзенчәлек бар: беренчедән, аның авылны яратуы – ул авыл белән физик бәйләнеше дип кенә аңлашылмый, ә рухый хәсияте дип аңлашыла. Әйтик, авыл белән турыдан-туры бәйләнмәгәндә дә, бөтенләй читтә булганда да (мәсәлән, фронтта – сугышта) ул яшәешен аннан башка күзаллый алмый: Сугышны бар дип тә белми // Ялгызы уйный колын. Икенчедән, шагыйрь шагыйрь инде: авыл образына ул сәеррәк, күнегелмәгәнрәк – үзе генә күрә, тоя алган, шушы авторга гына бәйле, ул гына таба ала, ясый ала торган **ассоциация-чагыштырулар** белән ирешә: “Күңелемә безнең “Шүрәле”нең // Җиле китсә тиеп, // Бел: туган илне, Тукайны // Бу малай сагна диеп”. Менә бит: сабый карашында Киме – ул Шүрәле!

Шагыйрь үзенең авылында юлыккан һәр күренеш, манзара, факт, вакыйгага – кадерле төбәген рәсемләгән сурәт итеп карарга, зур мәгънәле, кадерле нәрсә итеп тоярга күнеккән: “Күпме моңайдым авылда // Тәрәзә кадакланса; // Моңайдым караңгы, төпсез // Сүнгән күз карап калса”. Искәртеп китик әле: “сурәтне” үзең күрә алу – бер нәрсә, ә менә бүтәннәр дә сурәт итеп күрсен өчен аны тасвирлап

бирү – монысы инде талант кына булдыра алган осталык. Моңа ирешү өчен, бер караганда, әлләни дә кирәк түгел кебек – шагыйрь бу очракта да гап-гади, шул ук вакытта халыкның рухый дөньясын хасыйл иткән *моңаю, караңгы, кадаклану, төпсез, сүнгән* сүзләренең тәэсир көчен эшкә җиккән.

Әдипнең сүздән сурәт ясау осталыгына һәр әсәрендә юлыгып торабыз. Янә менә: "...Үз ягымны // *Эңгереннән* хәтта таныймын". Тоясыз: гап-гади *эңгер* – аңарга туган иленә карата хөрмәте, яратуы, тугрылык кебек олы хис белдерү чарасы: "Җанны оетып, чеметтерә торган // Ни саклана икән эңгердә?.." Өстәвенә әле эңгер сүзе контекстка *җанны оету, чеметтерү* кебек хисси берәмлекләрне дә тартып керткән.

Ил төшенчәсе аның сөйләмендә туган як булып илаһи канатлы, пафослы да яңгырый: "Күңелеңдә, әнкәй, туган як // Бербөтенгә әверелә, // Колак салам шул илаһи // Бөек көчнең әмренә...".

Күрдек ки, аның шигъриятендә туган җиргә, авылга бәйле теләсә кайсы төшенчә, нәрсә, күренеш, хәтта шушы авылда кулланыла торган гап-гади сүз, гыйбарә дә образ булып китә ала: "Урләреңне менгәч, туган ягым // Рәшәң белән битем юдың син"; "Коеныпүскән су буе, // Шылт та итми як-якта... // Яшәргә риза мин монда // Әйләнеп бер яфракка"; "Яр астында керәшәләр түгел, // Гүя җырлар оя ясаган". Яисә менә, мәсәлән, авылдан һич аерылгысыз *кош* төшенчәсе: "Көлгә әйләнгән авылны // Ул табу юлын сөйли; Бер төркем кошлар һавада // Әйләнеп очып йөри". Болар – чын-реаль кошлар, фашистлар җимереп киткән авылны табып кайткан кошлар... Икенче очрак: Менә Зифа Басыйрова җырлый: "Кошлар кайта безгә, син һаман юк, // Син һаман юк, никтер килмисең". Монда инде кош адәм баласының җанын телгәләргә сәләтле бөтен бер образга әйләнгән.

Авыл, аның төрледән-төрле күренеш, төшенчәләре бүтән темаларны яктыртканда да күзәтү, уйлану, образ тудыруга сәбәп, нигез, деталь була ала – фикере, хисе "авыл лексикасы" белән белдерелә, бәян ителә. Менә фронт темасы: "Ташлап киткән йөк арбасын күреп кырда // Печәненә күмелеп аның йокладым мин"; Күр, ничек ихлас белән ул // Хат укый кырын ятып"; "Молдаван хатыны бозаулы сыер сатып тора".

Яисә, менә шагыйрь, халык утырышчысы буларак, суд эшендә катнаша. Шул мохиттән шигырь дә яза: "Шәһәр судында туган авылым // Искә төшеп мине алҗытты"; Анда да авыл лексикасы: *җене сөйми, абынып сөртенү, көе китеп тору, тормышны көйгә салу, азып-тузу* һ.б.

Безнең авыл дигәндә, Сибгат Хәким Киме белән янәшә авылларда яшәгән мариларны, урысларны да безнекеләр дип, якын дип күз алдына китерә, моны ул аларның телләреннән сүз, гыйбарәләрне алынма итеп китереп тә ирешә: “Бу мари үлгәндер – *кулыйн*, дип”; “Соңгы юлга мине озатканда // Соңгы сүзе булыр: *чиверын”* (сау бул).

Әдипнең “Блокнотлар”ыннан бер өзек: “Кереш... Мин туган як турында әйтәсен әйтеп, язасын язып бетердем, дип уйладым. Язын яңа үлән болында калкып чыкты... Җир... Өстендә зәңгәр рәшә – икенче яшьлекнең моңсулыгы булып күренде... Юл, тузанлы юл... Хәтта зират... Кешеләр... Икенче буын, икенче төрле моңнар... Сандык, серле сандык кебек... Ачасың, һаман яңа нәрсә... Юк, язып бетереп булмый икән... мин бары җир өстендәге рәшәне, өске катны, зәңгәрлек белән өртелгән пәрдәне генә күтәреп караганмын”.

Иҗатының, илһамиятенең төп чыганагы – Ил булуын, яшәешенең шуннан аерылгысызлыгын әдип кабат-кабат искәртә: “Мин синеке, авыл, мин синеке; // Мин синеке туган көнемнән”. Шушы хисен ул сурәтнең иң якты сызыгы кебек кечкенәрәк образлар белән ачыграк, аһәңлерәк итеп бирә: “Мин шытканмын гүя яңгырыңнан, // Шыкландырган нарат төбеннән”. Уйлавымча, менә шушы сурәт-сызыклар, дәлил-сурәтчекләр, җыела-җыела, гомумиләштерелеп, чын халык афоризмы булырдай “Башка берни дә кирәкми...”не хасыйл иткән дә. Янә дә: “Туып-үскән шушы җирнең ямен // Алыштырмый икән һичнәрсәң”; “Туган якта һәр тал җырлый // Үз-үзенә тын гына...”.

Бөтенләем белән Җирнеке мин,
Минем барлык нәсел-нәсәбем –
Игенчеләр. Җирдән төртеп чыга
Һәр юлым, һәрбер әсәрем.
Кадер дә, хөрмәт тә сиңа
Тик туган җирдә икән.

Шагыйрьнең менә бу юллары язмабызның шушы өлешенә нәтиҗә кебегрәк яңгырый. Игътибарга алыйк: алар әдип гомеренең азагында язылган. Рабит Батулла бик дөрес тотып алган: “Шагыйрь Сибгат Хәким иҗатының тамырларында җирсү дигән хиснең каны ага. Ватанга, Туган туфракка, узган тарихка, дәүләтчелеккә, сагышлы авылның узганына, югалган һәм югала барган йолаларыбызга җирсү мәзугы Хәким иҗатының буеннан-буена сузылып бара”. (*Батулла Р.* Урыннары җәннәттә булсын! Мәрхүм шәхесләребез турында мәрсияләр, хәтирәләр. Казан; Рухият, 2007). Чыннан да Ил төшенчәсе

дә аның аңында, җанында конкрет бер нәрсә, күренеш булу белән бергә, хис төене булып та төсмерләнә.

Бу очракта Туган телгә җирсү дә үзеннән-үзе аңлашыла кебек. Бу фактор безгә шагыйрьнең осталык мәктәбе “формуласы”ның ике үзәкле икәнен искә төшерде. **Тел** үзәгенә махсус тукталырга вакыт җитте бугай. Хәер, ил турындагы фәлсәфәбез дә барыбер Телдән берничек тә аерылмады шикелле. Алар чын-чыннан аерылгысыз, игезәк төшенчәләр икән бит. Шагыйрь иҗатында Ил тоткан урын турындагы фикер агышыбыз бөтенләе белән Телгә үрелеп барды. Күңелгә тия торган, барчабызны да битараф калдырмый торган гап-гади төшенчәләр шагыйрьнең иң яраткан, Туган ил дигән төшенчәнең нигезен тәшкил иткән төшенчәләр белән бәйле икән бит. Әйтик, мисалга алынган “Яратам мин” шигыре авыл тормышыннан, шунда яшәү, эшләү мохитеннән, халык хәятеннән аерылгысыз гап-гади сүзләрдән (фәнчә әйтсәк, гомуми, битараф берәмлекләрдән) тора: *күктә йолдыз, урман, бүре, авыл, җемелдәгән ут, атлар пошкыруы, олау тавышы, юлчылар җыры, клуб, әкият сөйләү... капка төбе, кое каршында, зират, нигез* һ.б. Бөтен шигъриятенең башлануын да ул: “гап-гади бер сүздән”, дип саный: “...иң беренче җырым // Башланып бит киткән *уҗым*нан”.

Остазыбызның бөтен шигърият дәрьясы шушындый – барыбызга да якын, аңлаешлы, аһәңле, күтеп алынган ләйсән яңгыр кебек “тәмле” сүзләрдән җыела: “Иртәнге ак кар өстендә // Чананың эзе кала”; “Сез сузган буразналарда // Тәгәрәп үскән шагыйрь”; “Кечкенәдән миндә ат җене”.

Һәр сүз әйтергә теләгән мәгънә, төшенчәгә, эчтәлеккә тач тәңгәл килеп тора: *җәйге таң авыл өстендә (сызылып килә), гармун уйнавы (моңы) сибелә тыныч өйләргә, тәрәз гөле, ап-ак өлге, урам чаты, ындыр арты.*

Авыл төшенчәсе дә, анда яшәүче кешеләренең тормышы-яшәше кебек үк, төрле темалы, төрле юнәлешле. Шуңа бәйле рәвештә аларны сурәтләүнең лексик-семантик-стилистик мөмкинлекләре дә төрледән-төрле. Моңа ул үзе дә диккатьле: “Туган җир, ахры, күңлемнән // Кайчан да китмәс. // Ул хакта җырлап, сөйләп тә // Сүзләрем бетмәс”, – ди. Бу шигыре үзе үк шуңа дәлил: *урләр, җил тегермәне, көтү, кибән, кыр, ындыр, кое, чишмә, үлән, арба эзе, әнкәй, яшь таллар...* Нинди җанга якын, “үзебезнең” сүзләр!

Әлбәттә, эчтәлек дигәндә, иң беренче чиратта авылдагы хезмәт, аның белән бәйле мохит, урын, күренеш күз алдына килә. Мәсәлән, утын хәзерләү эше; бер кечкенә генә шигырьдә: *утын кисү, утын яру,*

имән тукмак, чөй, әрдәнә, чәер исе, лапас, балта һ.б. Шулай ук барысы да якын, кадерле кәлимә, гыйбарәләр. Менә "Балта остасы" шигыре сыендырган сүзләр: *бүрәнә, юну, чабу, кул җае, йорт, бура күтәрү, өрлек, түбә, әвен, тегермән, матча, сәке йөзлеге* һ.б. Менә уракка төшкән авыл күренешеннән: *яңа уңыш, ипи исе, басу капкасы, урамның аргы башы, муллык, тегермән тарта, арыш урагы, арпа, бодай, солы, кыр, әвен, ябык ындыр, атлар, көшел, машина, олау, башак, бөртек, иген, колхоз һ.б. Бастырык, чабата, борчак...*; "Артта гомер – кишәрлек җир, // Ята кырда сынган урак".

Монда мөһим бер хикмәт бар: ул сүзләр гап-гади көндәлек факт, төшенчәләрне дә аңлата, шул ук вакытта сурәт-образ ясау чарасы буларак та хезмәт итә. Бу хакта без инде әйткән идек. Шагыйрьнең тел белән оста эш итүенең асылы, хәсияте нәкъ менә шушында да бит инде. Нинди халыкчан, саф татарча яңгырашлы сөйләм хәзинәсе: "Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем // Үзем генә белгән җырлар бар. // Кайтам, кайтам туган якларыма, // Ашкындырып көткән юллар бар".

Сибгат Хәкимнең осталык мәктәбен ачарга-анализларга алынган тәнкыйтьчеләр арасында, ни кызганыч, аның тел осталыгына махсус тукталып, чын мәгънәсендә тулаем, тирәнтен фәнни анализ ясый алганнары әлегә күренми. Шулай да шагыйрьнең әлеге талант юнәлешенә игътибар итмәү мөмкин түгел. Моңа диккать итүчеләр арасында нәкь менә шагыйрьләрнең үзләре булуы бик уңай, сөендерә торган фалдыр. Бүген мисалга шагыйрь Разил Вәлиевнең фәнни күзәтүләреннән берничә юлны өзеп биреп кенә канәгатьләнергә мәҗбүрбез: "Анда авыл, әнкәй торган авыл, // Ветпунктны гына үтсеннәр... Ул дулкыннар безнең иске зират // Коймасына ятып үксерләр". Нинди зур сагыш, нинди ихлас хисләр һәм олы мәхәббәт сыйган бу шигъри юлларга! Нинди гади һәм күңелгә якын сүзләр, һәр сүз, челтәр бәйләмендәге камил күзәнәк кебек, нәкъ үз урынында! Табигый талант, шигъри камиллек үрнәге менә шушындый була торгандыр инде". Янә бер күзәтүе: "Сибгат ага Хәким иҗатында иң күп кабатлана торган сүзләр "сагыш" белән "язмыш" сүзләредер. Аның бөтен иҗаты да сагышлы язмышлардан тора кебек..." (Татарстан яшьләре. 2011. 26 ноябрь). Бүгенге яшь шагыйрьләребез, язучыларыбыз да әдипнең әсәрләрен укып, менә шушылай тел сабакларын алсын иде.

Хәзер килеп **Ил+Тел** бердәйлеге турында. Бу бердәйлекне шагыйрь турыдан-туры тоя, аның үзе өчен әһәмиятен шигырьләрендә әйтә килә: "Әкиятләрең белән ачылды телем, // Казан арты, әй Казан

арты; Менә авыл, таныш кешеләрем, // Хыялларым ник болай татлы? // Гел кояшка карый тәрәзәләрең, Казан арты, әй Казан арты”.

Бу күренешне әдип образ, сурәт итеп тә күзаллый: “Нечкәреп җиткән күңелне // Моңлы көй телеп уза; // Бу – туган илем көе бит // Кем болай җырда суза?”. Монда Тел белән Җыр (Көй) мәгънәдәш сүз – синонимга әверелгән.

Яисә: “Ат өшәнсә – атка алан бар, // Алан гүя атның тубалы...”; “Синдә шатлык, синдә горурлык, // Син шул җирдә шыткан бер орлык”.

Шагыйрьнең бу әһәмиятле үзенчәлегенә аның иҗатын төпле өйрәнгән тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре дә игътибар итми калмаган. Хәсән Хәйри күзәтүләреннән: “С. Хәким кешеләрнең шатлыгын да, кайгысын да күрә белә. Аның герое үзе турында кайгыртудан элек иле, халкы турында уйлый. Ул дан өчен түгел, халык бәхете өчен яши...” (*Хәйри Х.* “Чорым, синең хисләр белән янам...”: С. Хәкимнең “Шигырьләр” китабына кереш сүз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 12 б.). Янә ул болай ди: “Лирик шагыйрьләргә хас булганча, С. Хәким поэмаларында без һәрвакыт шагыйрьнең үз образын да яхшы ук тоябыз: аның уй-хисләре, кичерешләре, теге йә бу фактка үз мөнәсәбәте, шуларга нисбәт лирик тасвирлар, шигъри образлар... “Саф” хикәячелек, вакыйганы бәян кылу, тасвирлау, аның поэмалары өчен характерлы түгел” (шунда ук. 10 б.).

Менә шушы эчке дөньясын шагыйрьнең ничек-ничек “тышка чыгаруын”, укучыга җиткерү рәвешен, ягъни “тел белән ничек эш итүен” тәнкыйтьче болайрак бәян итә. “Кай очракта бу тасвир артык гомуми сүзләр белән, “томан” белән сугарып бәян ителә: “Халкым юлда күтәрелгән үрләр”не күреп, горурлык хисе белән җырлаучы шагыйрьнең сүзләре, шигъри тасвирлары халык моңы белән сугарылган, алар шагыйрь йөрәгеннән ташып чыгалар кебек. Ә йөрәк сүзе йөрәккә тоташмый калмый, диләр” (шунда ук. 8 б.). Шагыйрьнең шушы хәләтен ничек-ничек тасвирлавына конкрет килгәндә, ул болайрак күзаллый: “С. Хәким, артык төче, пафослы сүзләргә, риторик өндәү, “кычкыруларга” бирелмәстән, сәнгатьчә гади итеп, урыны-урыны белән бераз моңсу, урыны-урыны белән көчле күтәренке рухта геройның эчке дөнъясын ача, кичергән хәлләрен сөйли” (шунда ук. 12 б.).

Шул ук вакытта тәнкыйтьче әдипнең чын йөзен, тәэсир көчен һәм табигатен мондый гомуми сыйфатнамәләр белән ачып булмасын сизә, җитдирәк, профессионалларчарак фикерләп карый. Дөресен әйткәндә, мондый конкрет фикер-нәтиҗәгә аны С. Хәкимнең фикерләве, ачыграк әйткәндә, аның Пушкин иҗатының

нечкәлекләрен уйлавы, этәргән, ә шагыйрь Хәким болай дигән: “Пушкин реализмга ят булган күп сүзлелек, һәртөрле кирәксезгә сүз уйнату, чуарлау, әсәрнең ялыктыргыч озынлыгына каршы чыга. Ул үз әсәрләреннән төп фикерне ачудан читкә илткән тышкы ялтыравык, бу балласт сүзләрен шәфкатьсез рәвештә алып ташлаган...” (*Хәким С.* Үз тавышың белән // Совет әдәбияты. 1950. № 7. 87 б.).

Шагыйрьнең тел белән эш итүгә, осталык таләпләренә карашын аңлаганнан соң, тәнкыйтьче болай ди: “С. Хәкимнең мондый сүзләреннән аның осталык мәсьәләсенә никадәр җитди, таләпчән каравы аңлашыла. Аның шигырь һәм җырлары да, поэмалары да гадилек, пөхтәлек, җыйнаклык, фикер ачыклыгы белән аерылалар. С. Хәким дә сүзгә зур мәгънә сыйдыра белә, халык теле байлыгыннан мул итеп файдалана, шигырьнең эчке музыкальлеген тоя белә. Аның әсәрләрендә эчтәлек белән форма бердәмлеге, бөтенлек бар. С. Хәким шигырьләренең һәр сүзе, сүз тезмәләре, җөмләләре, рифмасы, ритмикасы, сюжеты – барысы да төп фикерне, төп идеяне, кеше хисләрен ачуга буйсындырылган. Интонация, эчке пафос шигырьнең иң әһәмиятле сыйфатларыннан саналганы күптән билгеле” (шунда ук. 18 б.).

Бу араларда мин күренекле публицист, галим Рафаэль Мостафинның публицистик осталыгы турында уйланып йөрим; күзәтүләремне уртаклашасы килә. Аның да публицистик мирасы С.Хәким иҗатыннан аерылгысыз бит: чын публицистлылыгын ул шушы шагыйрьнең иҗатын, беренче чиратта, аның шигъри тасвирлау-сурәтләү сәләтенең үзенчәлегенә игътибар итеп, башлап җибәрде шикелле. Ул байтак әдипнең, беренче нәүбәттә Муса Җәлилнең, осталык сәләтен ачарга омтылып, җитди фәнни күзәтүләр, нәтиҗәләр ясауга ирешкән галим. Ә бит, ялгышмасам, аны бу иҗат юлына кертеп җибәргән, илһам биргән, чын тикшеренүче иткән әдип – ул Сибгат Хәким. Дәлил итеп әлегә аның С. Хәкимнең тел осталыгы хәятен берникадәр ача алган кайбер күзәтү-бәяләрен генә китерим. Гади сөйләм тонында бәян итү: гадәти-көндәлек сүзләр (диалог чалымнары белән); әдәби, фәнни терминнарны кулланмаска тырышу; тамчы да риторика юк бу юлларда; ул бернәрсәне дә яшерми, бернинди кыенлыкларны да сылап-сыйпап үтәргә теләми; С. Хәким публицистикасының нигезе – документальлеккә таяну (Кокушкино крестьяннарының В.И. Ленинга язган хаты тексты); фәннипублицистик тон саф шигъри, моңлы-көйле аһәңле тон белән аралаша; ...аның шигырьләрен укыганда туган якларын сагынып кайткан киек казлар тавышын ишетәсең, кинәт яуган яңгырдан соң һавага

күтәрелгән дымлы җир исен тоясың. Синең алдыңда чылтырап аккан чишмәләре, үзенчә нур сипкән ае белән бөтен бер дөнья ачыла. Аның хисләре ирләрнекедәй тыйнак, кызларныкыдый нәфис...

Хәзер килеп, күренекле галимнәребезнең әдипнең иҗат илһамы чишмәсе булган Ил + Тел феномены турында әйткән гыйлми ачыш-концептларын үземнең дәлилләр белән беркетергә тырышып карарга кирәк. Шулай да башта Ил+Тел фәлсәфәсенә шагыйребезнең үзенең уй-тәкъдимнәрен өстәп китү артык булмас: "Минем иҗатымда тирән эз калдырган нәрсә авылның табигате, киң күңелле кешеләре булды. Мин шул беркатлы, нечкә хисле гади кешеләрне яраттым, җырларын яраттым. Татар халкының бөтен әйтергә теләгән сүзе – аның җырларында (*Хәким С.* Фазыл чишмәсе: кереш сүз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 6 б.). Бу фикерен ул "Җырларымда телим" шигырендә тагын да ачыграк, тулырак, калкуырак итеп әйткән: ...авылымның чиста һавасы, арышларның исе, агайларның фикере, авыл, аның кешеләренең рухы – менә аның төп шигъри дөньясы.

Инде Шагыйрь кулланган сүзләр дөньясына игътибар беләнрәк карыйк. Бактың исә, алар халык көндәлек куллана торган гап-гади сүзләр икән. Шагыйрнең тел хәзинәсен күзәткәндә, без аларның төрләрен, мөмкинлекләрен, сурәт чарасы буларак үзенчәлекләрен бераз бәяләгән идек инде. Шунысын аерып әйтик, гади сүзләрдән бигрәк тә аларның әдәби телдә сирәк очрый торганнары, шушы төбәккә күбрәк хаслары ныграк тәэсир итә икән, образ-сурәт тудыру өчен башлыча шулары файдаланыла икән: "Тап иптәшең булыр кешене, // Гади бер дус үзең ишене"; "Хаксызга мин сине кисәк кенә // Үпкәләтеп куйдым төнәген"; "Ташлап китәр идем, бик кызганам; // Сүнәр көйрәп торган күмере"; "Мин аңарга // Елмаймыйм да, // Килсә бире"; "Бүреләр дә качып киткән моннан // Килгән яуга – нәләт дигәннәр"; "Таң алдын кирәк көтәргә, // Дип кенә күнми икән"; "Җир генәме? Кимсетелгән җан да // Чирый, чирый икән бозланып" (менә сиңа өр-яңа афоризм – *җан чиравы);* "Ул (тал) әйләнеп, ул тулганып үскән // Аркасында зуп-зур могыллар"; "Тирәк картайган. // *Каныгалар* аңа яшеннәр..."; "Тирәкне // әйләндерсен давыл чырага". *Чыра* инде архаизм сүз дип тә кабул ителә. Күчерелмә мәгънәсе киң кулланылмый (чәрдәкләнгән нәрсә мәгънәсендә).

Сизәмсез, мисалга җыелган берәмлекләр үзгәчәрәк кулланылулары, ишетелүләре белән берникадәр аерылып тора кебек. Нәрсәсе белән? дигәндә, алар инде бүгенге сөйләмдә, хәтта авыл мохитендә дә, куллану дәрәҗәсеннән пассиврак түгелме?

“Урагымны тиргим: вак чаласың, // Тидең дә соң инде теңкәмә. // Дәфтәр битендәге *учмаларның* // Барын җыйсаң – җитми *көлтәгә”;* “Төшләргә кереп гел *йөдәтә”*; “Кайвакыт күп төрле // Уйлардан *йөдисең”*; “Казан юлы – олы, борыңгы юл, // Тора *орынып* кабере почмакта...”; “Җаным тәмам *гарык булганчы”*; “*Ышнада* каеннарның...”; “Ул көйне, ахры, төшендә // Тыңлыйдыр – киткән *оеп”*. Килешегез, хәзер инде боларның ни аңлатканын төпченергә теләсәң, сүзлеккә тотынырга туры килә. Бу әле безне, иң башта яшь язучыларыбызны, борчырга тиешле факт та түгелме; шундый тәэсирле, сурәтле сүзләребезнең сөйләмебездә сүрелә, кими баруы һич тә милләтебезнең киләчәге, телебезнең саклануы файдасына түгелдер. “Блокнотлар”да шагыйрь “Илдус Әхмәтҗановның укуы *аерата* ошады”, ди. Аерата сүзлекләрдә дә бар, тик мин, нигәдер, гел аеруча дип язам. Нигә? Ә менә шагыйребез куллану җаен тапкан.

Инде ничәнче тапкыр тәкърарлыйм: һәр сүз аңарга төп максатына – сәнгати, шигъри сурәт ясап, кешенең күңел түренә, бәгыренә үтү максатына ирешү өчен кирәк. Ул бит көнкүрештәге бик тә гади нәрсәләрдән дә сурәт итеп, образ итеп манзара тудыра: “Ерактан ук барыбер күреп торам // Клиндерне чәйдә җебеткәнен”. Иң гади сүзләрдән (клиндер, чәй, җебетү) сурәт пәйла булган.

Һавада сөт исе, җып-җылы сөт, // Иң куесы сөтнең, иң шәбе.
Башын арыш сөткә мана төсле, // Агарырга, ахры, исәбе.

Тасвир, сурәт өчен сәнгати чараларны ул шушы кыйбладан, мохиттән генә ала. Ул аларны күнегелгән тәртип, мәктәп өйрәткән система белән эзләми, урнаштырмый, әлбәттә. Шулай да без аларны осталык сабаклары критерийлары булганга, бәяләү нигезләре булганга күрә шундый система белән дә күзәтик, истә калдырыйк әле. Башта, әйткәнебезчә, төп чыганак ул – битараф, гомуми сүзләр. Шагыйрь тәэсир чарасы буларак “иске” сүзләрне генә куллана дигән нәтиҗә ясалмасын. Ул яңачарак сүз, гыйбарәләр кулланудан, хәтта аларны үзе ясаудан да курыкмый – шигъри аһәң, милли яңгыраш кына бирсен, сәнгати чара гына булсын: “Урман эче торсын *шаңгырап”*, – ди.

Сүзләрне төрләндерү, кабатланмау – аның осталык чишмәсенең бер тамчысы. Чөнки тема шул кадәр дә киң, төрле; шагыйрь үзе үк: “Яңа җыр синдә табармын, // Көн саен кайтсам да мин”, – ди. Тел байлыгын файдалана белү аң-фикер тирәнлегеннән, колачыннан киләдер. Аның фикри хәятендә бер гади генә сүз, төшенчә бөтен бер фәлсәфи тема булып китә: “Тартар” шигырен генә алыйк. Тартар сүзе белән,

аның яңгырашыннан гына да мәгънә табып, *татар, тар, тар сукмак, тапталмау* кебек төшенчәләр белән бәйләп, фәлсәфи фикер куерта.

Иң сокландырганы, тәэсирләндергәне: шул гап-гади сүзләр беренче чиратта сурәт ясау, образ тудыру чарасы бит. Без моңа мисалларны шактый китергән идек инде. Сурәтлеккә ирешүнең кайбер нечкәлекләренә янә дә мисаллар өстик әле:

– гади сөйләм элементы дәрәҗәсенә җитәрлек шомара алган **профессионализм, термин, җаргоннар** да шигырьне җылы, тәмле, чын мәгънәсендә шигырь итә: “игеннәрнең *серкә какканын”*; “тыңлый да *җәпли”*; “Боларга *тарысаң, // Бөгәрләр* хет кемне”; “*Ни пычагым* калган биредә”; “...сарайлар янына // Язгы *төн акты”;*

– **чагыштыру**: “Кошлар кайта безгә, син һаман юк, // Син һаман юк, никтер килмисең”; “Көзенең кабагы кызарган, // Көзендә сугышның шәүләсе”; “Тышта буран... Салам эскертләре – // Пароходлар калган адашып”. Кайдан аңарда мондый чагыштыру: авыл белән зур елга арасы ерак бит. Ә-ә-ә, ул бит туган иле дип Иделне дә саный, аны да авылы кебек яхшы белгән.

Күрәмсез, чагыштыру, ассоциацияләрдән бөтен бер сурәт, образлар барлыкка килә: “Бакчабызда шомырт агачлары // Җәй буена сине көттеләр”; “Үләннәргә салкын чык утырган, // Күтәрелә томан болыннан” һ.б.

Шигырьләре авыл кешесе генә күрә торган детальләргә бай: “Күгәрченнең тамак асты кебек // Батист яулык салып иңенә”; “Күренә урман еракта // Камалы бүрек сыман”; “Чаба ак бүксәле машина”. Туган илнең, авылның кадерен белүе төрле образ, сурәтләр белән бирелә. Мәсәлән, “Юнкерс” һәм бозау “ шигырен оксюморон белән атаган.

Сурәт ясау чаралары буларак янә берничә мөмкинлеккә мисал китерик:

– **синоним куллану** үзенчәлеге. Вариант сайлау ихтыяҗы туганда төп әдәби берәмлекне үз ягы сүзе белән җөпләп, тәгаенләп куюны урынлы саный: “Яралы япь-яшь егетнең // *Сөйгәне-җанашы* бар”. “Колын” шигыре *тай* сүзе белән тәмамлана. “Безне дә нәкъ шулай үстергәндер // Бик кадерләп кенә әнкәләр”. *Әнкә* Кимедә дә әнинең синонимы буларак бик таралган сүз түгел иде бугай, безнең авылда бөтенләй кулланылмый; хәер, малга, каз, үрдәккә карата әйтелә шикелле, ә бу очракта ул урынлы кулланган кебек – бәбкәгә бик тач рифма инде.

Сурәт ясауда синонимнарның контекстуаль дигәненнән Шагыйрь бик оста файдалана. Әйтик, образ буларак Ил иллә дә төрле, күпкырлы. Бер очракта – ул җыр. Ә менә монда – ул әрәмәдәге инеш: “Сау бул инде, тып-тын әрәмәдә // Күренмичә аккан инешем...”. Ә монда – ул чытырман: “Чыпчык та үз чытырманым дигән. // Туган җир тик булсын чытырман, аермасын сине язмышың шул // Чытырманда торган йортыңнан”;

– **күпмәгънәлелек** (омоним, омофон, пароним һ.б.) мөмкинлегеннән дә оста файдалана: “Көтүчеләр... *Дөнья көтүчеләр”*; “Сүзең көмеш, үзең – көмеш, көмеш, // Дуслар күңлен күргән *көмешкәң*”.

Ил+Тел берлегенең эчтәлек бөтенлеген тәшкил итә торган сүзчаралар арасында хисси лексика өстенлек итә. *Юксыну; сагыну...* Мондый сүзләр җыр исемнәре буларак та кешеләргә кадерле, якын; алар нәкъ менә Илнең һәм Телнең һәркайсыбыз өчен иң газиз икәнен раслый торган төшенчәләргә әверелгән;

– татарның саф үз берәмлеге **парлы сүз**ләрне ул нәкъ урынында, мәгънә төсмеренең нечкәлеген аерып күрсәтү өчен файдалана. Аның парлы сүзләре тел берәмлеге сүз буларак кына түгел, сөйләм берәмлеге булып танылырга тиеш: шул ягыннан да алар кызыклы: “Хәзер бернишләп тә булмый, // *Сагындың-сагынмадың”; “Үкенсәң-үкенмәсәң* дә, // Юлымның шул уртасы”.

Сибгат Хәким сөйләменең үзенчәлеге сүзләрдән генә түгел, авазлардан (әйтелешеннән), кушымча, иҗекләрдән (әйтелешеннән) үк башлана: “Ат*каем* тиргә манылган, // Бөкрәеп тарта йөген”; “Читтә, көрәккә таянып, // Карт конюх тора; // Күзәтә карлыгач*кайны...”*.

Сүз-берәмлекләр генә түгел, күчерелмә мәгънәгә сәләтле тезмәләр (фразеологизмнар, синтагма, гыйбарәләр) дә чын мәгънәсендә образ арсеналы булып тупланган. Хет бүген “Сибгат Хәким фразеологизмнары” сүзлеген бастырып чыгар: *Мин монда аунап үскән; Иптәшләрнең саны тулмый – иш ким чыга.* Ул алардан бөтен бер картина рәвешендә сурәтле манзара ясый, хәтта шигыренә куела торган таләпне дә ул авыл кешесе фикерләвеннән, аның көндәлек гыйбарәсеннән ала: “Мин эшләргә телим шигырьләрем // Алар кебек җиренә җиткереп”.

Халык фразеологизмнарын ул үзенчә үзгәртә; шигырь калыбына да яраклаштыра, шул ук вакытта эчтәлек нечкәлеген төгәлрәк бирү өчен дә юлын таба: “Күз бераз бәйләнә // Төшкәчтен, кинәттән”; “Мин киләп сарганга // Хатыным ярсына”. Сирәк очрый торганнарын

шигъри сөйләмгә кертеп җибәрә: “Ире моның кул яккандыр әле”; “Түзсә түзәр икән кеше, димен, // Үз эченә йотып зәһәрен”; “Күп тә димим, көнгә бер җылы сүз // Әйтсен иде... хет үл егылып”; “Көе китә эшнең, җае китә, Кайчагында чыгам чыгырдан...”; “Аты атмы, юллык азыгын тап, – // Агарткан ул мужик чәчләрен”; “Нигә, Шакир, бездән йөз чөйдең?”; “Борчак сибә бераз Хәйрулла”; “Син (Татарстан) тугансың – безгә сан булган”; “Сугышы ник китми кадалып”; “Аваз сала кебек үр аша”.

Гади генә үзгәртү дә ритмикага, рифмага уңай тәэсир итә: “Карап тордым калып хәйранга”. Образны да ул сүз белән генә түгел, тезмә гыйбарә – фразеологизмнар ярдәмендә дә ясый: Мактый халык: “Әптери, дип, үзе // Үлгәч хәтта сөяп куярлык”.

Мондый сурәтле, тере берәмлекләрне укып хисләнгәндә аларның чыганагын – халыкныкымы ул, әллә үзе ясаганмы – төпченмисең дә. Ә бит халык афоризмнарын уйнату, үзгәртү аңарда, кайбер шагыйрьләрдәге кебек, үзмаксат түгел. Аның шәхси гыйбарәсе чын мәгънәсендә сәнгати, шигъри ачыш-табыш. Монда шигъри аһәң, ритм, рифма таләбенә җавап бирү, шул ук вакытта тәмле җор теллелек, татарның кыскалыгы, тапкырлыгы да чагыла: “Тын йортларга керер ул (почта егете Касыймҗан) // Тол йортларга керер ул”. Янә: “Чабатадан аннан җылы аз”; “Чакырмый да дусны дус табар”.

Монда бер җитди чигенеш ясарга мөмкинлек бар. Дөресен әйткәндә, күп очракта Шагыйрь үзе дә, бу язмада без дә тел төшенчәсен артык гомуми мәгънәсендә кулланабыз, ә бит контекстта ул сөйләм мәгънәсендә бара, ягъни аралашу чарасы – телнең кулланылу хәсиятендәге төшенчәсе. “Авылга кайтсам, сүзләрне // Көн җыям да, төн җыям...” дигәндә, ул әлеге коралны, аның бер бөртеген күз алдында тота. Бу очракта ул сүзне нәкъ менә шундый бер корал дип күз алдына китерә. Менә аның бер уйлануы: “Тукайның “Җәйге таң хәтирәсе” дигән шигыре бар. Шундагы бер сүзгә сокланам. Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата. *“Галибанә”*. Шушы сүздән башкаларын бөтен шагыйрьләрдә таба алам. Ә бу сүзне Тукай гына тапкан. Шушы бер сүздә таңның бөек күренеше. Таң шикелле үзе озын, музыкаль. Яшь чакта авылда күпме таңнар аттырдым, күпме җыр, шигырь яздым соңыннан. Таң “уйчан”, “моңсу”. Шулардан узмадым. Безгә дә үз сүзебезне табарга кирәк иде бит. Юк, табу читен. Кайчакта шушындый бер сүз җитми. Бер генә сүз “Галибанә”!”. Корал буларак сүзне аңлатып, тасвирлап бирүнең, телче булуның чын үрнәге бу. Шул ук вакытта сүзне нәкъ менә корал буларак

тасвирлауның үзмаксат түгел икәнен төшенергә дә бер дигән мисал бу. Нигә кирәк сүзнең асылын, хәсиятен, тәмен, көчен белү? Килешегез, ул аңарга сөйләм оештыру өчен, үтемле сөйләм белән бүтәннәргә тәэсир итәр өчен кирәк!

Шагыйрьнең “Блокнотлар”ында кызык бер факт теркәлгән: “Язучылар белән очрашырга бер телсез дә килгән”... И-и-их, авторның үзе белән гәпләшеп алыр идем. Килсә соң, ул бит тел тыңларга түгел, ә сөйләм тыңларга килгән, ә сөйләм бит ул тел-сүз генә түгел, ул мәгънә белдерә торган тавыш, хәрәкәт (ым, ишарә, көлү, елау һ.б,), күз карашы да. Сибгат Хәкимнең шәхси үзенең сөйләме гаҗәеп үзенчәлекле – тәэсирле, хисле иде. Мин аның белән болай очрашып сөйләшкәләп алганым, төрле кичәләрдә шигырь сөйләгәнен, рәсми җыелыш, утырышларда нотык тотканын бирелеп тыңлаганым булды, Арчада, Кырлайда, Кимедә, Әтнәдә кешеләр белән аралашканын, бигрәк тә сабан туенда төрле кеше белән әңгәмәләшкәнен күзәткәнем булды. Сөйләм мотивларына (сөйләм адресатына, сөйләмнең ниятенә, шартына) карап сүз сайлавы, җөмлә төзелешенең, тавыш-интонациясе, хәрәкәтләренең үзгәрүе дисеңме. Хәер, бу үзенә бер тема юнәлеше. Аңа күчеш ясар өчен бер вакыйганы искә төшерү кирәктер. Узган гасырның илленче еллар азагы иде бугай. Пароходта эшләгәндә, җаен табып, Кимегә сабан туена кайттым. Киме кызы – минем әнинең әнисе Нәфисә әбинең сеңлесе, Казан артының орденлы, атаклы укытучысы Татарстан Югары Советының беренче чакырылыш депутаты Фатыйма апа Садыйкова да кайткан иде. Шагыйрь белән алар бик дус, гәпләшергә бик яраталар иде. Бу юлы миндә яңалык бар иде – “Социалистик Татарстан” газетында иң яхшы очеркка конкурста җиңеп, фотоаппаратлы булган идем, чын корреспондентка охшарга тырышып, шуны тагып йөрдем, апа белән Сибгат абыйны да кат-кат төшердем. Пароходка кайтуга ук, вахтада булсам да, түземлегем төкәнеп, кача-поса, ашык-пошык тасманы ачыкларга тотындым. Тик дулкынланудан аның бик тә нечкә, кабалануны кичерми торган эш икәнен онытып җибәргәнмен. Юдыра торган суның тиешле температурага төшкәнен көтәргә түземлек җитмәгән; тасмага күз салсам, артка чүгеп киттем – тасмада берни юк, ул юылып беткән иде. Үземне өзгәләп ташларга җитеп, әрнегәнем, күздән яшьләр атылып чыкканын гына хәтерлим.

Хәер, әлегә бит мин истәлек, хәтирәләр язарга алынмаганмын, әлегә мин татар сөйләме, Сибгат Хәким сөйләме төшенчәләренә мөнәсәбәтле генә детальләрне искә төшерәм. Кызганыч ки, бу юнәлештә әлегә күзәтүләрем бик аз. Үземнекеләр дә, башка чыганак-

лар да. Шулай да кайбер күзәтүләр теркәлгән икән. Менә “Сөйләм иясе буларак шагыйрь С. Хәким” дигән категориягә кайбер факт, детальләр язучы Рабит Батулла истәлекләреннән (*Батулла Р.* Урыннары җәннәттә булсын!): Тамашачыны шаккатырырлык итеп ул сәхнәдән шигырь укымый иде... Сибгат Хәким беркайчан да эффектка омтылмады. Тыйнаклык аның холкында, табигатендә иде. Ләкин шушы йомшак холыклы тыйнак кеше милли мәсьәләләрдә нык буынлы була килде. Рәсми олуг җыелышларда, өстән “урысча гына сөйләгез” дип бармак янап торганда да, Сибгат абый беркайчан да урысча сөйләмәде, татар шагыйре Сибгат Хәким фикерен гел ана телендә әйтә торган иде, “кирәк булса, ишетерләр, кирәк булса, аңларлар, тәрҗемә итәрләр”, ди торган иде мәрхүм.

Бөтен табындашлары шаркылдап көлгәндә дә Сибгат абый кычкырып көлмәде, ул елмая торган иде, аның елмаюы үзе бер музыка, үзе бер яктылык-нур чыганагы иде. Шагыйрьнең әнисе әйтмешли, “күңеле ак иде” Сибгат абыйның. Ак күңелле кешенең елмаюы матур була.

...Ул сыек буынлы түгел иде, сәләтсезлеге күренеп торган кешегә ул турысын да әйтә белә иде; Сибгат Хәкимнең сөйләм теле дә, язма теле дә һәрвакыт астарлы булыр. Ул киная белән үзен күтәрер, башкаларга суктырыр, ул сәяси мәүзугъка язылган әсәрләрендә аеруча хәйләкәр оста һәм сак була белде. Сибгат үзенә чигенергә, тар гына булса да сукмак калдыра килде...

Сибгат Хәким иҗатының тел-сөйләм белән бәйле осталыгын Рабит Батулла гомумирәк сүзләр белән бәян итә. Тәгаенрәк күзәтүләренә диккать итсәк, менә кайбер фикерләре генә: ...Сибгат абыйда да мәхәббәт лирикасы аз түгел, ләкин аның мәхәббәт аңлатуы үзгәрәк. Сибгатчәрәк. Аның бер генә шигырендә дә “яратам” дип шаран яру юк... Сибгат аганың бу мәүзугъка язылган һәр шигыре музыка сорап тора. Музыкантчарак әйтсәк, алар романсларның нигезе була ала һәм бу чыннан да шулай. Сибгат абый сүзләренә иҗат ителгән җырларның күбесе татар шигыре, татар музыка сәнгатенең алтын хәзинәләреннән санала... Сибгат аганың иҗаты отышлы сурәтләргә бай... Сибгат абыйның иҗатында Сибгаткә генә хас назик юмор, хәтта сатира да бар. “Хәйрулла “ исемле шигырен генә алсак та, Сибгат аганың юморга бай шәхес икәнен аңлап булыр иде: “Колхоз юри аңа тапшырды // Сакларга дип үзенең борчагын”. Колхозның-советларның асылы турында шулай парадоксаль көлке итеп кемнең язганы бар?

Кафия (рифма) мәсьәләсе Сибгат Хәким иҗатында аерым урын биләп тора... “Кан кискән – Дантеслар” кафиясен ишеткәч сокланма-

ган кеше калмады... Колак ерта торган, күзгә төртә торган, ирексездән “никахлаган” кафияләрне аның иҗатында табалмассың... Сибгат абый әйтәсе сүзен ашыкмыйча, салмак тавыш белән әйтер. Мактаганда да астына әче тәнкыйть орлыгы салып әйтер. Ул сөйләгән хикәянең кимендә ике тел төбе булыр. Бу хикәяләүдә Сибгат абый, ачыктан-ачык үзен мактамаса да, читләтеп булса да, үз шәхесен олылар, җанына якын булмаган, иҗатын хөрмәт итмәгән шәхесләр турында ул, читләтеп булса да, үзенең тәнкыйть яисә инкарь фикерен белдерер... Сибгат абыйның ике җәпле астарлы сүзе менә монда ялтырап ята. “Иҗат итте, язды дими, “тукылдатты” ди. (Гариф Ахунов турында. – *И.Н*). “Партактивный” сүзендә дә Сибгат салып калдырган, акрын шартлый торган сатира бомбасы яшеренгән. Бу – Сибгат инде. Үзе мактый, үзе астан гына елмая... Шул ук вакытта икенче бер биттә Батулла: “Сибгат абый елмайды. Аның елмаюы саф, сабыйларча елмая иде”, – ди. Аңламассың: әллә Сибгат абый ике төрле көлгән-елмайган, әллә Батулла аның елмаюын аңлап бетермәгән.

Р. Батулланың бу язмасында Сибгат Хәкимнең үз сөйләмен сүзгә-сүз китергән мисаллар булуы әһәмиятле. Аларда әдипнең сөйләү, сөйләм үзенчәлекләре чыннан да тотып алынган. Берничә генә мисал: 1905 ел азатлык хәрәкәте чорына туры килүе дә Тукайны Тукай иткән. Газета артыннан газета, журнал арты журналлар чыга башлый. Һәр җирдә Тукайны күтәп торалар. Бөтен халык Тукай кебек шагыйрьнең сүзләренә сусаган. Извозчигына, приказщигына, абыстаена кадәр, мулласы-шәкерте шушы телдә укый, яза. Тукайны җырлый бар халык. Алда барысы да сүнеп торган булса, Тукай да әллә кая бара алмаган булыр иде. Шушындый хәтәр шартларда ул да сикерә алмас иде... “Табиев әйтә, Вәлиев әйтә, Мусин әйтә, нигә татарда Гамзатовлар, Кулиевлар, Айтматовлар, Мостай кебек язучылар юк? Булса, без дә күтәрер идек андый кешене, диләр... Нишләп булмасын! Бар татарда да андыйлар. Талантларны күрә белергә кирәк... Тинчурин – чиста, затлы нәсел баласы, Сәйдәшкә нык йогынты ясаган кеше. Ул Сәйдәшне авылларга алып чыгып, “Кандыр буе”н яздырды. Андагы музыка! – Сибгат абый соклану хәрәкәте ясап тынып калды.– Тинчурин булмаса, Сәйдәшнең ул музыкасы язылмый кала иде...

Сибгат Хәкимне кеше буларак та, аның иҗатын тәнкыйтьче буларак та махсус өйрәнгән галим һәм язучы, публицист Тәлгат Галиуллинның шагыйрьне нәкъ менә сөйләм иясе буларак тасвирлаган, тәгаенләгән фикерләрен генә китерергә мөмкинлек табыйк: “...Артистларыбыз авыр кабул итмәсен, шагыйрь тышкы кылануга ко-

рылган ясалма җырларны, хистән бигрәк, акыл белән эш иткән профессиональ җырчыларны (искәрмәләр бар, әлбәттә) яратып бетерми иде шикелле. Олы җаны дөресен әйтергә ирек бирми, ул теләсә кемне йөзенә ихласлык чыгарып, чын күңелдән тыңлый. Табигый тыйнаклыгы, үзе үткән катлаулы тормыш юлы, ихтыяр көче аңа һәр очракта да олы шәхес булып калырга мөмкинлек бирә. Шулай да ул ясалмый, сәрхүшләнми, сәхнә буйлап тузан туздырып йөгерми, микрофонга кычкырмый торган гап-гади һәвәскәр җырчыларны ярата төшә иде шикелле. Һәрхәлдә миндә шундыйрак тәэсир калган" (*Галиуллин Т.* Замана балалары. 31 б.). "...Шулчаклысы бәхәссез; сәхнәдән иңгән илаһи моң (үзешчәннәрнең җыры. – *И.Н.*), көй, сүз матурлыгы, сөю хисе шагыйрьне иләсләндереп, үзенең колы итә. Ул кымшанырга да куркып, күңелен биләгән шатлыгыннан оялып, җыр тыңлый. Бу олы кичереш, тәэсирләнә белү сәләте янәшәдә утыручыларга да күчә. Син дә хис көченә буйсынып, гаҗәеп матур, назлы шигъри мохиттә яшисең..." (шунда ук. 32 б.). "Кайбер шагыйрьләр төсле җырчыларны кочакка алмый, кулларын үпми, купшы мәдхияләр әйтми. Әмма аннан гына җылылык, ихласлык тойгысы кимеми; Сибгат абыйга хас күңел көрлеге бернинди чикләрне белми: йөрәге җир шарының, анда яшәүче һәр адәми затның, җан иясенең кайгы-хәсрәтен, шатлыгын үзенә сыйдырырга разый иде. Чын-чын... Бу метафора да, гомуми сүз дә түгел. Ул әдәбиятка, телгә, тарихка мөнәсәбәте булган, өмет чаткылары күрсәткән һәркемгә ярдәм кулы сузарга әзер тора. Кемнеңдер шәхси үтенече булса, ул аны җиренә җиткереп үти, таш атканган да аш ата. Әмма бу олы йөрәккә куллары, уйлары бик үк чиста булмаган кешеләр дә килеп кагыла иде. Чөнки үзе кемгәдер аңлымы-аңсызмы явызлык, начарлык эшләүне күз алдына китерә алмаган шагыйрь куенына кем килеп кергәнен, җанына нинди бәндә кагылганын сизми дә кала. Ул явызлыкның чын йөзен барча кешедән соңрак ача, әмма инде кире кагуында да катгый, аны күңеленнән чүп үләнен йолкып аткандай бөтенләйгә чыгарып ташларга көч таба иде..." (шунда ук. 36 б.).

Хәзер инде С. Хәкимнең шигъри сөйләмен үзебезнең караштан бәяләүне, анализлауны дәвам иттерик.

Шагыйрьнең гомумән дә сөйләм төшенчәсен ачык күзаллавын күрсәткән мисаллар да аз түгел: "Киме базарына килеп йөри торган карт, Әхмәтҗан карт... Кешеләр аны әйләндереп ала, сөйләгәнен тыңлар өчен, телен, матур сүзен тыңлар өчен җыела халык...".

Инде үз сөйләменә килгәндә, аның аерым сүз, гыйбарәләре генә түгел, бөтен сөйләмен дә (җөмләләренең, бөтен текстының төзелеше)

халыкча, авылча дип бәяләргә булыр иде. Менә мисаллар: “Барысы да ашыга шәһәргә, // Билләһи, кызык та соң”; “Мехчылар туннар тегәләр // *Ни җитсен җылы тунга”*. Берәү булса, “бик җылы тун”, ким дигәндә, “җылы тунга җитәме соң”, дияр иде. Ә аныкы үзенчә, яңача, халыкча... Яисә менә бу строфага синтаксик анализ ясап карыйк әле, ягъни аның җөмлә төрләре, сүзләрнең җөмләдәге урыны без мәктәптә өйрәнгән стандарт-нормада каралган рәвештәме: “Безнең бу җир әйбәт кешеләргә // Ярлы түгел алай түгелен”. Яисә “Сагнуыннан һич туктамас җаным, // Ник урталай шунда ярмыйсың...”.

Нормага туры килми кебек, кытыршы кебек, ә уйлый калсаң, нинди халыкчан, шигъри көй, үзгә әйтеш, яңалык белән сәерсенеп, ана телебезнең көч-кодрәтен, тәмен тоеп ләззәт аласың! Яисә “Белмини, ник аны белмәскә”; “Һич шаяртмыйм, исем китте менә: // Бер төш тә юк кырда тургайсыз”; Ашарыма куеп чыга: // –Тамагыңа кап, балам”. Менә шушындый саф татарча сөйләм үрнәкләрен эзләп таба. Мәсәлән, хат үрнәгендә форма гына түгел, сөйләм төзелеше, аерым сүзләр дә төрләнәнә: “Әле хәзергә мин үзем исән...”.

С. Хәкимнең шигъри сөйләме татарның әйтмә сөйләменә нигезләнә. Шагыйрь аның табигыйлеген язуда да сакларга тырыша – беренче шигырьләрендә үк ул әйткәнчә язу үрнәкләрен бирде. Бүген тәмам сөрсеп-искереп беткән, милләтебезне адәм көлкесенә калдырган орфография кагыйдәләребез шартларында бу мәсьәләне гамәли хәл итү җиңелдән түгел; шулай да С. Хәким аны да әйтү-язу проблемасын да) татар теле, татар сөйләме файдасына хәл итә килде: “Ә хәзергә *сагну моңын онтып* // Фронт юлын сорый улыннан”; “Бу малай *сагна* диеп”; “Бу күңелнең тынычлыгы бетә,// Борчу арта июнь *кердисә...”*. Бу грамматик чараны ул урыны чыккан саен файдалана: “Карт сөяккә хәзер шул да ярый, // Озак җылынып булмый *югыйсәм*”; “Яңгырлар ныграк *юсайде* // Дөньяның җыелган тузанын”. Без инде шомарып, калыпланып беткән юса идегә күнеккән...

Күрәбез ки, сөйләмнең камиллеген, аһәңен кайвакыт сүзнең өлешләре (морфлар да) хәл итә – моны аеруча шагыйрь тоя. Ул синоним кушымча куллану остасы да. Янә бер мисал: “Өйрәнәләр юлын, юл – *әйләнчек”*. Без булсак, әйләнгеч дияр идек. Морфларны да ул эчтән ничек әйтелсә, шулай язарга да тырыша, искереп беткән, татар теле, татар сөйләме законнарына каршы килгән орфография һәм орфоэпия кагыйдәләрен күрмәскә, буйсынмаска омтыла: “Куркам да соң менә *пленнән”*.

Моны гамәлгә ашырыр өчен аңарга нәшриятнең кәҗүнни редакторлары белән күпме тартышырга, чәкәшергә туры килгәндер. Бит максаты яңача кушымча ясап яисә неологизм кушымча белән мөгез чыгару түгел, ә шигъри сөйләмне аһәңле, шома, күңелгә ятышлы итү: “Йөрим төнге урамнарда, // Йолдызларны күрсәнә”.

Тик хәтта монда да әйтү белән язу кәсәфәтенең татарны гына интектергән проблемалары калган әле: “Аңа инде йөз ел чамасымы // Артык *тадыр* бәлки”.

Мәгънәви өлешләргә игътибар итү шагыйрьгә сүзләрне дә төрле мәгънәдә (синоним, омоним һ.б.), төрле хис төсмерләренә игътибар итәргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, сүзләрне төрле мәгънәви, хисси төсмерләрен табып алып, кабатлаудан да качмый, тайчынмый. Менә *йөрәк* сүзе аңарда да еш очрый. Шәхсән үзем күптән түгел бу сүзнең бүгенге җырларда артык күп, урынсыз, мәгънә, хис төсмерен искә алмыйча, мәгънәсез тезмәләр хасил итеп язулары, җырлаулары турында борчылып махсус язма да бастырган идем. С. Хәкимнең “йөрәкләрен” шул тарафта да күзәтеп алган идем: бер генә урынсыз, кирәкмәс, тач туры килмәгән очрагын күрмәдем. Менә аның бу сүзләре күптән инде җырга салынып күп вакыт җырланып килә; беркемнең да аңа карата ризасызлык белдергәне юк: “Уяна кошлар тирәктә // Җәйге җил куя исеп: // Кузгала җырлар *йөрәктә,* // Шунда син искә төшеп”; яисә “Өздереп нигә карадың, // Ник тоттың чиләгемнән? // Суларым түгел, ялкыным // Түгелде *йөрәгемнән...*”; “Кайда да *йөрәктә, йөрәктә,* // Төшләргә гел кереп йөдәтә // Нигә соң // Нигә соң бу Кырлай яклары”.

Барсы да үз урынында, үз мәгънәсендә, саф татарча, халыкча, Сибгат Хәкимчә.

Оста барда телең тый. Сибгат Хәким шигърияте хәятенең асылын, ягъни без күзалларга омтылган Ил+Тел манзарасының тулы хәсиятен бик кыска һәм тулы итеп шагыйребезне, аның җисми асылын да, шигърятен дә тәфсилле, бөртекле белгән галимебез, шагыйрьнең улы Рафаэль Хәким әйтеп биргән. Башта аның Илгә мөнәсәбәтен: “Сибгат Хәким бөтен дөньяга туган авылы, хәтта үз тыкрыгы күзе белән карый иде, әйтерсең, туган авылы Күлле-Киме бөтен галәм үзе. Кешелек җәмгыяте абстракт булмый, ул синең белән янәшәдә яши торган конкрет кешеләрдән гыйбарәт...”. Инде килеп, Телгә мөнәсәбәтен: “...Телдән башка поэзия яши алмый, киң планда бу – тел стихиясе....”. Нәкъ шулай: Сибгат Хәкимнең шигърият хәяте – ул телебез дәрьясы, аның тынгысыз, мәгърүр яшәве тантанасы.

СҮЗ ТЫЛСЫМЫН ТОЕП

(Афзал Шамов иҗатында тасвирлау чаралары)

Бер укыган китапны кабат кулга алу теләге төрле сәбәптән килеп туадыр. Мәктәптә, югары уку йортында, әлбәттә инде, имтиханга әзерләнгәндә; эшеңдә, балалар тәрбиясенә кагылышлы хәлләрдә; бик истәлекле мизгелләрне яңартасы килеп, хәтирәләргә бирелеп киткәндә...

Шәхсән үземә яшь каләмдәшләргә сабак биргәндә еш кына классик остазларыбыздан үрнәк китерү ихтыяҗы туып тора. Нәкъ кирәкле өзекне эзли-эзли, мавыгып китеп, бөтен бер әсәрне тулысынча укып чыгасың.

Болары аның мәҗбүри килеп чыга торган ихтыяҗдан уку. Шул ук вакытта була сәер бер мизгел: күңелең тиктомалга тибрәнеп китә дә, хәтер зиһен төпкелендә кайчандыр бер сызылып калган нурны яисә бер моң-көй булып уелган сурәт-манзараны ялт итеп тартып чыгара да, күз алдына китереп бастыра. Бактың исә ул хәтирә күңелгә китаптан уелып калган икән. Каударланып китеп, үзеннән-үзе шул китапка үреләсең, йә тынгысызланып, аны табу хәстәрен күрә башлыйсың.

Бу юлы менә Афзал Шамов китабына тартылдым. Бөтен дөньяны онытып, “Рәүфә”гә суырылып кереп киттем. Исеме искә төшүгә үк күнегелгән, гомер буе димәсәң, еш кына кабатлана торган бер гадәт үзенекен итте – туган тел, иҗатта аны куллана белү турында борчылып йә сөенеп уйланганда, үзең язганда тәэсирле сурәт-тасвир чараларын эзләп азапланганда таяныр нокта, “бар иде бит шундый кодрәтле көч”, дип ышанып, үрнәк эзләгәндә, илһам тылсымы кирәк булганда Афзал абый әсәрләрен укыганда алган тел ләззәтен хәтерләп, китабына тартылган минутлар булып тора. Бу юлы да менә форсаттан файдаланып, аның чын мәгънәсендә тел тылсымчысы – телне нечкә тоемлау, оста кулланып укучыга тәэсир итү кодрәтенә ия булган әдип икәнен үзем генә тоеп-ләззәтләнеп калмыйча, башкаларга да – яшь каләмдәшләремә, укучыларыма да – җиткерү теләге кабынып китте. Элек әсәрләрен йотылып уку барышында аерым кәгазь кисәкләренә тәм, ләззәт биргән аерым сүз, гыйбарәләрне, фикерләрне төртеп бара идем. Бүген менә шулардан үзенә бер язма-мәкалә килеп чыкты.

Шулай да мәкаләне укырга керешкәнче бәлки Афзал Шамовның китапларын укып багарсыз. Инде элегрәк укыган булсагыз, кабат уку теләге кабынып китеп, укырга тотынмассызмы. Һәрхәлдә үкенмәссез!

Нәкъ менә шушы авторның, нәкъ менә шушы әсәренең кабат укырга теләк тудыруының шәхсән минем өчен беренчел сәбәбе – ул аның ана телемдә язылып, газиз телем белән тәэсир итүе, хәтергә дә шушы телемнең көче-тылсымы белән уелып-сызылып калынган булуында. Шуңа күрә бу факторның күпләрне кызыксындыруы табигыйдер. Фарыздыр да.

Бер караганда башка авторларның китаплары да ана телебездә, чагыштырмача шундый ук осталык белән, үзенчәлекле итеп язылган бит. Аннары, кабат уку теләге тудырып торган авторларыбыз, әсәрләребез дә, шөкер, аз түгел бит. Аларның да нәрсәсе шулай хәтергә уелып калган да, нинди серле тылсымы белән үзенә тартып тора? Бу хакта да инде беренче тапкыр гына уйланылмаган. Бу да бер миңа гына кагылмый.

Беләм дә кебек үзе: бу бит иҗатның бик тә ябык, нечкә төене, әдипнең шәхси сере-тылсымы, аны ачып-тәфсирләп тә булмыйдыр, шуңа күрә дә ул язучы-сәнгатьченең шәхси сере булып калырга тиештер дә. Шулай да, шулай да... Афзал Шамов дигән тылсымчының миңа тәэсир итә торган, күңел кылларымны тибрәтә алырдай тел тылсымын аз гына булса да ачыклап китәсе килә бит... Хәер, башта әсәрләрен укып карагыз әле, бергәләп ачыклый төшмәбезме.

Уйлый калсаң. төпченә-анализлый калсаң, бер дә аптырарлык, аңлашылмаслак бер ни юк та кебек – нәрсә уйласа, нәрсә кичерсә, шуны укучысына чын дөресен ничек әйтергә теләсә, шулай әйтә, шулай җиткерә. Халык әйтмешли: уендагы – телендә, телендәгесе – язуында. Ап-ачык, шоп-шома, бернинди төртелеп тору, томан-фәлән юк.

Бик гади кебек тә бит, ә ничек ирешә соң ул моңа? Уен-фикерен безгә ана телебезнең нинди чаралары белән җиткерә?

Диккать беләнрәк карый төшсәң, без көндәлек куллана торган гадәти сүзләр, тезмәләр, җөмләләр белән икән. Мәктәптә грамматика өйрәтә торган берәмлек, чаралар белән. Искә төшерик әле шул чараларны.

Көнкүреш сөйләмендә гадәттә гомуми (битараф дип тә атала) берәмлекләр өстенлек итә. Татар матур әдәбиятендә гомер-бакый норма буларак Казан арты сөйләме кулланылды. Төрле тарихый чорларда, төрле иҗтимагый-иктыйсадый-сәяси шартларга бәйле рәвештә ул үзгәрә, үсә, байый, төрләнә барды. Шул ук вакытта әдипләр нормага тугрылыкны, таләпчәнлекне кагыйдә-гадәткә әверелдерделәр, аңа тугры булу югары сәнгати һәм халыкчанлык сыйфаты санала, һәм татар әдипләре шул тугрылыкны сакларга, буыннан-буынга тапшы-

рырга тырышалар. Классикларыбыздан Афзал Шамов бу яктан иң беренче өлге күрсәтте. Аның әсәрләре татар кешесе кайда гына яшәсә дә аңа аңлаешлы, үз әнисенең теле-сөйләме кебек якын, кадерле.

Кайвакыт берәр классикның, хәтта яшьрәк язучының әсәрен, темасы беләнме, яшәү урыны беләнме, бүтән яклары беләнме кызыксынып, укып китәсең дә, тик бара-бара төртелә башлыйсың, аңлашылып бетми, күңелгә ятмый, сүзлекләргә үрелергә мәҗбүрсең. Ничек азагына чаклы укып бетерергә дип изаланасың. Үз телең бит, үз язучың бит, дип гарьләнәсең.

Афзал абыйныкы, менә, ничек шулай шома тәгәри, эссе көнне эчкән су кебек кенә йотыла бара соң ул? Димәк ки, аның сиңа тәкъдим ителгән фикер-төшенчәсе нәкъ синең күңелеңдә, зиһенеңдә теркәлгән, гомерең буе күнеккән төшенчә-сүз гыйбарәләргә туры килә, әдипнеке белән синеке тәңгәл килүе канәгатьлек, рәхәтлек бирә, хәтта горурлык кузгата.

Бер уйласаң, Афзал абый да минем төбәк кешесе түгел, ул үз районы, авылы (Яшел үзән районының Татар Танае авылы) сөйләмендә, үз әнисе телендә тәрбияләнгән. Ул сөйләм аңа якын, ул аның белән горурлана. Кулы да шулай язарга тартылып торгандыр. Ул якларда булганым бар, кайбер сүзләренә, әйтү тонына сәерсенгәнем бар. Әгәр тач ул сөйләмдә язылган текстка юлыксам, сәерсенер идем; чамалыйм, әсәрне буеннан- буена тәмләп укып чыга алмас идем. Әдибебез моны тойган, белгән, шуңа күрә ул барыбызга да якын, гомуми нормага җавап бирә торган шивәдә язарга алынган.

Шул ук вакытта аның әдәби нормага сукырларча буйсынмавын, иҗадый үзенчәлекләргә юл куюын тоясың. Менә гап-гади гомуми (битараф) берәмлекләрнең хәрәкәтен-сулышын күзәтик әле. Юк, юк, текстны уку барышында аларга, төрләренә, ничек аталуларына, классификациясенә һич тә игътибар итмисең, эчтән күңелгә ятышлы бер көй көйләгән кебек яисә бер артистның укыганын-сөйләгәнен колак салып тыңлаган кебек укыйсың да укыйсың. Аңлаешлы, аһәңле: “Язгы ташуның беренче шарлавыклары басылып килә. Кояшка каршы сыртын чыгарып кибә башлаган тау башында яшел уҗымнар күренгәли. Алар тауга түбән сузылып яткан буразналарга тезелгәннәр дә, язгы кояшны каршылап бик матур, бик матур җемелдиләр. Күз өстенә кулны куеп караган вакытларда, алар язгы җил белән дулкынланган кебек күренәләр” (*Шамов А.* Рәүфә: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 3 б.). Карашны аермыйча, тынны, су-

лышны бүлмичә укыйсы да укыйсы, елга агымына бирелеп китеп талгын гына аккан кебек агасы да агасы, тибрәләсе дә тибрәләсе килә.

Шулай да әсәрне бит беренче тапкыр укымыйбыз, ул кадәр исәрләнмәскә, онытылып бетмәскә дә, азга гына бүленеп торып, уйланып алырга да ярыйдыр бит. Гомуми берәмлекләрнең тәэсир көче нидән гыйбарәт? Нигә әсәргә баштук шулай суырылып кереп киттек? Инде ачыклый башлаган идек: авторның фикер агышы минем аңыма, күңелемә авторныкы белән тәңгәл сүзләр, тон белән килеп ирешә – гомуми сүзләр бик конкрет, тәгаен төшенчәләрне күз алдына китерә: *яз, ташу, кояш, тау башы, уҗым, буразна, кар суы...* Һәркайсы минем барлыгымны, яшәешемне, көнкүрешемне, хәсиятемне тәшкил иткән төшенчә-сүзләр, бер тоткарлыксыз җиңел укыла, эчтән җиңел әйтелеп бара.

Туктале, монда шушы тылсымның бер “сер” бөртеге дә җемелдәп китә түгелме: әлеге бик конкрет сүзләрнең күңелгә ятышлы булып сеңеп баруы ул аларның акылга гына түгел, күңелгә-җанга тәэсир итүе, ә моның гомуми берәмлекләрнең үзенчәлеклерәк “кардәшләре” белән табигый үрелеп, гармониядә килүләреннән бит: *сыртын чыгарып кибә башлаган, сузылып яткан буразна, яшел уҗым, бик матур, бик матур җемелдиләр, күз өстенә кулны куеп, язгы җил, су белән саубуллашу...* Болары инде акылга гына түгел хискә дә тәэсир итә торган тасвирый, сурәти чаралар.

Хисле, шигъриятле текст шулай укыла инде ул, диярсез. Ярар алайса, менә аның дәвамына күз салыйк; монысы көндәлек тормыш-яшәеш хәлләре – бик конкрет төшенчә-фикерләр: “Әнә авыл башына тимерче алачыгы янына бер төркем халык җыелган. Аларның кайберләре төзәтергә китерелгән шинсыз көпчәкләр, ватык сабаннар өстенә утырганнар, ә кайберләре тула оеклы, чабаталы аякларын җыйнак кына бөкләп, алачык буена чүгәләгәннәр, бик тәмләп, ләззәтен белеп тәмәке тарталар һәм ашыкмый гына сөйләшәләр...”.

Монда инде барчабызга да таныш гомуми сүзләргә шушы урынга (авылга), шушы кешеләргә (*керәстийәннәр*), шушы темага (*авыл хуҗалыгы, тимерчелек*) караган сүз, хәтта термин, һөнәри сүзләр дә өстәлеп китә: *тимерче алачыгы, шинсыз көпчәк, сабан, тула оек, чабата.* Аңа карап сөйләм агышында алар төерләнеп яисә тырпаеп тормый, ят түгел, бер көй, бер аһәң белән ага бара, күңелгә җылы тәм биреп тарала бара. *Тула, чабата, алачык* яшь укучыга томанлырак тоелса, өлкәннәрдән сорап алу, сүзлеккә күз ташлау телне баету, аннан тәм табу, зиһенеңне чарлау өчен үзенә бер өстәмә шөгыль генә.

Андый берәмлекләрне яшьләр генә түгел, өлкәннәр дә сиземли. Алары башлыча шушы шөгыль, өлкәгә караган (**профессионализм**), шушы шивәнеке булып саналган (**диалектизм**), шушы як кешеләренең, һөнәр кешеләренең үзләренә хас гыйбарә, әйтемнәре (**җаргоннар**) үзенчәлекле берәмлекләр. Әлеге гәптә катнашкан бер агай болай ди: "Ул тауда минем дә *ярымбишем* бар. Әнә ялгыз имәнне күрәсезме? Шуннан уң кулга өч-дүрт *ярымбиш* киткәч".

Бүген уку барышында мондый сәер сүзләргә кул селтәргә кирәкмәс, гомуми сөйләм агышында аларны төшенеп бару (ярымбиш – җир мәйданы, дисәтинәнең өчтән бер өлеше) гомуми аһәңне тулы гармонияле итә; сүзне төшенеп алгач, аның җөмләдәге урыны буш калмый, тулылана. Мондый берәмлекләр аерым, махсус темаларны (җир, игенчелек эше, хәрби хезмәт, медицина, кавалерия һ.б) яктырт-канда күбрәк очрый. Тик алар башка сүзләргә ятышмыйча, чекрәеп тормый. Менә ат мохите, дирбияләре белән бәйле терминнар: *чөңгереп җибәрде, өзәңге, ияр канатлары, нуктасын өзде...* Язучы фикерләвендә татарның ат җанлылыгы, ат дөньясы шулкадәр тулы чагыла ки, кешенең үзенә, үз тәне, үз хәяте белән бәйле төшенчә, күренешләр кебек үк аның хисләрен тулыландыра, бизи. Шунысы кызык, атка бәйле менә бу исем-атамалар күчерелмә мәгънәле троп-лар сыйфатында да кулланылып, сөйләмне табигать җанлы, сурәтле итә: "Юк, юл бирмәскә кирәк аларга, *дилбегәне ныгытып тотарга* кирәк, *авызлыкларга* кирәк аларны".

Башка төр терминнар (армия-солдат-сугыш, дин, медицина һ.б.): "Шулар белән бергә, озак еллар *мәчет мөнбәрендә* сөйләгән *вәгазьләр, коръәннәр, хөтбәләр, хәдисләр,* тагын әллә нәрсәләр көл булып күккә очкан шикелле булдылар".

Авторның телне тоемлау, куллану осталыгын сүз кулланудагы осталыгыннан башта телнең тагын да кечкенәрәк, иң нечкә күзәнәкләреннән, кылларыннан – авазлар, иҗек, мөнәсәбәтле берәмлекләрдән башлау хәерлерәктер. Менә ярдәмче фигыльләргә игътибар итик. Рәсми исеме "ярдәмче" булса да, сөйләмдә алар мәгълүмәт, хис төсмерен иң "җитди" сүзләрдән дә көчлерәк, тәэсирлерәк бирә ала: "Зур шатлыклы хәбәр *сөйли торганнардыр...* (Без булсак "сөйлиләрдер" дип кенә канәгатьләнер идек); "...түгәрәк күл *җәелеп ята"*; "...былчырак сөреп йөрергә *яратып та бетерми";* "...вакытында *түләп барырга* ярата...".

Шулай да гомуми сүзләргә кайтыйк әле – язучыбыз аларны бигрәк тә "түбән белеп" куллана. Иң әвәле ул халыкның **гади сөйләм**

гыйбарәләрен бик урынлы, "тәмләп" куллана: "Әгәр көннәр матур булып, игеннәр уңып китсә, рәхәтләнеп, киң итеп *бер сулар идек сулавын. Ачык-тишекләрне ямар идек"*; **"**Имеш, ул, ватмыйк дип *киңәш иткән була,* янәсе. *Итте пычагым, итмәгән кая! Кадалып китсен.* Менә ничек иде ул без яшь чакта"; "Тфү! Нуркамаллар янында *чүп кенә,* – диде. – *Аларның кисеп ташлаган тырнагына да тормый,* – диде".

Күрәбез ки, сүз дигәндә катып калган бер берәмлек кенә күзалланмый. Шуны тере күзәнәк итеп, төрле рәвешле, төзелешле, җанлы күзәнәк итеп тою кирәктер. Татарның үзенә генә хас берәмлекләрен язучы осталарча тоярга сәләтле. Менә **парлы сүзләр** – татар рухлы, милли сурәтле бөртекләр: "...үз юлына борылып, *зур-зур* атлап, озын артыш таягын селтәп *җибәрә-җибәрә*, тыкрык буйлап китте"; "Имамыгызны *ким-хур* итмәссез, дип ышанам"; "Нәрсәдер *әйтә-әйтә* шаулашырга, гөрләшергә тотындылар"; "*Карап-карап* торам да, җәмәгать, бөтенләй аптырап китәм"; "Алар рөхсәт *сорамый-нитми,* кирәкмәгән мәсьәлә күтәреп, халыкның вакытын әрәм итәләр"; "*Апалы-сеңелле* икәү тәрәзәдән *яшелле-мөшелле* тавыш белән кычкыралар"; "*Фәкыйрь-фокраның* актыккы әйберен тартып аласың"...

Сүзтезмәләргә күчкәнче Афзал Шамовның лексик хәзинәсенең семантик-стилистик асылы турында гәп корып алыйк әле. Әсәрләрен уку барышында бүгенге яшьләр аңлап бетермәгән берәмлекләр арасында гомумкулланыш берәмлекләре дип саналганнары да бар. Болар халык аңында яши, тик аларның куллану дәрәҗәсе бүген кимегән, ягъни пассив лексикага әйләнеп бара: **"**Бераздан соң алар игеннәр арасыннан *абаланып* бара башладылар"; **"***Хәйран* булып тынып калганнар"; "*чытлыклану*, назлану"; "...кешеләр дә бик *сүрән*"; "Егет сүзгә бик *зәвык, чая* булып чыкты"; **"**Келәт *кырпуыннан* шыбырдап тамчы тама иде"; "*кырпуы чачаклана* башлаган эшләпә чите"; "бер читкәрәк, *ышыккарак* куып кертте"; "Мулла өчен *кычынып* йөрүчеләр бар"; "Аның алдында *рияланып* кына аны яклаган булып күренергә маташалар"; "*Бетәшкән* карт".

Исемлек шактый озын килеп чыга. Телебезнең иң гади берәмлекләре дә пассивлаша икән. Моңа юл куярга ярамый. Классикларыбызның әсәрләрен уку, аларның сүз байлыгын өйрәнү – бу юлда иң нәтиҗәле чарадыр.

Гади сүзләр генә түгел, алардан төзелгән троплар да пассивлаша: "Нәсыйхның чираты койрыктарак иде"; "Ул аякларын итәге белән *томалап*, куллары белән тезләрен *кочкан* да".

Гомуми лексиканың да, димәк, пассив состав арасында да уңай һәм тискәре берәмлекләр барлыгын тоемлау бик мөһим. Әдип Шамов аларга бик сизгер, битараф түгел, аларның тәэсир көчен нечкә тоемлый: “Шулай да Хасиятнең *начар* ниятле, майлы, *елгыр* күзләре, *елан* сызгыруыдай чыҗылдап чыккан *әшәке* сүзләре күңелендә ...*җирәнгеч* бер тойгы калдырды”.

Хәзер әдип иҗатында сүзтезмәләрне, аерым алганда күчерелмә мәгънәле берәмлекләр – фразеологизмнарны, куллану үзенчәлеген күзәтүгә күчик. Афзал Шамов – сөйләмдә фразеологизмнарны куллану остасы. Менә озын булса да исемлек китерик әле. Аларны өйрәнү, сөйләмебездә кулланырга омтылу файдага гына булыр иде: “*Серкәсе һич тә су күтәрми...”; “Өлкәннәргә тел тидерү килешми дә инде...”; “Сүзләре йөрәгебезгә май булып ятты...”*; “Кайчак, әнием искә төшкәндә, *йөрәгем өзелеп китә...”; “Күлен күккә очырып* була...”; “*Йөрәккә кан сава...”; “Җенем сөйми* минем мыскылны”; “Ярар, ярар, *салам кыстырмагыз...”.*

Уңай һәм тискәре фразеологизнар нисбәте саклануы – уңай күренеш: “...Сезгә сүзем шул: каһәр суккан залимга илебезне, хөрриятебезне таптарга, мәсхәрәләргә ирек бирмәгез. *Себереп түгегез* аларны. *Юк итегез. Нәселләрен корытыгыз!”.*

Фразеологизмны катып калган, штамп фраза, үзгәртергә ярамый, дип күнеккәнбез. Афзал абый һич андый фикердә түгел. Ул аларны ничек кенә үзгәртә, хәрәкәттә иттерә, җанландыра әле! “Шат ул**,** *авызы ерылган,* халыкча арттырып әйткәндә, *колакларына җиткән.* Бәхетле ул бүген”.

Кирәге чыкканда, ул андый гыйбарәләрне үзе дә иҗат итә, “ясый”: “Йөрәкләре *күлгә әйләнер”;* Без бик күптән *тояк ялтыраткан* булыр идек”. Бу афоризмны ул – кавалерист бит – *аяк ялтыратканга* охшатып ясаган.

Фразеологизмнарны текстта урнаштыруның да тәэсири әһәмияте бар бит, әдип бу өлкәдә дә оста: әйтик ул аларны персонаж сөйләме аркылы кертә. Шулай табигый, үтемле килеп чыга: “Хатыңны гелән-гелән язгалап тор**.** *Кош теле буе гына* булса да яз. Онытма, яме. Без синең өчен монда *ут йотып...*”; “Итәкләреңне җый, ягъни *койрыгыңны җый.* Җыймасаң, бөтен эчәгең-ниең белән йолкып алып китәрләр”.

Татар телендә тезмә троплар мәгънә күләме ягыннан үсә барып, формасы белән дә төрләнәнә, үсә бара – әйтем, гыйбарәләргә, аннары инде мәкальләргә әверелә: өйләнгәннәренә *бишбылтыр; җир тишеге*

булса, кереп китәр идем; *кадалган,* җиле дә туктамый бит. *Эх, кадалып киткере.*

Афзал Шамов – әсәрләренә татар мәкальләрен җәлеп итү остасы. Моңа тәфсиллерәк тукталыйк әле. Башта иренмичә халык җәүһәрләрен кабат укып, ләззәт алыйк, зиһенгә сеңдерик, кирәге чыкмый калмас: *майсыз таба купмый бит ул; кыз кемгә бармас та, егет кемне алмас; җаны теләгән елан ите ашаган; борыңгылар: иш ишен эзли, җил тишеген эзли, дигәннәр; көлке көлә килә, артыңнан куа килә; сабыр төбе сабыр алтын; сыйлаганда су эч; тырышкан табар, ташка кадак кагар; киңәшле туй таркалмас; йөз сум акчаң булганчы, йөз дусың булсын; туйда тукмак та сикерә; башыңа төшкәч, башмакчы булырсың.*

Еш кына яшь язучылар әсәрне халыкчан итәм, дип, үзенең халык иҗатын белгәнен күрсәтер өчен әсәрнең буеннан-буена мәкаль, әйтемнәр, канатлы гыйбарәләр тезеп китә. Афзал Шамов халыкның гасырлар буе бөртекләп җыелып килгән ул хәзинә энҗеләрен алай уптым-иллаһый ыргытып бармый, кадерен-тәмен белеп, нәкъ кирәкле урында гына җемелдәтеп җибәрә: “Булса соң! Үз балаң бит. *Ана күрке – бала,* дигәннәр борыңгылар. Аннары, *бал татлы, балдан бала татлы,* дип тә әйткәннәр...”; “*Асыл суга батмас,* дигән сүзне ишеткәнең бармы синең, кызым?– диде Патый әби”.

Бездә кайбер язучы мәкаль, әйтемне әсәргә кирәксә дә, кирәкмәсә дә, җанландыру, халыкчанлык билгесе дип, төртеп баручан. Андый өстәмә юньле генә әсәрдә дә артык “бөкре” булып тырпаеп тора. Афзал Шамов әсәрләрендә мәкаль очрап торса да, алар нәкь үз урынында – мәгънәле һәм хисле. Иң башта алар – мәгънә төгәллегенә һәм тулылыгына ирешү чарасы. Икенчедән, ул әсәрнең композиция, сюжет төзеклеген саклау, камиллеккә, аһәңлеккә ирешү чарасы да. Менә берничә мисалга тәфсиллерәк тукталыйк әле. Бу очракларда мәкаль эчтәлек бөтенлеген генә түгел, әсәрнең төзелеш камиллеген дә сакларга хезмәт итә: *“Әйткән сүз – аткан ук,* – дигәннәр бабайлар. Аннары, *егетнең сүзе үлгәнче, үзе үлсен,* дип тә әйткәннәр. Сүзеңдә тор, Гыйсмәт, – диде”.

Бу мисалда мәкаль үзенә бер диалог тәшкил иткән. Ә менә болар әсәр эчендә кечкенә генә бер сюжетлы парча кебек кабул ителә: “Апамның сүзе чыннан да дөрес булып чыкты. Аннары, борыңгылар да белми әйтмәгәннәр бит: *матурлык туйда кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк,* дигәннәр. Нинди дөрес сүз! Каян белгәннәр!”.

“Кайчак борыңгыларга да ачуым килә. *Анасызны килен итмә, атасызны кияү итмә,* дип әйтеп калдырганнар. Имеш, мин атасыз егет. Ә мин менә, аларга үч итеп, анасызга да өйләнергә әзер”. Ә менә бу очракта бер мәкаль бөтен бер сюжет өзеге, үзе берничә җәпле фикер агышының сәбәпчесе булган: Кайчандар бер акыллы карт миңа: *“Туйга барсаң, борын бар, борын барсаң, урын бар; ашап-эчеп туй да кайт, соңа калсаң сугыш бар”,* – дигән иде”.

“...Күрше авылның бай гына бер картыннан Миңҗамалга яучы килеп төшкән. Ата-аналары бирергә риза булганнар. Миңҗамалны чагырып, яучы алдында сораганнар. Ул ни дип җавап биргәндер дисез? Ишетмәсәгез, ишетегез.

– *Карт куенында калач бар, калачы да кан белән, яшь куенында камчы бар, камчысы да бал белән – калачлыга күнә алмам, камчылыдан бизә алмам,* – дип җавап биргән.

– Кем соң ул камчылы яшь егет?– дип сораганннар аңардан.

– Кем булса, шул, – дигән ул. – Ләкин акыллы егет,– дигән”.

Кем икән соң ул акыллы егет? Мәкалгә нигезләнеп менә нинди үзенә бер парча килеп чыккан. Иҗат итә белгәч.

Тагын бер парча: “Бәлки, син расхут-фәлән дип курка торгансыңдыр? Бер дә курыкма, бер тиен дә расхут чыгачак түгел, Гыйсмәт акыллым, – диде, – өс-башы бөтен, сөлге-җәймәсе җитәрлек. Бу яктан бер дә кайгырма. Акылга дисәң – акыллы, эшкә дисәң – эшкә уңган, матурлык дисәң – матурлыгы килгән... *Яхшы хатын – җан азыгы, яман хатын – баш казыгы,* диләр бит. Аннары тагын: *уңса – казна. уңмаса – каза,* дигән сүз дә бар. Миңҗамал инде ул бер үк вакыт җан азыгы да, казна да, – диде”.

Укыганда сизә барасың: әдип мәкальләрне калып-рәсмилектән арындыра, җанландыра, хәрәкәтләндерә. Мәсәлән, ул аларны туры сөйләмгә, персонаж сөйләменә җәлеп итә, шунда үзгәртә: “Шулай менә. *Ашыккан ашка пешкән, дигәннәр. Авызың пешмәгәе”.*

Чын иҗатчы буларак, Афзал Шамов үзе дә сүз иҗатына һәвәс. Моңа мисалларны без телнең төрле чараларына (иҗек, кушымчалар, неологизмнарга) карата да күргән идек: “Инде күк йөзе аксылланганнан-аксыллана бара, авыл читләрендәге акшарлы йортлар... беленербеленмәс кенә *шәүләләнә* башладылар”; “Дмитрий Иванович – *чатлыктагы* пивной һәм бакалея магазины хуҗасы” һ.б. Аның мондый сәләте мәкаль белән эш иткәндә аеруча ачылып китә. Аның мәкальгә тартым гыйбарә, афоризмнары Нәкый Исәнбәт тарафыннан да теркәлгән иде. Менә без күзәткәннәре: *ач карын белән сугыш сугыш-*

мыни ул. Моны ул карт солдат авызыннан әйттертә. Бәлки автор үзе дә ясап куймады микән әле. Яисә: *командир приказы – безнең өчен закон. Ә законны үтәмичә ярамый.*

Әйткәнебезчә, Афзал Шамов мәкальләрне, гомумән, халык авыз иҗатын куллануны үзмаксат итеп куймаган, халык игътибарын тартып алып укырлык итү белән ул, халыкның тел җәүһәрен укучылары аша телдә саклап калу, аны буыннан-буынга тапшыру бурычын да куйган. Халык гыйбарәләренең нindiләрен генә табып кулланмый бит: *сөйләшмәгәч тә көлмәгәч, дөньяның ни кызыгы бар.* Әйтик, мәкаль бит ул гадәти сүзләр тезмәсе түгел, аның тарихи эчтәлеге, архаик бай, бик үзенчәлекле лексик хәзинәсе бар. *Сабырсызлык ул шайтан ләгыйнь вәсвәсәсе.* Менә бит: шайтан, ләгыйнь һ.б. Шуларны хәтердә яңартып, мәгънәләрен эзләп табып, үзең дә яңа энҗеләргә байыйсың, сөйләмеңне баетасың.

Тасвир, сурәт чараларына янә: гади сүздән **эпитет** ясау: “Алар, атларына атланып, шул авылга таба *очтылар”; ”*Салкын. Һавада *авыр* болытлар йөзә. Һәр залп аларның кан тамырларына *яңа көч, яңа дәрт* бирә”. Мәгънә төгәллегенә ирешү чараларыннан: **өстәлмә, аныклагычлар:** “Хатыннар да кайчандыр бу көйне тыңлый-тыңлый, үзләренең *җанкисәкләрен – ирләрен* каядыр еракка, кош-корт очып җитмәс җирләргә озатканнар. Барысына да, яшенә дә, картына да таныш иде бу көй”. Үзе сүз, сүзформалар ясый, сүзнең төзелешен үзгәртә **(неологизмнар):** “...Еракка, карлы тауга менеп киткән юлга, андагы *карамчыкларга* карап, һаман басып торалар иде”.

Осталык нечкәлекләренең тел белән сурәтләүгә караган янә кайбер факторлары. Хәрәкәтне күзаллаплык итеп, тасвирлы итеп бәянлавы: “Ә көзге яңгырлы җил белән ачылып киткән форточка туктаусыз шыгырдый – бер ачыла, бер ябыла. Ул кай минутларда җан әрнеткеч тавыш белән әкрен генә чинап тора, аннары шапылдап ябыла да, яңадан кайтарылып китеп, стенага килеп бәрелә. Көзге салкын, эре яңгыр тамчылары, бүлмә эченә керергә теләгәндәй, тәрәзәгә килеп бәреләләр”. Гомуми рәвешне, сыйфатны конкретлаштыра, тәгаенләштерә: “Таныш көй иде бу. Шуңа күрә *матур да,* моңлы да, кайгылы да, сагышлы да иде”. Конкрет булмаган, артык гомуми “матур”ны әдип тәгаенрәк итүне, “чәйнәп” бирүне кирәк таба.

Гомумән дә, рәвеш, сыйфатны ачыкларга, төгәлрәк итәргә омтыла: “Унтугызда гына булса да таза гәүдәле, *яшьлеге аңкып торган алсу йөзле,* кара чәчле, карасу күзле иде”. Моңа ул аерым эпитетлар белән дә, төрле сурәт чаралары белән дә ирешә: “Әлмәндәр егетләре

икәнен беркайчан да онытмасыннар. Аллага шөкер, безнең әлмәндәрләрнең *сыртларын җиргә салганы, йөзебезгә кызыллык китергәне* юк". Болар – фразеологизмнар.

Янә дә тасвир чараларыннан **кабатлау***: "Шулай,* – диделәр картлар, аның фикере белән килешеп. – *Шулай*. Нигә *шулай* булмасын. Билгеле*, шулай"; "*һавадан яз *исе*, кояш *исе* һәм сизелер-сизелмәс кенә булып бөре *исе* аңкый"; "...авыл да, нигезеннән кузгалып, түбәнгә, *бик тирән, бик тирән* упкынга мәтәлгән кебек булды"; "Нәрсә булса да *бик зур, бик зур* үзгәреш булган иде". **Чагыштыру***: "...*чүгәләп биергә, *орчык шикелле бөтерелергә* тотынды"; "Кузгала да алмыйм, телем дә әйләнми, башым да *үлгән кош башы кебек салынып төшкән;* "...сугышчыларның кайберләре... *мәчедәй бөгәрләнеп* ятканнар..."; "...гармун телләреннән *саф көмештәй* агылып чыккан моңлы авазларны ишетү".

Образ (сурәт) күп түгел, тешкә тими, туйдырмый. Аз булса да яңа, сирәклеге белән үзенә бер табыш булып тәэсир итә. Мәсәлән, әдәби сүзнең дә төрле вариантлары эзләп табыла: "Аларның сүзләрен *юпләп* тордылар". Тасвири детальләр табыла яисә ясала: "Алайса, ал да гөл икән..."; "Әбиеңә сәләм әйт, бабаң утырмага килсен"; "Сеңел дә яшь әле, *ватып эшли алмый"* (**оксюморан**); "Ә менә мин *тереләй утта янам"* һ.б.

Күрдек ки, Афзал Шамов – чын мәгънәсендә тел белгече. Шул ук вакытта әдибебез сөйләм белгече дә. Аның иҗатында да сүз куллану бит үзмаксат түгел, төп максат-ният – сөйләм ихтыяҗын канәгатьләндерү. Иң мөһиме, ул сөйләм оештырганда телдән башка чараларны да тоя, шуларны укучыга да җиткерергә тырыша: "Шул вакыт Гайфетдинев аңа, *бутылка сыман граната сузып, тыныч тавыш белән әйтте:*

– Мә, ременыңа кыстыр. Капсюле тыгылган. Тик бик кирәк чакта гына, өерелеп килгәндә генә ыргытырсың. Минем яндарак бул!

Бу сүзләр аны тынычландырып җибәрде. "Минем яндарак бул!" Аның мәгънәсендә генә түгел, *әйтелешендә* дә Нәсыйхка билгеле булмаган, аның күңелен *тынычландыра торган ниндидер көч* бар иде. Шул *көчкә буйсынып,* ул дошман солдатларының якынлашуларын көтте, хәтта кайсысын мушкага аласын да күңеленнән чамалады".

Әдип сүзне сөйләм мотивларына карап, кемнең әйтүе, кемгә, нинди нияттән әйтүенә карап сайлап ала. Хәрәкәтне тәэсирле тасвирлау үзенә бер осталык сораса, сыйфат, рәвешне тасвирлауга – үзенә бер сәләт, осталык. Менә ул, әйтик, сыйфатны ничек күзаллый: "Көн

караңгыланды, ярауланды. Миләрне кайнатырлык кызу сүрелде. Урамнардан кызган таш исе күтәрелә башлады”.

Сөйләмне табигый **бәйләү чараларын** табып, урынлы куллану – ул сөйләм оештыру осталыгы билгесе. Мәсәлән, текстта **сүз кабатлана:** “Бәлки, шүрли торгансың. *Гайкаларың бушагандыр?* Их, син, картлач. Ә үзең герой!..

Кавалеристлар көлеп җибәрделәр. Тик карт кызылармеец кына көлмәде, ләкин аның йөзенә ачу да чыкмады, хәтта ул иптәшләренең дусларча көлүеннән канәгать тә иде.

– *Гайкаларым бушамас,* алар нык беркетелгән, – диде ул тыныч кына. – Менә синең *бушый* күрмәсен, ул чагында эш чыннан да харап...”.

Кыскасы, телебезнең һәр бөртек сүзеннән дә хисси бер сурәт ясарга сәләтле әдибебездән өйрәнергә дә өйрәнергә әле...

ШАГЫЙРЬ ҖАНЫН НИ ТИБРӘТӘ?

(Чикләр чикли алмаган иҗатчы)

Шагыйрь – ул үз җанының талпынуын бүтәннәр җанына җиткерә алучы. Бу аның яшәвенең, иҗатының төп максаты. Шуңа күрә дә ул табигатьтә, тереклектә монын өчен кирәкле нинди ысул, җай, әмәл бар, барчасын күзәтергә, зиһененә сеңдерергә тырыша. Ә бит тереклек ияләре кардәшләрен җәлеп итәм дип ниләр генә кыланып бетми; ул күбәләкнең чуардан-чуар канатларын каккалапмы-каккалавы; ул сандугачның нинди генә тавыш тибрәлдерүләре белән күңелне җилкендерүләре; ул язгы тамчыларның беренче күлләвегендә кызыл тәпиле казның биюләре. Болар барысы да дәшү, чакыру, җәлеп итү хикмәтләре.

Ә җансыз күренеш-манзараларның күңел тибрәтүләре: ул чишмәнең нәфис камышларны чайкый-чайкый челтерәве дисеңме; ул усак яфракларының үтә талгын җилдә дә лепер-лепер «серләшергә» дәшүе дисеңме...

Боларның барысына да иң әүвәле шагыйрь гамьле, сизгер – бүтәннәр күңелен үз дулкынында тибрәтү өчен дөньяда күпме хәсият, әмәл бар икән!

Тик шагыйрь булып шагыйрь дә, никадәр генә сәләтле саналмасын, бигрәк тә кәгазьдә, сандугач кебек сайрый да, күбәләктәй кагына да алмый, җилдәй сызгырырга, дулкын кебек сарылырга да кулыннан

килми. Үз фикерен, хис төсмерләрен бүтәннәргә җиткерү өчен дә, менә бу хикмәтләрне күз алдына китерер өчен дә аның чара-коралы бер генә – ул да булса Сүз. Бүтән чарасы юк. Шагыйрь үз укучысы, тыңлаучы, тамашачысы белән араны бары шушы үтә нечкә серле җеп – Сүз – белән генә бәйли, тоенли, тукый ала.

Тукта, нигә соң әле һәркемгә мәгълүм бу хакыйкатьне бүген килеп шушындый пафос, үҗәтлек белән кабатларга кирәк булды? Болай эшләп – иҗат белән, талант, шигърият белән бәйле үтә нечкә, серле-тылсымлы гамәлне шәрәләндереп, схема-механизмга салып, сәнгати дәрәҗәсен төшермибезме? Асылда чын шагыйрь бу тылсымны үзе дә ачык кына күзаллап эш итә микән әле? Шәхсән үзем шигъри сүз иҗатының иң остасы дип Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Хәсән Туфанны санасам да, шигырьләрендәге һәр төшенчә-сүзне тере энҗе күзәнәкләр дип күз алдына китерсәм дә, аларның шушы могҗизаны шулай-шулай барлыкка китерәбез дип аңлатып-төшендереп бирә алуларына ышанып бетмим. Сүз нечкәлеген, тылсымын тоемлау ул ана сөте белән, табигый талант белән биреләдер, ә аның асылын, хәсиятен аңлатып бирү һәркемнең кулыннан килмидер.

Шулай да аңлатып бирә алу-алмау бер нәрсә, әмма шагыйрь үзенең төп коралы – теле турында барыбер уйланмый кала алмый. Сүзне – бердәнбер коралны – җентекле белү, үзең атап язган укучыга аның ничек барып җитүен күзәтү, кирәк булганда сүз байлыгыңны тулыландыру, сөйләмеңне чарлау зарур бит.

Монысы да мәгълүм хакыйкать ләбаса, шагыйрьләр бар икән, шигырь язалар икән, алар бары шулай гына эш итә ала, шулай язарга тиештер бит. Әйе, тиешен тиеш тә, ә нигә соң төрле шагыйрь укучысында төрле тәэсир калдыра, хәтта бер үк шагыйрьнең ике шигыре төрлечә тәэсир итә?

Шундый сорау куела икән, шагыйрьне аңлау коралы бердән-бер – ана теле булган кебек, укучының да бу сорауга җавабы да шагыйрьнең сүзгә, телгә мөнәсәбәтенә бәйле булыр.

Менә шушындый бормалы-сырмалы кереш сүзнең нигә кирәк булганын әйтер мәл дә, ниһаять, җитте бугай. Бүген мин шагыйрь Әнгам Атнабаев шигырьләренең тәэсир көчен, тылсымын аңларга телим. Ә нигә? диюче дә булыр, гадәттә яраткан шагыйреңнең китабын тансыклап, сагынып, эзләп табып аласың да, ямен, тәмен, хисен әкренләп сеңдерә барып, укыйсың йә тыңлыйсың. Бу мәлдә шагыйрьнең моңа ничек ирешүен, нинди сүзләр, җөмләләр белән шулай тәэсирле, оста яза, дип анализга бирелмичә, тәмләп, йотылып укый

бирәсең – шул гына. Шагыйрьнең максаты, бурычы да шулдыр бит. Димәк ки, бу очракта Әнгам Атнабаев та ният-максатына ирешкән.

Ии-и-х, бүтән шагыйрьләргә карата бик тә табигый тоелган бу теләк Атнабайга карата хыял булып кына кала шул. Барлык язган, басылганнарын тәмләп укырга, күңеленә сеңдерә барырга иде дә бит, юк шул, татар шагыйренең бер генә китабы да Казанда басылмаган. Уфада татарча басылган бер-ике китабы да әллә кайчан таралып беткән. Калган барысы да диярлек Башкортстанда башкорт шрифты белән басылган. Татарча басмага күнеккән кеше, табигый ки, аларны төртелмичә, тәмләп укый алмый. Мәсәлән, менә бу юлларны укыганда (гафу итегез): Йәйге койаш күзен асыу менән... Трибунаны косоп лыгырдай... «Чапай» уйнап Сейә тавында...

Мәгълүм сүзгә күз төшүгә үк иң башта төртеләсең, мәгънәсен аңларга теләп, тәрҗемә итәргә мәҗбүр буласың... Кая инде монда тәмләп, ләззәтләнеп уку...

Бик яхшы беләм, шагыйрь иҗатын тагын да якыннанрак белгән туган, кардәшләре, иҗатташлары да раслар – әдип һәр әсәренең һәр төшенчәсен татарча уйлап, һәр хис төсмерен татарча кичереп, һәр язганын күз алдына татар аваз-хәрефләре белән китереп (чөнки мәктәптә дә, югары уку йортында, эштә – татарча «Кызыл таң» газетында) иҗат иткән; кыскасы, бөтен гомере буе татарча уйлаган-язган, иҗат иткән; язганнарын да, әлегә кәгазьгә төшерелмәгән фикерен дә ул татар кешеләренә дә, башкорт дип аталганнарга да саф татарча гына сөйли иде. Үзем шаһит: инде мәҗбүр ителсә (рәсми җыелышларда, радио, телевидениедә) әлеге шул башкорт шрифты белән басылган китаптан сакаулый-сакаулый, төртелә-төртелә укый башласа да, азакка кадәр түзә алмыйча, татарчага күчеп, тәмләп, рәхәтләнеп әйтеп бетерер иде.

Автор үзе дә ихластан укый алмаган, сөйләргә теле әйләнмәгәнне ничек инде бүтән кеше теләп, ихластан укый алсын ди, йә. Ә шагыйрьгә моннан да авыр кичерерлек, гарьләнерлек тагын нинди хәләт булыр, йә. Гомумән дә, әйтәсе фикереңне, кичергән хисеңне бүтәннәргә нәкъ үзеңчә җиткерәм дип уйлап әзерләгәч, язгач, шуны нәкъ теләгәнчә җиткерә алмау, ягъни тыңлаучы, укучы, тамашачы белән уртак телдә аралаша, сөйләшә алмаудан да үкенечле фаҗига теләсә кайсы иҗатчы өчен тагын булырмы?!

Бәла шунда ки, бу фаҗига аерым кеше, төркемнәрне генә түгел, бөтен милләтнең җанын талкып килгән фаҗигадер. Әнгам Атнабайга мөнәсәбәттә яңарып китсә дә, ул күптән килгән яра бит: Татарстан – Башкортстан, татар теле – башкорт теле бәйләнешләрендә, Гафури,

Бабич, Юлтый, Таһиров, Кудаш кебек шәхесләргә дә кагылышлы рәвештә искә төшеп, күңелләрне җәрәхәтләп тора торган яра инде ул... Милләтне таркатуга, бүлгәләүгә мәҗбүр иткән ясалма-курчак республикалар, ясалма-курчак телләр яши килгәндә ул яраның тиз генә төзәлүе ай-һай ла бик тә икеле...

Хәтерлим, алтмышынчы-сиксәненче елларда да Башкортстанда бу фаҗигагә дучар булганнар бер Атнабай гына түгел иде. Берәүләр кендекләрен туган илдән өзеп-канатып, Казанга китәргә мәҗбүр иде. Ә Әхмәт Гайсин, Равил Шаммас, Муса Сираҗилар бердәнбер татар газеты «Кызыл таң»га сыенып, татарча язып бастыруларын дәвам иттерә алса да, татар халкының түгел, Башкортстанның да тулы хокуклы шагыйре була алмасына әрнеп, гарьләнеп, тешен кысып, җан асрарга мәҗбүр иде. Аларның һәркайсына үз хокукын даулап, шуның өчен көрәшеп, күпме өстәмә рухи һәм матди көч исраф итәргә туры килә иде.

Кайберәүләр әле дә шул гайре табигый, ясалма-зәгыйфь сөйләү, язу читлегенә кереп кысылып, талантлы гына әсәрләрен дә милләткә ят-сәер гибрид, мутант, кушылгак хәлендә тәкъдим итәргә, ягъни ирексезләнергә, икейөзлеләнергә мәҗбүр. Талант тәтемәгән әрсез адәмнәр, эшкуарлар исә шушындый хәләттән дә үзләренә файда чыгарудан, татар-башкорт каршылыгыннан тәмләззәт табудан да чирканмый.

Чын милли шагыйрь, әлбәттә, ясалмалыкка яраклаша алмый, ул һәрчак хакыйкать ягында. Тартышырга, көрәшергә мәҗбүр. Шамил Анак, Рим Идиятуллин, Фәрит Габдрәхимов кебек милләтпәрвәрләр шагыйрьлекләре өстенә ялкынлы публицист, сәяси трибун сәләтен дә күрсәтергә тиеш булдылар. Тик алар да күпме көч исраф итеп тә, үзгәреш җилләрен көтеп алсалар да, кәсәфәттән бөтенләй котыла алмадылар. Башкортстанда татар иҗатчылары тарыган ачы язмыш бүген дә яңа буын шагыйрьләрен дә ташламый, буа тора. Бу сәясәт милләт мәдәниятенең, әдәбиятенең тамырларын бу төбәктә яман шеш кебек кимерә тора.

Бу фаҗига-каза шигъриятьне генә түгел, иҗатның башка юнәлешләрен дә корыта. «Атнабай феномены»на шушы көнгә кадәр җавап табылмавы Башкортстанда фәннең дә шушы сырхауга тарыганын раслый түгелме. Чын әдәбият үзе булмагач, аны өйрәнергә тиешле әдәби тәнкыйть фәне була алырмы? Ул чыннан да юк, бүген Башкортстанда әдәби процесс, иҗади осталык мәсьәләләре объектив өйрәнелә алмый, дөрес нәтиҗәләр ясарга мөмкин түгел. Халык күпме

кызыксынса да, мәсәлән, шагыйрь Әнгам Атнабаевның үз укучысына көчле тәэсир итүенең сере, фәнни асылы нидән гыйбарәт, дигән сорауга «фән» нигезле җавап бирә алмаячак. Омтылып та карамаячак. Хәер, әйтик, Чокрый, Гафури, Бабичларны «башкорт теле әдипләре» дип анализлаганда нинди дөрес фәнни нәтиҗә ясап булсын.

Аңлашылса кирәк, болар хакында борчылучы, уйланучы бер мин генә түгел, чөнки бу бит бер Атнабай, бер шагыйрьләр, бер Башкортстан иҗатчылары хәсрәте генә түгел, бу телебез, мәдәниятебез, милләтебезгә кагылган, бөтен халыкның җан талкуына әйләнеп, казасы артканнан-арта барган чи төендер. Аны чишү юлларын эзләү — иң өлгергән мәсьәләдер.

Шул сәбәпле шәхсән үзем, бата барган кеше салам бөртегенә ябышкан сыман, мәсәлән, Әнгам Атнабаев турында чыккан «Был ерзе мин матурларга тыудым...» дигән башкорт шрифты белән басылган истәлекләр мәҗмугасына (Өфө: Китап, 2003) игътибар итми кала алмадым. Китап бер-ике утыруда укып та чыгылды. Бөтен эзләгәнем, төпченгәнем– әлеге дә баягы шул Әнгам Атнабаевның, шагыйрь буларак, төп коралы – ана теленә мөнәсәбәте: ничек ул уй нечкәлекләрен дә, хис-тойгы төсмерләрен дә шулай халыкчан итеп, барча укучыларының да зәвыгына, күңел талпынуы, дулкын тибрәнешенә тәңгәл килерлек итеп шигырь сөйләмен төзи белә; каян ала ул уй-хис төсмерләренә тач килгән сүз, гыйбарәләрне, татар аңына, аһәңенә, көенә муафыйк килә торган фраза, җөмлә, фигураларны ничек таба ала?

Хәер, боларга җавапны без фәнни хезмәтләрдән эзләргә тиеш идек тә бит, алары булмагач, нишлик соң? Шөкер, Башкортстанда туып-үсеп, татар шигъриятенең югары мөнбәренә күтәрелә алган дистәләп шагыйрьнең (Илдар Юзеев, Саҗидә Сөләйманова, Әхсән Баян һ.б.) татар халкына Казан аркылы мәгълүм булган иҗат җимешләре, шул җөмләдән тел куллану тәҗрибәсе дә фәнни яктан шактый җентекле өйрәнелгән – диссертацияләр язылган, кайбер әсәрләре мәктәп, югары уку йортлары программа, дәреслекләренә кертелгән. Тик бу исемлектә Әнгам Атнабай һәм аның дистәләп якташы юк. Талантны кайда яшәвенә карап өйрәнү, бәяләү – дөньяда күрелмәгән мәгънәсезлек ләбаса. Шундый түбәнлеккә килеп төштең мени инде, татар фәне! Чын талантларның иҗатын барламый торып, тәҗрибә сандыкларын ачып бетерми торып, яңа яшь иҗатчыларга ничек юл күрсәтергә, ничек илһам нуры, ялкыны бирергә була?!

Баштук бик пошынып һәм әрнеп әйтергә мәҗбүрмен: җанны талкыган әлеге борчулы төерне бу мәҗмуга да чишәргә булышмады. «Шагыйрь һәм ана теле», «Әнгам Атнабай шигъриятенең тәэсир тылсымы» мәсьәләләре чишелмичә, томан хәлендә кала бирә. Югыйсә, истәлек авторларының байтагы (Рәиф Әмирев, Суфиан Сафуанов, Суфиан Поварисов, Гайса Хөсәенев һ.б.) – филология фәне белгечләре, ягъни әдәбият нәзариясен, татар әдәбиятенең дә, яхшы белгән, аерым алганда, шагыйрьгә чын бәяне аның тел, сөйләм нечкәлекләрен ничек белүе, ничек оста куллануына карап кына биреп булуын яхшы төшенгән галимнәр.

Бу хезмәттә алар укучы көткән зарури ихтыяҗга җавап бирүдән шактый ерак тора, тулаем алганда, сүз куешкандай, бу темадан читкә киткәннәр; тел яшерәләр.

Әлбәттә, барлык укучыны, шигырь сөючене талкый торган борчуны әдәбият белгече саналган кеше бөтенләй үк күрмәмешкә сабыша алмыйдыр. Рәиф Әмирев, мәсәлән, Әнгам Атнабаевның үз төбәгендәге шагыйрьләрнең аяныч хәлен гомумиләштереп, яшерен тел белән тасвирлаган юлларына гамьсез кала алмаган.

Башын кискәндә үзебезчә
Җырлап үлде татар уллары.
Җырлап үлгән татар улларының
Бүген яшәп яткан уллары.
Телегезне кемнәр алмаштырды,
Җырыгызны кемнәр урлады?

Заманында шагыйрь күңелендә бөре хәлендә булган, мәгълүм шартларда чәчәк булып тулыша алмаган фикер-хисне бүген килеп галим, шагыйрьнең фикердәше булып, ачык тел белән тәфсирләп, тулыландырып бирә алыр иде бит; юк шул, шагыйрь кабыза башлаган очкынны ул тәмам сүнү хәленә төшергән, аның ачык кыйбласын читкә үк борып алып киткән: «Ә. Атнабаевның, тыңлаучыны хәйран калдырып, үз телендә тәмле итеп сөйләве үзе бер рухи көчкә әйләнде... Аның «ярамыйга карамый» эшләнгән бу адымы... аркасында Ә. Атнабаев иҗатын рәсми органнар күп еллар буена күрмәс, танымас булды...» дигән гомуми, томанлы мәгълүмат белән чикләнгән. Нәрсә ул бу очракта «үз теле», нәрсә ул «тәмле итеп сөйләү»? Шушы да булдымы шагыйрьне борчыган, укучыны талкыган конкрет проблеманы фәнни ачу?

Дөрес, бу галим истәлегендә шагыйрьнең иҗат лабораториясеннән бик әһәмиятле бер энҗе бөртеге ачылып китә –

шагыйрьнең бер фикере китерелә: «Әсәр ни тиклем милли рухлы, милли образлы булса, аны башка телгә тәрҗемә итүе шул тикле авыр. Бәлки мөмкин дә түгелдер...». Монда инде шагыйрьнең татар милләте, татар теле турында уйлаганы, әйткәне бәхәссездер. Галимгә исә бу фикерне үстерергә, аны шагыйрьнең үз иҗаты мисалында дәлилләргә нинди зур мөмкинлек файдаланмыйча калынган.

Мондый мөмкинлекләргә галим Суфиан Сафуанов та таянырга теләмәгән. «Туган җиренә бөтен булмышы белән береккәнлеге арка-сында ул, нигездә, татар телендә иҗат итүенә һәм ана теленә тугры-лыгын гомере буена саклавы...» дигән дөрес, ышанычлы тезисын төп кыйбла итеп алып, шуны реаль, тормышчан дәлилләр белән нигезләп биргәндә, шагыйребез нәкъ менә татар булганы, нәкъ менә татар телендә иҗат иткәнгә күрә шушындый халыкчан, шул ук вакытта кардәш телле башка халык, милләтләр дә яратып укыган оста әдипкә әверелеп китте, дигән гадел, фәнни нәтиҗәгә килә алган булыр иде. Юк бит, галим «Казанга китү-китмәү» мәсьәләсен куертып, төп со-рауга туры җаваптан читкә китә.

Башкортстанда яшәп татарча иҗат иткән әдипләрнең (аерым алганда, Галимҗан Ибраһимовның) иҗатын энәсеннән-җебенә тәфсилле өйрәнгән, үзе дә әдәби, публицистик әсәрләрен булсын, гыйльми хезмәтләрен булсын татарча язган галим Суфиан Повари-сов Әнгам Атнабаев иҗатын да, аның әдәби осталык хәзинәсен дә җентекле белә. Алар Казан педагогика институтында татар теле һәм әдәбияте бүлегендә бергә укый, аннары татарча газет – «Кызыл таң»да да бергә эшлиләр.

Бу истәлегендә дә галим Атнабаев иҗатын татар әдипләре Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, С. Хәким исемнәре белән бәйләп күзаллый. Димәк, аның шагыйрь иҗатына, шагыйрьнең туган телгә мөнәсәбәтенә, бөтен язганын халыкчан итүдә татар мохитенең, татар теленең алыштыргысыз әһәмиятен фәнни нигездә ачып бирергә бөтен мөмкинлеге, җирлеге бар. Тик ул да чын хакыйкать юлыннан китмәгән, сәясәт ягын караган.

Кайвакыт каршылык, бәхәс шартларында да хакыйкать ачыграк төсмерләнә башлый. Бу очракта бәлки «башкорт фәне» мәсьәләгә ачыклык кертәдер? Хәер, бу «фән» әһелләренең моңарчы да Әнгам Атнабаевка бирелгән рәсми югары мактаулы исем «Башкортстан ха-лык шагыйре» булса да аны «Башкорт шагыйре» дип, чыгышы белән башкорт дип аталган кабиләләрдән булгач, Башкортстанда яшәп, Башкортстан халкына хезмәт иткәч, китаплары «башкортча» басыл-

гач, башкорт булмыйча, кая китсен, дигән хата мантыйклы «фәлсәфә» сөрүе күптән мәгълүм.

Гайса Хөсәенев, мәсәлән, Әнгамнең аны, кордашы буларак, якын күрүен сәбәп итеп, аның иҗатына да кагылырга да үзен хокуклы дип саный, күрәсең, гадәтенчә аны да башкорт итәргә маташа — шагыйрьнең күңеленә тия торган нечкә теманы – татар-башкорт мәсьәләсен бу юлы да кузгата. Татар шагыйре Гали Чокрыйның дөресендә башкорт шагыйре булырга тиешлеген тәкърарлый да, шуны аның нәсел тамырыннан килгән Әнгамгә дә күчермәкче. Авторның бәян итүенчә, шушы хактагы сөйләнүләреннән соң Атнабаев та нәсел тамыры белән кызыксынып китеп, туган авылы хакында документлар җыя башлаган, кызыксынуын, имеш, авторга да мавыгып сөйләгән. Шуннан соң «башкорт рухлы шигырьләр язды», ди. Бу очракта ул, галим буларак, төгәлрәк тә әйтә алыр иде: нинди инде ул «башкорт рухлы»? Татар телендә язылган әсәрдә андый рух кайдан килсен икән?

Шул сорауларга җавап бирә алмаганга да, истәлек авторыбыз «Ләкин аның күңеле барыбер утырмаган иде шикелле. Ни дисәң дә шагыйрь үтә нечкә күңелле шул...» дип, икеле-микеле, томанлы нәтиҗә белән чикләнергә мәҗбүр. Әйе, шагыйребез үтә дә татар җанлы, теләсә нинди бүтән «рухка» бирелә, сатыла торганнардан түгел иде шул.

Әлбәттә, шагыйрьнең эчке уй-хисенә бәйле хәләтен, шул хәләтне кәгазьгә төшерү барышын аның әсәрләрен укып кына, иҗатын читтән күзәтеп кенә төгәл күзаллап, бәяләп булмый. Шөкер, истәлек китабына әдипнең иң якын кешеләре, ягъни аның ничек-ничек уйлавын, иҗат ләззәт-газапларын ничек-ничек кичерүен, нинди телдә сөйләшүен, язуын, бу мәсьәләгә карата нинди фикердә булуын үзләре дә даими күреп-белеп торган күренекле шәхесләр: бертуган сеңлесе, иҗатташы, мәгълүм актриса Зинира Атнабаева, хатыны Сәвия, бер коллективта, якыннан аралашып-аңлашып яшәгән хезмәттәшләре – «Кызыл таң»ның редакторы, үзе дә язучы Таһир Ахунҗанов (Таһир Таһиров), газетның аннан соңгы редакторы, үзе дә шагыйрь, журналист Рәсих Ханнанов (бу җыентыкны төзүче дә), үзләре дә күренекле шагыйрьләр Марат Кәримев, Рафаэль Сафин – һәркайсының без кызыксынган мәсьәләгә карата мул мәгълүматлы булуына шикләнмәскә мөмкин. Ләкин истәлек язганда алар да бу мәсьәләгә, мәгълүм сәяси сәбәпләр аркасында, максатлы якын килмәгән. Шулай да әдипнең ана теленә иҗади мөнәсәбәтенә

берникадәр ачыклык керткән кайбер деталь, фактлар җемелдәп-җемелдәп китә. Менә кайберләре генә.

З. Атнабаева: "Сугыш елларында безгә Ленинградтан күченгән балаларны Әнгам агаем үзе язган шигырьләрне ятлатып, кичәләрдә сөйләтә. Сугыштан соң кайтырга җыенганда Оксана да, Сережа да безнеңчә сөйләшүче, безнеңчә яшәүче, гомумән, безнең милләт балаларына әйләнгәннәр иде... Әниебезнең, язучы мәгърифәтче Гали Чокрыйның туганы буларак, якты зиһенле булуы, Тукайны яттан белүе саф шигъри күңеле безне дә шул йулыкта (әдәптә) тәрбияләүгә булышлык иткәндер, күрәсең" (Был ерзе мин матурларга тыудым... 31 б.).

Зинира ханымның «татар теле» дип авыз тутырып әйтәсе урынга «үзебезчә сөйләшү», «безнең милләт» дип дипломатларча «саклык» күрсәтүе, моның үзе теләпме, әллә мөхәррирнең «уяулыгы» беләнме үтәлүе бу очракта әлләни әһәмиятле дә түгел – әнисе саф татарча язган шагыйрь Гали Чокрыйның сеңлесе булгач, Габдулла Тукайны яттан белгәч, балаларын да татар телендә тәрбияләмичә нинди телдә тәрбияләсен, Әнгам беренче шигырьләрен нинди телдә язсын ди?!

«...Мәктәп аның җитәкчелегендә нинди генә кичәләр, ярышлар үткәрмәде, кайда гына катнашса да, дипломнар, алдынгы урыннар яулады. Ул «Туган тел» дәресен алып бара, матур шигъри дәресләр үткәрә. Барысы да аны Һади Такташка охшата торган иде... Бераздан «Кызыл таң» газетында эшли башлады..."(шунда ук. 36 б.).

Бу фактлар барысы да Әнгамнең мәктәп еллары татарча уйлап, татарча яза башлап үтүе турында сөйли. Алдагы тормышы да бары татарча гына уйлап, бары татарча гына язып узуы – бәхәссез. Дәлилләрне дәвам иттерик.

Инде телгә алган Марат Кәримевтән, Рафаэль Сафиннан әлеге томан пәрдәсен берникадәр ача төшмәсләрме дип өмет ителгән иде – ни әйтсәң дә бер чорда, бер мохиттә, ярыша-көнләшә иҗат иткән каләмдәшләр бит. Яшерен серләре дә булмый калмагандыр, иҗат бит; тик хәзер истәлек язарга алынгансың икән, ихлас, гадел булырга кирәктер. Рафаэль Сафин болай ди: Атнабайның шигырь уку осталыгы турында аерым сүз алып барырга була. Ярата идем мин аның шигырь укуын. Сәхнәгә чыккач, ул башта мәрәкә (көлкеле) сүзләр сөйләп, тамашачыны шигырь тыңларга әзерли, шуннан соң гына ашыкмыйча, һәр сүзне ачык итеп әйтеп, көлемсерәп укый башлый. Салават күперенең барлык төсләре белән җемелдәгән халыкчан тылсымлы шигърияте белән генә түгел, ә яхшы актерларча... юк, актерларча түгел, Атнабайча оста укуы белән дә ул шигырь укыганда

тамашачыларның таң калып, иләсләнеп кул чабуларына шаһит булырга туры килде...» (шунда ук. 104 б.).

Каләмдәшен күз алдына китерер өчен авторыбыз никадәр генә детальләр табарга тырышмасын, аның нинди телдә сөйләвен әйтмичә торып, дәлилләр китермичә торып, «атнабайча», «оста» эпитетлары берни аңлатмый, абстракт сүз генә булып кала шул.

Рәхмәт инде Марат Кәримевкә – ул күпләр яшеренеп азапланган пәрдәне берникадәр ачып куя, мондый юллар бәян итә: «Әйе, үзенең шигырьләре белән Әнгам күпме күңелләрдә йолдызлар кабызды! Матурлык йолдызлары! Мәхәббәт йолдызлары. Иман йолдызлары. Бихисап алар. Тагы да бер йолдыз хакында аерым әйтеп китәсем килә. Ул туган телгә ихтирам йолдызы. Әнгам үзенең иҗатында татар теленең байлыгын, нечкәлеген, сыгылмалыгын, бер сүз белән әйткәндә, бөеклеген күрсәтте. Хәтеремдә, Әнгам белән Тәтешле районы авылларында әдәби кичәләр үткәреп йөрибез. Шундый бер кичәдән соң яшәрен яшәгән өлкән генә бер агай килеп, Әнгамнең кулын кысты. "Кара әле, безнең телдә дә шулай матур итеп шигъри сүз әйтеп була икән. Моңа кадәр ничек шуны белмәгәнмен. Рәхмәт үзеңә күземне ачкан өчен..."» (шунда ук. 115 б.).

Менә бу инде безнең алда торган мәсьәләне чыннан да җитди һәм эшлекле күзаллый башлау. Шушындый саллы, өметле керештән соң каләмдәшенең туган телнең тылсымлы көче белән кабызган бөтен бер «йолдыз»ны ничек-ничек балкытуын тәфсилле ачып бирер, дип өмет итәсең дә, тик өмет акланмый кала. Моңа истәлек жанры кысалары да комачаулаган, ахрысы. Булганы өчен дә тагын бер кат рәхмәт. Югыйсә бит, шушы истәлекләр арасында да, шагыйрьнең бөтен барлыгын, талантының асылын яхшы белеп тә, аны белмәмешкә сабышканнар да аз түгел. Арада мәгълүм томанны, киресенчә, куерта гына төшкән, шагыйрьнең дәрәҗәсенә суккан фикерләр дә очрап куя. Бер караганда, безне борчыган сорауга журналист Әмир Гәрәев якынрак килә төсле: «...нинди бай, халыкчан тел, нинди осталык! һәрбер юлы: "Мин Атнабайныкы!" дип кычкырып тора сыман. Җитди дә, юморы да бар. Менә кайда ул яшь каләмдәшләргә өйрәнү мәктәбе!» (шунда ук. 53 б.).

Афәрин. Һай, дөрес сүзләр, изге ният! Тик нидән гыйбарәт соң ул «мәктәп»? Нәрсәгә өйрәтә? Мондый купшы мәдхиянең төбендә шагыйрьнең иҗатын ике телле, ике милләтле итеп күрсәтү, ягъни үзәксез калдыру максаты ята: бу инде әлерәк кенә телгә алган «галимнәрнең» тегермәненә су кою гына.

Шул авторның, шул истәлек текстыннан янә бер өзек: «Табында биш-алты кеше идек. Шунда Әнгам «Аракыга дан йыры» дигән шаян шигырен татарча сөйләде (аныңча, Әнгам башка шигырьләрен башкортча сөйләгән булып чыга, бу инде чеп-чи ялган; аннары ул бу шигырен башкортча язган булып та үзе үк татарчага тәрҗемә итеп, татарча сөйләгән булып чыга – монысы инде чын көлке). Шуннан "Атаклы якташы Гали Чокрыйның «Без урман башкорты булабыз» дигәнен кабатларга ярата, үзе башкорт, тик теленең татарча икәнлеген аерып әйтә торган иде" дип өстәп, янә үзенә үзе каршы килә. Шуннан соң шагыйрьнең әлеге әсәренең дүрт юлы нәкъ татарча, татар шрифты белән китерелә. Игътибар итик: гәрчә бөтен җыентык, андагы шигъри әсәрләрнең барысы да башкорт шрифты белән җыелган (шунда ук. 55 бит). Ә бу өзекнең болай җыелуы шагыйрьгә мыскыллы киная дип кабул ителә.

Мәҗмуганы «иләп» барганда берничә истәлекне тәфсилле укудан вакытлыча тыелып килдем, Татарстанда яшәгән шагыйрьләрнең; алар инде хәлне үз җилкәләрендә татыган, бөтен серне бер-ике гыйбарә белән ачарлар да салырлар кебек иде. Аннары Башкортстанда әйтеп булмый торганны ап-ачык әйтергә аларга беркем дә комачауламый, яккакка сагаеп карыйсы юк. Өстәвенә әле, авторлары да – Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнәшева – туры сүзле, гаделлек яклы шәхесләр.

Юк, булмады! Ничәнче тапкыр инде мин бу юлы да алдандым, өметем акланмады. Татарстан шагыйрьләре беркайчан да Башкортстандагы каләмдәшләренең хәленә кермәделәр – теләмәделәр дә, кулларыннан да килмәде. Хәер, бу очракта әле исеме аталган шагыйрьләребезгә үпкәләү дә урынсыздыр – истәлек истәлек инде ул, фәнни тикшеренү түгел.

Ә бит Казан шагыйрьләренең бу йомшаклыгын аклау мөмкинлеге булган икән. Әдипнең Уфада татарча чыккан «Җиз кыңгырау моңнары» дигән саллы җыентыгына (Өфө: Китап, 1998) кереш сүзне Башкортстанда туып-үсеп, Казанда төпләнеп иҗат иткән татар шагыйре Роберт Миңнуллин язган. Аны инде Әнгам Атнабаевны шәхес буларак та, шагыйрь буларак та белми дип әйтеп булмый.

Үз сүзләре белән әйткәндә, Атнабайны ул «остазы» дип, «кумиры» дип саный, «Атнабай шигъриятенең серләрен эзләүче» ди, аны үз шигъри мәктәбен тудырган шагыйрь дип таный.

Форсаттан файдаланып, бу кереш сүзне янә бер кат җентекләп укып чыктым. Иншалла, күз алды аз гына ачылып китте шикелле. Без эзләнгән юлда, ягъни остазының шигъри тылсымын ачарга, кайбер

адымнар да ясаган лабаса. «Атнабай иҗатының сихри бер тарту көче бар. Ниндидер йогышлы шигырьләр алар...». «Аның шигырьләре бөек көчкә – сүз көченә корылган. Дөресрәге, хис-эмоция көче, тапкырлык, җорлык көче ул. Халыкчанлык, тормышчанлык та шуннан киләдер, күрәсең», дигән нәтиҗә ясый (Җиз кыңгырау моңнары. 7–8 б.).

Шөкер, авторыбыз моңарчы да кайбер галим, шагыйрьләр әйткән шушы гомуми бәяне дәлилләргә, конкретлаштырырга да керешә. «Шагыйрь әйтергә теләгәнен афоризм дәрәҗәсенә җиткереп әйтә белә. Гади сөйләм үрнәкләрен, урыстан кергән, халыкта еш кулланылган гыйбарәләрне кертеп җибәрүе белән дә шигырьнең эчке аһәңен, тәэсир итү көчен арттыра. Шигырьләренең беренче юллары ук укучының күңелен иләсләндерә, җәлеп итә торган».

Шушы фикер-нәтиҗәләрне дәлилләргә мисал итеп китерелгән сүзләр, гыйбарәләр барысы да татарча... Шуннан соңгы шигырь исемнәре дә саф татарча... Ярый, кереш сүз татарча басылган, димәк, биредә сүз, нәтиҗәләр татар теленә карата әйтелә дип үзеннән-үзе аңлашыла. Ә бит шигырь сүзләре оригиналда башкорт шрифты белән басылган, бу текстның да шул шрифт белән басылып, автор фикере-нәтиҗәсе башкорт «теленә» дә карый дип аңлашылуы бар бит. Ә авторыбыз текст буена бер генә тапкыр да «татар теле» дип әйтми. Үзеннән-үзе аңлашыла ич инде, дияр укучы. Юк шул! Текст буена «буталчык» төшенчәләр дә очрап торганда (мәсәлән, «Ә. Атнабайның башкорт әдәбиятендә тоткан урыны бар», «Халык арасында аның шикелле шөһрәт казанган шагыйрь башкорт белән татарда тагын бар микән», «Атнабай тумышы, тормышы белән дә Башкортстан шагыйре. Башкортныкы да, татарныкы да...», «...халык аны ниндидер бер илаһи, буй җитмәс зат итеп түгел, ә үз кеше итеп кабул итә...». Нинди халык? Халык ул милләтсез була алмый. Ә милләт ул телсез була алмый. Шагыйрьнең милли теле бер генә була. Барлык дәүләт телләрен бертигез кулланам, дип сәясәтчеләр генә, хөкүмәткә ярарга теләгән эшем кешеләре – түрәләр генә сөйли. Бу хакыйкатьне Башкортстанда туса да, туган теле татар теле булып, шуңа күрә татарча язган, татар шагыйре дип танылган Роберт Миңнуллин бик яхшы белә, туган ягы Башкортстанга кайтса да, аны татар шагыйре дип беләләр, теле дә татар теле булганга, теләп укыйлар. Үзенә карата шулай уйлауны, бәяләүне таләп иткән шагыйрь остазы һәм кумирына карата да шундый фикер йөртергә, шул хакыйкатьне укучыларга җиткерергә тиеш иде.

Кереш сүз димәктән, Әнгам Атнабаевның тагын ике елдан Уфада басылып чыккан (Өфе: Рухият фонды, 2000) татарча саллы

җыентыгына керешне китап нәшире Мәҗит Мөдәрисов язган. Бөтенләй икенче каленкур. Монда шагыйрьнең тел мәсьәләсенә бернинди икейөзләнү юк. Бар да ачык, бар да халык уйлаганча, бар да чып-чын: «...Гомерең буе милләтеңә, ана телеңә, шигыреңә тупас кагылучы бәгъзе бәндәләрнең кулларына сугып, берүзең бөтен бер милли хәрәкәт булып яшәдең син, Әнгам абый...

Юлың, чыннан да, изгеләрдән-изге – ул туган милләтеңә хезмәт итүдән, аның тел матурлыгын, күңел бизәкләрен яныпярсып башкаларга танытудан гыйбарәт иде. Ничәмә-ничә еллар шушы шөгыленңнән, шушы «сәерлегеңнән» арындырырга, яраклаштырырга, тәртәгә кертергә тырышып карадылар, «кешечә» яшәргә өндәделәр. Каләмдәшләрең мул-мул бүләкләр алганда, үзең әйтмешли, иплэп кенә читкә типтеләр...».

Рәхмәт, каләмдәш, хакыйкатьне тулы ачып биргән мондый бәяләмәдән соң безнең язма берникадәр кабатлау да булып тоелыр, шулай да хакыйкатьне ачу, бәян итү генә җитми, аны төшендерергә, кешеләрнең аңына, күңеленә барып җитүенә дә ирешү кирәктер.

Истәлекләргә кабат кайтып, инде дилбегәне очлауга таба тартырга да вакыт җитәдер. Аның азагына якынайганда бер фикергә килә алуыбыз әһәмиятле: истәлек язарга алынган авторларның кайберләре әлеге хакыйкатьне аңлап, шуны дәвам иттергәндә, яшермәгәндә генә олы шагыйрьгә чын бәяне биреп буласын, аның остазлык мәктәбен ачып, бай үзенчәлекле тәҗрибәсен киләчәккә, яшь талантларга җиткереп буласын, әдипнең халык күңелен тибрәтеп торган ана теле нечкәлекләрен җиткереп, яңа талантлар үрчетеп буласын чамалый. Моның өчен шул хакыйкатьне ачу, күпләрнең күз алдындагы томанны таратырга теләү мисалларын да очратабыз. Мәсәлән, шагыйрьне, аның иҗат лабораториясен яхшы белгән мөхәррир Галим Дәүләди сүз арасында гына сыман бер ачыш ясап куя: «Мине гомер буе бер нәрсә – башкорт белән татарны каршы кую, чәкәштерергә омтылу борчый... Бер караганда – башкорт, икенче карасаң, татар булып икейөзлеләнеп йөрү бар. Үз куштаннарын таба, дуслык табынына чиләк белән дегет коярга маташа...». Истәлектә бу сүз югында сүз булсын кебегрәк кенә әйтелгән гыйбарәнең авторны борчыган дәвамы бардыр, ул юкка әйтелмәгәндер. Истәлекләрнең менә мондый урынлы тәкъдим-гыйбарә белән очлануы да гыйбрәтле, бик урынлы, барыбызны да уйландырырга тиештер: «Әдәбиятебезнең иң кояшлы битләрен бөтен таланты белән ихлас язышкан әдипнең серләрен әле укучылар күп эзләячәк» (Был ерзе мин матурларга тыудым... 214 б.).

Менә язмабызның төп максатына да килеп җиттек. Ниятебез бит сукрану, зарлану, кемгәдер гаеп ташлау, үпкә белдерү түгел иде, максатыбыз бит күренекле әдипнең чын шагыйрь булып әверелүендә, халыкның аны үз шагыйре дип тануында, бүген дә яратып укый бирүендә ана телебезнең – татар теленең – алыштыргысыз нигез булуын икърар итеп кенә калмыйча, дәлилләп тә бирү иде.

Нигә, нинди ихтыяждан туган бу теләк? Табигый ки, фикерен бүтәннәргә җиткерү төп эше булган һәр иҗатчы бердәнбер коралы ана теле икәнен яхшы аңлый, аны бөтен көче-кодрәтенә файдаланырга тырыша, аны барлык чыганаклардан өйрәнергә омтыла. Кем әйтмешли, үз җилкәмдә беләм – үзем дә язучы, журналистмын, минем дә коралым – бөтен таянычым, терәгем – ана телем. Аның бөтен нечкәлекләрен, мөмкинлекләрен белергә, үзләштерергә, кулланырга телим. Шуңа күрәдер инде бу юнәлештә фәнни эзләнүләргә дә кереешеп киттем. Бүгенге төп вазыйфам да яшь журналист-студентларны иҗатта ана телен – татар телен куллану үзенчәлекләренә, осталыгына өйрәтү. Шулай булгач, язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең, шул исәптән Әнгам Атнабаевның да, ана телен куллану тәҗрибәсен өйрәнүем табигыйдер. Бу өлкәдә осталык тәҗрибәсен өйрәнүгә юнәлтелгән һәр адым, гамәлне хуплау, моңа каршы килгән, комачаулаган теләсә нинди киртәне булдырмау намус эшемдер.

Чыннан да, ничек инде мин, “Туган илем – минем туган телем. Шушы телдән башка җырым юк,” дип, минем телемне – татар телен – иң югары рухи һәйкәл итеп күтәргән шагыйрьгә ышанмаска, аңа табынмаска, аны якламаска тиеш ди. Ничек инде мин аның шушы иманын танымаска, ишетмәскә сабышучыларга, шулай итеп туган телемне дә танымаска, дәрәҗәсен төшерергә, аның киләсе буыннар белән бәйләнешен кисәргә маташучыларга каршы төшмәскә тиеш ди. Шагыйрь бит үзенең иҗат җимешләрен нәкъ менә миңа – татар баласына дип, минем кардәшләрем – җиде миллионнан да күбрәк татар халкына дип, аларның һәркайсы шушы татар телендә укып, үз милләте, үз теле өчен горурланып, бүтәннәр арасында түбәнсенмәсен, башын югары тотсын, дип язган. Ничек инде мин аның шушы изге ниятенә аяк чалучыларга гамьсез булыйм ди!

Аннары, шагыйрь үзе киләчәктә дә онытылмасын өчен, яңаданяңа буыннар аны кардәше, милләттәше дип кабул итә барсын өчен аның бүген дә, иртәгә дә укылуы кирәк, моның өчен аны укыгыз, дип, гомуми өндәү, үгетләүләр генә җитми. Аны укуы никадәрле «тәмле», файдалы икәнен күрсәтеп, төшендереп тә бирергә кирәк.

Бу юнәлештә заманында бер адым ясаган кебек идем — шагыйрьнең 70 яше уңаеннан язган мәкаләмне нәкъ шушы максатка җигәргә тырышкан идем (Мәдәни җомга. 1998. 24 март). Анда бәян ителгән кайбер гомуми фикер-нәтиҗәләрне кабатлап китү дә урынлы булыр дип уйлыйм.

Нигә аның шигырьләрен җай чыккан саен укырга тырышам, алардан күңелемә тәм-ямь табам, гомумән, нигә мин аны чын шагыйрь дип саныйм? Минем өчен шигырь ул иң башта моң, җыр. Димәк, ул милли генә була ала. Ни өчен Тукай, Такташ, Туфан шигырьләрен нигездә тәрҗемә итә алмыйлар? Башка телгә күчерелсә, ул шигырь дә булмас, хикәя йә мәкалә булыр иде. Бүтән милләт шагыйрьләрен тәрҗемәдә укып хисләнергә азаплану да мәгънәсезлек ләбаса.

Нигә шулай икән? Мөгаен, бердәнбер дөрес җавап – шагыйрьнең шагыйрьлеге ул максат-ниятенә фәкать ана теле белән ирешә алуындадыр. Шагыйрьнең асыл сыйфаты тормыш-көнкүрешне, вакыйганы бары үзенчә күреп, үзенчә генә фикерләвендә, ә бу «үзенчәлек» тик ана теле белән генә сурәтләнә ала. Ә моның өчен ана телебезнең нәкъ менә безнең милләтне бүтәннәрдән аера торган тасвирлы сүзләре, гыйбарәләре, мәкаль-әйтемнәре, чагыштыру, гәүдәләндерүләре… янә дә дистәләрчә башка чаралары файдаланыла. Аларны бүтән телгә туп-туры күчереп була торган булса, милләтләр арасында аерма да яшәмәс иде.

Әлбәттә, шагыйрь күзаллавындагы тел төшенчәсен конкрет бер мәгънә, хис төсмерен белдерә торган корал дип кенә тарайтырга ярамый. Аның карашында тел төшенчәсе ул күп кырлы, зур бер фәлсәфи, психологик күренеш. Беренчедән, шагыйрьнең Атнабайга гына хас милли кыюлыгын, иҗат каһарманлыгын, ватандарлыгын күрсәткән шәхси сыйфат булса, шуның белән бергә, иҗтимагый күренеш тә. Менә бу юлларга диккать итик әле:

Татар-башкорт мәсьәләсе
Каяндыр килә һаман –
Бетми торган чир шикелле
Теңкәгә тия һаман.
“Ник татарса һөйләшәһең,
Башкортса һөйләш, имеш,
Был һөйләшең менән сиңә
Казанга китеү тейеш!»
Нишләп Казанга китим ди,
Шушында туып-үскәч?
Яфрак ярып, чәчкә атып

Җимеше булып пешкәч.
Нишләп Казанга китим ди?
Шушында атым-затым –
Минем сөйләшне аңлаучы
Миллионнан артык халкым...

Күрәсез, бу инде аның үзенең генә күңел кителүе түгел, ә бәлки миллионнан артык халкыныкы да. Үзенеке генә булса, ул аны мөгаен чыгармас та иде, эчтән сызып, түзәр иде. Ә менә бөтен халкыныкы булгач, аның шагыйре буларак, ул инде түзә алмый. Алай гына да түгел, халкының да игелекле җирлегенә төшкәч, ул бөре үсеп, гомумиләшеп тә китә — туган ил, туган өй, туган тел турында халыкның уй-хисен тасвирлаган җырга әверелә:

Туган илем – минем туган телем,
Шушы телдән башка җырым юк,
Дип җырласам әгәр җырларымда,
Бу – төчелек түгел, горурлык!..

Бу юлларны укыганда без инде Башкортстан кысаларыннан чыгабыз, дөньяның төрле кыйтгаларында яшәгән милләттәшләребез өчен, бөтен ана телебез өчен горурлык кичерәбез. Алай гына да түгел, шагыйрьнең «тел» төшенчәсе безне башкорт телен дә, урыс телен дә, бүтән телләрне дә уйларга, алар өчен дә борчылырга, кайгыртырга этәрә.

Икенчедән, әлбәттә инде, тел аның карашында шигырьләрнең укучыга уңай тәэсир итү чарасы да. Әнгам Атнабаев шигъриятен Башкортстанда озак еллар укып иялэнгән кеше буларак, менә нәрсәгә күнеккәнмен: кайсы гына әсәрен укысам да, аның әйтергә теләгән фикер, хисенең миңа барып җитүенең, күңелем кылларына тиеп, моңсулыкмы, горурлык йә нәфрәтме, елмаюмы әллә ләззәтме кузгатуының серен икебезнең дә бер телдә — ана телебездә – фикерләүдә, шул фикернең нәкъ миңа аңлаешлы, хуш килерлек сүз, тезмәләр, җөмлә төрләре, аһәң, интонация белән тасвирлануында, дип ачыш ясап, шуңа горурлануымдадыр.

Болар, әлбәттә, чын халык шагыйренең халыкчанлыгының өстән җемелдәгән энҗеләре генә. Ә асылы, тамыры тирәндә. Татарча язуында, милли хисле булуында гына да түгел. Ә халыкның иң авырткан, иң хаҗәт кылларына тиеп, аны уйларга, алга карарга булышкан шагыйрь-фәйләсуф булуында. Хәзер без моны мисаллар белән дәлилләргә тырышырбыз.

Иң башта, әдипкә карата еш әйтелә торган «халыкчан» эпитетын конкретлаштырыйк. Халыкчан, чөнки ул халыкны халык иткән,

милләтне милләт иткән «алтын баганалар»ның иң берәгәйлесе, иң ышанычлысының – туган теленең – кадерен белә. Юк, ул сүздән куыклар очырып, алар белән уйнамый. Телебезнең яме, тәме дә, көче, куәте дә гадилектә бит. Шагыйрь дә сүзгә, нәкъ халыкның үзе кебек үк, бөрегә, чык, тамчыга, кар бөртегенә караган кебек табигать ачышы итеп табынып та, шул ук вакытта, көндәлек хасият дип кадерен белеп, саклык белән дә карый. Шуңа күрә шигыре дә табигый бер тамчы булып, гадилеге, табигыйлеге, самимилеге белән җанга якын кабул ителә.

Бөгелмәм җилләреңә,
Сыгылмам давылыңа:
Җиңеллеккә түзү кыен,
Түзәрмен авырына.

Әлбәттә инде, ана теленең, сүзнең алыштыргысыз көче барлыгын, аның кадерен белергә, сакларга кирәклеген турыдан-туры әйтүдән дә шагыйрь тарсынмый. Моңа аның хакы бар – бөтен иҗаты шуңа мисал.

Кешене һәлакәттән тартып алыр өчен
Бер җылы сүз – күңел эретерлек наз җитә, ди ул.

Димәк, шагыйрьнең үз укучысы белән бер дулкында булуы өчен беренче шарт ул – тумышы, тәрбияләнеше белән шушы милләтнеке булып, аның бөтен асылы, хәсиятен тәшкил иткән сыйфатларына ия булып, аныңча уйлавы, хисләнүе, моңлануы, көлүе-елавы, аның һәр төрле йоласы, гореф-гадәте белән яшәве зарур. Икенче шарт исә нәкъ шушы милләтнең телен бөтен тулылыгы белән үзләштергән булуы. Шушы ике шартның тәңгәллеген тою, шуны тоюдан тәм табу – укучының табышы, бәхете.

Атта йөрдем: җәен арбаларда
Аяк салындырып йөредем.

Ат, арба, җәй, аяк сүзләренә тәңгәл төшенчәләр башка милләттә дә булса да *арбада аяк салындырып утыру* ул безгә бигрәк тә якын. Менә шушы күңелгә якын мәгънәнең үзебезнең сүзләр белән белдерелүе ләззәт бирә дә инде. Шагыйрьнең татар хәсиятен белдерергә яраклашкан гасырлар буе чарланган көндәлек кадерле, аһәңле сүзләрне таба белүе – осталыкның үзе дә инде.

Басу капкасыннан килеп керсәм,
Казан аса күрше-тирәләр.
    Ат саклаган кыңгыраулы төннең
    Бәрәңгеләр күмгән учагы...

Шунысы мөһим, әсәрдә миллилек тирәнрәк, халыкның хәсияте борынгырак, нечкәрәк тасвирлана икән, телнең ул сыйфатларга

барәбәр чаралары да эчтәлеге ягыннан да, төзелеше ягыннан да катлаулана бара. Әйтик, бездә татарлыгы эчке асылына салынган берәмлекләр – **парлы сүзләр** бар. Аларны күпләп белгән, бихисап мәгънә һәм хис төсмерләрен тоемлаган шагыйрьнең әсәрләре халыкчанрак, миллирәк була. Чөнки парлы сүзләр төшенчәләргә өстәмә төгәллек, конкретлык бирергә, хис төсмерләрен нечкәртергә сәләтле.

Алар татар психологиясенең төрледән-төрле бик үзенчәлекле, нечкә якларын белдерә ала. Беренче чиратта, алар каршылык, киеренкелек төшенчәләре белән бәйле төсмерләрне нечкә белдерә алуы белән көрәш рухлы Атнабайны җәлеп итә дә (кемнәр *кереп-чыкмаган; ачып-ябып* җилләр искән; *юклы-барлы; алыш-биреш; көне-төне* һ.б.).

Бу берәмлекләр юмор-сатира, төртмәлек төсмере белән дә сугарылган. Әлбәттә ки, Атнабай аларның бу сәләтеннән дә бик оста файдалана: *пыран-заран, кыек-мыек, алпан-тилпән, яман-ятлар, чатыр-чотыр, ордым-бәрдем, малай-шалай* һ.б.

Бу төр берәмлекләр шагыйрьгә рифма, ритм, көй-аһәң ихтыяҗын канәгатьләндерергә дә ярап куя. *Сап-сары, тап-таза, чүп-чар, телем-телем*: “Ул кайдадыр *бик-бик* якында”; “*Ара-тирә сирәк-мирәк* кенә”...

Сөйләмне нәкъ татарча шома, җор телле итү максатында да парлы сүзләрне иҗади файдаланырга, төрлечә үзгәртергә була икән: “*тора-бара, бара-тора* үзебез дә әйләнмәсәк ярар иде машинага”; *еласын-елаганнар* һ.б.

Мәгънә төгәллеген, хис төсмерләрен ситуациягә карап ачыграк күзаллау өчен шагыйрь теге-бу берәмлекне **мәгънәдәш** (ягъни синоним) кардәшләре ярдәмендә тулыландыра, «баета». Алар ясалма булып тоелмый, киресенчә, нәкъ менә халыкчан яңгыраш ала. Арада көндәлек сөйләмдә ишетелә, языла торган, хәтта сүзлекләрдә теркәлгән *җир-ана, алтын-көмеш, җил-давыл, төбе-тамыры, аллы-гөлле, көч-гайрәт* һ.б. рәтендә *эш-дәрәҗә, сөелү-сөю, озын-озак, күз-баш, сугыш-үлеш, кәгазь-китап, мирас-варислык, ялкын-нур* кебек үзе ясаганнары да табигый, күңелгә ятышлы булып кабул ителә.

Бу максатта ул татар теленең икенче бер асыл сыйфаты – ялганмалык чараларыннан (**кушымча**лардан), шулай ук **ярдәмче фигыль** кебек грамматик чаралардан да бик оста файдалана: *изгеләрдән-изге, елдан-елга* һ.б. Андыйлары да табигый булып кабул ителә.

Шагыйрь, әйткәнебезчә, татар кешесенең каршылыкны тоемлау, көрәшү рухын бөтен тулылыгы белән бирә ала. Шигырь исемнәренә генә игътибар итик: «Сикәлтәле юллар», «Егетләрне кы-

рау сукты», «Зәңгәр офык тагын карала», «Бөтен йортта утлар сүнде», «Кешегә нәрсә җитми», «Бар һәм юк» «Куркыныч», «Үзәкләргә үтеп җилләр исә», «Башларыма кара кайгы төште», «Талантларның язмышлары авыр» һ.б.

Һәртөр көндәлек сөйләмдә кулланыла торган гади генә сүзнең дә иҗатта гомумилекне белдерү, иҗтимагый күренешкә әверелү сәләте бар. Шагыйрь моңа да сизгер. Мәсәлән, «*курку»*ны ул социаль-иҗтимагый күренеш итеп тасвирлый: "Курку – тезген, аяктагы тышау, муендагы элмәк шикелле; Әйтер сүзләреңне әйттерми ул: Эшләттерми эшләр эшеңне" (Был ерзе мин матурларга тыудым... 196 б.). Чөнки курку халәтен ул иҗтимагый, иҗади тормышында үз җилкәсендә тоеп яшәде.

Парлы сүзләрнең нигезендә, гадәттә, **антонимнар** – кара каршы мәгънәле берәмлекләр ята. Татар теле аларга да ифрат бай. Кеше халәтенең, хисенең бихисап төрләрен белдерә алганга күрә дә, Ә. Атнабай иҗатында да алар иң актив, иң хәрәкәтчән берәмлекләр. Әле санап киткән шигырь исемнәренә генә күз салыйк: *ак-кара, бар-юк, ут-боз, елау-көлү* һ.б.

Инде әсәрләрнең эченә кереп китсәң, нәкъ тормыштагы кебек:

Бер караңгы – бер якты,
Ни гаҗәп бу: көз белән яз,
Берсе болыт, берсе аяз,
Берсе – яшәү, берсе – үлем...

Уйлый калсаң, сүз үзе төшенчә белдерүдә, хис төсмере белдерүдә никадәр мөстәкыйль, көчле, сәләтле булса да, аның гайрәте-көче, әлбәттә, сөйләм тукымасында, ягъни сүзләрдән тезелгән чылбыр-тезмәдә. Конкретлаштыру **сүзтезмә**дә көчлерәк. Әйтик, антоним берәмлекләрдән парлы сүзләр генә түгел, **антитеза** дигән бөтен бер фикри фигура да хасил була: болар да татар холкына-табигатенә туры килә торган, халыкның үз иҗат җимеше буларак барлыкка килә торган берәмлекләр. Шагыйрь аларны да иҗади корал буларак яратып куллана.

Бер яктан, ул халыкта, бигрәк тә үз төбәкләрендә даими кулланыла торганнарын табып алып, әсәрен халыкчан итә, тәэсирен, үтемлеген көчәйтә:

Утларына салып яндыра,
Бозларына салып туңдыра.
        Берәү булса агу бирер иде,
        Ә син миңа дару эчердең.
Йөз хыяллар белән йоклап китәм,

Мең хыяллар белән уянам.
Әл дә түзә бу йөрәкләр,
Бер янды да бер туңды

Икенче яктан, шул нигездә, шул рухта ул үзе дә мондый фигураларны иҗат итә, димәк, сөйләмебезне шәхси, ситуатив фигуралар белән баета:

Тик дошманның алтын тауларыннан
Кыйммәт минем чуер ташым да.
Сугышта да күз яшьләрен түгел,
Хәләл канын түгеп сугышкан.
Туган җиргә кеше киләмени,
Туган җиргә кеше кайта ул.

Каршы мәгънәле сүзләргә сизгерлек шагыйрьгә җор теллелек, сүз уйнату өчен бүтән мөмкинлекләр дә бирә. Әйтик, татарда бит әле сүзләрне бер тезмә эчендә каршы куеп, өр-яңа көләмәслек, төртмәлек, шуклык төсмере бирү күренеше дә бар – **оксюморан** дип атала. Осталыкның шундый иң югары алымы Атнабайның да кулыннан килә:

Без тилеләр булсак мәхәббәттә,
Алар – мәхәббәтсез акыллы.

Шагыйрь – эзләнүче. Төп коралы сүз дә аның бу холкына туры килә, сүзнең дә бит һәр төшенчәгә тач туры килгәне, кул астында әзере күп түгел, аны хәзинә сандыгыннан эзләргә дә эзләргә кирәк. Шагыйрьгә мәгънәнең, хиснең бик нечкә төсмерләренә тәңгәл бирәмлек табу мөмкинлекләре җитәрлек. **Мәгънәдәш** (синоним) **сүзләр** үзенә бер дөнья. Шагыйребез бу дөньяны нечкә тоя, аннан оста файдалана да. Аның бу мөмкинлектән парлы сүзләр ясаганда ничек файдаланганын күргән идек *(көч-гайрәт, төбе-тамыры* һ.б.).

Мәгънәдәш сүзне эзләгәндә ул сөйләм мотивларына таяну җаен карый – өлкәннәргә бер сүз булса, яшьләргә икенчерәк, авыл кешесенеке белән каланыкы бер төрле булмас. Бер шигырендә *муел* булса, икенчесендә *шомырт*. Ягъни үз авылы, үз төбәгенә карата язганда, сөйләгәндә аңа шушы төбәктә яраклашкан, еш кулланылган сүзләр (хәтта диалектизмнар) кадерлерәк. Бүтән төбәк укучылары моңа сукранмый, чөнки шагыйрь барыбер күп төрки аңларлык бирәмлекләр сайлый яисә урынчалыклы сүзне төшендереп бирә. *Тәүге, чәчкә, тәүбашлап, тиктәч, картәтәй* кебек сүзләрне аңлатып та торырга кирәкми ләбаса.

Мәгънә төгәллегенә хилафлык китермәс өчен халык бит үзе дә сүзне бүтән телдән булса да төгәлрәген алып куя, шулай да ул аны үз сөйләмебезгә яраклаштыра, шомарта, чарлый. Үзе дә яңа бирәмлекләр

ясап куя. Һәрхәлдә алынма элементлар сөйләмне төгәлрәк, тормышчанрак итә. Андыйларга шагыйрь дә сизгер: вакыт-вакыт ул «норма», әдәбилек таләпләренә каршы килеп булса да, «ярамыйга карамый», шигыренә кертеп җибәрә:

Әле менә чутлап утырдым да...
Күрмичә дә калып була инде
Иптәшеңнең кайбер *гыйлләсен* (кимчелеген).

Шулай да ул күбрәк үз сүзләребезне таба, моңарчы пассив кулланганнарын яңарта-җанландыра, халык иҗатына охшатып, төрле грамматик форма-чаралар уйлап табып, сүз, әйләнмәләрне төгәлрәк, хислерәк итә. Мондый яңа берәмлекләр (**неологизмнар**) төгәлрәк тә, серле-сәеррәк тә була.

Шулай итеп, аның туры да, күчерелмә мәгънәдәге дә яңа сүз, гыйбарәләре шактый җыелган.

Бәйрәм бүген, *тәрәз кашларында*
Күгәрченнәр гөрләп куана.

«Мин Минеч», «жулье-мулье» кебек юмор чаралары да, *«шигырьләнгән хатыным»* кебек ясалмалары да игътибарны җәлеп итеп, үз тәэсирен барыбер итә.

Эзләнү барышында шагыйрь **омоним** дигән берәмлекләрне дә игътибарсыз калдырмый. Шигырьне беренче чиратта ишеттерер өчен яза торган шагыйрьгә алар аеруча әһәмиятле. Тыңлагыз әле:

Язар юлларымны *юлларга*
Озатыгыз мине *юлларга*.
Үзегезгә булсын *бүлмәгез,*
Юлларымны берүк *бүлмәгез*.

Аларның чын миллилеге ике үзәкле: беренчедән, әнә шул яңгырашы, аһәңе белән алар халыкчан, күңелгә якын; аннары аларны тиз генә тәрҗемә дә итеп булмый, димәк, алар – чын халыкныкы, милләтнеке. Димәк, шул рәвешле әйтә алган, көйли алган шагыйрьне халык та ихластан үзенеке дип, халык шагыйре дип таный да.

Сүзләрнең көй, моң, аһәң барлыкка китерү сәләте тезмәләрдә (синтагмада) көчлерәк чагылыш таба. Ягъни гыйбарә, фразада, аеруча сөйләмдә гасырлар буе кулланылып, береккән, шомарып күңелгә үз булып әйләнгән, тел фәнендә **фразеологизм** дип аталган телбизәк берәмлекләрдә. Нәкъ менә шулар шигырьне шигырь итә дә бугай – әзер, образлы сурәтләр, бөтен бер манзаралар:

Бүләгемне алдың алуын да,
Ләкин аны *санга сукмадың*.
Типсә, тимер өзәр башы белән

Тырай тибеп йөргән ир-ат бар.
Яуда күрмәсәм дә солдатларга
Ега сугып пуля тигәнен.

Күз күреме җитмәс яклар; үстек бер әнигә баш тәрәп; башны иеп, йөз суымны түгеп һ.б.

Фразеологизмнар – халыкның буыннан-буынга килгән җәүһәр бөртекләре буларак, шагыйрьләрне, иҗатчыларны сүз, гыйбарә иҗатына дәртләндерә. Чынында халыкның тел хәзинәсе аерым чичән, шагыйрьләрнең иҗади җимешләре – энҗе бөртекләреннән җыела да инде. Атнабайның менә бу канатлы гыйбарәләре, афоризмнары хәтергә уелып калырлык түгелмени?!

Замана тудыра шагыйрьне,
Шагыйрьләр күтәрә заманны.
Җирдә кайгы күптән бетәр иде,
Бетерә алса аны күз яше.
Үзе килгән бәхет бәхет түгел,
Эзләп тапкан бәхет кадерле.
Бер ялгызлык – мең явызлык.
Мәңге көтеп булмый.
Ник туйдырмый икән бу дөнья.
Ә мәхәббәт дәвам итә ярамыйга карамый.
Тик күңелләр кара булмасын.

Хәер, хәтергә теркәлеп калырдай, җанны эретердәй мондый гыйбарәләр булдыру шагыйрьнең үзмаксаты түгел бит – шагыйрь тоташ әсәренең шулай бербөтен сурәт, укыр өчен дә, тыңлар өчен дә үзенә бер җыр булып, гамьсезләрне, туңҗаннарны да тетрәтерлек, алҗып туктап калганнарга дәрман биреп, кузгатып җибәрерлек, өметсезләрне өметләндерерлек илһам, көч-егәр чыганагы итәргә тели.

Бөтенлек исә бер-берсенә табигый үрелгән тезмәләрдән образлы сурәт, фигуралардан хасил була. Халык авыз иҗатында алар: мәкаль, әйтем, чагыштыру, кабатлаулар, канатлы гыйбарәләр, җырлардан өзекләр һ.б. Шагыйрь шуларны бик теләп, әзер килеш тә, бераз үзгәртеп тә куллана:

Гомерләр ике килми шул
Сагынып җырласаң да,
Телне тешләп, тешне кысып
Ирләрчә еласаң да.

Әсәрнең бөтенлеге ул аның эчтәлек бөтенлегеннән һәм форма, ягъни композиция-сюжет корылышының сәнгатьчә камиллегеннән – бөтенлегеннән гыйбарәт. Шул ук вакытта Әнгам Атнабаев шигырьләренә тагын бер бөтенлек – яңгыраш, аһәң бөтенлеге дә хас.

Әсәрләренә андый максат куйган шагыйрьләр, дөресрәге, шул максатка ирешә алган шагыйрьләр бик сирәктер. Атнабай – ул шигырен, беренче нәүбәттә, ишеттереп тәэсирләндерер өчен язган шагыйрь; бастыру, китап итеп чыгару аңарга икенче чиратта.

Шуңа күрә дә аңында шигырьнең бөтенлеге дигәндә эчтәлек бөтенлегеннән соң, һичшиксез, яңгыраш бөтенлеге, аһәң, көй-моң камиллеге булгандыр. Аһәң бөтенлеге үзеннән-үзе төзелеш-композиция камиллеген хасил итәдер. Дөресрәге, икесе бергә үрелеп килгәндә, бербөтен камил толым барлыкка киләдер.

Шагыйрь халыкка үткәзү максатын куеп яза икән, сөйли икән, димәк, ул халыкның күңел дулкынын, җан тибрәнешен яхшы тоемларга тиеш. Атнабай халкының көй, моңын туганнан бирле үз итеп, аңлап, күңеленә якын алып үскән, бөртекләп җыйган. Халык җырларын, такмак-такмазаларын белмәсә, яратмаса, ул менә мондый аһәңле юллар тезә алыр идемени?!

Тамчы гына җитәр микән,
Коеп яуганы кирәк.
Кичтән килеп, тәнгелеккә
Кунып калганы кирәк.

Чын халыкчан аһәң ул иҗатның иң югары осталык билгесе, ул халык иҗатындагы гомуми тәҗрибәне нәкъ менә шәхси талант күзәнәге аша үткәрү дигәнне аңлатадыр да. Шундый шарт үтәлгәндә иң фәлсәфи фикерләр, халык акылы, тирән психологик, мантыйкый нәтиҗәләр дә шигырьгә салына ала, шул ук вакытта җиңел юмор, такмак-көләмәслек тә урынлы кабул ителә.

Бабай әйтә: кешеләрнең бәхете
Кояш белән бергә чыга, ди.
Кояш чыккан мәлне күрмәүчеләр
Бәхетсезләр әнә шуңа, ди.

Ялгызыңа күңелсездер
Клубка китәек, ди.
Клубка барсаң да бәла,
«Танцевать итәек», ди.

Шигырьнең көе, аһәңе төрледән-төрле чаралар белән, шул исәптән тын, сулыш, авазларның милли әйтелеше, татар ритмы, рифмасы чаралары белән ирешелә.

Иртәләрдә зәңгәр күзле
Иркәмнең иркәләве.

Шигырьнең эчтәлеге языла барган сүзләрнең мәгънәви чылбырын тәшкил иткән фраза, текст агышы булып үсә барган кебек, әйтү

аһәңе дә аваз (фонема), иҗек (морфема), сүз (лексема), сүзтезмә (синтагма) чылбырыннан тезелә. Тамчы җыры, чишмә челтерәве, дулкын кагуы кебек. Тыңлыйк әле:

Җилләргә башын ия
Күлләрдә сары камыш.
Күлләрдә сары камыш...
Шыбырдый таныш тавыш.

Икенче строфа да шул тавыш, сагышны дәвам иттерә.

Күңелдә калды сагыш,
Кагыла күрмә ялгыш...

Бөтен әсәр шушы рухта, шушы аһәң, яңгыраштта агыла. Бу агыш һәр татарга якын, чөнки ул халык җырларына бик якын. Шагыйрьнең үз иҗади табышлары да шуңа тартым:

Алга барыш булган кебек,
Булды артка да калыш...

Бу – чын милли яңгыраш, аһәң; аны башка милли сөйләмдә очратуы кыен. Яисә менә бу аһәңне берәр телгә тәрҗемә итеп буламы?!

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Чылата керләремне.
Керфекләрең ник чыланган,
Сагындың кемнәреңне?

Әкрен искән таң җиленә
Лепердәп куйган була.
Артык иркәләнеп китсә,
Әнисе тыйган була.

Хәтта иң җитди фәлсәфи, сәяси темаларга да шагыйрь халык рухына, халык акылына, аһәңенә ирешә ала.

Җыен ялагайга җитә калды,
«Әфәндем» дип төче телләнә.
«Әфәнделәр» исә шул кичәге
«Иптәшләрдән» калган күләгә.

Алдыбызда зур авызын ачкан
Бөек Америка бабабыз.
Шул авызга сыер көтүедәй
Сагыз чәйнәп кереп барабыз.

Аңлашылса кирәк, аһәң ул милли төшенчә. Татарның бик күп җырын бүтән телгә тәрҗемә итеп булмый, тәрҗемә иткәндә дә төшенчә, күренешнең сәнгати-эстетик асылы тоныклана, табигый предмет, күренеш кенә алга чыга; ике өлештән торган җырның беренче өлеше белән икенчесе бөтенләй бәйләнмичә, «мәгънәсезлек» барлыкка килә. «Мәгънәле» булсын өчен аның татарча яңгыравы

зарур. Атнабай шигырь-җырлары да халык иҗатының бер тамчысы, аерылгысыз бер нуры буларак кабул ителә дә.

Шагыйрьнең аһәңлеккә ирешү арсеналында әйтү белән язу арасындагы каршылыкны, бүгенге алфавит-орфография кыенлыкларын аһәң файдасына хәл итә белү осталыгы да бар:

Малаема әгәр *карадисәм*

Әтиемне искә төшерәм, дигән фразаны язылганча (дөресрәге, мәктәп грамматикасы, редактор кагыйдәләре таләп иткәнчә) укып кара әле (яисә *мактаналмыйм* һ.б.). Мондый аһәңлек чараларына шагыйребез бик сизгер, таләпчән иде. Шуңа күрә дә әле телгә алган истәлекләр китабында, ул язган дип (хәтта сөйләгән дип), тәкъдим ителгән менә бу юлларны ничек укырга белмичә аптырыйсың, гаҗизләнәсең:

Йәйге койаш күзен асыу (ачу) менән...
Минең улым да бар арала (арада)...
Трибунаны косоп (кочып) лыгырдый...
Төрмәләрдән сыккан (чыккан) тоткындай...
Аслыкның (ачлыкның) да ни икәнен белдем...
Кеше тиеп (диеп) мине йөретмәгез...
Кайгыны эскә (эчкә) йотоп...
Кәрәгенгән артык мактана тип (дип)...
Әйтһә әйтер бары көнсөләр (көнчеләр)...
«Чапай» уйнай Сейә (чия) тавында...
Юк икән шул укып сараһы (чарасы)...
Сәсебездә сал (чал) калдырган...

Атнабайның саф татарча уйлап, саф татарча язган, саф татар аһәңе белән сөйләгән сүз, гыйбарәләрен болай гариплэндерү, шундыйлар белән татар баласын интектерү бернинди сәнгать, хәтта бернинди әдәп кысаларына да сыймый. Әгәр чын башкорт теле булган булса, бу берәмлекләр шул телнең үз берәмлекләренә тәрҗемә ителгән булса, алар, билләһи, болай тозсыз, мәгънәсез бирелмәсләр иде.

Язмабызны очларга да вакыт. Бәхәссез ки, Әнгам Атнабаев – татар шагыйре. Моны танырга, авыз тутырып әйтергә кирәк. Бу безгә ана телебез өчен, әдәбиятебез өчен горурлык хисе тәрбияләүдә кирәк. Бу – Әнгам Атнабаевның озак вакытларга татар халык шагыйре булып яшәве, иҗаты җимешләренең халыкка озакка җитүе өчен кирәк.

Ул үзенең татарлыгын беркайчан да яшермәде, шул яшермәве, икейөзләнмәве аркасында күп михнәт күрде. Шул ук вакытта бу хәлнең гайре табигый, җанталагыч икәнен дә яшермәде:

Ник талантлы татар якташларым

Казаннарга китеп торып кала?
Казаннарда татар булу җиңел,
Уфаларда татар булып кара!

Татарлыгының тамыр-нигезләрен шагыйрь ап-ачык әйтә килде:

«Баламишкин»ны җырлап үстек,
Әбиләрнең әкиятен тыңлап...

Иҗатында үз милләтенең, үз ана теленең нинди урын тотуын, нигез, таяныч икәнен, шуның белән генә чын шагыйрь булуга ирешкәнен, димәк, халкына, ана теленә һәрчак бурычлы икәнен ул белеп, тоеп яшәгән. Менә шуңа дәлил – аның төп коралы Сүз турында берничә җан авазы, һәйкәл булып калкып торырлык гыйбарәләр:

Якты дөнья белән бәхилләшеп,
Һәлакәтен эзләп йөргәндә,
Шул юлыннан тартып алыр өчен,
Бу кешегә ифрат аз җитә:
Бер җылы сүз –
Күңел эретерлек наз җитә.

Шагыйрь Рим Идиятуллинның (гомер буе татарча язып, гомер буе «Кызыл таң»да эшләгән күренекле татар шагыйре, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы) Әнгам Атнабаев белән «Кызыл таң»да басылган соңгы әңгәмәсе шагыйрьнең мондый бөек хакыйкате белән тәмамлана: «Бездә, әдипләрдә, башка беркемдә булмаган бөек көч бар – Сүз. Сүз белән үтереп тә була, үлгәнне терелтеп тә була». Әдип, әлбәттә инде, татар Сүзе турында татарча әйткән. Шөкер, ул татарча басылып та чыккан.

Теле өчен шундый горурлык, олы җаваплылык хисе иң башта аның халкы, милләте өчен горурлыктан киләдер.

Безнең буын төпкә җигелеп
Тарта торган ат бүген,
Юкка-барга бөгелеп төшеп
Елый торган зат түгел.

Шуңа күрә дә ул милләтенең, теленең кысрыклануына җан әрнүен, гарьләнүен еш сиздермәсә дә, тешен кысып түзсә дә, үзеннән бигрәк халкы өчен кирәк дип, язмыйча да кала алмаган.

Хатыным да оныклары белән
Сука сөрә урыс телендә.
Менә шулай яшәп яткан булам
Мин чи татар башкорт илендә...

Янә дә: “Син башкортмы, син татармы – анда түгел мәсьәлә, башкорттан да, татардан да урыс туа – вәт бәла», дигән канатлы гыйбарәсе халык афоризмына әйләнде.

Кош телләрен аңлау кая инде
Туган телдән мәхрүм калганбыз, дип әрнесә дә,
Һәрбер милләт үз илендә
Азат яшәргә хаклы.
Горур чечен карындашым,
Мин, татар, синең яклы, дип, үз халкы өчен горурлык, аның язмышына өмет белән каравын, димәк, теленең яшәячәгенә дә якты карашын белдерә.

Шагыйрь тылсымын, талантының серен чын шагыйрь генә тоемлый һәм аңлата аладыр. Без төшенергә теләгәнне, ягъни аның тәэсир серен Нажар Нәҗми болай аңлата: Сере – Әнгам Атнабаевка ходай тарафыннан бирелгән очкында... Шигырьнең кеше бәгыренә керүендә, шунда эрүендә, күңелләрне тетрәтүендә – болар барысы да шагыйрь үзе дә аңлата алмаслык көч! Ул көч – көтелмәгән бер мизгелне шигырь иткән кодрәт.

Шәхсән мин бу көч-кодрәтне Сүз дип кенә аңлыйм. Моны Хәсән Туфан төгәлрәк әйтә:

Бабичка хас юмористик нур бар,
Әнгам, синең көләчлегеңдә.
Такташтагы нәфис тирәнлек бар,
Төгәллек бар шигъри телеңдә.

Без ничә биткә сузылган язмабызда исбатларга омтылган хакыйкатьне олуг шагыйрь дүрт юлда әйтте дә бирде. Чын талантны чын талант кына шулай бәяли ала...

ТАЛАНТНЫҢ НИГЕЗЕ – СУРӘТЛЕ СҮЗ УЛ
(Ибраһим Сәләхев истәлеге)

Язучы иҗатының серләрен-тылсымын ачарга омтылган һәр иҗатчы, үзе язучымы ул, әллә тәнкыйтьчеме, әллә гади бер укучымы, аның талант орлыкларын үзенчә ачарга омтыла, язучының шәхси асылының төрледән-төрле якларына игътибар итеп, үз белгечлегенә караганнарына көчлерәк диккать итеп, күбрәк шуларына өстенлек бирә. Шәхсән үзем, иң әүвәл язучының төп коралы – теленә, сөйләм кору осталыгына, ягъни сүз белән эш итү сәләтенә игътибар биреп, Ибраһим Сәләхевның укучыга тәэсир итү чараларының иң көчлесе ул – аның ана теле белән эш итү осталыгы дип тоям.

Әлбәттә ки, бу минем генә бәям түгел; күпләр шулай уйлый, дип, бу фәнни дәлилләнгән бәя, дип санарга да хокукым бардыр. Менә язучыларыбыз турында яңа гына чыккан ике томлык мәҗмугада Ибраһим Сәләхев турындагы мәкаләдә мондый юллар: “И. Сәләхев әсәрләре тел-стиль ягыннан үзенчәлекле булуы белән дә кызыклы. Аларда дала табигатен, тугандаш казакъ халкының көнкүрешен, гореф-гадәтләрен тасвирлауга зур урын бирелә, казакъ җырлары, риваятьләре мәкальләре әсәр тукымасына нык керешеп, авторның хикәяләү стиленә дә үзгә бер яңгыраш өстиләр” (Ибраһим Сәләхев // Әдипләребез: биобиблографик белешмәлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 2 т. 314–317 б.). Монда әдипнең тел куллану үзенчәлегенең бер генә бөресе тотып алынган булса да, бу деталь аның телгә мөнәсәбәтенең үзенчәлекле булуын икрар итүе әһәмияткә ия – мәҗмугада бәян ителгән йөзләрчә язучының кайсысының гына ана теленә мөнәсәбәте менә шушылай, аерып алып, игътибар үзәгенә куелды икән!

Бу һәрхәлдә очраклы факт түгелдер, әдипнең иҗатын, әсәрләрен төрле яклап анализлаганда, аның бу үзенчәлегенә игътибар итми үтеп киткән тәнкыйтьче сирәктер. Талантның төп күзәнәкләренә битараф калырга мөмкинме соң! Ә И. Сәләхевның ана телебезне сизү-тоемлавы, аны бөтен нечкәлеге белән белүе, үзенчәлекле куллану сәләте аның талантыннан килә, дип саныйм. Бу язмабыз менә шуны дәлилләргә алынмакчы. Шул ук вакытта шушы бик конкрет максатның да үтә катлаулы икәнен дә аңлыйбыз. Язучының телне тоемлау, аны тумыштан куллану сәләтен өйрәнүгә үзенә бер маһирлык кирәклеген сизәсең. Бу бит һәр язучының үзенә хас хәсиятедер. Башкалардан аерым буларак, Ибраһим Сәләхевның бу сыйфатлары нидән гыйбарәт? Моны ачыклау өчен үзенә бер тематик тикшерену, анализ таләп ителә. Бүгенгә без әдипнең тел тоемлау сәләтенең бер күзәнәге – сүз-образ, ягъни күчерелмә мәгънәле берәмлекләр – троплар, фразеологизмнар – белән эш итү үзенчәлегенә генә туктала алырбыз.

Бәхәссез ки, һәр татарның асылында фикерләү, шул фикерен белдерү өчен сөйләм оештырганда акылны һәм хисне бер дәрәҗәдә тәгаенләү-белдерүне күздә тоткан бик әһәмиятле бер “нокта” яратылган: ул – төгәл мәгънәле берәмлекләрнең һәм дә образга сәләтле күчерелмә мәгънәле берәмлекләрнең бердәмлеге. Яхшы аңлаешлы, үтемле, тәэсирле камил сөйләм менә шул ике үзәкнең табигый үрелгән булуыннан, ягъни гармониясеннән хасил була. һәр татарның күзәнәкләре – геннары шулай яралган, тәрбияләнгән булырга тиеш. Бу хакыйкатьне белү язучы өчен үтә әһәмиятле.

Килешик, һәр иҗат иясендә сөйләмне туры мәгънәле һәм күчерелмә мәгънәле берәмлекләрнең дөрес нисбәтен җәлеп итү сәләте табигать тарафыннан бирелгән булса да, иҗат барышында моңа махсус игътибар сорала. Бу гармониянең үз әсәрендә ничек-ничек белдерелүен, язучы, кем әйтмешли, бизмәндә-контрольдә тотарга тиеш. Психологлар билгеләгәнчә, акыл төшенчәләре күпчелек очракта туры мәгънәле берәмлекләр (сан, даталар, исем-атамалар, термин, профессионализмнар һ.б.) белән, ә хис төсмерләре образлы-күчерелмә мәгънәле берәмлекләр (троплар – эпитет, фразеологизм, метафоралар, мәкаль, афоризмнар һ.б.) белән белдерелә.

Тик менә бу ике төрле үзәкнең гармониясе һәр шәхестә нәкъ бер нисбәттә сирәк була. Иҗат ияләрендә дә ул шулай, чөнки бу сыйфат адәм баласының талант дигән бөек хәсиятенең чагылышы үзе инде. Язучыбыз Ибраһим Сәләхев – менә шул талант хәсиятенә ия шәхес.

Моны дәлилләргә тотынганчы янә бер хакыйкатне искә төшерик әле. Татар баласының әлеге үзенчәлеген канәгатьләндерү өчен аны гамәлгә ашырырга телебез шул мөмкинлеккә ияме соң? Мәгълүм ки, милләтебез, халкыбыз күпне күргән-кичергән, бай тарихлы, мул мәгълүматлы, тирән фәлсәфи фикерләүгә гадәтләнгән, сүзе эштән аерылмаган милләт, “тотып карамыйча ышанмау” аның конкретлыкка маһир милләт икәненә уңай киная. Шуңа күрә дә аның акыл тирәнлеген һәм колачын тасвирлый торган лексик составын (төгәл мәгънәле сүзләр арсеналын) күп томлы сүзлекләр дә сыйдырып бетерә алмый. Терминология сүзлекләре генә дә бездә биш дистәдән ашкан.

Ә инде тел хәзинәсенең икенче үзәген бәяләүне бу өлкәнең белгеченә – галим һәм язучы Нәкый Исәнбәткә ышанып тапшырыйк: “Болгар-татар теле төрки телләр системасына керә. Бу телләр исә гомумән дә фразеологик әйтемнәргә (бу термин астында галим барлык күчерелмә мәгънәле берәмлекләрне дә истә тота. – *И.Н.*) байлыгы белән аерылып тора. Әйтик, инглиз, француз, испан, япон һәм башка телләр шикелле. Шулар өстенә, телебезнең гаять тәртипле фонетик сингармоник авазлар системасына корылган булуы, фигыль-рәвеш төрләренә гаять байлыгы, һәр рухи хәләтне процессында тотып алу сәләтлелеге, динамиклыгы һәм борынгы анимистик сихри җанлы сөйләм рухын саклап килүе кебек хәлләре бар ки, болар һәм башка күп кенә яклары табигый рәвештә аның фразиологик тәгъбирчән булуына да хезмәт иткәннәр һәм итәләр” (*Исәнбәт Н.* Автордан // Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 1 т. 5 б.).

Һәрхәлдә кайбер язучыларыбызга укучылар телне тоемламауда, тел байлыгын файдаланып җиткерә алмауда ризасызлык белдерә икән, моны язучының телебезнең ярлылыгына сылтавы һич тә урынлы түгел. Аның үзенең көчсезлеге, талантсызлыгы, тел хәерчелеге дип бәяләү гадел булырдыр. Бу кимчелектән котылыр өчен Ибраһим Сәләхев иҗатына мөрәҗәгать итү файдадан бүтән нәрсә бирмәстер.

Монда янә бер кечкенә искәрмә сорала. Күчерелмә мәгънәле берәмлекләрнең, фәнчә гомумиләштереп әйткәндә тропларның, бүгенге кулланылышын лексик-семантик һәм стилистик планда матбугат һәм матур әдәбият сөйләмендә генә түгел, тулаем да анализлауны актуаль дип саныйбыз. Моңа матбугаттагы, әдәбияттәге үзгәрешләрдән тыш тагын бер җитди сәбәп бар: телнең күчерелмә мәгънәле берәмлекләренең (икенче төрле әйткәндә, образлы фикерләү чараларының) сөйләмдә гомумән дә кими баруы. Кайбер тикшеренүләрдән ачыкланганча, бу тенденция, кызганычка каршы, көнкүреш сөйләмендә генә түгел, иҗтимагый-сәяси стильдә, шул җөмләдән журналистик-публицистик (ягъни мәгълүмат чаралары) сөйләмдә генә дә түгел, ә бәлки матур әдәбият стилендә дә күзәтелә. Соңгы елларда мәктәп, гуманитар югары уку йортлары программаларында тропларны өйрәнүгә, аларны куллану күнегүләренә сәгатьләр кимегән; фәнни өйрәнү дә сизелерлек сүлпәнәйде.

Бу – урысча уйлап, татарча сөйләп-язып азапланучыларның фаҗигасе. Татар теленең милли мөстәкыйльлеге, асыл үзенчәлеге башлыча агглютинативлыгы белән бергә, менә шушы күчерелмә мәгънәле берәмлекләрдә; чын татар сөйләменең асылы шушы сүзгыйбарәләрнең төп-төгәл мәгънәсен аңлап, нәкъ урынында куллана белүдә дә бит инде.

Фикер агышыбызны Ибраһим Сәләхев мисаллары белән дәвам иттерик. Бу язмада алар язучының “Тайгак кичү” романхроникасыннан китерелә (Казан утлары. 1988. № 8).

Менә әсәрдә көнкүреш сөйләме үрнәге. Монда, табигый ки, һәр татар кешесе сөйләмендәге кебек, туры мәгънәле сүз-гыйбарәләр күчерелмә мәгънәлеләре белән табигый үрелеп бара. Укыганда, аларны төпченеп аермыйсың да. Язучы да аларны аерым-аерым күз алдына китереп утырмый. И. Сәләхев әсәрләрендә дә бу бердәйлек менә шушылай үзеннән-үзе агылып килә: “Безнең институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгуны ректор быел да миңа тапшырды. Ни генә әйтмә, *командир кисәге* бит мин. Институтка килеп кергәндә шинель петлицаларымда чия кызыл *өчпочмаклар яна* иде. Әле дә өстән

хәрби *мундир төшми*. Ләкин студентларның әзерлеге *ташкүлчим*, нибары ике тапкыр җыелдык, саф дигәннең *исе дә юк, сыер көтүе кебек*, беребез алда, икенчебез артта. Бигрәк тә кызлар шырык-шырык килеп *теңкәгә тия*. Кычкыра-кычкыра тамагым карлыгып бетте. Ай-һай, бу хәтле дә *йөгәнсез* булыр икән хатын-кыз дигән халык!".

Текстта төп мәгънәне белдерә торган бик конкрет төшенчәле гомуми сүзләр (*бәйрәм, без, мин, быел, тапшыру, чия кызыл, алда, артта, кызлар, хатын-кыз* һ.б.), үтә конкрет терминнар, һөнәри төшенчәләр (*институт, колонна, демонстрация, ректор, шинель, петлица, студент* һ.б.) белән бергә шул төшенчәләрне тагын да төгәлрәк күз алдына китерү өчен образ характерын үти торган күчерелмә мәгнәле берәмлекләр дә үрелеп бара (*командир кисәге, өчпочмаклар яна, исе дә юк, сыер көтүе кебек, йөгәнсез* һ.б). Күрәсез ки, конкрет берәмлекләр төрле категориядән, формадан булган кебек, троп берәмлекләр дә төрледән. Әйтик, монда күчерелмәлеге инде күптән югалган, гади, битараф сүз булып кабул ителә торган берәмлекләр дә (*алып чыгу, саф, тамак карлыгу* һ.б), "чын" тропларның төрле категорияләре (фразеологизм: *исе дә юк, теңкәгә тию*; эпитет: *йөгәнсез*, чагыштыру да: *сыер көтүе кебек* һ.б.) дә бар.

Әдипнең тропларын системага салып барлый, анализлый башласак, аларның эчтәлеге ягыннан да, форма-төзелеше ягыннан бик катлаулы, төрледән-төрле үзенчәлекле бай бер хәзинә барлыкка килгәнен күрербез. Фразеологимнардан әйтем, мәкальләр, шәхси канатлы гыйбарәләр әсәрнең тере, сурәтле күзәнәкләре булып укучыга тәм биреп, ана телебез өчен горурлык хисе тудырып, гомуми канәгатьлек хисенә баетып барыр, ягьни әсәрне төртелмичә, әлсерәгәндә йотылып су эчкән кебек үзең дә нәрсә эчкәнеңгә хисап бирмичә укысың да укыйсың. Без инде фәнни анализ барышында гына ул энҗе бөртекләрен әсәрнең тоташ тукымасыннан аерып алып күрсәтәбез, ә укучы аларны алай аермый. Чөнки шулай уку, әсәрне шулай кабул итү аның күзәнәкләрендә, геннарында салынган. Димәк, язучы укучының шул асыл үзенчәлеген, чын татарның асыл үзенчәлеген белеп эш итә. Моның өчен аның таланты бар.

Менә бит ана телебезнең нинди барыбызга да якын, кадерле энҗе бөртекләрен укып, күңел канәгатьлеге кичерәбез: *төймә мыек; мин институтның кендеге түгел; авызына шайтан төкергән; яхшылыкка яманлык; җаным уч төбенә килде; дүрт күз белән көткән бәйрәм; нәфес – шайтан*; *кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый; минем кызым кияү күргәнмени; тиле таш җыяр, син китап җыясың; энәдән*

генә төшкән гимнастеркалар, чәче сүс сыман дулкынланып тора; боз төсле салкын; һәр җирдә кырмыска оясы; кыямәт көнемени; бәйрәм ашы – кара-каршы; сират күпереннән үтү һ.б.

Авторның җор теллелеге, троп-метафоралар белән оста эш итүе үзенең канатлы гыйбарә, афоризмнар иҗат итәргә алынуын да, моңа сәләтле икәнен дә укучы аңлый, кабул итә: *төрмәдә һәр нәрсәгә шикләнеп карыйсың бит* һ.б.

Ибраһим Сәләхев әсәрләренең йотылып укылуының сәбәбен таләпчән укучы барыбер вакыт-вакыт уйлап куя, ул бит шушы язучының гына әсәрен укымый, ә менә кайбер башкаларныкын укыганда еш кына шушындый ук образ тудыру максатында алынган берәмлекләргә – сүз, гыйбарәләргә төртелә. Әйе, төртелә, чөнки алар йотып җибәрелми, тешкә тиеп, шыкырдый. Кыскасы, укучы сәер, ясалма мәкаль гыйбарәләрдән гайрәте чигеп, китапны укудан туктый.

Яисә, киресенчә, шәрә фактлар, терминнар белән шыплап тулган документаль язмадан берәр күчерелмә мәгънәле, сүз-сурәт килеп чыкмасмы, дип зарыгып көтә. Аның күңел күзәнәкләре шуңа көйләнгән, шул гармонияне таләп итә. Юк! Шулай ук укудан туктый.

Димәк, әсәрдә туры һәм күчерелмә мәгънәле берәмлекләр гармониясе аларның һәр төренең булу-булмавына гына бәйле түгел, ә бәлки аларның әсәр агышында бер-берсенә бәйләнешенә, гармонияне ничек барлыкка китерү осталыгына да карый. Монысы инде өстә ялтырап торган, теләсә кем күрерлек, аңларлык манзара түгел, бу – язучының сере-могжизасы. Иҗатның шундый сер-тылсымнары булмаса, теләсә кем язучы, теләсә кем Сәләхев кебек оста язучы санала алган булыр иде.

Сүзләр гармониясенә ирешүнең И. Сәләхевка хас алымысулларын җентекләп өйрәнәсе бар әле. Шулай да кайбер “сер төеннәрен” ачыклап китәргә мөмкиндер. Иң әүвәле, язучының тел байлыгына ия булуы, татарның төрле катламнары, төрле шартларда, мөхиттә яшәп, төрле һөнәр ияләре белән аралашып, сөйләм чараларын үзләштерергә, белемгә омтылуы, һәр сүзнең тәэсир көчен күзәтә, тоя белергә омтылуы. Төрле телләрнең, аеруча казакъ теленең татар кешесенә ничек тәэсир итүен күзәтергә күнегүе. Тел байлыгын кайда, кайдан мөмкин, шуннан җыя, туплый килүе. Җыелган байлыгын кайда, кемгә мөмкин, шуңа җиткерергә, телен чарларга омтылуы. Хәтерлисез микән, төрмәдә аны ач үлемнән нәкъ менә шул “тел чарлау” сәләте коткарып кала да. “Менә бит, уйламаганда эшләр җанланды да китте. Көн дә өстәмә бер паек икмәк... Эше тузансыз да,

өреле дә. Нәрсә эшлим дисезме. Сөйлим. Көн дә кичке баландадан соң хикәят сөйлим. Кече яшьтән үк “Әлфе ләйлә вә ләйлә”, “Кырык вәзир”, “Шаһнамә”, “Әбугалисина”, “Тутыйнамә”, “Салсал” кебек гарәп әкиятләрен укып үскәнгә, запас җитәрлек...”.

Болары әдипнең гомуми, барлык әсәрләр язганда да җәлеп ителә торган сыйфат, алымнары. Ә менә конкрет әсәрне язганда, конкрет контекстта кулланыла торган, шушы авторның, ягъни Ибраһим Сәләхевның гына кулыннан килә торган “сер төеннәре”. Әйтик, берәүләр күчерелмә мәгънәле берәмлекләрне уңай хис, уңай мәгънә бирер өчен генә кулланырга күнегә. Ибраһим останың троплары функциональ чикләүгә дучар ителмәгән. Әнә аның сөйләме төрмә терминнарыннан, акырып-бакырып катгый команда биреп күнеккән, сүгенү сүзләреннән генә торган, пычрак авызлы надзирательләре дә: “Хәшәрәт! Баса яздың бит, *чулак җен!* ди. “Нәрсәгәдер сөртендем. Шундук мәсхәрәле тавыш. – *Корсаклы хатын.* Тизрәк!” ди”. Автор ат карагы мәхбүс чегәнне дә татарча троплар белән сөйләтә: “Алтын кеше бит син, *бөркетем. Авызыңнан энҗе-мәрҗәннәр коела*. Синең урын монда түгел, җәннәттә бит, *җаным*...”.

Тропны куллану үзмаксат түгел бит. Һәр очракта ул нәкъ гомуми сүз-гыйбарә кебек кабул ителергә тиеш; аерылып торса, укучы аңа аерым диккать итәр иде, ә бу инде әдәби әсәрдә гайре табигый хәл, укырга комачаулый торган, димәк ки, әсәрнең тәэсир көчен киметә торган тискәре хәл, язучы моңа юл куя алмый. Һәр троп, сүз, образ, гыйбарәнең үзеннән-үзе “йотылып эчелеп” барылуы кирәк. Мондый таләп үтәлсен өчен язучы аларны әсәр тукымасында табигый урнаша баруына, ягъни җөмләдә дөрес урнаштырылуына игътибар итәргә тиеш. Моңа ул төрле алымнар белән ирешә. Әйтик, бер очракта фразеологизм, мәкаль, әйтем, канатлы гыйбарә авторның үз фикер агышын белдерү рәвешендә була: “*Май кап!* – дип сикереп тордым”. Икенче очракта персонаж сөйләменең бер өлеше итеп бирелә: “Ибраһим, ашыкма, сабыр ит. *“Сабыр төбе – саф алтын”* дип, борынгылар белмичә әйтмәгән... – ди Галимҗан ага Нигъмәти”. Бу очракта халык сүзе аерым персонаж сөйләмендә тәкъдим ителә. Кай урында ул халыкныкы дип, автор сөйләмендә тәкъдим ителә. Кай очракта афоризмның кемлеге тәгаен икрар ителми: “Әмма, *нәфес шайтан*, диләр бит...”.

Язучыбыз тропларның укучыга тәэсир итү дәрәҗәсенә бик сизгер. Мәсәлән: “Әйтерсең лә, *кылыч белән чаптылар,* иңге-миңге булып киттем”. Бу очракта автор чагыштыруны урынлы саный – тикшерүченең көтелмәгән дорфалыгы аңарга үтә дә кискен тәэсир итә.

Әмма икенче тапкырында шундый ук ударны ул “Калын бас башыма *тукмак белән ордымыни*, күз алларым караңгыланды”, ди.

Осталыкның югары ноктасы ул – күчерелмә мәгънәле берәмлекнең, гыйбарәнең бөтен бер сәнгати образ-сурәт итеп үстерелүе: “Әллә нәрсәгә телем бәйләнде. Югыйсә, әле поездда килгәндә үк, нәрсәләр әйтәсен, нинди сораулар бирәсен күңелдән ятлап килгән идем бит. Әйтерсең лә, *абынып егылып, кулымдагы тәңкәләрне чәчтем”.*

Чагыштыру – сәнгати сурәтләүнең иң көчле чараларыннан. Ибраһим оста аларны мулдан, төрледән-төрле рәвештә куллана. Күрдек ки: гади чагыштырулар; *кебек, сыман, шикелле* мөнәсәбәтлекләре белән килә торган чагыштырулар; бөтен бер мөстәкыйль фәлсәфи уйлану – парча сыйфатында тасвирлана торган чагыштырулар. Мәсәлән*: “Сагыну! Татлы да ачы да син сагышлы сагыну. Синнән качам, сине онытырга тырышам. Әмма... Әмма үзем тагын-тагын кочагыңа – кайнар, назлы, гөләп куагы төсле гүзәл, чәнечкеле кочагыңа омтылам. Көнбагыш чәчәге төсле сокландыргыч син, сары сагыну. Синдә кояш чаткылары һәм әрем тәме...*”. Бер сурәт-образ барлыкка китерүдә парча композициясендә янә берничә троп җәлеп ителгән.

Нишләмәк кирәк, осталык кимәлебез төрлечәрәк: бәгъзе язучы аерым бер предмет, күренешләрне генә чагыштырып сурәтли ала; икенче берәүләр кешеләрнең кыяфәтен, холкын, өченчеләр табигатьне тасвирлаганда маһирлык күрсәтә. Ибраһим Сәләхев татар яшәешенең аерым бөртекләрен дә, бөтен хәятен дә образлы сурәтләү сәләтенә ия. Моңа без инде китерелгән мисаллар нәтиҗәсендә инандык. Образлылыкны ул тирән һәм колачлы фикерләү белән тасвирлап бирә ала. Сагынуны ничек тасвирлады! Аның мондый сәләтен иҗатын җитди анализлаган тәнкыйтьчеләр, галимнәр дә сизмитоймый кала алмаган. Менә галимә Ләйлә Минһаҗеваның әдибебезнең тууына 100 ел тулу уңаеннан басылган фәнни мәкаләсеннән бер фикер: «“Колыма хикәяләре”ндә әсәрнең буеннан-буена сузылган, җыелма, күзгә күренмәс, шартлы ике образ бар: көч куллану һәм курку. Курку әсәр персонажларының хәрәкәтләре белән идарә итә. Курку, куркытып тору әсәрнең сюжет, композиция факты буларак, тоткыннарның эчке дөньяларын, хәтта әһәмиятсез вакыйгаларның да юнәлешен билгели.

Көчләү – тоталитар системаның төп нигезе. Мәҗбүрият җәмгыятьтә аерым бер курку атмосферасы гына тудырып калмый,

Сөйләм оештыруның янә дә бер мәҗбүри мотивы-“кабыргасы” ул – сөйләм адресаты. Бу компонентны күз алдында тоту ихтыяҗына һәм мөмкинлекләренә Хәсән Сарьян ничек карый?

“VII–VIII класслар өчен өстәмә әдәбият” китабын (Казан, 1973) рецензияләгәндә, андагы Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге кайбер иске сүзләргә бит ахырында аңлатма бирелмәвен кисәтеп, ул болай ди: “...текстны укып чыккач, андагы байтак сүзне *бүгенге укучының* аңламаячагын беләсең. Мәсәлән, “Китап” шигырендә “Җиңелләнәм, мәгъсүмләнәм мин шул чакта” дигән җөмлә бар. Нәрсә ул “мәгъсүмләнәм”? Билгеле, VI–VII класс баласы моны аңламый. Яки нәрсә ул таифә, гаурәт, шәһвәт һ.б.? Ярый ла укучы үзе сорап, укытучы үзе аңлатып бирә алса. Ә укучы сорамаса яки сорап та укытучы белмәсә? Автор әйткән мәгънәгә төшенмәү өстенә укытучының да кыен хәлгә төшүе бар бит...”.

Төрле рәсми документларда, элмә атамаларда туган телнең бозылуын яисә бөтенләй татарча язылмавын аңлатканда да Сарьян сөйләм мәнфәгатен истә тота: “Өр-яңа культура йорты салганнар да маңгаена “Дом культуры” дип язып куйганнар. *Авыл – гел татар*. Яки өр-яңа кибет салып куйганнар да “Товары массового потребления” дип язып куйганнар. *Авыл – гел татар”* (*Сарьян Х.* Уеңны уйдырып сал... 96 б.).

Һәйкәлләрдәге язуларга да ул шундый караштa: “...һәйкәлләргә дә үзебезнең тел белән “Мәңгелек дан!” дип язып куйган булсак, үзебезнең халыкка, үзебезгә хөрмәт булмас иде микәнни!.. Аннары, авыл саен шушы һәйкәлләргә карап йөргәндә, бу авылдан ничә кеше үлде икән, дип исем-фамилияләрен укып, санап торганда, безнең янга берәрсенең әтисе яки әнисе дә килеп баса. Алар без юкта да киләләрдер. Әгәр шунда бер ана, төштә генә күргәндәй булып калган газиз улының исемен табып, “Дзяппаров Мутаххар” дип укыса – күңеле нишли икән аның? “И балам, үзең һәлак булу җитмәгән, инде исемеңне дә бозып бетергәннәр бит!” дип әрни торгандыр дип уйлыйм” (шунда ук. 97 б.).

Тәрҗемәнең сыйфатына бәя биргәндә дә Х. Сарьян аны менә нинди сүзләр белән билгели: “...мәгънәсез һәм аңлаешсыз җөмләләр... Төрле кульязмадан төрле йөз күрәсең: берсе куәтле, берсе куәтсез, берсе оялчан, берсе әрсез...”. Болар да иң әүвәле укучыны – сөйләм адресатын – күз алдында тоткан критерийлар. Кульязмага кеше сыйфатлары биреп, ул нәкъ менә текстның аралашу, аңлашу өчен әзерләнгән булуын искәртә. Югыйсә күпчелек тәнкыйтьче текстка ул

яктан бәя бирмиләр, бирсәләр дә, “матур”, “яхшы”, “тәэсирле”, “ошый” кебек гомуми бәяләр белән чикләнәләр. “Сүз мәңге хәрәкәттә, – ди Сарьян, – өстәвенә телдә дә тагын җәмгыятькә тиң хезмәт бүленеше бар”. Шунда ук Кави Нәҗми сүзләрен дә китерә: “Барлык татар халкының яше-карты бертигез белгән сүзләрне генә әдәбиятка кертү принцибы белән эш итсәк, телебезне ярлыландырудан башка нәтиҗә чыкмаячак” (шунда ук. 111 б.).

Шунысы аеруча әһәмиятле һәм кадерле: сөйләм белгече үзенең фәнни хезмәтләрендәге мондый “күрсәтмәләренә” әдәби һәм публицистик әсәрләрендә дә тугры кала. Әйтик, әгәр гарәп-фарсы сүзе нәкъ иң кирәкле сүз икән, бүтән сүз белән алыштырып булмый икән, әмма, ул шушы текстта адресатка аңлашылып бетмәс, дип шикләнелә икән, ул аны аңлатып китәр. Татарча йә урысча термин белән, йә бүтән чара белән: “Аннары тагын, әйткәнемчә, тел кагыйдәләребез бик нык унификацияләнү сәбәпле, бездә бернинди мөстәсна (исключение) юк” (шунда ук. 133 б.).

Үз йөзе, үз “кулы”

Мәшһүр бер язучы әсәрен йотылып укыганда, аның тел осталыгына сокланабыз да, моңа ничек ирешкәнен уйлап-төпченеп тормыйча, “талант кодрәте, табигать биргән могҗиза”, дип кенә куябыз. Дөрес микән? Хәсән Сарьян – танылган тел остасы, аның үз иҗат алымнары, үз йөзе. Ул моңа ничек ирешкән? Бүген бераз ачыклана төште кебек: язучыбыз укучысына әйтә торган сүзен нәкъ менәербөтен сөйләм итеп күзаллап, аның җанын, эчке һәм тышкы сулышын тоеп эш итә. Әйе, әйе, чын-чыннан эш итә. Ягъни армый-талмый эшли.

Язучы Евгений Замятин сүзләре истә калган: “Минем язмаларга карап ялгышырга да мөмкин – анда сызу-бозу, төзәтүләр күп түгел, җиңел язылган кебек тоелырлык. Әмма бу шулай тоела гына, барлык азаплар чаршау артында – һәр фикерне мин башта ун тапкырлап һәртөрле уйлыйм, аннары гына кәгазьгә салам. Эшкәргән фикер иртәгә, бәлки, ошамас та, үзгәртергә дә туры килер. Әмма бүген ул миңа тәмам ошарга тиеш, югыйсә мин алга бара алмыйм...”.

Беләм, Хәсән Сарьян да нәкъ менә шулай эшли иде: һәр сүзен, гыйбарәсен кабат-кабат карар, тыңлар, капшар, аннары гына энҗе бөртекләре кебек вак, җыйнак, бер-берсенә тыгыз тезелгән хәрефләр белән кәгазьгә төшерер. Аннары да әле, күп зиһенен, хәтерен, көчен салып, кайта-кайта эшкәртер, шомартыр, аһәңгә китерер иде. Менә ничек барлыкка килә бит ул язучының иҗади шәхси йөзе!

Останың йөзен аның куллары шәрехли. Хәсән Сарьян “кулы” дигәндә менә нинди конкрет “бизәк-нәкышьләр” күз алдына килеп баса:

– үзенчәлекле мәгънә төсмерләре булган, әмма соңгы вакытларда сөйләмдә пассивлашкан берәмлекләрне җанландыруы *(сыгымта, көлле, кәсәфәт, асла* һ.б.);

– кайбер алынма һәм үзебезнең гади сөйләм элементларын язма сөйләмгә урынлы кертүе (*зерә, керәч, тамансы, просто* һ.б.);

– уңышлы атама, терминнар тәкъдим итүе (*эленмә атама, туу таныклыгы* һ.б.);

– күп кенә гарәп-фарсы элементларын урынлы куллануга ирешүе (*аләт, муафыйк, мөбарәк, мөкәммәл, мәхбүс* һ.б.);

– сирәк кулланылып, онытылуга дучар ителгән фразеологизмнарны иҗади яңарту мөмкинлекләрен күрсәтеп бирүе (*ачкыч ярату, базары төшү, сөннәткә утырту, күз кабагын ачу* һ.б.);

– туган телебез хәзинәсендә аныкы гына булып җемелдәгән күпсанлы чагыштыру, троп, образлар, канатлы гыйбарәләр иҗат итүе. Менә берничәсе: “Әгәр без татар тел гыйлеменең җеп очын эзләп китсәк, *җепне сава-сава* мәшһүр бабабыз Каюм Насыйрига барып чыгачакбыз” (шунда ук. 109 б.); “Бик борынгы баба телендәге уртак тамыр сүзләрне исәпкә алмаганда, берничә сүздән башка, телебездә монголның *канат очы белән себерерлек тә* эзе калмаган” (шунда ук. 110 б.); “Бу соңгы елларда телебезнең грамматик кануннарын, *агач кортыдай, әкрен-әкрен генә кимерә* башладылар” (шунда ук. 116 б.).

Сүз җаеннан дигәндәй, грамматик чараларга Хәсән Сарьян үзе аеруча сак, аеруча игътибарлы:

– ярдәмче фигыльләрнең өстәмә мәгънә төсмерләрен ача, шулай итеп, штамп, калыплардан котыла (*йогынты иткән* халык – йогынты ясаган түгел... (шунда ук. 111 б.);

– телнең күпсанлы синтаксик фигураларын куллана, яңа төрләрен үзе дә иҗат итә, аеруча кабатлауларны иҗади файдалана (...гарәп сүзләре “бер сузыкка бер тартык” моделе белән татар теленә *калыпка калып, авазга аваз дигәндәй кергән дә утырган, кергән дә утырган...* (шунда ук. 11 б.);

– сүзләрнең сирәк кулланыла торган синонимнарын әйләнешкә кертеп, фикри калыплардан, стереотиплардан котылу юлын күрсәтә (телдә дә җәмгыятькә *тиң* (кебек, шикелле, сыман, хас, тәңгәл һ.б. урынына) хезмәт бүленеше бар...).

Хәсән Сарьянның тел куллануга, сөйләм оештыруга кагылган караш, фикерләренә мисалларны без аның фәнни һәм публицистик

әсәрләреннән, анда да әле бер генә китабыннан китердек. Матур әдәбият остасы буларак та Хәсән Сарьянның үз алымнары, үз йөзе бар. Ул соклангыч бай, тәэсирле вә үзенчәлекле. Анысы – үзе бер дәрья, анысы да фәнни өйрәнү өчен әһәмиятле, мавыктыргыч тема.

Хәсән Сарьянның "Әткәм һөнәре", "Егет язмышы", "Нокталы өтер", "Бер ананың биш улы" повестьлары, унлап хикәясе үз вакытында төрле сәяси вакыйга, кампанияләргә, социаль заказларга бәйләмичә, төрле бүләк-премияләргә исәп тотмыйча, социалистик реализм кысаларына көчләп кысмыйча, яраштырмыйча язылган, ә бәлки халкының рухи ихтыяҗына үзенең җан хәләте туры килгәнгә язылган, шуңа күрә укучыларының да күңеленә дым көтеп зарыккан туфракка җылы, шифалы яңгыр суы кебек көчләмичә, көчәнмичә, үзеннән-үзе сеңгән иҗат сутлары буларак кабул ителгән әсәрләр иде.

Бүген дә – халык матур әдәбиятне күпләп йотлыгып укымый башлаган бер заманда – бу әсәрләрнең укылудан туктамавы, бигрәк тә аларга яшьләрнең кызыксынуы сүрелмәве үзенә бер уйландырырлык күренештер.

Шөкер, безнең әдәби тәнкыйть мирасыбызда Хәсән Сарьянның үзен, аның иҗатын төпле белгән әдипләр Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Лирон Хәмидуллин, Марсель Галиев, тәнкыйтьче–галимнәрдән Фәрваз Миңнуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Галимуллиннарның истәлек-уйланулары, башлангыч күзәтү-тикшеренүләре бар. Шул хезмәтләрне тагын бер барларга, әдәбият сөюче яшьләргә җиткерергә, тагын да мөһимрәге, элгәрләребезнең шул мисалыннан үрнәк алып, илһамланып, әдипнең иҗат серләрен ачу юлында җитди фәнни тикшеренүләрне дәвам иттерергә кирәктер.

Без исә үз белгечлегебезгә якынрак темага – ана телебезне куллану өлкәсенә тугры калып, Сарьян әсәрләренең бүген дә укылуын танып, моның сәбәпләрен ачыкларга алынган галим, белгечләрнең, әдипләрнең һәркайсы аның татар телен бик нечкә белеп, барлык чараларын мөкәммәл куллану осталыгына игътибар итми калмас. Иң башта моны әсәрне укучы үзе тоя, әсәрнең җиңел, тәм белән укылуыннан ана теленең көч, тылсымын, тәэсирен тоюдан хисләнә, әсәрнең төп идеясенең, әйтер максатының нәкъ менә шул тылсымлы, могъҗизалы корал ярдәмендә генә күңеленә үткәзелә, сеңдерелә баруын аңлый. Моңардан үзенең ничек сихерләнүен укучы ачык кына әйтеп тә бирә алмас. Моның кирәге дә юк. Нигә әле ул теге-бу тәмле ризыкның ни өчен тәмле икәненә төшенеп торсын, әгәр ул аны пешерүче яисә дегустаторы булмаса, моңа ихтыяҗ да юк.

Ә менә язган кеше бу тылсымлы кодрәтне тоеп кына калмый, моның серен, нечкәлекләрен аңларга да тели. Хәсән Сарьянның каләмдәшләре аның әсәрләрен язганда телебездән шулай осталарча куллана алуының сер-сәбәбен төшенергә телиләр, өйрәнәләр, хуплыйлар иде. Менә Гариф Ахунов язмасыннан: “...шул ук вакытта ул тел галиме иде, төрки телләрдә сөйләшкән илебез халыкларының китапларын аларның ана телләрендә оригиналда укый иде, тел өлкәсендә ул байтак гыйльми хезмәт калдырды. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә катнашты, тел һәм стиль мәсьәләләренә багышланган китаплар бастырды, радиодан әдәби телебезгә кагылышлы әңгәмәләр алып барды...”.

Гариф Ахунов хөрмәт белән санап киткән менә бу хезмәтләре үзләре генә дә бер кешенең бөтен бер гомерен бирерлек хәзинәдер. Чыннан да, аның “Уеңны уйдырып сал...” дигән фәнни хезмәте менә ничә еллар инде мәктәптә, югары уку йортларында стилистика, журналистика, язучылык эше, риторика курсларын үтүчеләргә искермәс дәреслек санала.

Остазның менә бу иҗат юнәлеше, хезмәтләре аның үз әсәрләрен язганда телне оста, урынлы куллану өчен таяныч, терәк, чыганак кына булып калмыйча, бүтәннәргә дә, хәтта инде танылган, шомарган язучыларга да ярдәмлек булуы мәгълүмдер. Бу фикерне Гариф Ахунов сүзләре белән дәлиллик: “...Хәсән Сарьянның повесть һәм хикәяләрендәге лиризм, җылылык укучыларны дулкынландыра, телнең төгәллеге, гадилеге һәм халыкчанлыгы барыбызны да сокландыра. Тел мәсьәләсендә аңарга Гомәр Бәширев, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники кебек өлкән язучыларыбыз, аксакалларыбыз да мөрәҗәгать итә, әсәрләренең теле хакында әледән-әле киңәшә иде...”.

Шулай да мондый бәя, мәгълүмат та “Хәсән Сарьян – ана теле” мөнәсәбәтен, темасын гадиләштерү, өстен караш булыр иде. Вакытвакыт Хәсән Сарьянның тәрҗемәи хәленең, иҗатының төрле каршылыклар белән бәйле, катлаулы булуы искәртелсә дә, моның сәбәпләрен ачыкларга омтылмау, дөресрәге, ачыклый алмау очракларына юлыккалыйбыз. Ә бит боларның кайберләрен әдипнең ана телебезгә мөнәсәбәтендәге кайбер факторлар белән төшенергә һәм аңлатырга мөмкин булса кирәк. Уйланыйк әле...

Утызынчы елларда татар авылында туган балаларның башына төшкән тормыш михнәтләренең барысы да Сарьянга да язылган булган икән. Яшьли әтисез кала. Үсмер вакыты ачлык, ялангачлык белән җанбәгырьләрен парә-парә җәрәхәтләгән сугыш елларына туры килә. Ярый

әле эш яратуы, аның да кешене физик көч-куәт белән генә түгел, рухи яктан да баета торган балта остасы һөнәре белән мавыгып китүе, аннары белемгә омтылуы, әдәбият белән кызыксынуы, тырыша-тырыша Бөре педагогия училищесын тәмамлавы аны ялгыш-яман юллардан коткарып кала. Аның холкында үзеннән дә бигрәк бүтәннәрне кайгырту сыйфаты елдан-ел өстенлек ала бара. Журналистлыкка, каләм тибрәтүгә омтылуы шуннандыр да. Клуб мөдире булып эшләп китүе, берара сукыр артистлар белән, аларны авылдан авылга җитәкләп диярлек йөртеп, сәнгатькә, нәфис сүзгә сусаган кешеләргә концерт-спектакльләр куеп йөрүе шул хакта сөйли. Аннары ул Башкорстан педагогия институтын тәмамлый, халыкны агарту эшенә керешә: студентлар укыта, үзен журналистика хезмәтендә сыный башлый.

Язганнарының, сөйләгәннәренең кешеләргә кыенлык-авырлыкларны җиңәргә булышырлык көч икәнен ныграк аңлый барган саен, сүзгә ул бик таләпчән карый башлый. Бәхетенә, үзендә образлы-сурәтле фикерләү, тасвирлап-сурәтләп бирү сәләте, ягъни сүз сәнгате таланты барлыгын көннән-көн көчлерәк тоя бара. Бер үк вакытта ул нәсел тамырлары, ана сөте белән бирелгән менә шушы талантны кешеләргә түкми-чәчми теләсә нинди корал-чара белән түгел, ә бары тик шушы талантка тәңгәл тел белән генә, татар халкы дип аталган, уй-фикере, гореф-гадәте, эш-гамәле татар теле белән генә уелган-чигелгән халыкка нәкъ аның үз телендә генә ачык һәм тәэсирле, хисле вә үтемле итеп җиткереп буласын тәмам төшенгән иде.

Тик бу яп-якты ачыш дөм караңгы бәла белән, Сарьянча әйтсәк, кәсәфәт белән бергә килеп баскан иде: шушы изге, бөек хакыйкатьне аңлау-төшенү белән аны гамәлгә ашыру арасында котычкыч каршылык тора иде – шушы таләпкә туры килерлек әсәр яза алганда да ул аны укучылары яшәгән төбәктә – Башкортстанда бастыра алмаячак бит! Бу инде упкын читенә килеп басып, аны сикереп чыга алмаячагыңны белеп, үзеңә-үзең кул салу белән бер иде.

Бер караганда, бу арттыру да кебек. Ул чагында инде Сарьян югары белемле, язучылык эшенә сәләте ачылган, укыту-галимлектә дә өметле саналган, төпле генә гаилә корып җибәргән, кем әйтмешли, перспективалы зыялы иде. Башкорстанның Илеш районында туып-үсеп, шәҗәрәсе буенча татар булып та “башкорт” дип теркәлгән, Уфаның күпчелек каләм әһеле кебек, башкорт теле дип аталган җирле сөйләшне яхшы үзләштергән, сөйләшә дә, яза да ала иде. Бер караганда, моның бернинди кыенлыгы юк иде. Аның язганнарын Уфада чыга торган теләсә кайсы газет, журнал шундук әлеге шул “башкорт

теле” дип аталган язуда басарга әзер иде. Саф татарча уйлап, саф татарча язган кайбер каләм әһелләре менә шулай бастырып яшәп яталар да бит. Чөнки миллион ярым халкы саф татар саналган, шул телдә уйлаган, мәктәпләрдә татар теле дәресләре алган, Казаннан килгән татар әдәбияте, татар газет-журналлары алдырып укып яткан, Татарстан радиосы тыңлап тәрбияләнгән, гомер бакый татарча аралашып яшәгән халыкка Уфада татарча китап бастыру тыелган иде.

Нишләмәк кирәк?! Сарьянга да, тәкъдиреңә шулай язылгач нишлисең инде, дип, үзен-үзе акларга мөмкин иде. Әлбәттә, туган илдән яшьли аерылып, Казанга китеп төпләнүчеләр, татар язучылары саналучылар да аз түгел. Тик аларның күбесе, Уфа белән башта аралашып тормыйча, мәктәптән үк Казанга китеп укып, язарга шунда өйрәнеп, Татарстанның “үз” кадры булып киткән иҗатчылар; аларга мөһаҗирлек ярлыгы тагылмаган, өстәвенә әле паспортына да, Сарьянныкы кебек, башкорт тамгасы сугылмаган.

Шул ук вакытта үз телең була торып, шул тел белән яшәп яткан халкыңа бүтән бер ясалмарак телдә сүз катып булмый бит инде! Шулай итеп, Сарьян җанын бик озак талкып-тырнап торган зур вәсвәсә-каршылыкны җиңүгә ирешә: Казанга чыгып китә.

Табигый ки, Казан аны язучы буларак кочак җәеп каршы алмады, аны Уфада ук цензурада яманаты чыккан “Нокталы өтер” повестеның Казанда визит карточкасы була алмасы үзеннән-үзе аңлашыла иде. Тормышны ничек тә дөрес чагылдырырга омтылуы, шул чор идеологиясе, социализм реализмы дигән калып-алым таләпләренә җавап биреп бетермәве белән аерылып торган башка әсәрләрен дә Казанда күтәреп алулары икеле иде.

Ялгышмасам, баштагы чорда ул моңа омтылмады да. Уйлавымча, саф татар мохите шартларында әдәби тел белән эш итү, язучының аңа мөнәсәбәте мәсьәләләрен күзәтү, кыскасы, үзенең асыл коралын тәмам аңлап бетерү, яңа шартларда, яңа чыганаклардан аны төпле үзләштерү, озак елларга җитәрлек байлык туплап, мая җыю максатыннан телне өйрәнүгә, тел фәне өлкәсендә үзен чынлап торып сынап карарга тотынды, шулай итеп, Казанда яшәвенең башлангыч елларында ул, язучы булудан да бигрәк, тел белгече-тикшеренүчесе буларак танылды.

Аның тел белеме өлкәсендәге бу эшчәнлеге, гәрчә чын мәгънәсендә актуаль, фәндә яңа юнәлешле, ягъни телне куллану өлкәсен тикшерү эшчәнлеге булуга карамастан, ул чорда әле һаман телнең төзелешен, ягъни структура өлкәсен өйрәнү белән

шөгыльләнүче тел гыйлемендә бик күтәреп алынмаса да, әдәби телнең кулланылышы белән кызыксынган язучылар, киң җәмәгатьчелек арасында зур кызыксыну һәм хуплау тапты. Казанга күчеп килү, төпләнә башлау кыенлыгын кичергән Сарьянга таяныр булышчы була алган, ярдәм кулы сузган бик аз кешеләрнең берсе – Әмирхан Еники – аның бу эшчәнлеген менә болай бәяләгән иде: "...Казан Сарьянны, ниһаять, таныды, белде аның нинди талантка ия икәнен... Тик, кызганычка каршы, шактый соңлап. Ничектер шулай килеп чыкты ки, Сарьян башта үзен җитди тел белгече, аннары гына чын художник – әдип итеп танытты. Уфадан килеп, ул безнең туган телебезнең нечкәлекләрен аңларга, сүзләрне белеп, дөрес кулланырга өйрәтә башлады. Газетларыбызның, радиотапшыруларның шактый чүпләнгән, бозылган, агачланган телен анализлап язган мәкалә һәм чыгышлары бик вакытлы да, бик кирәкле дә эш булып чыкты. Әнә шулай тел бабында авторитет казанып, ул ахырда Татарстан радиосының "Тел күрке – сүз" дигән даими тапшыруларын алып бара башлады. Телебезнең сафлыгын, байлыгын саклауда күрсәткән аның бу тырышлыгын без, әлбәттә, онытмаска тиешбез".

Күрәсез, бу чорда Сарьянның тел куллану (сөйләмият) фәненә нигез ташлары булып салынырлык эзләнүләре, әйткәнебезчә, яңа шартларда көчәеп китәчәк иҗаты өчен төп коралын янә бер тапкыр барлып, сынап, чагыштырып карау, аның чыннан да ышанычлы корал икәненә үзен тагын бер тапкыр инандыру булса, икенчедән, аның бу иҗади тикшеренүләре башка әдипләргә, бигрәк тә яшьләргә, бигрәк тә гаммәви мәгълүмат чараларында эшләүче журналистларга, укытучыларга һәм, тулаем алганда, бөтен халыкка, ана телебезнең байлыгына, аның көче-кодрәтенә сокланып, горурлык, хөрмәт хисе уятуы, аны дөрес кулланырга, бүтән телләр тәэсиренә бирешмичә сакларга омтылу хәрәкәтен көчәйтеп җибәрүе белән дә әһәмиятле булды.

Кайсы язучының, бигрәк тә яшь иҗатчыларның, бу юнәлештә ни дәрәҗәдә талантлы-сәләтле икәненә ул бик сизгер иде, яңа әсәрләренә рецензияләр язып кына түгел, бүтән төрле киңәш-гамәлләр белән дә хәстәрлек, булышлык кыла иде. Кемгә абыйларча үгет-нәсихәт, ә кемгә җылы сүз кирәклеген ул эчке бер сизгерлек белән тоя иде.

Аның бу изгелеге үземә дә тиде. Казан артында туып үсеп, һөнәр, белемне Казанда алганнан соң, байтак еллар Уфада эшләргә туры килде. Язу эшен дә чынлап торып шунда җәеп җибәрдем. Журналистлык язмаларымны татарча чыга торган "Кызыл таң" газетында, ә кайсыларын, башкорт шрифтында язарга да күнегеп, "Агыйдел" ке-

бек башкортча алфавит белән чыга торган журналларда бастырып килсәм дә, чын әдәби әсәрләр язарга тотынгач, аларны тик анам телендә бастырып кына чын татар укучым белән ихластан аңлаша-аралаша алачагыма җаным-тәнем белән инангач, чыннан да, кыяга килеп төртелгән җанвардай, ничаралыктан башны бәреп ярыр хәлгә төшкән идем. Менә шунда мин Сарьян абый хәлен бөтен тәнем-җаным белән аңладым.

Әйе, Уфада гаиләле, эшле, квартирлы булып, журналистикада да шактый танылып, тәмам тамыр җибәреп яшәп киткәндә генә тәртәне кире Казанга борырга мәҗбүр идем. Хәер, бер уйласаң, хәлем Сарьян абыйныкыннан, аның хәленә тарыган кайбер бүтән язучыларныкыннан җиңелрәк иде бугай – мин бит Туган илемнән китмим, аңа кайтам гына, дөресен әйткәндә, минем бит Казаннан чынлап торып аерылып беткәнем дә булмады, һәрхәлдә, Казанга мин килмешәк түгел.

Шулай да Уфадан аерылу өчен үзенә бер кыюлык, тәвәккәллек кирәк иде. Менә шуны ничек кылырга белмичә икеле-микеле йөргән көннәрнең берсендә Казаннан Сарьян абый кайтып төште. Кулында татар телендә басылып чыккан “Әткәм һөнәре” китабы. Аның шатлыгы миңа да күчеп, сәер бер өмет, тәвәккәллек канатлары булып кагына башлады. Аннан соң да ул китапларын автограф белән биргәләде, әмма бу китаптагы язуын әти-әни фатыйхасы, абыем фәрманы дип кабул иттем: “Илдар дуска! Уфа җирендә күп яттың, Казаныңа кайт инде...”, – дип язган иде.

Шуннан соң ел ярым үтүгә, Казанга кайтып киттем. Беренче китабымның кулъязмасын Татарстан китап нәшриятенә җибәргән идем инде, кайта-кайтышка шунда йөгердем. Кулыма рецензия тоттырдылар. Кемнән рецензияләтү турында, әлбәттә инде, минем белән киңәшләшеп тормаганнар иде, иң таләпчән тәнкыйтьчегә бирәбез, дигәннәр иде. Анысы – факт. Сарьян абыйның энҗе кебек язуын күргәч, йөрәк кысылып килде.

Тик юкка шүрләгәнмен. Ул китапны басарга тәкъдим иткән. Гомер буе яшьләргә мәрхәмәтле булды. Шулай итеп, тагын бер елдан минем дә “Күңелеңдә ниләр бар?” дигән кечкенә парчалар җыентыгым басылып чыкты. Татар телендә – анам телендә.

Автограф димәктән, күрсәгез икән сез Сарьян остазның кул язуын – сабыйның тип-тигез булып тезелеп киткән бер зурлыктагы теш бөртекләре кебек җемелдәп торган хәрефләр. Сүз арты сүз. Язган кешенең үз-үзенә дә, укыган кешегә дә ихтирамы-хөрмәте, һәр сүзнең ничек тәэсир итәсен алдан уйлап хәстәрлек күргәне сизелеп тора. Һәр

аваз-хәрефкә, һәр сүзгә төп-төгәл мәгънә, аһәңле хис төсмере үлчәп-чамалап кына сеңдерелгән. Шул төгәл берәмлекләрдән сиңа да тылсымлы бер дулкын күчә бара, сеңә бара...

Сарьян һәрвакыт эш-хәрәкәттә булыр иде һәм шул хәрәкәттә, хәтта кешеләр белән аралашканда да, телефоннан сөйләшкәндә дә, фикерен төгәл әйтү өчен сүз эзләве чыраена чыга кебек иде. Хәер, без инде Хәсән Сарьянның остаханәсенә кереп барабыз бугай. Бу турыда без инде бераз сөйләшкән идек.

Хәсән Сарьян – редактор

Хәсән Сарьян – гомере буе редакторлык (мөхәррирлек) вазыйфасына тугры калган әдип. Беренчедән, ул үз әсәрләрен – гап-гади хат яисә газет мәкаләсеме, радиода чыгышмы, әллә хикәя, повестьмы – барчасын, һәр сүзен, гыйбарәсен, бөртекләп күздән кичереп чыгып, кимчелек-китеклекләрен тоеп-күреп, аларны иренмичә, уйлый-уйлый, телнең камилрәк чараларын эзли-эзли төзәтә; ана теленең – редакторның бердәнбер коралының – бөтен мөмкинлекләрен кулланырга тырыша, һәр җөмлә, гыйбарәсен иң нечкә шомартылган алмаз бөртеге хәленә җиткермичә тынычланмый иде.

Икенчедән, Хәсән Сарьян бөтен иҗат гомерендә бүтән авторларның кульязмалары, текстлары өстендә дә эшләде: шәхси ярдәм сыйфатында, авторларның, бигрәк тә яшь иҗатчыларның үтенечен канәгатьләндереп, кульязмаларын, басылып чыккан әсәрләрен игътибар белән, каты таләпләр куеп, шул ук вакытта аталарча кайгыртып, укыды-анализлады, төшендерде, үз кулы белән төзәтте; нәшриятләр үтенече белән кульязмаларга эчке рецензия әзерләп бирде; һәр рецензиясе тирән анализланган, төпле дәлилләнгән фәнни мәкаләгә тиң иде; әсәрләргә бәяләмәләрен матбугат аша киң җәмәгатьчелек игътибарына да җиткереп торды; редакцияләү барышында ана телен куллану осталыгын яктырткан фәнни-популяр мәкаләләр язды. Алар Татарстан радиосының “Тел күрке – сүз” тапшыруында даими яңгырады, газет-журналларда басылды.

Әдипнең редакцияләү эшендәге иҗади күренешләрне, язмаларда очраган хата, кимчелекләрне теркәп куя барган, бу хаталарга, аларны төзәтү алым-чараларына үз фикер-мөнәсәбәтен бәян итеп килгән яшел тышлы калын дәфтәре безгә мирас булып калган. Үз вакытында “Мәдәни җомга” газетының “И туган тел...” кушымтасы яшел тышлы дәфтәрдән кайбер өзекләрне **“Сарьянның тел сабаклары”** исеме астында бастырып та чыгарган иде.

-да/-дә тирәсендә өтер

"... Атыннан сикереп төште дә Гата үзе Миңнулла каршына килеп басты". Бу җөмләнең өтерен өч урынга куеп була: 1) "төште дә" артыннан; 2) "төште дә Гата" артыннан; 3) "төште дә Гата үзе" артыннан. Һәркайсында мәгънә төсмере үзгәрә төшә.

"Яктыргачрак карасак, аптырадык та калдык". Моны ике төрле үзгәртеп була: 1) "аптырадык та калдык" – кушма хәбәр; 2) "аптырадык та, калдык", ягъни башта аптыраганнар, аннары китмәгәннәр – калганнар.

Аһәң, музыкальлек

"Шунда мин түзмәдем, үзебезнең серле шагыйрьне атакаладым". "Атакаладым" – "ата каз" дигәндәге сыман татарча укыла, бик ямьсез аһәң хасил була.

"Бүтәннәре җыен читендә тукталып калды, ә Гата аты белән халык арасына ук килеп керде...". Монда "н"нар күп. "Гата аты" да "ата-аты" кебек ишетелә.

"Көтмәгәндә капкадан Гайнан анасы Җәүһәрия килеп керде". Ишетелә: "на-на-на-сы".

Мыгырдау, мөгрәү турында

"Тик үзенә генә аңлаешлы көйгә эченнән ниндидер җыр мөгрәп барды". Җырны ничек мөгрәп була икән. Мөгрәү фәкать сыер малы эше. Фигурально кешегә карата да әйтелә. Ләкин автор инде реаль итеп язганда, болай дип күчерү һич дөрес түгел.

"Йа ходай, ахыр заман җитүе шушыдыр инде. Йомыркадан борынларга өлгермиләр, нәчәлник сорыйлар. Шушында ничә ел эшлим, нәчәлник түгел, пумышнигы янына да кергәнем юк,– дип мыгырданды әби". Бу кадәр ачык итеп, күп сөйләгәч, нинди мыгырдау булсын; мыгырдау – сүзләре ачык ук түгел, кайсы аңлашыла, кайсы юк дигән мәгънәле була.

Шаблон сүз һәм тәгъбирләр

"Агымдагы ел планнарын тормышка ашыру перспективага бару юлында әһәмиятле адым булачак". "Быелгы ел планнары" дип кенә язарга кирәк бит югыйсә. (Рәсми текстта: "быелгы планнары". – *И.Н.*)

Калькалар

“Миңа бит бары сезне ишетеп карау гына кирәк”. Салих Гөләмдәнгә шулай ди. Ягъни: “уйнаганыгызны ишетеп карау кирәк”, дияргә тиеш иде. Урысча итеп кыскартылган.

Тиңдәш кисәк кушымчалары

“Бүген атакалап та борчымыйлар, бертуктаусыз пулеметлардан һәм автоматлардан сиптереп тә аптыратмыйлар”. Кирәк: “пулемет һәм автоматлардан”.

“Бүген ул кара костюм, ак күлмәк, кара бантиктан иде”. Бу – дөрес. Һәркайсына кушымча ялгап тормаган.

Килеш кушымчалары

“Хәтерлисеңдер. Беренчесендә парта астында тапкан пеналны гына хуҗасына бирмәдең син...”. Кирәк: “Парта астыннан тапкан”.

Калькалар

“Ләкин командир каушап калмый, соңгы тамчы канга кадәр сугышырга *чакыра”.*

“Син бигрәк тә *караңгы* кеше инде, Вакыйф, – дип, егетләр аннан көлешеп алдылар”. Монысы “темный человек”тыр инде.

“Кыска ударлар белән һөҗүмне *алып бар”.*

Кешенең йөзе, кыяфәте

“...Чем-кара чәчле һәм шундый ук кашлы, алга чыгып торган киң маңгайлы...”. Алга күпмерәк чыгып тора икән: сантиметрмы, метрмы?

Мәгънәсе башка сүзләр

“...Үзеңнең элек кем булганыңны һәм үзең теләп безнең якка чыкканыңны әйтеп, әсирләрне дә шулай эшләргә чакырсаң – шул бик җиткән!” Монда “эшләргә өндәсәң” кирәк. “Эшләргә чакыру” конкрет эш кушуга бәйле.

“Капчык эчендә тимер кыйный торган гади сандал иде”.

-лар/-ләр кушымчасы

“Усманның кулбашлары һәркайсына берәр тегермән ташы бастырып куйган төсле авырлар”. “Кулбашлары” – бердән, җансыз, икенчедән тартым кушымчасы бар, өченчедән, “авыр” – сыйфат.

Шушы өч сәбәп аркасында “авыр” үзе берлек санда булырга тиеш: кулбашлары авыр.

“Балалары аналарыннан җитезләр”. Өч сүз, өчесендә дә *-лар* бар. Беренче, икенчесендә кирәк, хәбәрдә кирәкми. Чөнки, беренчедән, иянең тартым (чикләү) кушымчасы бар; икенчедән, “җитез” – сыйфат; күплек кушылса, исемгә әйләнә.

Чама категориясе

“Йодрыгы белән генә түгел, наган түтәсе белән төйде Миңнулланың башын”. Бу баш нишләргә тиеш икән?

“Өйләренә кайткач, Әфләтун төн уртасында мунча артына чүмәлә салып куйган, шуңа күрше тавыгы батып, чыга алмыйча үлгән, ди”. Ай ямьсез! Моны автор әйтә. Персонаж түгел.

Кире типларның тавышы

“Ышанмагыз, Олег Васильевич, Карыйда мин нибары дүрт көн генә элек булдым, – дип *чәрелдәде* теге” (Хәйрулла). “Чәрелдәде” булгач, ул просто чәрелдәгән, ягъни тавыш кына чыгарган була, чөнки бер үк вакытта чәрелдәп һәм сөйләшеп булмый.

“Ах, син әле һаман акылыңа килмәдеңмени!” – дип *чинады* Кошкарев”.

“Шулай булмыйни! – Ананың тавышы *чыжлап-ысылдып* чыкты.

“Фатих хәлфәнең төсе качты. Озын бармаклы ябык кулы белән битен каплап, ачулы *гыжылдады:*

–Көфер сүз сөйләп торасың, фасикъ!..”.

Ике мәгънәле сүзләр, җөмләләр

“Шушы көннәрдә *Кукмарада ярышучы* Кукмара һәм Балтач районнарының “Хезмәт даны” һәм “Хезмәт” газетлары журналистларының киңәшмә летучкалары булды”. “Кукмарада киңәшмә булды “ дигән форма урынына *“Кукмарада ярышучы”* килеп чыккан. Шундый ук хата менә бу җөмләдәдә бар: *“Шундый йөгереш үткән атнада Казанда уздырылды”.* Нинди атна? *“Шундый йөгереш үткән атна”* килеп чыккан.

Грамматик калькалар

“...Бер аягында гына сикергәләп, (Альфа) читкәрәк атлады”. Кирәк: “бер аягы белән генә”.

“Альфа озак ялындырып тормады, барып пианино *артына* утырды”.

“Тукай сүзләренә җырлана башлагач, ул әйтерсең яңадан туды”. Шушы җөмләдән өч кенә юл өстә автор үзе үк “Мәрхүм Габдулла абый Тукай сүзләре *белән* аны хәзер бөтен мәктәпләрдә җырлыйлар” дип дөресен яза.

“Тик менә аякларда гына төрлечә – Сабирада шнурлы гади ботинка, ә миндә зур перламутр каптырмалы модный туфлиләр”. Аңлатма: “аякта итек һ.б. дисәң – дөрес. Әмма “Сабирада” яки “миндә” дигәч инде, мәгънәсе бөтенләй үзгәреп китә: “Сабирада ботинка” дигәч, “Сабираның ботинкасы бар” дигәнне аңлата, алай гына да түгел – “Сабира ботинка тоткан” дигән мәгънә күз алдына килә. Чагыштыр: “Сабирада капчык, миндә янчык”.

Дөрес грамматик формалар

“Мин бик мавыгып нәкыш, скульптураны өйрәнергә керештем” *(Б. Урманче).* Бу җөмләдә тиңдәш кисәкнең кушымчалары да, “керештем” сүзе дә дөрес кулланылган. Әйтик, “нәкышне, скульптураны” дип, кушымча кабатланмаган.

“Ун класс *бетергән* 154 егет һәм кызның 12се бүген институтларда укый” (“Социалистик Татарстан” газетыннан).

-да/-дә кушымчалары

“Яле, ташлагыз әле коралларыгызны да, күтәрегез әле кулларыгызны!” “Да” “ташлагыз”ныкы, ләкин аның “коралларыгызны да” булып аңлашылуы ихтимал. Өтер булмаса, “коралларыгызны да күтәрегез” дип тә укылуы мөмкин.

Аһәң, музыкальлек

“...Җидегә ярылса*лар* ярылыр*лар*, ләкин үз дигәннәрен эшләми калмас*лар*”. “Лар–ләр, “рыл–рыл–лыр” күп.

“Ә Нәҗип гамьсез, б*ашын* иеп а*шын шуп*ыра”. “Шын-шын-шуп”. Ямьсез ишетелә.

-лар/-ләр кушымчасы

“Башын бору*лар*ы**,** күз сирпү*ләр*е**,** гәүдә тотыш*лары* – барысы да анык*ы**лар*”

“Ачлар алар”. Ия-хәбәр янәшә торганда, “-лар”ның һич кирәге юк: хәбәрнең саны иядән аңлашыла.

“Ничек”, “нинди”

“*Менә хәзер алар икәү булса, ничек әйбәт булыр иде”.* Кирәк: “нинди”.

“Кара син аны, ничек яшереп йөргән миннән”. Болай да булуы мөмкин, ягъни “ничек яшергән”? Ни рәвешле хәйләсен табып яшергән. Ләкин контекстта “нинди” кирәк.

“Күрәсең”, “ахыры” һ.б.

“Уйнап бетергәч тә мин торып чыгып киттем – әйтерсең бизгәгем кузгалды, качтым тизрәк!” Искәрмә: “Әйтерсең” – ике мәгънәле: берсе – гүя; икенчесе – туры, үз мәгънәсендә.

“Мин, үбә ахырысы дип, бер мизгәлгә бөрешеп, өнсез булып калдым” (*Ә. Еники*). Искәрмә: “ахырысы”ның ике ягыннан да өтер куйсак, сүз саен өтер булыр иде: мин, үбә, ахырысы, дип! Әйтерсең, һәркайсы мөстәкыйль сүзләрне саныйбыз.

-да/-дә кушымчалары

“Арадан берсе, җитезрәге, ипи кисәген тиз генә эләктереп алды да ашый да башлады”. Бу җөмләдә ике хәбәр бар: 1) алды; 2) ашый башлады. Беренчесендә -*да* – теркәгеч, икенчесендә -*да* – кисәкчә. Мондый очракта беренче -*да* дан соң өтер мотлак кирәк.

“Ә син шунда берәр шифалы дару язып бирәсең, авыру тазара да китә”. “Тазара да китә” – бер кушма хәбәр. “Тазара да, китә” – ике хәбәр: башта тазара, аннан китә.

“Бу абзый чанадан очып төште дә калды”. Искәрмә: “төште дә”дән соң өтер куйсаң, ике хәбәр була.

“Бизи” ниләр бизи

“Мәктәп каршындагы бакчаны кечкенә генә һәйкәл *бизи”.*

“Бик күпләрнең күкрәген хөкүмәтебез орден-медальләре *бизи”***.**

Катлы-катлы аергычлар

“Урамның аргы очындагы, аскы катында ипи кибете булган зур таш йортта торучы ялгыз Тәскирә”.

“Самат, уң кулын алга сузып, *имән бармак бите белән баш бармак* очын ышкып күрсәтте”.

Чагыштырудагы ялгышлар

“Саимә апа – директор хатыны. Елның елында ул үзенә классны мәчет карты төсле тәртипле һәм җир тычканы төсле тырыш укучылардан гына туплый”. Хәзерге заман укытучысы балаларны “мәчет карты төсле” булса дип сайлый. Ә ул үзе мәчет картын беләме дә, бу хикәяне укыган балалар беләме?

Грамматик калька

“Казаннан Х. Сибгатов язган хаттан бу юллар”. Дөресе – “Казанның” йә “Казанда яшәүче” кирәк. Ә бу җөмләдә Сибгатовның Казанда яшәве, Казан кешесе булуы түгел, ә бәлки аның хатны Казаннан язуы аңлашыла. Бу форма, гомумән, урысчаның “Сибгатов из Казани” формасыннан калькалашкан.

Калькалар

“Бер аналарына гына очын очка ялгап *тормыш алып бару* авырдыр”.

“...Диде Тәскирә бу яңалыкны *үз манарасыннан чыгып бәяләп”.*

“Эш сәгате инде күптән *чыккан* булса да”.

Тиңдәш кисәк кушымчалары

“Шуның ничә елын (Равил) колонияләрдә һәм төрмәләрдә утырды”. Кирәк: “колония һәм төрмәләрдә”.

Иске грамматик формалар

“Озын томшык бар көченә җилкен*мәк* булды”.

Кешенең йөзе, кыяфәте

“Бик яшенең йөзе сөттәй ак, чәчләре чем-кара, ә күзләре зәпзәңгәр. Кара чәч, зәңгәр күз! – бу бит әллә ничек, бер дә табигый түгел сыман” *(Ә. Еники*). Аңлатма: күз алдына килгәне – зәңгәр күзләре. “Кара чәч, зәңгәр күз” дип кабатлап әйтмәсә, ягъни өстәп ныгытып куелмаса, сизелми укылуы бар иде.

Мәгънәсе башка сүзләр

“Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала”. Искәрмә: автор “олы хәсрәт сәбәпле” дигән мәгънә белән әйткән; текстта исә “хәсрәттән тирән” чыккан.

“Аның тәрәзәләреннән яктылык төшә, җир тавышы *саркый”.*

“Кызның әле яше чыкмаган, утыз белән бармый”.

Урынлы тавтология

“Күрәсең, күп кешеләр мин *уйлаган уйны* уйлаганнар *(Д. Юлтый).*

“Мин бит сине сагынып гакылдан *яза яздым”* (Ә. Еники К. Тинчуриннан цитата иткән).

Кешенең үзе, аяк-куллары югаламы?

“Фатыйма абыстай бердәнбер баласы Мансурның хәбәрсез *югалуы* турында кәгазь килгән көнне генә башын капкасына бәрә-бәрә елады да күрше-куланга бүтән күз яше күрсәтмәде, шыңшымады. Үзләре дә йә тормыш иптәшен, йә бердәнбер баласын югалткан күршеләреннән жәлләтәсе, кызгандырасы килми иде”.

“Зур сугышларда күп *кешеләрен югалткан,* арыган, талчыккан кызыллар отряды...”.

Берлек сан – үзе күплек

“Билет кассасы янында, Искәндәрләр яшь*ләр*ендә булыр*лар*, өч малай бутала”.

“Бу кызыйның күзләре шулкадәр зур*лар*, шулкадәр зәңгәрләр”.

“Җәйге каникул*лар* башланган чор иде”.

“Клумба яныннан әле өскә, әле аска таба туктаусыз кеше үтеп бара” (*А. Хәсәнов).* “Кеше” – күп. Бу җөмләдә ул ике яктан да оформлениеле: “туктаусыз” һәм “үтеп бара” – икесе дә дәвамлы мәгънә белән күп кешене күз алдында тота.

Ике мәгънәле сүзләр

“Төрле-төрле радиоалгычлар җыю белән Искәндәр үзе дә күптәннән бирле мавыга инде”. Монда “ясау” кирәк иде. “Җыю” – кешедән җыю.

-да/-дә кушымчалары

“Өчле” дә “дүртле” куеп чыктылар”. Димәк, -да/-дә кушымчасы “һәм”не фигыльдән башка сүз төркемнәрендә генә алыштыра. Мәсәлән, “Мин дә син”.

“Шулай диде дә Сәлихҗан абзый тынып калды”. Моны ике төрле укып була: 1) “Шулай диде дә, Сәлихҗан абзый тынып калды”; 2) “Шулай диде дә Сәлихҗан абзый, тынып калды”.

“Бар, тизрәк Усыга кайт та әтрәк алып кил” дигәнне, өтер булмау сәбәпле, ике тарафка да каратырга була. Димәк, телдәге инверсияне дә онытырга ярамый икән.

Иске сүз һәм тәгъбирләр

Ә. Еникине укыганда теркәлгән: “Алай димәгез, Салих әфәнде! Сезнең дәресләрегез минем өчен дә кызыклы, бик *мәмнүн* булып тыңлап утырам”.

“Сездән мактау сүзе ишетү безнең өчен зур *шәрәф* ул”; “*Кабилияте* бар...”.

Б. Урманчены укыганда: “Чөнки сынлы сәнгатька булган *һәвәсем* генә әле миңа бу төр сәнгатькә юл ачмый иде”; “Мин бик мавыгып *нәкыш*, скульптура өйрәнүгә керештем”.

Аһәң, музыкальлек

“Шул кыз белән иркенләбрәк бер сөйләшеп, сөйләшергә җае чыкмаса, ичмасам, күреп кенә китәргә иде Миңнулланың исәбе”. “Чыкмаса, ичмаса” – рифмадаш авазлардан ясалып, тавтология хасил иткән.

“Әгәр Гата атларны туктата калса...” “Т”лар кабатлана.

“Аның изге ният белән йөрүен кайдан белсен алар?” “Н”нар аллитерациясе.

Персонаж теле

“...Кәмитет беднота персидателе Хәкимҗанны үз кулы белән атып үтерде”; “Так чту менә шулай, агайне”; “Патамушты... өч солдат саклап тора”; “Мине дә прусты кызык итеп...” Бу 1918 ел. Авылның бер крестьяны. Рус сүзен шулкадәр сибәргә тиеш микән?

Шаблон сүз һәм тәгъбирләр

“...Авторучкасының башын суыра-суыра, нәрсә турындадыр уйланырга кереште”.

“Ирек нәүмиз, ач-ялангыч булмасын дип, көнен төнгә ялгап тырышты”.

“...Әнисенә ул Бурятиядә чакта хуҗалыкны ничек алып барырга кирәклеге турында соңгы күрсәтмәләрне бирергә кереште”.

Калькалар

“– Әсирләрне коткара алдыгызмы соң?

– *Ничек кенә* коткардык әле!”
“...*Зур саклык белән* кулындагы төргәкне сүтәргә кереште...”.

Изафә кушымчасы юк

“Тик берсе бик яшь әле, ә икенчесе – олырак. Бик яшенең... (дип монысы дөрес китә, шуннан). Ә олыракның чәче дә...”. “Ә олырагының...” кирәк.

“Минем”нең вазыйфасы

“Гаеп итмәгез, бик тә шуны беләсем килә минем!”

“Ә авазлардан гамма хасил була, ди Салих... минем Салих абыем...”.

“Җаным тыныч түгел, җаныма нидер кирәк минем...”.

Вакытны белдергән “-ны”, “-да” кушымчалары

“Көзгә кадәр ул бу елны никтер бик тиз, күзгә күренеп буйга үсте”. “Бер көнне кичкә табан караңгы булып болыт килде, көчле яңгыр яуды”. Соңгы мисалдагы “бер көнне” дигәнне “бер көндә” дип үзгәртеп буламы? Була. Ләкин ул чакны “бер көндә” “бер көн эчендә”, ягъни көн буена сузылган вакытны аңлатыр иде. Ә менә “бу елны” дигәнне “елда” дип үзгәртсәң, ул чакны ничек була? Мәгънәләрендә бер-бер үзгәреш килеп чыгамы? “Бу елны”, “бу елда”? Ә “бу ел – быел”? Чагыштыру өчен:

“Быел безгә килә аласыңмы?”

“Бу елны безгә килә аласыңмы?

“Бу елда безгә килә аласыңмы?”

“Көннәрдән бер көнне, юк кына нәрсә өчен хуҗасы белән әрләшеп, ашханәгә күчте”. Моны инде “көннәрдән бер көндә” дип әйтеп булмый.

Тыныш билгеләренә карата

“Инде үлем хәвефле булмагач, әлбәттә, барам”. “Әлбәттә” дигән ярдәмче сүзнең кайсы төп сүзгә каравына карап, җөмләнең мәгънәсе үзгәрә. Бу мисалда “әлбәттә” “булмагач” сүзеннән аңлашылган мәгънәне тәгаен итә, шуны раслый, ышанычлы ясый, бик нык конкретлаштыра. Инде “әлбәттә”не “барам” ягына күчерсәк, мәгънә төсмере бөтенләй үзгәрә: “барам” дигәнгә басым күчә – “барам” дигән сүздән аңлашылган мәгънә көчәеп, бармый калуны тәмам юкка чыгара.

Образлы сүзләр көче

“Никах мәҗлесеннән соң бер атна узуга, Хәнифә ерак чишмәгә суга барган җиреннән чәчен-башын туздырып, елап кайтып керде, баскыч төбендә үк көянтәсен ыргытып: “Суга бармыйм бүтән!” – диде” *(Г. Ахунов).* Монда без образ дип йөрткән чагыштырулар да юк, ләкин контекстында күз алдына килә торган образ бар. Эчке образ. Кеше халәтен тышкы хәрәкәтләр белән биргән.

“Арыш арасындагы бодай кебек, бер-ике ир-ат та бар. Болары – кичәге фронтовиклар. Алар җитди, кырыс... Куллар шинель кесәсендә. Һәр шинельдә кесә бар. Һәр кесәдә кул гына юк” *(А. Гыйләҗев).*

ҮЗЕБЕЗ ТАБЫП АЧКАН СЕРЛӘР

(Чаллы төбәге иҗатчылары тәҗрибәсенә бер күзәтү)

Гомер буе оста язучыларны эзләдем, аларның тел осталыгы серләрен ачарга омтылдым. Гомеремне журналист, язучы эшенә биргән кеше булганга, мондый мавыгуым табигыйдер, берәүне дә аптыратмыйдыр. Тик бу бер дә җиңел эш түгел икән. Беренчедән, һәр иҗатчының язарга өйрәнү, “сабак алу” юл-алымнары төрлечә, бик тә үзенчә. Икенчедән, әдипләр үзләре тәҗрибә “бүлешергә” юмарт түгел. Бу хакта махсус әсәр язган авторлар бик тә сирәк.

Нишләргә соң? Аларның осталык сандыгын ничек ачарга? Әдипләрнең тел куллану осталыгын өйрәнергә дип махсус максат куеп, бу юнәлештә төрледән-төрле күзәтүләр алып барсам да, башлыча төп ике чараны өстен күргәнмен икән. Беренчесе: үзем сокланып укыган, сиземләвемә караганда телебезне камил диярлек белгән, аны бөтен нечкәлеге белән куллана алган әдипнең, әлбәттә инде, үз тәҗрибәсен уртаклашкан, осталык серләрен үзе ачарга омтылган, чын сабак алырдай язмаларын табып уку. Гомәр Бәширев, Хәсән Сарьянның татар телен куллану мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрен ничәләр мәртәбә генә укымаганмындыр. Күбрәк булсын иде дә бит шундый “осталыкның өстәл дәреслекләре”, юк шул, алар, әйткәнебезчә, санаулы гына.

Икенчесе, ул – осталык сабагының иң үтемлесе, иң тәэсирлесе, үзең сокланган, тәэсир итү серен ачасың килгән әсәрнең үзен кат-кат укып, анализлау, төпченү, авторның тәэсир төенен үзең чишү, әдипнең осталык серенә ачкычны үзең табу.

Шулай да осталык мәсьәләсенә караган бу язмага алынуымның сәбәбе шәхсән үземне иҗади канәгатьләндерү максатыннан бигрәк (монысы да кирәк), язу остасын эзләп табып, аның серен ачуны бүтәннәргә дә җиткерү. Хәзер бу эш хезмәт вазыйфама да карый: ярты гасырдан озаграк инде Казан дәүләт университетының татар журналистикасы бүлегендә студент-журналистларны иҗатта татар телен куллану осталыгына өйрәтәм; фәнни эзләнүләремнең дә кыйбласы, башлыча, шул.

Монда да әдипнең (беренче чиратта публицистның) осталык дәресләрен үзләштерү методикасы ике юнәлештән гыйбарәт: аерым әдипләрнең осталыгын студентларга махсус программа, дәреслек, кулланмаларга таянып, лекция, семинарларда, редакцияләрдә остазларның үзләре кул астында эшләтеп, ана теле белән эш итү нечкәлекләрен төшендерү, шул белемне иҗади күнегүләр белән беркетү. Икенче төп юнәлеш-алым – ул, әлеге дә баягы, студентның үзе мөкиббән киткән остазының иҗат җимешләрен үзенең тәм табып укуы, укыганнарын үзе анализлап, үзе нәтиҗәләр ясавы.

Нәүбәттәге язмабыз да нәкъ менә яшь иҗатчыларның өлкәннәрнең осталык серләрен үз көче белән фәнни нигездә ничек ачуларын күрсәтергә омтыла.

Әйттем бит: осталык дип аталган олуг хәзинәне табу, туплау, өйрәнү һәм куллануның йөзләрчә алым, юллары бар. Шуларның берсен без Чаллыда таптык. Казан дәүләт университетының Чаллы филиалында татар журналистикасы бүлеге ачылган иде. Ел саен иҗатка омтылган дистәгә якын студент кабул ителә. Аларга беренче көннәрдән үк иҗат белән чын-чыннан кызыксыну өчен шартлар тудырыла. Татар теле – төп эш коралым, дигән иманга килеп, аның белән эш итүгә җитди тотынган яшьләргә төрле махсус курслар тәкъдим ителә. Мәсәлән, “Очерк” курсын үткәндә өлкән курстагыларга чын-чыннан иҗади мохит тудырыла – студентлар үзләре үк осталык дәресләрен төрләндерүгә, тирәнәйтүгә китерәчәк тәкъдимнәр әйтәләр.

Өйрәнү өчен остазларны барлаганда, кайсы студентның кайсы әдип иҗатын өйрәнәчәген тәгаенләгәндә аларның нәкъ менә Чаллы төбәге әдипләренең иҗаты белән төплерәк, якыннанрак кызыксынуы ачыкланды. Шуннан инде “ә нигә без программада каралган мәгълүм әдипләрнең иҗат остаханәсе белән генә чикләнәбез, мәктәп елларыннан ук таныш, хәтта үзләрен дә белеп-күреп үскән әдипләренең хезмәтләрен, иҗат үзенчәлекләрен анализламыйбыз?” дигән фикер кабынып китте.

Бу фикерне хуплау җиңел дә, шул ук вакытта шактый җаваплы да иде, чөнки программада каралган әдипләр турында инде фикерләр әйтелгән, хәтта моңарчыгы тикшеренүләргә таянып язылган фәнни хезмәтләр дә бар, ә без тәгаенләгән "җирле" әдипләр турында үзебезгә беренче булып бәя бирергә туры киләчәк бит.

Шундый башлангычларга яшь журналистлар да алынмагач, кем алынсын. Тәвәккәллибез! Аннары бит, аерым әдипнең осталык тәҗрибәсен бер студент ялгызы гына түгел, ә бөтен төркемебез белән, бергә-бергәләп тикшерәчәкбез. Димәк, күмәк җаваплылык.

Ниһаять, җентекле төзелгән планыбызга нигезләнеп без бер уку елында күренекле публицист һәм шагыйрь, нәфис сүз остасы Рахмай Хисмәтулланың иҗат остаханәсендә "яшәдек", аның иҗатының төрле якларын, беренче чиратта, ана теле белән эш итү ысул-юлларын нечкәләбрәк тикшерергә тырыштык; аерым-аерым темаларга рефератлар яклап, язгы сессия барышында шул рефератларны бөтен төркемебез катнашында, укытучылар алдында якладык.

Алай гынамы, шул рефератларга нигезләнгән фәнни-публицистик язма әзерләнде. Аны бу эшебезне башта ук хуплап, күзәтеп барган "Мәйдан" журналы бастырып та чыгарды (2004. № 10). Аңа җәмәгатьчелек гомумән уңай бәя бирде. Филиалның филология һәм журналистика бүлеге коллективының "Мәйдан" журналистлары белән очрашуында бу чара хуплауга лаек дип, аны дәвам иттерергә кирәк, дип табылды. Шул хуплаудан илһам алып һәм дә үзебезнең планга тугры калып, без икенче уку елында осталык тәҗрибәсе лабораториясен күренекле язучы-публицист һәм галим Эдуард Касыймов иҗатына багышладык. Хәзер шушы ике язманы тәкъдим итәбез.

Күкрәп килә инде безнең көннәр...

Кешеләргә акыл, хис бөртекләре өстәп кенә калмыйча, аларның үзләрен дә иҗатка илһамландыручы, омтылдыручы иҗат – ул, чын мәгънәсендә, җылы учактыр, җимешле агачтыр. Канатлы сүз-гыйбарәгә торырлык шушы нәтиҗәгә без Рахмай Хисмәтулла иҗатына, төгәлрәк алсак публицистикасына, тагын бер мәртәбә якынрак килеп, "җылынып", рухи ризыгын татып алгач килдек. Тик аңарчы әле...

Әдип иҗаты "лабораториясен" анализлауны без аның үзе белән очрашудан башларбыз, дип ниятләгән идек. Тик, ни кызганыч, курска керешкәнче үк әле остазыбыз вафат булып, без бу мавыктыргыч, кы-

зыклы ниятне гамәлгә ашырудан мәхрүм калдык. Кирәкле, тормышчан теләк-ният ул барыбер тиз генә искерми, барыбер үзенә ничектер юл таба – нәфис сүз осталыгына ирешүдә публицист Рахмай Хисмәтулла очеркистикасы мисалында өйрәнергә, үзләштерергә тиешбез, дигән ният-планнан без тайпылмаска булдык, курсны тулысынча аның публицистик иҗатына багышлыйбыз. Моңа төпле нигез-чыганак җитәрлек: публицистик иҗат хәзинәсе үзе генә дә дистәгә якын китап; матбугатта басылган язмалары, иҗтимагый чыгышлары, “Җидегән чишмә”гә бәйле риторик эшчәнлеге... Нинди мирас! Өйрәнер өчен әле берничә буынга җитәрлек.

Нәфис сүз осталыгының нигез ташларын очерк жанры мисалында күзаллау уңышлы. Рахмай Хисмәтулла – аның остасы. Алай гына да түгел, очеркны журналистиканың һәм матур әдәбиятнең башка жанрлары белән чагыштырып анализлаганда гына тулы аңлап була; бу яктан да Р. Хисмәтулла иҗаты – ифрат мул чыганак: ул гомере буе диярлек журналистиканың барлык жанрларын да “сөреп” чыкты: нәсер, хикәядән башлап, үзен повесть, романнарда сынады; ул эссе жанрын башлап җибәрүчеләрдән; ниһаять, шагыйрь буларак та танылды.

Иҗатның шушы төрләре арасыннан аның очеркка мөнәсәбәтенә аерым тукталу бик әһәмиятле. Чөнки нәфис сүз осталыгына ирешү мәсьәләсенә килгәндә, очерк тел белән эш итүдә, сөйләм оештыру осталыгына ирешүдә иң үзенчәлекле жанр санала. Гомумән дә, журналистика иҗатының үзенчәлекләре аның төп үзәге саналган документаль чынбарлык – фактка мөнәсәбәттә чагыла. Факт ул иҗат алымының этәргече буларак, вакыйга, проблема булып күзаллана. Журналистиканың хәбәри жанрлары (репортаж, интервью, хисап, хат-хәбәр һ.б.) фактны, ягъни вакыйга, проблеманы хәбәр итә; аналитик жанр (мөхбирнамә, мәкаләләр, күзәтү һ.б.) аларны анализлый, ягъни проблема биредә куела, ачып бирелә, хәл итү мәсьәләсе куертыла, ә менә әдәби-публицистик жанрлар (тасвирнамә, парча, эссе, очерк һ.б.) проблеманы ачып куеп, юлларын билгеләп кенә калмый, аларның чишелешен, тормышта хәл ителүен тасвирлый. Әйе, әйе, тege-бу проблеманың ничек-ничек чишелешен барлык укучы да ачык күрсен, аны үзендә дә гамәлгә ашырырга үрнәк алсын өчен, бөтен нечкәлеге, тулылыгы белән тасвирлап бирергә кирәк.

Тик “тиеш” дип әйтүе генә җиңел, моңа ирешү, ай-һай ла, бер дә җиңел түгел. Иң башта, әлеге дә баягы, шул очеркның асылына төшенеп бетмәү комачаулый. Әле әдәбият, журналистика нәзәриясендә хикәя, повесть, роман нәрсә ул, яисә репортаж, интер-

вью, мәкалә нәрсә ул кебек төшенчә-терминнар шактый ачык күзалланса да, очерк жанры шактый томанлы, үзләштерү-өйрәнү өчен катлаулы кебек тоела. Дәреслек, кулланмалар да моңарчы ачыклык кертеп бетерә алмады. Әйтик, журналистика фәнендә жанрларның ике төре (хәбәри, аналитик) бер сүзле атама белән, ә менә өченчесе – әдәби-публицистик – “ике җәпле” атама белән тәгаенләнгән: әдәби-публицистик, дип. Башваткыч бит: әдәби жанрмы, әллә публицистикмы? Әдәби ул уйлап чыгарылган образ, вакыйгалар белән эш итә, ә публицистика чын тормышка, документальлеккә нигезләнә.

Тагын да әһәмиятлерәге, очеркта теләсә нинди мәсьәлә куела алмый, тормышчан әһәмияте, иҗтимагыйлыгы ягыннан ул иң өлгереп җиткән, иң халыкчан, иң дәрәҗәле булырга тиеш. Кайсы проблема шундый санала? Аның чишелеше нидән гыйбарәт? Бу чишелеш барлык укучыны да дулкынланырга, уйланырга, хәрәкәткә омтылдырырга сәләтле тасвирлау нидән гыйбарәт? Менә бит күпме сорау! Монда инде без аларга Рахмай Хисмәтулланың осталык мәктәбе тулы җавап бирер дип ышанабыз.

Аның үзенең исеме үк шагыйрәнә аһәңле, саф татарча – көйле, моңлы иде. Рахмай. Рәхмәтулла. Уйлый калсаң, бөтен холкы-табигате, бөтен яшәеше дә җисеменә туры килгән булган икән: җаны-күңеле белән шагыйрь, акылы белән татар фикерле, аек журналист-публицист иде ул.

Берникадәр кызганыч та ки, бу кыска язмада без аның менә шушы журналистлык, публицистлык хәсиятенә генә җәелебрәк туктала алырбыз. Публицистика төшенчәсе күңел, вөждан иреге белән бәйле, публицистик иҗат ул менә шул ирек өчен көрәш, иҗатта кыюлыкка бару сыйфатлары чагылу дигәнне аңлата. Публицистик рух иҗатта төрлечә чагылыш таба: берәүләр иҗтимагый рухлы шигырьләр яза, икенчеләрнең проза әсәрләре көчле публицистика белән сугарылган була, өченчеләр турыдан-туры саф публицистик жанрларда иҗат итүгә гомере буена тугры кала.

Җитмешенче-сиксәненче елларда совет хакимияте чорында да шәхес культы томанасыннан ычкынып киткән, бездә демократия бөреләре тернәкләнә башлаган бер чор булып алган иде. Шул елларда татар иҗтимагый хәрәкәтендә, әдәби иҗат рухында да публицистика үзен күрсәтергә тотынды. Язучылар берлегендә үзенә аерым очеркчылар секциясе эшли башлады. Ул нәкъ менә шушы рухта язучы иҗатчыларны берләштереп, аларны Язучылар союзына да шул секция тәкъдим итә иде. Ул елларда Союзга алынган язучылар арасыннан

Марсель Зарипов, Кояш Тимбикова, Рахмай Хисмәтуллин (шул җөмләдән шәхсән үзем дә) кебек каләм ияләре нәкъ менә җитлеккән публицист-очеркчы буларак кабул ителде.

Димәк, Рахмай Хисмәтулла очерк остасы буларак инде күптән танылган. Чын иҗатчылар яхшы белә: мондый бәягә теләсә кайсы язучы ия була алмый – элекке язучыларыбыздан да, бүгенгеләрдән дә мондый кыйблада иҗат итүчеләр сирәктер. Шулай булгач, аның иҗат тәҗрибәсен өйрәнү мәктәбе дип сайлап алуыбыз ялгыш түгелдер. Керешик соң шул мәктәптә сабак алырга.

Очеркның үзәгендә – иҗтимагый проблеманың чишелеше, дигән идек. Очерк өчен проблема – ул аерым кешеләрне, хәтта аерым төркем, авыл, шәһәрләрне генә борчыган мәсьәлә түгел, бөтен республика, төбәкне, бөтен милләтне, халыкны борчыган, хәл ителүе чыннан да бөтен халык өчен икътыйсадый, мәдәни, тәрбияви вакыйга булырлык мәсьәлә куелуы.

Рахмай Хисмәтулла беркайчан да проблема эзләп матавыкланмады. Ул чын мәгънәсендә тормышны, республикасын, милләтен яраткан, өмет, оптимизм рухында яшәүче шәхес иде. Аһ-зарлар белән вакланмады. Гомере буе аны хезмәт кешесе, хезмәтнең дә иҗтимагый кирәкле өлкәләре кызыксындырды. Аларны да читтән күзәтүче, алар турында гомуми фикер йөртүче түгел, ә бәлки шул өлкәдә, шул кешеләр белән бергә, үз көчен, илһамын шуларныкына кушудан, күмәклек нәтиҗәсе-җимешеннән тәм, кодрәт ала белүче иде. Үзе күбрәк Түбән Камада, Чаллыда яшәп иҗат итсә дә, ул бөтен республиканы, бөтен халыкны кызыксындырган, дулкынландырган хезмәт урыннарында, кайнар төзелешләрдә турыдан-туры эшләргә омтылды – Казанның органик синтез заводы төзелешендә бетончы, Түбән Кама нефть-химия комбинаты төзелешендә икътыйсадчы, инженер һәм башка төрле вазыйфаларда хезмәт итте. Инде чын хезмәтнең ачысын да, төчесен дә үз җилкәсендә, үз кулларына кабарып чыккан сөялләрдән татыгач, бүтән төр хезмәт ияләренең, башка төбәкләрнең иҗтимагый хәлләрен, проблемаларын җентекле өйрәнү өчен күбрәк кеше белән аралашу, әһәмиятле вакыйга, проблемаларның эчендә кайнау мөмкинлекләрен, чараларын эзләп таба иде – башта Түбән Каманың зур эшханәләрендә, җәмәгать оешмаларында, мәдәни үзәкләрдә, күптиражлы газетта, аннары шушы төбәктә “Социалистик Татарстан” газетының үзхәбәрчесе булып эшли, бихисап, оешма, эшханәләрдә, авыл, калаларда, төзелешләрдә катнашу мөмкинлеге ала.

Авторның менә мондый тормыш тәҗрибәсенең очеркларының үзәге – проблемага – ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгән булуын студентыбыз **Миләүшә Мөлекованың** күзәтүләреннән ачык тоемларга була. “Рахмай Хисмәтуллин бер-бер артлы чыгып торган очерк китапларында (“Салават күпере”, “Күкрәү авазлары”, “Үземне таптым”, “Сусау” һ.б.) төрледән-төрле темаларга туктала. Аның каһарманнары – төрле һөнәр кешеләре: эшче яшьләр, техник, инженерлар, галим, врачлар, партия ветераннары, колхозчылар, сәнгать вәкилләре һ.б.

Тема әсәрдә чагылган тормыш даирәсен билгеләсә, проблема исә авторның шул өлкәгә мөнәсәбәтен аңлата. Проблема күтәрү – мәгълүм бер иҗтимагый каршылыкны чишәргә алыну. Әдип кайбер хәлләрнең тормыш закончалыклары белән ярашмавын күрә, күпләрне дулкынландырган, аларның күңелендә йөргән, ләкин әле томанлы гына төсмерләнгән, анык сурәткә кермәгән әһәмиятле конфликтны тормышның башка катлаулы күренешләре арасыннан аралап ала, аны алгы планга куя, аңа җәмәгать игътибарын юнәлтә.

Боларны “Сусау” җыентыгына тупланган очерклар мисалында күзаллап карыйк (*Хисмәтуллин Р.* Сусау: хикәяләр һәм очерклар: кереш сүз авторы С. Маннапов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 189 б.). “Үземне таптым” очеркында автор хезмәт сөюне беренче планга куя. Шулай да кеше берүзе генә берни эшли алмый. Бердәмлектә – көч, дип юкка гына әйтелми бит. Ә менә очерк персонажы Ярмәкнең төп ялгышы – бергә эшләүче иптәшләре алдында үзенә кимсенеп каравы. “Юкка шатланасың. Син барыбер элекке карак... Кызганып, юри генә юаталар...”.

Бүген аңарга шушы коллективта үз урынын табу мөһим. Бу, чыннан да, проблема. Аңарга гына да түгел. Иң әһәмиятлесе, автор аның чишелеше юлларын да күрсәтергә омтыла. Иң мөһиме – коллективта бер-беренә ихтирамлы, яхшы мөнәсәбәт булдыру. Ярмәк бик үк яхшы эшләмәсә дә, бригадир Әнәс Дәминев аны идарә җитәкчесенә әйбәт эшли дип әйтә. “Озак еллар буе җылы сүз ишетмәгән Ярмәккә бу “әйбәт”, “рәхмәт” сүзләре һич көтелмәгәнчә тәэсир итте. Бернигә исе китмәс кебек тоелган Ярмәкнең күңеленә әлләнинди бер җылы тамчы төште дә, ул зурайганнан-зурайды, якты куанычка әверелде. Ул да кеше, аны да мактыйлар. Ул да алар кебек, бер дә ким түгел (Сусау. 12–17 б.).

Бу вакыйга Ярмәккә тормышка бүтәнчә карарга, яңадан чын кеше булып туарга ярдәм итә. Ярмәк үз эшенә хәтта сокланып, рәхәтләнеп эшли башлый. Разрядын да күтәрәләр.

“Алтын бөртек” очеркы Түбән Кама шәһәрендә аппаратчы булып эшләүче Зәлифә Шәймәрдәнева турында. Бик уңган, тыйнак, акыллы кыз. Эше бик авыр булса да, яраткан шөгыле бар – сәхнә белән дә мавыга, үзешчән театрга йөри. Ләкин бергә эшләүче иптәшләре аны аңламый. “И Зәлифә, кемнәргә кирәк соң синең ул театрда уйнауларың? Йә кемнәргә? Кем соң синең кадереңне белеп, “карагыз әле, Шәймәрдәнева театрда уйный икән бит, әйдәгез әле бер-ике смена аның өчен эшкә калыйк!” дип кем сикереп төшә, җаныкаем!”. “Ничек кенә аңлатыйм соң: сәхнәгә басып, йөрәктән чыккан бөтен кайгы-сагышларыңны, уй-фикерләреңне кешеләргә җиткерү иң зур шатлык, тормыш яме бит ул”, – дип өзгәләнә Зәлифә.

Бу очеркта проблема – кешеләрнең сәнгатькә битараф булулары. Алар күбрәк эш, акча дип яши. Ә Зәлифәнең аларның “киңәшләрен” тыңлаганда йөрәге өзелеп төшәрдәй булып ярсый, тыпырчына. “Нигә бу аның танышлары баюны-малны дөньядагы иң гүзәл әйбердән – сәнгатьтән – өстен куялар икән?! Булмас эш бит, буш сүз бит ул” (Сусау, 174–188 б.).

Зәлифә, бернигә дә карамастан, театрга йөрүен дәвам иттерә. Техника йортында халык театры үзенең ун еллыгына багышлап бер-бер артлы спектакльләр куя. Алтысында да иң авыр, җаваплы рольләрне бер кеше – Зәлифә уйный. Зәлифә бу спектакльләргә бергә эшләүче иптәшләренә дә беренче мәртәбә чакыру билеты өләшкән була. Соңыннан алар җыелышып сәхнә артына менә. Кочаклый-кочаклый үзен котлыйлар.

Зәлифәнең сәхнәгә тугры калуы, тырышлыгы, бергә эшләгән иптәшләренә ачу сакламавы бу проблеманың чишелешенә китерә дә.

“Олы кеше – солы кеше” очеркын автор проблеманы турыдан-туры тасвирлаудан башлый. Зариф бабай малаеның дүрт бүлмәле квартирында картлык көннәрен уздыра. Автор бабай белән сөйләшергә килгән. Ләкин аны якты йөз белән каршы алмыйлар. Килене шунда ук кырт борылып, кухняга кереп китә. Квартир күз явын алырлык шәп мебель белән җиһазландырылган. Ләкин улы әтисен иске киемнәр саклый торган караңгы бүлмәдән алып чыга. Аңарга урын шунда, сандыгы өстенә көйләнгән икән.

Зариф бабайның авылдагы зур йортын сатканнар икән. Аннары, карт Ватан сугышы инвалиды буларак, квартир алганда да боларга бик ярап куйган. Бабай хөрмәтенә бирелгән кыйммәтле гаражга да хуҗа булганнар. Килен белән улы эшкә киткәч, балаларын да карый икән.

Автор ялгыз калган ташландык картлар, аларның вөҗдансыз балалары проблемасын күтәрә. Чишү юллары турында да җитди уйлана. Нәтиҗәсе дә ачык һәм катгый: "Баланың үзенә, балаларның балаларына да кирәк... картлар янәшәлеге. Аксакал картлар – алар әле бер китапта да ахырына кадәр бәя биреп бетерелмәгән акыл, киңәштабыш чыганаклары". "Үкенечләрне тормыш ахырына калдырмыйк. Үзебезгә матур, якты картлык теләсәк, моңсулыкта гомер кичереп, сүнеп барган әби-бабайларыбызны, мәңгедән килгән гореф-гадәтләребез кушканча зур хөрмәт белән гаилә түрләребезгә уздырыйк, квартирларыбыз түрендәге телевизор һәм затлы мебель алып торган хөрмәтле урыннарны якты чырайлы әби-бабайлар биләсен" (Сусау, 165–170 б.).

Сүзне **Илүзә Шәйхетдинева** дәвам иттерә. Ул публицистик иҗатта "тема һәм проблема" нисбәтен ачыклауның әһәмиятенә игътибар итә. Рахмай Хисмәтуллин ачыкларга омтылган, кузгаткан темалар шулкадәр күп һәм төрле ки ("Кыйбла җиле" китабында гына да егермедән күбрәк темага туктала), монда бер темага берничә проблема күтәрелү ихтималын да күздә тотканда, проблема өстенөстенлеге аның чишелешенә зарар китерү куркынычы юкмы? Әйтик, әхлак темасы гына да ничәме-ничә әһәмиятле проблеманы колачлый: кешелеклелек, ата-анага, олыларга, зәгыйфьләргә шәфкать, җир-суга, туган илгә хөрмәт...

Бүгенге проблемаларның күпчелеге, кагыйдә буларак, икътыйсад, социаль, әхлакый тәрбия темаларыннан килеп чыга. Кайсын гына чишәргә алынганда да аларга бердәйлектә (комплекслы) карау әһәмиятле. Бер-берсеннән аермыйча. Бу тормыш таләп иткән закончалык кына түгел, публицистик сәнгатьнең бер сыйфаты да. Рахмай Хисмәтуллин иҗаты аның бу закончалыкка тугрылыгын раслый.

Шулай да ул һәр проблемага, аның чишелешенә бик конкрет килә. Моны "Сезгә рәхмәт, акыллы кешеләр!" очеркында җентеклäбрәк күзәтик әле (шунда ук. 98–106 б.). Илдус Гафаровка – докторга – Валераның әти-әнисе ярдәм сорап мөрәҗәгать итә: бала акылдан чыга башлаган. Доктор җентекләп сораша, нинди сәбәпләр аркасында дип. Ата-ана дөресен әйтми. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә ачыклана: балага ашаганда берничә тамчы алкоголь тамыза торган булганнар. Шуның аркасында миенә зәгыйфьлек килгән.

Юк шул, бу аерым кеше проблемасы гына түгел, бу – алкоголизм, наркомания, экология хәле аркасында акылга зәгыйфь кешеләрнең күмәк проблемасы. Ул безнең көннәрдә дә актуаль. Ав-

тор бу казадан котылу юлларын эзли, укучыны да шуңа әйди. Ышандырырлык, үтемле фактлар, детальләр җыя, тикшеренү-эзләнү процессы алып бара, төрле диагнозларны җентекләп тикшерә. Бер шәхси проблеманың иҗтимагый мәсьәләгә әйләнүен исбатлый.

Очеркта проблема үзмаксат түгел. Төп максат – проблеманың чишелешен тасвирлау. Рахмай Хисмәтуллин язмаларының очерк дип танылуы да – аның адәм баласын борчыган проблеманың чишелешен күрсәтергә-тасвирларга омтылуы. Дөресен әйткәндә, бөтен яшәвенең максаты да шушы бит.

Беләбез, шундый максат белән яшәгән иҗатчыга совет чорында гомер итүләре, ай-һай, җиңелдән түгел иде. Проблема кую – үзе зур батырлык иде. Ә чишелеше белән төпчену үзенә күрә "әхлаксызлык" иде. Шулай да публицист Хисмәтуллин халыкны борчыган кимчелекне ачып салудан курыкмады, урынында ярып салды, ә урынында сүз арасында, кыстырып кына булса да белгертә, күрсәтеп китә иде: "Кемнәрнеңдер төзү материалларын харап итеп эшләүләрен дә, эшкә салкын карауларын да – барчасын да шушы хатын-кызлар җилкәсе күтәрә. Әйтик, агач материаллар заводтан буялган килеш алынырга тиеш. Юк бит, аны шушы ук хатыннар буйый. Аларга әлифтә эретелгән майлы буяу бирелергә тиеш тә бит, юк шул. Аның урынына очсызлы эмульсия генә. Шунлыктан норма буенча ике тапкыр гына буйыйсыны өч тапкыр буятып, эшне авырайттылар, ә түләү барыбер ике кат буягандагыча гына кала килә..." (шунда ук. 113 б.).

Проблеманы куеп кына калмыйча, моның белән генә тынычланмыйча, ә бәлки бөтен көчен аны гамәлгә ашыруга куйган әдипнең вакыт-вакыт кимчелекләргә күз йомарга мәҗбүр булуы, чынлыктагы аерым гына күренешне гомумиләштереп күрсәтүе дә теләгәнне тизрәк күрергә омтылуыннан дип аңларга кирәктер.

Әдипнең менә мондый тирән, фәлсәфи фикер-нәтиҗәләре яктысында алар "тоныкланып" калмый мыни! "Ветераннар яшь буынга караганда ипинең кадерен, хезмәтнең тәмен ныграк беләләр, үз тәҗрибәләрен оныклары белән бүлешергә бик телиләр. Ләкин аларның күпчелеге оныклардан аерым тора яисә торырга мәҗбүр. Менә бу оныклар, үскәч, әби-бабалы кешеләрдән көнләшмәсләр, балаларын әби-бабайлардан аерган ата-аналарын гаепләмәсләр, дип кем гарантия бирә ала?.." (шунда ук. 169 б.).

"Әйе, еллар үткән саен кеше табигатькә якыная. Аның һәр ташы, комы, үләне, аланы, кыры, сазы-урманы карап, күреп, йөреп туя алмаслык могҗизага әверелә бара" (шунда ук. 170 б.). Тәҗрибәле әдип менә

мондый хакыйкать-нәтиҗәләрне бәян итүнең төрле юлларын таба. Бер әсәрдә ул аларны күренекле, абруйлы фикердәшләре (М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев һ.б.) сүзе дип җиткерсә (Кыйбла җиле // Сусау. 41, 47 б.), икенче әсәрдә ул аны шушы проблеманы хәл итүне үз өстенә алган характер авызыннан бәян иттерә. Менә "Җидегән чишмә"нең чираттагы мәҗлесендә аны оештыручы, алып баручы әдибебез сүзне мәктәп директоры Әнвәр Шамовка бирә. Гәп ата-ана традициясен дәвам иттерү турында бара, аны бозу очраклары санала. "...Бездә хәзер татар ата-аналары балаларын туган тел дәресләренә, ата-бабаларның изге төсе булган татар теле дәресләренә йөртмичә дә бик зур хата ясыйлар. Туган телдә сөйләшә белмәү гореф-гадәтләребезне инкарь итүебез аркасында улы әтисен, кызы анасын аңламый. Нәтиҗәдә: күпме аерылулар, күпме ятим балалар, күз яшьләре, эчкечелек... Күпме асыл яшьләр, упкынга төшеп киткән кебек, бернинди эзсез юкка чыгалар, әрәм булалар..." (Кыйбла // Сусау. 22 б.).

Менә шушындый тормыштан алынган конкрет нәтиҗәләргә таянып, публицист бүген дә яшәү программасы булырга хаклы фәлсәфи нигезле йомгаклар ясауга ирешә: "Без тагы да мулрак тормышка омтылып, туган нигезләрдән, туган моңнардан, туган телләрдән, мең гасырлык тарихы булган гореф-гадәтләрдән бик җиңел мәхрүм калдык. Уйламадык та. Балаларыбызны җинаятьчел төстә шул рухи байлыктан аердык. Ата-бабаларга изге итеп карауны оныттык Аларның каберләренә таш куйдыру түгел, сукмакларны чүп үләннәр басып китте. Безне хәзер ата-ана, бала һәм дус бурычлары бугазлый. Ана балага дошман, бала – анага, дус-иш дус-ишне, туган туганны хәйләли, яман юлга этәрә. Аналар авылда авырып ята. Ә без шәһәрләрдә типтереп яшәп, түләүсез генә бәхеткә омтылабыз. Юк, алай бәхетле булып булмый" (Кыйбла. 31 б.).

Проблеманы хәл итәргә алынган кеше – ул чын мәгънәсендә характер; чын очеркчы буларак, Рахмай Хисмәтуллин яхшы үзләштергән, үз тәҗрибәсендә инанган: проблеманы бары кеше генә, анда да эшеннән тәм табып, аның максатчан, нәтиҗәле булуын үзе һәрдаим кайгыртып торган хезмәт кешесе хәл итә ала. Һәр очеркында аның менә шушындый кеше-характер күз алдына килеп баса. Авторның бөтен теләге, тырышлыгы шул характерны укучы да бөтен күңеле белән аңласын, җентекле хәтерләп калсын! Шунсыз ул аңардан үрнәк ала алмас, аңа иярү, аны кабатлау теләге тумас.

Характерны күз алдына китерерлек, истә калдырырлык итү өчен автор ниләр кыла? Бу хакта студентыбыз, Түбән Кама кызы **Айгөл**

Габдрахманова фикерләре кызыклы. “Характерны күз алдына китерү гап-гади фактлардан башлана, геройны мактап, гомуми сүзләр тезүдән түгел. “Яңа төзелеп яткан йортның бүлмәләрендә язгы кояш нурлары уйнаклый. Шаян сөйләшүләр, измә, буяу сорап дәшүләр яңгырап тора. Кайнар һава өрдерүче калориферлар гүли”. Димәк, автор героен нәкъ менә шушында – төзелеш барган җирдә тасвирлаячак, димәк, бу герой төзүчедер. “Анна апа туе” очеркын укый башлагач та, укучыга шундый уй килә. Һәм ул ялгышмый. Язучы героеның эш урынын шулай яратып тасвирлый икән, димәк, каһарманы да күңелендә шундый ук олы хисле зат булырга тиеш, дип уйлап куясың. “Тирә-юнь хезмәт кенә тудыра ала торган күңелле ашкыну, яшәүнең татлы өметләре белән өртелгән”, дип яза әдип. Алдымда берсеннән-берсе җитез төзүчеләр. Шәһәрне иң беренче башлап күтәрүчеләр. Ике-өч бала аналары...”. Әнә шулай, деталь, фактлар ярдәмендә язучы укучысын акрынлап-акрынлап, баскыч өсте баскыч менеп, әсәренә, герое язмышына алып кереп китә.

Гомумән, деталь, фактның, публицистикага караган нинди генә жанрны алма, һәркайсында әһәмияте зур. Журналист әсәре нәкъ менә фактка нигезләнеп языла бит. Бер карашка әлләни әһәмияте булмаган кебек тоелган кечкенә генә факт та публицист әсәрендә характерны тасвирлауда мөһим урын тота. Әнә бит: буяучы хатыннар, араларыннан берсе турында очерк язарга теләүләрен ишеткәч, бертавыштан: “Безне түгел, әнә Анна апаны язарга кирәк, шуны гына”, диюләре дә хезмәттәшләре алдында Аннаның абруе ни дәрәҗәдә зур булуын сөйли.

Очеркта характерны тасвирлау өчен факт кына җитми, проблемага мөнәсәбәттә генә ул тулысынча ачыла, күренә ала. Аннага да “авыр иде авылда яшәве. Әтисе колхозга керергә теләмәде. Налог өстенә налог салынды. Тәмам бөлделәр. Ата-ана ни сөйләсә, шуны дөреслек дип кабул иткән кызга бу хәл рәхимсезлек, гаделсезлек булып тоелды...”. Болар барысы да уналты яшьлек кызның, туган нигезен калдырып, бәхет эстәп читкә чыгып китүенә сәбәп була. Нинди генә проблемалар китереп куясы бар иде әле аңарга язмыш дигәнең. Кайларда гына булмый Анна: Уралы, Себере калмый. Кайда нужа, авыр хезмәт – Анна шунда булыр. Өйдән чыгып киткәндә, әтисенең: “...Акчадан башка беркемгә дә ышанма, байлык иманың булсын”, дигән сүзләрен күңеленә беркеткән булса да, тормыш аңа бүтән хакыйкатьләрне дә инандыра: бәхет үзеңнең тырыш хезмәтеңнән тора, хезмәттәшләреңә дә таянырга була. Аннаның өй туенда автор шул хакта уйлана. Анна белән атасы арасындагы каршылыкны ата белән

кыз арасында булган каршылык, аңлашылмаучылык дип кенә түгел, бәлки ике буын арасындагы каршылык дип бәяләүгә килеп җитә.

Без әле публицистның характерны үтемле тасвирлау алымчараларына тәфсиллəбрәк тукталырбыз. Ә хәзергә аның бу юнәлештәге уңышының бер сәбәбен аерып алу кирәк дип саныйбыз. Вакыт-вакыт әдип теге-бу проблеманы чишү бурычына герое белән бергә үзе дә “җигелеп китә”, әсәренең характерына әверелә. Кай әсәрендә ул әлеге вазыйфаны тулысынча үз өстенә ала. Мәсәлән, күренекле шагыйрь, тарихи шәхес Нур Баянны “кайтару” проблемасын хәл итүгә үзе керешеп китә. Бөтен бер повесть буйлап (Казан утлары. 2000. № 4. 89–132 б.) без аның үзен күзәтәбез, аның белән бергә авыр юл үтәбез, хакыйкатьне бергәләп табарга омтылабыз.

Бу уңайдан публицист, җәмәгать эшлеклесе, шул ук вакытта гапгади бер ватандашыбыз, милләттәшебез Рахмайны әдәбипублицистик әсәр герое-характеры буларак күзәтү ифрат та кызыклы, әһәмиятле. Бу очракта ул, табигый ки, әсәрләрендәге башка характерларга да охшый бит, аның йөзендә бүтән геройларының сыйфатларын эзләү дә дөрес булырдыр. Бу әсәрдә дә характер бурыч-проблеманы бик конкрет куя: “Нур Баянның токымы өзелергә тиеш түгел. Түгел!” Менә шушы изге, иҗтимагый әһәмиятле бурычны үтәү өчен бөтен кешелек сәләтен, публицистлык осталыгын җигә, чын мәгънәсендә характерын күрсәтә. Укучы аны ихластан күзәтә; хәрәкәт, шөгыль, сыйфатларыннан үрнәк ала; аны уйлый.

Кем ул Рахмай Хисмәтуллин кеше, шәхес буларак? Студентыбыз **Роза Әхмәтсәлихева** бу сорауга менә нindиерәк җавап әзерләгән.

Гаяз Исхакый бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рахмай Хисмәтулланы республика әдәбият сөючеләре арасында белмәгән кеше юктыр. Ул Актаныш районы егете. Әнәк авылында 1934 елның 25 сентябрендә туган. Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Балтыйк диңгезендәге Кронштадт шәһәрендә хәрби училищеда укый, аннары, армиядән кайткач, Казан университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Аннары... күңелендә сандугач оялагач, нишлисең, дипломлы физикматематик Питрәч районына журналист булып газетка китә.

Журналист һәм язучы Рахмай Хисмәтулла эзләнүдән тукталмый; аны яңадан-яңа юллар дәшә. Казан, Түбән Кама, Чаллы төзелешләре... Яңадан-яңа хезмәт ияләре, яңа коллективлар белән танышу, аралашу. Ниһаять, башкаланы ташлап, Түбән Кама шәһәрендә төпләнү... Бу

шәһәр аның язмышында иң кадерле хәтирәләрдән берседер, мөгаен. Биредә ул эшче яшьләр кичке мәктәбендә укытучы, төзелештә инженер, республика газеты хәбәрчесе, халык театрында режиссер булып та эшли. Менә бу соңгы һөнәре аны “Җидегән чишмә” белән бәйләде дә. “Җидегән чишмә” берләшмәсе күп кенә язучы, артист, композитор, галимгә, гомумән, халыкның күренекле әһелләренә мәшһүр мөнбәргә әверелә. Монда аның публицистлык сәләте бөтен колачына ачылды, шуның белән халык абруен казанды. Чөнки ул үзе өчен генә түгел, халык өчен яшәде. Бер шигырендә ул үзе турында болай яза:

Ниләр булса да ил белән:
Тәмугым да, оҗмахым да.
Гафу ит, кайчак сөйләнсәк –
Хагын да, нахагын да.
Нинди вакытың булмасын
Син, илем – газиз Ватан.
Син миңа гомер-җан биргән,
Син анам һәм дә атам.

Рахмай Хисмәтулла 1989 елдан Чаллы шәһәрендә яшәде. 1992–1997 елларда Чаллы язучылар оешмасына җитәкчелек итте. Ул аз сөйләп, күп эшләргә тырышучы иде. Матурдан-матур хикәяләр, нәсер, шигырьләр авторы башта үзен әдәбиятнең иң оператив жанры – очерклар – язып танытты, аларны гомеренең соңгы көннәренәчә язды.

Бу булды әдип “мин”енең бер ягы – биографик, рәсми-мәгълүмәти ягы. Икенче “мин” ул, инде әйткәнебезчә, аның үз әсәрләренең герое-чагылышы. Иң башта әдип монда да “чын” үзеннән әлләни аерылмый: үзенең шәхси сыйфатларын героена “тагу”дан ул һич тарсынмый. “Иң яраткан шөгыльләремнең берсе булган кадак турайту минем рухымны сихерләп җибәрде. Тимер кисәкләрен юкка гына баш очына куеп йокларга киңәш итмиләр икән...”. “Мин үзем белгән, үзем күргән кешеләр турында язарга яратканлыктан, Габделбаянның бертуганы Гапсәләмне тасвир итеп, Нур Баян образын да күпмедер ача алырмындыр сыман...”; “Заманында мине Казаннан биредә борынгы тамырларым һәм фатирым булмау куаласа, икенчедән, аның эчкечеләр дөньясында харап булуымнан куркып, Түбән Кама кебек яшь шәһәргә китеп барган идем. Инде хәзер Казанга кире кайта алмыйча гомерем үтеп бара. Әмма барыбер мин әле бирегә кайтырмын сыман...” (Оныкларым // Сусау. 94, 96, 107 б.).

Игътибар итегез, “мин”дә ясалмалык юк, ул самими, ихласый, шуңа күрә характерны да укучы тиз аңлый, якын итә, үз күрә. “Трамвай кузгалып киткәч, тегеләрнең җыры тагын да көчәйде. Артистла-

нып түгел, ә тормышның үзе кузгаткан чын тойгылар белән тулышып, җырланмый кала алмаганга җырлана торган һәр җырны кайда гына ишетсәм дә, тукталып, исләрем китеп, йотылып тыңлап торам мин “ (Сусау. 172 б.). “Таныргa кирәк, дуслар, Казанның урыс газетлары теле, стиле, кыюлыгы, югары юморы, энергиясе, заманчалыгы белән татар газетларыннан күпкә өстен. Татар газеты һаман да тел, милләт тирәсендә казына, ләкин аны үзәкләргә үткәзерлек көчле итеп, давыл куптарырлык итеп күтәрә белми!” (Оныкларым. 107 б.).

Аның “мин”е вак түгел, ул үз тирәсендә, үз борчу-мәшәкатьләре белән генә бәргәләнми, аның “мин”е бүтәннәргә дә кагылган уй-борчулар бит... Сизәсездер, “мин” һәр очракта диярлек гомумиерәк тон ала, “без”гә якыная, бу фикерләр инде бөтенхалык мәнфәгате колачына якыная: “Ризыгым бар, ятагым чиста, бүлмәм җылы, ләкин күңелдә болыт, әллә нинди татар ятимлеге. Барысы да бик тиз уалырга, җимерелергә тора сыман. Бик мескен бит әле бу милләт дөньясы. Ирек килеп тә, без әле аңардан рәтләп җимешләр өзеп каба алмадык...” (Оныкларым. 109 б.).

“Мин”нең конкрет проблема турындагы уй-нәтиҗәләре (мәсәлән, Нур Баянны “кайтару” мәсьәләсе) тагын да колачлырак, бөтен халык мәнфәгатьләренә тоташкан мәсьәләләрне кузгатуга китерә: “Язучыларның архивлары төрле аерым кулларда... кайсы кайда чәчелеп-сибелеп яталар. Кайчан да булса татар аларны бер җиргә җыеп, бер рәткә сала алырмы? Шул архивларны һәм халыктан җыйган меңләгән сирәк кульязмаларны бергә туплап, әрмәннеке кебек үзенең Матенадаранын булдыра алырмы? Белмим... Моны, ахры, бары тик Президент указы гына хәл итә аладыр...” (Оныкларым. 110 б.).

Очерк “мин”енең мондый саллы гомумиләштерүгә, нәтиҗәләр ясарга сәләтле булуына мисалларны китергән идек инде. Янә берсен искә төшерү белән чикләник: “Әй, күп тә соң безнең горурлынырлык кешеләребез! Алар беркайчан да “мин мин” дип тормыш сәхнәсенә, күренекле урыннарга чәчрәп чыкмаслар. Күп вакыт алар басынкы, тыйнак, түземле. Алар тормышның ыбыр-чыбырын куәтле җилкәләре белән ярып, туктаусыз хезмәт мәйданында кала бирәләр. Без яшәгән шушы дөньяны нигезләрен ныклы итеп, мәңгелек итеп төзеп баралар” (Сусау. 128 б.).

Ниһаять, очеркта автор “мин”енең өченче яссылыгы турында берничә сүз. Очерк нәзәриясендә бу жанрда “мин” дип язу кирәкме, мәҗбүриме, дигән бәхәс тә куертылып алына. Бу сорауга без инде җавап бирдек кебек. Очерк кешеләрнең аерым сыйфатларын, таби-

гать күренешләрен бәян итү, сурәтләү белән генә чикләнми, персонажларының эш-гамәлләрен, уй-фикерләрен, үзара мөнәсәбәтләрен дә ачыклый. Автор дөреслекне, хакыйкатьне эзли, укучы белән, персонаж белән, хәтта ки үз-үзе белән бәхәскә керә, шуның белән укучыда мәсьәләгә, очеркка кызыксыну уята.

Болар – бәхәссез. Шул ук вакытта төрле автор үз “мин”ен төрлечә файдалана ала. Рахмай Хисмәтулланың төрле очеркларында “мин” төрлечә чагыла. Бу хакта менә **Алсу Корбанова** фикере мондый: “Мәсәлән, “Тәүбә” җыентыгыннан “Янартаулар кебек дулап...” очеркында Р. Хисмәтуллин туксанынчы еллар башында һәм, гомумән, татар әдәбиятендә язучыларны кысу, аларның мәхәббәтне, интим хисләрне белдерүне тыюлар турында шәхси үз фикерен яза. “Әйе, кызыл замана үзе бозык булса да, безгә бу турыда язарга рөхсәт ителмәде. Кызыл замана албастысы шагыйрьләрне никадәр генә печеп бетерергә тырышмасын, ул үзенең иң заманча шагыйрен дә ахыргача үтереп бетерә алмаган икән...”. Моңа мисал итеп автор 1993 елда “Казан утлары” журналында басылган Ренат Харисның “Өч үбешү” дигән эротик поэмасын китерә. “Минем бөтен аһ-зарларым артка чигеп, онытылып югалгандай булды. Гаҗәп бит, бу өметсез, котсыз заманда көтмәгәндә шушындый юллар яңгырасын әле! Беренче карашка кабинетный, кырыс тоелган, гел рәсмилектә йөргән шәхес шундый табигый рәхәт шигырьләр тоҗырсын әле! Чыннан да әкәмәт бит бу! Мин Ренат Хариска бик аптырап карап тордым...”.

Болар әдипнең үтә дә шәхси фикер, хисләре. “Дөресен әйткәндә, хатын-кызга карата җаным-бәгырем каткан чак иде. Аны хуплау сүзе әйтсәләр дә, җен ачуларым чыгып, пырдымсызланырга әзер идем...”.

Аерым мәсьәләләргә, күренекле шәхесләргә, вакыйгаларга карата менә шушылай үтә шәхси фикер әйтә алуы аны эссе тибындагы әсәрләр язарга да этәрде; ул татар эссеистикасына юл салучы беренче публицистлардан саналырга хаклы.

Автор “мине” “мин” сүзе белән белдерелмәскә дә мөмкин, “без”, “сез” дип, яисә бүтәнчә әйтелергә мөмкин. Мәсәлән, “Җидегән чишмә” очеркының “Рухи тирәнлекләр” бүлегендә автор үз фикерен, уй-кичерешләрен “мин” дип түгел, “без” дип, барлык милли җанлы татарлар исеменнән белдерә: “Менә ничә ел инде без миллилекне бозып аңлаттык, ул турыда сөйләшергә, авыз ачарга да куркып яшәдек...”.

Кайвакыт автор “мин”е бөтенләй арткы планга күчә. Ул вакыйганы читтән күзәтеп, укучыга хәбәр генә бирүче ролендә кала

кебек. “Татарның юлы бер генә” язмасында автор авыл егете Азатның каладагы тормышын сурәтли. Битараф кеше сыйфатында. “Җиденчене тәмамлап зур конкурс аша узып, Казан авиация техникумына кергәч, шәһәр саф күңелле авыл үсмерен ике яктан шатырдатып китереп кысты...”.

Шул ук вакытта без күренекле публицистның “мин”ен барыбер тоябыз – ул аның тонында да, бер сүзендә генә дә чагылып китә ала. Бу инде осталык билгесе. Хәер, бу инде аерым бүлекчә темасы.

Осталык мәсьәләсенә килгәндә, очеркта бит, башка жанрларга караганда, үзгәрәк таләпләр куела: ул проблеманың чишелешен, характерны тасвирларга, сурәтләргә тиеш. Тасвирлау өчен һәм публицистик, һәм әдәби чараларны куллану мөмкин. Менә шул ике яклы чараларны бергә үрә белү – очеркчының осталыгы санала да инде. Бу яктан Рахмай Хисмәтулла иҗаты – чын мәгънәсендә осталык мәктәбе. Бу үзенә бер фәнни өйрәнү-тикшеренү темасы. Бүген исә без әдипнең характерны тасвирлаганда кулланган кайбер публицистик һәм әдәби чараларга гына тукталып китәбез. Кайберләрен, аерым алганда факт, деталь кебек чараларны, тасвир чарасы буларак ничек кулллануын без инде берникадәр ачыклаган идек. Янә кайберләрен барлап карыйк.

Р. Хисмәтуллин – портрет остасы. Юк, кешенең йөзе-чыраен, тышкы кыяфәтен тасвирлау аңарга һич тә үзмаксат түгел. Моны ул нәкъ менә характер-геройның эчке хәләтен, рухи үзгәрешен, омтылыш-кичерешләрен тирәнрәк, төгәлрәк, тәэсирлерәк итеп тасвирлау өчен куллана. Менә “Мәтрүшкәләр” очеркында ике кешенең киеренке бер мәлдәге рухи хәләтен ачыграк күзаллау, хәтергә сеңдереп калдыру өчен ул аларның йөз-кыяфәтләренә дә диккатьне юнәлттерә. “Егет, аптырап, күзен шардай ачып, Сибгатовка текәлде. “Мин сөйлимен япун белән кытайны, син сөйлисең Сәхипҗамал түтәйне”, дигән мәгънә аңлаткандай, авызы ачылган килеш бер мизгел катып калды. Ә кабинет хуҗасы кай ягы беләндер тау ягы кешеләрен хәтерләткән озын кылыч борынлы, әмма татар җирендә күбрәк очрый торган яшькелт-соры күзле, куе кара кашлы кеше, бернинди борчулары юк сыман иренен бөреп, эче әйбер капкандай урт кырыйларын суырып куйды” (Сусау. 95 б.).

Әдип, чын сәнгатьчә фикерләүче, шагыйрь буларак, детальләргә бик игътибарлы. Портретны тасвирлы итү өчен ул аларны урынлы куллана: “Ярмәкнең нервыланудан уң яңагындагы җөй эзен каплатып үстергән бакенбардлары селкенгәләде” (Сусау. 130 б.).

Реаль кеше портретын бирү өчен аның тышкы кыяфәтен нечкә күзәтү генә җитми бит, чөнки портрет ул бу шәхеснең холыкфигылен дә, үткәнен дә, шушы ситуация, мөхиттәге әхвәлен дә яхшы белүне сорый. “...Сирәк кулъязмалар бүлеге хуҗасы, күптәнге танышым татарның асыл зыялысы Җәүдәт Миңнуллин мине хөрмәт белән каршы алды. Ул каты эшлидер инде, бераз ябыга төшкән, саргайганрак та димме, нечкә кысалы күзлекләре дә тартылып, ябыгып киткән шикелле” (Оныкларым. 108 б.).

Очеркчының портретка әһәмият бирүенә студентыбыз **Әлинә Идиятева** да игътибар иткән. “Олы кеше – солы кеше” очеркында автор бабай белән аның улының тышкы кыяфәтен тасвирлап бик күп нәрсә аңлатуга ирешкән. “Бабайдан, әлбәттә, “искелек” исе килә иде: иске киемнәр, аксыл-саргылт йөз... Ә малайдан яңалык “исе” аңкый: кып-кызыл таза чырай, тук караш һәм тамак астына салынган ”хушбуй исе”. Киленнең дә нинди кош икәнлеге кыяфәтеннән бик яхшы күренә: “И, Алла, баронессадай йөрергә тырышып кыланган хуҗабикәнең шуңа да сырты кабарды... Гаеп итәрләр дип уйлау кая, юка иреннәрен чат кысып, йөзен каралтып, усал итеп дәшүдән үзен чак тыеп тирәбездә йөренде”.

Ә менә “Ялгыз торна күле” очеркында бөтенләй бүтән характер; портреты да бөтенләй башкача. Очеркчы сугыш елларында тол калган Хәлимә апаның йөзендә андыйларның хәлен тасвирлый. Менә автор аның өендә кара-каршы сөйләшеп утыра. “Киттем шул инде фермадан, киттем шул,– диде ул, нәрсәгәдер үкенгән сыман. Ул бу сүзләрне әйткәндә, керфек очларында яшь тамчылары мөлдерәп тора кебек. Урта буй, озынча, матур нәфис йөз, коңгырт тыныч күзләр. Маңгаена, кашларына һаман да дөнья авырлыгы эленгән сыман. Өстендә бәби итәкле чип-чиста ак алъяпкыч, башында әллә нинди моңлы яулык. Муенында сары тонык гәрәбә төймәләр...”.

Беренче очракта социаль портрет булса, икенчесе психологик портрет үрнәге. Әдибебез һәр икесен оста куллана.

Очеркта пейзаж да – көчле тәэсир чарасы. Күп очракта безнең проблемалар табигать кыенлыкларыннан да аерылгысыз. Аннары кеше-характер үзе дә табигать баласы, аның эче-тышы дигәндәй, табигать хәлләренә, ел фасылларына карап та үзгәрә. Пейзажны кеше психологиясе белән тыгыз бәйли белеп, очеркчы характерны сурәтләү өчен стандарт булмаган, тапталмаган пейзаж элементларын таба ала.

Әлбәттә, сүз югында сүз булсын дип, “кызарып кояш чыкты”, “каурый болытлар”, “чык җемелди”ләр белән чуарланган докумен-

таль әсәрләр укучының ышанычын гына югалта. Әлбәттә, пейзаж да үзмаксат түгел. Монда ул документальлекне көчәйтү, фактның чын мәгънәсендә тәэсир чарасы булуын тәэмин итү өчен файдаланыла.

Рахмай Хисмәтулла иҗатына бәйле рәвештә бу хакта **Роза Әхмәтвәлиева** да уйлана: "Боз кузгалды..." дигән очеркында бер мәктәпнең "Ак каен" түгәрәге җыелышы бара. Монда күңелләрне тетрәндергән вакыйга сөйләнелә: урыс теле укытучысы Клара Мисбахованың әти-әнисе кечкенәдән урыс телен ныклап белмәү аркасында кыенлык кичергән. Шуңа күрә балаларын урысча укытканнар. "Мин гомерем буена бары тик рус телен укыттым, шуны пропагандаладым, класста татар балалары белән дә татарча сөйләшмәдем, аларга да татарча сөйләшергә рөхсәт итмәдем. Юл куймадым, ана телен кирәксез санадым...", дип сөйли Клара ханым. Пенсиягә чыгып, балалары, оныклары белән бик тә татарча сөйләшәсе килә дә, тик алар татар телен белмиләр. Шунда гына ул ялгышын аңлый.

"Ул сөйләп бетергәч, шактый ук шомлы тынлык торды. Барысының да күңелләре нечкәреп, моңланып калган иде. Бу апа үз күңелен үзе ярлыландырган, үз тормышының ямен үзе сүндерә язган, дип уйлыйлар иде ахры". Автор бу укымышлы олы кешене калын боз астында катып калган зур елга итеп күз алдына китердек, ди. Шулай итеп, зур елга бозы чатнадымы әллә? Чатнады!

Укучы исә боздан арынырга омтылган елганы күз алдына китереп, үзе дә нык дулкынлана.

"Батыр рухлы шагыйрь" дигән очеркта (Тәүбә // Сусау. 324 б.) Равил Фәйзуллин тасвирлана. Монда да пейзаж әһәмиятле урын тота. "Равилнең шагыйрь булырга гына түгел, кеше булырга да, җитәкче булырга да сулышы, рухы, тазалыгы җитте", дип билгели автор. Шунысы сокландыра: ул рух, тазалык, аңарга күктән төшмәгән. "Ул аларны кырлардан-урманнардан, үләннәрдән һәм чәчәкләрдән, каеннардан-имәннәрдән җыя белде. Экстрасенс һәм гипнозчы сыман чишмәләрдән, инешләрдән, елгалардан һәм диңгезләрдән үзенә сер иңдерә алды". Димәк, шагыйрьгә илһам дулкыннары табигать аша кергән. "Ул урман-кырлар, үлән-чәчәкләр... аша хис-тойгыларын, кичерешләрен халыкка җиткерә алган...".

Язучы Газиз Кашшафның вафатына бәйле хисләрен дә Р. Хисмәтулла пейзаж аша белдерүгә ирешкән. "...Иртәсен бөтен авыл вак яңгырлы томан эчендә иде. Тора-бара ул төрле халәтләргә кереп бетте: әле елый-елый яңгыр яуды, әле бик азга гына кояш чыгып, көлеп алгандай итте, әле болыт каплап, күзгә ямьсезлек чорна-

ды...”; “Бөтен тирә-якта язучыбыз җыр башлаган Аксубай-Үзи таллары-өянкеләре сакка басканнар. Гүя алар гади таллар гына түгел, ә язучыны соңгы юлга озату хөрмәтенә күкләр тарафынан эленгән яшел байраклар иде...”.

Журналистик иҗат ул мотлак ике төр хезмәтне – акыл һәм физик хезмәтне бергә кушканда, шуларның нәтиҗәсен тойганда гына җимеш бирә. Өстәвенә әле, хис белән дә өртелсә генә татлы була. Рахмай шагыйрь җанлы кеше иде – иҗатын ул шигърияттән башлап җибәрде, шигырь китаплары да бастырып чыгарды, гомеренең азагына кадәр шагыйрь булып калды. Моны аерып әйтү бик мөһим, чөнки тумыштан шагыйрь җанлы, хисчән булмаган булса, аңардан чын публицист җитлекмәгән дә булыр иде. Әйткәнебезчә, чын очеркчы ул проблеманың чишелешен нәкъ менә тасвирлап бирергә тиеш. Тасвирлау гына ышандыруның, инандыруның аеруча тәэсирле чарасы.

Публицист Р. Хисмәтулла – кешенең эчке хәләтен, аның тормыш киртәләрен ничек үтә алуын нәкъ менә тасвирлап-сурәтләп кенә бүтәннәргә тәэсирле итеп, хәтергә сеңеп калырлык итеп җиткереп була, дигән иманга килгән, моның өчен үзендә бихисап чаралар туплаган иҗатчы.

Әлбәттә инде, беренче чиратта, образ чаралары. Тик публицистик иҗатта факт кына түгел, хәтта образга ирешүче тасвирлау чаралары да уйлап чыгарыла алмый, алары да документаль, реаль булырга тиеш, шуңа күрә аларны, матур әдәбияттән аермалы буларак, микрообраз дип аерыбрак карау гадәткә кергән.

Очеркта тасвирлау өчен һәм публиистик, һәм әдәби чараларны кулланырга мөмкин. Менә шул ике яклы чараларны бергә үрә белү очеркчының осталыгы санала да инде. Бу яктан, кабатлаудан курыкмыйча әйтәбез, Рахмай Хисмәтулла иҗаты – чын мәгънәсендә осталык мәктәбе. Бу үзенә бер фәнни өйрәнү-тикшеренү темасы. Без инде публицистик чараларны, аерым алганда, факт, деталь кебек чараларны тәэсир өчен куллануына мисалларны күп китердек, ә әдәби чаралардан портрет, пейзаж мөмкинлекләрен дә барлый алдык.

Менә образлы сурәтләүне гомуми күзаллау өчен кайбер мисаллар. “Акылларыбызны җыяр чак” очеркының “Бәләкәй арбадагы хәтер” исемле беренче бүлегендә автор Златоустта хирург булып эшләгән Әхмәт Даушев дигән кеше турында яза. Бу кешенең Биләр-Болгар морзасыннан башланып киткән шәҗәрәсе бар икән. Аны тасвирлаганда автор болай ди: “Халкыбыз тарихының тагын бер зөбәрҗәт муенсасы!”. Шул ук очеркның “Кая тарих язу, ул яла яга!”

дигән өченче бүлегендә безне менә бу юллар тәэсирләндерә: "...алар арасында аракы агуында, тәмәке төтенендә вобла кебек ысланып беткән берәү – кая инде ул аңардан милләт тарихын язу, ялкынлы чакырулар ыргыту, инде хет ичмасам авызын тыйса иде, оятсыз – ә юк! – аны урыс аракысы иң изге кешеләребезгә түкерергә котырта – ул үзенең аракы кандаласы хәлендә калуы турында уйлап та тормастан, иң авыр чакларда милләт күгендә иң якты йолдыз булып янып торган иң актив, иң намуслы, чын милләт язучысы Фәүзия Бәйрәмеваларга каршы өрә, аңа пычрак ата...".

Микрообраз тудыруның иң төп чыганагы ул ана телебезнең "бизәкләү" чаралары:

– күчерелмә мәгънәле, хис белдерү үзенчәлеге сизелеп, аерылып торган сүзләр: *күкләргә чөйде, ярып салды* һ.б.;

– битараф берәмлекләр арасында йөреп тә, кулланууда сирәк булган сүзләр, гыйбарәләр*: күзге ямьсезлек чорнады: йөзең ашала; вөҗданың ертыла* һ.б.;

– күпчелек укучыга аңлашылып та, диалектизм, жаргон, гади сөйләм элементы рәтендә йөргән, авторның үзе иҗат иткән сүз, гыйбарәләр: *кайгының юан башы; аракы кандаласы; кояшның үбүе* һ.б.

Р. Хисмәтулла характерны тасвирлау өчен әдәби чаралар белән публицистик чараларны оста үрә белә, ул хатлардан, геройларының истәлек, чыгыш, диалог, туры сөйләмнәреннән оста файдалана. Мәсәлән, әле әйтеп киткән шәҗәрә тексты, "Югалту һәм табу" очеркында Газиз Кашшафны җирләгәндәге сүз, чыгышлары, "Күкрәп килә" очеркында депутатларның сөйләве һ.б. Болар барсы тел-сурәтләү чаралары белән үрелеп, үзенә бер микрообраз тәшкил итәләр.

Чираттагы күзәтүчебез **Гөлнара Кашапова** да рефератын публицистның тасвирлау чараларын эзләп табу, куллану, ясау алымнарына мисаллар китерә. Аерым алганда ул авторның сүзләрнең күпмәгънәлелегеннән максатчан, урынлы файдалануына игътибар итә. Автор гел бер сүзне кабатлаудан арынырга тырыша, нечкә төсмерләрне дә сиземләрлек итеп тасвирлау өчен сүзләрнең синонимнарын эзләп таба: "Сабыр гына салмак, тын гына шәүләләр сыман булып, бер-бер артлы авылдашлары бәхилләшергә агылды...".

Образлы синтаксик фигуралар куллану остасы буларак та Рахмай Хисмәтулла өйрәнелергә хаклы. Ул иҗтимагый чагыштыруларда кабатлау алымын иҗади куллана: "*Татар ул*, Гаяз Исхакый шикелле, гомере буена чит илләрдә каңгырып яшәп-яшәп тә, илдән-илгә күчеп, милли давыллар куптарып йөри! *Татар ул* Г. Бәширев, Ә. Еники кебек

саф рухлы, таза гомерле. *Татар ул* А. Гыйләҗев, М. Мәһдиевләр булып чәчләре чаларгач та, унсигез яшьлек егетләрдәй, һаман да дөньясын ду китереп, гүзәл романнар иҗат итеп ята торган диңгездәй интеллектуаль запаслы...” (Тәүбә. 247 б.). Әдип тормыш күренешләрен, бигрәк тә характерны тасвирлаганда каршылыклы, контрастлы фикерләрне шундый сыйфатлы синтаксик конструкцияләр белән бәян итүдән дә курыкмый: “Заманында урыс белән татар табигатьтәге *плюс белән минус, салкын һәм ялкын, иблис һәм фәрештә* кебек бер-берсен тулыландырып, бер-берсен үсендереп әйдәп торучы көчләр иде...”. Аның һәр очеркын диярлек риторик өндәү, риторик сорау җөмләләр дә, кайнар нурлар кебек бизәп тора: *“Җиңә кодрәтле татар рухы! Ишәя шөһрәтле татар рухы! Оча талантлы татар рухы!”* (Тәүбә. 243 б.).

Рәсилә Латыйпованың рефераты да очеркчы останың ана теленә мөнәсәбәте, төгәллеккә, хиссилеккә ирешүдә һәр сүзнең кадерен белеп, урынлы файдалануына күп кенә мисал белән бәян ителгән иде. Аерым алганда, ул очеркларда да герой сөйләме белән автор сөйләме арасында аерма барына игътибар итә. Төрле социаль катлау вәкилләренең сөйләшү үзенчәлекләре бер-берсеннән аерылып тора. Моны тою, әсәргә кертү геройның индивидуальлеген ачарга мөмкинлек бирә. Шушы шәхси йөз-холыкны тасвирлау зарурлыгыннан автор мөмкин кадәр героеның сөйләм үзенчәлекләрен дә: интонациясен, әйтү, үзен тоту манерасын, шул үзенчәлекле сөйләмнән алган тәэсирен дә кулланырга омтыла. Әйтик, герое Анна апа – өлкән буын вәкиле, урысча фикерли. Сөйләме дә җайлы гына, тыныч кына: “Иптәш Королев, Сез безнең эшләрне ошатасыз, без тырышабыз инде. Менә минем Сезгә үтенечем бар иде. Торак мәсьәләсендә...”. Ә менә чын татар апасы болайрак сөйли: “И-и, ул күргәннәрен сөйләсә, дивана, елап җибәрерсең...” (Үземне таптым // Сусау. 93 б.).

Ландыш Камалиева исә очеркчының иҗади табышларын текст тышыннан да эзли. Таба да. Аерым алганда, ул әсәрнең композициясе, сюжетының аерылгысыз өлеше булган баш исемнәренә диккатен төби. Аныңча, Рахмай Хисмәтулла әсәрнең бу өлешен дә тәэсир итү чарасы дип саный, аңа да җитди игътибар бирә. Әйтик, “Кыйбла җиле” җыентыгына егермеләп очерк тупланган. Һәркайсының үз темасы үзенчә төзелешле. Баш исеменең һәркайсы укучының диккатен тартып алырлык итеп куелган; әсәрнең композиция гармониясен, яңгыравын, төзеклеген сакларлык баш исемнәре табу чыннан да осталык сорый бит. Монда әдипкә аның шагыйрьлеге нык ярдәм итә. Тыңлап кына карагыз

әле: “Яшь аралаш көләч моң”, “Олы юлның тузаны”, “Оясында ни күрсә...”, “Җидегән чишмәләргә йөзек салдым” һ.б.

Кыска гына йомгак ясап, студентларыбыз – булачак журналистлар әдипнең тасвирлау осталыгын сизгер тоемлап, үрнәк мисаллар табып, аларны фәнни әйләнешкә кертеп кенә калмаслар, киләчәктә үз иҗатларында да кулланырлар, дип ышанырга була. Рефератларында ук инде алар бу хакта белдерәләр. Бу – бик мөһим. Бу инде әдипнең осталык хәзинәсе, бай публицистик мирасы эзсез югалмас, иҗатка илһам һәм үрнәк булып буыннан-буынга күчә килер, дигән сүз. Ә ул мирасны, аерым алганда публицистикасында тасвирлау чараларын, фәнни өйрәнүне студентлар, галимнәр өзмәс, киләчәктә дә дәвам иттерер, дип ышанып калыйк.

Кем ул безгә Эдуард Касыймов?

Хәзер инде Чаллы төбәгенең күренекле әдипләреннән Эдуард Касыймов иҗатына күчик. Аның иҗатын да без әлегедәй күмәкләп өйрәнергә карар иттек. Студетларыбыз инде мәгълүм планга нигезләнеп реферат темалары алып, семестр буена шуны әзерләделәр һәм гомуми анализга чыгардылар. Без аларны гомумиләштереп, фәнни мәкалә итеп “Мәйдан”га тәкъдим иттек. Басылып та чыкты (2005. № 11).

Ә нигә күмәк тикшеренү объекты итеп нәкь менә Эдуард Касыймовны тәгаенләдек? XX гасыр урталарында заманның актуаль темаларында, бигрәк тә чоры өчен шактый тансык роман жанрында “уңдырышлы” эшләгән, яшь укучыларны мавыктырган, публицистик рухлы язучы саналса да, яшь укучыга, татар милләтенә кем ул бүген Касыймов? Осталыгы, ана телен куллану ягыннан да кичәге язучылардан, бигрәк тә бүгенгеләреннән нәрсәсе белән аерыла, ни өчен без аңарга күмәк игътибар бирдек?

Әйткәнебезчә, без шушы төбәк иҗатчыларының үзенчәлекләренә тәфсиллерәк күзәтү кирәк, дип санадык, чөнки алар үз төбәге яшьләренә якынрак, өйрәнү өчен дә, киләчәктә кулланыр өчен алар мирасы җиңелрәк үзләштерелә, кулланырга җайлырак, диикме. Безгә, журналистларга, аның иҗатында публицистиканың әһәмиятле урын тотуы, үзенең дә вакытында матбугатта эшләве, өстәвенә әле студент елларыннан ук фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнүе, ягъни тел белән эш иткәндә аның әдәби, публицистик, фәнни катламнарының синтезын куллануы да әһәмиятле. Андый әдипләр бездә әле күп түгел.

Ниһаять, иң мөһиме, ул калдырган әсәрләр бүген дә укыр өчен, әдәби осталыкка өйрәнер өчен әһәмиятен югалтмаган. Без аларның барысын да диярлек кызыксынып укыдык.

Кем ул Эдуард Касыймов? Әсәрләрне анализларга, безне кызыксындырган үзенчәлекләрне табарга керешкәнче, аларны язган әдибебезнең тәрҗемәи хәленә, тормыш хәл-әхвәлләренә кыскача гына күз салу хәерле булыр. Бу юнәлештә без яңа материал, чыганаклар эзләү белән мавыкмадык, мәгълүм чыганакларга, әле исән-сау шаһитларның истәлек-хәтирәләренә таяндык. Дөресен әйткәндә, Эдуард Касыймовның иҗаты, биографиясе дә чордаш-кордаш каләмдәшләре белән чагыштырганда азрак өйрәнелгән, дигән фикер белән тулаем килешсәк тә, аңа караган шактый кызыклы язмаларны барлавыбызны икрар итүне кирәк саныйбыз (*Галимуллин Ф.* Чишмә җыры // Нур. 1995. 4 ноябрь; *Зөлкәрнәев Ф.* Соклану сәләте // Казан утлары. 1982. № 6; *Миңлебаев К.* Чишмә юлында калган дустым // Социалистик Татарстан. 1990. 15 ноябрь).

Эдуард Касыймов татар теленең төп сөйләмнәренең берсен тәшкил иткән тарихи үзенчәлекле, бай Нократ сөйләменең үзәгендә – Нократ авылында 1930 елның 9 ноябрендә туа. Тел тоемлау, аны куллану сәләте әти-әнисеннән килә. Әтисе укымышлы, аралашучан, актив зат буларак (авыл советын җитәкли, колхоз оештыруда катнаша, укытучы була), бу сыйфатларын балаларына да йоктыра. Тик Эдуардка әтисе мәктәбендә озак укырга туры килми – мәктәп директоры Салихҗан Касыймов "халык дошманына" әйләнә, кулга алынып, 1937 елны атыла.

Эдуардның әнисе, балаларын ияртеп, туган каласы Малмыжга китәргә, туган-тумачага сыенырга мәҗбүр була. Эдуард шунда татар мәктәбендә сигезне, урыс урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлый. 1948–1953 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Биредә аның язучылык сәләте ачылганнан-ачыла бара. Сабакташларының берсе моның сәбәбен болайрак аңлата: туган төбәгендә ана телен өйрәнеп үсүе, бик яшьли кайгы-хәсрәт күрүе, ятимлекнең ачысын татуы, әйләнә-тирәгә ачык күз белән карарга, кеше танырга күнегүе, адым саен гаделсезлекләр күрүе, намуссызлыкка юлыгулар Эдуардның күңелендә каршылыклы уйлар һәм хисләр тудыра. Өстәвенә, җәмгыятебездә бер төрле сөйләп тә, бөтенләй икенче төрле эшләүнең хуплануы, ялагайларның юл яруы, икейөзлелекнең чәчәк атуы әлеге хисләрне көннән-көн көчәйтә.

Уку елларында аның беренче тасвирнамә, очерклары, хикәяләре көндәлек матбугатта күренә башлый. Аларга карата инде матбугатта "яшь язучының үз тематикасы, үз теле бар", дип югары бәя бирелсә дә, алар әле, әлбәттә, сәнгати камиллектән шактый ерак була, чөнки әле тормыш тәҗрибәсе җитешмәгәнлектән, зур проблемалар аңардан ераграк тора. Аннары, "халык дошманы баласы" дигән кара тамга әледәнәле исенә төшеп торса да (мәсәлән, бик теләсә дә, аны аспирантурада калдырмыйлар), бу хәл әле яшь әдипнең күңелендәге өермәне кузгатып җибәрерлек этәргеч булырга тулышып җитә алмаган.

Э. Касыймов диплом иясе булганда, узган гасырның илленче елларында, татар мәктәпләре күпләп ябыла, татар телен укыту да кимегәннән-кими бара. Шунлыктан күп студентка урыс телен укытырга дигән тәкъдим белән килешергә туры килә. Касыймов та 1957 елның җәенә кадәр башта Азнакай эшчеләр поселогында, аннары Киров өлкәсенең Вятские Поляны районына кергән Түбән Шөн авылы урта мәктәбендә урыс теле, тарих укыта, соңыннан шул мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли.

Искә төшерсәк, бу бит шәхес культының кара пәрдәсе ачылып, "халык дошманы" уйдырмасына да яктылык төшкән чор. Университетта фольклордан лекцияләр укыган галим Хәмит Ярми Касыймовны Түбән Шөннән эзләп таба, яңадан Казанга килеп, Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керергә булыша. Өч елдан инде Эдуард шул институтның татар фольклоры секторында кече гыйльми хезмәткәр булып эшләп китә, халык авыз иҗатының төрле жанрларын җентекләп өйрәнә, диссертация яза.

Шул ук вакытта ул әдәби иҗатны да ташламый. 1959 елда аның беренче мөстәкыйль китабы – балаларга багышланган "Кызыл маяклар" исемле хикәяләр җыентыгы, ә 1962 елда "Совет әдәбияты" журналында "Кояш көн дә чыга" повесте басыла. Бу әсәрләрендә үк инде авторыбыз кешеләргә игелек кылу, шәфкать-миһербанлык, әдәплеинсафлы булу, фидәкарьлекне хуплау, кыскасы, гуманистик идеяләрне алга сөрә. Сәнгать кешеләре, галимнәр тормышыннан алып язылган һәм драматик вакыйгаларга шактый бай әлеге повестьне дә укучылар хуплап кабул итте.

Әдипнең күңелендә еллар буе җыелган каршылыклы хисләр – гарьләнү һәм әрнү, мәхәббәт һәм нәфрәтнең тәмам тулышып, ташкындай ургылып чыккан әсәре ул – "Гомер ике килми" романы. Китап язарга материал җыйганда, яшь әдип этисе үткән юлларны барлый, этисенең – совет хәкимияте өчен тир һәм кан түгеп көрәшкән,

колхозлар оештыруда активлык күрсәткән, сабыйларны белемле итү өчен тырышкан укытучының, коммунистның чыннан да бернинди гөнаһсызга кулга алынганына, бинахак атылганына үзе инана. Ул нинди генә җан өшеткеч фактларга юлыкмый! Үзе кичергәннәре дә азмы! Мәсәлән, Салихҗан Касыймовның 1937 елда ук атылганын әйтмичә, төрмәчеләр, әтиегез безнең төрмәдә утыра, тик хат алышырга ярамый, дигәннәр, ә үзләре озак еллар буе ризык ташыттырганнар. Сабыйларның авызыннан өзеп. Вәхшиләр!

Язучы каләме өр-яңа романлык ягулыкка байый. Тормыш чынбарлыгына, документальлеккә табынган, рухы белән публицист булса да, бу фактларны ул шәхсән үзенә генә кагылган, үзе генә кичерергә тиешле чыганак дип санамый, язучы буларак, инде кыйбла итеп кабул кылган әлеге гуманистик юнәлешкә җигәргә үзендә көч таба. Менә ни сәбәпле автобиографик планда язылган һәм гыйбрәтле язмышларны, тормышның катлаулы, четрекле якларын психологизм алымнары белән сурәтләгән “Гомер ике килми” романы да, әдәбият белгече билгеләп үткәнчә, әдәби җәмәгатьчелектә уңай фикер уята һәм лирик әсәр буларак яңгыраш ала. Бу романда авторның бөтен эрудициясе, тел байлыгы, галимлеге, Нократ сөйләменең үзенчәлекләре гаять тулы чагылыш таба.

Барлык публицист-язучыларга да хас бер сыйфат бар – алар ирешкәннәр белән тукталып торырга, канәгатьләнергә күнекмәгән. Эдуард Касыймов та, әйтик, Хәмит Ярми канаты астында фәнни экспедицияләргә йөри, экиятләр җыеп, китап итеп чыгара, диссертациясе әзер, Хәмит ага аны үз урынына фольклор бүлегенә җитәкче итеп, пенсиягә китәсен игълан итә, доктор диссертациясенә материал әзер, китаплары чыгып тора. яңаларына мая җитәрлек – яши бир тыныч кына Казан каласында...

Юк бит! Ул арада Касыймов гаиләсе белән Алабугага күченергә дә өлгергән! Анда ул җирле халыкның яшәешен-көнкүрешен өйрәнә, янәшәдә генә урнашкан Бондюг химиклары белән якыннан аралаша, педагогия институтында лекцияләр укый – нәтиҗәдә “Томан аша”, “Һаваларда тургай” роман-дилогиясе барлыкка килә.

Ә иҗат мөмкинлекләре һич кимеми, яшә дә яшә шушында тыныч кына. Юк шул, янында гына ГЭС, автогигант калка башлаганда, анда бөтен илдән яшьләр җыелганда, бу төбәк тормышның иң кайнап торган җиренә әверелгәндә, ничек тыныч яшәп ятарга була! Каләм әһелләреннән беренчеләрдән булып Э. Касыймов шунда күчеп төпләнә. Инде бай тәҗрибә туплаган язучы, вакытлы “ура-

патриотизмга” артык бирешмичә, шул төбәктәге халыкны борчыган мәсьәләләр белән күбрәк кызыксына, әйтик, нигезеннән күчәргә мәҗбүр ителүнең кире яклары аны да борчый. Шуңа бәйле проблемаларны ул җентекләп өйрәнә. Шуларны хәл итү өчен кайгыртып, матбугатта публицистик әсәрләр яза. Иң мөһиме, ул материал сәнгати оеткы, мая булып та җыела килгән – яңа повесть, романнар языла.

Кайнар төзелешләрдә аралашу белән бергә 1965–1967 елларда Э. Касыймов Алабуга педагогия институтында татар фольклоры һәм әдәбияте курсын укыта. 1966 елда ул “Татар халык экиятләрендә сатира һәм юмор” дигән темага диссертация яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Бу елларда Э. Касыймовның әле телгә алган романнары рәтендә “Бир кулыңны, дустым!”, “Көмеш язулы кылыч”, “Сорбонна профессоры һәм без” повестьлары да басылып чыга. “Сорбонна профессоры һәм без” повесте документаль нигезгә корылган: авторның яшь чагы, университет еллары... Үзәктә профессор Одинцов образы. Дөнья күләмендә танылган зур галим. Ләкин ул гаять катлаулы һәм драматик язмыш кичергән. Әсәр дәвамында вакыйгадан вакыйгага аның бик күп күркәм сыйфатлары ачылып, укучы күз алдына килеп баса: зур эрудицияле галим булуы өстенә үтә нечкә күңелле, йомшак табигатьле олы галим үз язмышында, юк, сөйгән ватаны һәм бөтен дөнья язмышында иң куркыныч, иң хәтәр чакны – фашизм дәһшәте алдында бил бөкми, баш ими, алай гынамы, көрәш юлына басып, зур фаҗигаләр кичерә... Андый кешегә чиксез ихтирам уянмыйча буламы соң! Повестьтә професор белән бергә бүтән геройларның да, аеруча студент Рифкатьнең (аны авторның үзе дип фаразларга да нигез бар) кешелек сыйфатлары ачылганнан-ачыла бара, карашлары ныгый, характерлары чыныга. Әсәр профессорның үлеме белән тәмамланса да кешенең сынмас ихтыярына, аның рухи бөеклегенә үзенә бер мәдхия булып яңгырый, дип бәяләде бу повестьне заманында әдәбият белгечләре.

Бу елларда Э. Касыймов шулай ук “Томан аша” әсәренең дәвамы булган “Һаваларда тургай” романын тәмамлый. Бу әсәрләр дә укучы тарафыннан җылы каршы алына һәм, тәрҗемә ителеп, “Чулман – река внуков” исемендә роман-дилогия рәвешендә Мәскәүнең “Современник” нәшриятендә урыс телендә дә басылып чыга. Бу әсәр эшчеләр темасына язылган проза әсәрләре арасыннан Бөтенсоюз күләмендә оештырылган махсус конкурста премиягә лаек була.

Чаллыда яшәү чоры Э. Касыймовның иҗатын документаль әсәрләргә баета. Байтак кына очерк, кыска хикәя, мәкаләләр язып бастыра. 1979 елда аның “Советская Россия” нәшриятендә Кама буе нефтьчеләренә багышланган “На Каме-реке” дигән очерклар китабы дөнья күрде.

Эдуард Касыймов күп еллар буена шеф-консультант сыйфатында автомобиль үзәгендәге “Ләйсән” әдәби берләшмәсенә җитәкчелек итте. Чаллы язучылар оешмасы ачылгач, аның җаваплы сәркатибе булып эшләде. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңаеннан язучыбыз 1980 елда “Почет билгесе” ордены белән бүләкләнде. Ул 1986 елда вафат булып, Чаллы зиратында җирләнде.

Китаплары киләсе буыннарга мирас булып калды. Ул мирас шактый саллы, күләмле; язучының татар әдәбиятенә керткән өлеше дә, үтәлми калган вәгъдәләре дә, өметләре дә ачык күренә. Чынлыкта ул үз бәясен вакытында ала алмыйча дөнья куйган кызыклы, үзенчәлекле фидакарь шәхесләрнең берсе булып калган.

Язмабызның күренекле әдәбият белгече бәясе белән тәмамланган бу өлешен Эдуард Касыймовның тәрҗемәи хәленә һәм иҗат юнәлешләренә гомуми күзәтүне, башка чыганакларга да таянып, студентыбыз **Р. Мингалимов** әзерләде.

Публицистика кыйбласында. Каләм иясенең осталыгы, кайсы жанрда иҗат итүенә карап та, төрлечә ачыла. Жанрның нигезендә тормыш куйган һәм иҗатчыны уйланырга, борчылырга мәҗбүр иткән проблема ята: әгәр автор чишелмәгән мәсьәләне табып хәбәр итә икән, ул хәбәр жанрында яза (репортаж, интервью, хисап һ.б.), әгәр ул мәсьәләне анализлый, тикшерә һәм кайбер нәтиҗәләр ясый икән, ул – аналитик, ягъни мәкалә, күзәтү, рецензия остасы; әгәр инде үзәккә проблеманың чишелешен куеп, ничек хәл ителгәнен тасвирлап бирә икән, бу инде чын мәгънәсендә әдәби-публицистик жанр таләп итә – тасвирнамә, очерк, эссе.

Журналистиканың нигез ташы – факт та менә шушыңа бәйле рәвештә барлана, җыела, эш ителә: хәбәр жанрларында ул – хәбәр чыганагы, аналитик жанрларда ул – анализ коралы, ә менә әдәби-публицистик жанрларда автор фактны проблеманың чишелеше хәтердә калсын, илһамландырсын, хәрәкәтләндерсен өчен тасвир чарасы буларак файдалана. Бу инде чын мәгънәсендә осталык сорый торган, талант белән бәйле коралдыр.

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятендә публицистик сулыш нык көчәйде, тормыш чынбарлыгына – документальлеккә тая-

ну әдәби-сәнгати алымнарның иң көчлесенә әверелде. Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Миргазыян Юныс, Мәдинә Маликова кебек язучыларның барысы да иҗатны публицистика-журналистикадан башлап, сәнгать әсәрләре дә публицистика белән сугарылган язучылар иде. Ә Барлас Камалов, Кояш Тимбикова, Җәмит Рәхимев, Рахмай Хисмәтулла, Альберт Хәсәнев, Марсель Зариповлар бөтен иҗатлары баштан азагынача публицистика белән сугарылган язучылар сафын тәшкил итте – аларны шул елларның журналистикасыннан аерып карау мөмкин түгел.

Эдуард Касыймов та шулар рәтендә диярлек иде. Моны дәлилләр өчен башка фактлар рәтендә аның үз сүзләрен китерү аеруча нигезле булыр. Аның әсәрләрен укыгач уй-тойгылары белән уртаклашкан хатлар "Казан утлары" журналына да килә. Журнал шулардагы язучыга булган сорауларның җидесен аерып алып, аларга язучының җавапларын бастыра (Казан утлары. 1968. № 10). "Әсәрләрегезнең прототиплары бармы?" дигән сорауга ул: "Барлык әсәрләремдә дә персонажларның прототибы бар, "Сорбонна профессоры"нда гына юк", дип җавап бирә. Менә сиңа мә! Әле генә без "профессор" образы турында бик тә реаль, тормышчан образ дип авторның Казан дәүләт университетында бергә укыган каләмдәшләренең фикерен җиткергән идек. Иҗат кыйбласы чын документальлек-публицистлык булган әдип кенә шундый бәя ала аладыр.

Күзәтүчеләр искәрткәнчә, аның иҗатында документальлек чыннан да өстенлек итә. Шунысы характерлы: иҗатының башында ук ул реаль тормыш вакыйгаларын тасвирлауга алына. Мәсәлән, аның беренчеләрдән язылган "Ул Ленинградныкы иде" хикәясе (Үсү юлы. 1958. 13нче китап), Ленинградтан эвакуацияләнеп, алар авылында төпләнгән урыс гаиләсенең сугыш хәлләре, авылда ияләшү вакыйгаларын ничек булган, шулай бәян итә. Шул ук вакытта ул бер караганда көндәлек булып тоелган вакыйга, күренешләрне гомумиләштереп, барлык кешеләрнең дә күпчелегенә тия торган сурәтләр белән тасвирлап, образ дәрәҗәсенә җиткерә алган.

Әлбәттә, публицистикада – иҗатның үзенчәлекле, катлаулы бер сәнгати юнәлешендә – документальлек бердәнбер асыл сыйфат түгел. Эдуард Касыймов әсәрләре мисалында аларның башкалары да ачык күзаллана. Әйдәгез, әдипнең публицистик осталыгының кайбер "алтын баганалары"н барлап карыйк.

Игътибарда – проблеманың хәл ителүе. Әдәби-публицистик иҗатның катлаулылыгы, аңа теләсә кемнең алына алмавы шуның

белән аңлатыла: ул проблеманың колачлы, тирәннән куптарылуы белән бергә, чишелергә тиешле мәсьәләне ачып, куеп, аңлатып, хәтта хәл итүнең юлларын күрсәтеп кенә калмый, ә проблеманың гамәлдә хәл ителүен, чишелешен тирәнтен анализлап, алай гына да түгел, күзалдына килеп басардай итеп сурәтләп, тасвирлап күрсәтергә, бүтән җирдә дә бу проблеманы хәл итәргә алынырга теләк, илһам, омтылыш тудырырлык итеп сурәтләп язылырга тиеш.

Бездә әле публицистика төшенчәсенә бик җиңел караш өстенлек итә: матбугатта басылган барлык нәрсә – публицистика. Юк шул, публицистика ул (бигрәк тә очерк жанрында) әдәбилек белән публицистлылыкның үтә дә катлаулы, бик тә нечкә үрелүе, фәнчә әйтсәк, синтезлануы. Чын әдипләр тәҗрибәсеннән моңа мисаллар табу яшь каләмчеләр өчен бик әһәмиятле. Монда башта нәрсә ул публицистлык, нәрсә ул әдәбилек икәненә төшенеп бетү бик мөһим. Эдуард Касыймов тәҗрибәсе бу юлда безгә нәрсә бирә?

Публицистика үзәгендә – проблема, дидек. Шулай да әдәбилек + публицистлык осталыгының югары ноктасы ул проблемага карата теләсә кайсы мөнәсәбәттә (әйтик, хәбәр итүдә, анализлауда) түгел, ә бәлки аның чишелешен тасвирлаганда гына ирешелә, дип кабатлыйк.

Эдуард Касыймовның үз вакытында проблемага карашы турында бүгенге таләпләр яссылыгында **З. Миршәрипова** уйлана.

Гыйлемлек алга илтә. Проблемага мөнәсәбәте публицистның шәхси холкына-табигатенә, аның тормыш-яшәешенә, үзенә куйган таләпләренә нык бәйле. Эдуард Касыймов Казан университетының тарих-филология факультеты студенты чорында ук кешеләр белән мөлаем сөйләшә белү, тиз арада дуслашып китә алуы, иптәшләренең хәленә керә белүе, эчкерсез гадилеге, тыйнаклыгы һәм гаять активлыгы белән күзгә ташланып, дусларының күңеленә кереп кала.

Аның язучылык хезмәте белән чын-чынлап кызыксынганлыгын бик күпләр белә, ул моны яшерми дә – әдәби түгәрәк әгъзаларыннан иң җитдие, иң активы, төрле әдәби кичәләрне оештыруда, стена газетлары чыгаруда башлап йөрүчеләрнең берсе. Хәер, ул заманда студентлардан кем генә үзен-үзе сынап, каләм тибрәтеп карамады икән! Ә күпмесе генә чын әдип яисә зур шагыйрь булып җитлекте? Бик азлар.

Э. Касыймовның КДУда укыган чорында язылган “Сорбонна профессоры һәм без” миңа аеруча ошады. Чөнки мин үзем дә КДУ филиалында белем алам һәм безгә кадәрге буыннарның тормышы безгә бик тә кызыклы.

Биредә язучы гыйлемлек проблемасын күтәрә. Әсәрне беренче мәртәбә укып чыккач, үземнең студент елларын теге чорныкы белән чагыштырып утырдым, университет тормышына чумдым. Ул ерак елларның татлы студент һавасын кабат сулагандай булдым. Элеккеге һәм хәзерге студент тормышы белән охшаш яклар да, аерымлыклар да очрый. Охшаш якларның берсе дип гыйлемлекне әйтергә була. Ләкин элеккеге чорда белемгә омтылу көчлерәк булган, минемчә. Ә хәзер барысы да акчага килеп терәлә... Шулай да хәзерге чор студентлары арасында да “Сорбонна профессоры һәм без” әсәрендәге геройлар – Рифкать Кәримов, Вил Вахитов, Миша Черепанов кебек тырышлары да күп кенә.

Әсәр профессорның үлеме белән тәмамлана. Аның үлгән хәбәре бәян ителгән өзек миңа аеруча тәэсир итте һәм күземә яшь тулды. Чөнки аның үлеме белән гыйлемлек тә китеп барды сыман булды. Ул бит студентларны белемгә өндәүче иде. Әйе, профессор Одинцов студентларның әтиләренә әйләнгән иде. Ул аларга гыйлем иленә юл ачучы булды, дип әйтсәм дә, ялгышмам.

Әсәрдәге гыйлемлек проблемасын да автор нәкъ шушы герой аша бирә. Бу проблеманы ул шушы образ мисалында чишә дә. Аның тәэсирендә студентлар зур югарылыкка ирешә. Кемдер университет доценты дәрәҗәсенә ирешә, кемдер мөгаллим булып китә. Бу проблема бүген дә актуаль. Одинцов кебек шәхесләр аз булса да, бүген дә бар. Безнең укытучыларыбыз арасында да. Алар бүген дә белемлекне, гыйлем дәрәҗәсен үстерүгә зур тырышлык салалар.

Саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр өчен. Университетны уңышлы тәмамлагач, Э. Касыймов берничә ел туган ягы Нократ буйларында мәктәптә укыта. Аннары Татарстан радиосында хәбәрче булып эшләп ала, аннары аспирантурага укырга керә. Монда ул фольклор өйрәнә, халык иҗатының чын җәүһәрләре белән җентекләп таныша. Менә кайлардан ала язучы тормыш чынбарлыгын! Фольклор экспедицияләре биргән бай материалга таянып, язучы “Кояш көн дә чыга” повестен яза. Тумыштан сукыр кеше язмышының аянычлары, гаять авыр хәләте, аңа төрле кешеләрнең төрлечә мөнәсәбәте һәм чын дусларының ярдәме белән, ниһаять, күзе ачылуы – болар һәммәсе дә әсәрдә ышандыргыч итеп сурәтләнгән. Автор кешеләрнең үзара мөнәсәбәтенең ни дәрәҗәдә саф һәм ярдәмчел булырга тиешлеге проблемасын алга китереп куя. Проблема тумыштан сукыр Абдулла образы ярдәмендә чишелә. Барлык геройлар да Абдулланың кимчелегенә карамыйча, аны бик хөрмәтләп, яратып яши: хатыны

Гәзизә, кызы Җәмилә, Җәлүк бабай, колхоз рәисе Бикәшев, парторг Хәир Әхәтев һәм бигрәк тә авылның фольклорын өйрәнергә килгән Якуп Сәйфи – барысы да Абдуллага ярдәм итәргә, аны терелтергә ниятлиләр. Тик Кәрибулла гына аңа бүтән мөнәсәбәттә – аның сукырлыгыннан файдаланып улы Гариф белән акча эшләргә исәп тота. Абдулла гармунда яхшы уйный, моңлы җырлый, димәк, хәер җыя ала. Бу мәкер турында белү Абдуллага бик начар тәэсир итә. Шулай да хатыны аңарга күңелен сүрелдерергә юл куймый.

Һәрхәлдә повестьтә саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр өскә чыга – нәтиҗәдә Абдулла күрә башлый, дөньяның матурлыгына, гүзәллегенә шаһит була. Әдипнең сафлык, ярдәмчеллек проблемасы бүген дә актуаль. Бүген дә Абдулла кебек тумыштан сукыр кешеләр бар, аларга ярдәм кулы сузу ихтыяҗы да җитәрлек. Тик, минемчә, элекке чор белән хәзергене чагыштырсаң, бу саф һәм ярдәмчеллек мәсьәләләре акчага кайтып кала.

Ватанны саклау – изге бурыч. Э. Касыймовның “Көмеш язулы кылыч” повесте, әдәби зәвык, тирән психология белән язылганга, күңелләрне тирәнтен дулкынландыра. Анда кешенең батырлыгы мәсьәләсе күтәрелә, героеның ватанны саклап калу бәрабәренә күргән җәфа, авырлыклары тормышчан чагылдырыла. Проблема Гыйлаҗ агай образы аркылы чишелә. Агай туры мәгънәсендә телсез: улы ипи тотып ант итеп сөйләвенә караганда, этисенең телен, әсирлеккә эләккәч, сер бирмәгәне өчен явыз дошманнар кисеп алган, бөтенләй сөйләшә алмый...

Мондый “кимчелекле” геройга укучы игътибарын юнәлтер өчен “кылыч сюжетын” тәкъдим итә: ватанны саклаганда чиккән җәфалары өчен Гыйлаҗ агай кылыч белән бүләкләнгән икән. Аңа ул кылычны өендә тоту хокукы да бирелгән. Ул стенада төрле чәчәкләр чигелгән келәмдә, дәрәҗәле урында эленеп тора. Аның янында тагы авыл кешеләре “пертупэй” дип атаган каешлар да эленгән. Кылычның сабында ялтыравык калай кисәгенә матурлап уеп урысчалатып аның Гыйлаҗ абыйга сугышта зур батырлык күрсәткәне өчен бүләк ителүе язылган. Хәтта кайсы полк икәне дә теркәлгән. Күпләр, аеруча яшьләр, бу казанышка зур горурлык кичерә. Авылыбызда тагын кемдә бар мондый кызык нәрсә, кемгә чын сугыш коралын өендә тотарга хокук бирелгән!

Шул ук вакытта Гыйлаҗ агайның батырлыгына, бүләкнең чынлыгына шикләнүчеләр дә бар. Хәкимҗан агай, мәсәлән, “Имеш, аклар телен кисеп алган, ди. Булмастыр ла. Андый явызлыкка барырмы соң

адәм баласы”. Шулай да әдип оста алымнар белән Хәкимҗан агайны ышандыруга ирешә.

Әлеге проблема – Ватанны саклау бәрабәренә үзеңне корбан итү – хәзер дә вакытлы һәм урынлы. Бүген дә илебезне дошманардан саклау ихтыяҗы көн кадагыннан төшмәгән.

Яшь чак – юләр чак. “Бир кулыңны, дустым” повестендә Эдуард Касыймов яшьләр мәсьәләсен күтәрә. Әлбинә Әхсән исемле егетне ярата, ләкин алдана. Егет аны авырлы килеш ташлый. Әлбинәгә дуслары ярдәмгә килә. Әйтик, Роберт аны электән үк яратып йөргән икән – хәзер инде авылга барып, аның “ире” дип белдерә. Минемчә, автор бу әсәрендә яшьләрне нинди ялгышлыклар ясамаска икәнен кисәтә, якын дусларның нинди булырга тиешлеген тасвирлый. Бирердәге вакыйгалардан бүген дә гыйбрәт алырга була. Бүген дә без мондый хәлләргә адым саен юлыгып торабыз. Шулай да кызлар уяурак булсын, беркатлы булмасын, дусларың чыннан да элекке яшьләр кебек тугры була белсеннәр, дигән теләктә калабыз.

Күренде ки, Эдуард Касыймов иң катлаулы проблемаларны чишү юлларын тасвирлауга да кыю алынган, бүгенге буын укучыларга да тәэсир итәрлек итеп тасвирлауга ирешкән. Ничек, нинди алым, ысуллар, нинди әдәби һәм публицистик чаралар белән?

Публицистиканың нигезе документальлек, дидек. Документальлек ул иң төгәл, иң конкрет чаралар – конкрет мәгълүмат (сан, дата; документ, диалог, туры сөйләм һ.б.), телнең иң төгәл берәмлекләре (сүз, сүзтезмә, әйтем, мәкаль, синтаксик фигура һ.б.), башка конкрет чыганаклар (әсәрләрдән, чыгышлардан өзекләр, канатлы гыйбарәләр һ.б.).

Бу конкретикадан тыш, әле төгәл күзаллауны көчәйтә торган, кискенрәк, ачыграк итә торган әдәби-публицистик алым, юллар да публицистик иҗатта аерым урынга чыга. Мәсәлән, портрет, пейзаж, публицистик чигенеш, автор “мин”е кебек күренешләр әдәби чарадан бигрәк публицистик чара буларак игътибар үзәгенә куела. Менә шуларның кайберләре безнең рефератларда да чагылыш тапты. Мәсәлән, тасвир чарасы буларак портретны **Гөлназ Мансурова** өйрәнде.

Портрет – тасвир чарасы. Эдуард Касыймовның иҗат мирасы шактый саллы, күләмле. Курсны үтү чорында барлык әсәрләрен укып бетереп тә булмады. Тик шунысы мөһим, укыган бер әсәр хәтергә уелып калды. Нигә шулай икән – гомер буена күпме китап укылган, истә калганнары бармак белән генә санарлык бит.

Уйлана торгач, башта гомуми бер нәтиҗә ясала: Э. Касыймовның һәр китабындагы төп геройлар, нәкъ тормыштагыча, каршылыклы булса да, күпчелеге татар җанлы – әдәпле вә итәгатьле кешеләр. Алар бүтәннәр хакына кереп, рәнҗетеп, үзләренә күбрәк мал төшерергә, җылырак фатирны, майлырак калҗаны эләктереп калырга ашыкмый, берәүгә дә этлек эшләргә, кемгәдер явызлык кылырга атлыгып тормый, чөнки андый максат аларның холкы-табигатенә туры килми. Э. Касыймовның яратып язган, җан җылысын кызганмыйча сурәтләгән геройлары, үзе шикелле үк, бүтәннәргә нинди дә булса изгелек эшләргә, мәрхәмәт күрсәтергә тырыша – ул аларга кыйбладан тайпылырга, хыянәт юлына басарга һичбер вакыт юл куймады.

Бу – гомуми тәэсир, ә инде ул "гомуми" нинди өлешләрдән тора соң, дип уйлана башласаң, күз алдына нәкъ менә конкрет затлар килеп баса, "томанлы", гомумиләштерелгән образлар түгел. ә конкрет адәм балалары. Хәер, аларны да әле уйда-аңда гомумиләштереп була икән.

Э. Касыймов көчле кешеләр, үзләренә ияртерлек, соклангыч кешеләр турында яза. Моны әдәбият белгечләре дә билгеләп үтә. Көчле кешеләр. Кемнәр алар? Сабыйларча ышанучан һәм самими күңелле профессор Одинцовмы? Бәлки "Ади-ади" кушаматлы телсез Гыйлаждыр? Яисә алданган кыз Әлбинәме? Болар һич тә без күз алдына китергән, тормышта күреп күнеккән көчле кешеләргә охшамаган ич. Әмма повестьләрне укып, алардагы вакыйгаларны күңелең аша кичергәннән соң, язучының үз геройларына карата булган җылы мөнәсәбәте әкренләп сиңа да күчә, уйларың үзгәрә. Әйе, алар көчле. Язучы аларны шуңа ышандырырлык итеп тасвирлый алган. Нинди чаралар белән? Моңа конкрет мисаллардан төшеник әле.

Башта "Сорбонна профессоры һәм без" повестен искә төшерик. Язучы Рафаэль Мостафин: "Мин аны... укыгач, яңадан үземнең студент елларыма, үзем өчен бик тә кадерле булган университет тормышына чумгандай булдым. Әсәрдә байтак персонажларның исеме үзгәртелгән булса да, мин аларның бөтенесен диярлек күз алдына китердем: төс-кыяфәтләрен генә түгел, хәтта холык-фигыльләренә кадәр...".

Бу уңышта авторның портрет остасы булуын да искә алынырга тиеш. Профессор Одинцовның студентлар янына килеп кергәндә үк нинди кеше икәнлеге күзгә бәрелә: "Ачык калдырылган ишектә иң әүвәл сары күн портфель һәм трость, аннары ап-ак башлы картыбыз үзе күренде. Тукталып калды, чал кашлары астындагы зәңгәр күзләрен салмак йөрткәләп, безгә карады һәм кисәк нигәдер тотлы-

гып-каушап, карлыкканрак тавыш белән исәнләште... Кафедра артына кереп басмады, каршыбызга, өстәл артына килеп утырды, кулларын шәп күннән эшләнгән портфеленә куйды. Озын-нәзек бармаклары, сизелерлек булып калтырый иде... Күпереп торган чал мыегы селкенеп алды – сәер генә иттереп елмайды. Юк, аның бармаклары гына түгел, тавышы да калтырана – тамак төбеннән ничектер сыныпөзелеп чыга иде...”.

Автор профессорның кыяфәтен, сөйләмен шундый оста иттереп сурәтли ки, шунда ук аның нечкә күңелле, яхшы кеше икәнлеген сизеп аласың. Әйтик, профессорның тактага ничек язуы аша да аның эчке һәм тышкы хәлэтенең ни дәрәҗәдә төрле булуын сурәтли.

Әдип портретны бәян иткәндә публицистикада аеруча әһәмиятле чара – детальгә бик игътибарлы: “Менә, ниһаять, аның чал мыек тирәсе хәрәкәткә килде...” һ.б.

“Бир кулыңны, дустым” повесте герое Әлбинәнең чибәр, әдәпле, намуслы, эшчән, белемгә омтылучы кыз икәнен ул портреты аша да сурәтли: “Әлбинәнең Идел буенда туып-үскәнлеген әллә каян белеп була – әнә бит ул, аккош кебек җиңелчә тибрәнгәләп, йомры беләкләрен ничек тигез һәм ыспай салып бара...”. Әдип әсәрдә аның “энҗе тешләрен”, “озын керфекле карлыган күзләрен” ничәме-ничә тапкыр кабатлый.

“Көмеш язулы кылыч” повесте герое Гыйлаҗны язучы бүтәннәрдән аерып куя. Беренче чиратта, мыек-сакалы белән. “...Шактый олы күренә иде: киң иягеннән асылынып төшкән, чылгыйлары бөтерелеп торган хәтәр мыек, яссы маңгай астында бергә кушылып үсә язган яман да калын кашлар һәм болар һәммәсе дә сумаладай чем-кара төстә, тик сакал-мыегында гына көмеш төкләр күренгәли...”.

Повесть яңа буын ирләрнең Бөек Ватан сугышына китүе белән тәмамлана. Көмеш язулы кылычына таянып баскан көенчә аларны озатып калган Гыйлажның мәһабәт сыны укучы күз алдыннан китми. Автор үз героена дастаннарга хас монументальлек бирә алган: “Гыйлаҗ агайны танырлык та түгел иде: өстендә күн туҗурка, зәңгәр галифе, аягында күн итекләр, ә башында зур йолдызлы шлем. Күкрәгенең сул ягына кызыл тасма да кадаган... Тагы күкрәген аркылы-торкылы тар каеш, билен яссы каеш кыскан. Билендәге яссы каешта көмеш язулы кылыч асулы... Хәтәр кыяфәт!.. Менә ул каба сакалын як-якка борып, китүче егетләр йөзеннән утлы карашын кичерде...”.

Әлбәттә инде, тәҗрибәле әдип кешенең тышкы кыяфәтен сурәтләү белән генә чикләнми, моны үзмаксат дип тә санамый, ә

бәлки бу чараны героеның эчке хәләтен, рухи үзгәрешен, кичерешләрен, бөтен холкын ачып бирү, шулай итеп укучыга да уңай тәэсир ясау өчен өстәмә чара буларак оста файдалана.

Табигать һәм кеше – аерылгысыз. Бәян итүдә, тасвирлауда төгәллеккә ирешүнең янә бер сәнгати-публицистик чарасы – ул пейзаж. Аны куллануда да Э. Касыймов бай тәҗрибә туплаган. Һәр әсәрендә диярлек без соклангыч, күңелне җәлеп итәрлек манзара, күренешләргә юлыгып тәэсирләнәбез.

Әдәби әсәрләрдә портрет, пейзаж, интерьер ярдәмче вазыйфа үти. Әсәр мәйданында чагыштырмача аз урын били. Монда каләм остасы табигать манзарасының яки персонаж кыяфәтенең барлык детальләрен дә бөртекләп сурәтләүне мәҗбүри санамый. Аерым деталь, штрихларга гына басым ясау – аның өчен табигый хәл, ди әдәбият нәзәриясе белгече. Ә менә Э. Касыймов әсәрләрендә табигать күренешләренә аларның кешегә тәэсир итү очракларына зур урын бирелә. “Ишкәй елгасы диләр аны... Әллә кайларда, тау-таш араларыннан чылтырап бәреп чыккан чишмә сулары, урыс, мукшы, татар авылларының ямьле, киң тугайларында боргалана-сыргалана, йомшак камыш үләннәрен тибрәндереп, әкренләп бергә кушыла баралар. Агым су, Апчатар үзәнендә тирән генә, матур гына елгага әверелеп, Ишкәй авылына килеп җитә, аның бакча артларындагы ярларга бәрелеп үтә, аннары үз юлында исемле һәм исемсез инешләр белән очрашып, талгын гына Идел кочагына барып керә...”.

Беренчедән, бу пейзаж “Кояш көн дә чыга” повестенең башламы буларак игътибарга лаек, димәк, укучы пейзаж күренешләрен әсәрнең буеннан-буена очратырга әзерләнә. Дөрестән дә шулай – аның өмете аклана. Персонажларның бөтен хәләте диярлек табигатьтән аерылгысыз.

Икенчедән, табигать күренешләре әдәби әсәрдә хәбәр җиткерү бурычын да башкара ала. Алар вакыйганың нинди төбәктә, кайсы тирәлектә баруын искәртәләр. Җирле колоритны сиздерәләр. Моны без әлеге мисалдан да күрә алдык: Ишкәй елгасы, Апчатар үзәне, Апкатар, Бүрәнә таулары һ.б.

Әгәр дә рәсем сәнгатендә тамашачы бөтен картинаны берьюлы, бер карап алу белән күрсә, әдәби әсәрдә исә язучы пейзаж, портрет күренешләрен акрынлап, эзлекле рәвештә, хәрәкәт дәвамында гына күрә һәм укучыларга да шулай тәкъдим итә. Э. Касыймов бу сәнгати закончалыкны төгәл үти.

Аның һәр әсәрендә төп герой табигать белән турыдан-туры мөнәсәбәттә: кеше аның йогынтысында яши, табигать аны сыный да. Геройның хис-тойгылары табигать күренешләре белән аерылгысыз үрелеп бара: “...Абдулла йомшак үләнгә яткан көйгә, гадәтенчә, әйләнә-тирәдәге тавышларга колак салды, һавада бал кортлары, төклетуралар безелди, үлән арасында чикерткә сызгыра, таллыкта ара-тирә саескан шагырдап куя... Абдуллага рәхәт бүген, күңеле шат аның...”.

Пейзаж әсәрдә күп очракларда, бигрәк тә публицистик әсәрдә, характерның проблеманы чишү белән бәйле катлаулы хәләтен ачыграк күрсәтергә дә, аны яхшырак аңларга да ярдәм итә. Сүз белән әйтеп җиткерә алмаганны табигать күренеше, пейзаж ачык итеп, өстәмә чара буларак та күрсәтә ала.

Халык иҗатына якын, аны яхшы белгән иҗатчылар, гадәттә, табигатькә дә якын була икән. Эдуард Касыймовның пейзаж, табигать күренешләрен тасвирлау остасы булуын шуның белән дә аңлатып буладыр. Аны яхшы белгән каләмдәшләре әйтүенчә, авыл баласы буларак, үз туган ягын ул бик яраткан, якын иткән, аның табигатенә сокланып туя алмаган, оста балыкчы булган, балыкчылар турында китап та язарга хыялланган... Тик 1986 елның 21 мартында чишмә юлында әдипнең гомере өзелә.

Чишмә – әдәбияттә дә мәңгелек шигъри-романтик образ. Эдуард Касыймовның йөрәге, шул рәвешле, чишмә типкән урында туктавы да үзенә күрә бик мәгънәле-символик образ булып кабул ителә. Аның әсәрләре дә халык күңелендә туктаусыз чылтырап торыр, дип ышанырга кирәк.

Яшьләрнең әдип иҗатында пейзажның әһәмиятле урын тотуына игътибар итүләре очраклы түгелдер. Бу темага берничә реферат язылды. Әлеге бүлекчәдә фикерләр **Гөлшат Галиуллина, Ләйсән Гатауллина, Илнар Галиев** рефератларыннан китерелде.

Иң тылсымлы корал белән... Ниһаять, Эдуард Касыймовның публицистик осталыгының иң нечкә, иң катлаулы “сер”ләреннән берсе – ана теле белән эш итү үзенчәлегенә тукталырга да вакыт җитте. Нигезе документальлектән торган публицистлыкка да ана теле белән үзенчәлекле эш итү таләпләре куела микәнни, монда тел осталыгы турында уйлану зарурмы? Без бит инде публицистикада төгәллек-конкретлыкка ирешүнең төп чараларын барладык та шикелле.

Юк икән шул, барлап бетермәгәнбез икән, иң көчле, тәэсирле коралыбыз булып барыбер ана телебез кала икән. Э. Касыймовның

бәлки аларны үзенең коралына, бер-берсенә әләк (донос) коралына әйләндерә» (Казан утлары. 2011. № 8. 162–163 б.).

Менә нинди тирән, җәмгать тормышының иң борчыган, бөтен халыкка тынгы бирми торган хәлләре турындагы уйлануларга китерә әдипнең сүз-сурәт белән үтемле, тәэсирле образ тудыру осталыгы. Укучы мондый ачышларны әсәрне укыганда аның буеннан-буена ясый, шулай итеп үзен рухи баета килә.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ҖАН СУЛЫШЫ

Тел – халыкның җан сулышы.
Шамил Анак

Кайвакыт миннән “Шагыйрь дә түгелсең, әдәби тәнкыйть белән дә турыдан-туры шөгыльләнмисең бугай, ә нигә вакыт-вакыт шагыйрьләр иҗатына кагыласың?” дип сорыйлар. Әйе, төп темама – татар телен төрле даирәдә куллану мәсьәләләренә караган фәнни хезмәтләрем арасында күп кенә прозачы әдибебез рәтендә шагыйрьләребезнең, мәсәлән, Мифтахетдин Акмулла, Сибгат Хәким, Әнгам Атнабаев, Хәкимҗан Халиков, Рим Идиятуллин, Булат Сөләйманов һәм башкаларның иҗатын анализлаганнары да бар. Тел куллану осталыгы мәсьәләләрен ачыклаган фәнни эзләнүләрем-язмаларымда, уку әсбаплары – дәреслекләремдә Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Илдар Юзеев, Фәнис Яруллин, Зөлфәт, Рахмай Хисмәтулла, Разил Вәлиев һәм башка шагыйрьләрнең сөйләм үзенчәлекләрен ачыклаганмын, әсәрләреннән мисаллар китергәнмен. Анализ үзәге, әлбәттә инде, – әдипләребезнең шигърият осталыгы, анда да, иң беренче чиратта, тасвир, тәэсир итү чарасы буларак ана телебезне куллану, сөйләм оештыру маһирлыгы.

Өйрәнү объекты буларак нигә нәкъ менә шушы шагыйрь алынды, барысының да төп тәэсир чарасы-коралы – ул ана телебез бит, дигән сорауга җавабым мондый: теге-бу сөйләм төрен оештыру өчен телне куллануның гомуми кагыйдәләре, закончалыклары береккән булса да, гамәлдә сөйләм оештыру – ул һәр аерым очракта катлаулы, күп тармаклы, һәркайсыныкы үзенчәлекле. Беренчедән, тел дигән коралны куллану үзе күп яссылыклы, әйтик, бар сүзнең мәгънәсенә өстенлек бирүче, бар аның сөйләмдәге урынына, яңгырашына таләпчән; берәүсе конкрет фикерләүгә һәвәс, икенчесе метафорик фикерләүче. Икенчедән, телне кулланучы, ягъни әдип, шәхес буларак

та, иҗатчы буларак та ифрат катлаулы, төрле-төрле. Монда анализчының теге-бу әдип иҗатының үзенчәлекле бер ягына карата шәхси мөнәсәбәте булуы да әһәмиятледер. Әйтик, педагог буларак минем Сибгат Хәким сөйләменең һәркемне тартып тора торган йомшак, сабыр, киң сулышлы булуын, һәр сүзенең мәгънәсенә тач туры килүен, адәм баласы кичерә торган иң катлаулы хис-тойгыларны гади генә сүз-гыйбарәләр, ым-ишарә, өн чаралары белән әйтеп бирә ала торган, тәмле телле булуының серләрен ачып, шуны шәкертләремә дә җиткерәсе килүем сәбәпчедер. Моны булдыра алырмын, дигән ышаныч та бар, чөнки үзем дә Казан арты баласы. Нәселем Күлле Кимедән. Сибгат Хәкимнең якташы.

Иҗатын үзем анализлаган һәр шагыйрьгә шәхси мөнәсәбәтемне мин менә шушылай төшендереп бирә алам. Шул җөмләдән Шамил Анак иҗатына мөнәсәбәтемне дә. Нигә аның шигъри осталык үзенчәлеген анализларга алындым? Иң әүвәле, аның иҗаты белән кызыксынуның еллар үткән саен кимемәве. Илленче-алтмышынчы елларда яшь шагыйрьләр яңача ритм, рифма белән мавыгып киткән иде; бу күренешкә шигърият белгечләре генә түгел, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек чын шагыйрьләр дә сизгерлек күрсәтте; җәмәгатьчелек игътибары да кузгалды.

Арада Шамил Мәхмүтев (Анак) та бар иде. Мин Уфага күчеп, матбугат, әдәбият белән якыннан шөгыльләнергә тотынгач, үзе белән дә танышлык башлангач, аның иҗатына диккатем тагын да көчәйде; шигырьләрен даими укый бару, үзе белән дә аралашу мөмкинлеге артты. Беренче китабын бүләк тә иткән иде – укып тәэсирләнгәннән соң, язган һәр шигырен даими укый барып, яңаларын көтеп яшәүгә күнегелде. Аннан соң инде кире Казанга кайтып яшәп киткәч, әле Уфада, әле Казанда, әле Мәскәүдә очрашкалап торып, бик сирәк булса да әңгәмәләшеп алырга, шигырь, иҗат турында аның үз авызыннан кайбер фикерләр ишеткәләп торганга, вакыт-вакыт бәхәсләр дә кузгатып, Башкортстан – Татарстан мөнәсәбәтләре, төрки телләр бәйләнеше турында төрле сорауларны ачыкларга туры килде. Иң мөһиме: аның шигырьләренең үзгә бер тәэсире турында, моңа авторының нәкъ менә ана телебезне куллануга үзгә карашы, серләре барлыгын сиземләп, тоеп кызыксынудан туктамау, шул осталык тылсымын ачасы килү теләгенең беркайчан да сүнмәве анализ ясарга этәреп торды, кайбер нәтиҗәләргә дә киленде. Менә шулар шагыйрь-иҗатчыларга да, башлыча укучыларыбызга да ярап куяр, дип уйлап, бу язмага алынганмындыр да.

Аннары, Шамил Анак иҗаты әдәбиятчеләрнең, шагыйрьләрнең, әдәбият белгечләренең үзләренең дә игътибарыннан төшмәде бит. Ренат Харис, Тәлгат Галиуллин, Илдус Ахунҗанов, Әмир Мәхмүдев заманында аның шигъри феноменын ачарга омтылган җитди анализ ясадылар. Вакыт-вакыт шулар белән әңгәмә корып, бәхәсләшеп алу, әдип турында хакыйкатькә килү теләге дә кабынып торды. Шулар да бу язмага этәргәндер. Һәрхәлдә халык күңеленнән төшми килгән иҗат турында янә бер сөйләшеп алу ихтыяҗын канәгатьләндерү фарыздыр кебек тоела.

Һәр чын шагыйрьнең укучыны җәлеп иткән, тартып тора, мавыктыра, тәэсир итә торган үзенчәлеге – фикерләү, бәян итү, хис белдерү, тасвирлау алымнары булырга тиештер. Аны башкалардан аерып тора торган. Шунсыз ул шагыйрь дә була алмый, кешегә тәэсир дә итә алмый. Шамил Анакның шәхси иҗадый йөзе нидән гыйбарәт?

Үзебезнең төп “ачышларыбызны” бәян итә башлаганчы, моңарчы ачыкланган, белдерелгән фикерләрне искә төшерик. Ш. Анак шигъриятенең төп үзенчәлеге, асыл хәсияти сыйфатлары фәнни өйрәнелгән, хәтта энциклопедия дәрәҗәсендә танылган: “Анак әсәрләренең лирик героена рухи дөнья бөтенлеге, әхлакый максимализм хас. Анак хәзерге татар шигыре төзелешенә, аның җанрлары үсешенә сизелерлек йогынты ясый, татар һәм башкорт поэзиясенә верлибр (ирекле шигырь) формасын кертә, беренчеләрдән булып татар поэзиясендә сонетлар бәйләме булдыра, итальян терцинасын куллана, ода, касыйдә җанрларын яңарта, япон поэзиясендәге хайку һәм танка җанрларына назирәләр иҗат итә. Аның шигырьләре фәлсәфи уйлануларга бай, афоризм кебек яңгырый. Иҗатында еш кына новелла һәм шигъри проза формасына да мөрәҗәгать итә...” (Татар энциклопедиясе. 1 т. 161 б.).

Аңлашылса кирәк, Ш. Анак иҗатының үзенчәлеге шагыйрьнең шәхес буларак уйлау, хискә бирелү, тормыш-яшәешкә, дөньяга фәлсәфи карашы төсмерләреннән хасил була, күрәсең, “рухи дөнья бөтенлеге, әхлакый максимализм, фәлсәфи уйлануларга бай” дигәннәре шуңа кинаядер. Аннары, шигыренең корылышы-төзелеше, яңгырашы үзгә булуы игътибарга алынган: верлибр, сонет, терцина, ода, хайку, танка, назирә дигән төшенчә-терминнар башлыча әсәрнең төзелешенә карый бит.

Болар эчтәлекнең һәм форманың чыннан да үзенчәлекле икәнен раслый торган факторлар. Тик болар гомуми иҗатка караган бәяләмә, ә аерым шигырьнең үзенчәлеге нидән тора; иҗат, шигърият ул аерым

әсәрдән, строфалардан, тексттан, җөмлә, сүзләрдән тора бит. Аерым шигырь эчендә “рухи дөнья”, “фәлсәфи уйлану”, “верлибр”, “назирә” ничек белдерелә, бәян ителә?

Хәер, әдәбият нәзәриясеннән берникадәр хәбәрдәр кеше дә бу сораудан бөтенләй үк хәбәрсез түгелдер – шигъри фикер теләсә кайсы очракта бары тел чаралары (аваз, сүз, гыйбарә, җөмлә, текст) белән тукылган сөйләм белән бәян ителә. Сөйләм, дибез икән, димәк, монда телдән башка әле шагыйрьнең тавыш-өн, ым-ишарәләре, фикерне, хисне белдерә торган бүтән чаралары да искә алынырга тиеш. Димәк, Ш. Анакның шигъри осталыгының нигезе – аның сөйләме! Бары шулай гына. Димәк, Анак шигыренең дә әле икрар ителгән эчтәлек һәм форма рәвешләре, факторлары тик татар теле чаралары белән өретелгән сөйләмендә белдерелә.

Ш. Анак сөйләменең үзенчәлеге нидән гыйбарәт соң? Шагыйрь иҗатының, аның йөзенең асылын ачыкларга алынган белгечләргә менә шушы әсаси нигезне ап-ачык итеп тәгаенләргә, бәян итәргә кирәк тә иде. Югыйсә, энциклопедик сыйфатнамәдә афоризм төшенчә-терминын алмаганда турыдан-туры тел, сөйләм өлкәсенә, гыйлеменә караган төшенчә юк диярлек; барысы да шуңа кинаяле генә абстракт фәнни гыйбарәләр.

Бу сорауга тәгаенрәк җавап бәлки шагыйрь иҗатын махсус өйрәнгән белгечләр фикерендә ачыграк, төгәлрәк белдерелгәндер? Менә үзе дә шагыйрь, өстәвенә әле каләмдәшләре иҗатына бик игътибарлы, аларга фәнни анализ бирүдә тәҗрибә туплаган шагыйрь Ренат Харисның фикерләре (Юл өстендә кояш // Казан утлары. 1967. № 12. 127–132 б.). «“Гади әйберләр” дигән циклның логик төзелеше әнә шундый. Китапның калган биш циклы да нәкъ шулай төз логикага корылган һәм һәр цикл берсе-берсеннән үсеп чыга. Циклларның мондый төзелеше үзенә бертөрле сурәтләү чарасына әверелә, һәм бу чараның, сүз, рифма, ритм, аллитерация һәм башка әдәби чаралар кебек үк, мөһим, тормышчан икәнлеге күренеп тора... Укып үткән һәр шигырь үзенең ассоциатив җебен укучының күңеленә суза. Ул җепләрдән бер үк вакытта гади һәм катлаулы чигеш барлыкка килә... Образның фәлсәфи халәтен тулырак, тирәнрәк ачарга теләп, автор үз образларын, детальләрен икенче, өченче, унынчы шигырендә үстерә икән, бу тарлык билгесе түгел».

Монда да Ш. Анакның үзенчәлеге әдәби иҗат закончалыкларының нигез төшенчәләре: сурәтләү чаралары – әсәрнең төз логик төзелеше, рифма, ритм, аллитерация, ассоциатив җеп, тор-

мышчан, фәлсәфи халәт һ.б. төшенчәләре белән ачыкланырга тырышыла. Килешегез: болар да шигырьнең тулаем эчтәлегенә һәм төзелешенә (формасына) караган, ягъни барлык шагыйрьләргә дә, тулаем шигъриятькә караган гомуми тезис-сыйфатлар.

Аңлыйм мин: әле саналган үзенчәлекләрне, әйтик образның фәлсәфи хәләтен тулырак итеп тик тел чаралары белән генә бирергә мөмкин. Детальләрне, образларны үстерү дә тел белән генә мөмкин. Автор бәлки "шулай булгач, үзәктә тел һәм сөйләм икәнен тәкърарлап торасы да юк", дип уйлыйдыр. Килешмәскә рөхсәт итегез, тезисны бит бик анык дәлилләр белән исбат итәргә кирәк, гомуми, абстракт гыйбарәләр белән түгел. Бу очракта үзәккә Ш. Анакның сөйләм рәвешен куеп кына.

Шөкер, шигърият хәсиятен төпле белүче галим Тәлгат Галиуллин ("Тыйнак табын"га кил, укучы! // Казан утлары. 1983. № 11. 141–144 б.) Анак шигърияте серенең нәкъ менә телгә – шагыйрьнең сөйләменә турыдан-туры бәйле булуын аңлатуга якыная кебек. "...Ул үз-үзенә тугрылыклы: гадилектән шигърият таба, табигать матурлыгын рәссамнарча, каударланмыйча, ашыкмыйча, тәфсилләп тәсбихка тезә. Өлгереп килгән кырлар, тугайлар матурлыгы, күзне чагылдырырлык аклык, пакълек, пөхтәлек, "бәйрәм көндә ак күлмәк кигәндәй – җылы ихтирам", "җан-тән белән бирелеп сөйгәндәй – кешелекле ихтирам", ихлас күңел, саф вөҗдан болар барысы да аның поэзиясенең нигез ташлары, илһам чыганагы".

Галим шигырьне сөйләм төшенчәсе белән күзаллый: "...сөйләм эзлекле фабула канвасы белән бара. Шигырь белән проза арасындагы чик, киртә бөтенләй югала, фикер агышы, зиһен уены сине үз артыннан ияртеп китә. Җитмәсә, әсәргә еш кына, драмага хас, шигырьнең классик кануннарына баш бирмәгән диалоглар килеп керә... Ш. Анакның уңышлы әсәрләрен укыганда, сәнгать законнары турында уйламыйсың. Шагыйрьнең тынгысыз уе, үз тормышы, үз язмышы турында ачыктан-ачык, яшермичә сөйләве, импульсив, хәрәкәтчән, интеллектуаль фикере, кадрларны көтелмәгән яклары белән, экспрессив чаралар ярдәмендә яңача, үзенчә үзгәртә, алыштыра, яңарта белүе, комдагы алтын кебек, ялтырап киткән нәфис бизәкләр, анафора, ялгау, цезураны һич көтмәгәндә бүлү, өзү, авазлар тәңгәллеге сокландыра, уйландыра, гаҗәпләндерә. Күзәтү, деталь, төсмер, төс, ис, фикер агышына, идеягә буйсына... Ш. Анак шигыренең көче, җегәре образлылыкта, тормыштан алынган детальләрдә...".

Әйе, болар инде Ш. Анакның шигъри сөйләме үзенчәлекләрен ачыкларга, бәяләргә омтылган күзәтү-фикерләр. Алардан без бу сыйфатларга шагыйрь ана телебез белән оста эш итеп кенә ирешә ала, бары тик тел чаралары белән генә, сөйләмдә генә, дигән нәтиҗә ясый алабыз. Тик галим бу нәтиҗәне үзе үк ап-ачык итеп безгә җиткерә алган булыр иде бит, моның тәэсире, дәлил көче күпкә өстен булган булыр иде.

Мондый өстенлекне икенче бер әдәбият белгече Илдус Ахунҗанов кулдан ычкындырмаган (Үзенчәлекле шигърият // Казан утлары. 1983. № 11. 144–148 б.). Ул Анакның шигъри сөйләменә турыдан-туры якын килә, бу сөйләмнең асылын аңлатырга омтылыш ясый: "...сәнгать дөньясы белән фән дөньясы арасындагы зур аерманы ныклап аңлап алгандыр Шамил Анак. Сәнгатьтә, әдәбияттә бит шундый уникаль үзенчәлек бар: анда тормыш бүлгәләнмичә, өлешләргә таркалмыйча өйрәнелә, шулай тере хәлендә сурәтләнә һәм карала. Фәнни фикерләү исә өлешләргә бүлүне, төгәл логиканы һәм абстракт уйлауны таләп итә. Ә җанлы тормыш һәм аны чагылдыручы әдәбият-сәнгать дөньясы законнарга гына сыеп бетәме соң?!! Юк, әлбәттә. Әдәбият теле, поэзия теле ул – киң колачлырак һәм тулырак! ...(Шамилчә) әдәбиятнең, сәнгатьнең максаты – икенче бер шартлы тормыш хасил итү, тудыру. Шигърият дип алганда исә, сүз ярдәмендә яши һәм ачыла торган шартлы дөнья тудыру...". Диккать итик*: сүз ярдәмендә!*

Илдус Ахунҗановның бу язмасында гомумән дә шигъри сөйләм нәзәриясенә нигез әсасы булырдай бер фикер бар: "Шагыйрьнең үзенчәлеген аңлар өчен, аның теләк, хисләре белән теләктәш, хистәш булсын өчен укучы үзе дә шуңа әзер булырга тиеш. ...Әлеге сәнгатьле һәм шартлы сүзләрдәге яшәүнең югары культуралы укучы күңеле белән очрашуы кирәк, нечкә һәм тирән бәйләнеше кирәк...

...Аның әсәрләренең тулы яшәеше хасил булсын өчен укучы күңеленең үзенең бай һәм тирән булуы, югары культуралы булуы гаять мөһим".

Шушындый җитди искәрмә белән без төп максатыбызга – Шамил Анакның шигъри сөйләме асылын ачыклауга күчик.

Аңлашыла булса кирәк, мондый темага фикер алышу өчен башта аның, кем әйтмешли, матди нигезе булу мотлактыр. Сөйләм барлыкка китерү өчен Шамил Анакның беренчел чыганагы – тел "байлыгы" нидән гыйбарәт булган? Андый байлык туплансын өчен адәм баласына иң әүвәл тел тоемлавы дигән сәләт сорала, аннары шул

сәләт белән тупланган тел байлыгыңны эшкә җигү, ягъни сөйләм кору һәвәслеге. Шөкер, Шамил абыйга бу сәләт татар каны, ана сөте белән бирелгән. Саф татарча аралаша торган төбәктә – Башкортстанның Әлшәй районы Габдрәхим авылында туып үскән, татар мәктәбендә укыган, шушы төбәктән чыккан саф татар әдипләре Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Гайнан Әмири, Сәйфи Кудаш, Мирсәй Әмир әсәрләрен укып ләззәтләнгән Шамил әби-бабайлары, әти-әниләре аралашып яшәгән, борын-борыннан төрле төрки халыклар сөйләшләре белән чигелеп, бай сүз келәме тәшкил иткән тел хәзинәсенә бик игътибарлы булган – күпме сүз, гыйбарә тупланган аның хәзинә сандыгында. Гомере буе ул шушы хәзинә мөмкинлекләрен, ана теленең халык рухын саклаган аһәңен, көч-куәтен аралашуда булсын, әдәби әсәрләр язуда булсын ничек тә мул-рак файдаланырга омтыла.

Язмыш аңарга бу хәзинәне өстәгәннән-өсти бару мөмкинлеген дә бирә: Татарстан белән, аның иҗатчылары, тел белгечләре белән тыгызрак аралашып китә, Мәскәү уку йортларында төрки телле даирә, тел белгечләре белән аралашу җаен таба. Төрекнең атаклы шагыйре Назыйм Хикмәт белән танышып, аның әсәрләрен чын про-фессионалларча тәрҗемә иҗатына керешеп китә. Гомумән дә, тәрҗемә эшчәнлеге аның тормыш тәҗрибәсен дә, телләрне өйрәнү кысаларын да киңәйтә – телләрне чагыштырып, ана теленең яңадан-яңа мөмкинлекләрен, бигрәк тә сурәт ясау сәләтен ачуга ирешә бара. Чех һәм башка телләрдә аралаша, Прага университетында, Мәскәү югары уку йортларында укыта – болар барысы да аңарга сөйләмен баету файдасына...

Иҗат барышында ул, шагыйрь буларак, бердәнбер коралы сүз икәненә тәмам төшенә. Кешегә тәэсир итү, хис белдерү өчен сүзнең хәрәкәттәге егәрен акылың белән генә түгел, җаның-күңелең белән тойганда гына мөмкин икәнен аңлый. Һәр сүзнең көчен, гайрәтен, сурәт мөмкинлекләрен ачык тоемларга омтыла, моның өчен сүзләрне бер-берсе белән чагыштырып, кешеләргә тәкъдим итеп карап, ба-шындагы-күңелендәге "сүз лабораториясендә" сынап, тәҗрибә үткәреп, энәсеннән-җебенә кадәр "җиз иләктән или".

Төп коралы – ана теленең эчке хәсиятен төшенүдә Ш. Анакның шушындый иҗади тәҗрибәсенә мондый югары бәя бирергә минем хакым бармы? Укучым моны язманың азагында үзе бәяләр. Ә әлегә кереш сүз сыйфатында, дәлил дә булсын дип, шагыйрьнең тел хакын-да әйткән афоризмнарын санап кына китәм:

Тел – халыкның җан сулышы.

Тел бар икән, яши икән – халык та бар, халык та яши.

Тел аралашу, аңлашу чарасы гына түгел ул, тел – иң беренче нәүбәттә, халыкның рухи байлыгын, меңнәрчә еллык тәҗрибәсен җыйган бетмәс хәзинә.

Сүзләр – кодрәтле тел агачының мәңге яшел, мәңге яшь яфраклары.

Тел – милләтне милләт иткән иң беренче шарт.

Ватан, җир киткәндә дә, тел, кан кала.

Тел белән кан киткәндә, ватан, җир калса да, милләт китә.

Бөек дастаннар теле, бөек шагыйрьләр теле, моңлы җырлар теле, телләр арасында мәгърур тел, туган телем, синдә беренче кешелек сүземне әйттем һәм җирдән киткәндә соңгы хушлашу сүзләрен дә синдә әйтсәм иде!

Менә шагыйрьнең ана теленә карата фикере, кыйбласы, ышанычтаянычы, өмете. Аны куллану үзенчәлекләрен менә шушы кыйбладан ачык күзалларга була. Безнең фикер агышыбыз, дәлил һәм нәтиҗәләребез дә шушылардан килеп чыга.

Адәм баласы ике үзәкле бит: акыл һәм хистән яралган. Гәрчә шагыйрьне күбрәк хис белгече, хис остасы, дисәләр дә, аның фәлсәфәсе барыбер акылга һәм хискә таяна. Ике үзәк тә сүз белән белдерелә: туры мәгънәле һәм дә күчерелмә мәгънәле берәмлекләр белән. Шагыйрь ике төркемне дә мулдан белергә, аларның сөйләм оештыру мөмкинлекләрен нечкә үзләштергән булырга тиеш. Шагыйрьгә сүзләрнең мәгънә төгәллеген аеруча яхшы белергә, бик тә нечкә тоемларга һәм сиземләргә кирәк. Ш. Анакта сүзнең мәгънәви һәм хисси төсмер-ньюансларын тоемлау ифрат көчле. Бер сүз аның өчен – үзе бер дөнья. Лексик чараларның барлык төрләренә дә игътибарлы, “үгисетелгән” яисә “үз күргән” сүзләре юк. Шулай да аңарга бигрәк тә сурәт, образ ясау сәләте, куәсе булган берәмлекләр якын.

Ш. Анак лексиконының нигез ташларын бик конкрет мәгънәле гомуми (битараф) сүзләр тәшкил итә: *өй, оя, кеше, ут, җир, йорт, дөнья...* Арада атама, термин саналган бик төгәл мәгънәле берәмлекләр дә бар: *Кояш, Ай, Эстәрле юлы, Дим елгасы, Хәсән Туфан, Марина Цветаева, Сабрия әби, Әхмәт кызы Хәтимә, Моабит, Переделкино, Хиросима, Прага, Швейк...* Абстракт мәгънәле берәмлекләр: *бәрәкәт, вакыт, өмет, мәхәббәт, тантана...* Хис белдерүче сүзләр*: йомшак, моңсу, ярсу, юксыну...*

Нигә кирәк шагыйрьгә сүзнең мәгънәви һәм хисси төсмерләрен, мөмкинлекләрен шулай нечкә күзаллау, сизгер тоемлау (күрү, ишетү)? Шагыйрь иң башта дөньяга, яшәешкә, кешегә, аның гамәлләренә карата фәлсәфи фикер йөртә. Дөнья тоткан борыңгы, цивилизацияле-мәдәниятле халыклар фәлсәфи фикерле, димәк ки, шушы фәлсәфи

төшенчә, уй-фикерләрне белдерергә, аңлатырга, тасвирларга сәләтле теле булган халыклар. Татар шундый халык. Халыкның шушындый сәләтен, асылын белдерә торган сүзләр Ш. Анак "хәзинәи сандыгында" да бихисап: *галәм, бәхет, дөнья, моң, рух, күңел, хыял, хәйлә, язмыш, өмет...* Әйтик, яшәешнең төп законы бит ул – көрәш, ягъни каршылыкны җиңү. Татарның каршылык төшенчәсен ап-ачык, төгәл итеп бәян итә, тасвирлый торган сүзләре – шагыйрьгә зур табыш инде*: якты – караңгы, уңай – тискәре, ак – кара, көн – төн, яшәү – үлем...*

Кыскартып әйткәндә, фәлсәфи фикер йөртү өчен Анак телебезнең бөтен байлыгыннан файдалана, без әле искә алган туры мәгънәле берәмлекләрне дә, күчерелмә мәгънәлеләрен, битарафларын да. Ул һәр сүзнең хәсиятен тоя, бу хакта уйлый. Шигырьнең үзендә дә ул бу уйларын белдереп куя, укучы белән фикерләшә: *"Төндә* килә *яман* кунак, // *Төндә* килә *яман* хәбәр, // Әйтелә *"талак"* сүзе"...

Сүзнең көчен бик нечкә белгәнгә, ул, ихтыяҗ туганда, үзе дә яңа сүз (неологизм) ясаргә җөрьят итә. Берничә генә мисал: *Күчәбәлек*; *Юаныилмас* бу сагышта юындым мин лимон сарысы белән. Бу иҗади процесста ул татар теленең иң нечкә асыл үзенчәлекләрен тоемлавын күрсәтә. Мәсәлән, ялганмалык үзенчәлеген – кушымчалар да бездә хис белдерү, метафора ясау сәләтенә ия; парлы сүзләр дә татарның иң "милли" үз берәмлекләреннән: "Яшәү үзе // *очсыз-соңсыз* бау түгел"...

Күрдек ки, гәрчә фәндә шагыйрь күчерелмә мәгънәлелеккә, ягъни сурәт тудыру чараларына өстенлек бирергә тиеш, дигән закончалык яшәп ятса да, Ш. Анак ана теленең һәр энҗе бөртегенә газиз нәрсә итеп караган. Әле генә без Ш. Анакның ана телебез турында афоризмнарын бәян иттек. Анда менә мондый мисаллар да бар: *"Тел – милләтне милләт иткән иң беренче шарт".* Күрегез: афоризм туры мәгънәле берәмлекләрдән оешкан. Ә менә икенче гыйбарә: *"Тел – халыкның җан сулышы"* – монысы инде күчерелмә мәгънәле метафора, телбизәк белән оешкан афоризм. Хәер, менә шушы факт белән без әңгәмәбезнең яңа юнәлешен куертып җибәрербез дә.

Тел бит шагыйрьгә иң әүвәле шигъри сөйләменең төп максатын гамәлгә ашыру өчен кирәк: әйтергә теләгән фикерен сурәтләп, тасвирлап, образ тудырып җиткерү, үткәзү өчен. Шагыйрьдә бу сәләт – табигатьтән. Мондый мөмкинлек шагыйрьгә генә бирелә, аннан теләсә кем файдалана да алмый. Сөбханалла, Шамил Анакның сүздән сурәт ясау таланты чыннан да сокландыргыч, гаҗәпләндергеч. Ул татар телендә мәгънә белдерә торган нинди сүз бар, барысын да образ тудырырга җәлеп итә ала. Без әле генә санап киткән иң туры мәгънәле, бита-

раф, гап-гади көндәлек сүзләр дә образ ясау чарасы буларак та кулланылган. *Кояш, ай, көн, төн, ипи, агач, чәчәк, су, кар* һ.б. кебекләрен әйтеп торасы да юк, алар туры мәгънәле чын нәрсәләр буларак та, образ максатында сурәт ясау чарасы буларак та бер үк дәрәҗәдә, бер үк бәядә кулланылалар. Теге-бу күренешкә укучы игътибарын көчлерәк тартып алу, җәлеп итү, уйландыру, хискә урату өчен һәр мәгънәле сүздән образ-сурәт ясауны ул иҗади гадәткә әйләндергән. Теләсә кайсы сүздән сурәт ясый ала. Ә бит аның аңында яшәгән сүз укучыга таныш та булмавы ихтимал. Мәсәлән, Татарстан яисә Уфа укучысына. Әйтик, аның сөйләменә нәселдән, җирле халыктан яисә халык иҗаты әсәреннән сеңеп калган үзгә сүз, гыйбарә, канатлы сүз шигырьгә төште ди. Булса соң! Укыган кеше аның мәгънәсен ничек тә аңлар, иң мөһиме аның күңеле тибрәнеп куйсын, хисе уянып, аны ниндидер хәрәкәткә этәрсен. Шагыйрьнең изге максаты шул бит!

Әйтик, бүгенге укучы сөйләмендә шактый пассивлашкан, сирәк очрый торган яисә диалектизм берәмлек. Ә әсәр тукымасында ул барыбер образ буларак күзаллана, тәэсир тудыра: "Әчкелт тәмле дала *емшаны"; "мотлак* имән бармагы белән"; "хәтта картлар *мыжуы* ала алмый *мазамны";* "яллары *көпшәк* күбек"; "ерак *әбкәләре";* "күңел барсын *яд итә"* һ.б. Аерым торган яисә аерым тезмәдә ачык кына аңлашылмый кебек, тик текстны эзләп табып укыганда һәр сүз үзенә бер сурәт, манзара булып күз алдына килеп баса. Менә тагын бер тәлгәш бүгенге сөйләмдә пассиврак берәмлекләр: *шык, ышык, сан, җисем, терәк* һ.б. Бик томанлы сүзләр, мәгънәсен ачыклар өчен сүзлеккә карарга яисә өлкәннәрдән сорарга кирәк. Ә менә шигырьне укыганда бернинди сорау яисә шик калмый, күңелне тартып, биләп алган хисле бербөтен рәхәт биреп күңелгә сеңеп, йотылып китә.

Өйсез – // кеше утсыз, *ышыксыз*, // оясы юк, тормышы *шыксыз* (Өен сакласа, җирен дә саклый кеше).

Җирсез – // кеше көчсез, *терәк*сез, // тамыры юк, яуда йөрәксез (Җирен сакласа, өен дә саклый кеше).

Илсез – кеше *сансыз*, исемсез, // шәүлә кебек, җансыз, *җисем*сез, (Ни өмете, ни сөюе, ни эше).

Йорт, Җир, Ватан – // шулай булса гына, кеше бит кеше.

Күрәбез, тоябыз ки, телнең теләсә кайсы берәмлеге сурәт була ала икән, тик бу әле шагыйрь аларны эзләми, ала да куя, уйланмый, дигәнне аңлатмый. Ничек кенә эзли, уйлана, борчыла әле! Күз алдына китерү, сурәт, образ – шагыйрьнең төп максаты, бу максатка ирешү өчен тасвир чаралары табу үзенә бер фәлсәфә, үзенә бер фән. Бу

фәнне барлыкка китерүдә, яшәтүдә, камилләштерүдә шагыйрь Ш. Анакның да өлеше зурдан.

Татар теленең һәр берәмлеге күчерелмә мәгънә алу сәләтенә ия булу өстенә әле күчерелмә мәгънәсе берегеп, махсус сурәт (образ) вазыйфасын алган берәмлекләре үзенә бер катлам булып аерылып чыга. Болар троп, метафора, перефразлар, фразеологик берәмлекләр, канатлы гыйбарә, афоризмнар, Нәкый Исәнбәт атаганча, телбизәкләр. Шамил Анак шуларны куллану остасы.

Троп барлыкка килү битараф мәгънәле сүзләрнең күчерелмә мәгънә алуыннан башлана. Бу – татар сүзенең могҗизасы. Менә Анак шигырьләреннән дә берничә генә мисал: “Яңа юллар эзләп без *баш ватабыз,* // гомер бакый “матурлык”! дип *җан атабыз*”; “бөек хыяллар белән яшибез *янып”...* Һәркайсы үзенә бер сурәт: *“Рәхәт җебеп* язгы җир ята”; “бодай бөртекләре кебек *точ,* авыр”; “*тасма сүзләр* түкмичә”; *мәет җыйганда* һ.б.

Шагыйрь күчерелмә мәгънәлелекне башлыча чагыштыру чарасы буларак куллана. Чагыштырып сурәт ясый. Һәр эпитет – үзе бер рәсем, манзара: *томанлы вәгъдә; тонык елмаю; дымлы караш; шомлы шытырдау; кара шәүлә; тынсу җиләслек; чыклы яфрак; тар сукмак; саф чишмә; куркак болан; якты, җиңел күләгәң; йолдызлы сәгать; кара кайгы; язгыча киенгән кызлар; ак сәгать, йолдызлы сүзләр; сары сагыш яфраклары; ялгызлык йөге.*

Ш. Анакта эпитетлар рәте дигән көчле бер тасвир чарасы бар: менә җирдәге мәхәббәт сыйфатлары: *иң илаһи, иң гүзәл, иң олы, иң горур* яисә җил ничек сынландырыла, кешеләштерелә: *хәтерсез, узгынчы, тугрылыкны белми, назлары бер мизгеллек, сукырларча саксыз, куркак дигән даны юк, җисемсез, җылы каны юк, аермый яхшыяманны, шәфкать белмәс.*

Чын эпитетлар арасында туры мәгънәле тезмә дә очрый *(чыклы яфрак, куркак болан),* сурәтле фикер сөйләмендә алар да сурәтле эпитет кебек кабул ителә, хисләндерә.

Күчерелмә мәгънәле тезмәләр халык сөйләмендә еллар, гасырлар буе кабатланып, береккән тезмәләргә – идиомаларга әверелә. Анакта болар бихисап: ике төркемгә аерырга була; халык сөйләмендә кулланылганча, үз рәвешләрендә, үзгәртелмичә алына яисә эчтәлеккә өстәмә төсмер биреп, рәвешен дә бераз үзгәртеп алына.

Икенче зур бер төркем троплар – шагыйрь үзе “ясаган” тезмәләр, шәхси афоризмнар, канатлы гыйбарәләр. Юкка гына аны энциклопедиядә афоризм остасы дип билгеләмәгәннәр. Беренчедән ул

халык афоризмнарына, фразеологизм, мәкаль, әйтемнәргә бик сизгер, аларның образ сәләтен нечкә тоя, нәкъ урынында файдалана белә. Алар шигырь саен диярлек. Ул аларны ата-бабасыннан җыйган, хәтерендә саклаган: *Кунак ул – алладан; Алла бер ул, телгә карамый* һ.б. Әйтик, “Иртә”, “Өйлә”, “Кич”, “Төн” шигырьләренә эпиграф итеп китерелгән “Борыңгылар сүз”ләреннән тәэсирләнеп, аларны үземнең “Телбизәк сүзлеге”мә теркәп куйдым да, шигырьләрен укый башлагач, теркәүне дәвам иттерергә туры килде – һәр строфа, һәр гыйбарә афоризм иде. Бөтен шигырь тулаем афоризмнан тора булып чыкты. *“Иртә – көннең якты, ак чагы”* дигән беренче строфасыннан *“Иртән кеше икмәкле. Иртә кичтән хикмәтле”* дигән соңгы строфага кадәр бер сулыш белән укылды.

Үзе иҗат иткән троплар исә гади генә канатлы сүздән башлана: “Ярда *чук тал*ларны юып, Ока суы ага тын гына”. Яисә телдә булган телбизәкне үз сөйләменә яраклаштыра: “Эшләргә җирдә – батып *җиде кат тиргә”; “Күрәселәр күрелгән”; “Эре ярып гайбәт борчагын”; “*Яу-чирләрдән имин калган картлар // бер дә бер көн *эчәләр әҗәл суын”; “Йөрәгем сөеп туймаган әле”.*

Шагыйрьнең метафорага сәләте үскәннән-үсә бара. Аның канатлы гыйбарәләре эчтәлеге ягыннан да, төзелеше-формасы белән дә халыкчан мәкаль, әйтемнәргә тарта бара. *Дөреслек – бер, ә ялганнар һәркемнеке үзенә башка; чын шигырь – хис тамчысы; сагышсыз белеп булмый шатлыкларның татын да; кошлар бит туган илгә кайткач кына җырлыйлар; дала чикләре биксез; таулар түгел, урман – җирнең яшел калканы; ялан күз булса, урман колак; кешеләрнең күңеле – яхшылык яши торган урын; кешене мөмкин үтерергә, елмаюны мөмкин түгел; җиргә яшәр өчен килгәннәр үлем эзләми җирдә; кеше генә көлә белә. Көлү – кешенең кешелек байрагы, ирек байрагы; әйберләр кол итә кешене; үлән үзенең түбәнчелеге белән олы* һ.б.

Телбизәкне шагыйрь һәр мәгънәле һәм хисси берәмлек кебек тере итеп хис итә. Сүзнең мәктәптә өйрәткән кебек мәгънәдәш кардәшләре (синонимнар), охшаш мәгънәдәшләре (омоним, пароним), каршы мәгънәдәшләре (антоним) булган кебек, телбизәкләрнең дә йә үзара, йә туры мәгънәле берәмлекләргә тиңдәшләрен, охшашларын, каршыдашларын табарга була. Шигырьдә мәгънә тәңгәллегенә ирешү, аеруча хис төсмерләрен төгәл бирү өчен болардан да файдалану уңышлы килеп чыга. Менә мисал: “Куллар инде *ял* сорый. // *Ару* охшый нәкъ өлгергән җимешкә”. *Ару* (алҗу) белән *ял* каршылык белдерә (антонимнар) кебек. Шул ук вакытта бу очракта ару ялга

сәбәпче булганга уңай төсмергә лаек бит. Нечкә күңелле шагыйрь шуны тоемлап, аруга уңай сыйфат (өлгергән җимеш) бирә. Югыйсә, безнең сөйләмдә аруга тискәре, караңгы охшатулар күбрәктер (эт булып арыдым һ.б.). Гомумән дә Ш. Анак оксюморон күренешен бик нечкә тоемлый, татар теленең бу көчле тасвир чарасыннан оста файдалана: “Бу сәгатьнең сагышы – иң *якты сагыш”.* Янә бер мисал – безгә иң караңгы, иң шомлы җисем *төн* дә анық фикерләвенчә ике яклы: “Төндә килә *яман* кунак; Төндә килә *яман* хәбәр”. Шул ук вакытта: “Төн катында иң изге – *аналарның догасы”; “*Иртән туар бу *тормыш башлана* төн сагында”.

Сизәмсез, текст агышында без тел төшенчәсе белән сөйләм төшенчәсен урыны-урыны белән бер мәгънәдә кулланып барабыз, гәрчә алар бер-берсеннән нык аерыла. Сөйләм дигәндә без фикерне белдергәндә тел чараларыннан тыш тавыш, хәрәкәт, мөхиттә катнашкан күрү, тыңлау, ишетү, төс күренешләрен дә сизәбез, күрәбез, тоябыз. Шагыйрь инде аларны конкрет бер манзараны әйтеп бирү, вакыйганы бәян итү өчен генә түгел, әлеге дә баягы шул тасвирлау, сурәтләү, сынландыру, хисләндерү максатында да куллануга сәләтле. Шул телдән тыш чараларны (фәндә экстралингвистик, паралингвистик чаралар дип атала) шагыйрьнең төп коралларыннан берсе буларак ничек-ничек кулланылуына кыскача гына булса да тукталып китү зарурдыр.

Тавыш. Шагыйрь иҗатында без буйдан-буйга тавышны “ишетеп” торабыз. Кеше тавышын. Яшәештәге, табигатьтәге төрледән-төрле тавышларны. Ул *тавыш* сүзе белән дә (Урман җыры мең *тавышлы* // иртән шат, кичен сагышлы), бүтән контекстуаль синонимнар, вариантлар белән дә белдерелә: “Кайчак ул *гүли* ачу белән, // ә кайчак – *зарлана, елый...*”; “Урман сизгер // *аваз кайтара”; “*Йолдызлар *кычкыра”.*

Шагыйрь әсәрләрендә тавыш төшенчәсенә тартым сүзләр арасында *өн* аеруча еш күренә. Өн нәрсә ул? Таныш сүз дә үзе, тик көндәлек сөйләмебездә еш ишетелми. Сүзлектә болай диелгән: 1) Чынбарлык, реальлек. Төш түгел, хыял түгел, саташу түгел. “*Өнемме бу, төшемме?*”... 3) Нинди дә булса тавыш, аваз. *Ишетелде һавада аккаш өне.* Дәрдмәнд. *Өнең чыкмасын*!

Ш. Анактан мисаллар:

Чыгам да төнгә, сөйләшәм тынлык белән –
тынлык кебек тын гына, *өнсез* генә;
Ни турында сөйли төн тирәнлеге *өнсез?*
Төндә йолдызлар гына кычкыра өзлексез.

Аңлармынмы мин аларның *өнсез телләрен?*

Күрәбез ки, шагыйрь иң башта өнне тавыш белән мәгнәдәш итеп аңлый. Янәшә (мәгънәдәш) төшенчәләр: *тынлык – өнсез.* Шулай да *өн* тавышка караганда предметсызрак, димме. Бер шигырендә ул күреп, ишетеп, аңлап булмаган нәрсәләрне барлый. Арада *йолдыз өне* бар. Ә бер шигырендә *йолдызлар кычкыра* дигән иде.

Шулай да шигырь сөйләме дигәндә без шагыйрьнең әлеге төшенчәләрне (тавыш, өн) нәкъ менә сурәт ясау чарасы буларак куллану нечкәлекләренә күбрәк диккать бирәбез. Күрдек ки: сүздән сурәт ясап була, ә тавыштан буламы? Сорауның мәгънәсез икәнен инде мисаллардан күрдек бит. Менә тагын берсе: бик диккать белән укыгыз... әй, юк ла, тыңлагыз әле: “Яңгырның *шыпыртын тавышы* җаннарга үтеп керә // һәм хыянәтчел *пышылдый*: “Онытъ, оныт, оныт!”. Янә дә тыңлыйк. Әйе, тавыш ул сурәт, дигән хакыйкатькә ышанганнан-ышана барабыз түгелме?! Шагыйрь аларны нәкъ шул максатта да еш куллана. *Уйный* оркестр, *укси* саксофон, *елый* гитара. “Агачлар нидер сөйли *шыпырт кына...”; “*Бәлки *йомшак шыбырдап* яфраклар // назлы *сүз әйтмәк* буладыр”; “Бәлки, урман шәрә ботакларның *ыңгырашы* белән туладыр?”. Кошларның *шомлы* тавышы һ.б.

Шагыйрьчә сурәтләү, образ тудыру максатыннан Анак, әйтик, табигатьтә мөмкин булмаган нәрсәләрне барлый: ташларның *телгә килүе, кошларның көлүе, өн шәүләсе...*

Шушында тын алганда минем шигърият сөйләмен өйрәнүче белгечләр белән киңәшләшеп аласым килә: шәхсән үзем Шамил абыйның халык алдында, тамашага дип шигырь укыганын ишеткәнен-күргәнем булмады. Болай аралашканда, редакцияләрдә шигырь турында сүз чыгып, мисаллар китергәндә өзекләр, фразалар әйткәнен хәтерлим, анда ул күбрәк шигырьнең эчтәлегенә, формасына кагылган фикерләрен белдерә, сүзләр турында бәхәсләшкәндә теге-бу сүзнең яңгырашыннан бигрәк кайдан алынуын, тарихи этимологиясен төшендергәне истә. Хәзер менә уйлыйм: әлбәттә, ул, һәр шигырен кәгазьгә төшергәнче, аны эчтән әйтми калмагандыр, тавышның, өннең, моң-көйнең эчке хәсиятен тоеп, язуга төшергәндә интонация дигән сурәт чарасының мөмкинлекләрен укучыга да җиткерү хәстәрен күргәндер. Шунсыз ул үзен шагыйрь дип йөртмәс иде.

Шулай да, шулай да... Шигырьне ул нигездә сөйләр өчен түгел, ә укыр өчен язгандыр кебек тоела. Ирекле формадагы шигырьне сөйләве шактый авыр бит. Ә татарның китапны көйләп укуы аның канында, ә көйләп укыла торган китаплары аның тезмә формада, ягъ-

ни шигырь каннуннарына буйсынып языла. Ш. Анак бу хакыйкатьне нигәдер вакыт-вакыт “оныта”. Мәсәлән, шактый шигырендә адым саен *һәм* сүзенә абынам; йотылып укып килгәндә, кантарга сөрлеккән кебек, шул мәгънәсез сүзгә киләм дә сөртенәм. Күпчелегендә бу “кантарның” шигырь эчтәлегенә бөтенләй дә кагылышы юк (ул бит татар сүзе дә түгел, бу мәгънәне татар *белән, берлән, илә, вә* сүзләре белән белдерә). Әйтмә сөйләмдә *һәм* тын белән, сулыш (пауза) белән белдерелә. Язуда аның бөтенләй кирәге юк; тыныш билгеләре белән белдереп була. “Хәтерлим бөтен мин сөйгән *һәм* мине сөйгән хатыннарны”... шигырендә алты *һәм*. Әйтмәдә берсенә дә ихтыяҗ юк.

Тавыш, өн төшенчәләре әйтү-ишетү күренешләреннән дә аерылгысыз. Ә бу төшенчә-категорияләр шагыйрь сөйләмендә әһәмиятле урын били. *Әйтү* сүзе һәм төшенчәсе үзе үк мәгънәле дә, хисле дә санала: “Нинди *җиңел, шат* әйтелә бу “гомергә!” сүзе // беренче сөю антында һәм нинди *авыр* яңгырый ул соңгы хушлашуда”. Монысы – кешенең әйтүе. Шагыйрь табигать “әйтүен” дә еш, тәэсирле куллана: “Үләннәрнең бардыр без белмәгән *теле,* // һәм яфраклар, сабый кебек, елый-көләдер; хәрәкәтсез йолдызлар гүя *кычкырган* сыман безгә: – Кем сез? // Тик без аңламыйбыз аларның сүзсез, сәер *телләрен.* Ни турында кычкыралар алар *өнсез”.*

Өн бу очракта тавыш түгел, ә мәгънәле сүз, сөйләм. Ш. Анак шигъриятендә *өн* еш очрый. Нәрсәне аңлата ул? Гомумән дә шагыйребез сөйләмендә *тел, сөйләм, өн, сүз* төшенчәләренең катлаулы гына фәлсәфи мәгънә төсмерләрен бирү өчен куллануын күзәтеп, уйланып алу мәслихәттер.

Тел белми дип кошлар-хайваннар // ник без инанганбыз шулкадәр?
Каян килә “диңгездә балыклар // *өнсез* йөзә “ дигән буш хәбәр?
Кайчак тоела миңа: гүяки // яфрак-үлән *телен* мин беләм.
Өйрәнсәң иде шулай сөйләргә –
эйтерсең эндәшмисең.
Өйрәнсәң иде шулай эндәшмәскә –
эйтерсең сөйлисең.
Өйрәнсәң иде иң бөек сәнгатькә –
сүз ирке сәнгатенә.
Уйга баткан, ул *өнсез...*
Өнсезлегендә – зур мәгънә...

Төннең иң тын сәгатендә, пышылдау шикелле, // чак-чак ишетелгән *өннәр* килә колакка. Бу – ерак галәм *өннәре*, әллә нинди сәер, ят, юксынулы, сагышлы *өннәр...*

Бөекләрнең язганнарын укыган чакта күрәм: *сүзләре* шул ук, без белгән сүзләр, ләкин алар башкача яңгырыйлар һәм *мәгънәләре* дә башка...

Ярар, монысы тын алу мәлендә уйланыр өчен бер күчеш кенә. Ә күчәбез шагыйрьнең сөйләмендәге телдән башка чараларның тагын берсенә – төс белдерү мөмкинлегенә. *Төс* – ул фикерне күз алдына китерү, сурәт ясау өчен шагыйрьгә янә бер көчле чара. Әйтик, рәссамга ул иң төп, бердәнбер чарадыр. Буяу белән биреп була. Иң төгәле төсле фото белән. Табигатьнең үзен төгәл күрү, тою, сизү – менә аның төп мөмкинлеге, чарасы. Шагыйрьдә менә шул байлыкны тою, күңеленә фото итеп төшереп, бала чактан ук картаеп беткәнче шул сурәтне саклый белү сәләте бар. Төсне күрсәтү, чагылдыру табигатнең иң көчле сыйфатыдыр. Моны Шамил Анак та сизгән. Бер шигырендә ул: “Күрсәтмиме бу бөек табигать мең сыйфатын, *төсен,* чыраен?”– ди.

Шагыйрь соң төснең сурәтләү көчен ничек күрсәтә, белдерә ала? Кулында буявы, төсле каләме юк, фотоаппарат та аның коралы түгел, бурычы ук бүтән. Сүз белән, төсләрне дә әйтеп-атап бирә алган сүз белән! Шөкер, телебез андый хәзинәгә дә бик бай.

Башта төсне белдерә торган сүзләрнең шигырь сөйләмендә туры мәгънәдә ни дәрәҗәдә дөрес тоемлап белдерелүе. Моңа да күзәтүчәнлек, төс тоемлавы, хис белән бәйли белүе сорала. Төсне башта натуралистларча, рәссамнарча, реалистларча күреп тану, хис итү сорала. Шулай да ул бу сыйфатта рәссамнан да сизгеррәк, хыялыйрак булырга тиеш: “Көзге тын *сарыларда* япа-ялгызым // басып торырмын *ак* каеннар төбендә”. *Ак* каен – монда ике семантик функция үти: каенның чын төсен; икенчесе: хис белдерү максатында эпитет функциясе. Метонимик сурәтле күренешкә әверелгән. Шулай да шагыйрьнең сурәтләү теләге моның белән генә чикләнә алмый. Төснең сурәт мөмкинлеген шушы *ак* төс мисалында дәвам иттерик әле. Аннары бүтән төсләргә күчәрбез.

Төснең мәгънә күләме бик конкреттан абстракт колачсыз күләмгә кадәр җитә: *ак* каеннан ак дөнья, ак догага кадәр: “Иртә – *ак дөньяга* аяк баскан чак; ә төн – ак догалар, сөю сәгате”; “оча иде үкереп көн-төн самолетлар, // эзләре озын иде, *ак* иде”.

Ак төс үзе бер образ югарылыгына күтәрелә: “Кызлар май башында каенсарда каен суы җыялар. Күлмәкләре *ап-ак.* Саф тамчыларны... учларына җыеп алалар, башта битләренә сөртәләр. аннан изүләрен чишеп, *ак* күкрәкләренә сөртәләр, йөзләре каен тузыдай *ак* һәм күкрәк сөтләре каен суыдай шифалы булсын дип... Йөзләре *ак,* күкрәк сөтләре пакъ булсын!”.

“Ак”ка бөтен бер шигырь багышлаган: “Юмаган кул кагылмадым *ак* икмәккә; // кичерсеннәр, җитлекмәгән юллар белән *ак* кәгазьне чуарлаган чак булды”; Атылган йолдыз // кабына кабаттан кызлар күзендә – гашыйклар йокламасын бу *ак* сәгатьтә”.

Акның чыннан да ак икәнен аны башка төсләр белән чагыштырып тагын да “агартып” була икән. Әлбәттә, беренче чиратта *кара* белән чагыштырып: “*Кара* эшләр эшләнсә дә, *кара* (әшәке. – *И.Н.*) түгел төн үзе”; “Иң караңгы, озын төндә дә // таң нурлары яра төнге *караны”;* “Үлем генә мәңге *кара,* // үлем генә мәңге караңгы”; “...берсен сугыш дигән *кара кош* алды...”; “*Кара* таңнан *кара* таңга кадәр эшләде”; “Киенгәнсең матәм төсе *карадан”; “Без аңладык, кара кара ул, ак ул ак”; “*Ялгыз калган хатыннарның күзләре сагышлы, // күлмәкләре *кара”.*

Әлбәттә инде, шагыйребез теге-бу төскә өстенлек бирми, аның шигырьләрендә барлык төсләр дә искә, телгә алына; теләгән сурәтен, образын гына бирсен. Шунысы мөһим, төс белдергән сүзләр, башка кайбер шагыйрьләрдәге кебек рифма, ритмга яраклаштыру, җанлылык бирү өчен гадәти эпитет кына түгел: “Ниләр килер хәтергә бу төнге тын сәгатьтә – гомеремнең ерак калган *яшел* язымы”.

Яшел монда “чуарлау” өчен артык бер өстәмә кебек. Юк шул, “яшел”сез дә сурәт булыр иде булырын, тик ул шактый тонык булыр иде, килешегез.

Төс шагыйрь аерып күрсәтергә теләгән предмет, күренешне ачыграк күзаллау, сурәтләү чарасыннан бигрәк (гадәттә ул шул максатта кулланыла да) Ш. Анак шигырендә хәрәкәтне, вакыйганы, хисне тасвирлау чарасына әверелә:

Бу янгын, гаҗәеп янгын, бу көз янгыны!
Сары янгын телләре,
кызыл янгын телләре,
зәңгәр ялкын телләре!

Менә төсне белдерүче сүзләрнең шушы максатта ничек “җемелдәвен” үзегез дә күзәтегез әле: “...ага иде су, ярлары *зәңгәр* камыш иде...”; “...җиргә эңгер *зәңгәре* төшкәндә...”; “...бу *алсу* көзге көндә мин алма күрәм һаман”; “Зур *кызыл* алма кебек, иртәләрен кояш калка иркәләнеп”; “Менә тагын бер көн үтте, // тынып калган кошлары, моңсу *зәңгәр* агачлары, // *алсу* шәфәгы белән; “...урманнарны *сары* тут алган – сулган *сары* яфрактай, *сары* сагыш төсенә буялып, китә көннәр”; “*сары* гомер болыным белән янәшә чәчәкләнсен яңа, матур гөлләр”. Нинди гомумиләштерү!

Сары сагыш яфракларын коеп, // елый көз // син дә елыйсың.
Юанылмас бу сагышта юындым мин *лимон сарысы* белән.

Төс белдергән сүз (*яшел*) бүтән сүз, мәгънә белән синоним була ала: “өмет гөле *сулмый, яшел кала* иң соңгы көнгә кадәр”. Төс төслеген югалта, үзенә бер төсмергә әйләнә: “*алтын-сары* чәчләрең булды йөрәгем путасы...”.

Төс ул кешенең *күрү, карау* төшенчәләре белән дә бәйле. Шагыйрь иҗатында, сурәт ясау сәләтен гамәлгә ашыруда шулай ук зур урын тота. Кызык бер күзәтү: күрүнең әһәмиятен ачыграк төшенү өчен шагыйрьнең “Күреп булмаган нәрсәләр: елан эзе, рух җисеме, хатын-кыз йөрәге...” дигән парчасын искә төшерү кирәктер. Икенче бер шигырендә ул табигатьтә күренүе мөмкин булмаган нәрсәләрне саный: җил күләгәсе, өн шәүләсе...

Гадәттә адәмне адәм иткән җисемнәре арасында *тою, сизү*не искә алмасак, Ш. Анак шигъриятенең, аның сурәтләү чараларының арсеналы китек булыр иде. Тик бу хәсиятенә җәелеп тукталу мөмкинлеге чикләнгән, язма болай да озынга китте. Тәннең тою үзенчәлеген чагылдырып, шагыйрь бик үзенчәлекле сурәтләр барлыкка китерә. Берничә мисал белән генә чикләнәбез: “Тәнең белән тойган кебек // *тоярга җирнең сулышын, // гүя ул синең балаң”;* “Сөякләргә кадәр үтеп керә кулымдагы стаканың *салкыны”*.

Кешене, аның холкы-фигылен, эш-гамәлләрен, хис-тойгылы хәләтләрен сурәтләп биргәндә аның *хәрәкәтләре*, шул хәрәкәтне күрсәтергә, белдерергә сәләтле тел чаралары шагыйрьгә бик әһәмиятле. Теләсә кайсы сөйләм төрендә болардан башка хәбәр итү, тасвирлау мөмкин дә түгелдер әле. Телевидение, кино, сәхнә сөйләмнәрен әйтеп тә торасы юк. Гәрчә шигърият дөньясы язма сөйләмгә нигезләнсә дә, аның нигезе әйтмә рәвештә формалаша, күп очракта әйтмә рәвештә дә башкарыла.

Татарның хәрәкәтне белдерү сүз, гыйбарәләре бик мулдан. Теләсә нинди ым-ишарә, тән-гәүдә хәрәкәтләрен, табигатьтә күзәтелә торган хәрәкәт-чалымнарын белдерү, күрсәтү, ишеттерү мөмкинлекләре җитәрлек. Алай гына да түгел, шагыйрь өчен аеруча әһәмиятлесе, хәрәкәтне гади факт, күренеш буларак хәбәр итү өчен генә түгел, образлы сурәтләү, сыйфатландыру, тере-җанлы итеп күз алдына китерү өчен дә иң бай корал-чыганак була ала. Акыллы, хисле шагыйрь моннан файдаланмый калмый, әлбәттә. Шамил Анак иҗаты бу уңайдан да безгә осталык мәктәбе була ала.

Мисалларны кеше хәрәкәтен белдерә, күрсәтә, сурәтли торган мисаллардан башлыйк. Иң көчле, хисле хәрәкәт ул – *күз, караш хәрәкәте:* **“**Мең кеше арасында көтмәгәндә без очраштык // һәм *күңел күзе белән* бер-беребезне таныдык”; “*Хәйран күз белән карап* җан сөйгәне Зөһрәсенә...”.

Адәм баласының теләсә кайсы әгъзасы, тәне-гәүдәсе белән, эш кораллары, тирә-юнь мохитне тәшкил иткән әйбер-нәрсәләр белән ясалган хәрәкәт шагыйрьгә тәэсирле сурәт чарасы ул. Анак аларга бик тә игътибарлы. Бу – натуралист күзәтүе генә түгел: “Постовойлар янына киләм чатта, // алар *читкә бора йөзләрен,* эндәшми...”; “Акча бирәм официантларга, алар *баш чайкый,* алмый, акчамны кире кайтара”. Автор *эндәшми, алмый* дип кенә дә мәгънәне төгәл бирә алыр иде; юк бит – аңарга сурәт, гәүдәләндерү кирәк: “Син минем якты кояшым, гүзәллек сәнамым, // һәм мин, мәҗүси, *тезем чүгеп* табынам сиңа”.

Анак кеше белән бәйле теләсә кайсы хәрәкәтне табигать белән бәйләп җибәрә, сурәтле ассоциациягә, чагыштырып сыйфатландыруга ирешә: “Ерак агачлар // *кул изи* миңа. *Аккан* болытлар // *күз ата* миңа. // *Очкан* кошлар // кычкыра миңа”.

Табигать хәрәкәтләре дә иң әүвәле сурәт тудыру максатында бәян ителә, хис белдерү чарасы буларак сөйләмгә җәлеп ителә. Менә гап-гади *яңгыр ява***.** *Ява* сүзе *яңгыр ява* тезмәсендә болай да хисле. Ә менә чагыштырылып, ассоциатив рәвештә бирелгәндә *(ялгызлык төсле, ялыктыргыч, сагышлы)* аның хис куәсе тагын да көчәя. Өстәвенә әле тавыш белән катнаштырылып, кушылып, яңа хис төсмере өстәлә: *яңгыр тавышында сорау...*

Янә бер мисал: “Көзге яңгырда агачлар *бөрешкән* нәкъ кеше төсле...”. Хәрәкәтнең сурәт буларак күзаллануы ике чара белән ирешелә: сүзнең семантикасына хәрәкәт салынган: бөрешү (калтырау, дерелдәү, ыргылу, укталу һ.б. кебек); икенчесе – ул шушы хәрәкәтне чагыштырып бирү: *бөрешкән – кеше төсле.*

Анакның чагыштыру сәләтендә үзенә хас аерымлык – ул кеше сыйфатларын, хәрәкәтләрен табигать, җәмгыять күренешләренә күчерү белән бергә, табигать күренешләрен дә кеше сыйфатына, хәрәкәтләренә күчерә – кешенең теге-бу гамәлен, хисси хәләтен тагын да көчлерәк, тәэсирлерәк итеп күрсәтү, укучыга тәэсир итү өчен: “Ә бәлки миңа *кул болгыйсыңдыр*, // киткән җәй белән хушлашып, сары *яфракларны болгыйсың”;* “Әнә анда еракта *томанлана* ялгызлык”; “Болытлардан *тамдыңмы* син тамчы-тамчы, // агачлардан *коелдыңмы* яфрак-яфрак”; “Каен сиртмәләрендә *тирбәлеп* үстең

мәллә... билләрең шундый сыгылмалы”; “Йолдыз атылды. Атылды һәм *сызылып* юк булды”; “Исемеңне ярда комга яздым – дулкын *җуйды.* Исемеңне ак карга яздым – буран *каплады”.*

Хәрәкәт дигәндә төрле сүз төркемнәренең мөмкинлекләре төрлечә. Аеруча фигыль актив. Фигыльнең көчерелмә мәгънәлелек алу мөмкинлеге: “Кайдадыр тирәндә *күңелемдә тибә уй”.* Игътибар иттегезме: тирән бер фәлсәфи күренешне дә хәрәкәт сүзе белән белдереп була икән.

Хәрәкәтне тасвирлаганда татар стилистикасының төрледән-төрле чара-алымнары, аеруча синтаксик фигураларның яңадан-яңа мөмкинлекләре табыла. Аеруча көчлеләреннән – *кабатлау.* Инде төрле тезисларны дәлилләү максатында китерелгән мисалларда без бу фигурага күп юлыктык. Янә берничәсе генә: “Керфегеңдә *сиксән* бөртек – *сиксән* сөңге, // *сиксәне* дә йөрәгемә кадалды, // *Сиксән* үлдем, *сиксән* терелдем!”. *Сиксән*не кабатлап – сурәт, образ барлыкка килә. Шунысы да кызык: бу синтаксик фигура мәгънә, сурәт белдерү чарасы буларак кына түгел, шигырьнең төзелешен-структурасын үзенчәлекле итү чарасы да. Мәсәлән бер шигырендә *Көзге яңгырда агачлар бөрешкән нәкъ кеше...* дигән строфа сюжетны өлешләргә – бөтен бер сурәт-күренеш сыйфатында өч тапкыр кабатлана. Гадәттә бит текст кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф һ.б бүленеп, алар башисем, сан, тамгалар һ.б. рәвешендә тәгаенләнә, ә монда сүз белән сурәтләнгән бөтен бер күренеш (хәтта манзара) бүленеш чарасы.

Синтаксик фигуралардан янә Ш. Анак чагыштырулар остасы дигән идек. Алар да ана теленең бихисап мөмкинлекләреннән барлыкка килә, беренче чиратта, телбизәкләрдән: “*Озын кызыл томшыклы гаҗәп кошка – тимер кранга”; “Сез, рояль капкачыдай, яптыгыз да йөрәгегезне, музыка бетте”; “Мин ялгыз агач көзге яңгырда”; “Ят өйдә үзен тартыныбрак тоткан кунактай”.*

Тагын бер ачыш – хәрәкәтнең нечкә төсмерләрен белдерү максатында ана теленең ялганмалы (агглютинатив) тел буларак мул үзенчәлекләрен эшкә җигәргә мөмкин. Мәсәлән, теләсә кайсы фигыльгә ярдәмче фигыль өстәп, бихисап метафорик мәгънә һәм хис төсмеренә ирешеп була. Аннары, бездә бит теләсә кайсы фигыль ярдәмче сыйфатында да мәгънә, хис төсмерләрен баета: менәсем *килә;* кайтып *килә;* аерыла *алмый;* кайтмый *калу;* ачтан *калган;* актарып *чыгара* һ.б.

Кушымча (морфема) да вакыт-вакыт шигъри бизәккә әверелә: “Без, чыннан та, йөзләрчә ел туган-кар*дәш*без – яуда яу*даш*, данда

дан*даш* һәм, егылсак, кабер*дәш*без, тыныч көндә сабан*даш*быз, бәйрәмдә табын*даш*быз // һәм мәңге җир*дәш*без...”.

Чү, синтаксик фигуралар турында сүз куерта башлап без инде әсәрнең төзелеше – структарасы өлкәсенә керә башладык түгелме. Бүгенге бурычыбыз бит, кисәткәнебезчә, Ш. Анакның шигырь төзелешенә бәйле үзенчәлекләре турында түгел; сөйләм үзенчәлекләре иде бит. Ә сөйләм башлыча мәгънә белдерә торган чаралар белән бәйле, турыдан-туры структура белән бәйләнмәгән.

Шулай да, шулай да... Алай кистереп әйтү, ягъни әсәрнең төзелешен аның төп асылы – образ тудыру чарасы түгел, дип икрарлау дөрес микән? Сөйләм үзенчәлекләрен ачыклаган мисалларда әсәрнең төзелешенә караган факторлар да очрап торды бит (мәсәлән, шигырьнең өлешләргә бүленеше һ.б.). Яисә әле менә чын тезмә рәвешендә тезелгән – көйле-моңлы, ритм, рифмалы шигырьләрне укып, тәм, ләззәт алып килдек килдек тә, “Каен суы җыю” әсәренә җиттек. Бернинди тукталышсыз, тын алусыз, паузасыз укуны дәвам иттердек. Бактың исә үзебез дә сизмичә-белешмичә тезмәгә күчеп киткәнбез икән – яңгырап торган ритм, рифма да, иҗек саннары белән тәгаенләнә торган строфалар да юк икән бит. Төзелеше, рухы белән парча ич бу! Шәхсән үзем андый жанрны бик үз күреп язам, парча китапларым, парча турында фәнни күзәтүләрем бар. Беләм, Ш. Анак та парчачы. “Каен суы җыю” да чын парча. “Куллар”, “Үзсүзле йолдыз” вә башка хәтсез тезмәләр – парча. Тышкы рәвеш үзгәрде, ә эчтәлек, ә асыл? Ә хис? Хис шулай ук шигырьдәге кебек, кайный, үзәкне өзә. Димәк ки, образ тудыру максатында Ш. Анак тезмә белән чәчмәне бер үк дәрәҗәдә оста куллана.

Без инде Ш. Анак шигъриятенең үзенчәлеге энциклопедиядә “верлибр, сонет, терцина, ода, касыйдә, хайку, танка, назирә, афоризм, новелла” төшенчәләре белән билгеләнүен, боларның исә башлыча әсәрнең төзелеше белән бәйле сыйфатлар булуын искәртеп киткән идек. Төпченә башласаң, бер караганда шигърияттәге форма (төзелеш-структура) үзенчәлеге кебек тоелган, галимнәр шулай дип аңлатырга да тырышкан менә бу хәсият сыйфатлары тегеләй дә болай да тел, сөйләм асылына кайтып кала түгелме!? Без анализлаган кабатлау, чагыштыру мисаллары шуңа дәлил түгелмени. Менә уйланыр өчен соңгы мисал: “Тик *көннән-көн якынаям җиргә, // Җиргә якынаям көннән-көн.* Монда фәлсәфи хис тудыру чарасы нәрсә, дигәндә, белгеч сүзләрнең җөмләдәге урыны (рефрен күренеше) дияр. Ә без анысы да бит ана теле чарасы, сөйләм төзелеше үзенчәлеге, дип

өстәрбез. Моңа да Шамил Анак ана телен нечкә тоемлавы, белүе, оста куллануы нәтиҗәсендә ирешкән, диярбез.

Шул хакта уйлануларыбызны дәвам иттерик. Осталык серләрен ачуның, аңа ирешүнең чиге юк.

УЕЛЫП КАЛДЫ УЙЛАРЫ

(Хәсән Сарьян киңәшләре)

Кем ул тел белгече?

Хәсән Сарьян чын-чыннан тел белгече иде. “Тел белгече” дигәндә, без башлыча ике төшенчәне күз алдына китерергә күнеккәнбез. Беренчесе, үз әсәрләрен үткәзерлек, тәэсирләндерерлек, җиңел укырлык тел белән язган әдип. Хәсән Сарьян нәкъ шундый язучы иде – балта остасы үз коралларын, галәмгә юл тоткан космонавт үз аппаратларын ничек яратып, төпле белсә, ул да туган телен шулай яраткан, үзләштергән, үтемле куллана белгән оста иде. Аның бу иҗади таланты, сәләте һәм тәҗрибәсе аерым өйрәнелергә хаклы киң бер мәйдандыр.

Икенчесе, “тел белгече” дигәндә, без янә лингвистика галимен, ягъни телнең төзелешен, тарихи һәм бүгенге хәлен өйрәнүче белгечне күзалларга күнеккәнбез. Хәсән Сарьян бер үк вакытта шундый оста да иде. Ул фикерләү чарасы, аралашу коралы, әдәби образлар тудыру чыганагы булган телне фәнни ачыклаган гыйльми белгеч иде. Бу өлкәдәге тикшеренү-уйлануларын, белемен, тәҗрибәсен ул үзендә йомып яткырмады, университетта студентларга бирде, тел гыйлеменә кагылган хезмәтләрендә халыкка җиткерде.

Ниһаять, Хәсән Сарьян иҗаты аркылы без “тел белгече” төшенчәсенең өченче бер мәгънәсен ачыклый алабыз. Сүз сөйләм турында бара. Кызганыч ки, “сөйләм” төшенчәсен – асылы белән гаҗәп катлаулы күренешне – без, үтә дә гадиләштереп, әйтү, сөйләшү мәгънәсендәге көнкүреш төшенчәсе дип кенә күз алдына китерергә күнеккәнбез. Безнең галимнәргә, телнең асылын, төзелешен аңлатып кына канәгатьләнмичә, аны, фикерләү вә аралашу коралы буларак, ничек-ничек куллану, ягъни сөйләм оештыру закончалыкларын да ачып, аңлатып бирергә, димәк, сөйләмият фәнен үстереп җибәрергә күптән вакыт та бит... Әнә урысларда, башка милләтләрдә дә речеведение, психолингвистика, социолингвистика кебек фәннәр үсеп ята, бездә генә мәктәптә дә, университетта да һаман шул тел төзелешен

өйрәтү. Моңа борчылып, күпме чаң сугылды, күпме язылды инде. Ләкин туңны эретү бик кыен.

Мөхәммәт Мәһдиев интервью бирә: “...Бездә бит укыту системасы формаль методикага корылган. Менә безгә гомер буена татар һәм рус теле дәресләрендә иянең астына бер сызык, хәбәрнең астына ике сызык, ә аергыч астына дулкынлы сызык сызарга өйрәттеләр. Гомер буе безгә суффикс, приставканы өйрәттеләр. Ә практик яктан сөйләшергә, аралашырга өйрәтмәделәр...” (Мәгърифәт. 1993. 13 февр.).

Ә бит моңа фәнни нигез салырга күптән җирлек бар. Г. Ибраһимов, Г. Бәширев, Х. Курбатов, В. Хаков, Ф. Сафиуллина, И. Бәширева һ.б. хезмәтләре белән бергә Хәсән Сарьяннныкылар да анда саллы-саллы кирпечләр белып тезелә алыр иде.

Сөйләмият дигән фән, иң башта сөйләм белән тел мөнәсәбәтен тәмам ачыклар иде. Сөйләм – ул аралашу-аңлашу максатында фикерне оештыру, белдерү һәм кабул итүнең бөтен бер системасы. Аның асылын аралашуның (коммуникациянең) мотивлары: сөйләм иясе, адресаты, нияте һәм сөйләм оештыруның шартлары, шулай ук аралашу чаралары: тел һәм телдән башка чаралар (ым, ишарә, тавыш, сурәт, шрифт һ.б.) тәшкил итә. Сөйләмдә мотивларга карап тел чаралары тәгаенләнә дә. Димәк, фәнни күзаллау өчен дә, сөйләмне үзенә бер, телне үзенә бер чагыштырмача мөстәкыйль, әмма мәңге аерылгысыз төшенчәләр итеп карау хәерле.

Хәсән Сарьян моны болайрак төшендерә: “Татарча “тел бозу” дип сөйләнсә дә, татар теле дигән гомуми телебезгә бу һич тә кагылмый. Чөнки гомуми “телне” бозып булмый. Чыннан да, менә мин, менә әле, шушы тел белән сөйлим икән, мин, аның матур да, камил дә, бай да икәнлегенә сокланып, күңелемдәге уйның, хисләремнең һәммәсен әйтә алуыма горурланып сөйлим. Ул телне мин ясамаган. Мин аны боза да алмыйм!” (*Сарьян Х.* Уеңны уйдырып сал... Тел, әдәби осталык турында мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 73 б.).

Фикерне куәтләп, без дә өстик: бүген дә кайбер кешеләр урысчалатып-татарчалатып сөйли икән, хәтта матбугат басмалары да, иске сүзләрне кайтарабыз дип, аңлашыр-аңлашылмас сөйләм оештыруны хуплый икән, яисә үзләре дә, тел кагыйдәләрен бозып, наданлык күрсәтәләр икән, моңардан татар теле “бозылу” түгел, селкенми дә. Чөнки аның һәр сүзе үз урынында кала бирә. Чөнки алар – зур туган телебезнең һич бозылмас энҗеләре. “Халык ни гомер яшәсә – теле дә шул гомер яшәячәк” ди Х. Сарьян (шунда ук. 73 б.).

Фикер + сөйләм + тел

Тел һәм сөйләмне менә шушылый якынча мөстәкыйль итеп күзаллау белән беррәттән, Хәсән Сарьян бу ике төшенчәнең берберсеннән аерылгысыз икәнен дә буйдан-буйга басым ясап әйтеп килә. Мәсәлән, телнең барлыкка килүен, үсешен, камилләшүен дә ул нәкъ менә сөйләм белән бәйләнештә аңлата. Аның телгә бәяләмәсен карыйк: "Телне без иң камил бер аңлашу коралы, кешелек дөньясын алга әйдәүче бер прогресс чарасы, дибез. Тел ул буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мөкатдәс бер мирас булып, телен җуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер. Тел, ниһаять,– туган ил, туган җир ул" (шунда ук. 109 б.).

Төрле яклы, колачлы билгеләмә бу. Монда телнең төрле функцияләре искә алынган. Шулай да беренче нәүбәттә аның сөйләм өчен хезмәт итүе ярылып ята. Без аерып күрсәткән берәмлекләргә игътибар итегез: алар шушы фикерне раслый. Аннары бер телнең үз кысасындагы бурычына гына түгел, ә бүтән телләр белән мөнәсәбәтенә дә караш бар: "Бик борын заманнардан бирле халыклар бер-берсе белән аралашып яшәгән: сәүдә итешкән, сугышкан, берберсеннән дин, гыйлем, һөнәр алган һәм сүз алган. Чөнки бер халыкның үзендә булмаган әйбер, төшенчә, идеяләр икенче халыктан сүзе белән үк кергәннәр" (шунда ук. 75 б.).

Һәрхәлдә, Сарьян "тел өчен тел" чиреннән азат. Аның бер генә күзәтүе, фәнни нәтиҗәсе дә тел гыйлеменең тар кысаларында гына йомылып калмый, ә бәлки, сөйләм кыйбласына карап хәл ителә. Менә берничә дәлил. Телгә теге яки бу яңа сүзне алыргамы-юкмы, теге яки бу архаизмны, тарихи сүзне кайтарыргамы-юкмы, дип элек тә бәхәсләшкәннәр, бүген исә бу чын-чыннан чәкәшләр төененә әйләнде. Әмма мондый очракның күпчелегендә хисси дуамаллык өстенлек итә, фәнни нигезләүләргә урын калмый. Ә Сарьян булса, менә болайрак фикер йөртер иде: "...телгә сүз алу-алмау мәсьәләсен заман үзе хәл иткән – калдырасын калдырган, калдырмыйсын агызган. Әйтик, хәзер бер язучы да индустрия, промышленность урынына сәнәгать сүзен кире кайтарыйк дип дәгъва сөрми (Сөрә шул, Сарьян абый, кадерлем, хәзер әллә нәрсәләр дә "сөрәләр". – *И.Н.*). Әмма ләкин сүзнең аһәңе, эчке ритмы хакына бер язучы, мәсәлән, мин, менә бер, анда да сүз сөрешеннән аңларлык итеп, сәнәгать сүзен кыстырып җибәрәм икән яки әгәр тәрбиясендә гарәпчәлек һич булмаган яшь буын шагыйрь Ренат Харис "Синең аша үткән җилләр силгә әйләнсен шатлык тулып" дип, "ташкын" урынына "сил" сүзен кулла-

на икән, аңардан гына татар әдәби теленең бер чите дә кителеп төшмәячәк” (шунда ук. 112 б.).

Сөйләм оештыруның үз канун-кагыйдәләре булса да, алар тел законнары белән тыгыз үрелеп бара. Монда шәхси башбаштаклыкка да, өстән әмер бирү – волюнтаризмга да урын юк. “Казан дәүләт медицина институты” дигән атаманы “Казани дәүләти медикаль институт” дип тәкъдим иткән бер иптәшкә Хәсән Сарьян болай аңлата: “Сез тәкъдим иткән мисаллар да, сүзләр бәйләнеше дә татарча булмау сәбәпле, һич безнеңчә түгел”. “Безнеңчә түгел”, ягъни тел законына туры килмәүнең ни-нәрсә икәнен ул менә ничегрәк төшендерә: “Казани дәүләти медикаль институт” дип язар өчен союзда яшәгән алты миллион татарның, һич югы, Казан арты дигән бәләкәй генә бер төбәге сөйләшү кирәк...” (шунда ук. 99 б.).

Хәтта исем кушканда да, кеше исемен тел һәм сөйләм берәмлеге дип карап, аның бүтәннәргә (ягъни сөйләм адресатына) ничек-ничек тәэсир итәчәген күз уңыннан төшермәскә кирәклеген кисәтә Сарьян. Чыннан да, Инфекция кебекләрне әйткән дә юк (бер апа кызына шундый исем куша), Гүзәл, Сылу шикелле исем кушар алдыннан да уйланырга иде, күрәләтә ямьсез бер кызга Гүзәл дип әйтергә кыенсына башлыйсың – мыскыл иткән кебегрәк килеп чыга (шунда ук. 107 б.).

Тел белгече буларак Хәсән Сарьян телне, әлбәттә инде, тоташ бер нәрсә дип, аморф хәлдә дип күз алдына китерми. Ул аны, фәндә каралганча, категорияләрдән тора дип белә. Иң әһәмиятлесе шунда ки, урта мәктәп тәмамлап, үзен белемле дип йөргән күпчелегебез, хәтта галимнәребез, ул әлеге категорияләргә катып калган бер төшенчә яисә форма дип түгел, ә бәлки сөйләм хаҗәтен канәгатьләндерү өчен кирәкле нәрсә дип карый. Әйтик, синоним күренешен Сарьян болайрак аңлата: *биек* белән *югары* синоним сүзләр, һәркайсы аерым торганда бернинди мәгънә аермалары юк кебек: икесе дә берәр әйбернең, берәр билгенең җирдән өстә булуын белдерә. Әмма сүзләр *бәйләнешендә* (ассызык безнеке. – *И.Н.*) алар берсен-берсе алмаштыра алмый. Мәсәлән, *биек йорт* – бер, *югары урын* – икенче.

Кызык бит: Сарьян *сүзтезмә* дими, бу – тел гыйлеме берәмлеге, ә сүзләр бәйләнеше ди. Сөйләмияттә, бәлки, *сүзбәйләнеш* дигән термин кереп китәр?

Яисә аның тавтология дигән тел күренеше турындагы уйфикере: ул бездә форма тавтологиясе (чәчү чәчү, чигү чигү, тегү тегү һ.б.), тамыр тавтологиясе (эш эшләү, буа буу, урам урау һ.б.) барлыгын искә төшерә дә, хәзер бу мөмкинлекләрдән аз файдалануыбызга

офтана: “...ике кабат кабатлаудан курыккан булып, икенче өлешен икенче сүз белән алмаштыра башладык. Шуның берсе *башкару* дигән сүз. Мәсәлән, көтү көтә генә түгел, ә *көтүче хезмәтен башкара*...” (шунда ук. 125 б.). Нишләмәк кирәк, хөрмәтле язучыбыз борчылып, кисәтеп язган *эш башкарыла* (эш эшләү урынына), *җыр башкарыла* (җыр җырлый урынына) һәм башка шундыйлар әле бүген дә күңелне тырнап, әйтелеп тә, язылып та тора.

Хәсән Сарьянның сөйләмият белгече булуы аның орфоэпия мәсьәләләре белән шөгыльләнүендә, бүген тәмам онытылып беткән бу фәннең язмышы белән кызыксынуында да чагылды. Аның әлеге күзәтүләре, мәсәлән, язу белән әйтүдә тартык авазлар ассимиляциясенең бозылу күренеше (*дибәйтәм* урынына *дип әйтәм* һ.б.) бүген дә актуаль.

Фикеребезнең бу өлешен түгәрәкләп әйтсәк, иҗат кешесе буларак, Хәсән Сарьян фикер + сөйләм + тел берлеген нечкә тоя, моны ул әсәрләрен язганда файдаланып кына калмый, башкаларга да төшендерергә омтыла. Бу хакта аның менә нинди тәэсирле гыйбарәләре игътибарга лаек.

“...Идея һәм тел – бер кешенең ике күзе, ике кулы, ике аягы; ниһаять, ул – бер кешенең сөяге белән каны, йөрәге белән акылы! Чын идея чын тел белән язганда гына халык күңеленә төшеп сеңә” (шунда ук. 140 б.). “...Тел безнең бердәнбер эш коралы да. Ул бер, ә без мең! Шуңа күрә без инде аны меңебез мең яктан бозмыйк. Киресенчә, меңебез мең яктан үстерик, баетыйк... Халыктан тел җәүһәрләрен алганбыз, ә кайтарганыбыз канәгать итәрлек түгел” (шунда ук. 139 б.).

Менә шушы инде ул сөйләмне Сарьянча аңлау.

Табып әйткән сүз – гәүһәр

Сөйләм ничек оеша? Әйе, тел бар. Әйе, сүзләр күп. Ләкин кайсы соң иң кирәклесе, аралашу өчен нәкъ шушысы? Әнә бит халык та, табып әйткән сүз генә гәүһәр, ягъни нәкъ үтемлесе, тәэсирлесе, дигән. Табып әйтү дигәне нидән гыйбарәт? Күрәсең, ул без бая әйткән сөйләм системасы. Ә ул мәгълүм законнарга нигезләнә, мәгълүм бер механизм белән хәрәкәткә китерелә. Хәрәкәт чарыклары ул – мотивлар: сөйләм иясе, адресаты, нияте һәм шарты.

Сөйләмият фәне нигезенә Хәсән Сарьян хезмәтләре кирпеч-кирпеч ятарга хаклы дигәндә, без сөйләм белгеченең менә шушы ме-

ханизмны ачык тоемлаган булуын истә тотабыз. Аның фикер агышын әлеге система белән анализлап карыйк әле.

Иң әүвәл шулдыр: Хәсән Сарьян, әлбәттә инде, сөйләмне кем оештыруга карап, телнең үзенчәлекле кулланылуына игътибар итми калмаган. Әйе, аныңча да, сөйләм иясе – мөһим мотив-компонентларның берсе, тел чараларының сайлануы шуңа бәйле. Менә дәлилләр чылбыры: “...татар әдәби теле, җегәрләнеп, дөньядагы алдынгы телләрдән һич калышмас дәрәҗәгә басты. Чыннан да, әгәр *кешесенә эләксә*, җәүһәр-алмазлар уйната ул безнең тел!” (шунда ук. 109 б.).

“Өстәл артында утыра”, “руль артында утыра” кебек тәгъбирләр дә берзаман бик еш күренә башлаган иде, без аларны хәзер шактый киметтек. Шулай да кайвакыт *татарча белмәүчеләр яисә татарча уйлап җиткермәүчеләр* телендә бүген дә күренгәләп китә “ (шунда ук. 135 б.).

“Телнең грамматик нигезен кем кимерә соң? Бер ишесе, мәсәлән, *телне тумыштан ук белми*, аны инде үгетләп түгел, дегетләсәң дә берни чыкмас; кайберсенең *тел тою хисе атрофияләнеп*, үлек җыелган – ул хәзер кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнлеген дә аермый, “алай да була” дип, телебезнең төзек һәм мөкаммәл бинасына үзе сыярлык кына тишек тишеп, шуннан йөри башлаган; өченчесе просто *үз телен өйрәнер-өйрәнмәстән Европа йә Азиянең модалы бер агымына ияргән була да*, телне мескен бакага әйләндереп, мәктәп баласыдай тәҗрибә ясый. Тагын бер ишесе бар: болары исә *“мин беләм инде!” дигән җирдә туктаган да* бүтән бер адым алга атламас. Әмма көллесенең дә кәсәфәте бер: телне бозалар” (шунда ук. 117 б.). (Ассызыклар алга таба да безнеке. – *И.Н.*)

Шәхси сөйләм иясе буларак, тел куллануда шагыйрь хикәячедән, тәрҗемәче драматургтан, очеркчы фельетончыдан аерыла. Сарьян да шулай уйлый. Ул, мәсәлән, шагыйрьгә нинди таләп куя? “...Туган җиренең туфрак, үз халкының күкрәк җылысын йөрәк ите белән тоймаган шагыйрь минем йөрәгемә керә алмый, аңа шулай ук башка халыклар күңеленә дә юллар ябык була. Үзеңнең туган җиреңнең, үз халкыңның син булмаганда кыен булачак бер күзәнәге булганда гына син юлны башкаларга да киң ярасың...” (шунда ук. 69 б.).

Ә тәрҗемәченең тел куллану үзенчәлеге ничек күзаллана? Ул да сөйләм булдыручы, ул бер телдә әйтелгән фикерне икенче телдә бирә. Кайберәүләр өчен тәрҗемә ул бер сүзне икенче сүзгә каплап бару гына кебек, әмма юк икән, монда да иҗади үзенчәлек таләп ителә икән. “Кыям Миңлебаев – үзенә аерым зәвыклы, үзенә генә хас куллы

тәрҗемәчеләребезнең берсе”, – ди дә, менә шушы үзенә хас “кулын” болай төшендереп бирә: “Ул тәрҗемә өчен һәм лексик, һәм грамматик, һәм философик яктан үтә авыр әсәрләрне сайлап ала: күңеленә шулар якын аның... Әгәр бер кеше бер үк язучының (А. Толстой әсәре) башта бер әсәрен, аннары икенче, өченче әсәрен тәрҗемә итә башлаган икән, монда инде “очраклы” дигәннең эзе дә калмый. Димәк, Миңлебаев Алексей Толстой иҗатын йөрәгенә уйлары, хисләре аша үзенеке итеп кабул иткән” (шунда ук. 58–59 б.).

Әле китерелгән мисаллардан тел чараларын сайлауда янә бер мотив-компонентның, ягъни сөйләм оештыруда ниятнең (максат, теләкнең) дә әһәмиятле урын тотуы ярылып ята. Чыннан да, шулай бит: фикереңне нинди нияттән җиткерергә теләвеңә карап (үгетләпме, көлдерепме, образ-сурәт беләнме, әллә фактка нигезләнепме яисә нинди хис-тойгы белдерергә теләвеңә карап) тел чараларын сайларга мәҗбүрсең. Хәсән Сарьянның бу хакта да фәнни фикерләүләре барлыгына бер генә мисал китереп китик: аптырау, гаҗәпләнү тойгысын белдерү өчен язучы, телнең башка чаралары белән бергә, “ничек” сүзенә дә игътибар итә. “Ничек” сүзе, гамәлнең рәвешеннән тыш, төрле дәрәҗә аптырау, гаҗәпләнүне аңлата. Янә дә үрнәге Тукайда бар: “Ничек соң без табындык потка, дип хәйранга калганнар” (шунда ук. 127 б.).

Чыннан да, әйтергә теләгән ниятеңә муафыйк берәмлек табуы, ай-һай, җиңел түгел. Күпме сүз-синоним арасыннан нәкъ шушысын табып куярга кирәк. Күп очракта, азапланмыйча, кул селтәп китәбез бит. Остазларны нәкъ шул мизгелдә искә төшерергә күнегергә кирәк тә бит. Мәсәлән, тискәре фикерле нәтиҗә ясыйсың ди, ә “*нәтиҗә*” сүзенең асылында уңай төсмер өстенлек итә, шуңа күрә дә *начар эш нәтиҗәсе* яки *ялкаулык нәтиҗәсе* дию ниятеңә нәкъ тәңгәл булмый. Шуңадыр да, күрәсең, телгә *результат* сүзе кереп бара иде, анда тискәрелек төсмере көчлерәк шикелле. Әмма ул “килмешәк”кә дә күңел ятмый. Нәкъ менә шундый азаплы эзләнү минутында остазның *кәсәфәт* сүзе искә төште дә. Без ул мисалны бая китердек инде: “Әмма көллесенең дә кәсәфәте бер: телне бозалар!”. Күптән түгел бу сүзне публицист, шагыйрь Айдар Хәлим мәкаләсендә дә күреп сөендем, остазлар үрнәгендә эзләнсәң, чыннан да, “гәүһәрләр”гә юлыкмый калмыйсың! Шулардан үрнәк алганда без *авария нәтиҗәсендә, корылык нәтиҗәсендә* кебек мәгънәсезлекләрдән котыла барыр идек.

әсәрләрен кабат укыганда мин вакыт-вакыт үземнең бер хәләтемә диккать иткәләдем: укудан туктыйм да, карале, гади генә бер күренеш, вакыйга, персонаж бәян ителгән, тасвирланган, әллә нинди махсус чара да кулланылмаган, ә шул күренеш яисә персонажның, кешенең кыяфәте яисә хәрәкәте күз алдына шулкадәр ачык, сурәтле булып килеп баса ки, бик ачык төшерелгән фотосурәткә юлыккан кебек текәлеп каласың, аның ачыклыгыннан, төгәллегеннән тәм, ләззәт аласың. Ничек, нинди алымнар белән ирешкән моңа язучыбыз?

Җентекләп күзәтә барганда, әдипнең шушы юлларны язгандагы сулышын, йөрәк тибешен үзең дә тоя башлагач кына, әсәрнең ритмын, тонын үз иткәч кенә дулкынлануыңның сер төбенә төшенә аласың: гап-гади сүзләр, җөмлә төзелеше, сүзләр белән генә барлыка килә торган төгәллек чаралары (*чагыштырулар, канатлы гыйбарә, фигуралар* һ.б.), йөзек кашында җемелдәгән энҗе, гәрәбә бөртекләре сыман, игътибар явын били бара, гади генә күренешне дә сурәт итеп күрсәтә бара икән.

Әйтик, иҗатының соңгы елларында Эдуард Касыймов нефть чыгаруны арттыру проблемасын хәл итүне тасвирларга алынды. Андагы катлаулы төеннәрне күтәрү өчен белгечләргә генә мәгълүм схема, тамга, махсус терминнар, саннар һ.б. кебек чаралар кирәк кебек. Шуларсыз сурәт ясап булмас шикелле. Була икән. Әдибебез моны телебезнең сүзләре, башка чаралары белән дә төшендерә алган: "...Иң четерекле хәл Ык тамагындагы "Күлләр" чыганагындадыр, мөгаен. Анда катламдагы басымны күтәртмәсәң, нефть суыртуның күзгә күренеп кимүен көт тә тор. Димәк, катламга су кудырырга кирәк. Инде махсус скважиналары да борауланган. Әмма кудыру өчен Кама белән Ык суы бөтенләй яраксыз – пычрак. Иң кулае, әлбәттә, нефтькә ияреп чыккан тозлы су. Катламның үз суы... Кулаен кулай да, ләкин аны ныклап аерырга һәм тупларга кирәк. Чыганакның үзендә үк зур күләмле махсус резервуар кормыйча котыла алмыйсың... Шәүкәт Хәсәнев моны НГДУ җитәкчеләре алдына күптән куйган, күптән таләп итә. Ниһаять, төзүчеләр куба... Ләкин аларның эшләре ничек бара: акрынмы, шәпме? Менә ни өчен Хәсәнев иң әүвәл Ык тамагыннан әйләнеп кайтырга ниятләде шикелле...".

Катламга иярчен су кудырып, нефть чыгаруны арттыру проблемасын язучыбыз үтемле генә итеп бәянлый да бирә. Сурәтләү чаралары да элек халык сөйләмендә гомуми мәгънәдә киң кулланылган һәм нефть темасына бик урынлы терминлаша алган *катлам, басымны күтәрү, су кудыру, чыганак, бораулау, суны аеру һәм туплау* сүзләре

һәм сүзформалары үтә катлаулы техник һәм технологик күренешне ачык, үтемле итеп аңларга мөмкинлек бирә. Бу контекстта *нефть, скважина, резервуар* кебек татарның үз сүзләре булып күнегелгән термин берәмлекләр генә түгел, *НГДУ* кебек аббревиатура-техницизм да сулышка төртелмичә, җиңел "йотыла".

Текстның документаль-төгәллеген хасил итә торган тел чараларыннан кереш сүзләрнең (*димәк, әлбәттә, ниһаять* һ.б.) нәкъ үз урынында, төп мәгънәгә басым ясап, төгәллеккә махсус ирешү өчен кулланылуын да әйтеп китик. Монда термин, хәтта профессионализм берәмлекләрнең үзләштерелүе алар белән аралашып килгән номинатив атамаларның (*Ык тамагы, "Күлләр" чыганагы, Шәүкәт Хөсәенев* һ.б.) саф татарча булуында.

Шул ук вакытта битараф берәмлекләрдән ясалган образлы-сурәтле берәмлекләр, фигуралар да (*кабатлау, чагыштыру, антитеза* һ.б.) ситуатив конкретлыкны көчәйтәләр генә (*шулаен шулай да* һ.б.).

Әдипнең төгәллек чараларын барлаганда аның деталь остасы икәнлегенә ышанасың. Аңарда деталь – гап-гади, барыбызга да таныш предмет яисә күренешнең нәкъ менә кирәкле урында, иң кирәкле вакытта әйтелүе, аның бер сыйфатын бик вакытлы, урынлы тотып алуы ул, укучының: "Карале, моны мин генә шулай дип беләидем, баксаң, язучы да белә икән", – дип, ачыш ясап, канәгатьлек кичерүе. Моңа да сүз-детальләр ярдәмендә ирешелә: "Минем бәхет басты. Махсус машинаның ябык кузовына менеп кунакладым да аның бәләкәй генә тәрәзәсенә борынымны төрттем. Кузгалдык...".

Әлбәттә, проблеманы чишү максатын куйган язучы да теманы ачканда аның бөтен нечкәлекләрен белеп бетерә алмас. Нефть чыгару кебек катлаулы процессларны белгечләр үзләре дә бүтәннәргә сурәтләп бирә алыр микән?! Язучы бит белгеч үк түгел. Мондый хәлдә аның ихласлыгы, шундый катлаулы техника, технологияне белгәнгә сабышмавы, шуны оста итеп бәянлый алуы – шул үзе төгәллек, конкретлык түгелмени! Монда әдип берничә алым куллана. Беренчедән, техниканы, процессны ничек кенә булса да белгечләр генә ачык аңлый торган күренешне гади укучы да күзалларлык сурәтләү чаралары таба. "Мирзанур... бер почмакта эленеп торган саклавыч тактадагы кнопкага баса. Кинәт бу авыр махина, бик каты дыңгырдап-ухылдап, хәрәкәткә килде һәм яньчелгән олы башын, тавык ашлык бөртеге чүпләгән сыман, әле күтәреп, әле төшереп, скважина тамагын "чукырга" кереште.

Икенче бер очракта ул бу хәлне белгеч кенә белергә тиешлеген, чыннан да төгәл белмәвен яшерми. Нәкъ менә шушы "наданлыгын" яшермәве, ачыктан-ачык әйтергә җөрьәт итүе белән ота да; конкретлыкка шуны ихласый сүзләр табып әйтә алуы белән ирешә дә. "Группалы установкада Мирзанур озаграк тоткарланды. Винтельләрне тыгызлады яисә бушата төште, нәрсәләрнедер сөртештерде, тазартты, аннары куен дәфтәренә нидер язып куйды...".

Шулай да конкрет тәшендерү – язучының төп бурычы. Моңа ирешү өчен барлык иҗади сәләтен җигә. Шушы максаттан, мәсәлән, чагыштыруларның яңадан-яңаларын эзләп табарга остара. Бер генә мисал: "Группалы установка культбудка артындарак. Анда өч булит тора. Булит – сигарага охшашлы озын һәм юан чан ул. Аны, янтайтып, җирдән беркадәр күтәртеп салганнар...".

Күренешләрне, аеруча персонажларны ачык күзаллауда диалог, туры сөйләм, персонажның сөйләм үзенчәлеге дә зур урын тота. Боларда да үзенчәлек тел берәмлекләре белән ирешелә. Мәсәлән, "Ык тамагында" дигән очеркында төп персонаж Мирзанурның сөйләме еш кулланыла. Анда *скважина, вахта, насос, парафин, смена, качалка, дебит, оператор* кебек терминнар, *АДУ, РИТС* кебек профессионализмнар, гади сөйләм элементлары булып китә башлаган *кантур, нәчәлство, напарник, уха* кебек жаргон берәмлекләр дә сөйләмдә төгәллекне көчәйтүгә булышлык итә.

Әйтерең бармы, төгәллек дигәндә, ул – татарның канында. Татар тотып карамаса ышанмый, дигән мәкаль дә шуңа ишарә. Менә бу үзенчәлек язучы әсәрендә тел белән эш иткәндә урынсыз "конкретлаштыру" очракларына да китерә, мәгънәви тавтология, хәтта оста, тәҗрибәле язучыларда да очрап-очрап куя. Яшь Касыймов та алардан азат түгел ("кояш *үзенең* алтын нурларын җәлләми", "миңа *таба* борылды", "... дидем *мин* аңа", "башын миңа *таба* борып..." һ.б).

Тормышчанлыкка ирешәм, конкретлыкны көчәйтәм, дип табигыйлеккә хилафлык китерергә ярамыйдыр (*"нефть исе аның канына бик яшьләй сеңгән...", "яшь киленчә җитезлек белән кухняда эштер-өштер килә башлады", "хан кызыдай кире беткән насосы", "җир куеныннан май кысып чыгаручы"* һ.б.).

Эдуард Касыймов та остара, тәҗрибәсе арта барган саен тел куллануда үз-үзенә таләпчәнлекне көчәйткән, әсәрләрендә мондый "артыклыклар", төгәлсезлекләр кимегәннән-кими барган, сөйләме камилләшкән.

Шушы урында тукталып, без яшь иҗатчыларыбыз, яшь тикшеренүчеләребез публицист Эдуард Касыймовның иҗат казанышларын нәкъ менә шушы кыйбладагы аның бай тәҗрибәсен киләчәктә дә өйрәнерләр, дип ышаныч белдерик.

ЯШИ: ЭЗЛӘРЕ, СҮЗЛӘРЕ

(Хәкимҗан Халиков шигърияте турында)

2008 елның гыйнвар аенда күренекле балалар шагыйре Хәкимҗан Халиковның тууына 75 ел тулган иде. Шагыйребез әсәрләре онытылмый икән – Татарстан китап нәшрияте шигъри әкиятләрен туплап (төзүчесе Айдар Җамалиев), шактый тулы, зәвыклы бизәлгән җыентыгын бастырып чыгарды.

2008 елның 27 ноябрендә шагыйрьнең туып-үскән төбәге Әтнә районы Яңа Шашы урта мәктәбе гөрләп торды. Музей бүлмәсендә Хәкимҗан Халиковка багышланган "почмак" ачылды: шагыйрьнең эш өстәле, язу әсбаплары; элгечтә костюмы; шүрлекләрдә кулъязмалар, документ, бүләкләре, китаплары, китаплары... Экспонатның күпчелеген хатыны Нурия ханым, кызлары Лилия белән Зилә, туганнары тәкъдим иткән, әзерләгән. Бүген "фонд" күз алдында ишәеп китте – музей ачуга, шул уңайдан укучылар белән очрашуга кайткан Казан кунаклары – язучы, журналистлар, якыннары да әдипкә бәйле истәлек, китапларын бүләк итте. "Музей кунаклары фикере" кенәгәсен булдырырга карар ителгән икән; беренче истәлек сәхифәсен Хәкимҗан Халиков белән иҗади аралашып яшәгән, аңардан сабаклар алган халык шагыйре, Татарстан Дәүләт советы депутаты, балалар шигырьләре өчен Һ.-Х. Андерсен бүләгенә лаек булган Роберт Миңнуллин язып куйды.

Музейга экспонатлар мәктәпнең шыгрым тулы зур залында үткән тантаналы мәҗлес барышында аудио-, видеоязмалар сыйфатында тагын да өстәлде – анда балалар шагыйрь, язучылары Роберт Миңнуллин, Вакыйф Нуриев, Фәйрүзә Мөслимева, Рафис Корбан, Ләбиб Лерон, Йолдыз Шәрәпева, укытучылар, журналистлар, туган-якыннары истәлек-хәтирәләр белән уртаклашты. Аларда Хәкимҗан абыйларының тормыш адымнары, иҗади казанышлары, педагог, журналист буларак та, аеруча балалар күңелендә яшәүче шагыйрь буларак та, сыйфат-үзенчәлекләре, иҗат хәсияте тагын да тулырак ачылды.

Мамыш авылы зиратында шагыйрьне кабере тарафында искә алганда, аннары туган нигезендә – хәзер туганнары яшәгән йортта та-

бында истәлек-хәтирәләр белән уртаклашканда да аның туган төбәгендә, авылдашлары күңелендә, укытучылык, журналистлык хезмәтендә калдырган гамәл-эзләре, шуларның әсәрләрендә дә чагылуы турында күп кенә мисал, дәлилләр китерелде. Боларның да музей хәзинәсендә берегеп калуы, укучыларга буыннан-буынга тапшыру хәстәре күрелүе бик тә әһәмиятле.

Тантана барышында укучы балалар әзерләгән әдәби-музыкаль тамашада да шагыйребезнең тормыш һәм иҗат юлы тәфсилле һәм тәэсирле итеп тасвирланды. Аның тормыш тәҗрибәсе, чыннан да, мулдан – сугыш чорының барлык михнәтләрен үз башыннан кичергән, күпне күргән. Хәер, язучы өчен шунсыз мөмкин дә түгелдер. Шәхсән мин үзем аны иң әүвәл туган төбәген, үз авылын, шушы тирә табигатьне, аның кешеләрен хөрмәт иткән, аларга игътибарлы, гамьле, сабыр, миһербанлы кеше дип танып хөрмәт итә, үрнәк ала, ияреpгә тырыша идем. Районыбыздан республика күләменә чыккан чын журналист дип горурлана, аның бу һөнәрдә ирешкән осталык серләрен ачарга омтыла идем.

Балалар матбугатында эшләү җиңел түгел, үзенә бер осталык, сәләт сорала. Хәкимҗан башта авыл мәктәбендә укытучы булып, аннары район матбугатында журналист булып эшләп, балалар күңеленә күпер салу, урын алу осталыгына иреште. Аларны үзенчәлекле иҗат алымнары белән язылган шигырьләренә җәлеп итү белән бергә, ул балаларны, яшьләрне матбугат, әдәбият, шигърият белән якыннан таныштыру, кызыксындыру, мавыктыру юлында да күп көч салды. Аның шәкертләре хәзер – үзләре күренекле иҗатчылар.

Күңелле хәл: аның шушы тылсымлы йогынтысы бүген дә дәвам итә икән. Әлбәттә, шигырьләре аша. Аның хөрмәтенә оештырылган концерт-тамашаны диккать белән, йотылып, ихластан карап-тыңлап утыруыбыз үзе дә шуңа дәлил икән бит. Шагыйрьнең сүзләренә салган җырмы ул, әллә шигыренә нигезләнеп сурәтләнгән тамашакүренешме, әллә турыдан-туры шигырь үземе, балалар башкаруында алар чын сәнгать әсәре сыйфатында, өстәвенә әле шагыйрь белән генә түгел, шушы төбәк белән, ана телебез белән горурлану хисе дә уралып, күңелне нечкәртте, илһамландырды, уйландырды. Яши икән шагыйрь рухы, бар икән дәвамчылары, дидек.

Шушы минутта мондый шагыйрьләрне тәрбияләп үстергән төбәкнең – Казан артының, аның халкының элек-электән милли җанлы булуын, ана теленә, әдәбиятенә, иҗатчыларына сак, кайгыртучан, хөрмәт белән карап, иҗатка тартылып яшәвен тоеп, бүген дә

бөтен мәктәпнең, китапханәчеләрнең, хакимият, хуҗалык җитәкчеләренең шул гадәтне дәвам иттерергә тырышуларын хуплап та хисләнәсең. Хәер, бу гореф-гадәтләрнең нигезе нык шул. Монда Шиһабеддин Мәрҗәни, Нәкый Исәнбәт игътибарын җәлеп иткән, алар тарафыннан тупланган халык авыз иҗаты, якташлары Габдулла Тукай, Сибгат Хәким, Рафаэль Төхвәтуллин, Фирая Зыятдинева, Нәҗип Мәдьяров, Әхәт Фазылҗанов, Рүзәл Йосыпов, Лена Шагыйрьҗан, Равил Вәлиев һәм башка иҗатчыларның саф татарча язылган, бүген дә укыла торган әсәрләре дә шул нигездә илһам энҗеләре булып салынган. Бүген аларны барларга, ишәйтергә, яшьләргә җиткерергә, иҗат мохитен дәвам иттерергә кирәк. Мәҗлестә бу хакта уйлану, сүз куерту да уңай тәэсир калдырды.

Халиков иҗатына якыннанрак килгәндә, алга таба шагыйрьнең иҗат осталыгын тулырак ачып бирү, мирасын җентеклерәк барлап, бигрәк тә балалар шигърияте керткән өлешен фәнни нигездә өйрәнеп, яшь иҗатчыларга җиткерү бурычы тора. Форсаттан файдаланып, бүген без Хәкимҗан Халиков шигъриятендә тел осталыгы мисалларына гына тукталып алыйк.

Бала – ул сөйләмгә, теләсә кайсы хәрәкәткә, җанлы күренешкә диккать иткән кебек үк, бик игътибарлы. Үзенә яңа хәбәр, яңа фикер җиткерә торган, уйланырга мәҗбүр итә торган “могҗизага”, ягъни телгә, хәтта аның аерым-аерым берәмлекләре – аваз (хәреф), иҗек, сүз, җөмләләренә дә ул бик сизгер. Үз сөйләмендә дә ул алардан файдаланырга омтыла. Өстәвенә әле сөйләмнең мәктәптә җитәрлек өйрәнелми торган тавыш, сурәт, ым-ишарә кебек чараларына да игътибар итә. Шагыйрь Халиковның балаларга атап язган шигырьләрендә менә бу үзенчәлекне белеп, табигый сиземләү белән нечкә тоеп эш итүен ачык күрәсең.

Шигъри сөйләм аһәңе өн-аваз яңгырашыннан ук башлана. Һәр авазның үз яңгырашы. Һәр аваз үзенчәлекле. Белгечләр гадәттә сузык авазлар гармониясенә күбрәк игътибар итә. Балалар сөйләменә, аеруча шигырь укуларына диккать итсәгез, тартык авазларның үзенчә яңгыравына да юлыкмый калмассыз (*тррр; бррр; сыззз; ашшшык* һ.б.). Халиковның бала сөйләмендә еш очрый торган *куркак* сүзен кулланып, өстәвенә аны әле *кырык куркак* гыйбарәсенә җиткерүе очраклы түгел. Монда “к” авазы (хәрефе дә) идәнгә сибелгән борчак тавышларын хәтерләтә кебек. Яисә *“Беттем диген бер бәрсә...”* гыйбарәсендә *“б”* үзе бер йодрык булып бәрергә җыена кебек тоелмый мыни.

Аваз(хәреф)лардан иҗек, кушымчалар укмаша. Алар да тере, алар да бала фантазиясен хәрәкәткә китерү сәләтенә ия. Менә “Силби” дигән шигъри әкияттә Хазбулат исемле малай яңа танышының “ялганла син, хәйләлә”, “хәзер базар заманы: өйрән ныграк алдарга” дигән өйрәтүенә, тик торганда миләш ботагын сындыруына аптыраса да, бу әшәкелекләр танышының исеме белән бәйле дип башына да китермәгән иде – беткән мени татарда сәер исемнәр – ә хикмәт исемдә, анда да аны укмаштырган иҗекләрдә икән: бала-чага бит сүзләрне тезгән иҗекләрне уртадан яисә азактан укып кызык таба; бактың исә Силби дә *иблис* икән.

Менә бит иҗек нечкәлеген сизү шагыйрьгә нинди “ачыш” биргән! Гомумән дә, шигырьне аһәңле, яңгырашлы итеп ишеттерү, саф һава сулаган кебек кенә җиңел укып, ләззәт кичерү өчен иҗекнең хикмәтле чара икәнен шагыйрь бик белеп эш итә. Чын татарлык иҗектә шул. Фәндә дә телебезнең агглютинативлыгы (ягъни кушымчаларның өстәлә баруы) башка телләрдән үзгәлеге буларак өйрәнелә. Шигырьдә дә иҗекнең мәгънә төрлелеге барлыкка китерү сәләте, аларны төрле яңгырашлы иттерү, иҗек үзгәргәч, бөтен сүз, бөтен сөйләм үзгәрү мөмкинлеге балада кызыксыну барлыкка китерә, аларны үзгәртеп карау, яңаларын уйлап чыгару теләге туа, аның шуктеллелек, җортеллелек күнекмәләре ясыйсы килә. Монда ул Хәкимҗан абыйсы шигырьләреннән күпләп мисал таба ала: *сызгырып – ыжгырып, карарга – чабарга, чыккан – суккан, көлке – төлке, карчык – капчык, бүре – шүре, шаян – наян* һ.б. Иҗекнең әйтүдәге төрле өстәмә мөмкинлекләре дә шигырьдә тулырак чагыла: Каеш белән этием бер сыдырса – әллә-лә...

Ә сүз дигән хәзинә белән Хәкимҗан әдип ничек хәсиятле эш итә, дөресрәге, иҗат итә. Һәр сүзе нәкъ бала күнеккән, теләгән төшенчәгә тач килеп тора. Шагыйрьнең шушы татлы иҗат җимешеннән укучы да канәгатьлек кичерә, ул сүз, гыйбарәне хәтеренә сеңдереп кала, куллана башлый, чөнки алар бераз сәерлеге, сүрәтлелеге, олыларныкыннан аерылыбрак торуы белән бала күңеленә, психологиясенә ятышрак. Башлыча алар – канатлы гыйбарә-фразеологизмнар, диалекталь берәмлекләр, гади сөйләм, жаргон элементлары һ.б.: *коты очкан, ычкын тизрәк, бетте баш, җен ачуы чыгу, шап иттереп суккан, чытыр чапкан, күрмәгәнне күрерсең, алтын икән акылың* һ.б.

Бала сөйләмен яңа сүзләр белән баета бару – шагыйрьнең төп, әһәмиятле бурычларыннан. Әйтик, җай чыкканда ул сүзләрнең

мәгънә ягыннан (синоним) һәм әйтелеш ягыннан (омоним, омофон) төрле вариантларын тәкъдим итеп, балалар лексик байлыгын арттырырга омтыла: бер сарыгы *аяк сузган*, икенчесе *үлеп киткән* һ.б.

Бала иң гади төшенчәне дә сурәтле-образлы итеп күрү сәләте белән туа. Кешенең, беренче чиратта татар кешесенең, менә бу сәләтен һәр шагыйрь үзе кичергән булырга тиеш, шуны тоймаса, ул шагыйрь дә була алмый. Шәһәрдә туып-үсеп, урысча уйлап, татарча язарга күчәнгән каләмче беркайчан да авыл баласы аңларлык, хисләнерлек шигырь яза алмас. Кызганыч ки, бүген яшьләрнең сүрәтле уйлау, сөйләү сәләте сүрелә, тоныклана бара бугай. Ә образлылык ул гап-гади сүздән, күчерелмә мәгънәле гыйбарә-канатлы сүздән башлана, бөтен бер сурәт булып үсеп китә. Моңа төрле чаралар белән ирешелә: мәсәлән, чагыштыру (*коштай очып бара; сөттәй ап-ак томан; очып чыкты туп кебек; орчык буе булса да, чәче гүя пумала* һ.б.). Шул ук вакытта балада ул чаралар үзенчәлекле чагылыш таба, әйтик, шул ук чагыштыруда баланың хыялыйлык, арттыру (гипербола) сыйфаты күперенкерәк була (*эчке яктан ишеккә кырык терәү куйганнар; Сарбай инде алардан күпме таяк ашады* һ.б.).

Баланың дөньяны танып белүе үзенчәрәк булгач, аның телне кулланускы, сөйләм оештыруы да аерылыбрак торуы табигый – анда хәрәкәт-елгырлык, сурәт-рәсем көчлерәк, ә болар шигырьдә дә җөмләнең ким, сегментлы, инверсия, парцелляцияле һәм нормадан "тайпылган" башка рәвешләренә юлыгабыз: "Ә куянның күрсәң шулчак көлгәнен..."; "Бүре килеп чыкмасынмы шул чакта..."; "Торма болай ыжгырып, ычкын тизрәк..." һ.б.

Сурәтләү дигәндә, шигырьдә сүз-гыйбарәләр белән ирешелгән аерым-аерым микрообраз-рәсемнәр генә түгел, ә бөтен бер образлы күренешләр (әдәбият нәзариясендә алар сынландыру, гәүдәләндерү дип тә атала) тудырып кына максатка ирешеп була. Хәкимҗан Халиков бу хакыйкатькә бөтен иҗат юлында тугры калды. Менә бу сурәтләрне күз алдына китереп, баланың ничек сөенеп куюын тою кыен түгелдер: "Куркакларны күрүгә ай елмаеп куйган ди..."; "Авыл йоклый төренеп сөттәй ап-ак томанга...". Гомумән алганда, аның бөтен бер шигырьләре балалар хыялында туган, аларның фантазиясен үстерүгә сәләтле сурәт-образлар бит. "Канатлы куян" әкияте (соңгы китабы да шул исемле) генә дә ни тора!

Образ-сурәт тудыруның төрле әдәби чаралары бар, без инде башлыча тел чараларына тукталдык. Хәкимҗан Халиков нәкъ менә шушы кыйбла остасы. Аның шигырьләрен укыган бала сүз белән

теләсә нинди сурәт ясап буласына үзе ышана. Менә бай мәчесе Мыекбай үзен “тәнкыйть иткән” көчекне дә “танымый”:

– Ләң-ләң килеп, чәңгелдәп
Торма әле янымда!
Ычкын тизрәк, югыйсә
Биетәм бит мин сине!
Гади песи түгел мин,
Мин бит фарсы песие!

Чамаладыкмы, күзалладыкмы – бу бит песи түгел, бу бит койган да куйган һавалы “яңа татар” үзе.

Тагын да әһәмиятлесе шунда, шагыйребезнең мондый тәэсир көченең нәкъ менә ана телебезне нечкә белеп, оста куллануында икәнен дә бала сизә, тел байлыгын арттыруда аңардан үрнәк алырга, өйрәнергә мөмкин икәнен тоемлый. Күңеленә аеруча ятышлы сүз, әйтем, гыйбарәләрне шагыйрь абыйның халык сөйләменнән табып алуын, өстәвенә әле үзе дә уйлап чыгарганын – “ясаганын” да ул сиземли (“Үз күләгәңнән үзең кача алмыйсың икән!”; “Дуслар кирәк сиңа да, дуслар кирәк миңа да”; “Әни әйтә: Ялгыз, – ди, – яшәп булмый тормышта”; “Тик үзеңне ярату – дуслык өчен агу ул”). Менә бит: ул әти-әнисе, туганнары, иптәшләре белән көн дә сөйләшә торган гапгади туган теле менә нинди тәэсирле шигырьләр язарга, канатлы, могҗизалы гыйбарәләр уйлап чыгарырга сәләтле икән!

СЕБЕР ДӘ ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

(Булат Сөләймәнов шигърияте)

Һич көтмәгәндә-белешмәгәндә дигәндәй, кулыма Булат Сөләймәновның “Мин Себер татарымын” дигән җыентыгы килеп керде. Аны байтак еллар инде Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлап, хәзер үз якларында мәдәният, матбугат өлкәсендә эшләүче шәкертем – Себер кызы Гөлшат Туйчикова алып килгән иде.

Китапны күренекле татар шагыйренең якташлары – төзүчесе Асия Сәйфуллина, баш редактор Рифкат Нәсибуллин, әдәби редактор һәм корректор Эльза Латфуллина, кереш сүз язучы Нилүфәр Йосыпова һәм башкалардан торган иҗат төркеме – Булат Сөләймәновның тууына 60 ел тулуга (1998 ел) багышлап, эчтәлеге ягыннан да бай итеп, бизәлешен дә күңелгә ятышлы, зәвыклы итеп әзерләгән. Ул,

Екатеринбургта Төмән өлкәсе хакимиятенең матбугат һәм массакүләм мәгълүмат Комитеты ярдәмендә басылып, 1998 елда дөнья күргән булган. Бер сүз белән әйткәндә, бу – Себер китабы.

Булат Сөләйманов шигырьләрен элек тә матбугаттан, Татарстан китап нәшрияте 1988 елда чыгарган “Ак метеор” дигән китабыннан яратып укыганым бар иде. Алар ихласый самимилеге белән, туып-үскән төбәге – Себер якларына мөкиббәни табынып, аны үзенчә күреп, үзенчә тоеп тасвирлавы белән истә калган.

Булат белән якыннан аралашырга туры килмәде. 1960–1970 нче елларда Казанда язучыларның җыелыш, съездларында гына күрешкәли идек. Әңгәмәләребез аягүрә генә “исәнме-саумы”дан узмады. Шулай да үзенә сиздермичә генә аңарга диккать итүемне, аны ничектер фикердәш, теләктәш дип тоеп, якыннанрак аралашасы, дуслашасы килүемне хәтерлим. Язмышлар охшаш, дип уйланылгангадыр инде: Казанга ул Себердән килә, ә минем Уфада яшәгән чак, шуннан киләм. Икебез дә татарча язабыз, икебезгә дә яшәгән урында ана телебездә китап чыгару ябык. Казанда, анысы, якты йөз күрсәтәләр, “яхшы язасыз”, дип аркадан кагалар. Ә китап чыгаруга килгәндә, безгә чират барыбер гел киртәләр аша, иң азактан гына җитә иде.

Булатның моңа тирәнтен гарьләнүен, эчтән дулкынлануын ничек тоймыйм ди! Шулай да үпкәсе, дуамаллыгы кыска гына вакытка карашында, хәрәкәтләрендә чагылып китсә дә, мин аның зарланып, үпкәсен чыраена чыгарып, турсаеп йә тузынып йөргәнен күрмәдем. Горур иде, карашы берникадәр кырыс, берникадәр сагышлы булса да, ягымлы, кешелекле иде.

Хәтер төпкелендәге шул чаткыларны өреп кабыза-кабыза, тын да алмыйча китапны укырга тотындым. Яртысыннан күбрәге шигырьләр. Ничек яраткан Булат Себерен! Хәер, туган ягына – авылына, районы, төбәгенә мәдхия җырламаган шагыйрь гомумән дә юктыр. Ә Себер ул инде гади бер авыл гына түгел, шагыйрьнең үз сүзе белән әйтсәк, “орлык кебек бөтен Себер буйлап татар авыллары сибелгән”. Себер ул Иртеш, Обь кебек дәрьялар да, Тубыл, Варта, Соргыт, Самотлор, Салехард кебек борыңгы вә хәзерге яңа шәһәрләр дә; монда әле ханты, манси төбәкләре, тундра дигән иксез-чиксез серле карурман дөньясы да.

Менә шушы колачка да, карашка да, вакыт-вакыт акылга, хиськә дә сыеп бетә алмый торган киңлекләр, андагы табигать манзаралары, халыкның гореф-гадәте, тарихының чишелмәс “ төеннәре” – барысы, барысы да шигырьләрдә чагылыш тапкан – нинди олы җанлы, киң колачлы булгансың син, шагыйрь!

Шуңа күрә китапның “Мин Себер татарымын” дип аталуы аклана да кебек, тик бу исемне кем кушкандыр, белмим, Булатның шәхсән үзенең болай турыдан-туры кистереп, дәгъвалап, “кылтаебрак” димме, әйткән шигыре юк шикелле. Себернеке булуын, аны яратуын ул маңгайга бәреп, купшы сүз-гыйбарәләр белән әйтмәгән, ә бәлки хис кылларын чиртеп-тартып ала торган сурәтләр белән тасвирлаган. Колак салыгыз әле:

Гөрләвек ашкына еракка,
Елгада кар суы калыккан.
Әйтерсең *боланнар мөгезе*
Күренә ялангыч таллыктан.

Яисә:

Җилләре дә йөгереп килеп,
Битемнән үпкән була.
Юлың йомшак булсын, дипме,
Ак карлар сипкән була.

Әлбәттә, аның ул хисләрен яшермичә, турыдан-туры әйткән гыйбарәләре дә бар.

Әйтсәгез Себерем хакында:
“Үткәндә каргалган җир булган”,
Каргалса каргалсын, аңлагыз,
Ул минем туган җир. И туган!

Яисә:

Бу дөньяда
Себер агачының
Мин бер серле,
Моңлы яфрагы.

Андый хисләрен ул бигрәк тә Себердән читләргә киткәч, мәсәлән, Казанда яшәгәндә, Кавказда, диңгез буйларында кәгазьгә төшереп, эчен бушаткан.

Казандагы топольләргә
Себер җиле хәбәр иткән:
Мин утырткан каенкаем
Мине сагынып җырлый икән.

Мондый юлларны укыганда без шагыйрьнең шәхси хистойгыларын аның белән бергә кичерәбез, шул ук вакытта аның Себере аша үзебезнең туган якларга кайтабыз, аны сагынуыбызны, җирсүебезне басабыз – чын шагыйрьнең сихри гомумиләштерү көче шушыннан гыйбарәт тә бит. Ул да бит Себеренә генә йомылмый, тар күңеллелек күрсәтми. Аерым алганда, аның Казан турындагы шигырьләре безгә аеруча якын.

Туган җирем мине ир булырга,
Чигенмәскә юлда өйрәтсә,
Синең моңнар миңа
Канат бирде,
Җыр уятты кыргый йөрәктә.

“Моң” дигәндә Булат, әлбәттә инде, җыр, музыканы, шигърият-не генә түгел, Болгарны да, Сөембикә манарасын, Тукай һәйкәлен, Аккош күлен, Идел, Кабан буйларын да, үзе укыган университетны да күз алдына китерә.

Яхшы аңлыйбыз ки, шагыйрь мин яшәгән, син яшәгән төбәккә мәдхия җырлаудан бигрәк, кайда гына яшәвебезгә карамастан, барыбызга да бердәй тәэсир итәрлек, барчабызның күңел хисләрен бер дәрәҗәдә тибрәтеп, җаннарны илһамландырырлык хәситәләр эзли. Таба да. Менә шундый образ, сурәтләрнең кайберләре генә:

Ак калфаклы шаулы дулкыннарың җырларыма кереп калганнар...
Авыр икән канат кагулары – дулкынланып калды күл өсте...
Көн егылды. Төн, тол хатын сыман, толымын сүтте...
Түземсезлегемнең җәя җебедәй тартылган чагы...

Менә мондый хәситә-сурәтләрнең, аерым бер җанда-күңелдә бөреләнеп тә, башка күңелләрдә чәчәк атуы шигъриятнең серледән-серле могъҗизасыдыр. Шулай да бу могъҗизаның бер серен мин тоям кебек: ул сурәтләрнең яралгысы һәм дә тукымасы барыбызга да бердәй аңлаешлы вә кадерле ана телебез булуыдыр. Татар теле! Тел ул шагыйрьнең хис бөресенә оеткы да, аңарга канат та.

Булат Сөләйманов та татар әдәби теленең бөтен байлыгын, нечкәлеген, тәмен, моң-аһәңен тоеп иҗат итә. Шушы илаһи көчкә табынуын, аның бөеклегенә горурлануын ул яшерми дә. Менә аның “Җирсү” шигырен тыңлыйк әле: шагыйрь туган авылы Сопрага, үз сүзләре белән әйтсәк, “сагынуларын салып иңенә”, кайтып төшә.

Шушы йортта
Әнкәм назы сеңгән,
Туган телем сеңгән күңелгә,
“Һаваларда очкан аккошларның”
Туган йорттан моңы сибелә.

Аңлыйсыз булыр: мондый изге сүзләр, чыннан да, бишектән үк, әти-әни назы белән сугарылган иң кадерле вә җанга иң якын сүзләр белән генә язылa ала. Ишеттегез-күрдегез: аның рухына якын бу сүзләр – барыбызга да аңлаешлы, кадерле татар әдәби теле сүзләре.

Дөрес, “туган телем” дигәндә ул туган ягы сөйләмен күз алдында тота. Мәгълүм ки, Себер диалекты татар әдәби телен тулыландырып,

баетып торган диалектлардан санала. Аның берникадәр үзгә авазларын, морфологик һәм лексик чараларын да шагыйрь әдәби телне яхшы белгән кебек, җентекле белә, кирәк булганда аларга да мөрәҗәгать итә. Шулай иткәндә сүзләрнең без ишетеп күнеккән мәгънәләренә өстәп, яңача төсмерләре җемелдәп-җемелдәп китә. Мәсәлән, "теләнчегә җил *отыры*", "Дагаң табып, бәхеткә дип, // Кактым капкам *кашына"* яисә "карны каралты-курага, өйләргә *сылап* йөри иде" һәм башкалар.

Ара-тирә шигырьгә әдәби телдә булмаган йә бик сирәк куллана торган берәмлекләрне дә кертеп җибәрә: *зәң, сирәнкә, төрәкә, шеңкә, кус, ашык* һәм башкалар. Шулай да калын бер китапта алар бер дистәдән артмыйдыр. Хикәяләрендә дә ул аларны кулланмый диярлек, инде алмаска һич мөмкин түгел, дип санаганда ул, әсәрне бөтен татар халкы укый икән дип исәп тотып, андый берәмлекләрне ничек тә төшендереп бирү чарасын эзләп таба. Мәсәлән, "Арыксы егетләренең Розалия кебек чибәр кызларга карата мактау сүзләре бер генә – *"курцак шикелле"* дип әйтәләр, яисә "Мин утырган шушы төп башыннан урман башланып китә. Яки үзебезнең Себер татарлары телендә әйтсәк, *төс* башланып китә".

Хикәя димәктән, бу китапка Булат Сөләймәновның проза әсәрләре – хикәяләре һәм публицистикасы да кергән. Аларга да җәенке анализ ясарга җыенмыйбыз. Беренче тәэсирне генә уртаклашып китик: талантлы шагыйребез хикәя остасы да икән әле. Һәм монда да ул туган ягына мәхәббәтен бүтәннәргә дә йоктыру өчен уртак ана телебездән бик тә оста файдалана икән.

Сизгер укучым-тыңлаучым шәйләми калмагандыр: берничә тапкыр инде мин Булат Сөләймәновның нәкъ менә татар әдәби телендә язуын тәкърарладым, шуны исбат итәргә омтылдым. Нигә? Татар шагыйре икән, ул тагын нинди телдә язсын ди! Әйе, мин дә бу хакыйкатьне аңлыйм да бит, бәлки бу язмага алынмаган да булыр идем дә бит, тик, нишләмәк кирәк, моңа Булат үзе, җыентыгында иң азакта бирелгән ике урысча публицистик язмасы сәбәп булды.

Язмаларның эчтәлеге бер үк диярлек: борыңгы заманда Себердә мөстәкыйль дәүләт (ханлык) булган, анда мөселман халкы яшәгән, аның төрки нигезле, әмма башка төрки халыклардан үзгә аерым теле булган. Хәзер менә шуларны кайтарырга кирәк. Үз чикләре, үз икътыйсады, мәдәнияте булган дәүләт оешсын, Казан татарларыныкыннан нык аерылган үз теле кайтарылсын, шул телдә мәдәнияте, әдәбияте үссен.

Ирек рухлы шагыйрь үз ягының гасырлар буе изелеп, кимсетелеп, милли асылының, туган теленең тәмам бетү хәленә төшерелүенә җан

ачысы белән әрнүен ничек басарга белмәгән, моның сәбәбен ул Себер сөйләмен Казан татар теленең “басып алуы” белән, татар теле галимнәренең аны, янәсе, кимсетеп, диалект кына дип атауларыннан күрә. Ул елларда, һәм әле хәзер дә, бер себерләр генә изелгән дә, татар мәктәпләре Себердә генә ябылып беткән дә, татар телен тамырдан корыту сәясәте бер Себердә генә булган да, бүген дә бер Себердә генә хөкем сөрә диярсең!

Әлбәттә, шул заманда әле ул моның төп сәбәпчесен ачып бирә алмаган. Шуңа күрә дә язмаларында каршылыклар “чекерәешеп” тора. Әйтик, аныңча себер-татар лексикасының нигезе – гомуми төрки сүзләр. Себер татарларының 40 проценты төрекләшкән угор-фин халыкларыннан, ягъни телләре дә шул халыкларның төркинә лексикасыннан тора булып чыга. Ислам дине кабул ителгәннән соң күпләп гарәп алынмалары кергән, ди. Бик дөрес, нәкъ шулай. Димәк, бүгенге татар әдәби теле нинди булса, себер татар теле дә шундый булып чыга. Шул ук вакытта акка кара белән болай дип язылган: “Мы, сибирские татары, самостоятельный народ со своим удивительным самобытным языком, который отличается от всех тюркских языков”.

Өзекне нинди телдә басылган, шундый телдә күндердек. Ул татарча язылган булса әлеге каршылык ярылып ятар иде, ягъни татар әдәби теленнән үзгә бернинди Себер теле юклыгы ап-ачык күренер иде.

Үзе үк ул икенче бер урында болай ди: “Естественно, каждый народ хочет выжить. И мы, сибирские татары, хотим говорить на том языке, на котором разговаривали наши предки, хотим обладать теми озерами, реками, полями, лугами, лесами, которые оставили нам в наследство...”.

Афәрин, Булат кардәш, бик тә дөрес фикер. Барыбыз да шуны тели, шуңа омтыла. Тик моңа ирешү өчен Себер диалектын татар әдәби теленә, димәк, аны Казан арты – Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Сибгат Хәким сөйләменә яисә көнбатыш – Һади Такташ, Кави Нәҗми сөйләменә каршы кую, Себер татарын бүтән төбәк татарларына каршы куеп ирешеп булыр, дип уйлау гына – чеп-чи мәгънәсезлек бит! Ата-бабалар теленә килгәндә дә үзең үк бит җаныңнан чыккан шигырьләреңдә: “телләре дә гүя таныш кебек, ул телләрдә, димәк, җирлегем”, бишектә үк “һаваларда очкан аккошлар” җыры белән тәрбияләндем, дип яздың бит.

Шагыйрь мирасында әлләни әһәмияте булмаган бу язмаларны җыентыкка кертмәскә дә, инде кергән икән, игътибар бирмәскә бул-

ган булыр иде дә бит, юк шул, бүген килеп, шагыйрьнең шигырьләреннән бигрәк менә шушындый сәяси, “ачышларын” якынрак күреп, шуларны күпертеп, шулардан үзләренә файда итәргә маташынулар да бар икән. Иң аянычы, алар шуны милләтебезне, уртак телебезне таркату максатында байрак итеп, чынында кәнфит вә камчы итеп эшкә җигәләр икән.

Саф татар әдәби телендә язып, себерләрнең генә түгел, бәлки бөтен татар халкы ихтирамын казанган, шулай итеп барлык татар укучыларын, гомумән, милләтебезне берләштерүгә өлеш керткән шәхесне бүген килеп таркату, бүлгәләү максатында файдалану – шагыйрь рухына, аның хәтирә-истәлегенә карата моннан да мыскыллы түбәнлек тагын да була алырмы?! Шушы олуг уртак телебездә язганга, аңа табынганга күрә дә бит Булат Себер кысаларыннан чыгып, татар яшәгән барлык төбәкләрдә дә мәгълүм булды. Себерне дә данлады.

Шик юк ки, Булат Сөләйманов киләчәктә дә яшәр, аллаһы боерса, Себерен киләчәктә дә данлар, китапларын Себердә дә, Казанда да бастырып чыгарырлар. Тик моның өчен бер шарт зарур: Булат хыялланган мөстәкыйльлек, милләтнең кайда гына – Себердәме, Урал, Идел буйларындамы – яшәвенә карамастан, үз байлыгы, үз мәмләкәте, үз мәдәнияте булып, чәчәк атканда, үзенең уртак телендә уйлап, укый-яза, аралаша алганда гына.

Әгәр милләт, халык таркала икән, аның мәдәнияте, әдәбияте, башка тарихи уртак казанышлары, теле дә вакланачак, төссезләнәчәк, хәлсезләнәчәк, зәгыйфьләнәчәк. Һәм, тфү-тфү, әстәгфирулла, бетү-югалуы да ихтимал!

Йомгак сүзебез шушыдыр: татар шагыйре, сөекле уллары Булат Сөләймановны искә алып, Себердә дә татар әдәби телендә китап чыгарып, себерләр изге бер эш эшләгән. Киләчәктә дә башка шагыйрь, әдипләребезнең, яшь иҗатчыларның да китапларын, мәктәпләргә дәреслекләр чыгарсыннар иде. Бу милләтебез, телебез саклансын, үссен өчен алардан да зур өлеш булыр иде.

ОСТАЛЫКНЫ ТОЕМЛАУ

(Туфан Миңнуллинның тел куллану тәҗрибәсеннән)

Туфан Миңнуллинның, язучы буларак, үзенең төп эш коралы – ана теленә мөнәсәбәте, аны куллану үзенчәлеге турында фикер әйтү теләге күптән туган иде инде. Дөресрәге, бу теләк әле дә, һәр әсәрен

диярлек укыган саен, кабынып-кабынып тора. Тик бу чаткыларны укмаштырып бер йомгак итәрдәй “кызыл җеп” күзалланып бетми иде.

Ә мондый теләкнең кабынып китүе дә, бер язучы иҗатын еллар буе өзлексез күзәтә-өйрәнә барганга көчәйгәннән-көчәюе дә очраклы түгелдер, табигыйдер, дим; ник дигәндә, үземнең дә, журналист буларак, эш коралым татар теле; фәнни эзләнүләрне дә шушы юнәлештә алып барам. Ниһаять, бүгенге төп хезмәт вазыйфам да журналист-студентларны иҗатта ана телен куллану үзенчәлекләренә өйрәтү. Аңлашылса кирәк, мин шуларга үрнәк алырлык, үз мисалында өйрәтерлек остаз эзлим. Хәзер менә Туфан Миңнуллинга да тукталуымның нигезсез түгеллеген исбат итәргә тиешмен.

Туктале, нигә Туфан Миңнуллинның ана теленә мөнәсәбәтен ачыкларга алынуымны болай озаклап, тәфсилләп төшендерәм? Монда бит әлеге теләк минем галим яисә укытучы булганымнан түгел, бәлки язучыбызның әсәрләрен телебезнең бөтен көчен, нечкәлекләрен, моң-аһәңен тоеп, үтемле, тәэсирле итеп язуыннан тәм, ләззәт, канәгатьләнү алганга туган. Башка бихисап укучыларда туган кебек.

Күпчелек укучы моны, шулай булырга тиеш, дип саный (“язучы да үз коралын яхшы белмичә, аны хәстәрләп, чарлап тормаса, бүтәннәргә ни кала!”), бу хакта фикер әйтүне кирәк тә санамый, йә бик кыска тота, эчтән ләззәтләнеп, сокланып, язучыга рәхмәт әйтә дә – вәссәләм. Без инде фикеребезне киңәйтебрәк бәянләргә җөрьят итәбез икән, бу, әйткәнебезчә, вазыйфа кушканга, башкаларга да кирәге чыкмасмы, дип.

Үзенең төп коралы, аның белән ничек-ничек эш итүе турында оста үзе төшендереп бирсә, хәерлерәк булмас иде микән? Ни әйтсәң дә, үзенең коралын аңардан да яхшырак тагын кем белә; гәрчә “корал эшли, ир мактала”, диелсә дә, чын ир, чын оста коралының кадерен бик белә, хөрмәт итә, карап кына тора. Әлбәттә, аның хакында оста үзе тәфсирләсә, бик хуп булыр иде. Без бит ана телебезнең барлык мөмкинлекләреннән оста файдаланып, сокландыгыч әсәрләр язып, бер үк вакытта шул осталык тәҗрибәсен үзләре үк ачып биргән, телебезне иҗади куллануның олуг сабагын калдырган Гомәр Бәширевне, Хәсән Сарьянны беләбез. Дәвамчылар бик кирәк тә бит. Хәер, тормышта күз явын алырлык йорт яисә берәр җиһаз ясаган останың үзенең балтасы яки станогы турында, берәр чемпионның үзенең чаңгысы яисә тубы турында сөйләве йә язуы сирәк очрый

торган хәлдер. Моны күбесе җитди эшкә санамый да. Язучыларның да күпчелеге шул фикердә шикелле.

Мондый хәл аларның төп коралга битарафлыгыннан дию һич дөрес булмас. Кем әйтер, Туфан Миңнуллин үзенең тел байлыгына, аннан сөйләм оештыру үзенчәлегенә, гомумән дә тел төшенчәсенә, аерым алганда, үзенең туган теле – татар теле – мәсьәләләренә битараф, гамьсез, дип. Һич юк! Коралы – теле турында ул, даими үк булмаса да, еш уйлана, фикерләрен теркәп тә бара; шул темага басылып чыккан этюд, парчалары да аз түгел; әлегә алар504 бербөтен әсәр (тикшеренү) рәвешендә язылмаган, язылган хәтлесе дә бер мәҗмуга хәленә китерелмәгән генә.

Без исә андый хезмәт һичшиксез башкарылыр дип нык ышанып калган хәлдә, бүген әдипнең туган телнең язучы иҗатында гына түгел, бөтен халык яшәешендә, аның язмышында тоткан урыны турындагы фикерләрен бер җепкә тезебрәк үзебезнең күзаллау рәвешендә бәян итеп карарга булдык. Ул “җепне” “Туфан Миңнуллинның публицистикасында татар телен куллану үзенчәлеге” дип тәгаенләргә булыр иде. Фактик материал, мисаллар башлыча аның “Утырып уйлар уйладым” дигән публицистик китабыннан алынды.

Шул китапта язучының үзенең үк “Туфан Миңнуллинның язучы буларак төп коралы – ана теленә мөнәсәбәте нинди? дигән кызыксынуны берникадәр канәгатьләндерерлек фикере бар: “Мин тел буенча белгеч түгел. Мин татар теленең – үз телемнең матурлыгына (барлык телләр дә матурдыр), байлыгына (башка телләр дә байдыр) сокланып иҗат итүче генә. Кайвакытларда туган телемнең бөтен нечкәлекләрен белеп бетермәвемә үземне ачуланам да. Әмма миңа шунысы рәхәт: мин аны тоям. Мин туган телемдә әйтелгән сүзләрнең исен дә сизәм, хәтта төсен дә күрәм. Юк, бу кылану да, алдашу да түгел...”.

Әйе, “тел тоемлау” бу очракта – тирән мәгънәле, фәлсәфи, фәнни бер төшенчәдер. Ул язучыга үз коралын аңлау, сәләтен үлчәү-бәяләү өчен, ә укучыга аның осталыгы серен ачар өчен тылсымлы ачкычтыр. Ике тараф та аның ни икәнен сиземли, берникадәр күз алдына китерә. Дөрес, Т. Миңнуллин төшенчәгә әлегә фәнни аңлатма бирми, шулай да телне тоемлавының “алдашу” түгеллеген әсәрләренең буеннан-буена мисаллар белән дәлилли килә. Аңлаган кешегә төртеп күрсәтмичә дә аңларлык. Менә бер генә мисал: “Йөрмәгән җир калмады. Юк кычыткан. Төртеп чыккан берен, күрәсең, җыеп алып ашап барганнар. Өйгә буш кайтсам, әни әрләүдән куркам. Ул бит ачуны китерә торган бер сүз

әйтеп әрли. Шушы булдыксызга эш кушкан мин җүләр, ди. Булдыксыз сүзен ишетүдән дә авыррак сүз юк минем өчен".

Т. Миңнуллинның "тел тоемлавын" ачыграк күзаллау өчен ике җәпле фикер йөртергә кирәк. Беренчесе, каян төшкән аңарга бу "бәхет орлыгы"? Икенчесе, аны ул ничек шулай "үстерә", эшкә җигә белә? Беренчесенә килгәндә, табигать аңарга, чыннан да, телне олы бер бик кирәкле хәзинә итеп тоемларлык, үзенең зәвыгын, ихтыяҗын канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә, мул итеп биргән. Бу аңарга нәселдән, әти, әнисеннән килә. Әтисе белемле булган. "Урысча шәп белә иде. Гарәпчә язуны да су кебек эчә иде. Язу яздырырга әти янына киләләр иде (урысча да, татарча да). Иске китаплардан ул "Йосыф-Зөләйха"ны безгә кычкырып укый иде". Ул шигырьләр язып, район газетында бастырган.

Әнисе үз төбәк халкының сүз байлыгын, тапкыр һәм канатлы гыйбарәләрен, сөйләм моң-аһәңен бик яхшы белеп, шуны балалар тәрбияләгәндә, тормыш иткәндә оста файдаланган.

Туганнары, авылдашлары да татар телендә генә аралашып, кызыксынучан Туфанга да тәмен сеңдергәннәр. Зиһенле бала бу хәзинәне милләт җанлы булганга да, язар өчен кирәк булыр, дип тә хәтеренә җыя барган. Моңа мәктәп тә өстәгән; матур әдәбият укуның да файдасы тигән. Тормыш нечкәлекләренә битараф булмау, аларны бүтәннәргә дә җиткерергә омтылу – болар барысы да ана теленә игътибарлы булырга, хөрмәт белән карарга күнектергән. Кыскасы, сүзнең тәмен, исен тоярга аны тормыш өйрәткән, ә өйрәнү өчен ихтыяҗ һәркемгә үткәзерлек итеп язу омтылышы, җаваплылыгы булган.

Менә шуңа күрә дә без аның язганнарын бер сулыш белән, төртелмичә-көчәнмичә, тәмләп су эчкән кебек "эчәбез дә эчәбез", күпчелегебез "нигә шулай җиңел, шома укыла?" дип сорау да биреп тормыйбыз, уйланган очракта да "тормышны яхшы белә", "милләтенең үз баласы", " йөгрек каләмле", дип тынычланабыз...

Шул ук вакытта фикернең икенче җәбе дә истә: "тел тоемлау"ның Ходай биргән сәләте генә шулай шома, төерсез язарга җитә микән? Хәтта гади укучы башына да шундый уй килә икән, иҗат кешесе һич шөбһәләнмичә: "Җитми!" дияр. Никадәр талантлы булсаң да, болай тел-теш тидермәслек диярлек язу үзеннән-үзе була алмый, дияр. Талант ул, чыннан да, хезмәт нәтиҗәсе бит.

Менә шушында инде үз коралын энәсеннән-җебенә белгән, аны хөрмәт итеп, кайгыртып, чарлап торган, шуның белән соклангыч әйберләр ясаган алтын куллы оста күз алдына килеп баса да.

Т. Миңнуллин да үзенең төп коралы-инструментын без күрмәгәндә-белмәгәндә махсус “чарлап” торадыр? Хәер, авторның бер генә әсәрен укып чыккач яисә сәхнәдән бер генә әсәрен карап бу хакта әле аерып уйланмыйсың. Инде әсәрләрен бер-бер артлы даими укып барсаң, язучыбызның “тел тоемлавы”ның эчке хәсиятен, сулышын төшенгәннән-төшенә барасың.

Иң әүвәле, Т. Миңнуллинның ана телебезгә битараф түгеллеген, аны шәхси иҗат коралы буларак кына түгел, ә бөтен милләтенең уйлау, аралашу, яшәү чарасы буларак кирәклеген, бүгенге хәлен, киләчәген кайгыртуын аңлаганнан-аңлый барасың. Дәлилләргәдер? Башта бер искәрмә. Т. Миңнуллин, башлыча, драматург буларак танылган. Шулай да, гәрчә аның драма әсәрләрен дә укып барсам да, аларның тел ягын өйрәнүне максат итеп куймадым. Алар бит сәхнәдә уйнар өчен языла, димәк, бу очракта спектакль сөйләме бәяләнергә тиеш була, ә сәхнә сөйләме ул – күмәк иҗат җимеше – әсәрнең нигезен драматург салса да, һәр персонажның сөйләмен үзе бөртекләп тупласа да, сөйләмгә бары-бер режиссер һәм актер өлеше дә керми калмый.

Бер үк вакытта әдипнең “тел тоемлау” закончалыклары публицистик әсәрләре белән беррәттән тулысынча драматургиясенә дә кагыла, дип саныйм һәм хәзер шуларга тәфсиллерәк тукталам.

Әдип телне нинди максатта тоемлый, “тоемлаган тел”не нишләтә ул, ягъни язучының “тел өстендә эшләве” нидән гыйбарәт? Әлбәттә инде, төп максаты үтемле, тәэсирле, аһәңле сөйләм оештыру. Нәрсә ул сөйләм? Тирән фәннилеккә төшеп китмәстән вә инде әйтелгәннәрне дә кабатламас өчен, без моны гади укучы “каланчасы”ннан төшендереп карыйк. Язучы, журналист, гомумән дә, кешегә ана телендә тәэсир итәргә алынган теләсә кайсы иҗат иясе, аның асылын яхшы белергә тиеш. Сөйләмгә тел чаралары – сүзме, канатлы гыйбарәме, җөмлә төреме – сөйләм мотивларына (сәбәпләренә) карап эзләп табыла. Алар: сөйләмнең иясе, адресаты, нияте (максаты) һәм шарты (язылмы, әйтепме һ.б.).

Т. Миңнуллинның “тел тоемлау” дигән серле ачкычы менә шушы нечкә “механизм”ны тоемлавы да инде ул. Әйтик, аның өчен сөйләм иясе авторның үзе генә түгел, ә барлык әсәрләренең персонажлары да. Ә алар аның иҗат арсеналында күпме икән! Моны санап чыгу мөмкин дә түгелдер. Җитмәсә, яше, һөнәре, җенесе, яшәгән урыны, социаль хәленә, холкы-табигатенә карап алар нинди төрледән-төрле! Язучы, бер яктан, шул үтә дә төрле шәхесләрне тәэсирле итеп тасвирлау өчен, фәнчә әйтсәк, чын образ тудыру, ягъни хәтергә сеңеп калырлык итеп

сурәтләү-гәүдәләндерү өчен, төрледән-төрле сәнгати чаралар эзләп таба. Икенче яктан, һәр персонажның үзенә хас сөйләү үзенчәлекләреннән дә файдалана – моның белән аның уңаймы, тискәреме тәэсир ясавына ирешә. Күз алдына китерегез: аның гади эшчесе үзенчә, авыл агае үзенчә сөйли; бар яшүсмере, бар карты, түрәсе яисә зыялы, артисты яисә шоферы – без аларны сөйләменә карап та аерабыз. Шәхсән үземә, мәсәлән, читкә китеп ана телен оныта язган татарның, элекке спекулянт мишәр татарының, Финляндиядә яшәүче татарның сөйләм үзенчәлеге аеруча тәэсир иткән.

Боларның һәркайсына мисал-дәлил китерү язмабызда урынны күп алыр иде, кызыксынган укучым аларны үзе дә эзләп табып, тагын бер мәртәбә ләззәт кичерә алыр.

Сөйләм үзенчәлекләрен бирер өчен татар теленең төрле катлам, стиль, һөнәри, тарихи, диалектологик мөмкинлекләрен барлау белән бергә төрледән-төрле жанр, композиция үрнәкләрен дә эзләп таба: язучы персонажының сөйләм күчермәсен монолог рәвешендә бирә; сөйләшеп утыру сыйфатында яза – диалог; хат тексты итеп; персонаж фикерен өченче берәүнең монологы итеп; кайчандыр тыңланганны хәтердә яңартып, үзенең сөйләме рәвешендә һ.б.

Менә без “тел тоемлау” дигән тылсымлы төшенчәнең асылын акрынлап ача барабыз – ул табигать биргән сәләтеңне үзең үк гамәлгә ашыруың икән ләбаса. Һәр иҗатчы, һәр сөйләм иясе өчен бурыч бер: әйтергә, белдерергә теләгән мәгънә-төшенчәгә тәңгәл сүз табарга һәм сөйләмдә аны нәкъ үз урынына куярга. Таләп, бурыч бер дә бит, тик аны үтәү чара-юллары бик төрле. Шулардан һәр әдипнең осталык “мәктәпләре” барлыкка килә дә инде. Туфан Миңнуллинның тәҗрибә остаханәсен тулаем ачып бирү мөмкин эштерме, әйтүе кыен, шулай да берникадәр омтылыш ясап карыйк.

Белдерәсе мәгънә-төшенчәгә нәкъ тәңгәл сүз, гыйбарә табу өчен төрледән-төрле иҗади алымнар, грамматик, лексик чаралар кулланыла. Менә кайберләре:

– сөйләмдә шундук аңлашылмый торган яисә томанлы, икеле-микеле берәмлек булмаска тиеш. Менә бер караганда *изү, котсыз система* дигән сүзләр хәтта контексттан тышта да шактый ачык аңлашыла – тискәре мәгънәгә бәрәбәр сүзләр. Тик моны белүдән генә укучы тәэсирләнми, чөнки конкретлык җитми. Бу кимчелек булмасын өчен автор алардан алдагы контекстта конкретлаштыра торган сурәтләү ясый – бер әбинең гомер фаҗыйгасын тәфсилле детальләр, фактлар белән бәян итә, хисле сүзләр белән тасвирлый. Менә шуннан

соң инде ул китергән хаттагы “Безне *изгән котсыз система*га гаепләү акты булып саклансын”, дигән, бер карашка “купшы”, абстракт гыйбарәсе дә тәэсир көченә ия була;

– әдипнең мәгънәдәш берәмлекләре (синонимнар) запасы бик мулдан. Аларны ул инде конкрет берәмлеккә өстәмә мәгънә, хис төсмере бирер өчен, төгәллек кертү өчен куллана. Моның өчен лексиканың төрле стиль катламнарыннан (китаби, һөнәри, фәнни, рәсми һ.б.) вариантлар тәкъдим ителә: “Безне ул (әнисе) эшләмәгән өчен түгел, ә *рәтсез* итеп, *эштер-өштер* генә эшләгән өчен ачуланды...”; “Әни яшәгән ара илебезнең шактый ук *катмарлы* чорына, тормышыбызның бик киеренке чагына туры килгән заман”. Текстта гадәти көнкүреш тоны рәсми, китаби тонга күчкәч, *катмарлы* варианты урынлы кебек тоела;

– шул ук вакытта сүзне төрләләндерүдән мәгънәгә хилафлык киләчәген тойса, ул аны төрләләндерергә ашыкмый, кабатлаудан ваз кичми: “Кайчакларда ялкауланып китеп, *эшләргә* тиешле *эшем эшләнми* торса, әнине искә төшерәм дә оялып *эшкә* тотынам”.

Чын иҗатчы буларак, Т. Миңнуллин лексик арсеналны баетуга вә камилләштерүгә үзе дә өлеш кертә:

– элек кулланылып та безнең чорда пассивлашкан сүзләрне эзләп табып, җанландыру хәстәрен күрә: “Кайвакыт урамда чибәр егетне култыклаган *мәшүрәтне* күрәсең дә...”;

– алынмаларга талымсыз түгел, арзан тормышчанлыкка бирелми, мәгънәне, хисне көчәйтү өчен генә куллана: “Түзүнең дә бер чиге булырга тиеш, *канса да кансов,* дип уйладым”. Гади сөйләмгә җайлашкан вариантларны да неологизм ясарга файдалана: “Кияүгә чыгып бер ай да тора алмаган, ире ялгыш сүз әйтсә, чәчрәп судка йөгергән *келтрифүнләләр*гә Рабига апа турында сөйләргә кирәк”. Неологизмны чит-ят варваризм дип санаса, ул аңа аңлатма бирә: “Мин бу игътибарга мөкиббән китеп, рәхәтләнеп *дуракавәләйт* итәм, ягъни, мәсәлән*, бии белмәсәм дә биим”*.

Кыскасы, язучыбыз һәр сүзне, коралы буларак, күңеле аша үткәрә. Уйлану-эзләнү барышында ул фәнни алымнардан да файдалана, тарихи лингвистика, этимология биләмәләренә керүдән дә курыкмый. Мәсәлән, аның *тау* сүзе белән бәйле егермеләп сүзтезмәне барлавы, аларның этимологиясен милләт тарихы белән аңлатырга омтылуы кызыклы. Яки *ит йон эчендә була* дигән әйтемнең төбенә төшәргә тырышуы игътибарга лаек.

Әлегәчә без Т. Миңнуллинның “тел тоемлавын” аның сүз тоемлавы, сүз белән эш итүе тирәсендә ачыкладык. Тел дигәндә, сүз әле ул төп коралның бер өлеше генә. Тел әле ул сүзтезмә дә, җөмлә дә, бүтән синтаксик тезелмәләр дә. Т. Миңнуллин аларын да нечкә тоемлый, алар белән дә осталарча иҗади эш итә. Сүзнең тәэсир көче аерым торудан бигрәк сөйләм эчендә төгәлрәк ачыклана, шуңа күрә язучының синтаксис (нәхү) остасы булырга тиешлеге табигыйдер. Т. Миңнуллинга карата менә кайбер мисаллар гына – ул төрледән-төрле синтаксик фигураларны оста файдалана:

– **кабатлау**: “Минем бөтен дөнья мәдәнияте белән таныш буласым килә. Ләкин татарлыгымны югалту исәбенә түгел. Нишлим, мин *татар гына,* бары тик *татар гына*”;

– **стиль әйләнмәсе**: “Әмма ни генә димәсен, ул апаның *җаны имгәнгән. Имгәнгән аның җаны*”; *“Безнең авылныкылар түгел алар. Безнекеләр түгел. Түгел алар безнекеләр”*;

– **чагыштыру:** “Печәнне ул *оста парикмахерлар сокланырлык итеп* чаба иде, атны ул җиксә, иң йолкыш ат та тәртә арасында *көяз булып күренә* иде, утын ярырга тотынса, иң ботаклы түмәр дә *өлгерүе килгән карбыз шикелле* шартлап ярыла иде”.

“Тел тоемлау” – ул тулаем сөйләмнең (ягъни текстның) төрледән-төрле кисәк-өлешләрен, аларның бәйләү чараларын, тулаем текстның аһәң-моңын тою да. Аерым алганда, драматург Т. Миңнуллинның телнең туры сөйләм, диалог кебек категорияләрен яхшы белү, сөйләмне оста куллануы игътибарга лаек. Аның һәр төр әсәрендә персонаж сөйләменә әһәмият бирү гадәтен әйткән идек инде. Нәкъ шушы персонаж сөйләменә тач килгән сүзне, гыйбарәне табар өчен аңарга күпме сүз көшелен җилгәрергә туры килә! Ул һәр әңгәмәдәшенең сөйләменә игътибарлы: “Мөхәммәт Мәһдиев һәм аның абыйсы белән Тукай музееннан кайтып киләбез. Сүздән-сүз чыгып, ярлылык, хәерчелек, теләнчелек турында сөйләшеп киттек. Мөхәммәт телгә оста – һәр сүзен кәнфит кәгазенә төреп бирә. Абыйсы да аннан күпкә калышмый икән...”.

Персонажның сөйләм үзенчәлеген авторыбыз аңа бәя бирү, аны сурәтләү-тасвирлау чарасы итеп куллана. Бик тә чибәр, әмма бүтәннәргә ифрат гамьсез кызны бары бер сүз белән ачып бирә: “Йа, хода, кызымның керфекләре селкенде. Күзләре кысылды. Шундый итеп чирканып карады миңа, кинәт маңаема тир бәреп чыкты. Үзем дә сизмәстән: “Гафу итегез”, – дидем. “Чево...” – диде дә бу үземне генә калдырып... китеп барды”.

Шунысы хуплауга лаектыр: күп очракта авторның тоны белән персонажының тоны бер дулкында була. Бу – әсәрнең бер аһәңдә, бер яңгыраштa булуына китерә. Менә аның бер герое монологыннан өзек: “Сез сарык булып бәэлдәгән кәҗәне күргәнегез бармы? Озакламый булачак. Безнең дә телебезгә төкерүебез – шул үзгәреш галәмәте. Ничек инде ул, мәсәлән, кеше үз телендә сөйләшергә теләми? Алай булмаска тиеш бит инде, ә менә була...”.

Шул ук вакытта “тел тоемлавы”на никадәр таләпчән булмасын, ана телебезне кулланудагы заман кимчелекләре Т. Миңнуллин иҗатында да чагылып-чагылып китә:

– **калька** зәхмәтеннән ул да азат түгел: “*...күзлегеннән чыгып караганда*” кебек татарның үз калькалары да очрап куя. Гәрчә күп кенә каләмчедән аермалы буларак, ул әле “*Мин утыра торган өстәлгә...*” дип саф татарча язарга батырчылык итә;

– **артыклыклар**, мәсәлән, лексик тавтология: “*Мин үзем* кайсына керәм икән? *Мөгаен,* икенчесен*әдер*”. “Еш уйлага*ным* бар *минем* ул турыда”.

Әйтү белән язу арасындагы аерманы тоемламау кебек күпчелек язучыга хас кимчелек бу әдибебездә сирәк очрый. Шулай да, мәсәлән, “авыл *әкренләп* (*акрынлап* урынына) тарала башлады” кебек, сингармонизм законы үтәлмәгән фразалар юк-юк та очрап куя.

Нәфис публицистикада “үзләре дә *үкенеп туя* алмыйлар”, “шулаерак *кебек сыман шикелле* тоела” кебек кытыршылыклар, артыклыклар да ят сыман.

Аның каруы “тел тоемлау”ның иң югары ноктасы саналырга хаклы канатлы гыйбарәләр, тапкыр һәм үткен фразеологик неологизмнар еш очрап, куандыра, теге кимчелекләрне дә гафу иттерә. Аларны әле махсус өйрәнәсе бар, ә хәзергә берничә мисал китерү белән чикләнәбез: *нәселен белмәгән кешегә диңгез тубыктан; түзүнең дә бер чиге булырга тиеш; кеше җаны ваклыкны өнәп бетерми; базда яшәргә күнеккән кешегә кояш нуры күрсәтергә ярамый* һ.б.

Әле күптән түгел генә язучының шушындый канатлы гыйбарәләр тупланмасы булып махсус китабы басылып чыкты. Гаҗәп үзенчәлекле, язучының нәкь менә телбизәк остасы икәнен төрле яклап күрсәткән хезмәт. Әле генә әйткән фикер-тәкъдимебезне кабатлыйбыз: язучының бу юнәлештәге иҗади сәләтен, осталыгын махсус өйрәнү зарурияте өлгереп җиткән.

Хәзер килеп бик әһәмиятле бер социолингвистик фактор турында уйланып алыйк. Т. Миңнуллин, күренекле драматург, язучы-

публицист, җәмәгать эшлеклесе буларак, татар телен үзенең шәхси иҗат коралы итеп кенә түгел, бөтен милләтенең иҗтимагый аралашу чарасы итеп тә нечкә тоемлый. Бу – шактый катлаулы күренеш. Асылы шунда ки, нәрсә генә уйласа да, яшәешнең нинди генә катлаулы күренешен бәян итсә, тасвирласа да, әдипнең фикерләве, бәяны ана теленнән аерылгысыз. Теләсә кайсы милли үзенчәлекне бары шушы милләт теле белән генә чын-чыннан аңлаешлы, үтемле итеп төшендереп була – менә аның иманы. Бу бер мисалда ачык чагыла: Бер парчасында ул белен пешерү осталыгының алар нәселендә буыннан-буынга күчә килүен сөйләгәндә бабасының “үзгәртмәгез кулыгызны” дигән тел гыйбарәсен сюжет нигезе итеп ала. Гадәттә беленне бик юка итеп пешереп дан тоткан нәселнең киленнәре бервакыт калынайтып җибәргәннәр. Нәсел данын төшерергә юл куймаска күнеккән карт кискен генә менә шушындый әмерне биргән... Киләчәктә бу канатлы гыйбарә теләсә кайсы уңай гадәтне үзгәртмәскә, яхшы юлдан читкә тайпылмаска кушылган амәнәт булып берегә. “Кул үзгәртмәү” кагыйдәсе телгә дә карый. Автор моны болай төшендерә: “Балаларыбызга бабайларыбызның телен өйрәнү шактый мәшәкатьле ич. Урамда нинди телгә өйрәнсә, шул җиткән. Сүгенә икән, сүгенсен, ни зыян. Юк инде, кулны үзгәртмәскә, ата-баба телен дәвам иттерергә!”. “Бабайлар белми генә әйтмәгән шул: үзгәртмәгез кулыгызны, үзгәртмәгез телегезне, үзгәртмәгез иманыгызны!” – дип ялкынлы төгәлли парчасын әдибебез.

Публицист бит ул нечкә тоемлаучы психолог та. Менә икесе дә ике аяксыз инвалидлар Гариф абый белән Рабига апаның утыз елдан озаграк ирле-хатынлы яшәп, бүтәннәргә үрнәк булырлык гаилә коруларын тасвирлаганда, кечкенә генә бер вакыйганы алып, татарча бер гыйбарәгә бәйләп бөтен бер психологик күренешне тирәнтен бәян итә: Гариф абый күршегә кереп бераз төшереп утыра. Рабига апа: “Ничек оялмыйча кердең кешегә. Гарип-горабә мени син, теләнеп йөрергә!” – дип, бик каты рәнҗи. Менә шушы, бер караганда, бик гади ишетелгән гыйбарәне катлаулы психологик тирәнлектә анализлаган язучы үзенчә тон табып, аңа бүтән бәя бирә: “Монда бер-берсе белән кулга-кул тотынышып, йөрәк белән йөрәкне бәйләп яшәүче ике олы характерның, ике көчле рухның бөтенлеге ята”, – ди. Язучының ана теленең төрле стиль катламнарын белеп, аларны урынлы куллануы телне чын-чыннан иҗтимагый корал итеп файдаланырга мөмкинлек бирә.

Милләтнең иң югары әхлакый сыйфатларының да турыдан-туры тел белән бәйле икәнен дә публицист берничә парчада ачык тасвир-

лый. Әйтик, туган авылны ярату, аны сагыну көчен тел кадерен белү белән тиңләштерә. Шәһәр балалары шәһәрне сагынмый, яратмый, ди, аның нәрсәсен сагынасың, дигәндә телне дә күз алдына китерә. “Аларның сагынып искә алырлык үз телләре дә, үз җырлары да юк. Алар, минем милләттәшләрем, бүтәннәр телендә сөйләшәләр, бүтәннәр җырын җырлыйлар. Ә бүтәннәрнең телен, җырын сагынып буламыни ул?!” – ди.

Янә иң катлаулы төшенчәләрдән Ватанны аңлатканда да аның нигез ташларыннан ул туган телне саный: “Чөнки ул җир минем кендегемнең каны тамган җир, аның зиратында әби-бабаларым ята, минем телем шушында ачылды...”.

Ниһаять, ирек, азатлык, мөстәкыйльлек төшенчәләре турында фикер йөрткәндә дә аның аңында тел аерылгысыз. Бу “алтын багана-лар”ның милләткә насыйп булыр-булмасының алшарты да тел иреге, тел мөстәкыйльлеге, дип саный. Моңа ул гомуми, купшы, декларатив гыйбарә-шигарьләр белән түгел, ә тормышчан, гыйбрәтле, халык хәтерендә сакланган мисаллар белән ышандыра.

Ана теленең чын-чыннан тәэсирле, көчле корал икәнен публи-цист-язучы аның белән кешеләр арасындагы теләсә нинди мөнәсәбәтне уңай хәл итеп булуын да ышандыргыч күренешләр белән, телебезнең реаль көч-сәләтен тормышчан мисаллар белән күрсәтеп бирә. Мондый мисаллар белән кешеләрне “ана телеңне ни-чаклы яхшы белсәң, тормышта шул чаклы җиңеллеккә, уңышларга тарырсың” дигән нәтиҗә ясауга китерә. Хәтерләгез әле: “Килен иртүк, кояш чыкканчы ук уянып, чыбылдык артыннан чыккан. Кайнанасы аяк өстендә икән инде. “Тордыңмы?” – дигән ул киленгә. “Тордым”, – дигән килен. “Тордым, әнкәй, дип әйтсәң, телең корыр идемени”, – дигән кайнана. “Тордыңмы, кызым, дип әйткән булсаң, тордым, әнкәем, дип әйтермен, әнкәй”, – дип җавап биргән ди килене.

Тагын бер әһәмиятле социолингвистик фактор: тел турында уй-ланганда да, сүз алып барганда да публицист-язучыбыз, табигый ки, үз ана теле – татар теле турында алып бара. Шул ук вакытта барлык телләрне дә күздә тота. Үз теленә мөкиббән китүе белән ул башка-ларныкын һич тә кимсетми. Кешенең уңай яисә тискәре сыйфатын бәян итәргә кирәк булганда, аның телен мисалга ала икән, бу һич тә гомуми телне түбәнсетү түгел. Үз телен яраткан, хөрмәт иткән, дөрес кулланган бүтән милләт кешесе – аның әсәрләрендә һәр очрак-та уңай персонаж.

Т. Миңнуллинның да татар телен сакларга, бозмаска, өйрәнергә өндәп язган, сөйләгән кайнар чыгышлары бихисап. Ул үгетләүче, өндәүче, көрәшче. Аның Дәүләт советы депутаты буларак бу юнәлештәге эшчәнлеге – үзе зур батырлык, Башка телләрне яклап та ул шундый ук кайнар чыгышлар ясый. Бу да үзенә аерым бер язма темасы була алыр иде.

Ә хәзергә Туфан Миңнуллинның "тел тоемлавы" менә шушындый фикер, нәтиҗәләргә китерде.

Туфан Миңнуллин гамәли әдәбияттә, аның нәзәриясендә драматург дип, җәмәгать яшәешендә язучы-публицист дип, җәмәгать эшлеклесе дип йөртелсә дә, халык аңында ул киң колачлы шәхес, катлы-катлы иҗатчы, чын мәгънәсендә халык язучысы, акыл иясе, әдип булып берегеп кала. Ул әле менә шушы фәнни һәм гамәли юнәлешләрдә төпле өйрәнеләчәк. Бу тәрбияви мирас безгә киләсе иҗатчыларны чын сәләтле белгечләр, язучы, журналистлар, гомумән дә, бай рухлы, татар җанлы, чын кешеләр итеп тәрбияләү өчен озак елларга кирәк булачак.

Без инде бүгенге темабыз итеп, "И туган тел..."нең һәм үзебезнең фәнни кыйблабызга тугры калып, язучы, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның үз иҗатында, тормышында татар теленә мөнәсәбәтен алдык. Мәсьәләнең татар әдәбияте өчен генә түгел, бүгенге яшәешебез, киләчәгебез өчен дә актуальлеген исбатлап торуның кирәге юктыр. Ана телебез язмышы бүген кыл өстендә. Шуны аңлап, хәлне бер генә карышка булса да уңайга үзгәртү өчен сүз белән дә, эш белән дә нидер кылырга алынган теләсә кайсы затның гамәлләре, тәҗрибәсе бик кыйммәтле хәзинәгә әйләнеп бара. Бүгенгә без Туфан Миңнуллинның тормышында, иҗатында бөртекләп тупланган шул тәҗрибә игътибарга лаек дип, аны бүтәннәргә дә җиткерү, таралуына ирешү кирәкле, нәкъ вакыты җиткән эш, өлгергән изге бурыч дип саныйбыз.

"Ана теленә мөнәсәбәт" һәр язучыга кагылмый калмый, чөнки тел – аның төп коралы, шуннан башка аңарда әсәр язарга, нидер әйтергә ният тә туа алмый, аны әйтә дә, кәгазьгә төшерә дә алмый. Тик менә бу сәләт, мөмкинлек төрле язучыда төрлечә була. Еллар буе Т. Миңнуллинның иҗатын тел тоемлау-куллану юнәлешендә махсус күзәтү, фәнни анализлау темага карата материалның нәкъ менә шушы әдип иҗаты йөзендә шактый мул өйрәнелүен, укытуөйрәтү максатында бүтәннәргә тәкъдим итәрлек дәрәҗәдә җитәрлек булуын күрсәтте.

Беренчедән, әдипнең “ана теленә мөнәсәбәте”, төшенчә, фәнни категория буларак да киң аспектлы-колачлы: шәхес буларак аңарда тел байлыгының (авазлардан алып лексиканың төрле катламы, җөмләләрнең төрлелеге, синтаксик конструкцияләрнең әйтмә сөйләмгә якын рәвешләре, телнең төзелеше белән бәйле башка чара-мөмкинлекләре; шуларны мотивларга карап (кемгә, нинди ният-максаттан, нинди шартларда – әйтепме, языпмы – белдерелүенә карап), һәр төр сөйләмдә дөрес, урынлы куллануы; тел белеме белән кызыксынып, сүзләрнең мәгънә төгәллеген, хис белдерү нечкәлекләрен тоюы, һәр әсәрендә шуларны оста файдалануы; сүзләрнең тарихын-этимологиясен ачыкларга омтылуы, гомумән дә тел тарихы мәсьәләләреннән мәгълүматлы булуы; телне тоемлавын укучы-тыңлаучысына да җиткерергә омтылу; телнең милләт язмышында тоткан урыны турында, аны өйрәнү, укыту, башка телләр белән мөнәсәбәт-бәйләнеше, дәрәҗәсе, киләчәге турында уйлану, борчылу, шуны башкалар белән уртаклашу һ.б. мәсьәләләрне бердәйлекле-комплекслы фикерли, җәмәгатьчелеккә җиткерү тәҗрибәсе. Боларның барысын без бер төенгә төенләп “Туфанның тел тоемлавы” дигән тирән мәгънәле фәнни төшенчә сыйфатында анализларга, гамәли әһәмиятле нәтиҗәләр чыгарырга кирәк, дигән карарга килдек.

Нәрсә ул “тел тоемлау”? Туфанга карата бу төшенчәне без ачыклый башлаган идек инде. Башта шушы әсәр белән бәйле, алда да кирәк булачак ике фикерне әйтеп китик. Язма газетта басылып, берникадәр вакыт үткәч (көнендә үк түгел, очрашканда-ниткәндә дә түгел, сүз уңаеннан да түгел), Туфан абый үзе шылтыратты. Сүзгә сүз сеңеп калмаган, мәгънәсе мондый иде: “Ошады, дөрес язылган. Минем әсәрләрнең теле турында моңарчы да язганнары бар иде, тик болай – фәнни нигезле, төпле итеп әйтүче юк иде әле. Рәхмәт”, – диде. Бу, аңлавымча, беренчедән, эшем кешесе кебек, өстән төшерим әле, дип минутлы хискә бирелеп, әйтү түгел, ә уйлану нәтиҗәсе иде. Икенчедән, мин язучыбызның тел кулланудагы кимчелекләре турында да искә алган, мисаллар китергән идем. Максатым аңардан да бигрәк барлык язучыларга хас булган типиграк кимчелекләрне, мөмкинлектән файдаланып, улым сиңа әйтәм, киленем син тыңла, кинаясе беләнрәк әйтелгән кимчелекләр иде. Мин инде эчтән генә, гөнаһ шомлыгы, шуларны телгә алырмы, дигән идем дә, Туфан абый әңгәмәне озайтып тормады, тагын бер кат җылы гына рәхмәт әйтеп, уңышлар теләп, саубуллашты.

Хәзер уйлыйм, Туфан минем нечкә хәйләмне дөрес аңлаган, монда да ул үзенең “тел тою”ын күрсәткән. Әлбәттә, тәнкыйть өлеше күңеленә тими калмагандыр, тик телебез хакына уңай максатны аңлаган, хуплаган, чөнки, күрәсең, минем тәкъдимнәрне өйрәтү, күрсәтмә, әмер бирү дип кабул итмәгән (мин чыннан да андый ният-теләктән язмаган идем бит), шуңа күрә ул ихластан шылтыраткан да. Минем аңардан рәхмәт-фикер көтмәгәнне дә белгән, аңлаган хәлдә. Моның белән нәрсә әйтмәкче булам: шушы хәсияттәге фәнни анализ һәр язучы иҗатына карата зарарлы булмас иде, аны дәвам иттерү зарурдыр.

Хәзер инде төп язмабызны дәвам иттерү өчен әлеге мәкаләдән кайбер тезисларны искә төшереп, тирәнтенрәк барлап китик. Күрдегез, Туфан Миңнуллинның, язучы буларак, үзенең төп эш коралы – ана теленә мөнәсәбәте, аны куллану үзенчәлеге турында фикер әйтү теләге күптән туган булган. Дөресрәге, бу теләк әле дә, һәр әсәрен диярлек укыган саен, кабынып-кабынып тора. Моның нәзәри нигезен болай төшендереп буладыр. Бүген тел, сөйләмият фәннәрендә, әдәбият нәзәриясендә, мәктәпнең, югары уку йортының тел гыйлеме программаларына кертелеп махсус өйрәнелергә вакыт җиткән “тел тоемлау” категория-төшенчәсен Туфан Миңнуллин аңында, сөйләмендә “тел тою” төшенчәсе белән барлыкка килгән, береккән икән. Нәрсә соң ул аныңча “тел тою”? Әле китерелгән билгеләмәгә өстәп, укучым, тыңлаучым сукранмасын, мөмкинлектән файдаланып, фәнни анализ тәртибе дә таләп иткәнчә, аның үзенең бер язмасын тулысынча күчереп тәкъдим итәм.

Тагын тел турында

Язучылар союзында прозаиклар һәм тел белгечләре җыйналып “Бүгенге көн татар прозасында тел мәсьәләләре”н тикшерәләр. Үземне прозаик дип санамасам да, утырышка чакырылмасам да, кереп утырдым. Бик озак сөйләштеләр, акыллы-акыллы фикерләр әйтелде.

Әрсезләнеп мин дә сүз сорадым һәм җай белән генә барган сөйләшүнең тәмен җибәрдем бугай. Тел белгечләренең кайберләре мине “надан” дип, кызганып та куйдылар шикелле.

Эш менә нәрсәдә: язучы һәм аның теле дигән мәсьәлә һичнинди анализга бирелми, минемчә. Гомумән, ул проблема юк. Язучы дибез икән, үзеннән үзе аның теле булырга тиешлеге аңлашыла. Әдәби әсәр язарлык теле юк икән кемнеңдер, димәк, ул язучы түгел. Күз алдына китереп карыйк әле – композиторлар җыелды ди дә,

композиторның колагы ишетергә тиешме-юкмы дип җитди итеп сөйләшә башладылар ди. Адәм көлкесе булыр иде. Яки рәссамнар җыелып, тумыштан күзе сукыр булган кеше картина яза аламы, дип сөйләштеләр ди. Җитди булмас иде.

Ишетү, күрү сәләте табигать тарафыннан бирелгән кебек, *сүзне тою сәләте дә* (Ассызык безнеке. – *И.Н.*), минемчә, кешеләргә тумыштан ук бирелә. Колагы искиткеч ишеткән кешеләр арасыннан композитор, музыкантларның чыкмавы ихтимал. Әмма тумыштан ишетү сәләтеннән мәхрүм кешедән композитор чыгуын минем ишеткәнем юк.

Язучы белән дә шулай. Авылда бер класс та укымаган кайбер абзыйлар шундый тәмле итеп сөйлиләр, авызларына карап торасың. Әгәр шул кеше вакытында тиешле юнәлеш, белем алган булса, аңардан язучы чыгуы бик мөмкин. Әмма иң кызыклы мәзәкне сөйләргә алынып та аны рәтле-юньле сөйли белмәгәннән, сүзнең тәмен тоймаган кешедән язучы чыкмаслыгына иманым камил. Хет ун институт бетерсен, чыкмый аңардан язучы. Бөтен сүзлекләрне яттан белсен, чыкмый аннан язучы. Ул сүзне сүзгә акыл белән ялгап җөмлә төзи һәм җөмләсе чуртан балыгы сыман шома була; кулга эләкми – шуып төшә, ягъни мәсәлән, күңелгә ятмый.

Авылның көяз егетләре искә төште. Алар маңгай чәчләрен бүрек астыннан чыгарып, бүрекне кыңыр салып, илле градус салкын булса да изүне ачып җибәреп клубка килеп керәләр иде. Сөйләшкәндә, җырлаганда да кыланып, сүзләрне юри бозып әйтерләр иде. “Сибелә чәчем уң якка” дип әйтәсе урынга”Сибелә сачем” диярләр иде. Чәчәк аларча “сачәк” булыр иде.

Мин аларның кыланганнарын аңлыйм, хәтта кыланчыкларын яратам да. Әмма язучы сүз ясап “кылана” башласа, ул көязлектән түгел, мескенлектән, телнең матурлыгын тоймаудан, дип беләм.

Әйтик, безнең заманның япь-яшь кенә язучысы тәэсир дип язасы урынга тәэсорат дип язып куя. Янәсе ул гади итеп язарга теләми, янәсе, ул күбрәк белә. Ә менә мин – укучы – ул язганны укыйм да күп белгәненә шаккатмыйм, киресенчә, кызганам, Чөнки “тәэсорат” дип аның “әсәр”ендә гап-гади авыл агае сөйләшә. Кыланып сөйләшми, чынлап сөйләшә. Бактың исә, әлеге авыл агае, тәэсоратны түгел, тәэсир дигән сүзне әйтә микән әле. Мин үзем, мәсәлән, тәэсир дигән сүзне авылда ишеткәнем юк. Димәк, “тәэсорат”ны язучы иптәш телне тоймый, тоймый икән – аны өйрәнеп тә булмый.

Минемчә, теге яки бу яшь иптәшнең беренче кульязмасын укыганда аның теленә нык әһәмият бирергә кирәк. Телне тою сәләте юк икән иптәшнең, турысын әйтергә кирәк – интекмәсен кеше, алданмасын. Көчен бүтән нәрсәгә юнәлтсен, бәлки бүтән өлкәдә аңардан шәп белгеч чыгар. Теле булмаган кеше образлы фикер йөртә алмый. Ә әдәбият ул – образлы фикерләү (*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр. Т. 7. 32 б.).

"Тел тоемлау" термин-төшенчәсен ачыклауга караган үзебезнең кайбер фикерләр. Тел тоемлау кешегә табигатьтән бирелә. Тик ул кешедә үсә барган саен, аның һәр әгъзасы кебек, үзеннән үзе үзгәрми, үсми икән. Кеше үз кызыксынуы, үз теләге белән аны үстерергә тиеш икән. Кемдер чәчкән орлыкны бүтән берәү үстерер, дип ышансаң, тел тоемлау хисең, талантын дымсыз балчыкта корып, үлеп калуы да ихтимал икән.

Туфан үзенең тел тоюына ничек-ничек каравын, тәрбияләвен махсус язмаган. Шулай да без аны үзебез тоемларга, барларга тиешбез. Бу татар җанлы һәркемгә кирәк: беренче чиратта, язучы, журналистларга, тәрбиячеләргә, укытучыларга, бала тәрбияләүгә алынган әти, әниләргә, гомумән, һәркемгә.

Әйткәнемчә, беренче язмабызның төп чыганагы Т. Миңнуллинның төп публицистик әсәрләреннән торган "Утырып уйлар уйладым" китабы иде. Бу язмабызның чыганагы, табигый ки, максатыбызга ярашлы рәвештә, күләмлерәк, колачлырак булырга тиеш иде – асылда ул әдипнең 10 томлык "Сайланма әсәрләр"ен тәшкил итте. Өстәвенә әле, сайланма әсәрләр басылып чыкканнан соң матбугатта бәян ителгән әсәрләрнең күпчелеге күзәтелде, мисаллар шулардан да алынды. Янә бер чыганакка искәрмә бирү кирәктер. "Казан утлары"ның 2012 елгы 1 нче, 3 нче саннарында Т. Миңнуллинның "Үзгәрү" (Үзем турында үзем) дигән үзенчәлекле, уйландырырлык язмасы басылды. Укучылар игътибарын да җәлеп итте. Интернетка чыгарылган нөсхәсе белән 170 интернетчы танышкан. Төрледән-төрле фикерләр әйтелгән. Темабыздан бераз читләшеп, бер фикер әйтәсем килеп китте. Туфан абыйның кайсы гына язмасына, чыгыш, тапшыруына юлыксам да, аны күз салуга йотылып укып китү гадәтенә күнегелгән иде. Тик бу язмасын теләртеләмәс кенә укый башладым, нәрсәсе белән дә хәтирә-истәлеккә тартым булгангадыр, күрәсең. Сау-сәламәт язучының хәтирәистәлек язуы мине, нишләптер, сискәндерә. Бу юлы да капылт кына Мөхәммәт абый Мәһдиев искә төште. Вакыт-вакыт аның "Мир" ки-

нотеатры артындагы кечкенә генә бакчада уйланып утырган чагына юлыккалый идем. Бер вакыт шулай хәл-әхвәл сорашып киттек. “Менә архивны барлап, арып чыктым әле...” дип сукранып алды. Шуннан соң, мәрхүм, озак яшәмәде...

Туфан абыйның язмасы миндә бер генә мизгелгә менә шундый күңелсез хис калдырды: хисап тота башлаган икән... Бүтәннәрдә дә ул язма шундыйрак хис калдырган булып чыкты. Ә бит язма, чыннан да, аның иң җитди язма, чыгышларының соңгыларыннан берсе булган икән.

Шулай да мина ул канәгатьлек хисе дә бирде. Мин аны, әлеге дә баягы, төп темама мөнәсәбәттә – татар телен тоемлавы, телнең язмышы өчен борчылуы турында уйланып укыдым. Шөкер, бу язмада да Туфанның “тел тоюы” без күзаллаганча системалы, фәнни нигезле ачыла алган иде. Алай гына да түгел, иҗади йомгакка тартымрак бу хезмәт без куйган мәсьәләдә дә үзенә күрә тарихи йомгак ясарга ярарлык иде. Иң мөһим нәтиҗә шул: үз шәхесенең, тормышының, иҗатының кайсы гына әһәмиятле өлешен алмасын, ул аны ана теленнән башка күз алдына китермәгән, “тел тоюы” аны гомере буе ташламаган, ул үзенең шушы асыл хәсияте-сыйфатына битараф калмаган, шул тойгы-хисен үстерү, камилләштерү өчен омтылган, тырышкан. Бу очракта аеруча әһәмиятлесе шушыдыр: әдип бу асыл үзенчәлегенең үзендә булуын, иҗатында илһамландыруын, үсәргә. камилләшергә таяныч икәнлеген, теләсә нинди үзгәрешкә дучар булганда да аңардан ваз кичмәвен тоеп яшәгән. Шуны укучыларына, тамашачы, тыңлаучыларына җиткерә тору ихтыяҗын тойган, һәм даими җиткерүдән, шулай итеп аларга да илһам, көч бирә алуыннан канәгатьлек кичергән. Шөкер, аның шушы изге сыйфатын безгә бүген әсәрләре җиткереп тора. Мең рәхмәт аңарга.

Нәтиҗәләребезне берничә мисал белән бик кыскача гына дәлилләп китик; алга таба без аларга әле тәфсилле тукталырбыз. Менә “Дөньяны таный башлау” бүлекчәсендә “тел тою” сәләтенең чагылышына мисаллар: “Татарча яңа сүз өйрәнгәнем дә хәтердә. Сугыш башлангач, әти район үзәгенә – “Камски усте”гә каралырга китте. Әни әйтте шулай дип: “Әтиегез каралырга китте”, – диде. Мин “каралырга” дигән сүзне кара төскә буялырга дип кенә белә идем, икенче мәгънәсе дә бар икән (Казан утлары. 2012. № 1. 96 б.). Сабый чорын яктырткан шушы бүлекчәдә үк инде язучының “Нигә Россиядә татар теле урыс теленнән кайтыш санала?” дигән сорау куюы мәсьәләнең алга таба да “тоем” булып дәвам иттереләчәгенә киная бит.

Бу тема “Ватан” бүлекчәсендә дә дәвам иттерелә: “Олыларга ияреп Камскига бару кызык үзе. Анда Идел, пароходлар. Пристендә базар. Салам башлы марҗа кызлары, көрәк сакаллы урыслар урысча гына сиптерәләр. Урысча сөйләшкән кеше безнең өчен бөек кеше инде ул. Камскига баргач берәр сүз өйрәнеп кайтабыз да, мактанышып йөрибез. Мәктәптә дә укыталар урыс телен. Тик мәктәптә укыткан тел кызык түгел. Базарда өйрәнгән тел кызыграк та, кирәгрәк тә...” (шунда ук. 97 б.). “...Патриотизм дигән сүзнең ватанга бирелгәнлек икәнен кайсыдыр укытучыбыз бик кызык итеп аңлаткан иде. Патриотизм – ул “патер” сүзеннән килеп чыккан икән. Ә “патер” латин телендә эти дигән сүз икән. Монда бераз бәхәс тә булып алды шикелле. Чөнки без ватанны әни белән тиңләргә өйрәнгән идек. Ватан-ана, Родина-мать дия идек, ә монда эти дә килеп кысылды. Урыс теле укытучысы Рәхимә апа ватанның родина дип тә, отечество дип тә йөртелгәнен төшендергәч, ватанга этиләрнең дә катнашы барлыгы беленде...” (шунда ук. 98 б.). Әйтик, язмада үзенең тормышында “Халыклар дуслыгы” төшенчәсенә бәйле үзгәрешләрен бәян иткәндә автор мондый юллар яза: “Безне юкка чыгару өчен Мәскәү ачыктан-ачык тырыша. Хәтта туган телләребезне укытуны тыя. Халыкларның табигый дуслыгын бетерү өчен бөтенесен эшли Мәскәү. Һәм моны Халыклар дуслыгы дия-дия эшли” (шунда ук.103 б.).

Алга таба әсәренең “Дин”, “Идея, идеология, партияләр, коммунизм” бүлекчәләренә, шулай ук шәхси үзенә караган “”Холык, гадәт”, “Шәхес”, “Депутат” бүлекчәләрендә үзенең үзгәрешләрен аңлатканда, ана теле төшенчәләре белән аңлаткан тезис, тасвирлары әсәрнең буеннан-буена үрелеп бара. (Без аларның күпчелегенә бәйнә-бәйнә тукталырбыз әле.) Бу факт кына да аңарда “тел тою” хисе, үзенә бер җаваплы сыйфат булып берегеп, бөтен гомере буе яшәгәнлеген, тынгылык бирмәгәнлеген сөйлидер. Бирсен иде табигать һәр язучыбызга, җәмәгать эшлеклесенә, һәркайсыбызга шундый сыйфат чаткысын! Хәер, үзең булдырырга омтылмасаң, тырышмасаң аны синңа кем китереп тоттырсын. Туфан остазыбызга таянып, аңардан үрнәк алып, күп нәрсәгә ирешкән булыр идек тә...

Нигә әле язмамны Туфанча ышанычлы, өметле рухта язарга ниятләп тә, аның шушы кереш өлешен үк сәер бер бер төшенкелек төсмере белән очларга җыенам? Сәбәпсез берни булмый – Туфанның вафатыннан соң үткән чорда инде, әйткәнебезчә, әдибебезнең тормышы, иҗаты, җәмәгать эшчәнлеге турында шактый мул хәтирә, истәлекләр, фәнни язмалар, рәсми һәм шәхси чыгышлар дөнья күрде.

Бик табигый рәвештә аның кайсы гына яклары телгә алынмады да, тасвирланмады. Шулай да... Әйтик, яхшы мәгълүм “Заря Поволжья” газетында гомере буе әдип белән хезмәт иткән, иҗат иткән күренекле шәхесебез аның бихисап уңай якларын-сыйфатларын санап, тасвирлап бирсә дә, менә без кузгаткан, сүз алып бара башлаган – җәмәгатьчелек өчен, милләтебез киләчәге өчен бөтен милләткә йоктырырга кирәкле төп сыйфатына – ана теленә мөнәсәбәтенә бөтенләй дә тукталмаган. Яисә “Үзгәрү” дигән язманы интернетта 170ләп кеше күргән, фикерләрен әйткән дигән идек, әмма арада безнең темага караган ник бер юньле-башлы, уйланырлыр-уйландырырлык фикер булсын. Хәер, чү, бер фикер булган икән: “Кичә татар теле – дәүләт теле, татар университеты дип яран салу, бүген татар теле өчен гаилә җаваплы, дип сөйләү – намуслылыкмы?” (Иркә). Хәер, бу реплик сораудан, фикердән бигрәк (аңа язманың үзендә үк җавап бирелгән) астыртын төрттерү булса да, бу үзенә бер “фикер” бит: шөкер, ике йөз интернетчыдан Туфанның тел сәясәтенә дә кагылышлы зат икәнен шәйләүче бер кеше (татар интернетчыларының күпчелеге кебек, мәсьәлә белән җитди кызыксынмый торган, вакыт үткәрү өчен генә кысылып утыра торган булса да) бар икән...

Язмабызның кереш өлешендә *тел тоемлау* төшенчәсенең хәзер инде көндәлек кулланышта да, фәндә дә урын алганлыгын, аның мөстәкыйль категория дәрәҗәсендә тел, сөйләмият гыйлемнәрендә генә түгел, кардәш психолингвистика, социолингвистика тармакларында да өйрәнелергә тиешле фәнни күренеш икәнен искәртеп, асылы, хәсияте нидән гыйбарәт икәнен берникадәр ачыклый төшкән идек. Бу күренешне төпле өйрәнер өчен, үзебезнең тормыш тәҗрибәбездә, мәдәният, әдәбиятебездә, тел гыйлемебездә җитәрлек әсәси мирасыбыз да бар икән. Күзәтүләрдән күренгәнчә, ул мираста әдип Туфан Миңнуллинның иҗат тәҗрибәсе дә әһәмиятле урын тота. Кереш сүздә шуларны да ачыклаган идек. “Тел тоемлау” төшенчәсенә билгеләмәне без Туфан фикер-нәтиҗәләренә таянып та тәгаенләдек.

Туфан аны гади генә *тел тою* дип атый, язмаларында аның асылын, хәсиятен үз фикерләве, иҗаты мисалында, шулай ук башка иҗатчыларның да мисалында төшендереп бирә. Без аны фәнни термин буларак *тел тоемы*, *тел тоемлау* берәмлекләре рәвешендә дә кулланырбыз.

Шул турыда төп сүзгә керешкәнче, бер искәрмә биреп китим әле. Бу язмага тотыныр алдыннан “Туфан теле” дигән темага җыйган материалымны йөгертеп кенә барлап чыккач, бераз югалып та кал-

дым – Туфанның тел осталыгын барларга алыну – ул аның бөтен яшәешен, барлык иҗатын анализларга алыну, дигән сүз бугай бит. Тел мәсьәләсе аның тормышының бер генә өлкәсен дә читләтеп калдырмаган икән. Әдипнең бер гыйбарәсе игътибарга лаек: “Минем язганнарым – минем уйлануларым, минем бәргәләнүләрем, борчылуларым, шатлыкларым нәтиҗәсе “ (т. 9, 59 б.). Ә бит аның бөтен язганы – тулаем уй-фикере, хисләре ана теленә нигезләнеп, шуңа таянып, шуның белән азыкланып, шуның белән сурәтләнү нәтиҗәсе. Шулай булгач, аның теленә анализ ясарга алыну безнең кулдан килерлек, без колачлап бетерерлек гамәлме соң?

Шулай да кемдер эшләргә тиеш бит инде моны. Тәвәккәллик соң. Иң әүвәле, Туфанның дәрьядай киң, тирән фикер агышының, фәлсәфәсенең, иҗтимагый эшчәнлегенең, иҗат кыйблаларының кайсы тарафында тел мәсьәләсе аеруча үзенчәлекле, күперенке чагылыш таба икән? Кайсысында аның тел тоемлавы актырак, тулырак күренә икән? Гомуми күзәтү ясаганнан соң, мондыйрак нәтиҗәгә килергә була икән: тел тоемлау күренеше-категориясе, гомумән фәнни төшенчә буларак та, безнең очракта, беренче чиратта Туфанга карата да, төп ике юнәлештә күзәтелергә, анализланырга мөмкин. Беренчесе, аерым бер кешенең – мәгълүм затның, аерым иҗатчының шәхси тел тоемлавы (монысын *иҗади тел тоемлау* дип тә атарбыз – сөйләм оештыру, язу, сөйләү осталыгы һ.б.); икенчесе, шәхеснең гомумән уйлау, аралашу чарасы-коралы буларак, телне белүе, дөрес куллануы, ана теленә мөнәсәбәте, аны гаиләдә үзләштерү, мәктәптә уку-өйрәнү, укыту мәсьәләләренә мөнәсәбәте, телнең җәмгыятьтәге урыны һ.б. Монысын *иҗтимагый тел тоемлау* диярга була.

Башка әдип, язучыларның күпчелегеннән аермалы буларак, Туфанның тел тоемының өстенлеге менә шул ике “җәп”нең дә бер дәрәҗәдә диярлек үрелеп баруында, табигый рәвештә бердәйлекле күренеш барлыкка китерүендә. Ана теленең тәмен, көчен-кодрәтен ул әсәрләрендә, беренче чиратта драматургиясендә, аннары публицистикасында, бүтәннәр дә тоемларлык итеп күрсәтеп-тасвирлап бирүендә һәм җәмгыять әгъзасы, иҗтимагый шәхес (депутат) буларак шул тел могъҗизасын башкалар да төгәл аңларлык, хискә бирелерлек итеп (өндәп-үгетләп тә, гарьләндереп-оялтып та, көлдереп-мыскыллап та һ.б.) аңлатып-төшендереп (язып та, сөйләп тә) бирүендә. Ике кыйблада да ул – белгеч, укытучы-мөгаллим, пропагандист-сәясәтче. Ике юнәлештәге тәҗрибәсе дә өйрәнер өчен бай чыганак. Аллага тапшырып, без менә шул кирәкле эшкә тотынабыз да.

Әлбәттә инде, үзәккә аның, язучы драматург, публицист буларак, иҗади тел тоемлавын куярга тиешбез. Аның тел куллану осталыгы, беренче чиратта, драма, публицистик әсәрләр язу тәҗрибәсе берникадәр өйрәнелгән (аның иҗатына карата реферат, фәнни мәкаләләр, диплом эшләре, диссертацияләр дә язылды, конференция, симпозиумнарда фәнни чыгышлар сөйләнелде). Шулай да бу язмабызда без әңгәмәне Туфанның *иҗтимагый тел тоемлавы*ннан башлап җибәрергә булдык. Ни әйтсәк тә, язмабызның төп адресаты – гадәти татар кешесе. Ә адәм баласы үзен иң әүвәл җәмгыятьнең бер әгъзасы, мәгълүм бер милләт баласы итеп тоя. Аннан соң гына үзен китап укучы, тамашачы, әдәбият белгече яисә мәдәниятче – теге-бу өлкәгә, һөнәргә караган белгеч дип хис итә.

Туфан, адәм баласында тел тоемлау сәләте туганнан ук башланып китә, дип саный. Чыннан да, кеше һәм тел, милләт һәм тел мәсьәләсе кеше яшәешеннән табигый аерылгысыз; туганнан алып гомере тәмамланганчы алар бергә. Кешенең әнисеннән, әтисеннән, туган өйдән, төбәгеннән, милләтеннән аерылып торган чаклары була; алардан башка да көн иткән очраклары була, хәтта төрле фаҗига килеп чыгып, аерым әгъзаларсыз да яши ала, ә менә телдән башка кеше яши алмый. Җәмгыятьтә кеше кешедән башка, бер-берсе белән аралашмыйча-сөйләшмичә, яшәеш була алмый. Табигый ки, димәк, кешенең тел тоемлавы да шундый ук мәҗбүри ихтыяҗыдыр, аерылгысыз сыйфатыдыр.

Бу хакыйкать баланың яралган мизгеленнән үк, әнисе карынында ук башлана икән. Психологларның, күпчелек аналарның әйтүенчә, баланың тугыз айлык башлангыч гомере әнисенең ата-бабадан килгән сөйләм, моң, гореф-гадәт мохитендә үтсә, киләчәктә дә шул мохиткә җиңел яраклашачак, ягъни аңа тел тоемлау сәләтен саклау, үстерү өчен ышанычлы нигез булачак. Һәрхәлдә баланы дөньяга китергән әнисе, әтисендә тел тоемлау “орлыгы-күзәнәге” булган булса, бер генә бала да бу сәләттән мәхрүм калмый.

Туфанда бу орлык сәламәт, тулы булган. Аның тел тоемлавы әби-бабасыннан, әти-әнисеннән, милли каныннан килә. Сабый Туфанның моңа карата уй-фикерен кереш язмада бәян итә башлаган идек. (Аның район үзәгенә, базарга баруы турындагы хәтирәсен искә төшерик.)

Тел тоемлау сәләтен әдип гомере буе үстерә, саклый алды, тулы файдалана белде. Без инде бу хәзинәне бүген өйрәнә, үзебез дә куллана алабыз. Аның тәрҗемәи хәленең төп этапларын да, холкы-

фигыленең төп сыйфатларын да шул тел тоемлау сәләте белән бәйләп күзәтергә була икән. Әйтик, аның кеше буларак сыйфатларын ана теленә мөнәсәбәте белән аңлату кызыклы фикерләр уята. Менә холкы-фигыленең кайбер сызымталары әнисенең сөйләү рәвешеннән, аерым гыйбарә, сүзләренең хәтердә уелып калуыннан формалашкан дип була. “...Безнең Туфанга әйтеп тә торасы юк, казларны үзе алып кайтып яба ул”, – дип эшләтә иде. Һәм мин, ни хикмәттер, йөгерепйөгереп эшли идем. Ул гадәтем әле дә сакланып калган. Мине ачуланып, сүгеп, приказ биреп бер эш эшләтә алмыйлар, мине эшләтер өчен “җил ягына салам кыстырыбрак” эш итәргә кирәктер. Ә бит ул холык миңа әнинең үзеннән күчкән... Ул горурлык хисенең үземдә булуына сөенеп бетә алмыйм” (т. 7, 19 б.).

Гомумән дә, табигать аңарга кеше сүзенә игътибарлы булу, алай гына да түгел, бүтәннәрнең сөйләмен акылы белән дә, җаны-күңеле аша да сөзеп-иләп үткәрү һәвәслеген биргән. Гомер буе ул бүтәннәрнең сөйләмен, сүзен диккать биреп тыңлаган, йөрәге белән кабул иткән. Менә ул аэропорттан шәһәргә очраклы юлдашы белән машинада кайтып килә. Сөйләшеп кайталар. Юлдашы аны үзләренә кунакка дәшә. “...Олы кешенең шулай инәлеп чакыруыннан соң ничек инде, туктат, дип төшеп каласың?! Сәбәп табып төшеп калырга да була, әмма миндә, Нәҗибә (хатыны) әйтмешли, чегән этләренең характеры бар, ахры, кешегә тиз ияреп китәм, күңелемә ошаган кеше булса, сөйләшеп туя алмыйм” (т. 7, 114 б.).

Табигать биргән, әти-әни, гаилә саклаган, тәрбияләгән, үстергән, чарлаган, бала үзе дә сүзгә, телгә сизгер булып, аның көчен, сихәтен, тәмен тойып, шул тоемлавын сакларга, үстерергә омтылган шәхес булса да, әлеге сәләте гомерлеккә берегеп калган мирас түгел, тәненең төрле әгъзалары, холкы-фигыленең төрле сыйфатлары үзгәрә барган кебек, бу үзенчәлеге дә үсештә, үзгәрештә, хәрәкәттә булырга тиеш. Гаиләдән аерылгыч та – балалар бакчасында, мәктәптә, урам мохитендә, эштә һ.б.

Үзенә-үзе таләпчән кеше үзендәге тел тоемлау сәләтен сүндермәү, сүлпәнләндермәү, тоныклатмау хәстәрен гомер буе үзе дә күрергә тиеш, чын татар үз телендә аралашуда пассивлашуының сәбәпләрен бүтәннәрдән эзләми, мәктәпләрне, оешмаларны, дәүләтне гаепләргә ашыкмый. Бу юнәлештә үз өстендә эшләү үрнәген дә Туфаннан өйрәнергә була. Туфан телне гомере буе максус өйрәнгән. Нигә махсус өйрәнергә, көчеңне исраф итәргә; тел тоемлавы, табигый кызыксынуы, әтисе, әнисеннән бирелгән бушлай хәзинә ич, дип кенә

аңлатырга да булыр иде. Юк шул! Кабатлыйм: Туфан телне максус өйрәнгән. Хәтта базарга барып. Көн саен иртән базарга барган. Тел күзәтер өчен (т. 7, 150 б.). Атаклы тел остасы Хәсән Сарьянның сүзләре искә төште: кирәкле сүзне эзләгәндә, әни ничек әйтә иде, урамда, базарда ничек әйтәләр иде, тел остасы әдипләр ничек яза иде, дип эзләргә кирәк, дигән иде. Эх, нигә ешрак искә төшермибез без остазларыбызның киңәш-үгетен. Ә менә Туфан ул васияткә гомербакый тугры калган.

Хәзер килеп Туфанның иҗтимагый тел тоемының аеруча куе булып төенләнеп калган мизгелләрен барлап карыйк. Аның "тел сәясәте" нинди юнәлешләргә төбәлгән булган икән.

Кеше һәм тел "төене". Туфан, телләр күп булырга, тигез булырга тиеш, дип уйлый. Туры килгән саен, шушы фикерен, инануын алга сөрергә тырыша. "...Кешеләр берсен берсе аңламый, берсен берсе аңлар өчен бер телдә генә сөйләп, бер көйне көйләргә тиеш, диючеләр җир өстендәге матурлыкка, камиллеккә каршы көрәшүчеләр, кешелек дөньясын һәлакәткә илтергә маташучылар. Кайчандыр бер заман дөньяда бер генә тел калачак, дип сөйләнәләр. Мин моңа ышанмыйм. Ул чакта дөнья бетәчәк. Әгәр дә инде мин ялгышсам, һәм чыннан да Җир шарында бер генә тел калса, Аллага шөкер, мин ул вакытта үлгән булачакмын, кешеләрнең иң соңгы ахмаклыгын күрмәячәкмен" (т. 7, 87 б.).

Шул ук вакытта ул аңлый, белә: бу хакыйкать кешеләр җәмгыятендә үзеннән-үзе генә, кешеләрнең үзләреннән бәйсез рәвештә гамәлгә ашырылып ятмый. Аның гамәлдә булуы өчен кешеләр хәстәрлек күрергә, кирәк очракта үз ихтыярын күрсәтергә, көрәшергә, хәтта гомерләрен куркыныч астына куярга тиеш булалар. Туфан да, бу хакыйкать тормышчан булсын, кешеләр аны үз файдаларына җиксеннәр өчен, гомере буе борчыла, уйлана, хәрәкәт итә, һич арттырусыз әйтәм, җан ата – көрәшә.

Бу җан атуы төрлечә чагылыш таба: бер очракта ул шушы хакыйкатьнең үз җәмгыяте яшәешендә булуын күреп сөенә. Әйтик, "...Бүгенге азгын заманда унбиш яшьлек кызның (оныгы Диләрәнең) бабаларыбыз телендә шигырь язуы шатлык лабаса" (т. 9, 128 б.), дип ул ихластан сөенә. Ә менә бервакыт хөкем ителгән хатын-кызларның колониясенә барып чыккач, ул бер төркем булып җыелып торучылардан: "Арагызда татар кызлары бармы? – дип сораган идем, берсе:

– Есть! – дип атылып чыкты.

– Татарча беләсезме? – дип сорадым.

– Нет! – диде дә, шаркылдап көлде ул” (т. 9, 76 б.), дип әдип, өзгәләнеп, көенә.

Дөресен әйткәндә, кеше һәм тел төшенчәсе, әлбәттә инде, бер генә шәхес кысасына сыймый, Туфанда да ул аның үзе белән генә чикләнми, аның аңында ул чын мәгънәсендә иҗтимагый төшенчә булып береккән. Шушы характердагы уйлану, гамәлләренә менә берничә генә мисал – бу очракларда ул үзе турында гына түгел, бөтен милләтен, бөтен халкын күз алдында тота. Шунысы әһәмиятле, аның бу күзәтү-нәтиҗәләре факт, күренеш буларак кына теркәлмәгән, ә бәлки публицист, җәмәгать эшлеклесе буларак борчылу, уйлану нәтиҗәләре сыйфатында, барыбыз да уйлансын, борчылсын, хәрәкәтләнсен, көрәшсен, дип сәнгати чаралар белән, үтемле сүрәтләү алымнарын кулланып язылган.

“Урыс дәүләте элек тә булган һәм ул татарны хәзергегә караганда күбрәк кыскан, ләкин татар иманыннан язмаган. Чөнки ул үз-үзен саклый белгән. Бүген сакларга теләми. Теләми икән, депутатларга урысча хат язып кына акыл өйрәтмәгез. Башта үзең әби-бабаңның телен өйрән дә, балаңа өйрәт, аннан “Нишлибез без, җәмәгать?!” дип урамга чыгып кычкыр. Аңгыра сарык булып, “Татар теле нигә кирәк?” дип шыңшып йөрмә. Әнә Казанда яһүдләр яһүд мәктәбе ачарга йөриләр. Анда яһүд теле белән бергә рус һәм татар телләре укытылачак. Мин ышанам – ул мәктәпне тәмамлаган яһүд балалары үз телләрен һәм татар, урыс телләрен менә дигән итеп беләчәкләр. Анда укып чыккан татарлар һәм урысларның татар телен беләчәкләренә ышанмыйм Урыслар да, татарлар да “Нигә кирәк ул татар теле” диячәкләр...” (т. 9, 91 б.).

“Казан мәктәпләренең берсендә яһүд сыйныфлары оештырылган. Шундагы яһүд балалары татар телен ныклап өйрәнәләр икән. Хәтта җәйге ялда да махсус лагерь оештырып, шунда бөтен эшне бары тик татар телендә генә алып барырга җыеналар икән. Барлык 55 укучы татар телендә татар җырлары җырлап, иртәнге физик күнегүләрне дә татарча гына алып баралар икән. Мондагы 10–12 яшьлек яһүд балалары үскәч кем булачаклар инде? Үз телен һәм үзе яшәгән җирдәге милләтнең телен тирәнтен үзләштергән, берничә телдә чартлатып сөйләшүче белемле яһүд белән кем ярыша алачак. Татар теле нигә кирәк, дип, акыл сатып вакыт уздыручы татармы? Безнең телебез бөек, калганнары чепуха дип масаючы урысмы? Юк. Алар кычкырып сүгенеп йөрүче көтү генә булачак. Ул көтүне көтүчеләр яһүдләр булмый, кем булсын.

Шушы хакыйкатьне аңламаган татарның киләчәге юк. Әлегә безнең сәнгатетебез, әдәбиятыбыз татарлар кулында. Тиздән безнең өчен яһүдләр татарча яза башлаячак. Татар театрында яһүдләр уйнаячак. Ә үз теленең кадерен белмәгән, бабайларын оныткан татар урысча сүгенә-сүгенә, яһүдләрне хурлый-хурлый денатурат эчәчәк" (т. 9, 99 б.).

"Әйтик, син татар теле турында кайгыртып шигырь яз, ә трибунага чыгып урысча сөйлә – мин моны аңлый алмыйм, үзең татар, татар дип җырла, ә балаларыңны татарчага өйрәтмә – моны мин гафу итә алмыйм. Димәк, син шигыреңдә һәм җырыңда ихлас түгел" (т. 9, 242 б.).

"Бездән Русияне яратуыбызны таләп итәләр, ә үзләре безнең телебезне мәхкәмә залларында хөкем итәләр" (т. 9, 323 б.) ...Татарстан Президенты татарча белергә тиешме, түгелме, дигән үтә дә мәгънәсез һәм халыкны мәсхәрәли торган сорау куела. Президент сайлау турындагы законны судка бирделәр һәм, Республикабызның башкаласы Казанның үзәк урамында суд ясап, Президент постын телебездән мәхрүм иттеләр. Бу – бары тик карагруһчылар гына эшли торган гамәл. Нигә балаларыбызны татарча укытасыз, дип Мәгариф министрлыгын судка бирүче дә табылды. Ярый әле судның бу юлы ояты җитте, дәгъва канәгатьләндерелмәде. Ләкин дәгъвачының бирелергә исәбе юк...

...Татар теле безгә кирәкми, диючеләр арасында үзен "татарин" дип атаучылар да табыла. Оят юк, итәгать юк. Мондыйларның ата-бабалары кемнәр булды икән? Оятсыз оныкларының кыланышына җаннары үрсәләнәдер, мәрхүмнәрнең. Менә без дистә еллар буе шапырынып сөйләгән "халыклар дуслыгы"ның нәтиҗәсе инде бу. Без дуслашыйк, дуслашыйк дип, җыр җырладык, дуслар безнең телебезне судка бирәләр, дуслыкка ышанучы тотрыксыз балаларыбыздан маңкорт ясыйлар" (т. 9, 324 б.).

Туфанның бу фикерен-нәтиҗәсен ничә тапкыр гына укысам да тетрәнеп куям, чөнки шәхсән үземә турыдан-туры кагыла. Ул мине дә гаепли – гомер буе үзем дә журналист буларак шул темага "шапырындым", китаплар чыгардым, башка каләмдәшләремнең шул темага язганнарын хуплап, мәдхия җырладым! Нишләмәк кирәк, әле дә менә замана корбаны шул без дип, эчтән акланып утырам. Бер кәкрәйгәч, тиз генә турая алмыйсың, кабер генә төзәтсә инде. Ә менә Туфан кәкрәймәгән, гел туры булган. Яшьләргә онытылмаслык сабак биреп калдырган.

Милләт һәм тел мәсьәләсе. Туфан аңында бу ике төшенчә – игезәкләр, мәңге аерылгысыз. Бу хакта заманында, узган гасырның туксанынчы елларында, үзем дә күп уйланган, язган идем. Бер мин генә дә түгел. Милләтнең асылын, аның төп сыйфатларын, чын татар милләте дип аталуның төп шартларын ачыкларга теләүчеләр булды, аны төрлечә аңлатулар булды. Милләт дип аталыр өчен телнең булуы мәҗбүри түгел, диючеләр дә бар иде. Алай фикерләүчеләр, үз туксанын туксанлаучылар бүген дә җитәрлек. Бу юлда аумакай булмавымның төп таянычы – Туфанның фикердәшем булуы иде; ул үз кыйбласында каты торды, боргаланмады, җил уңаена колагын шомартмады, ә җилгә каршы басып, үз фикерен, үз сүзен әйтергә, каты итеп әйтергә, үҗәтләнеп әйтергә җөрьят итте. Милләтнең телдән башка була алмасын төшенеп, уйланып кына калмады, туган тел өчен көрәш кирәклеген башкаларга да төшендерде, үзе дә көрәште. Нинди генә сурәтләү чаралары тапмады ул бу хәләтне тасвирлау өчен: “Шулай шул дөнья. Дурака вәләйт итеп йөргәндә бар да ярый. Үзәгең өзелгәндә, бәгырең киселгәндә, җаның бәргәләнгәндә үзеңнеке кирәк, үз әбиеңнең йомшак кулы кирәк, бабаларыңның моңлы, сагышлы җыры кирәк. жандагы бушлыкны шырдый-бырдый белән тутырып булмый” (т. 9, 146 б.).

Көрәш төшенчәсен Туфан мисалында бик тәгаен күз алдына китерергә була. Нинди юнәлешләрдә көрәшүен ап-ачык күзалдына китерәбез бит. Бөтенесе безнең чорда, халык алдында булды бит. Аларны искә төшерү – үзе бер кирәкле сабак күнегүләредер. Нинди юнәлешләр алар?

Башта “көрәш” сүзен Туфанның үз авызыннан ишетик әле: “Үткән ел (1987 ел) туган телебезнең хәвефле хәле турында ныклап сөйләшә башладык. Вакыт җитте. Әгәр киләсе ун-унбиш ел эчендә ни дә булса эшләнмәсә, телсез калабыз. Көрәшмичә булмый” (т. 7, 282 б.). Бу сүзне ул янә дә берничә мәртәбә искә төшерә: “...Һәр халык үзе һәм аның теле үзенә күрә бөек, һәр халык җирдә бер-берсен хөрмәт итәргә тиеш. Әгәр минем әниемнең телен кемдер кимсетергә тели икән, мин андыйлар белән аяусыз көрәшәм. Ул көрәшнең ни белән бетәчәгеннән курыкмый көрәшәчәкмен” (т. 9, 101 б.).

Аның көрәш объектлары бик конкрет. Менә *Ана теленә хөрмәт тәрбияләү* тезисы. “Укытучы һәм әдәбият” дигән мәкаләсендә төп сүз: укытучы, аның әһәмияте, әдәбият укыту проблемалары. Озынозак тасвирлаганнан соң ясалган нәтиҗәдә, моңарчы бер сүз дә булмаган “тел” үзәккә килеп төшә: “Ә милли әдәбиятка, туган телгә игъ-

тибарны киметеп, без кешене җирлегеннән аерабыз. Патриотизм абстракт төшенчә түгел, ул – конкрет. Олы Ватанга мәхәббәтне туган җиргә, аның теленә мәхәббәттә генә тәрбияләп була – әнисенең теленнән бизгән кеше бүтән аналарның телен беркайчан да хөрмәт итә белми. Бу – хакыйкать!“ (т. 7, 105).

Яисә тагын да конкретрак тезис – *барлык телләр арасында татар теле дә тигез булсын; Татарстанда дәүләт телләренең икесе дә тигез булсын.* Депутат вакытында бу тема аның чыгышларында аеруча еш ишетелде. “...Татар, татар, дип, үз милләтем язмышы турында күбрәк борчылуым да, бәлки, кайберәүләрнең күңеленә хуш килмәгәндер. Ләкин аңа карап үз мәсләгемнән китмәдем. Татар теле – дәүләт теле һәм дәүләтебез күләмендә тигез хокуклы булырга тиеш, дип иң югары трибуналардан шул телдә сөйләдем...” (т. 9, 101 б.), – дигән иде ул үзе дә.

Туфанны иң борчыганы – татарның үзенең *ана теленең киләчәгенә битарафлыгы,* гамьсезлеге, алай гына да түгел, татарның бүгенге көнгә яраклашып, ана теленә хыянәт итүе, балаларын-оныкларын шундый мирастан мәхрүм итүләре. Публицистикасының күп өлешендә, хәтта әдәби әсәрләренең дә кайберләрендә бу мәсьәлә махсус куела. “Мин күреп, белеп, ишетеп торам: үз халкына сыенып кеше булучыларның (булганнарның) кайберләре балаларын шул халыкның теленнән биздерәләр. Болар – оятсызлар, һәртөрле сылтау эзләмәсеннәр, болар – спекулянтлар. Мин: “Татар белән кая барып була?” диючеләрне томана дип саныйм. Әнә Америкадан килеп Казанда вакытлыча гына яшәүче Кристина исемле ханым татарча сөйләшә башлаган. Өйрәнгән. Югыйсә аңа нигә кирәк татар теле? Ә ул белә нигә кирәклеген, чөнки ул акыллы адәм баласы, чөнки ул адәм рәтле илдән килгән. Ә монда гомер буе татар арасында яшәгән рус-марҗалар ике сүз татарча әйтә алмый... Юк, моңа алар гаепле түгел, чөнки аларның канына син өстен, синең телең бөек дигән каршылыкны сеңдергәннәр...” (т. 9, 315 б.).

Әйе, милләт сакланса гына, тел дә яшәячәк. Ә менә милләтебез татар язмышы гел кыл өстендә. Шуңа күрә Туфанның тел дип януын милләт дип яну дип, милләт дип кайгыртуын тел дип кайгырту, дип аңлыйбыз да. Хәзер халык исәбен алу бездә милләтләр язмышына тыкшынуның бер җинаятьчел галәмәте дип бәяләнү хәленә килеп җитте. Бигрәк тә татар санын киметү, аның дәрәҗә-абруен төшерү өчен ниләр генә лыгырданмый да, ниләр генә эшләнми. Шуны эчке бер вәсвәсә, борчылу белән тойган Туфан бу “тыкшынуга” битараф

кала алмады, әлбәттә. Заманында аның Себер татарлары, керәшеннәр, мишәрләр турында язмалары бөтен җәмәгатьчелекне уятып җибәргән бәхәсләр кузгаткан иде. Татар халкының бу аерылгысыз төркемнәрен милләттән аеру өчен барган ыгы-зыгыга каршы чын мәгънәсендә милләтпәрвәр буларак публицист осталыгы белән ялкынланып әйткән сүзләре милләтне саклауда эзсез калмагандыр. Бу тема бүген дә актуаль, кайнарлыгы сүрелмәгән. Шәхсән үзем дә, аңа моңарчы да берничә язма багышлаган булсам да, эзләнүләремне, иҗатым дәвам иттерәм. Себер татарларының тел үзенчәлегенә бәйле чыгышларым әзерләнә. Шуңа күрә Туфанның бу хактагы чыгыш, язмаларын алда әле бер генә тапкыр искә төшермәбез. Үзенә бер бүлекчә багышламакчы булып, киләчәккә калдырып торыйк.

Инде бәян ителгән тезисларны никадәр генә тормышчан, актуаль, конкрет дисәк тә, алар әле барыбер гомумирәк, адәм баласына болар бит шәхсән миңа кагылмый, ә бөтен милләткә, халыкка кагыла, дигән сылтау табарга юл калдыра. Моны тойган Туфан *һәркем телне белергә, белмәгән очракта өйрәнергә-укырга тиеш*, җәмгыятьтә моның өчен шартлар, ихтыяҗ булырга тиеш, дигән тагын да конкретрак тезис куя. “Әйе, яшьләребезнең яраткан җырчылары арасында Салават Фәтхетдиневнең генә булуы Салаватка дан өсти, әлбәттә. Ләкин калган кумирларының Селин Дион, Джо Кокер, Элтон Джон, “Вопли Видоплясова”лар, тагын без белмәгән әллә кемнәр булуы – бу буынның бездән аерылганын раслаучы факт. Болар инде “Кара урман”, “Уел”, “Сибелә чәчәк”ләрне тыңлап җан рәхәтлеге тапмаячак, “Әпипәгә” сикереп төшеп биемәячәк.

Әгәр дә безнең милли мирасыбыздан аерылган яшьләр шушы өч бала гына булса, әллә ни борчылмас идем. Ләкин алар күп, бик күп, Милли чиновниклар элитасы балаларының 90 проценты шундый дисәм, һич кенә дә ялгыш булмас. Гаҗәеп хәл – татар түрә булып алдымы, балаларын татар итмәскә тырыша. Әллә соң бу татар дигән кавемне саклап калыр өчен татарны авылда гына бикләп тотып, башлангыч белемнән артыгын бирмәскәме?” (т. 9, 144 б.).

“Бәлки, күз яше аша күлеп матавадыр татар, аның үз илендә, үз телендә рәхәтләнеп сөйләшергә дә хокукы чикләнгән. Аңа еш кына “говори человеческим языком” дип кисәтү ясыйлар. Гозерен берәр учреждениедә үз телендә әйтсә, “не понимаю по-вашему” диләр. Татар үз теленнән ваз кичеп, чит телдә сөйләшергә мәҗбүр...” (т. 9, 163 б.).

“Я не стану философствовать на тему о необходимости знания родного языка. Разве можно дискутировать на тему: нужна родная мама или не нужна? Нет надобности доказывать и необходимость знания русского языка как языка межнационального общения. Но как это совмещать? Не как-то легко давать рецепты, но что-то надо делать” (т. 9, 192 б.).

Хәер, Туфанча тыйнаклык күрсәтеп, әдип “рецепт билгеләү бик җиңел түгел” дисә дә, үзенең бай тормыш тәҗрибәсенә, халыкның мул мирасына таянып, иң кирәкле киңәшләрен биреп килә. Беренчеләрдән, мәсәлән, *телне саклау – ата-баба васияте ул.* Аның “Үзгәртмәгез кулыгызны!” дигән парчасы бар. Бабасы өйдәге хатын-кызга күнегелгән уңай эш-гамәлне, гадәтләрне тик торганда үзгәртмәскә киңәш итә. Шул васиятне үтәп, Туфан үз киңәшен бирә: “Кулны гына түгел, телебезне, иманыбызны үзгәртергә дә әзербез... Балаларыбызга бабаларыбызның телен өйрәтү шактый мәшәкатьле ич. Урамда нинди телгә өйрәнсә, шул җиткән. Сүгенә икән сүгенсен, ни зыян... Ни чәчсәң шуны урасың инде ул. Башта телебездән биздерәбез балабызны, аннары – үзебездән. Бик табигый.

Бабайлар белми генә әйтмәгән шул: үзгәртмәгез кулыгызны, үзгәртмәгез телегезне, үзгәртмәгез иманыгызны” (т. 7, 216 б.).

Монда гомуми үгет-нәсихәт белән генә ерак китеп булмасын Туфан яхшы белә. Аның иҗтимагый иҗатының күп өлешен *татар телен өйрәнү мәсьәләсе* тәшкил итә. Ул мәсьәләнең төрле аспектларын белгечләрчә анализлый, оста публицистларча тасвирлап та бирә.

Әлбәттә инде, Туфанның бу юнәлештәге уй-фикере, бәяны-тасвиры үткен тәнкыйть, чәнечкеле юмор-сатира белән сугарылган. Хәтерлим: ул бер күренешне тасвирлый: оныгы Диләрәнең классташы – рус кызы Иринаның – татар телен бик өйрәнәсе килә икән. Мәктәптә эштер-өштер генә өйрәтүгә ризалашмыйча, татар авылына барып, шунда бераз яшәп өйрәнергә булган. Әнисенең танышы аша сөйләшеп-килешеп, киткән бу чеп-чи татар авылына җәй җәйләргә. Әмма дә ләкин берничә көннән кайтып төшкән. Сөйләгән. Йорт хуҗасы әби “Здрастуй” дип исәнләшкән. Урысча гына сукалый ди. Оныклары барысы да урысча гына сөйләшә ди.

“...Син мин язганнарны барыбыр укый алмаячаксың. Чөнки югарыга үрмәләгән татарның баласын татарчага өйрәтмиләр. Югары баскычта торган гаиләләрнең 90 процентында тәрбия татар теленнән җирәнүгә корылган “ (т. 9, 36 б.).

Телне өйрәнергә өндәү кирәк нәрсә, тик монда да конкрет фикерләр, тормышчан үрнәк-сабаклар белән эш итү хәерле, икәнен Туфан бик яхшы белә. Кешенең тел тоемлау сәләте дә эзлекле күнегүләр, максатчан уку нәтиҗәсендә генә бөртекләп җыела. Ә мондый күнегүләрне бары мәктәптә генә бирәләр. Шуңа күрә дә Туфанның иҗтимагый эшчәнлегендә *телне мәктәптә укыту проблемасы*ның үзәктә булуы табигыйдер. Анда да тел тоемлау сәләте бигрәк тә бала бакчасында, мәктәптә программада каралган таләпләргә нигезләнеп, эзлекле, системалы, үзләрендә тел тоемлавы һичшиксез булган укытучы-мөгаллимнәр тарафыннан бирелергә, үстерелергә тиеш. Бу мәсьәлә Туфанны нык борчый иде. Гомумән, мәктәптә татар теленә өйрәтү, укыту проблемасы аның җәмәгать эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе булды. Аның укытучыларга, мәгариф чиновникларына, белгечләргә мөрәҗәгатьләре еш басылды, Дәүләт советы утырышларнда кайнар чыгышлары еш яңгырады.

Мәктәптә телләрне, аерым алганда татар телен, укытуга караган кайбер фикерләре: “Шактый ата-аналар татар телендә укытуның кирәге юк, дигәнрәк фикердә торып, балаларын татарча укытмаска тырышалар. Татар теле белән югары уку йортларына кереп булмый, диләр. Асылда, бу фикер ялгыш кына түгел, ялган һәм зарарлы да. Татар мәктәбендә татарча укыган яшьләр арасында укуларын институт, университетларда дәвам итә алмаучылар бар икән, анда татар теленең һич кенә дә гаебе юк. Аларга аларны укыткан укытучылар гаепле – тиешле белемне, димәк, бирә алмаганнар. Үзләрен аклар өчен шундый укытучылар татар телен гаеплиләр. Татарча укып беркая да кереп булмый, дигән ялганны гадәттә укытучылар үзләре тараталар. Әгәр дә мин татар телендә тиешле, төпле белемне алам икән, Япониягә барып япон институтында да имтихан тота алам” (т. 9, 277 б.). “Татар теле белән татар балаларын куркытучыларны мин провакаторлар дип атар идем “ (т. 9, 283 б.).

“Рус мәктәпләрендә, белгәнебезчә, татар теле укыта башладылар. Шул турыда сөйләгәндә, бу гамәлне зур җиңү итеп күрсәтәбез, янәсе, татар теленә игътибар арта, янәсе, үз телен оныткан татар балалары телләрен беләчәк, башка милләт балалары татар телен өйрәнәчәк. Теләк, әлбәттә, изге. Әмма бу асылда уйдырма. Дәүләт теле дип игълан ителгән татар теленә социаль ихтыяҗ булмау сәбәпле, мәктәпләрдә татар телен укыту формаль бер чарага әйләнде дә калды. Ул бары тик “татар теле”,”татар теле” дип кычкыручыларның авызын

томалар өчен генә эшләнә шикелле. Монда инде күз буяуның чиге-чамасы юк" (т. 9, 280 б.).

"Очрашулар вакытында укытучылар дәреслекләрнең камил булмавыннан зарланалар. Бу асылда татар теле дәреслекләренә, аның да рус мәктәпләрендә укытыла торганнарына кагыла" (т. 9, 281 б.).

Туфанның иҗтимагый тел эшчәнлегендә *тел һәм дин мәсьәләсе дә* (аеруча соңгы еллар иҗатында) шактый әһәмиятле урын алып тора. Милләтне телдән башка күз алдына китерә алмаган кебек, Туфан аны дин белән дә тыгыз бәйли, димәк ки, тел белән дин бәйләнешен дә ул табигый аерылгысыз дип саный, аеруча ул моңа соңгы елларында инануга килде. Бу хакта тезислап кына менә кайбер уй-фикерләре: "Татар – динле халык, әмма ул беркайчан да фанатик булмады. Татар кешесе – эш кешесе. Аңа синең капитализмың ни, коммунизмың ни, ваххабизмың-фәләнизмың ни. Син бары тик аның иреген кысма, аягыңа богау салма, ике кулына эш бир, үз телендә сөйләшүне тыйма, үз көенә моңлануына бәйләнмә" (т. 9, 263 б.).

"Бүген иртән Татарстан радиосыннан бер дин әһеле чыгышын тыңладым. Татар телен белмәгән һәм белергә теләмәгән (теләгән булса, өйрәнгән булыр иде) Президентка кандидатны яклап сөйли. Иман дигән сүз куллана. Коллегаларым исеменнән дип сөйли. Димәк, безнең хәзрәтләребез дә аныңча уйлый?

Әгәр дә безнең мәчетләребездә татар телен санга сукмаучылар утыра икән, без, язучылар, татар халкын ул мәчетләргә йөрмәскә өндәячәкбез. Татарга каршы эшләүче мәчетләр безгә кирәкми. Аллаһы тәгалә безне татар кавеме итеп яраткан" (т. 9, 291 б.).

"Кайбер мәдрәсәләрдә татар балаларына урысча дин сабаклары укытучы хәзрәтләрнең гамәле дә ошамый миңа. Алар андый балаларга иман индерәбез дип алданалар. Телебездән бизгән татар балаларына иң элек ата-бабаларының телен өйрәтергә кирәк. Менә шуннан соң ул иманның да ни икәнен аңлый башлар" (т. 9, 243 б.).

"Нишли бу татар? Үзбашына азынамы? Шул хәтле дә аңгыра сарыкмыни соң без? Теленнән бизеп, кая бармакчы, кем булмакчы була? Диненнән качып, кемнәр оҗмахына керәсе килә?" (т. 9, 138 б.).

Туфанны өзлексез талкыган, аны даими хәрәкәткә китереп, иҗатка ыргылырга мәҗбүр итеп килгән әлеге проблемаларны барлаганда, аларны хәл итү юлларын эзләгәндә, халыкка үтемле итеп тәкъдим иткәндә, әдип башка халыкларның, милләтләрнең телләрен, алар алдында да торган мәсьәләләрне йә үрнәк итеп, йә гыйбрәт итеп, йә безнеке белән вә үзара чагыштырып башка телләрне, халыкларны

да китерә. *Башка милләтләр, телләр белән чагыштырганда* без нинди, нинди сабаклар ала алабыз, шул ук вакытта алар безнең белән чагыштырганда нинди үрнәк, нинди сабак ала ала?

“Аннан соң үзенең артталыгын рус иптәшләрнең күбесе бүтәннәргә сылтый. Имеш, татар игосы шулай иткән, татарлар җимергән. Җимерерлек нәрсәсе булганмы соң? дигән уй еш туа миндә. Булган булса, кем җимергән? Татарлармы? Ярым җимерек чиркәүләрне кем шул хәлгә китергән? Газеталарда укыйм, яһүдләр шулай эшләгән, дигән сүзләрне очратам да көләсем килә, йөз миллионга якын халыкның хезмәтен 2 миллион яһүд җимереп бара аламы? Кирәкми үз вәхшилегеңне бүтәнгә сылтарга. Әйт, без әле вәхшиләр, диген. Әйдәгез ул вәхшилектән котылыйк, дип халыкны уят. Монда мин, русны яманлап, татарны әйбәт дип әйтергә җыенмыйм. Без дә шул. Бүтәннәрне сүгәбез. Ә үзебез телебезне оныттык. Юк, без түбән аңлы халык әле, дип әйтәсе урынга, объектив сәбәпләр эзлибез. Үзенең баласын татарча өйрәтмәгәнгә русны сүгеп йөрүче татарлар әзме? Өйрәт балаңны үз телеңә. Өйрәтмә, дисәләр дә өйрәт, менә ул чагында сине кешегә санап була инде. Әйе, кеше камил түгел. Кеше корсак өчен яшәүче башка җанварлардан әлегә әлләни аерылмый” (т. 7, 352 б.)

“Без әле кол булсак та, нигә дә булса өметләнеп яшибез. Азатлык алырбыз, мөстәкыйль дәүләтебез булыр, үзебезчә яшәрбез, дибез. Урысның өмете дә юк. Аласын алган, ләкин бернәрсәсе дә юк. Теле генә калган. Анысы да инде урыс үзе аңламаслык хәлгә төште...” (т. 9, 64 б.).

“...Мин казахча ярыйсы ук сукалый башлаган идем. Ни гаҗәптер, мин казах телен бик тиз өйрәндем һәм ул телне дөньядагы иң ягымлы телләрнең берсе дип саныйм” (т. 9, 212 б.).

“Урысның урыс булудан туктавының сәбәпләрен ул (урыс язучысы Николай Пантелеевич Анкилов) әллә кайдан эзли. Ә урыс күптән инде урыс түгел. Теле генә сакланып калган. Анысы да инде чуарланып беткән. Ярослав Смеляков дигән урыс шагыйре “Килмешәк татар телен рус тегермәне тартты” дигән иде дә, кем тегермәнендә кемнең теле тартылганы шактый ук бәхәсле әле. Урыс шовинистларының бүленмәс бербөтен Россия, бөекдержава, бөек рус теле дип шапырынуы гына урыс рухын саклый алмый шул. Аны саклар өчен акыру гына җитми, акыл да кирәк. Татарларны һәм башка халыкларны руслаштыру сәясәте дәвам итә. Урыслашкан татар ничаклы гына урыс булырга азапланса да, урыс рухы юк инде аңарда.

Халкын, милләтен, телен саткан кешенең токымы да имансыз буладыр ул...” (т. 9, 223 б.).

Бүтән күпчелек иҗтимагый язучы, җәмәгать эшлеклеләреннән аермалы буларак, Туфан тел төшенчәсен гомуми абстракт күренеш буларак фикерләми, ә бәлки фикерләү, язу, сөйләү өчен конкрет бер корал буларак куллануны күз алдында тотып уйлана, эзләнә, борчыла. Ягъни ул телне сөйләмнән аермый. Шулай да аның өчен тел һәм сөйләм төшенчәләре бер түгел. Болай фикер йөрткәндә, ул сөйләмнең мотивлары-сәбәп-максатларына ярашлы рәвештә сыйфаты турында җитди уйланырга, эзләнергә, гамәли әһәмиятле нәтиҗәләр чыгарырга мәҗбүр итә. Бу уңайдан ул сөйләмнең саф татарчалыгы, чисталыгы, телнең байлыгын саклау, аны бозмау, чүпләмәү, тел культурасы мәсьәләләренә игътибарлы булуга иҗтимагый эшчәнлегендә җитди урын бирә. Беренчедән, ул бу таләпләрне үз әсәрләрен язганда катгый үтәргә омтылып иҗат итте. Икенчедән, халыкны, башка иҗатчыларны сөйләмнәренә шулай таләпчән булырга өндәде.

«“Минем әбиләр” (поездда барганда купедашлар) моны, әлбәттә, (офицерларның сүгенүләрен) ишетеп баралар. Хәзерге заман кешеләренең телләре тәмсезләнү турында сөйләшеп алалар. “Мин ирем белән илле ел тордым, сүгенгәнен, ямьсез сүз әйткәнен ишетмәдем”, – ди авыл карчыгы. Врач, сүгенү сүзен ишеткән саен, зыялыларга хас тыйнаклык белән колагын томалап ала да, “Мин сугышка чаклы булган кызыл командирларны хәтерлим, нинди культура иде аларда, нинди культура иде. Кайда ул сүгенү, кыңгыр сүз дә әйтмиләр иде. Ә болар Совет Армиясе офицерлары – телләре бродягалар теле кебек...”, – ди» (т. 7, 112 б.).

Язмабызның бу өлешен дә йомгакларга вакыт җитте. Әйтелгәннәрдән укучым бер нәтиҗә ясамый калмагандыр: телебез язмышы турында нинди генә борчулы, күңелсез факт, күренешләрне фаш итеп, фаҗигале нәтиҗәләр ясамасын, Туфан тәмам өметсезлеккә бирелми, һәр фикерендә, һәр нәтиҗәсендә кечкенә генә булса да өмет чаткысын җемелдәтми калмый. Гомумән дә, миңа милләтпәрвәрләр арасында Туфан, шәхес буларак, милләт баласы буларак, өмет төшенчәсенә тәңгәл зат кебек тоела.

“Татарга беркайчан да җиңел булмаган. Әмма без исән һәм исән булачакбыз да. Мең еллар буе үз җирендә тамыр җәйгән имәнне йолкып ыргыту җиңел эш түгел ул. Мин суверенитетның ун еллыгын бәйрәм итәчәкмен. Исән булсам, унбиш, егерме еллыгын да бәйрәм итәргә исәп...” (т. 9, 153 б.)

Менә бу күренешкә диккать итик әле: “Җир өстеннән без үтеп барганда, кемнәрдер безне күреп: “Ай-яй, бигрәк горурлар, бигрәк чибәрләр, акыллы, дус-тату, булган икәнлекләре йөзләренә чыккан, дисеннәр иде. Кемнәр икән алар? Нинди телдә сөйләшәләр? дисәләр, икенче берәүләр: “Белмисезмени, татарлар ич алар, үз телләрендә сөйләшәләр”, – дисеннәр иде” (т. 9, 340 б.).

Уйлый калсаң, Туфанның бу канатлы гыйбарәсе аның бөтен иҗатына, бөтен яшәешенә эпиграф бит. Ул аның безгә васияте дә. Безнең, аның милләттәшләренең бүген, милләтебез, телебез яшәячәк, дигән сүнмәс өметтә яшәвебездә Туфанның да өлеше аз түгелдер.

Хәтерлисездер, тел тоемлау төшенчә-категориясен Туфан иҗаты мисалында ике фәнни яссылыкта анализларга килешкән идек: иҗтимагый тоемлау һәм иҗади тоемлау юнәлешләрендә. Язучы иҗатында, әлбәттә инде, иҗади тоемлау рәвеше өстенлекле каралырга тиеш. Шулай да Туфанның аеруча киң кырлы язучы булуын, аның җәмәгать эшлеклесе һәм публицист буларак иҗат тәҗрибәсенең ифрат әһәмиятле һәм бай булуын, аннары бу язма адресланган укучыларыбызның да үзенчәлеген күз уңында тотып, язманың беренче өлешен иҗтимагый тел тоемлауга багышлаган идек. Хәзер менә икенче өлешенә – *телне иҗатта тоемлау* өлешенә – керешәбез.

Төп эчтәлеккә күчкәнче ике чигенеш ясап алу сорала. Беренчесе: язучы һәм тел мәсьәләсе. Тел тоемлау нечкәлеге гадәти укучыныкыннан, гади кешенекеннән язучыныкы аерылырга тиешлеге бәхәссез. Моны Туфан үзе бик яхшы аерган, без дә аңларлык итеп язып та калдырган. Бу хакта инде әйткән идек. Ә хәзер аның гомумән дә язучының телгә мөнәсәбәтенә караган кайбер фикерләрен күзәтеп китик.

Язучы һәм тел мөнәсәбәте. “Минемчә болай: кем әйтмешли, эчтәлегебез безнең барыбызныкы да бер – социалистик, формабыз милли. Миллилекне ничек аңларга? Кайсы халыкның моңын үз телеңдә көйлисең, син шул халыкның язучысыдыр. Телдән һәм моңнан башка әдәбият була алмый. Әгәр мин татар телендә татар моңын көйлим, татар җырын җырлыйм икән, Австралиядә яки Бәләбәйдә тууымның ни катнашы бар?” (т. 7, 39 б.); ”Язучы өчен төп сыйфатларның берсе – сүзне тою сәләте” (диккать итеп китик әле: Туфан “сүзне тою” ди, “телне” дими).

“Әйе, мин татар теленнән башка телдә иҗат итүчеләрне татар язучысы дип санамыйм...

...Бик тә татар язучысы буласы килүчегә (Диас Валеевка) әйтәсе сүземне әйтәм: татар телен белмәгән, белергә теләмәгән, рухы белән

татар булмаган, бары тик фамилиясе белән этисенең исеме генә татарча булган кешене дә татар язучысы дип атасам, мин үзем кем булам икән” (т. 9, 377 б.).

“Д. Валеев мәкаләсендә татар теле инкарь ителә, киләчәктә аның кирәге булмаячак, дигән фикер ята. Монда инде мин дәшми кала алмыйм. Тагын бер кат әйтәм: татарча язмаган, татарча белмәгән һәм белергә теләмәгән, татар күңелен аңламаган, җанында татарлык булмаган, татарча язучыны националист дип атаган кеше татар язучысы була алмый, дим” (т. 9, 379 б.).

“Инде иң четерекле мәсьәләгә килеп җиттек. Туган теленнән мәхрүм ителгән, әмма язарга сәләте, дәрте булганнарга нишләргә? Бу турыда Валеев әйткән резолюция чыгарырга минем дә, бүтәннәрнең дә хакы юк. Үзләренә карасыннар инде. Тик соңыннан, мине татар язучысы дип санагыз, дип бимазалап йөрмәсеннәр. Кемнең кем итеп санарга кирәклеген халык хәл итә. Хәзергә безнең халык үз телендә язучыларны үз итә” (т. 9, 380 б.).

Икенче чигенеш – ул драматургның тел тоемлавы, драматургия, сәхнә сөйләме мәсьәләсе. Туфан – драматург. Ул татарның иң үзенчәлекле сөйләме – сәхнә сөйләме белгече. Аның сәхнә сөйләменә мөнәсәбәте гамәли дә, фәнни дә әһәмиятле. Башта без аның фикерләрен бәян итик. Аннары шуларны да искә алып, бу хакта әңгәмә куертырбыз.

“Сәхнәнең бит үзенә генә хас теле бар. Җәрәхәт турында сөйләү бер нәрсә, күрсәтү икенче нәрсә. Сүз, билгеле, җан җәрәхәте турында бара” (т. 9, 371 б.);

“Ни генә әйтсәләр дә, театрның (драма театры турында сүз бара) нигезендә сүз ята. Тамашачы театрга сүз аша фикер ишетергә, сүз аша уен карарга килә. Әгәр дә театрдан сүз качса, анда тоташ чинау гына калса ни булыр? Тфү, тфү, шулай була күрмәсен“ (т. 9, 285 б.);

“Бию, пантомима кебек нәрсәләр белән театрдан галиҗәнап сүзне сөрделәр” (т. 9, 313 б.). Сәхнә сөйләме, анда тел һәм башка чараларның куллану үзенчәлеге турында алда да тукталгалап китәрбез.

Хәзер инде Туфанның тел тою асылының төп хәсиятенә күчәбез. Аның бу асыл таланты язучы буларак, иң әүвәле драматург буларак, иҗатында ничек чагылыш таба? Нәрсә ул аның иҗатында тел тоемлау күренеше?

Искәрткән идек: тел тоемлау дигәндә, Туфан сүзне тою дигән иде. Сүз дигәндә, ул гомумән телне күз алдында тотамы, монысын ул

искәртми. Шулай да без аның сүзгә мөнәсәбәтеннән башлыйк әле. Гәрчә аның уйлануларында телнең беренчел берәмлекләре аваз, хәреф (фонема), иҗек (морфема) һ.б. кисәкләре турында да фикер, күзәтүләр очрый, аларын да игътибарга алырбыз. Шулай да тел тоемлауны Туфан сүзгә таянып төшендерә бит. Әйдәгез алайса Туфан иҗатында *тел* сүзе һәм тел мәгънәсендә килә торган *сүз* төшенчәләренә мөнәсәбәтеннән башлыйк..

Менә аның публицистик әсәрләреннән *тел* сүзенең сүзлеге. Шул берәмлек белән ясалган телбизәкләр, сүзнең семантик мәгънә төсмерләре, синоним, омоним һ.б. сыйфатында кулланылу мөмкинлекләре турында әдипнең фикерләре.

Депутат теле: *Депутат теле* белән туктаусыз сөйләү дә телне ярлыландыра. Һаман бер сүз, һаман бер сүз, шуны да ишетүче юк. Сөйләмичә дә булмый. Хет ичмасам сүз белән үзебезнең исән икәнне белдереп торырга кирәк. Югыйсә татар үз телен үзе йотты, дип сөенүләре бар. *Сөйләвегездән* ни мәгънә дип әйтәләр дә ул безгә кайберәүләр, *сөйләми* дә башласак ни булыр? (т. 9, 433–434 б.);

Кәҗүнни тел белән әйткәндә, кайбер җитешсезлекләре булуга карамастан, әйбәт, йөрәккә, күңелгә һәм акылга да тәэсир итә торган шигырьләр (Р. Зәйдулла шигырьләре. Дүрт шигырьдән өчесе аңарга ошаган. “Кәҗүнни сүз” диюе “кайбер җитешсезлекләре булуга карамастан” дигән штампка карыйлардыр (т. 7, 93 б.); *Бродягалар теле* (т. 7, 242 б.); *Вәхшиләр теле* (т. 7, 355 б.); *Теле тәмле*: Бу агайдан алалар (өрекне, базарда). Чөнки *теле тәмле.* Сата белә (т. 7, 151 б.); *Тел тидерү*: Кайвакыт, кызып китеп, бүгенге заман яшьләренә *тел тидерәбез* (т. 7, 190 б.); *Телең кору:* Яхшылык эшләмәсәләр дә, рәхмәтеңне әйт, аннан *телең корымас* (т. 7, 195 б.); *Телеңне тыю*: *Телеңне тыя* белмәгәнең өчен авызыңа кундырырмын, тешләреңне җыеп бетерә алмассың (т. 7, 157 б.); *Телләрен тешләп түзәләр* (т. 9, 429 б.) һ.б.

Бу урында бер өстәмә сорала икән. “Тел” төшенчәсенә мөнәсәбәтен махсус күзәтергә тотынгач, Туфанның унтомлыгын янә анализладым. Әлбәттә, күзәтүнең төп максаты “тел” булгач, күз карашы иң башта “тел”, “сүз”, “сөйләм” мәгънәсен белдергән төшенчәләргә төшәргә тиеш иде. Шулай булды да. Бераздан аңлашылды: “тел” сүзе кергән язмаларны, башлыча, икегә төркемләп була икән – темасы нинди булуга карамастан, тел төшенчәсе катышкан фикер, нәтиҗәләр; икенчесе, махсус тел турында, аны фәнни төшенчә буларак ачыклау, мәгънәсен анализлау, язучыга, аның язу проблемасына турыдан-туры кагылган язмалар. Аеруча әһәмиятлесе шулдыр: күпчелек язмаларында,

иң җитди темаларга алынганга күрә, анда телнең ниндидер яссылыкта барыбер чагылмый калмаганын күрәбез.

Янә бер кызыклы “ачыш”: кайбер язмаларда эчтәлегенә “тел“ төшенчәсе салынган очракта да “тел” сүзе мәҗбүри түгел икән. Менә “Ир-ат, хатын-кыз, гаилә” дигән язма. “Сездә сабырлык та, хәйләкәрлек тә җитәрлек. Курыккан булып кыланыгыз шул эгоист ир затыннан, үзен йорт башы дип уйласын, шайтан алгырысы! Ул бит әле элекке инстинктларыннан арынмаган. Сез әкрен генә идарә итегез (Бу киңәшләрне үтәү гомумән дә тел, сөйләм төшенчәләреннән башка мөмкин түгел, ә ул сүзләр текстта бөтенләй юк. – *Н.И.*). Кычкырырга, битәрләргә, милиция чакырырга ашыкмагыз. Җаным, бәгърем, дисәң, җайлап әйтсәң, керегезне, идәнегезне юып бирер ирегез. Чөнки ир-ат ул чыбыркы белән түгел, солы белән куганны ярата” (т. 7, 110 б.). Солы инде – ул рухи ризык – бу очракта аны *тәмле тел* (сүз) дип аңлыйбыз. Гәрчә текстта андый сүз үзе булмаса да.

Сүз сүзенең сүзлеген барлау уңаеннан да Туфанның бу төшенчәне публицистикада һәм драматургиядә (язма һәм әйтмә әсәрләрдә) иҗади куллану мөмкинлекләре, мәгънә төсмерләрен аңларга омтылып, эзләнүләре, аңлатма бирү алымнары, синоним табарга тырышуы кебек лексик мәсьәләләргә караган фикерләренә диккать иттек.

Дөрес һәм ялгыш сүз (т. 7, 219 б.); *Каргый торган сүзләр.* Боларга Р. Зәйдулла шигырьләрендәге *“Муеның астыңа килгере”, “Кулың коргыры”, “Тәгәрәп җан биргере”* һ.б. китерә. Туфан аларга карата тискәре караште. Кай җирен ошатмый? Күрәсең, мәгънәсе бик төгәл булмавы күңеленә ятмыйдыр. Шул ук язмасында ул “Җанны асраганда, мәгънә күреп // Кыса эчендәге яшәештән” дигән гыйбарәдәге сүзләргә дә “бәйләнә”. “Нәрсә аңлата бу сүзләр? Кем әйтә болай дип?” – ди. (т. 7, 94 б.). Һәр сүзгә, аның һәр мәгънә төсмеренең төгәллегенә менә нинди таләпчәнлек! *Ачынып әйтелгән сүз* (т. 7, 262 б.); *чын йөрәктән әйтелгән сүз* (т. 7, 262 б.); *авыр сүз* (т. 7, 267 б.); *усал сүз* (т. 7, 268 б.); *ямьсез сүз* (т. 7, 112, 235 б.); *иләмсез сүз* (т. 7, 314 б.); *кыңгыр сүз; кырын сүз* (т. 7, 242 б.); *китап сүзе*: Һәрвакыт *китап сүзе* генә сөйли идем (т. 7, 242 б.); *коры сүз*: Димәк, без язганнар – комга су сибү генә? Мәрхәмәтле булыйк, дип язуыбыз *коры сүз* генә (т. 7, 118 б.); *мактау сүзләре*: Бик күп *мактау сүзләре* ишеттем (т. 7, 172 б.); *матур сүз* (т. 7, 317 б.); *мәгънәсез сүз:* Кайвакыт әдәбиятта гражданлык хисе, дип сөйлибез, *коры, мәгънәсез* сүзләр кулланып, ул төшенчәнең асылын югалтабыз (т. 7, 120 б.); *мәзәк сүз*

(т. 7, 314 б.); *сүгенү сүзе, сүгенүгә охшаш сүз: сүгенү түгел, сүгенүгә охшаш сүз* дә ишеткәнем булмады (Сибгат Хәкимнән) (т. 7, 14 б.); *изге сүз: Изге дигән сүзнең* мәгънәсен тарайтканбыздыр (т. 7, 175 б.) (Зират дигән сүз); *иркә сүз* (т. 7, 337 б.); *кизү сүз*: Һавада илле-алтмыш сүз генә яңгырап тора. Аның да кырыгы – сүгенү сүзе, калган ун-егармесе "Ну", "Че ты", "Уйди" кебек *кизү сүзләр* генә". Ишетелмәгән, сәеррәк сүз. Дежур сүз, ягъни сирәк кенә, спонтан гына, әйтелә торган сүз, диюме? Кайдан алган ул *кизү*не? Әллә редактор тәкъдим иткәнме? *Хилаф сүз* (т. 7, 231 б.); *көфер сүз* (т. 9, 107 б.) (язманың баш исеме); *галиҗәнап сүз* (т. 9, 313 б.); *яңа сүз*: Иске авыздан *яңа сүз* (т. 7, 249 б.).

Туфанның сүзне уйлау, әйтү, куллану үзенчәлеген белдергән гыйбарәләре: *сүзгә тапкырлык*: аның бер сыйфатын – *сүзгә тапкырлыгын* әйтми мөмкин түгел (т. 7, 150 б.); *тавышын күтәреп сүз әйтү* (т. 7, 222 б.); *ялгыш кына сүз ычкындыру* (т. 7, 285 б.); *сүзне кистереп әйтү* (т. 9, 314 б.); *сүз белән уйнау: тәнкыйть сүзе белән уйнамасыннар* (т. 7, 157 б.); *сүзе сүз булган* (т. 7, 364); *сүзебезне өзеп әйтә киләбез* (т. 9, 101). *Сүзне өзү*– әйткәндә кысылу, дигәненнән аерыла.

Сүз – иҗат коралы, аны иҗатта куллану турында Туфанның уй-фикерләрен барлауны дәвам иттерәбез. Мәсәлән, сүзнең мәгънәсен аңларга тырышуы, шуның нәтиҗәсен бүтәннәргә дә төшендерергә, җиткерергә омтылуы турында: "Аннары татарда мокытлык дигән сүз дә бар. Ул инде кирәгеннән артык тыйнаклык. Безнең шактый гына талантлы татар малайларын шул мокытлык харап итте" (т. 9, 10 б.); "Инде килеп, сине берәр "мохнатая рука" (моның татарчасы ничек икән?) күтәреп алган булса..." (т. 9, 34 б.). "Хөсетлек (баш исеме). Бу сүзне мин элек белми идем. Күрәсең, безнең якта аны еш кулланмаганнар, һәрхәлдә минем ишеткәнем булмады. Беренче тапкыр ул сүзне ишеткәч, аның мәгънәсен сораштым. Кара көнләшү диделәр" (т. 9, 56 б.); "Аның (Брежневнең) "систематически" дигән сүзне, кәгазьгә карап абына-сөртенә "сисиматически" дип укуын күреп көлдек. Кычкырып көлдек" (т. 9, 185 б.). Гомәр Бәширов белән хастаханәдә ятканда: "Шифаханә дисезме әле сез? Дөрес түгел бит. Шифаханә ул санаторий. Ә без хастәханәдә ятабыз. Больницаны хастәханә дияргә кирәк. Дөресе шулай. Сүзләрне дөрес кулланырга кирәк" (т. 9, 229 б.). "Казанга киләсе килми. ..."Кайтасы килми" дип язарга кирәктер ич. Юк икән шул: туган авылымнан килдем бит мин бүген. Ничек инде туган җирдән кайтып булсын ди" (т. 9, 249 б.). "Шәхсән үземне суверенитет сүзен еш кабатлау бераз ялыктырса да,

ул татар сүзе булмаса да, барыбер күңелемә якын. Мин аны барыбер кабатлаячакмын һәм 30 августта бәйрәм итәчәкмен“ (т. 9, 317 б.). “Моң турында уйланам да җырның сүзләрен тикшерә башлыйм. Нинди матур, нинди шигъри яңгырашлы сүз – “сибелә”! Без инде ул сүзне кушып сөйләгәндә, аның матурлыгына игътибар да итмибез. Җырда да ул сүз кайгылы, хәсрәтле халәтне сурәтләгәндә кулланыла икән.

Сибеләчәчем, сибеләчәчем,
Сибелә чәчем, тарала.
Йә суга сал, йә утка ат,
Йә кайгымнан арала” (т. 9, 319 б.).

“Ак бай дигәнне ишеткәнем дә, укыганым да юк шикелле. Кара бай дигәнне күп тапкырлар ишеткәнем булды. Мин, Аллага тапшырып, ак бай дигән сүзне әйләнешкә кертеп җибәрергә уйлыйм. Ул – юмарт бай дигәнне аңлатыр инде. Ә кара бай дигәнен барыбыз да беләбездер, ул саран бай дигәнне аңлата” (т. 9, 427 б.) һ.б.

Туфанның сүз тәҗрибәсе дигән бүлекчәдә “Туфан – этимолог” дигән параграф та ачып җибәргәнмен икән. Материал җитәрлек булганга шулай эшләнелгән, күрәсең. Менә кайбер мисаллар: “Урыс хатынлы булыр өчен өйләнә, татар өйле булыр өчен өйләнә икән ич. Урыс женится. Жена хатын бит инде. Татар өйләнә. Ягъни өйле була. Кызык. Әйтәм аны татарда йортка кергән ирне ир кешегә санамыйлар. Урыста ул гадәти хәл. Шуның аркасында урыс иренең яратмаган кешесе – хатынының әнисе – теща, ягъни мәсәлән. Урысларның гаиләгә кагылышлы бөтен мәзәкләре тещадан көлүгә корылган” (т. 9, 435 б.).

Козырь сүзенең кузырдан (уйный торган сөяктән) чыкканын тәмләп төшендерә – “козырять; козырек” (т. 7, 144 б.). Үлем сүзе турында – морто, смерть, казахча мерт, татарча мәрт һ.б. Әни сүзе: ана, мама. Әти дә: ата, папа, патер, папан... (т. 7, 214 б.).

Туфан лексиконында сүз белән эш иткәндә (уйлаганда, әйткәндә, язганда) барлыкка килә торган гамәл, күренешләрне атаган кәлимәләр дә бихисап: *дәшү, эндәшү, сөйләү, сөйләшү, әңгәмә, гәп* һ.б. Шул төсмерләрне эченә алган тезмә, гыйбарәләр “сүзлеге” барлыкка килә: *тупас итеп эндәшү* (т. 7, 221 б.); *корсагына төртеп сөйләшү* (т. 7, 222 б.); *әйтү:* Минемчә, кешеләргә ниндидер мәгънәле сүз *әйтергә* җыенган кешеләр уйландырырлык *сүз әйтә* белергә тиештер. Уйлана белгән кеше – ул инде кеше (т. 9, 241 б.); *сөйләү:* Депутат теле белән туктаусыз *сөйләү* дә телне ярлыландыра. Һаман бер сүз, һаман бер сүз, шуны да ишетүче юк. Сөйләмичә дә булмый. Хет

ичмасам сүз белән үзебезнең исән икәнне белдереп торырга кирәк. Югыйсә татар үз телен үзе йотты, дип сөенүләре бар. *Сөйләвегездән* ни мәгънә, дип әйтәләр дә ул безгә кайберәүләр, *сөйләми* дә башласак ни булыр? (т. 9, 433–434 б.); *әкият сөйләмә* (т. 7, 250 б.); *каравыл кычкыру:* ...моңынны оныткан булсаң, каравыл кычкырып үләсең, диләр (т. 7, 208 б.); *очы очка ялганмый* (т. 7, 225 б.); *рәхмәт уку*: эчтән генә *рәхмәт укыганнардыр* (т. 7, 21 б.); *тукып тору*: ...үзебезгә үзебез *тукып торырга* тиешбез; *чәйнәп ташлау:* Ничек әле ул (Батый хан) Александрны *чәйнәп ташламады* (т. 7, 84 б.); *тел тидерү:* Кайвакыт, кызып китеп, бүгенге заман яшьләренә *тел тидерәбез* (т. 7, 190 б.); *телең кору:* Яхшылык эшләмәсәләр дә, рәхмәтеңне әйт, аннан *телең корымас* (т. 7, 195 б.); *телеңне тыю: Телеңне тыя* белмәгәнең өчен авызыңа кундырырмын, тешләреңне җыеп бетерә алмассың (т. 7, 157 б.); *тетмәсен тету*: *Тетсә тетсен инде тетмәмне,* бәлки сүзләрендә хаклык бардыр, искә алырга кирәк булыр киләчәктә, дип уйладым (т. 7, 133 б.); *сүзгә кесәгә керми* (т. 9, 161 б.); *сөйләшү: Бөер белән сөйләшү* (т. 9, 33 б.); *һәр сүзен конфет кәгазенә төреп бирә* (М. Мәһдиев турында) (т. 7, 297 б.).

Сүз, тел сүзләрен Туфан уйлауның иң югары ноктасы афоризм ясауга да җәлеп итә: *Шаярмаска иде тел белән, шаярмаска иде* (т. 7, 88 б.); *Кешеләр һәрвакытта бер сүзне әйткәндә, икенче сүзне күңелләрендә тоталар* (т. 9, 43 б.); *Ишетү, күрү сәләте табигать тарафыннан бирелгән кебек, сүзне тою сәләте дә, минемчә, кешеләргә тумыштан ук бирелә* (т. 7, 31 б.) һ.б.

Алга таба Туфанның афоризм тәҗрибәсенә махсус бүлекчә багышларбыз әле. Ә хәзер әдипнең үз әсәрләрен язганда сүз белән аерым корал-берәмлек буларак ничек эш итүен күзәтеп алыйк.

Фикерен белдерер өчен сүз сайлаганда аның беренче максаты – әйтергә теләгән фикеренә иң тәңгәл туры килә торган берәмлек табу. Әлбәттә инде, татар сүзе булсын, шушы әсәр тәгаенләнгән укучы, тамашачы, тыңлаучы аңларлык, аның уе белән барәбәр булсын. Нинди берәмлек алар?

Беренче чиратта иң конкрет мәгънә белдерүче берәмлекләр. Тел гыйлемендә алар **конкрет-номинатив берәмлек** дип атала. Аларга исем, атамалар, сан, даталар, терминнар керә.

Башлыча документаль әсәрләр тәшкил иткән публицистика да, конкрет персонажлар сөйләменнән торган драматургия дә кеше исемнәре (фамилия, әтисе исеме, кушаматы), урын, вакыйга, оешма, предмет атамаларын куллануда аерым бер осталык таләп ителә. Ту-

фан шуңа ия дип танылган. Аның драма әсәрләрендә ономастика дигән темага кандидатлык диссертациясе якланды. Болай уйлый калганда да, әсәрләренең исеменә чыгарылган *"Әлдермештән Әлмәндәр", Канкай углы Бәхтияр", "Диләфрүзгә дүрт кияү", "Миләүшәнең туган көне", "Айбикә", "Гөргери кияүләре", "Авыл эте Акбай", "Айбулат"* һ.б. исем, атамалар чын мәгънәсендә сәнгати чара икәнлеге, аларның тәэсир көчен өйрәнергә кирәклеге бәхәссездер. Публицистик әсәрләрнең баш исемнәренә дә диккать итик: *"Камил Шакиров", "Чынгыз Айтматов турында бер-ике сүз","Керәшен кызы Зоя","Сагынырбыз әле Ельцинны","Берегись, Николай Пантелеевич!","Иркә-Иркуша", "Хәдичә апа һәм аның балалары","Мунчали", "Төмән – Тубыл арасы", "Тәрбияче Флера"* һ.б.

Бу төр лексик чараларның әһәмияте, аларны дөрес язу-әйтүнең актуальлеге турында Туфанның махсус язмалары да *бар ("Исемнәр һәм кушаматлар", "Гали, Вәли, Флинт, Кокер һәм башкалар"* һ.б.).

Туфанның исем, кушамат, атамаларның этимологиясе белән кызыксынуы, өйрәнеп, нәтиҗәләр ясарга омтылуы да игътибарга лаек: "Ул үзе (Ирфат Халиков) Чүпрәле районының Мунчали авылыннан икән. Колакка сәер яңгыраган Мунчали исеме бик гади аңлатыла икән – Мунчалы өй. Димәк, әлеге урынга беренче килеп утыручылар хәлле кешеләр булганнар: өйләре янына шәп итеп мунча да салып куйганнар" (т. 9, 326 б.). Икенче язмасында ул бер фамилиянең үзгәреш юлын күзәтә. Гатаулладан Котовка кадәр килеп җиткән фамилия тарихы (Гатауллин, Гатов, Котов) (т. 7, 184 б.) һ.б.

Публицистикада төгәллеккә ирешү чараларыннан янә иң кулае, әһәмиятлесе – ул **термин** берәмлекләр. Туфан аларга игътибарлы, кадерен белә. Тел берәмлеге буларак алар турында уйлана, камилләштерү-шомарту чараларын күрә, укучы аңламас, дип шикләнсә, аларны төшендереп бирү җаен эзли, үзенчә ачышлар да ясый. Менә кайберләре генә: "Соңгы вакытта безнең телебезгә ике яңа термин килеп керде: үзгәртеп кору һәм тизләнеш (ускорение)".

Аеруча үзе компетентлы, яхшы белгән темаларга терминны төпле аңлатырга махсус алына. *Типик* төшенчәсен аңлаткан язмасы, мәсәлән, әдәби терминнар сүзлегенә ярарлык.

Без бүген дә бәхәсләшкән кайбер терминнарны Туфан үзенә әллә кайчан ачыклаган. Әйтик, бүгенге сөйләмдә *шылтырату* термины шалтырату, чылтырату, челтерәтү вариантларында бик төрлечә кулланыла. Туфанда ул *шылтырату:* "Туктале, – ди инженер, – Әгзам абыйга *шылтыратыйм* әле. ...Тотынды бу *шылтыратырга*"

(т. 7, 106). Инженер да, Туфан да шулай ди. Терминологиядә төрлелек булырга да тиеш түгел.

Туфан яңа сүзләргә **(неологизмнар)** дә бик сизгер, ул аларны ясау сәләтенә дә ия**,** кайберләренең авторы да. Ул иҗат иткән неофразеологизмнар (безнеңчә әйтсәк, неотелбизәкләр) – аеруча кадерле җимешләр. Мисалларга үзегез дә бәя бирегез.

Җилкуар (т. 7, 61 б.); *келтерифүнкә:* ...Ире ялгыш сүз әйтсә, чәчрәп судка йөгергән *келтрифүнкәләргә* Рабига апа турында сөйләргә кирәк (т. 7, 130 б.); *туфанюга* (монысы атаклы режиссер, Туфанның иҗатташы, дусты Марсель Сәлимҗанов сүзе. Кем белә, бәлки, Туфан үзе ясагандыр); *кылмуен:* ...кызлары да үз авылының егетләренә борын җыерып карап, берәр *кылмуенга* ияреп китәләр (т. 7, 272 б.). Яшьләр безгә караганда *мәдәниятлерәк* (т. 7, 350 б.). Каян алган? *Культура*дан качу хикмәтеме? "*Градуслы макташу*" (т. 7, 353 б.). Үзе ясаганмы, берәрсеннән алганмы? *Сәяси әтәчлек* (т. 7, 354 б.); Шулай булгач, төшерелгән түрә *әбрәкәй сандугачы* белән бер, аның тирәсендә чуалсаң, нәҗескә буялуыңны көт тә тор (т. 9, 34 б.); *Күсәк сәясәтенең* бүген бары тик һәлакәткә генә алып барачагын әллә аңлый алмыйлар... (т. 9, 136 б.); Әгәр *Илбашы* үзен ышанычлы итеп сизә икән, димәк, өметебезне өзәргә ярамаганлыгын аңладык (т. 9, 314 б.); Җыелышны хәзер *җыен* дип атый башлаганнар икән (т. 9, 428 б.); Ни белән бетәр икән бу *галәмәтство*? (Хатыннарның ирләрдән активрак булуы.) (т. 9, 429 б.) һ.б.

Туфанның тел тоемлау сәләте, табигате фәкать ана теленә нигезләнә, ул шуның белән сугарылып бөреләнгән, чәчәк аткан, җимеш биргән. Иң төгәл мәгънәле берәмлекләрне иң әүвәл ул ана телебез хәзинәсеннән эзләп таба, неологизмнарны да шуның грамматик байлыгына таянып ясый-иҗат итә.

Иң әүвәле ул хәтерендә сакланган, ягъни ана теле арсеналында булып, сүзлекләрдә теркәлгән, ул бала чакта авылда еш кулланылып та хәзер **пассивлашкан** сүзләргә игътибарлы, **тарихи, архаик** берәмлекләрне хәтерендә саклый, кирәк чагында зиһененнән эзләп таба, нәкъ урынында куллана, кирәк санаса, аңлатып бирү хәстәрен күрә, шул сүзләрне кулланып, өстәмә мәгънә һәм хис төсмерләрен бирүгә ирешә. Хәзер Туфан әсәрләреннән шундый берәмлекләргә мисаллар.

*Аздыру***:** Без бүгенге көндә бер бала табабыз да, аны җиде яшенә хәтле иркәләп, бозып, *аздырып*, мәктәпкә илтеп ыргытабыз (т. 7, 99 б.); *бөтәю:* Колхозыбыз оешканга ничә ел, һаман *бөтәя* алганыбыз юк (т. 7, 158 б.); *өнәп бетермәү* (т. 7, 222 б.); *тырмашу*: *...тырмашканыңны* бе-

леп яшәргә кирәк (т. 7, 164 б.); *үртәү:* Ләкин ничаклы гына *үртәмәсеннәр*, "безнең авылда" дигән сүзне ташламаячакмын (т. 7, 52 б.); *үшәнләнү*: ...акыл *үшәнләнә*, уйламый башлый (т. 7, 55 б.); *һәйбәт*: Син *һәйбәтләп* кенә буби алтыдан йөрисең (т. 7, 144 б.); *бүлтәю:* корсаклар *бүлтәйгәнче* ашадык (т. 7, 177 б.); *мыштырдау*: *Мыштырдарга* вакытыбыз юк (т. 7, 238 б.); *каныгу:* без аларга шул чаклы *каныгабыз?* (т. 7, 238 б.); *үрсәләнү*: Җан *үрсәләнә* (т. 7, 244 б.); *киндерә бау* (т. 7, 343 б.); *катмарлы*: Әни яшәгән ара илебезнең шактый ук *катмарлы* чорына, тормышыбызның бик киеренке чагына туры килгән заман (т. 7, 17 б.).

Бәлки бу сүзләр бүгенге сөйләмдә пассивлашмагандыр да, мин генә сирәк кулланам, бөтенләй кулланмыймдыр. Шулай да мин исемлекне дәвам иттерәм. Чөнки әдәбиятне, матбугатны даими укып бару, яшьләр сөйләмен даими күзәтү нәтиҗәсендә шундый исемлек төзүнең зыянга булмасын чамалыйм. Ә бәлки башкалар да аларны пассивлашкан дип уйлый, ә яшьләр арасында бөтенләй ишетмәгән-күрмәгәннәр дә юк дип кем кистереп әйтер?!

Әдәби сөйләмдә сирәк очрый торган берәмлекләр – **диалектизм, гади сөйләм элементларының** да Туфан сөйләмендә ешрак кулланылуы аның лексикон хәзинәсенең мул булуына ишарә. Ул аларны да махсус эзләп таба, нәкъ мәгънә, хис төсмере бирү ихтыяҗыннан файдалана, нәкъ урынында куллана, сөйләмдә активлаштыра. Менә гади сөйләм элементлары (чаралары).

Анасын саткыры: Картаелудыр инде, *анасын саткыры* (т. 7, 124 б.); *хәерсез:* "Йокыны бигрәкләр дә яратасың, үзең генә калгач, ачка үләрсең инде, *хәерсез",* – дип ачулана иде мине (т. 7, 18 б.); *оятсыз:* Иртән йокыдан уятканда: "Тор, *оятсыз*, өстеңә кояш төшкән бит. Кешедән оялмасаң, кояштан оял", – дип уята иде (әнисе) (т. 7, 18 б.); *караңгы кабу*: Әни тавышына уянып киткәндә, *караңгы капкан* иде инде (т. 7, 19 б.); *маташтыру:* Бүтән мәсьәләләрдә тормыш дөреслеге дип тормыйбыз – алдашабыз ич, нигә бу мәсьәләдә *маташтырырга* (т. 7, 41 б.). *Мәтәштерү* варианты да очрый (ул сингармонизм законына тугрылык билгесе: Йә ачыктан-ачык, *мәтәштермичә* әйт (т. 7, 354 б.). Хәер, Туфанның законны хәтерләмәве дә бар, ә үтәве әйтмә сөйләм остасы булуыннан, ничек уйлый – шулай язуыннандыр; *ни шайтаныма:* Аңарга синең тамашачыларың *ни шайтаныма* (т. 7. 47 б.); *сызу:* Берәр сәбәп табып, *сызарга* гына кирәк яныннан (т. 7, 149 б.); *тыкырдату:* Әни *тыкырдатып* торганга гына иске өй урынына яңа өй салырга ризалашты ул (этисе) (т. 7, 8 б.); *шаярткалаган бу-*

лу: ...төзеп бетергәч, сатасыңдыр инде, дип *шаярткалаган булалар* (т. 7, 54 б.); *чамадан чыгу:* битәрләргә ярата иде, тик беркайчан да *чамадан чыкмады* (т. 7, 22 б.); *чыкылдап тору:* Әни үзе *чыкылдап торган* җир кешесе булса да (т. 7, 11 б.).

Туфанның гади сөйләм элементларын аерым-аерым гына кулланып, тәэсир эффекты казануына өстәп, аның әнә шул элементлардан тезмә ясавы, аеруча көчерелмә мәгънәле берәмлек – телбизәкләр ясавы аеруча хуплауга лаектыр: "Хәзер шушы йодрык белән мурдаңа бер *сыласам, дөмегәсең* бит, хайван" (т. 9, 260 б.); *ышкыланмаган авыл малае* (т. 9, 377 б.); *бала табу йорты* (т. 9, 418 б.). Безнең кебек "Бала тудыру йорты" дими. Персонажы да, үзе дә дөрес – халык ничек әйтсә, шулай әйтә; "Аракы таптырып шуның белән *кәефне сипләп куялар*" (т. 9, 421 б.) һ.б.

Туфанның гади сүзләрдәге тискәре мәгънә төсмерләренә карашы турында инде белдергән идек, ул һәр очракта тәмле теллелек, саф әдәби телдә аралашу ягында. Моны ул әдәби әсәрләренең персонажлары сөйләме аша да белдерергә омтыла:

"Фәрхия. ...Билетын да алдан алып куйган иде кияү, карчык кешегә дип сорамагандыр инде. Сораган булса, үзем кебек кешеләр янына биргән булырые. Ярар, түзәрмен әле. Тәмсез телле кешеләрне яратмыйм шул, тәмсез телне яратмыйм. Кырык биш ел гомер итеп, сүгенгәнен ишеткәнем булмады Габдуллаҗанның. Малайларым да биргәненә шөкер" (т. 1, 278 б.).

Туфан **диалектизмнарны** да урынлы куллана: *кычыткан капчык:* Кызның җавабы әзер: нәрсә, ул мужиклар шикелле *кычыткан капчык* күтәреп йөрсенмени (т. 7, 123 б.); *мулата* (юшкын, ләмне безнең авылда шулай диләр) (т. 7, 10 б.); *яңгаллау:* Карт башың белән *яңгаллап* утырма, күрше (т. 7, 68 б.).

Диалектизмнар аның персонажлары сөйләмен дә җанлы, тәэсирле итә:

"Гарифулла. Кояш *корык* буе күтәрелгән" (т. 1, 32 б.).

"Әлмәндәр. *Гумер*" (т. 2, 12 б.).

Туфан ана телебезгә тугры калып, саф татарча гына, татар сүзләре белән генә язарга омтыла да бит, тик, нишләмәк кирәк, татар – аралашып яшәргә һәвәс халык, дөньяның кайсы гына почмагында, кемнәр белән генә аралашып көн итми ул. Аеруча гарәп, урыс телләре белән бәйләнеше аның телен нык "баеткан", чуарлаган. **Алынмалар** дигән берәмлекләр – татар язучысының төп чаралары арасында инкарь ителми торган берәмлекләр. Туфан иҗатын да алар-

дан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Тел тоемлау категориясен анализлаганда да алар мөһим урын тәшкил итә.

Алынма дип без телдә береккән чит тел берәмлекләрен (инглиз, урыс, гарәп, фарсы берәмлекләрен, сүзлекләрдә китап сүзләре дип тамгаланган сүзләрне дә) атыйбыз. Туфан әсәрләрендә кулланылганнарын төп ике төркемгә бүләргә мөмкин: элекке һәм хәзерге алынмалар. Аларны кистереп чикләү мөмкин дә түгелдер, хәер, моның фәнни ихтыяҗы да юктыр. Аерым язучының бу өлкәдә иҗатын күзәтү өчен генә әһәмияте бардыр. Менә Туфан әсәрләрендәге татар телендә элек-электән кулланылып киленгән алынмалар сүзлеге: *бур:* ...як-ягыңа каранып, әйбер урлаган *бур* шикелле (т. 7, 165 б.); *вәт, маладис:* Кызганычка каршы, карап торып сокланучы, *вәт, маладис*, дип әйтүче юк (т. 7, 154 б.); *гүләнке:* Башлана *гүләнке*! (т. 7, 210 б.); *чүтеки:* Кәефләр начар түгел, *чүтеки* (т. 7, 118 б.); *какжы: Какжы*, безнең дә бит ирен өстендәге бала йоннары әз-мәз карала башлаган (т. 7, 153 б.); *канса да кансов:* Мин барыбер аңламадым. Шулай кирәктер, дип күңелем белән тойдым, акылым белән аңламадым. Түзүнең дә бер чиге булырга тиеш, *канса да кансов* дип; *чуртым:* Алайса сез дөньяның матурлыгын *чуртым* да күрмәгәнсез (т. 7, 153 б.); *нишуткы:* Үндүрт яшь безгә! *Нишуткы* (т. 7, 153 б.); *мужик, мыжик:* безнең ише *мыжиклар* аңлап җиткермәслек җөмләләр белән сөйлиләрдер (т. 7, 164 б.); *козырь: Козырь* туз (т. 7, 143 б.); *кәнишне* (т. 7, 356 б.); *кәрҗин* (т. 7, 357 б.) һ.б.

Бүгенге алынмалар дип бүлү, әлбәттә, бик шартлы бүленеш, аларның кайберләре элек-электән телдә яшәп килгән, арада бар Туфан гына, яңа гына тәкъдим иткәннәре дә. Бу төр алынмалар мисал өчен генә тәкъдим ителә; тулысынча барлап, анализ ясау эле – киләчәк эше. Тагын бер искәртү: алынмалар арасында автор сөйләмендәгеләр дә, персонаж сөйләмендәгеләр дә теркәлде. Соңгыларына искәрмә ясалды.

Хәзерге алынмаларга карата Туфанның үз фикерләре кызыклы. Диккать итик әле: *гонорар:* Кая ул баш чабу, әле начар язган өчен акча *(гонорар)* да түлиләр (т. 7, 145 б.); *дурак*: *Дурак* уйлый белми (т. 7, 69 б.); *ералаш:* Монда да *ералаш*. Кайберләре рус язучысы, кайберләре совет язучысы... (т. 7, 39 б.); *заслуга:* Бу очракта бәлки авторның *заслугасы* әлләни юктыр (т. 7, 42 б.); *конъюктура:* Интегеп язган *конъюктураң* белән алдап маташма мине. Төкерим мин синең коры осталыгыңа (т. 7, 47 б.); *копировать:* гадәттә профессиональ артистны кабатлау *(копировать)* хисабына остарып табигыйлеген югалта (т. 7, 46 б.); *карьера* турында аз гына да уйламый (т. 7, 223 б.);

кәтигәрически: Безгә, драматургларга да, пьеса язарга утырганда моны истән чыгару *кәтигәрически* тыелырга тиеш (т. 7, 172 б.). Бу алынманың шулай язылуы бәхәс тудыра. Гадәттә алай язу ирония төсмере бирү максатында эшләнә (Туфан әсәрләреннән дә моңа мисаллар китерергә була), тик бу очракта текстта ирония, төрттерү төсмере юк, бар да җитди; *копия:* ...бөтен кешелек җәмгыяте фәкать аның *копиясе* (т. 7, 52 б.); *крупным планом, молодец:* Оператор *молодец* – кызларның берсен безгә якынайтып *(крупным планом)* күрсәтте (т. 7, 46 б.); *набат* (т. 7, 242 б.); *наив:* ...әсәр, алай булмагыз, дигән *наив* сүз әйтүгә кайтып калган (т. 7, 49 б.); *нәчәльство* (т. 7, 310 б.); *начальство; общественный:* Шунда аның үзенең *общественный* йөзе барлыкка килә (т. 7, 52 б.); *персональ: Персональ* эш (т. 7, 244 б.); *позвольте: Позвольте*, әфәнделәр, Г. Коләхмәтовның иҗаты бездә һәрвакыт зур хөрмәт белән өйрәнелеп килде... (т. 7, 70 б.); *права:* Ярый, кызлар икән кызлар, *кем әйтмешли*, барыбыз да бер *правада* (т. 7, 101 б.). Алынманың урынсыз икәнен сизгән очракта Туфан аны акларга тырышып, өстәмә бирә – аклана, янәсе *(кем әйтмешли* һ.б.); *профессия:* Әйе, соңгы елларда укытучы *профессиясе* үзенең бөеклеген, газизлеген бераз югалтты шикелле (т. 7, 98 б.); *примитив*: ...бу мәсьлә бик *примитив* тикшерелә (т. 7, 208 б.); *расценка:* Яки *расценкалар* идеаль шартлардан чыгып ясалган (т. 7, 58 б.). Уйланыр өчен бер өстәмә: алынма сөйләм агышына тискәре тәэсир итә, саф татарчалыкка хилафлык килә. Менә бу мисалда *чыгып* калькасы килеп кергән, бу да алынма кәсәфәте. *Резина* итекләр (т. 7, 254 б.). *Резин* варианты да очрый; *рецепт* (т. 7, 233 б.); *спец* (т. 7, 286 б.); *тормоз* (язманың баш исеме) (т. 7, 344 б.); *фанатик* (т. 7, 275 б.); *хамство:* Мин *хамство* турында еш уйланам (т. 7, 142 б.); *шантрапа* (т. 7, 314 б.); *чепуха:* ...дөнья малы бик *чепух*а бер нәрсәгә әйләнеп кала... (т. 7, 217 б.); *чертов круг:* Нәтиҗәдә, үзе дә башкаларны шулай өйрәтә башлый – *"чертов круг"* барлыкка килә (т. 7, 104 б.). Бу очракта куштырнак нинди максаттан куела икән? Җитдилек, рәсмилек, терминга тартымлык билгеседер? *Чурт вәзми* (т. 7, 262 б.); *чурту матыр* (т. 7, 262 б.); *Спискәдән* сызып ташларлар әле (т. 7, 351 б.); *процедура* (т. 7, 362 б.); *ярлык* (т. 7, 364 б.); *компанийски:* Заманында радиокомитетта бер *компанийски* егет эшли иде (т. 9, 32 б.); *кәприз:* Бераз гына *кәприз...* (т. 9, 120 б.) һ.б.

Туфан башка алынмаларга, аерым алганда гарәп-фарсы алынмаларына да игътибарлы булды. Аларга караш үзгәргәннән соң да, ул

бер яктан икенче якка ташланмады. Сөйләменә нәкъ яраклы алынмаларны кабул итте. Мәсәлән, *тәрәккыять*не (т. 9, 427 б.).

Күрәсез ки, алынмаларны ничек язу мәсьәләсе Туфанда да хәл ителеп бетелмәгән. Драма әсәрләрендә ул, башлыча, ничек әйтелә (сингармонизм, басым законнарына буйсындырылып), шулай яза. Ә публицистик әсәрләрдә – ике төрле. Монда басма редактор, корректорларының “кысылышы” юк түгелдер. Һәрхәлдә теләсә кайсы алынма әйтелүе белән дә, язылуы белән да татар теленә, татар сөйләменә тулысынча яраклаштырылырга тиеш. Туфан, тулаем алганда, шул яклы. Тик ул монда да ана телебез мөмкинлекләрен тулысынча файдаланып бетерә алмады. Мәсәлән, *джунгли*не ул алай язмаска тиеш иде (урысчадан алмыйча, кайсы телдән кергән (һинд), шул телдә әйтелгәнчә алырга тиеш иде). Нигәдер уйлап бетермәгән, әллә янә редактор кысылды микән (т. 9, 431 б.).

Монда орфография һәм орфоэпия кагыйдәләре, аларны үтәү, әйтү белән язу арасындагы аерма мәсьәләсе дә килеп чыга бит әле. Татарның искереп беткән орфография кагыйдәләрен яңарту турында Туфан да уйланмый калмагандыр. Ул бит драма әсәрләре язган кеше, анда әйтер өчен язу – мәҗбүри шарт, ул инде “ничек язсам да ярый, артист дөрес әйтер әле”, дип битараф кала алмый.

Алынмаларга карата фикерен Туфан персонажлары аркылы да белдерә.

“Гөлнара. Авыз ачып бер сүз әйттегез, анысы да *грубо.*

Рәшит (төзәтеп). *Дорфа.*

Гөлнара. Ярый, *дорфа”* (т. 1, 280 б.).

Хәзер килеп Туфан иҗатында алынма **гыйбарә (цитатлар)** турында берничә сүз**.** Алар гадәттә әсәргә җәлеп ителгән шәхесләрнең авторы сөйләменнән яисә персонаж сөйләменнән аерым фикергә яисә гыйбарәгә (сүзгә) диккать иттерү максатыннан үзгәртелмичә яисә максатчан үзгәртелеп (мәсәлән, ирония максатында) алына. Менә кайбер мисаллар.

Автомобильная катастрофа, нравственное падение: Автор теләгән нравственное падение урынына гап-гади автомобильная катастрофа килеп чыккан (т. 7, 49 б.); Бәлки бүген Айдан төшкән Ай кешесе дә**:** *“Монда что-то не так”,* – дияр иде (т. 7, 58 б.); Хәзерге кайбер җилкуарлар кебек искитмәгән кыяфәт белән *“подумаешь”* дип кенә котылып булмый бу сораулардан (т. 7, 61 б.); *“Запад есть запад, восток есть восток”*, – дигән Киплинг (т. 7, 79 б.); *“В гробу видел”*, – ди баҗасы. Шуннан Туфан да шуны кабатлый. “Пенсиям

җитәрлек, тынычлап яшәп калыйм әле ди. Ягъни мәсәлән, *“в гробу видел”* (т. 7, 155 б.). Монда алынма гыйбарәне тәрҗемә итмичә, ничек әйтелгән, шулай кабатлау – стиль чарасы. Әмма безнең публицистларның күпчелегендә, хәтта кайбер прозачыларыбыз, шагыйрьләребездә дә урыс чыганакларыннан мисалларны битләп-битләп тәрҗемә итмичә күчерү “чире” бар. Ул шаукым мәрхүм каләмдәшебездә дә булган икән – менә бер язмасында “Жизнь и подвиги святого благоверного Великого князя Александра Невского” дигән китаптан ярты бит урысча текст. Туфан үзе “...колоритны саклар өчен” китаптан күчереп язам, ди. Нинди колорит! Саф татарча текст тәнендә сәер бер “кутыр”! Тәрҗемә итәргә ирену кәсәфәте, шул гына (т. 7, 83 б.).

Туфан иҗатының лексик байлыгын әлегә без аның публицистикасыннан барладык. Ә драма әсәрләренең сүз байлыгын анализлау фәнни яссылыкта моннан шактый үзгә булырга тиеш, чөнки бу лексик хәзинәне, публицистик әсәрләрендәге кебек, Туфанның шәхси үзенеке дип булмый, бу үзгә бер байлык (персонаҗ сөйләмен тулы бирү өчен аңа шәхси үз байлыгы гына җитмичә, ул әле төрле чыганаклардан да файдаланырга тиеш була – бу хакта аерым сүз куертып алу кирәктер).

Шулай да, әле китергән категорияләрнең Туфан иҗатында закончалыклы күренеш икәнен әйтер өчен, драма әсәрләреннән дә мисаллар китерү зарурдыр, дибез. Чөнки публицистик әсәрләрдән аермалы буларак, Туфан драматургиясенең лексикасын ике төркемгә аерырга була: автор лексикасы һәм персонаж лексикасы. Публицистик әсәрләр лексикасын без инде анализладык. Драматургия сөйләмендә автор лексикасы публицистик лексикага тартым, шулай да ул берникадәр үзенчәлекле. Башлыча, әйтмә сөйләм өстенлек итә. Шул ук вакытта хәтта шул төр сөйләмгә дә Туфанның публицистик язма сөйләме барыбер тәэсир итми калмый. Мисалга, алга таба без бу төп сөйләмдә дә язма сөйләм элементларыннан калькаларны китерербез.

Менә персонаж сөйләме үзенчәлекләренә кайбер мисаллар. Монда без әлеге лексик категориянең ни дәрәҗәдә урынлы кулланылуын күрсәтер өчен персонажга берникадәр сурәтнамә дә биреп китәбез.

Неологизм, ясалмалар:

Нуриәхмәт. Авыл кешесе. Урта яшьләрдә. Бригадир: “Җитмештән узган яшендә син шушы *келдерикүштә* яшәргә тиешме?” (т. 1, 14 б.);

Хәйретдин. Өлкән кеше. Авылныкы: “Син монда *пешекче* булып эшлим дисеңмени?” (т. 1, 126 б.).

Гади сөйләм:

Гарифулла. Авыл карты: *“Яңак төбеңә берне утыртырмын, тәгәрәп китәрсең”* (т. 1, 27 б.);

Шәкүр. Җор телле егет: *“Котым ботыма төште”* (т. 1, 86 б.).

Алынма, варваризмнар:

Хәйдәр. Кыланчыграк егет. Белдекле булып кылана: “*Чурт* булганмы аңа, майлаган, җайлаган, син минем белән булганда, аптырама. Абзаң *махы* бирә торганнардан түгел ул” (т. 1, 128 б.) Бәйләнмәгез, *пажалысты*; Каян килгән *культурный* халык (шунда ук); Мин сезгә *малакасус* түгел; *Жалоб*а бирде, диген; *Заводить* итеп бирегез; Чык миңа, *ыслушай*; Кулларыңны уйнатма, *слушай*; (т. 1, 150 б.);

Әминә. Югары белемле. Шәһәр кызы: “*Ой,* нинди акмак мин!” (т. 1, 151 б.);

Касыйм. Авыл агае. Күп сөйләүчән. Нахалрак: “Районнан *нәчәлство* авылга килсә, *списиәлне* минем бәдрәпкә пес итеп китә” (т. 1, 184 б.); *Шәләй-вәләй* түгел; “Бер тапкыр утырып кына торган идем *пыртуар* читенә, милиционер тартып торгызды, *мать якасын”* (т. 1, 185 б.); *И* ясап бирдем; Безнең колхоз *булгахтиры* әйтмешли, *рассинкасы* шулай; *Шалишь... Кәртинкә; Пинсә; Праписыр; Дурак; Кәнишне һ.б.*;

Әлмәндәр. Авыл карты. Туксан яшь. Җор телле, уенчак: “Шулай... *Чурту-матыр*, дөбер-шатыр, үтте китте яшь гумер” (т. 2, 12 б.); *Жибадур* кебек таза; *Чуртым* да сөйләшмәдек; *Хураша знакум; Ассалу-ди, былгаруди*.

Татар тел гыйлемендә лексик состав ике зур төркемгә бүленеп өйрәнелә: конкрет-номинатив берәмлекләр һәм күчерелмә мәгънәле берәмлекләр – троплар (телбизәкләр). Туфан иҗаты һәр ике төркемнән туена. Аларның икесен дә куллану тәҗрибәсе – әдип осталыгының бер дигән үрнәкләре. Хәзер **күчерелмә мәгънәле берәмлекләргә** махсус бүлекчә багышлыйбыз. Башта мисалларны Туфанның публицистик әсәрләреннән, аннары драма әсәрләреннән китерербез. Арада күчерелмә мәгънәле бер генә сүзле троплар бихисап – телбизәкнең беренче буыны сүзбизәкләр. *Оеткы:* Элекке заманның *оеткысында* өлгергән килеш яңа заманда яшәргә, бала үстерергә туры килде аңарга (т. 7, 17 б.); *остару:* Төкерим мин синең коры *осталыгыңа.* (т. 7, 47 б.). Бу иш лексика сүзлеген кыскартабыз, күп урын алыр иде. Сүзтезмә троплар – **фразеологизм телбизәкләр**гә күчик.

Акылдан шашу: ...Туган авылың кешесен очратсаң, *акылдан шашар* иде*ң* (т. 7, 51); *акча яву:* Белмим, ничә тапкыр җибәргәнмендер эниләргә акча, әмма авыл халкының хәтерендә миннән *акча явып кына торган* кебек булып калган (т. 7, 21 б.); *алланың кашка тәкәсе* (т. 7, 321); *Баш белән эшләргә кирәк* (т. 7, 80 б.); *башын күтәрми эшләү:* Үз хуҗалыгында да *башын күтәрми эшли* (т. 7, 209 б.); *йөрәген май баскан* (симерүдән) (т. 7, 228 б.); *каравыл кычкыру:* ...моңыңны оныткан булсаң, *каравыл кычкырып* үләсең, диләр (т. 7, 208 б.); *караңгы кабу* (т. 7, 19 б.); *очы очка ялганмый* (т. 7, 225 б.); *поты бер тиен:* ...әсәрләребездә тизләнеш, үзгәртеп кору дигән терминнарны бит саен кабатлап бер айда романнар, пьесалар язып өлгерсәк, безнең үзгәрешнең *поты бер тиен* (т. 7, 231 б.); *рәхмәт уку:* эчтән генә *рәхмәт укыганнардыр* (т. 7, 21 б.); *сакал саву:* Хәйбрахман бабай биш бармагы белән *сакалын савып* куйды (т. 7, 68 б.); *санга сугу:* Мине *санга сугып*, олылап, эч серләрен ачкан кешеләргә... (т. 7, 187 б.); *сөйкемле сөяк:* ...кешегә мактау сүзләре яудырып, *сөйкемле сөяк* булып күренә белмиләр иде (әнисенең туганнары) (т. 7, 21 б.); *сүз белән уйнау: Тәнкыйть сүзе белән уйнамасыннар* (т. 7, 157 б.); *тукып тору:* ...үзебезгә үзебез *тукып торырга* тиешбез (шунда ук); *түшәмгә төкереп ята*сым килә (т. 7, 324 б.); *үзеңне әллә кемгә санау:* Укучыдан акыллы булып, *үзеңне әллә кемгә санап*, әсәрләреңдә укучыга акыл өйрәтсәң... укучы синнән кача (т. 7, 48 б.); *чәйнәп ташлау:* Ничек әле ул (Батый хан) Александрны *чәйнәп ташламады* (т. 7, 84 б.); *комга су сибү:* Димәк, без язганнар – *комга су сибү* генә? (т. 7, 118 б.); *тел тидерү:* Кайвакыт, кызып китеп, бүгенге заман яшьләренә *тел тидерәбез* (т. 7, 190 б.); *телең корымас:* Яхшылык эшләмәсәләр дә, рәхмәтеңне әйт, аннан *телең корымас* (т. 7, 195 б.); *телеңне тыю: Телеңне тыя* белмәгәнең өчен авызыңа кундырырмын, тешләреңне җыеп бетерә алмассың (т. 7, 157 б.); *тетмәсен тету: Тетсә тетсен инде тетмәмне*, бәлки сүзләрендә хаклык бардыр, искә алырга кирәк булыр киләчәктә, дип уйладым (т. 7, 133 б.); *шайтан вәсвәсәсе:* ...дип елмая *шайтан вәсвәсәсе* (җор телле чибәр хатын) (т. 7, 151 б.); *чыбык очы туган* (т. 7, 155 б.); *калай күз белән карау* (т. 7, 238 б.); *уңны-сулны аера белү (белмәү)* (т. 7, 269 б.); *җил ягына салам кыстыру* (т. 7, 296 б.); *этлек ясап яту* (т. 7, 352 б.); *сүзе сүз булган* (т. 7, 364 б.); *төшеп калганнардан түгел* (т. 7, 364 б.); *еректан килеп* суктыра (т. 7, 367 б.); *арадан кара мәче үтү* (т. 7, 368 б.); *вәгъдә тузаны сибү* (т. 7, 368 б.); *шомартып яшәү:* Алар *шомартып яшәргә* күнеккәннәр (т. 7, 224 б.);

Соңгы ике телбизәк классик берәмлекләр түгел бугай. Аларны Туфан кешедән ишетеп теркәгәнме, әллә урысчадан калькалаштырганмы яисә үзе ясаганмы, тәгаен әйтә алмыйм. Һәрхәлдә андыйлар байтак. Махсус өйрәнү сорала. Тезмә тропларны барлауны дәвам иттерик. Бу урында укучы белән болай килешү сораладыр. Барланган материалны мөмкин кадәр тулырак бирергә тырышачакмын. Киләчәктә аларны өйрәнеп сабак алырга ниятләгән яшьләргә һәр мисал файдалы булыр, дип уйлыйм. Ә бүгенге укучы инде үзе карасын, кирәге юк, дип санаса, күз йөгертеп кенә үтсен.

Менә Туфанның **телбизәкләре (фразеологизмнары)** сүзлегенең дәвамы: *алланың кашка тәкәсе***:** Мин инде Алланың *кашка тәкәсе* булдым, дип, түбәндәгеләрнең артына сөзәргә ашыкма (т. 9, 32 б.); *бөер белән сөйләшү* (т. 9, 33 б.); *кеше аралау*: Мондый гаделсезлек, *кеше аралау* бик күңелне әрнетә (т. 9, 179 б.); *мыегы да селкенми* (т. 9, 248 б.); *җенем сөйми: Җенем сөйми* нәрсә аңлата ул (т. 9, 248 б.); *хәтер саклап тору* (т. 9, 139 б.); *комнан бау ишү* (т. 9, 152 б.); *сүзгә кесәгә керми* (т. 9, 161 б.); *кәҗә калу* (т. 9, 384 б.); *кубызына бию:* Аның *кубызына биергә* теләмәгәннәр; *арага чөй кагу; эзгә керү:* Һаман *эзгә керә алмыйм* (т. 9, 402 б.); *кабер тынлыгы* (т. 9, 428 б.); *Телләрен тешләп түзәләр* (т. 9, 429 б.); *ташка үлчәү:* Пенсиясе дә *ташка үлчим* (т. 9, 433 б.); *җан талашу:* Америкалашмас өчен (французлар) *җан талашып* тырышалар (т. 9, 438 б.).

Үзе ясап, персонажы сөйләмен баетканнары да бар: *Ничек без шул чаклы бүкән булдык икән* (т. 9, 233 б.); *чалмалар чалып* (т. 9, 254 б.); *сүзне өзү: Сүзебезне өзеп* әйтә киләбез (т. 9, 101 б.). (Сүзне өзү, ягъни әңгәмәне, гәпне өзү мәгънәсендәгесе дә бар.**)** *Кешегә сан калмаячак* (шунда ук); *Баш ташлап эчәләр* (т. 9, 111 б.**)**; *башны җүләргә салу: Башны җүләргә салып* типтерәсе килә (т. 9, 112 б.); *дөнья тоткасы булу: Дөнья тоткасы булырлык* яшьләр (т. 9, 111 б.); *юкә бау белән бәйләү: Юкә бау белән бәйләп* тотылган СССР (т. 9, 136 б.); *үзем дә кәнфит түгел* (шунда ук).

Туфанның иҗат мирасының телбизәкләргә ифрат бай булуы аның драматурлыгыннан да килә. Әсәрдә һәр персонаж үзгә бер сөйләм иясе бит: бар авыл кешесе, бар шәһәрнеке, бар ачык йөзле, җор теллесе, бар йомыкые, телгә сараны, бар яше, бар карты, бар белемлесе, бар наданы. Һәркайсы сөйләм мотивларына бәйле рәвештә телбизәкне үзенчә куллана. Туфан, тәҗрибәле драматург буларак, бу үзенчәлекне яхшы тоемлый һәм бик тә урынлы куллана. Моңа аның тел байлыгы да, артистлык сәләте, татар сәхнәсенең тарихын,

үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен белүе дә зур плюс. Персонажлары сөйләмендә телбизәк куллану мисалларын китерәбез. Бу очракта телбизәк дигәндә фразеологизмнарны, әйтем, мәкальләрне дә күз алдында тоттык.

Гарифулла. Авыл карты: “Син тик тор, *татарга тылмач кирәкми”* (1,14); “Сыер дуласа, аттан яман” (т. 1, 32 б.); “ Син әйбәт, *Алланың кашка тәкәсе* “; *“Җил ягына салам кыстырма”; “Укаң коелмас”; “Туры әйткән туганына ярамаган”* (т. 1, 32 б.);

Галим. Холкындагы фәннилек шаукымы сөйләменә дә тәэсир итә – мәкальләр җыю белән шөгыльләнә: “Гаилә кору турында халыкның аерым мәкальләре бар. *Җиде кат үлчә, бер кат кис* һәм башкалар”(т. 1, 71 б.). *Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый; Ни чәчсәң, шуны урырсың; Авыру җылатыр, гыйшык саргайтыр; Гыйшыксыз-кыйшыксыз кеше булмый; Гыйшык хәлләре яман, йөрәгемне ут алган; Мәхәббәт мәхәббәт белән яши* (т. 1, 70 б.); *Ат азгыны тайга иярер* (т. 1, 106 б.);

Хәниф. Авылдан киткән, шәһәрдә яши: “*Биргәннең битенә бакмыйлар”* (т. 1, 41 б.).

Фәния. Актив кыз: “*Күңел иркен булса, урын табыла”; “Бер рәхмәт мең бәладән коткара”* (т. 1, 110 б.);

Әлмәндәр: *Җырның җыртыгы юк* (т. 2, 18 б.); *Эшләгән кеше янында торганчы пес иткән кеше янында тор; Укаң коелмас; Гомеремне өзәргә килгәнсең; Арттан кергән акыл җил белән кире чыга* (т. 2, 21 б.); *Мыегы да селкенми; Кәҗә маеңны чыгарамы? Чиләгенә күрә капкачы табыла* (т. 2, 25 б.); *Ир мактаныр, корал эшләр* (т. 2, 26 б.); *Акылың алтын икән; Ашап туймаганны ялап туймассың* (т. 2, 41 б.); *Әйтмәк бар, көчләмәк юк* (т. 2, 42 б.); *Комнан бау ишәр идем* (т. 2, 45 б.).

Диккать итәрлек бер деталь: телбизәк уйлап чыгару сәләтен автор үзенең персонажына да “бирә” кебек. Әйтик, бу контексга Әлмәндәр сөйләмендәге *“Әйтмәк бар, көчләмәк юк”* әйтемен Әлмәндәр үзе уйлап чыгарган дигәнрәк тойгы туа. Драматург осталыгы хикмәте инде бу!

Телбизәкләр арасыннан **әйтемнәрне** аерып күрсәтергә була: *Шундый шундый эшләр, бара-тора нишләр* (т. 7, 87 б.); *Ите сиңа, сөяге миңа* (т. 7, 99 б.); *Эт баш – сыер аяк* (т. 7, 224 б.); *Каплаган да куйган* (т. 7, 343 б.); *Коты ботына төшкән* (т. 7, 247 б.; т. 9, 293 б.); *Иске авыздан яңа сүз* (т. 7, 249 б.); *Талкыга салып талкыдым да,*

килегә салып төйдем (т. 7, 307 б.); *Әкият сөйләмә* (т. 7, 250 б.); *Киленгә дә катыкмы* (т. 9, 185 б.); *Әбиеңә сәлам әйт* (т. 9, 377 б.).

Хәзер килеп Туфанның публицистик әсәрләреннән тупланган **мәкальләр** сүзлеге. Биредә аның мәкальнең асылына, эчтәлегенә карата фикерләре, контекстка ярашлы рәвештә аларны үзгәртү мөмкинлекләре дә ачыклана.

Акчаны ашап булмый (т. 7, 76 б.); *Кеше кайгысы кешегә иртә керә, кич чыга* (т. 7, 189 б.); *Син дә мулла, мин дә мулла – атка печән кем сала?* (т. 7, 110 б.); *Сулар үргә таба акмый* (т. 7, 23); *Тавык төшенә тары керә* (т. 7, 32 б.); *Юаштан юан чыга* (т. 7, 8 б.); *Язмыштан узмыш юк* (т. 7, 37 б.); *Үлгәннәрнең кадерен белгәннәр генә исәннәрне хөрмәтли* (т. 7, 40 б.); *Көлмә кешедән – авызың өшегән. Авызым өшегән булса да, көләм синең ишедән* (т. 7, 53 б.); *Үземне сөймиләр, бугымны ашыйлар* (тычкан әйтмешли) (т. 7, 89 б.); *Тозсызны күзсез дә аера* (т. 7, 237 б.); *Ярты җүләр атын мактар, тулы җүләр хатынын мактар* (т. 7, 283 б.); *Иелгән башны кылыч кисми* (т. 7, 311 б.); *Дәрт бар, дәрман юк* (т. 9, 400 б.); *Ирне чук иткән дә хатын, чүп иткән дә хатын,* дип әллә кайчан ук әйтеп калдырганнар (т. 9, 36 б.); *Иске коега төкермә, кайтып суын эчәрсең*, дигән мәкальне онытканмын (т. 9, 33 б.); *Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын* (т. 9, 43 б.); *Чир китә, гадәт китми* (т. 9, 45 б.); *Үзең алданмыйча бүтәннәрне алдап булмый* (т. 9, 46 б.); *Акча санаганны ярата* (т. 9, 46 б.); *Иртә кичтән хәерлерәк* (т. 9, 54 б.); *Алма агачыннан ерак төшми* (т. 9, 120 б.); *Татар тешләп карамыйча ышанмый* (т. 9, 152 б.). *Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска,* дип әйтә бит татар агае, әмма бу бик бәхәсле. Беренчедән, кыска чәчле мужиклар арасында аңгыраларның исәбе-хисабы юк; икенчедән, кем белә, бәлки, кыска акыл озын акылдан әйбәтрәктердер дә әле (т. 9, 167 б.); *Татарның акылы төштән соң* (т. 9, 289 б.); *Карга каркылдап яз ясый алмаган кебек, бүре улаганга гына кыш та килми* (т. 9, 382 б.); *Ике татар булган җирдә өч партия була* (т. 9, 415 б.); *Эт өрә тора, бүре йөри тора* (т. 9, 425 б.); *Санасаң санамасаң да, сәгать теле уникe* (т. 9, 432 б.); *Бөкрене кабер генә төзәтә* (т. 9, 432 б.); *Ходай сакланганны саклый* (т. 9, 437 б.) һ.б.

Туфан – күренә ки, халык авыз иҗатын, беренче чиратта, күчерелмә мәгънәле сүз һәм гыйбарәләрне, ягъни телбизәкләрне нечкә белеп, аны иҗади максатта бик тә оста файдаланучы иҗатчы. Алай гына түгел икән шул, ул әле үзе дә телбизәкләрне уйлап чыгарырга, аларны ясарга сәләтле талант иясе дә. Шәхси телбизәк **афо-**

ризм дип атала. Аерым бер затның гомумиләштерелгән акыллы фикер гыйбарәсе мәгънәсендә. Афоризмны теләсә кем “таба” (“тудыру” мәгънәсендә) алмый. Ул әдипнең фәлсәфи, сурәтле фикерләү, күп уйлау, тормыш күренешләрен чагыштырып, нечкә күзәтү, чагыштыру, анализлау, бай тәҗрибәле булу сыйфатларына таянып иҗат итү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу хакта уйланыр өчен Туфанның әдәбият укыту турында борчылып язган мәкаләсендә романга торырлык проблеманы публицистик, сәнгати чаралар кулланып язган фикеренең йомгагын тәшкил иткән “күңеле надан, җаны томана кешеләрнең күзәнәк... җан иясе юк” дигән гыйбарәсе – афоризмы өлге була аладыр. Хәзер без Туфанның үзебез туплаган кадәр афоризмнары “сүзлеген”н тәкъдим итәбез. Аларның барысын да укып чыгу, уйлану, анализлау, кирәк кадәрен хәтер дәфтәреңә күчереп алу – сезнең эш. Һәрхәлдә әдипнең ана телебез хәзинәсенә кереп калырлык бу иҗат җимеше күңелләрдә сакланырга тиеш, безне рухи баетырга тиеш. Мондый хәзинәи ядкәрдән файдаланмау мәнсезлек, милләткә хилафлык булыр иде. Әгәр Туфан афоризмын укыгач, ул әйткән фикернең синдә дә барлыгын, аның Туфанныкы белән тәңгәл килүен сизү, шуның өчен эчке бер горурлык кичерү – уңай фалдыр бит. Менә Туфан *афоризмнары.*

Ашыйсың килсә, өйрәнәсең ул, әллә кемчә сөйләргә өйрәнәсең. Өйрәнмәсәң, сиңа ашарга гына бирмиләр, вәссәлам (т. 7, 161 б.);

Татарда йортка кергән ирне ир кешегә санамыйлар (т. 9, 435 б.);

Баш белән эшләргә кирәк (т. 7, 80 б.);

Безнең кул белән тел акылдан алда йөри (т. 7, 10 б.);

Вак уйлардан арый кеше (т. 7, 195 б.);

Горур кешене беркем бернишләтә алмый (т. 7, 312 б.);

Дурак уйлый белми (т. 7, 69 б.);

Дусыңны тыңлый белү зур осталык бит ул (т. 7, 338 б.);

Олыраклары ахмак булгач, кечкенәләр нишләмәс (әтисе сүзе) (т. 7, 10 б.);

Сагына белмәгән кеше – җансыз кеше (т. 7, 51 б.);

Син карак булсаң да, кесә карагы булма, карак булсаң да, зурргы бул – банк бас (әтисе сүзе) (т. 7, 16 б.);

Әниләр киң күңелле шул алар (т. 7, 17 б.);

Җимерүгә караганда, төзү яхшырак бит инде (т. 7, 55 б.);

Ил алдында хур булма, кеше көлдермә, яманатың дөньяга чыкмасын (әнисе сүзе) (т. 7, 21 б.);

Икейөзлеләнүне күпләр яратмый, әмма яратмасалар да, кайберәүләр еш кына үзләре икейөзләнәләр (т. 7, 21 б.);

Кануннар колы булган кеше яхшылык эшли алмый (т. 7, 309 б.);

Картаясы килми, килми, шайтан алгыры. Картаю бөтен яктан да күңелле эш түгелдер (т. 7, 147 б.);

Картлык ул вакыйга турында тәфсилләп сөйләргә ярата. Яшьлек шуның өчен картлыкка мыек астыннан көлебрәк карый (т. 7, 147 б.);

Кеше акыл сатканны яратмый. Ә киңәшне тыңларга әзер, җавапны бергәләп эзләргә әзер (т. 7, 48 б.);

Кеше кешеләр өчен яши. Югыйсә кешеләр җәмгыять булып яши алмаслар иде (т. 7, 122 б.);

Кешене гаепләү җиңел, аңлавы читен (т. 7, 233 б.);

Кешене кеше иткән нәрсә – аның бүтәннәр арасында яши алырлык акылы булуында (т. 7, 122 б.);

Кешеләр арасында кешеләрне кайгыртып яшәү – кешенең рухи ихтыяҗы (т. 7, 122 б.);

Милләтне укыган кешеләр милләт итә (т. 7, 80 б.);

Моңның кадерен моңланганнар гына белә (т. 7, 339 б.);

Үзеңнең өеңнең чебене дә ят җирнең күбәләгеннән матурдыр (т. 7, 161 б.);

Үткәнсез бүгенге һәм киләчәк була алмый (т. 7, 147 б.);

Хатын-кызсыз без бигрәкләр дә булдыксыз икәнбез шул (т. 7, 23 б.);

Муртаеп беткән карамага чуртым буламы (Хәйбрахман бабай);

Шаярмаска иде тел белән, шаярмаска иде (т. 7, 88 б.);

Ишетү, күрү сәләте табигать тарафыннан бирелгән кебек, сүзне тою сәләте дә, минемчә, кешеләргә тумыштан ук бирелә (т. 7, 31 б.);

Яшьлек һәрвакыт ашыга (т. 7,124 б.);

Елаган саен яра күбрәк сызлый (Гариф абый сүзе) (т. 7, 125 б.);

Туры белгәннәр батыр була, туры белгәннәр илен сатмый, туры белгәннәр үз-үзенә хыянәт итми (т. 7, 126 б.);

Яктылык кирәк. Яктылык төнлә дә кирәк кешегә. Караңгыны карак кына ярата (т. 7, 153 б.);

Яхшылыкның кадерен белмәүчеләр яманлык эшләргә һәрваыт әзерләрдер (т. 7, 195 б.);

Җимерү өчен төзегән әйберең булу тиеш. Булмаганны ничек җимерәсең (т. 7, 173 б.);

Дөньяга карт кеше күзе белән карау ярамый (т. 7, 174 б.);

Мактауны ишетү барыбер рәхәт (т. 7, 217 б.);

Җитәкченең көче бүтәннәрне ышандыра алудадыр, үз фикеренең төпле икәнлегенә үзе ышанудадыр (т. 7, 222 б.);

Сүзне еш кулланган саен аның тәэсир итү көче кими (т. 7, 229 б.);

Нәфеснең чиге юк (т. 7, 237 б.);

Кеше кадерле булган җәмгыятьтә шәхес ирекле, аның рухы бай була (т. 7, 238 б.);

Нәчәльство да Алла түгел, ул да кеше, син үзеңне кешеләрчә тотсаң, ул да кешеләрчә сөйләшер (т. 7, 310 б.);

Үзең генә хәсрәтләнеп утырудан да газаплы нәрсә юк (т. 7, 331 б.);

Тәртипсез җәмгыятьтә сүзнең кадере бетә, ул төссезләнә, тупаслана (т. 7, 349 б.);

Җиңел түгел икән телдән, моңнан аерылулары (т. 7, 350 б.);

Язганда кан уйнап торырга тиеш бит ул (т. 7, 351 б.);

Кызганыч ир – иң куркыныч зат, чөнки ул үч ала башлый (т. 9, 15 б.);

Мактанчык ирләрдән дә көлке җан иясе юк (т. 9, 42 б.);

Куян шулпасының шулпасы да үзен итле аш дип саный башлый (т. 9, 42 б.);

Кешеләр һәрвакытта бер сүзне әйткәндә, икенче сүзне күңелләрендә тоталар (т. 9, 43 б.);

Мескеннәрнең генә дошманнары булмый. Син нихәтле намуслы булсаң, дошманнарың шулчаклы күбрәк була (т. 9, 44 б.);

Зимагур беркайчан да бай булмый (т. 9, 46 б.);

Кирәгеннән артык әрсез дә булма. Өстәгеләрнең ашына чебен булып төшсәң, гомерең кыскалыгын шунда ук аңлыйсың (т. 9, 48 б.);

Кол беркайчан да бай булмый һәм данга ирешә алмый. Шулай булгач, аңа югарыга да юл юк (т. 9, 48 б.);

Көнләшү – яшәү стимулыдыр ул. Көнләшә белмәгән кеше утын агачыдыр (т. 9, 56 б.);

Кешенең җанына тоз салу – хөсетлеләрнең бердәнбер яшәү стимулыдыр (т. 9, 58 б.);

Изгеләр изгелекне бурычка эшләмиләр (т. 9, 119 б.);

Акчасы күп кеше акчаның кадерен белми, диләр. Кеше күбәйсә дә, кадере бетәдер (т. 9, 205 б.);

Үзен хөрмәт итә белмәгән бүтәннәргә дә хөрмәт белән карамый (т. 9, 274 б.);

Дус бит ул күпмедер дәрәҗәдә үзеңне корбан итү (шунда ук);

Без бит кыйналганга түзәбез, мактаганга түзә алмыйбыз (шунда ук).

Бәләкәй генә түмгәккә бассак, Каф тавы түбәсен мендек дип уйлап ялгышабыз (т. 9, 274 б.);

Дөньяда әдәп дигән нәрсә бар. Әдәпле кеше кешеләрне кимсетә торган сүз әйтми (т. 9, 312 б.);

Кеше картлыгын каршыларга әзер булырга тиеш (т. 9, 335 б.);

Шәхес булган һәр кеше мөстәкыйль фикерле була (шунда ук);

Берәр эш эшләп ял итәргә кирәк. Эшсез кеше кирәкмәгәнне уйлый торган була (т. 9, 435 б.);

Кешеләрне бары тик кешеләр генә үстерә. Әллә кем булып тусаң да, ялгыз берни кыра алмыйсың (т. 9, 443 б.).

Афоризмга һәвәслек халыкның үзеннән килә. Моны яхшы тойган Туфан аның бу осталыгын сәхнә әсәрләрендә дә чагылдыра алган. Димәк ки, халыкның бу хәзинәсен ул халыктан алып, аңарга кире бирә. Бер генә мисал: Фәрхия. *Мәхәббәт аерым торуны яратмый; Юк, мәхәббәт гел кирәк. Мәхәббәтсез дөнья – сусыз дәрья...* (т. 1, 287 б.).

Туфанның тел хәзинәсен шулай "йөгертеп" кенә барлаудан да соклангыч йомгак ясап була: укучыга, тамашачыга, тыңлаучыга тәэсир итү өчен, әдипнең гаҗәеп мул тел байлыгы булган. Төрледән-төрле чаралар: туры мәгънәлеләре дә, күчерелмә мәгънәлеләре дә. Шуңа күрә дә әдипнең укучы, тамашачының акылына да, хисенә дә нечкә тәэсир итәрлек нинди генә сурәт, тасвир мөмкинлекләре сокландырмый! Язучы өчен бу бит бәяләп бетергесез бәхет! Тасвирлау, сурәтләү аның иң төп һөнәри максаты бит! Туфан – менә шундый бәхеткә ия тасвирлау остасы. Моны кайбер мисаллар белән дәлиллик: *"Таш өстенә утырып Идел өстендә аунаган дулкыннарга карап тора идем..."* (т. 7, 254 б.); *"Атна-ун көн кырынмаган, күрәсең, уч төбе хәтле генә йөзенә куе кара сакал-мыек шытып чыгып, буй җибәргән"* (т. 7, 254 б.); *"...Вак ташларга килеп сөрлеккән дулкыннар"* (т. 7, 255 б.); *"Ул ире әйткән һәр сүзне йотып бара, иренең иреннәренең хәрәкәтен моның иреннәре дә кабатлый"* (т. 7, 330 б.); *"Ай яктысы җаннан шәһәрнең рухи корымын юа"* (т. 7, 335 б.); *"Олы авызлы кыз"* (т. 7, 46 б.).

Публицист Туфанның тасвир чараларына һәвәслеге драматург Туфанда да һич ким түгел: драма әсәрләрендәге сурәтләү чараларын махсус өйрәнергә кирәк булыр. Әлегә бер генә мисал: Әлмәндәр: *Болытлар ышкылып йөреп шулай ялтыратып бетергәннәр аны* (айны); *Басма өстендә Мәкәрҗә чиләге кебек матур кыз утыра, кем икән ул, дип күзләрен кысып-кысып карыйлар* (йолдызлар) (т. 2, 49 б.).

Туфанның **тасвир чараларын** фәнни система белән, кайберләренең фәнчә атамаларына нигезләнеп анализларга була. **Детальдән** башлыйк: "Хәтта безнең беренче өйнең чоланы да иске баржаның *кабыргаларыннан* корыштырылган иде". Мин, мәсәлән, баржаның бер "әгъзасын" кабырга дип уйлап чыгара алмас идем, елгачы булуыма да сылтап, шпонгаут дип термин белән азапланган булыр идем. Ә ул үзенә бер сурәт барлыкка китергән – "кабырга" дигән термин-троп уйлап тапкан.

Образлылыкка ирешү, сурәт ясау өчен ул башта һәр сүзнең төрле мөмкинлекләреннән файдалана. Мәсәлән, бер үк мәгънәле дип уйланылган **синоним** сүзләрнең бик нечкә аерымлыкларын да истә тота, шуннан мәгънә төсмерен аерып, тәэсир итәр өчен файдалана: Мәсәлән, "*Якланмый"*. Шул ук текстта "*кыланмый*" да. Рәсми текстта *эшмәкәрлек, эшмәкәр*, башка кайбер текстларда *эшкуарлык* (т. 9, 427 б.). Шунысы кызык: мәгънә төсмерләренең нечкәлеген эзләү, сүзләрне үзгәртү барышын ул үз-үзенә яисә укучыга хисап бергән кебек өстәмә аңлатып бара. Кечкенә генә бер детальгә бәйләп китеп,

бөтен бер фәнни күзәтү яисә сурәтле парча барлыкка килә. Бу иҗатчы яшьләргә үзенә күрә бер файдалы “дәрес” бит: “Язып *арыдым*. Юк, арымадым, *ялыктым”* (т. 9, 388 б.); “Балтаны кайрар алдыннан сапларга кирәк булыр. *Саплау* дигән сүзнең икенче мәгънәсе дә бар бугай татарда. Инәгә җеп кигезүне саплау дип атыйлар. Әкәмәт бу татар теле. Ние ошамыйдыр шуның Мәскәүгә. Миңа, мәсәлән, бик ошый ул. Урыс теле дә ошый. Япун телен белсәм, ул да ошар иде. Кызык, нигә кешеләр төрле-төрле телләрдә сөйләшәләр икән. Нигә татарча гына сөйләшмиләр икән? Матур да, җиңел дә. Тик менә шәһәрдә яшияши телнең матурлыгын югалтабыз. Депутат теле белән туктаусыз сөйләү дә телне ярлыландыра. Һаман бер сүз, һаман бер сүз, шуны да ишетүче юк. Сөйләмичә дә булмый. Хет ичмасам сүз белән үзебезнең исән икәнне белдереп торырга кирәк. Югыйсә татар үз телен үзе йотты, дип сөенүләре бар. Сөйләвегездән ни мәгънә дип әйтәләр дә ул безгә кайберәүләр, сөйләми дә башласак ни булыр?” (т. 9, 433–434 б.).

Омоним (омофон), пароним (парономас) күренешләре дә публицистик әсәрләрдә дә, драма әсәрләрендә дә буйдан-буйга тәэсир, сурәт чарасы булып үрелеп бара, әдипнең сүз ясау, сүз үзгәртү осталыгына шаһит булып бара. Янә дә **каламбур, сүз уйнату** күренешләренә берничә мисал: Мин *оттырып отам* килеп чыга (т. 7, 76 б.); *Кызыгудан күзләр кызара (ККК)* (т. 7, 272 б.); “Безнең авылда бер әбигә: “Әби, “Им-том” дигән газетка языласыңмы?” – дигәч: “Язылам, бәбкәм, им-том булгач, безгә яраклы гәҗиттер”, – дигән. Сүз “Интим” газетасы турында барганын авыл почтальоны да, әби дә аңламаган” (т. 9, 388 б.).

Сүз белән, сүзне куллану белән бәйле әлеге лингвистик күренешләрне **(сүз уйнату, каламбур, тизәйткеч, табышмаклар** һ.б.**)** персонажлар сөйләмендә дә урынлы кулланып, әдип аларның тәэсир, тасвир көчен арттыра, халыкчанрак итә:

Саҗидә. Ул сугышып тормас синең белән. Бар*, элдерт* моннан.

Шәкүр. Мин элдертергә күнекмәгән. *Элдертә торган кулмәкләрем* күптән тузган (т. 1, 74 б.).

Уйлап куйдым: тел тоемлаган, аны төрлечә кулланудан тәм табучы иҗатчы гына тасвир чараларын халыкныкын да мулдан эзләп таба, үзе дә аларны иҗат итәргә һәвәс буладыр.

Хәзер килеп Туфанның чын сәнгати тасвир чараларыннан – **синтаксик фигураларны** күзәтүгә күчик. Әдип **чагыштыру** остасы. Публицистикасына бигрәк тә ассоциатив чагыштыру хас: “Арсланнарның кыланышын күзәтеп торганнан соң (телевизорда),

бер ачыш сыман нәрсә ясадым: аерып алып корбанны юк итү кешеләр арасында да бар түгелме соң? Арсланнар ысулы Русиядә халык санын алуда оста файдаланыла ич. Әнә Русия дәүләте дигән арыслан бер көтү булып яшәп үз-үзләрен саклап кала алган халыкларны аерып, тамак ялгарга җыена лабаса. Без татар көтүендә йөрергә теләмибез, без аерым көтү дип, читкәрәк китәргә җыенучы агай-энеләрне “арслан” күзәтте-күзәтте дә ауга чыкты. Күрде арслан – аерылган көтү зур түгел икән ич, кабып йоту өчен күп вакыт кирәкми икән. Ау башланды” (т. 9, 390 б.).

Тормышта игътибарлы, күзәтүчән шәхес буларак, әдипнең чагыштырулары үзенчәлекле, бүтәннәрдән нык аерылган, нечкә тоемлаулы чагыштырулары сурәт ясап тәэсир итүнең иң тәэсирле чараларыдыр дим: “Нәрсә ул *мәхәббәт? Ипи кыерчыгы өстенә яккан бал гына ич ул*. Балын ялап бетерәсең дә ипие генә кала, гомер буе шул ипи кыерчыгын кимерәсең аннары” (т. 9, 36 б.); “Сере бик гади, *алабута орлыгыннан да арзанрак*” (т. 9, 44 б.); *“Көнләшә белмәгән кеше утын агачыдыр”* (т. 9, 56 б.); “Кайтып керде берзаман каенага. *Тегермән хәтле үк булмаса да кибән хәтле булыр*” (т. 9, 125 б.); “*Печәнне ул (әнисе) оста парикмахерлар сокланырлык итеп чаба иде*, ат җиксә, иң йолкыш ат та тәртә арасында көяз булып күренә иде, утын ярырга тотынса, иң ботаклы түмәр дә *өлгерүе килгән карбыз сыман шартлап ярыла* иде” (т. 7, 17 б.); Шыгырдап торган нарат (т. 7, 40 б.).

Туфанның бу сәләте, әлбәттә инде, әсәрләрендә дә чагылмый калмый.

Гөлҗиһан. Авыл карчыгы. “...Нәрсә булсын аңа. *Убыр ташы кебек тәгәрәп йөри”* (т. 1, 18 б.). Мисалларны барлауны укучы, тамашачыларның үзләренә дә калдырыйк. Файдасы булмый калмас.

Синтаксик фигуралардан **кабатлаулары** да үзенчәлекле: “*...сагыныр каеның, сагыныр ермагың, сагыныр урамың, сагыныр шәһәрең, сагыныр халкың* булмаса, әсәр язма, кулыңа каләм алма” (т. 7, 51 б.); “Тамаклары карлыкկан*чы* яңа җырны җырлыйлар, аяклары талган*чы*, хәлдән тайган*чы* шул җырлар ритмына бииләр” (т. 7, 61 б.); *“...Түзә белгәннәр* батыр була, *түзә белгәннәр* илен сатмый**,** *түзә белгәннәр* үз-үзенә хыянәт итми” (т. 7, 126 б.); ”Көне-төне *эшли дә эшли, эшли дә эшли*” (т. 7, 210).

Һәр әдип-язучыбызның тел тоемлау сыйфат-сәләтен менә шушы схема белән анализлап булыр иде. Тик Туфанның тел тоемы бу система кысаларына гына сыймый. Монда үзенә бер яңа төшенчә, **сөйләм тоемлавы** дигән үзгә бер категория тәкъдим итәргә кирәк таптык. Без аны

Туфан тоемлавын анализлаганда тоеп алдык. Анализ барышында күренде ки, тел тоемлау төшенчәсе ике тармактан тора икән: тел тоемлавы (Туфан билгеләвенчә, сүз тоемлау). Икенче тармак ул – сөйләм тоемлавы. Алар, әлбәттә инде, бер берсеннән аерылгысыз. Шулай да фәнни максатта сөйләм тоемлавын, ягъни аралашу барышында, сөйләм оештырганда сүздән башка белдерелә торган мәгънәви берәмлекләр (беренче чиратта тавыш һәм хәрәкәт чаралары, фәнчә әйткәндә, экстра-, паралингвистик чаралар) әһәмиятле урын тота.

Сөйләм тоемлавы ана телен яхшы белгән, аны актив кулланган һәр кешенең табигатен-холкын-фигылен, яшәү рәвешен чагылдыра. Сүзе нинди – үзе шундый, дигән гыйбарә дә тәкъдим итеп булыр иде. Хәер, шуңа охшаш-мәгънәдәш мәкаль, әйтемнәр дә аз түгел.

Инде мисалга Туфанның үзен алсак, чыннан да, аның публицистикасында, драма әсәрләрендә – кыскасы, аның һәр төр сөйләмендә үзенең кешелек сыйфатлары, шәхси холкы-фигыле сызыклары чагылыш таба. Әйтик, аның җырга мөнәсәбәте. "Миңа җырның көеннән бигрәк сүзләре якын. Гап-гади, көн саен сөйләшеп йөргән бер тәртипкә тезеләләр дә җылыта һәм юата торган җыр барлыкка килә:

Сандугачлар гына күрде
Төшеп су алганымны.
Күрми дә калырсыз әле
Төшеп югалганымны (т. 7, 56 б.).

Кайвакыт ул тәкъдим иткән бер сүз аның бөтен бер сыйфат-ягын ачып бирә. Мәсәлән, аның "кызык" сүзенә салган мәгънәсе гаҗәп "кызык" тоелды. Сүзгә Туфанча яңа мәгънә салынган. "Дөньядагы бөтен кызыгым минем – иҗат. Бүтән кызыгым юк, дисәм дә, ялгыш булмас" (т. 7, 72 б.). Яисә аның сүзне уйлап, аны әйтү арасындагы хәләте игътибарга лаек бит. "Бүтән чакларда мин, мактанып әйтсәм, сүзгә кесәгә кереп тормыйм. Бу юлы, сизәм, югалып калдым. Хәер, мәгънәсезлеккә (мәгънәсезлек кенәме!) сүз белән каршы тору бик читен шул: бер сәбәпсез синең йөзеңә төкергән кешегә кешелеклелек, әдәп, культура турында никадәр генә сөйләмә, ул ырҗаеп кына көлә дә, төкеренүен дәвам итә. Андый чакта иң яхшысы, узынучының кулыннан тотып алып, авызына сугу кирәктер" (т. 7, 133 б.). Хәтерләп калыйк әле: бу фразада сүз бирә торган мәгънә төшенчәләреннән башка тавыш, хәрәкәт белән белдерелә торган *ырҗаю, йөзеңә төкерү, кулыннан тоту, авызына сугу* һ.б., ягъни **пара-, экстралингвистик чаралар** да бар. Болар инде нәкъ менә сөйләм белән бәйле чаралар.

Алары да һәр иҗатчының, һәркемнең үзенә хас чаралар. Туфанныкына аерым тукталып алырбыз.

Тагын бер күзәтү. Ихласлык табигате һәр кешедә бар. Тик менә һәркем аны тулы белдерә алмый. Тел байлыгың мул булган очракта да, сөйләм тоемлавың җитмәсә, ихласлыгыңны ачып сала алмыйсың. Туфаннан өйрәнергә була! “Мин эш сөймәс ялкауларны яратмыйм. Кызганмыйм да. Эшләми икән, ач йөрсен. Әмма эшләгән кешеләребез бит... Коммунизмга ышанмасалар да, өмет белән яшәгән кешеләребез... Илне яклап сугышкан инвалидлар бер кило май алырга интегәләр. Моны гамьсез карашлы тук караклар ачыктан-ачык урлашып бер бәйләм редисканы 3 сумга алалар. Шушындый власть буламы?

Артыгын язасым да килми. Яшисе дә килми. Башны юләргә салып күпме йөрергә мөмкин?” (т. 7, 358 б.).

Туфан ихласлыгында кызып китү бар. Шәхси фикерен “без” дип белдерә. Дәлилли, янәсе, бәхәсләшергә юл куймый: “Әйе-е. Шул партиягә табынып, шул партиянең тәгълиматына ышанып яшәдек бит. Хәзер барысы да көлке генә. Идеалларның чәлпәрәмә килүе көлке нәрсә түгел бит югыйсә. Ул – фаҗига. Ә без көләбез. Димәк, идеаллар булмаган, димәк, без ул идеалларга элек тә ышанмаганбыз. Ышанган булып кыланганбыз, әмма ышанмаганбыз. Димәк, партиягә кергәндә үк, без, идеалларга ышанып түгел, ниндидер башка максатны күздә тотып кергәнбез...” (т. 7, 362 б.). Моны тыңлап, “алай гомумиләштермә, давай, үзең турында гына сөйлә!” диючеләр дә булмый калмагандыр. Хәер, аның менә бу гыйбарәсе дә күңелгә килешеп калган: “...Дөньяны коммунизм байрагы астында матурлау, камил итү мөмкин икәнлегенә ышана идем” (т. 7, 365 б.).

Көлү, елау кебек күренешләрне бәян итү, тасвирлау Туфаннан тел осталыгын да, сөйләм осталыгын да үреп баруны таләп итә. Монда, башлыча, паралингвистик чаралар (тавыш, хәрәкәт һ.б.) сорала. Туфан бу катлаулы паралингвистик күренешне дә тормышчан чагылдыру остасы. Монда да аңа сәхнә кешесе булуы, сәхнәне яхшы үзләштергән булуы ярдәм иткән. Менә “Туфан көлүе-юморы-сатирасы” бар дигәнне аңлатучы, аның кайбер якларын ачып бирүче берничә генә факт: “...Үзәк өзгеч хәлләр, прәме. Трибунага менеп: “Алай ярамый бит инде, җәмәгать, тимәгез инде рус иптәшләргә, бик әйбәтләр бит алар”, – дип ялынып-ялварып сөйлисе килеп китте. Болай да бит инде ничә гасыр буе рәнҗетелгән халык, нигә аларга тияргә?” (т. 7, 360 б.). “...Әгәр минем әниемнең телен бәләкәй тел, рус әнисенең телен бөек тел дип сөйлиләр икән, минем күңелемә бик

рәхәт була, дип уйлыйлар микән. Юк инде, агай-эне, алай булмый ул. Андый чакта мин “гафу итегез” дип төзәтергә мәҗбүрмен. Әгәр алай әйтергә куркам икән, мине үзләрен яратырга мәҗбүр итүчеләргә дәшмичә генә астан карап йөриячәкмен. Насильно мил не будешь, дигәннәр русның акыллы кешеләре. Ул сүзне башкаларга карата гына түгел, үзеңә карата да әйтергә кирәк” (т. 7, 361 б.).

Көләмәслек, көлү, елмаю, көлдерү галәмәте кешедә була икән, ул, беренче чиратта, аның чыраенда, хәрәкәтендә, яисә тавышында бәреп чыга. Бу яктан артистларга җиңел. Ә язучыга? Сүз белән эш итүчегә табигать биргән, нәселдән килгән шул кыйммәтле сыйфатын ничек җиткерергә? Әлбәттә, махсус эзләнеп, уйлап чыгару сәләтеңне эшкә җигеп. Туфанның да андый табышлары аз түгел: ”Беркөн Татарстаннан сайланган РСФСР халык депутатларының киңәшмәсендә булдым. Ельцов дигән бер рус агай-энесе “Никаких государственности татарскому языку, никакой союзной республики!” дип кычкыра. Мин ул питекантропны яратырга тиешме? “ (т. 7, 361 б.). “*Питекантроп!*” Елмайта бит, көлдерә бит!

«Мин яздым да, дәфтәремне ябып куйдым һәм рәтлерәк нәрсәләр язу турында уйлана башладым. Ә теге мескен хөсет нишли икән? Кем икәнлегемне сизмәсәләр ярар иде, дип, дер калтырыйдыр инде “бәгырькәем”» (т. 9, 59 б.). *“Бәгырькәем”* – монда көлдерү чарасы. Тик гадәти сөйләмдә ул җитди мәгънәле берәмлекләр рәтендә. Ә монда Туфанның көлдерү чарасы – *куштырнак*. Ягьни бу очракта Туфан бу сүзне үзгә бер тавыш белән – *көлдерү интонациясе* белән әйтүне күздә тоткан, пара-, экстралингвистик чара кулланган.

Сибгат Хәким аңарга бер вакыт язучылар алдында “уйнаганда”: “Туфан бер байның шук приказчигы булыр иде”, – дигән. Туфанның хәтере калган. “Мин приказчик булсам, Сез, Сибгат абый, мин сату иткән кибеткә бурычка бер әчмуха чәй сорап килүче булыр идегез, – дип әйтмәкче идем, тыелып калдым. Хәтерен калдырырмын, дип курыктым” (т. 7, 44–45 б.). Монысы инде Туфанның сатира – астыртын көлү сыйфатына да һәвәс, аңарда шул хисне язуда белдерү сәләте дә барлыгын раслаучы факт. Аларны да аның публицистикасыннан байтак китерергә була.

Туфанның сөйләм тоемлавын, аның тел белән бәйле экстра-, паралингвистик чараларын махсус өйрәнү сорала. Әлегә күзәтү, уйлану максатында берничә мисал белән генә чикләнәбез: “Җитәкче иптәшләрнең 99 проценты үзеннән түбәнрәк дәрәҗәдәгеләргә син дип

бармак төртеп сөйләшә” (т. 7, 143 б.); “Бәлки иркенләп талашырлар” (т. 7, 143 б.) һ.б.

Сөйләм тоемлавының үзенчәлекләре арасында **әйтү белән язу аермасы** проблемасы да бар. Туфан аны әйткәнчә язу кыйбласын тотып хәл итү ягында. Дөресе дә шулай бит. Татар язуы фонетик принципка нигезләнә, моңа ул татар теленең сингармонизм, басым законнарына таянып ирешә.

“Ник шунда чукынып китмиләр, *диң* дә, үзеңчә җайлап кына яши бир” (т. 9, 54 б.). “Көлсәң көл, *җ*ыласаң *җ*ыла (т. 9, 207 б.).

Публицистик текстларда бу берникадәр сәер – нормадан тайпылу дип кабул ителсә, драма әсәрләрендә (сәхнә сөйләмендә), шулай булырга тиеш, дип кабул ителә. Дөресе шулай да.

Исмәгыйль: Күрше авыл егете. Җор телле. Җырлый: “Түшләреңне бик киермә; *Җиңәлмәссең* кычкырып” (т. 1, 186 б.).

Илгизәр. Врач чакырталар. Врач, авыру *табалмагач*, зыяны тимәс әле, дип бирәр укол кадый да китә (Яшьлегем-юләрлегем // Казан утлары. 1979. № 6. 50 б.).

Сүккәндә, тәнкыйть иткәндә, тискәре мәгънәдә *нәчәлство*, ә җитди, термин мәгънәсендә *начальство* (т. 9, 186 б.).

Илгизәр. Гөлнара, мин яңагыма сукканнарны гафу *итә алам* (Яшьлегем-юләрлегем. 49 б.)

Аның драма әсәрләре бу төр сөйләмне өйрәнер өчен чын-чыннан чиксез дәрья – бетмәс хәзинә.

Әлбәттә, сәхнә сөйләмендә автор сөйләме белән бергә персонаж сөйләме дә алыштыргысыз урын тота, анда тавыш-җыр-музыка да, декорация һәм башкалар да сөйләм чарасы ролен башкара. Туфан әсәрләрен татарның иң оста, тәҗрибәле артистлары уйный, һәркайсы – үз сөйләм тәҗрибәсен булдырган оста. Шул ук вакытта төп сөйләм үрнәген автор сөйләме бирә. Ул бит персонаж сөйләменең үзәген-умырткасын булдырып кына калмый, шушы әсәргә кагылган барлык мәгънәви һәм хисси төсмерләрнең тел нигезен дә барлыкка китерә, оеткысын сала. Менә ремаркадан мисал: “Мансур белән Гөлфирә Әлмәндәр тавышын ишетеп *сызалар*“ (т. 2, 46 б.).

Драматург Туфанның сөйләмен анализлаганда аның җөмлә төзелешенә, җөмләнең эчке һәм тышкы компонентларына, синтаксисның җөмләдән эрерәк кисәкләренә (микротекст, макротекст, текст, парцелляция, инверсия кебек структур өлешләренә) бик игътибарлы булуына диккать итми калмыйсың. Бу – осталык мәсьәләсенең үзенә бер кыйбласы. Хәзергә бер генә мисал белән чикләнеп,

бүлекчәне тәмамлыйк: Малай. Җор телле. “Әминә апа укыган башы белән әнисенә дәшми. Зоотехник имеш! *Бик инде*” (т. 1, 140 б.). “Хуш. Мин *очтым”* (т. 1, 157 б.).

Туфанның тел тоемлавы турындагы бу фәнни күзәтүләрне без “Осталык дәресләре” дигән рубрика астында да тәкъдим итәбез. Ягъни әдипнең телебезне куллану, сөйләм оештыру, телгә, сөйләмгә карашының үрнәк булырлык, кулланырга, бигрәк тә яшь иҗатчыларга үрнәк алыр өчен дип тәкъдим итәбез. Шул ук вакытта бер дә кимчелекләре юкмыни соң; хәтта гади укучы да, тамашачы да, менә үзеңнең дә язучы өчен борчылып, ризасызлык белдереп куйган мизгелләрең булды бит, “җитешсез яклары” дип тамгаланган мисалларың да байтак җыелды бит, дип, чырай сытып кую ихтималын да кире какмыйбыз; бәхәсләшмибез дә. Аңлыйм: идеаль, бар җире түгәрәк язучы була алмый. Дөресен әйткәндә, чагыштырып бәяләр өчен нәрсә камил, нәрсә хатасыз, дигән әдәби нормалары, орфография, орфопия кагыйдәләре дә юк бит аның, кем ничек фаразлый, кайсы мәктәптә ничек укыталар, шулай бәяләнә. Әйтик, үзем Туфан иҗатында нинди тел, сөйләм хилафлыклары күргәнмен соң? Алар хакында беренче генә әйтүем түгел, беренче мәкаләмдә мисаллар китергән идем; ул язмамны Туфан үзе дә укыган иде. Шылтыратып, фикерен әйткәндә ул хакта искәрмәде, димәк, нигездә килешкән. Чыннан да, кимчелек дип санаган очракларымны үзем, мәсәлән, киләчәктә истә тотачакмын; бүтәннәргә дә, аеруча яшьләргә дә кабатламаска киңәш итәм, бүген шул ният тән язам икән, димәк ки, аларга юл куярга ярамый, дигән изге теләктән эшлим. Башкалар, Туфан әйтмешли, үзләре карасын инде.

Бүгенке татар сөйләменең “яман шеше”, аның җелеген корыта торган “колорадо” корты – ул тарихи хастабыз – **калька**. Табигый ки, Туфан да аннан азат түгел. Менә татар сөйләмендә иң таралган калькалар Туфан әсәрләренә дә кереп оялаган: “Расценкалар идеаль шартлардан *чыгып* ясалган” (т. 7, 58 б.); “Китапта Александр Невскийның батырлыклары христиан дине *күзлегеннән чыгып* сурәтләнгән” (т. 7, 83 б.); “Дөньяга, кешеләргә бары тик законнарда язылган статьялар *күзлегеннән генә карый”* (т. 9, 307 б.).

-Лар/-ләр чире аны да аямаган: “Авыл картлары сарык абзары ремонтлый*лар”* (т. 7, 77 б.); “Күрәсең, безнең бабайлар бу уенны уйнаган*нар*” (т. 7, 143 б.); “Бер төркем язучы*лар* бер иптәшнең яңа фатирын котларга барган идек” (т. 7, 143 б.). Туфан да сайлау*лар* дип язды, шулай дип сөйләде. Сүз бер сайлау мәгънәсендә булса да (т. 9, 18 б.). Шул ук вакытта тел тоемы да “уянып” куя иде: “Тагын сайлаулар килеп

җитте. Үткән *сайлаудан* соңгы биш ел депутатлык гомере үтте дә ките" (т. 9, 99 б.); Тишек-тошык*лар*, ди (т. 7, 175 б.). Парлы сүзләргә татар бер кайчан да күплек кушымчасы ялгамады. Бүгенге радио, телевидение генә ул явым-төшем*нәр* дип наданлыгын күрсәтеп, сөйләмен пычрата.

Яңа калькаларга да Туфан, сизгерелеген югалтып, әсәрләрендә урын биргәли: "*Ярым надан* буын тәрбияләгәнбез" (т. 7, 349 б.). Язучыларыбызның барысы да *ярым караңгы* дигәндә, чын *татар караңгылы-яктылы* дия дә бит.

Тешкә тия-тия *аралык* сүзе бүтән мәгънәсендә сөйләмгә кереп бара. Барлык татар авылларындагы кебек Туфан авылында да ул мич белән стена арасыдыр, гадәттә анда кышын яшь бозау, бәрәннәрне салкыннан саклыйлар иде. Бүген мәгълүмат чаралары теләсә нинди араны аралык дия башлады. Туфан да сизгерлеген югалткалады, әллә "заманча" редакторлар "кысылдымы"? "Сталин һәм ул хакимлек иткән вакыт *аралыгы* инәсеннән җебенә хәтле тикшерелгәч..." (т. 7, 375 б.). Кайдан алган ул бу сүзне?..

Сүз сайлаудагы, җөмлә төзелешендәге мондый кытыршылыклар, кызганыч ки, очрап тора: *Мин бер сүз дә дәшмәдем* (т. 7, 34 б.); Үзең дә сизмәгәндә, сине узып китүе *мөмкин* (т. 9, 52 б.). (*Ихтимал*дыр? – *Н.И.*) "Үзе ул *безнең яшьләрдә* һәм ниндидер заводта эшли иде" (т. 9, 118 б.). Текст агышында эчтәлек буенча *безнең яшьләрдә* дигән сүзтезмә у нашей молодежи дип аңлашыла иде (омоним барлыкка килгән); "Җан белән җан сөйләшеп аңлашканда кайбер *хәрефләрнең* икенче төрлерәк әйтелеше бигрәк вак мәсьәлә булып кала" (т. 9, 442 б.). *Авазлар*ныңдыр?

Әйтү белән язу арасындагы каршылык, хилафлыклар да уйландыра. Дөресен әйткәндә, Туфанга без бу мәсьәләне хәл итүдә белгеч буларак таяна, өметләнә идек. Ул бит фикерне әйтеп белдерә торган әдәбият белгече. Әйткәнен язуда иң дөрес чагылдыру – аның һөнәри белгечлеге билгесе. Бу кыйблада ул, чыннан да, иҗат итә алды, әйткәнчә язу өчен татар теленең басым, сингармонизм законнарын гамәлдә куллану үрнәкләрен күрсәтә алды.

Шул ук вакытта һәр очракта үзе дә законнарны бозарга мәҗбүр булды, сөрсеп беткән кагыйдәләргә азагынача каршы тора алмады. *Киоск, бомж, факт* дип яза (т. 9, 101 б.); Гыйбрәт алырлыклары да *әз* түгел (т. 9, 111 б.). Бу очракта *аз* сорала бит.

Шул ук вакытта: "*Маташтырмагыз* Алимовлар! *Мәтәштермәгез,* Юсиннар!" (т. 9, 115 б.). Ә нигә Юсин*нар*? (*Мәтәштермәгез* нечкә булгач, Юсин*нәр* таләп ителә, ләбаса. *Йусыйн* булса инде, икенче мәсьәлә).

Боларга тукталып та тормас идек, искәртү зарур. Беренчедән, болар типик кимчелекләр, башка язучыларга да хас, димәк, киләчәктә булдырмас өчен аларны һәрдаим кисәтә килергә кирәк. Икенчедән, монысы аеруча мөһим, шул төр кимчелекләр Туфан драмаларының персонажлары сөйләмендә дә очрый. Димәк, әсәр аша, аннан да бигрәк сәхнә аша ул кимчелекләр тыңлаучы, тамашачыга да барып җитә, тискәре тәэсир ясый. Менә кайберләре. **Калькалар***:*

Хәмит. Нәчәльство. Авылдан чыккан. Белемле. "Әти *капризыннан чыгып* баш тартыргамы?" (т. 1, 29 б.).

Хәлим. Авылдан чыккан. Шәһәрдә яши. "Абый *тәнкыйтьтән югары*" (т. 1, 43 б.).

Галим. Авыл укытучысы. Мәкальләр җыя. Китапча сөйләшә. Сөйләмендә атлаган саен "һәм". "Бу өченчесе *һәм* соңгысы; ...Бу табигый. ...*һәм* күздә тоткан кешегез дә юк; ...*һәм*, ниһаять, халык мәкальләрен ярдәмгә чакыра алабыз (т. 1, 70 б.); Бу икенче мәсьәлә *һәм* четерекле; *Һәм* ни өчен? Әйе, минем эш *һәм* сезнең эш (т. 1, 82 б.);

Фәния. Әйе, яратам, *һәм* бик күптәннән; Менә ул кайтты, *һәм* мин сезнең таныш икәнегезне ишеттем, очрашканыгызны күреп тордым (т. 1, 124 б.);

Фәнил. Урысча уйлап, татарча сөйләргә азапланучы. Шәһәрдә төпләнгән: "*Һәм* ул уегыздан кире кайтачаксыз, әлбәттә? (т. 1, 167 б.). Шуннан соң, Марат: Гафу итегез, кысылмыйча түзә алмыйм. Җизни нигә татарча сөйләп интегәсез. Татарча белмисез, сөйләгез русча. Монда бит бөтенесе дә русча әйбәт белә (т. 1, 167 б.);

Фәнил. *Һәм* югалуы да ихтимал (т. 1, 169 б.).

Бу пьесада хәтта татарча бик яхшы белүче уңай персонажлар сөйләмендә дә (Шамбасов, Хәсәнәт, хәтта татарча яхшы беләм дип мактанган Марат сөйләменә дә) әйтмә сөйләмдә бөтенләй кулланылмаска тиешле (аны пауза алыштыра) *һәм* кергәли;

Марат. *Һәм*, гомумән, минем белән авыз чайкама (т. 1, 175 б.);

Әлмәндәр: Чардуган корыр *өчен* (корырга) такта кирәкме? (т. 2, 18 б.).

Илгизәр. Авыл тракторчысы: Абый җиңгинең уйнаганын сизми, пошаманга төшә, гафу үтенә. *Һәм* җиңги, ходайның хикмәте, шунда ук терелә (т. 1, 305 б.).

Хәер, кешенекен күрү җиңел ул, аңа күп акыл кирәкми, ә менә үзең язып, үзең әйтеп кара!

ЙОМГАК УРЫНЫНА

Татар нәфис сүз сәнгатенең һәм аны өйрәнүче фәннең ике мең елдан күбрәк тарихы бар. Татар үзаңына, теленә таянып, үзҗирлегендә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш риторикаларының да тәэсирендә барлыкка килеп, гасырлар буе үсеш алган татар риторикасы да гомуммәдәнияткә, сәнгатьнең башка төрләренә – шигърияткә, рәсем, сынлы, музыка сәнгатьләренә бөреләнеп, үсеп китәргә нигез, этәргеч булган.

Татар халкы элек-электән холкы-табигате белән дә, иҗтимагый яшәеш шартлары кушканга да, үзара һәм башка милләт халыклары белән аралашучан. Тормышта фикерен, ихтыярын ышандырырлык итеп, үтемле, тәэсирле итеп белдерү, җиткерү өчен ул акыл һәм хис егәрлеген оста җигә белгән, ана теленең нечкә мөмкинлекләреннән, тавыш, моң-көй, ым, ишарә кебек чаралардан да һәрдаим файдаланган, шул тәэсир хәзинәсен, аны оста куллану тәҗрибәсен бөртекләп туплап, гасырлар буе чарлап, буыннан-буынга мирас итеп тапшыра килгән.

Кызганыч ки, яңа буыннарга ул хәзинәне файдаланырга, эзлекле тапкырларга насыйп кына булмый – иҗтимагый, милли изелү шартларында ана телебезнең кулланылуы бетү хәленә җиткәндә, тулаем мәдәниятнең, аерым алганда, милли сәнгатьләребезнең күпчелеге аяк сузам дип торганда, шул сәнгатьләрнең чишмә башы, үзәге булган нәфис сүз сәнгате генә (риторика дип тә атыйк) исән-бөтен сакланып кала алыр идемени!

Шулай да халыкның милли рухы, теле, көй-моңы, гореф-йолалары, дине нәфис сүз хәзинәсен азмы-күпме саклап кала алган, хәлдән килгәнчә хәрәкәтләндерергә, яшәтергә көч тапкан. Моның өчен халык авыз иҗатына, әдәбиятебезгә, театрларыбызга, матбугатыбызга рәхмәт әйтик.

Дөрес, бу кыйблада XXI гасыр башында бераз җанланып алу сизелсә дә, соңгы чорларда янә бер урында таптану гына, татар нәфис сүз сәнгатенең чын мәгънәсендә милли чәчәк ату чоры, күрәсең, әле алда.

Моның өчен милләт җанлы һәр татарның үз теле белән горурлануы, аны яшәтер өчен, киләчәк буыннарга исән-имин тапшыруы өчен, һәркайсыбызның тырышлык салуы сорала. Монда чын мәгънәсендә осталык мәктәбе үтү зарурдыр. Шөкер, сабак алыр өчен, көндәлек күнегүләр алу өчен, халык авыз иҗатында да, әдәбият, театр, фән мирасыбызда да байлыгыбыз җитәрлек. Күрдегез ки, шушы җыентыкта гына да ике дистә тирәсе чын мәгънәсендә чыганак бәян

ителде. Бүгенге язучыларыбыз, журналистларыбыз, артистларыбыз иҗаты да шушы юнәлештә өйрәнелүдән туктамаган. Шәхсән үземнең иҗади эш планымда да күренекле публицистларыбыз Рафаэль Мостафин, Радик Фәизев, күренекле шагыйрәбез Лена Шагыйрҗан иҗатының нәфис сүз осталыгын тәфсилле өйрәнү күздә тотыла. Ә бит бездә бүтән әдипләрнең, иҗатчыларның нәфис сүз осталыгы мирасы барланган чыганаклар аз түгел. Алар бүген дә фәндә өйрәнелә, өстәлә, туплана тора, халыкка җиткерелә тора. Иренмәскә, өйрәнергә генә кирәк. Иншаллаһ, тел чишмәләребез киләчәктә дә челтерәп торыр, томаланмас, тоныкмас, балаларыбыз, оныкларыбыз да аларны дәвам иттерер, дигән өметтән өзелмик.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ 4
БУБЫЙЛАР САЛГАН НИГЕЗДӘ 10
ТАТАР РИТОРИКАСЫ ҺӘМ АКМУЛЛА 17
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ СУРӘТ КОЛАЧЫ 34
ИЛ ҺӘМ ТЕЛ (Сибгат Хәким шигърияте хәятендә) 47
СҮЗ ТЫЛСЫМЫН ТОЕП (Афзал Шамов иҗатында тасвирлау чаралары) 68
ШАГЫЙРЬ ҖАНЫН НИ ТИБРӘТӘ? *(*Чикләр чикли алмаган иҗатчы*)* 79
ТАЛАНТНЫҢ НИГЕЗЕ – СУРӘТЛЕ СҮЗ УЛ (Ибраһим Сәләхев истәлеге) 105
ШАГЫЙРЬНЕҢ ҖАН СУЛЫШЫ 113
УЕЛЫП КАЛДЫ УЙЛАРЫ (Хәсән Сарьян киңәшләре) 134
ҮЗЕБЕЗ ТАБЫП АЧКАН СЕРЛӘР (Чаллы төбәге иҗатчылары тәҗрибәсенә бер күзәтү) 160
ЯШИ: ЭЗЛӘРЕ, СҮЗЛӘРЕ (Хәкимҗан Халиков шигърияте турында) 200
СЕБЕР ДӘ ҮЗЕБЕЗНЕКЕ (Булат Сөләйманов шигърияте) 205
ОСТАЛЫКНЫ ТОЕМЛАУ (Туфан Миңнуллинның тел куллану тәҗрибәсеннән) 211
ЙОМГАК УРЫНЫНА 276

Низамов Ильдар Маликович

ИСКУССТВО СЛОВА
учебное пособие по риторике

Корректура и верстка
Л.Ш. Давлетшиной

Дизайн обложки
Н.С. Загайновой

Подписано в печать 13.11.2013 г.
Бумага офсетная. Печать ризографическая
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times». Усл. печ. л. 16,28
Уч.-изд. л. 15,34. Тираж 250 экз. Заказ 73/5

Казанский университет

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 233-73-59, 292-65-60